Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Галиәсгар Камал

# Әсәрләр
Өч томда

3 том

Хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр

Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма

Казан
Татарстан китап
нәшрияты
2010

Редколлегия:
З.Р.Вәлиева, К.М.Миңнуллин, Д.С.Шакиров,А.Г.Әхмәдуллин (баш мөхәррир), З.З.Рәмиев
Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр:
Зөфәр Рәмиев, Назыйм Ханзафаров, Фатыйма Ибраһимова, Әнисә Алиева, Мәгъсум Хәбибуллин

Әсәрләр : 3 томда / Галиәсгар Камал. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.
ISBN 978-5-298-01900-2
3 т. : хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр / текст., иск. һәм аңл. әзерл. З.Рәмиев, Н.Ханзафаров, Ф.Ибраһимова, Ә.Алиева, М.Хәбибуллин. – Төз. һәм тулыл. 2 нче басма. – 2010.
ISBN 978-5-298-01903-3
Татар халкының классик язучысы, журналист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм җәмәгать эшлеклесе Галиәсгар Камал әсәрләренең әлеге томында әдипнең «Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт», «Күгәргән алтыннар» хикәяләре, мәкаләләре, рецензияләре, истәлекләре туплап бирелде.
© Татарстан китап нәшрияты, 2010

## Хикәяләр

### Сабир хәзрәт, яки гыйбрәт

I

Казанга якын бер бай карьянең имамы Сабир хәзрәт яки Сабир хаҗи дәю мәшһүрдер. Бу хәзрәт ир урталарында, зурга кариб урта буйлы, кызгылт чырайлы, сакалына чал керә башлаган, илле яшьләр чамасындадыр. Борыны зур вә калку, күзләре һәм зур вә өстә. Буены да озынрак, беләкләре юан, бармаклары ире, иркәк йөзле, киң иңсәле сәламәт адәмдер. Йөзе күренекле һәм ачык вә бәшашәтледер. Киеме тәкәллефсез, ләкин тәмиз улып, урта бәһале заттан җилән вә гяһа әгъля бәнарис1 чапан вә көзнең башыннан ук тамак тун2 киеп, галибән чуар чалмадан йөрүчедер.

Бу хәзрәт – нәсәп иясе, өч-дүрт бабадан бирле мәншүрле имамнар сөяләсеннән улып, яхшы ук галим вә мөдәррис кешеләрне, аталары гавамнан (мужиктан) улдыгы өчен, «маштан катык»[3] дәю истиһза иткүчедер. Сабир хәзрәтнең әукаты яхшы, мәшәкатьсез вә хафасыз гомер кичермәктәдер. Сабир хәзрәт бер кәррә үзе өчен хаж[4] итмештер, соңра, юл хәрежлеге күбрәк бирелсә, бер-ике елда бер бәдәл хаҗны һәм кабул итәр иде.
Сабир хаҗи, бәдәл белән Хиҗазга[5] барса, хаҗга васыять иткән мәрхүмнең җанына шәфкать, варисларына мәрхәмәт өчен генә барам, дәю сөйләнер иде. Бу хәзрәт мәктәп вә мәдрәсә илә иштигальне файдасыз, биһүдә вә мәшәкатьле санап, һичбер вакыт аның мәхәлләсендә мәктәп булганы юк иде. «Әнә мөәзин Сафаның олугъ хатыны үзенең ашханәсендә балалар укытадыр. Гавам баласы, кирәк, иркәк, кирәк, кыз бала булсын, шунда барып, «Кәлимәтен тайибәтен»[6], бераз намаз тирәсе үгрәнсә, шул җитә, анлар мулла булачак түгел», – дәю, мөнәсәбәт чыкканда, мәхәлләнең кешеләрен җуатадыр (йобата) иде.
Сабир хәзрәт тереклеккә пәк оста, йорты төзек. Кара-каршы ике агач өйнең берендә Сабир хәзрәт белән бер абыстай ятканда, каршы ханәдә ике абыстай ятарлар иде.
Бу хәзрәт, гайрәт иясе булып, остазбикәләрне забыт вә идарә итә белмәке белән мәшһүр иде.
Хәзрәтнең ахурда (кәнүшнидә) бер пар яхшы атлары вә ашханәсендә хатынлы хезмәткәре бар иде. Аның ханәләре азбар (йорт) уртасында, бакча эчендә; ишегалдысы хәтфә түшәгән кеби яшел үлән (үләм) берлә өртелмеш иде. Мәгәр кара якта ирләреннән зарланып килгән җиңгәй вә киленнәр эзе белән сукмак пәк тапталган вә карайган иде. Сабир хәзрәттә бәгъзе вакыт асрау кызлар юргаласа да, абыстайлар аны тиз качыралар иде.
Бер кәррә зыяфәттә Сабир мулла карьясенең икенче мәхәллә мулласы, ләтыйфә йөзеннән (уйнап-көлеп):
– Безгә бер асрау кыз кергән иде, бән, түзә алмый, бер-ике көннән кызга кул салмакчы булдым.
Ләкин кыз:
– Ай-һай, син, мулла абзый! Бигрәк ашыгасың икән! Мин Сабир хәзрәттә тордым, ул ун көнсез бәңа кул тикермәгән иде, дип әйтәдер, – диде.
Сабир мулла, авылдаш мулласының бу сүзенә ни әйтәчәкне шашырып, бер җавап бирмәй, фәкать кызарып калды.
Сабир хаҗи бервакытта дүртенче хатынга бер гами кызын алмыш иде. Кызның агасы, кардәшенең хәлен белмәгә кәлдекендә, кияү хәзрәтнең чәй эчкән җиренә очрап, чәйгә утырды. Сөйләшә торгач, мулланың каенагасы: «Безнең кардәшемез сәламәттер, шаять», – дидектә, Сабир мулла: «Ун көннән бирле күргәнем юк, шунда ашханәдә бозаулар имезеп йөри бугай», – диде.
Сабир телгә чапак, пәк җавапчан, мәгәр күбрәк фахиш сүзләр иде.
Бәдәл хаҗы Сабир муллага бирелгән бай угыллары вә анларның тол калмыш әһлияләре, үзен хөрмәт итеп, зәкят[7] вә гошер[8], вә һәдияләр бирерләр иде. Туксан биш сәнәдә «Туй итмәс» карьясенең бае Хикмәтулла, атасы Гыйззәтулла мәрхүмнең бәдәле өчен мең сум юл хәрежлеге биреп, Сабир мулланы Хиҗазга озатты, вә, бу бәдәл Сабир хаҗиның башка бәдәлләреннән артыграк вә җибәргән бае да Хикмәтулла бине Гыйззәтулла могтәбәр вә шөһрәтле булдыгыннан, хаҗи хәзрәте: «Әгәр дә бу сәфәремнән сәламәт йөреп кайтсам, шул Хикмәтулланың кардәше Бибимәрзияне соратып карармын, шаять, бирсә кирәк. Бәндә мәхәббәтләре бар, бәне сәвәләр. Әгәр дә бәңа мәхәббәтләре булмаса, бунча гозер итеп вә бу кадәр акча биреп, бәне хаҗга җибәрмәсләр иде. Әлбәттә, бунлар бәнем кыйммәт вә кадеремне тәкъдир итә белерләр», – дип, күңелене тынычландырды. Вә Бөре суы буендагы карьяләрнең береннән бер итекче мөселманны үзенә юлдаш итеп, Хиҗаз сәфәренә рәван улды. Бибимәрзия дәрте берлә нәшьәләнеп, сәфәр мәшәкатеме тоймас иде. Буннан әүвәлге сәфәрләрендә Сабир хаҗи һәнүз телендә фахиш сүзләр йөрткүче иде. Әмма бу сәфәрендә көенечле вә фикерле бер хәлдә йөрде.

Һәрни исә Сабир хаҗи сахибелхаҗның әһелләренә зәмзәм сулары9, тәсбих вә мисвәк, вә хөрмә җимеше, вә төрбәи шәриф10 тупрагы, вә хәтта «муе мөбарәк» дип, бер «кыл» да кәлдерде.
Вә кайтышта хатынларга мәхсус Истанбул затларыннан, җәүһәр вә ефәктән һәдия вә җиһазлар алып, анлары Бибимәрзиягә атап, гыйзьле вә яшерен саклар иде.
Хаҗдан кайтдыкта Сабир хаҗи, тугъры Хикмәтулла бай йортына инеп, берничә көн кунак булды.
Мулла Сабир хаҗи, Хикмәтулланың ханәсеннән зыяфәткә чыктыгында вә кайтдыгында, өй алдындагы ачык ишекләр үтәли күз уйнатып, Бибимәрзияне күзәтмәгә вә, һич булмаса, аның күлмәк итәгене күреп калмага тырышадыр иде. Бибимәрзия сагышы Сабир мулланы күп рәхәтсез итте, хәтта кичәләрдә йокусы тынычсыз вә низамсызга әйләнде. Сабир мулла Хикмәтулла байга серне ачу өчен һичбер ышанычлы кеше тапмай вә бу хосуста һичкемгә әмнияд итмәйдер иде. Чөнки йортындагы хур кызлары кеби өч абыстайның өстенә дүртенчегә яучы булмакның агырлыгыннан һичбер төрле бәһанә берлә бу тәзәүвеҗгә хәйлә вә зарурәт күрсәтмәк мөмкин түгел иде.
Ахыр хаҗиемыз бу мәслихәт хосусында биззат үзе батырлык кыйлмага карар бирде. Беркөн, ишрактан соң иртәге чәйдә, бу илтимасны байга әйтмәк нияте барлыгыннан әллә нигә җаны тыгызланып, вөҗданы тәгъзиб итмәктә иде. Ул көн иртә намазында хәтта күршеләре сизәрлек мозтариб булып ултырды. Намаздан соң байның үзенә мәхсус залында чәйгә ултырдыкта, хаҗиемыз кәмаль мәртәбә ыспайланып, бер-ике кәррә агызыны вә иреннәрене селкетеп, сул кулы берлә бот төбенә таянып вә уң кулына йомарлап тоткан кыйммәтле балкашыгыны кулында бер-ике кәррә уйнатып, бисмиллаһир-рахманир-рахимне кычкырып әйтәрәк, саф балга сузылып, чынаяк астындагы чәйне эчеп җибәрдектә: «Йә инде, мулла Хикмәтулла! Бу хезмәтне икмаль вә әда иттек, иншалла, атаңыз мәрхүмнең хаҗы кабулдыр. Бу хосуста күп кәрамәтләр вә хикмәтләр заһир булды, Гар шәрифтән11 үткәндә вә Гарәфәттә12 төрле серләр ачылды. Хосусән ихрамнан13 чыгасы көндә, уяулы-йокылы чагымда, әгъля вә бәләнд тавыш белән «әгузе билләһи минәшшәйтанир-раҗим, иннә ма ятәкаббәлуллаһу минәлмоттакыйн»* кауле шәрифе колагыма керде. Атаң мәрхүмне бән күрә алмадым; арамыз ерак вә катнашып өлфәтләнүгә сәбәп булмадыгыннан, күрешү насыйп булмагандыр. Ул мәрхүмне сәхи (җумарт) вә мөттәкый, вә голямага мәхәббәтле кеше иде, диләр. Алла Тәгалә аның рухы пакьне шат вә хәррәм әйләсен!
Инде насыйп булса, мулла Хикмәтулла, хезмәтнең тәкабелене Алла Тәгаләдән сорыймыз. Шулай да булса буйлә булдык. Бу исә сезнең берлә безнең арамызда бер карабәт вә якынлык булды инде. Буның ядкяренә (сагынмаклыгына), насыйп булса, безгә шул кардәшең Бибимәрзияне никахландырырсыз бит?» – диеп, Сабир мулла, имтихан йөзеннән, Хикмәтулланың йөзенә бакты.
Ул вакыт Хикмәтулланың йөзендә «Бу ниткән гаҗаиб сүз сөйлисең син, хаҗи?» дигән сүзләр укыладыр иде.
Хаҗи, Хикмәтулланың йөзенә язылмыш ушбу гыйбарәне укыдыкында, сүзене дәвам итеп: «Бу мәслихәт сезгә гаҗәп тоелмас, шаять? Сез дөнья күрмәгән кеше түгел, сезнең гыйлемнән дә өлешеңез бар бит, сез Алуш карьясенең Ярулла хәзрәттә яхшы дәрес укыдыңыз бугай? Сезгә инанамыз, сез Коръәннән һәм мәгънә фәһем итсәңез кирәк: «Әгузе билләһи минәш-шәйтанир-раҗим, фәнкиху матабә ләкем миннисаин мәсьна вә сөляса вә робагъ».
Бу эшне бертөрле дөнья күрмәгән наданнар, хасидләр, бәлки, хәрислыктан (туемсызлыктан) диярләр.
Әмма безнең мәкъсудымыз Ходага мәгълүм. Безнең күңелемездә асла ул ният юк. Әгәр безнең күңелемездә ярамас ният булса иде, раузаи мотаһһәрә14 тотар иде; насыйп булса, мулла Хикмәтулла, бу мәслихәтне кабул итеп, шушы сәфәремдә атаңыз мәрхүмнең хаҗына бер ядкяр булсын өчен безгә шул кардәшең Бибимәрзияне гакды никах итүгә риза булырсыз бит?» – диде вә үзе, поднос өстенәрәк сөрлегеп вә тәрилкәдәге багырсак

данәләрене аралаштырып, берәр данәсене алып капмак булып, вә күзләре берлә җылмаебрак, Хикмәтулланың өстенә тугъры карап торды.
Хаҗи хәзрәте бу сүзләрне сөйләгәндә, Хикмәтулла бай бер агарып, бер күгәреп, ни кыйлачагыны шашырып, тыгызланып вә мозтариб булып ултырды. Хаҗиның бу сүзләренә «ля»дән, «нәгам»нән һичбер җавап әйтмәй, берничә дәкыйка торып, соңра уңга-сулга боргаланып, бераз тәҗаһел вә белемсезлек итәрәк: «Йә, хәзрәт! Кәрәм идеңез әле, чәеңез суынгандыр, әллә яңартып биримме?» – диде. Хаҗи хәзрәт, суынып беткән ярым чынаяк чәйне чынаякның өстеннән генә бер-ике йотымда бетереп, чынаяк чокырыны шалдыратып астына куярак: «Мә, мулла Хикмәтулла, яса әле!» – дәю, сүз вә җөмләне кисмәү өчен (әгәр дә шул арада бераз туктап торылса, янә сүз башлап вә кузгатып җибәрүе көч булачагыннан), мәгънәсез буш сүзләр берлә булса да, хаҗи яргычны туктатмай әйләндерә бирде (ягъни сүзне өзмәде). Вә шул арада: «Йә, мулла Хикмәтулла, ни әйтәсең? Бунда ят кеше юктыр әле. «Әлхәйре ля йэәххәр»*, бер сүз әйтеңез. Бу хосуста һичкемгә мөшавәрә вә киңәш итмәк лязим түгел. Буның кебек эштә вәсвәсә (коткы) була торган. Ашыгу шайтаннан, бәгъзе эшләрдә ашыгу мәкруһ вә мәзмүм булса да, җиткән кызны тапшыруда ашыгу сәвап, бәлки важиб эштер. Насыйп булса, киленбикә берлә генә сөйләшеңез дә, мулла Рәхимҗанны чакырып, эшне тәмам итәек, мулла Хикмәтулла!» – диде.
Хикмәтулла бай, хаҗиның илтимасына шафи җавап бирмәсә дә: «Яхшы, хәзрәт, бераз мөһләт биреңез, ләкин бездә һичбер вакыт андай фикер булганы юктыр. Бу хосуста бездән артык кардәшнең үзендә ихтыяр», – диде. «Синең өч хатының өстенә бармаса яхшы иде», – дигән фикер берлә үзене мөтәсәлли әйләде.
Бибимәрзияне Сабир мулла Хикмәтулланың туган сеңелесе дәю бәллидер иде. Хәлбуки Бибимәрзия Хикмәтулланың халәсе (анасы берлә тугъма кыз кардәше) Гайшәдән туган иде. Гайшә, баласы Мәрзияне дөньяга кәлдергәч, баладан вафат булмыш вә тутасы Гафифә абыстайның һәм шул көннәрдә алты көнлек баласы үлеп, сөт вә икътизаи табигать вә кардәшлек вә инсаният җәһәтләреннән бу ятимне бала иденмәк лязим кәлдекеннән; Мәрзияне үз баласы җиренә тотып, имезеп тәрбия итмеш иде.
Хикмәтулла Мәрзиянең бинте халә идекене beләдер иде, әмма башкалар күбе белмәйләр иде.
Бу Мәрзия тарафындагы осул вә кардәшләре күптән үлеп бетдекләреннән, аның ата вә анасы кемнәр идеке хосуста сөйләшергә урын да юк иде. Саниян, Мәрзия үзе пәк илтифатлы вә назик, вә мөләемә улдыгыннан, шул йортның үз кызы кебек, Гыйззәтулла бай йортына өлфәтләнгән вә җөмләне үзенә ияләштереп сәүдергән иде. Вә мәга һаза Хикмәтулла бай, Сабирның яңлыш занын белепме, белмәйме, Мәрзиянең туган сеңел дәгел идекене әйтмәде. Хаҗи хәзрәте, аулак мәйләр хәзерләтеп, Хикмәтулланы янә берничә кәррә кысып вә тыгызлап караса да, озын фикерле яшь байның агызыннан бер яхшы сүз дә ала алмады.
Хаҗины озатдыкта, Хикмәтулла, рәфыйкасе Хәнифә ханым катына чыгып, зиядә гаҗәпләнмәк берлә: «Ни эшләргә кирәк, әнисе, хаҗи Бибимәрзияне сорый бит?» – диде. Ул вакытта Хәнифә җиңгәйнең күңеленә бер-берсенә хилаф булган ике нәрсә хотур итте. Әүвәле ирләрнең гаддарлыгына вә туемсызлыгына, шулкадәр гүзәл абыстайлар өстенә хаҗиның янә хатын алмак арзусында булуына зиядә ачуланды. Шул ук дәкыйкада хаҗиның куәтенә вә, затән, хатынларга бунча мәхәббәтле вә анлар юлында мөбтәля вә корбан булуына бераз да йомшарып, башыннан җиңелчә бер фикер кичерде.
Шулай да булса Хикмәтулла бай вә Хәнифә җиңгәй һәр икәве бу эшкә асла разый дәгелләр иде. Хаҗиның һәр сәнәдә берничә хатын алыштырганы анларның колагына һәм төшкән иде.
Мәрзиянең анасы Гайшә мәрхүмә берлә Хикмәтулланың апасы Гафифә Вятка корбендә ...ге мәншүрсез имамның кызлары иде. Шул җиргә кыска вакытта мөсафирлык берлә кәлүп ... карьясенең имамы Ышанмасов Гайшәне тәзәүвеҗ итмеш вә ике кич хилвәти сахихәдән соңра үзенең йортына киткәч, Гайшәнең кесәсеннән бер парча мәктүб табылмыш иде. Мәктүб каралдыкта, фәна каләм берлә язылмыш: «Мәнкүхәм мулла

Габделмәлик кызыны, арамызда мәхәббәт юклыгыннан, бер мәртәбә баин берлә ...к* иттем», – дигән сүзләр укылды.
Ике тәүлек кияү куены күрмеш Гайшәнең йөзендә әүвәлге кызлык нисбәте бетеп, бертөрле оятыннан кызарган сыман кызарып, шешемсерәп вә өрелеп киткән кебек күренә башламыш иде. Ул вакыт Гайшә туташ артык киенеп-ясанудан вә урамнан үткүчеләрне тәрәзә үтәли карап калудан тукталды. Хәтта хәер-сәдака килдергән хатыннар янына да бер-ике дәкыйка вакытка гына чыгып, һәмишә үзенең бүлмәсендә көн кичермәктә иде.
Гайшәнең санаулы көннәре үтеп, бер кыз бала дөньяга кәлде. Гайшә шул баладан үлеп, югарыда мәзкүр рәвешчә, кыз бала Мәрзия халәсе Гафифә абыстай тәрбиясендә калды.
Сабир мулла, Мәрзия мәсьәләсене үзе башкара алмагач, серне яучылык берлә мәшһүрә Шәрифә карчыкка чиште. Аңа халык Шәркәй диярләр иде. Шәркәй бер кешенең капкасы төбендә күренсә: «Бу убыр карчыгы кыз сихерләмәгә кәлгәндер», – дәю, күргән егетләр сүгеп калырлар иде.
Шәркәйгә Сабир мулладан хәзер бер савыт зәмзәм, әбнүс тисбә15 (тәсбих), бер мисвәк, хаҗ хөрмәсе вә бераз тупрак һәм унике аршын ситсы һәдия ителде. Шәркәй әбигә бу кадәр һәдия төшкәнен күргәч, абыстайлар: «Бу эш бер хикмәтсез булмас, бунда, әлбәттә, бер сер бардыр», – диештеләр. Ләкин абыстайлар хәзер дә өстләренә көндәш килүеннән анча курыкмыйлар иде. Мулланың кинә өйләнәчәге хакында үзара сөйләшеп көлешәләр иде.
Шәркәй карчык Сабир хаҗи катыннан чыгып килдектә, уртанчы абыстай, аңа каршы торып: «Шәрифә әби, хәерле булсын! Изге юлга!» – дәю әйтеп калды.
Шәркәй йөз төрле мәкер берлә Хикмәтулла бай карьясенә китте. Бу Шәркәй өчен карьядән карьягә йөрмәк бернәрсә түгел иде.
Хикмәтулла бай карьясе берлә Сабир мулла карьясе арасы байтак мәсафә булса да, Шәркәй ике көндә «Туй итмәс» карьясенә барып җитте. Ул карьядә Шәркәй карчык сөлек сатып вә салып һәм өшкереп-төкереп йөрдекендә берничә кәррә булдыкыннан, Хәнифә җиңгәй Шәркәйне пәк таныйдыр иде. Шул сәбәпле Шәркәйне тәрәзәдән күргәч тә: «Алланың каһәре суксын, Шәркәй килә! Мөгаен, шул эшкә килә инде», – диде.
Шәркәй, йөз наз берлә кереп: «Исәнме, җаным, балакаем Бибихәнифә? Сәлимә исәнме? Мәсгуд исәнме?.. Яхшы, яхшы, Алла Тәгалә тәүфикъларын, бәхетләрен бирсен», – дәю, бер җиргә чүгәләп, әлләрен маңгае тугърысына кадәр күтәреп, пышын-пышын белгәннәрен укып, озын бер дога кыйлдыктан соңра, филхаль урыныннан кузгалып: «Кайда соң әле, кызым Бибимәрзия кайда?» – дәю, кызның үз бүлмәсенә узып, кызга бик озын догалар итеп вә зур теләкләр теләп, гизлечә бик күп сүзләр сөйләшеп, ничә сәгать кыз катында утырды.
Озын сүзнең кыскасы, Шәркәй әби ни итсә дә итте, кызны ризаландырып, Хикмәтулла байның вәгъдәсен алып, туйның вакытын тәгаен иттереп китте.
Сабир хаҗига шатлык хәбәр килдектә, Шәрифәне зиядә кадер вә хөрмәт итеп: «Әби! Гомерем булса, сине ташламам, бу хезмәтнең каршулыгыны бу дөньяда җиткермәк безнең хәлемездән килмәй, менә мә, сиңа бу бездән сәдака булсын, син ятимә кешесең, тәрбияң һәркайчан безгә ваҗиб, аз булса да, буны кабул итеп ал әле, әби», – дәю, Сабир мулла Шәркәйгә бер күк кәгазьне сонды.
Шәркәй: «Юк, юк, кирәкмәс, хәзрәт, минем хезмәтем Ходай ризасына булсын, мин сездән һичбер нәрсә тамгы вә өмет итмәймен, тик без ятимне хәер-догаңыздан ташламаңыз, хәзрәт», – дәю, бераз чигенгән булып, ул арада күк кәгазьне (бишлекне) алып, бүлмә буена утырып, акчаны итәгенә куярак, әлләрене кыз катындагысыннан да югарырак күтәреп, гаять озын бер дога кыйлды.
Сабир хәзрәт тә: «Әби, насыйп булып янә бер хаҗга барсам, раузаи мотаһһәрәдә сезнең өчен мәхсус дога кыйлырым. Фәхригаләм саллаллаһе галәйһи вәссәламга16 сездән биззат сәлам сөйләп, кыямәт көнендә шәфәгатьче булмасыны риҗа идәрем», – диде.
Шәркәй әбине хаҗи озатып чыгардыкта, мәзкүрә уртанчы абыстай, кинә үзе өчен һәм, көндәшләре тарафыннан яучы карчыкка каршы чыгып: «Хәерле булсын, Шәрифә әби!

Туйга кайчан барамыз? Өчәү генә безгә күңелсез. Әүемезнең бер почмагы китек кебек иде. Иптәшемезне күрәсемез килә, туйны тизрәк булдырыңыз инде», – диде.
Һәр тарафтан туй хәзерлеге күрелмәгә башлады. Хаҗиның күңеле, никах булачагына тәмам ышанып: «Бу Хикмәтулла бай кызның хиссасыны төгәл тапшырыр микән?» – дигән фикергә төште.
Байның вакытына карап, туй Сембер кайтуга17 билгеләнде. Вәгъдә никах көненәчә берничә һәфтә көтмәк лязим иде. Шул һәфтәләрдә Сабир мулла, Шәркәйне «Туй итмәс» карьясе юлыннан чыгармай, кызга һәдияләр (бүләкләр) җибәрде вә мәктүб язды. Сабир мулла бер мәктүбендә язадыр: «Бибимәрзия җаным! Хаҗ сәфәренә чыкмас борын, сәнең нурлы йөзеңне күреп, сәңа гашыйк булдым. Күз каравың берлә бәни хәйран иттең. Аһ! Сәфәремнән йөреп кайтканчы, көнемдә-төшемдә сән булдың. Алла Тәгалә хәзрәтеннән дога мәкъбүл була торган урыннарда вә мәхсус вакытларда сәне сорадым. Имди, шаять ки, догаларым кабул булгандыр, күзем нуры! Һәрничек Алла Тәгалә тизлек берлә безне кавыштырса икән», – дәю.
II
Хикмәтулла бай Сабир мулланы хаҗга озатканда, Сабир муллага Мәрзиянең сач тараганыны күрмәк мөяссәр булган иде. Бөтен тәнле, урта буйлы, ак йөзле, кара сачлы, маи күзле сылу кыз, су читенә чыгып утырган пәри кызы кеби, саурынача салынган көр вә зур сачыны тараганда күренеп (габденниса улан), хаҗины фитнәгә салмыш иде.
Бу Мәрзия ни сәбәпле бу кадәр гүзәл күренгәнлекене Сабир әфәнде үзе дә белмәйдер иде. (Ки бундагы гаҗәп серне белгәч, укучымыз хәйран булачактыр.)
Бу туй хаҗи хәзрәтенә аерым әсәр итеп, әллә нигә Сабирның йөрәге җилкенә вә эче поша; эчене бушатырга һичбер әхбаб юк иде*. Никахка өч көн калдыкта, хаҗи хәзрәте, үзенең санаулы көннәре вә сәгатьләре тиз үтсен өчен вә бу эшкә бер тәяммен өчен, мәдрәсәдә хәлфәсе –... карьянең имамы мулла Габдулла хәзрәткә бер дәгъвәтнамә язып, пар атыны җибәрде. Бәсмәлә, хәмдәлә, хәмде сәна вә салават соңында, намәсендә язадыр ки:
«Әфзалел фозала вә әгъләмел голяма иткаәл әткыя вә әкмәлел әүлия остазы мохтәрәм вә шәйхе мөкәррәм дамелля Габдулла хәзрәтдән кәмаль тәвазигълык илә догаи хәйриягезне риҗа итеп, сәламе сөннәтелисламла-рымызы укыдык. Вә баз мәхфи улмая ки, бу сәнә Хәрәмәен мохтәрәмәеннән сагъ вә сәламәт кайтуымның шатлыгына, сез бөзрекне хөрмәт итмәк вә җәнабыңыз өчен мәхсус кәлдердекем маи зәмзәм вә хөрмәдән тәнавел иттермәк вә муе мөбарәкне һәм зиярәт иттермәк өчен, бу намәне хамил хадимем Гыймран илә пар атымны тарафыңызга йибәрдем. Шушы атларга ултырып, һәрничек фәкыйрь шәкердеңезгә дога бирмәк өчен тәшриф боермакыңызны үтенәмен. Вә бундан соң янә бер мәслихәт вә мөшавәрәм бардыр ки: әсыйлем Гыйззәтулла мәрхүмнең хаҗыны әда кыйлып кайтдыкымның шатлыгына бер ядкяр булсын өчен, мәрхүмнең угълы мулла Хикмәтулланың үтенүе буенча, кардәше Бибимәрзияне тәзәүвеҗ итмәк касдындамын. Насыйп булса, Алла тәбарәкә вә Тәгалә әҗәлгә сабырлык бирсә, шушы мартның ...нче көнендә гакде никах иҗра ителәчәктер. Һич кичекмәй кәрәм боерасыз, хәзрәт! Никах көненәчә сез бөзрекне хөрмәт итеп, тәяммәнә никах хөтбәсене сездән үтенмәк буламыз. Бакый гафуыгызны риҗа улынадыр.
Әлхаҗ Мөхәммәт Сабир Ышанмасов. ... сәнә, ... март»*.
Сабирның остазы Габдулла хәзрәт тәкъва вә риясыз бер имам иде ки, табгы сәлим, күңеле канигъ, хөсен вә вәкарь сахибе, хөсен вә кобыхне фәрекъ итүче, тәхәммелле вә сахибел-әүрад бер имам иде. Фәкать: «Бу замандагы ишаннарның бар ниятләре җәмгы мал, бар эшләре тәнәгъгом вә тәрәффәдер. Үзләре наданнар, даим дин танымаган җаһил мужиклар берлә вакыт заигъ итәләр», – дип, замана ишаннарыны гаеп иткүче иде. Үзенең шәкерте мулла Сабир хосусында дәхи ул кадәр разый түгел иде. Бер кәррә фарызны әда иткәч, хаҗ белән сәүдә кыйлмак нигә кирәк? Даим хатыннар белән шөгыльләнмәк, бер тоташ нәфес арзусына хезмәт итмәк мәшругъ булырмы икән? «Загел гыйльме фи әфхазенниса» дәю, чырае бозылып, Сабир мулланы истихфаф вә истиһза сурәтендә зикер итәр ирде.

Сабир мулладан килгән мәктүбне алгач, ачып укымас борын, Габдулла хәзрәт мәктүбнең тышыннан вә адресыннан вә саир каринәләреннән белеп, эшнең асылына төшмәк вә бер микъдар әсрарга ирешмәк өчен: «Бу ни? Буны кем бирде? Ул атлар кемнеке? Кайдан килгән?» – дәю, тәвәкъкыф вә тәрәддедтә калды. Ихтисас кабләл вәкугь кабиленнән, мәктүбне әленә алдыкта, монкабиз вә мозтариб булды. Мәктүбне ачып, тиз-тиз күз йөртеп чыктыгында, хәйран булып, башыны уңга-сулга салып: «Ай ахмак! Әүвәл язганы ялган! Гүя миңа мәхсус маи зәмзәм вә хөрмә кәлдермеш. Буннан әүвәл ничә кәррә хаҗга барып, бер катрә зәмзәм вә бер данә хөрмә кәлдергәне юк иде. Бу кәррәсендә бәңа һәдияләр кәлдермеш!» – дәю, Габдулла хәзрәт үз-үзенә сөйләнде. «Бу ахмак дөнья вә ахирәт [тә] хәрап вә рисвай булыр; тизрәк бармасам, әллә ни хилаф шәргы эшкә икъдам кыйлыр, ахмак! Хикмәтулла үзе үтенеп бирә, имеш! Әллә ничә яучы йөрткәнсең дә... Кызы кем бит!» – диде.
Габдулла хәзрәт, үзенә мәгълүм сергә бинаән (түгел ки Сабир мулланың ялганлап язган мәктүбенә имтисалән), иртә таң атар-атмас намаз укып, сәфәргә чыкты. Ике арада байтак мәсафә булса да, шул көн кеше ятканчы, Габдулла хәзрәт Сабир мулланың йортына барып җитте. Остаз хәзрәтенең кәефе бозылып, ачигълы бер кәйфияттә түргә узды. Хәзрәтнең кәефсезлеге юл мәшәкатеннән дәгел иде, бәлки Сабир хаҗиның хәрислыгы (комсызлыгы) берлә икъдам кыйла язып калдыгы эш хосусында бер яшерен сергә мотталигъ улдыгыннан иде. Габдулла хәзрәт, әүдә кеше калдырмай чыгартып, ишекне элдердектән соңра, Сабир муллага бер иске мәктүб бирде. Мәктүбтә язылмыштыр: «Дустым вә шәригем мулла Габдулла хәзрәткә дога вә сәлам бәгъдендә, тәкъдире илаһи ирешеп, кече кызым Гайшәне шәкердегез Сабир хаҗига никахландырмыш идек. Ике кич зөфаф улынып, кияү киткәч, кызымыз кесәсеннән кияүнең язып калдырмыш хәрам хатыны тапты. Кызымыз Гайшә хәмелле булып вә вакыты җитдектә бер кыз бала тугъдырып, шул баладан вафат тапмыш иде. Иттифакан, шул вакытларда Гыйззәтулла исемле адәмдәге олугъ кызым Гафифәнең алты көнлек баласы үлеп, Гайшәдән калган тыйфел Мәрзияне Гафифәгә тапшырдык. Кияүнең даимән үз-үзене тәрбия итмәсе, гыйш вә гыйшрәт, вә нисван берлә иштигале, вә балаларына тәрбия вә илтифаты юклыгы атасы мәрхүмгә кыясән дә мәгълүмдер. Бу Сабирның йортындагы балалары да ни табылганны киеп, ятим балалар кеби тәрбиясезләрдер. Шуның өчен баланың вөҗүде хакында кияүне агяһландыруда файда зан итмәдек. (Вакыйган, Сабир мулла бер никахына кергән хатынларына вә балаларына асла игътибар итмәйдер иде; үзенең нәфесенә ошаган нәрсәләрне кәсеп итүдә тәкъдир вә язмышны теленә дә алмый, ля йөбали теле вә фигыле берлә кеше рәнҗетмәктә иде.) Бән исә, кыз сората башлагач, Сабирны кып-кыска кайтармыш идем. Остабикә дигән нәрсә: «Шушындый бай хаҗига да кыз бирмәгәч, кызны кемгә бирерсең? Үземез фәкыйрь, карыйлыгымыз да бар, бәлкем, дөньямызга да бернәрсә файдасы булыр бай кешенең», – диеп, гаҗиз иткәч бирдек иде. Вә кянә әмруллаһе кадрән мәкъдура... Имди, мулла Габдулла хәзрәт, сез һәм дустым, һәм шәригем, һәм сахибе серем улдыгыннан, бу серне сезгә әманәт идәрем. Һәрничек Гыйззәтулла кияү ятимәнең тәрбиясеннән агырсынмак, яхуд гаҗиз булмак ихтималы барлыгыннан вә яхуд башка бер-бер сәбәптән, вакыты хаҗәттә бу серне фаш итәрсез, дәю раҗи кәминә Габделмалик... Ф.».
Аңладыкмы, әфәндем? Бу мәктүбтә ни беленде?
Мәрзиянең анасы Гайшә – Сабирның мәнкүхәсе, Мәрзия дә Сабирның кызыдыр. Сабир мулланың алып аерган хатынлары ике дистәдән артык булдыгыннан, Сабир ике кичлек мәнкүхәсе Гайшәне оныта язган, хәтта оныткан иде. Бу хаҗиның тәвәккәле там Ходаның рәззакы галәм булуына иманы кәмаль иде. Пигамбәр сөннәте18 диеп, һәр сәнә берничә хатын ала, балалар тәрбиясене биззат Ходаның үзенә тапшырадыр иде ки: аның йортына да төшермәй хәрам хаты бирелгән хатынларыннан туган балалары күп иде. Сабир мулла гаять голулектә улып, берәр-икешәр генә кичлек хатынларны бер аергач, кайтарып сөйләмәгә вә телгә алмага (тәнәззел итмәс) гарьләнер иде. Сач тараганда, Мәрзиянең Сабир мулла күзенә фәүкыльгадә сөемле (сөйкемле) күренүе мәрхүмә Бибигайшәнең рәсемен вә сурәтен күрсәтдекеннән иде. Бибимәрзия хәзерге көндә бигайниһи унсигез

яшендә чагындагы анасы Гайшә улдыгыннан, бу Мәрзия Гайшәгә гаять охшаган икән диеп, Сабир мулланың уйламавы гаҗәп иде.
Сабир мулла Гайшәне гаять сәвәчәк иде. Ләкин гали күңелле Гайшә, зөфаф көннәрендә Сабир мулладан бизеп: «Күземә аю кебек күренәсең, синдә тузан кадәр дә мәхәббәтем юк, әлбәттә, мине аерып калдыр», – дәю, катгыян таләп итдекеннән, мулласы да ул кадәр агыр сүзләр әйткән хатын берлә хөсне могашәрә мөмкин булмаячагыны белеп, вә буның җиренә башка бер кызны алмак һәм мөмкин булсын хәйләсе илә хәрам хатыны гизлечә мәнкүхәсенең җәебенә куеп калдырмыш иде.
Сабир мулла, остазы Габдулла хәзрәттән мәктүбне алып укыдыкта, бу дәсисә Мәрзияне алдырмас өчен корылган бер вәсвәсә улачагыны зан итәчәк иде. Мәгәр саргаеп вә искереп беткән мәктүб бу тәһмәтне кабул итмәдекеннән, зарурәтән буның чын эш идекене игътираф итмәк лязим кәлде. Буның кеби хәрислыктан килгән хаталыкка кешенең вөҗданы рәхәтсез улмаса, лөзүме улдыгыннан, Сабир мулла, йорт-җир вә җәмигъ мал вә дәүләтене мәсҗед вә мәдрәсә файдасына ташлап, хатынларыны аерып, бер төннең эчендә карьясеннән чыгып качты.
Сабир мулла әлхаль сәламәттер, Азия халыклары арасында сәрсәм вә гариб сәяхәт итәр. Сачы-сакалы җитен кеби агарган, яңаклары ябышкан, иңсәсе чыккан, башы салынган, кулында агыр таягы, өстендә керләнгән ак җиләне бардыр.
Бу үзе хосусында булган вакыйгане бәңа сөйләп: «Сән килештереп яза беләсең, яз! Мөселман кардәшләремә гыйбрәт булсын, анлар, милләтләрен онытып, тиешсез эш берлә вакыт качырмасынлар», – дәю, бәңа бу кыйссаны язып нәшер итмәгә әмер итте. Кәндесе, ияген уйнатып вә агыр аякларыны сөйрәп, «Мөхәммәдия»19 укый-укый, Җөмә әкәнең тирмәсеннән чыгып, Казимөхәммәд хәзрәткә барам дәю, мал таптаган кылган өсте берлә далага юнәлде.

## Күгәргән алтыннар

### I

Май аеның иң әгъля, җылы көннәреннән берендә хәзрәт мәсҗедтән кәмаль вәкарь илә чыгып килә иде. Мәсҗедтән чыгуга, икенде1 алдыннан гына явып киткән ягъмур саясендә тузаннары басылып сафланган һава һәм яңа яфрак ярып бетергән каен агачларыннан чыккан хуш исләр хәзрәтнең борынына килеп керде. Бу яхшы һаваны иснәү илә, хәзрәтнең әүвәлдән дә йомшак табигатьләре яңадан бер йомшарып, үпкәләре җәелеп, рәхәтләнеп китте. Бу кадәр хуш исле яхшы һаваны борыннарыны бераз югарырак күтәреп иснәгәннән соң, һаваның татлылыгыннан күбрәк ләззәт алып калу өчен, агызып ачып та бер кәррә сулу алып куйды. Хәзрәт бу ләззәтләр вакытында акрын вә вәкарьле йөрүеннән дә туктаган иде. Ушбу кадәр аз бер тәләззез илә эше тәмам булганнан соң, хәзрәт янәдән гадәттәге рәвешендә мәсҗед ишегалдындагы каеннарны артта калдырып, вәкарь илә генә урам капкасыннан чыкты.
Капка төбендә, капкадан дүрт-биш адым кадәр читтәрәк, бер шәкерт илә җәяүле юлның баганасына сөялеп тора торган, башына чиркәс бүреге, өстенә керләнгән җилән сымак нәрсә кигән төрек борынлы бер кеше хәзрәтнең мәсҗедтән чыкканын көтеп торалар иде. Иң әүвәл шәкерт, мәхрәҗләрен кәмаль чыгарып, бик ихтият илә аның артыннан теге намәгълүм кеше гарәпчәгә бер дә оешмаган агызлары илә сәлам бирделәр.
Хәзрәт, бер дә вәкарьне бозмыйча гына, акрынлык илә сәлам алганнан соң, гәрчә бүген җәй көненең якты кичләреннән бер кич исә дә, китап күп моталәга кыйлганлыктан, күзләре бераз кайткан булганлыктан, каршысындагы кешеләрне танып өчен, куен кесәсенең бер почмагына гына җирләштерелгән пенснәсене акрын гына алып, гадәттәгечә, ак яулыгы илә бер мәртәбә сөрткәннән соң, матур һәм мәһабәт кенә кылыч борынына куйды. Каршысындагы кешеләргә бераз күз йөрткәннән соң, ике кешенең берсе танымаган адәми булдыкыннан, иң әүвәл ул шәкерткә илтифат итеп, ни йомыш илә килгәнлегене сорады.
Шәкерт хәзрәтнең мәдрәсәсендә игъдадия сыйныфларының берсендә укый торган бер шәкерт иде. Бу көн хәзрәттән өенә кайтырга рөхсәт сорау өчен килгән иде. Бу шәкерт

мәдрәсәдә вакытларында тәнгә сыланып тегелгән тужуркалар, брюкалар киеп, гәрчә тәрбияли алмаса да, чәчне озын итеп җиткереп, «базар»га чыккан вакытларында биш тиенлек ак якаларыны куеп, хәлфәләр күрмәгәндә, иптәшләре арасында яланбаш көенчә йөри торган «образованный» бер шәкерт исә дә, бу көн ни өчендер хәзрәт каршына килгәндә, аягында читек илә кәвеш, өстендә җөббә, башында да озын чәчне күмәрлек итеп кара кәләпүш өстенә «бохари»ча ураган чалма иде. Баштагы чалма бик керләнгән булса да, кич караңгылыгында ак төсле булып күренә иде.
Гадәттә, хәзрәт бундай өенә кайтырга рөхсәт сорап килүче шәкертләргә: «Атаңа хат язып бирәсем бар, иртәгә килерсең», – дип җибәрә торган иде, һәм шәкертләр, һәр намаз соңында хәзрәтнең вакытын тугъры китерер өчен, бер-ике көн мәсҗедкә килеп йөрсәләр дә, ахырдан хәзрәтнең хат язарга вакыты булмаганлыктан, болай гына рөхсәт алып китә торганнар иде.
Бу көн харикыльгадә бер эш булды. Хәзрәтнең яхшы һава иснәп табигате йомшарган иде. Шул сәбәптән, атасына хат язам дип, шәкертне бер-ике көн кичектереп торуны мәгъкуль күрмичә, тугърыдан-тугъры рөхсәт бирде.
Шәкерт, бик зур шатлык илә хәзрәтнең кулыны үбеп, күрешеп, тиешле сәдакасыны биреп, янәдән кулын күкрәгенә куеп, башларын иеп, кәмаль тәвазигълык илә сәлам биргәннән соң, «Тәгълимел-мөтәгаллим»2 китабының кушуы буенча, остазы күзенә күренмәс булганга кадәр арты илә барып, чаттан борылып, күздән югалды.
Нәүбәт намәгълүм адәмгә килде. Бу вакытка кадәр багана янында сөялеп торган бу кеше, шәкертнең китә башлаганыны күреп, хәзрәткә таба якынлашты. Шәкерт китүгә, үзенең ватык агызлары илә яңадан бер кәррә сәлам биреп, хәзер генә шәкерттән күреп өйрәнгән белеме илә, хәзрәтнең эш илә мәшгуль булмаганлыктан йомшарган, бикәләр кулы шикелле ак вә йомшак кулларыны үзенең күсәк кеби бармаклары илә кысып күрешеп, щетина мыеклы тупас иреннәре илә хәзрәтнең кулыны үбеп, бераз чәнечке урыннары калдырып, эзләндереп, чын кальбеннән тәвазигълык әсәрләре күрсәтте. Хәзрәт, бераз уңга таба мәел итеп, ике аршын озынлыгындагы көмеш башлы кызыл камыш таягыны ярты адым кадәр алга таба куеп, алга таба атлый башлап, өенә таба хәрәкәткә хәзерләндегене мөсафирга белдерде. Мөсафир да, хәзрәткә ияреп, аның артыннан барырга риза идекене күрсәтте. Вак адымнар илә урамның икенче тарафына чыга башладылар. Хәзрәт акрынлап мөсафирның кем вә нинди кеше идекене сораша башлады. Хәзрәт мөсафирны сәдака җыеп көн күреп йөрер өчен йортыннан чыккан бер чиркәс булыр дип фараз кыйлып та куйган иде һәм гариб мөсафирга ярдәм кыйлдыру өчен байларга мөрәҗәгать кыйлуны да уйлап, бер-ике байның исемнәрене дә күңеленнән кичереп алган иде. Ләкин мөсафир, аның фараз кыйлганынча, чиркәс тә һәм сәдакачы да булып чыкмады.
Мөсафир үзенең анатолияле бер төрек идекене, һөнәре дә бакчачылык булып, ушбу шәһәрдәге Лимонадов нам бер бакчачыда иптәше илә бакчада хезмәт кыйлганнарыны ярым-йорты тупас төрек теле илә аңлатты.
Хәзрәт тә, мөсафир да сүз ушбу җиргә җиткән вакытта, никадәр акрын йөрсәләр дә, урам аркылы чыгып, хәзрәтнең урамдагы кунак як ишеге төбенә килеп туктаганнар иде.
Хәзрәт, ак җон хиркасы эченнән кигән бикасап казакиенең кесәсеннән юка гына ясмык ачкычыны алып, ишекнең Америка системасында эшләнгән бигене ачып, ишектән яртылаш кереп, мөсафирга йөзе илә әйләнде.
Хәзрәт, гадәттә, үзенең каршына, мәсҗед алдына килгән кешеләрнең иң ахырдагысы илә һәрвакытта ушбу рәвештә сөйләп, йомышларыны йомышлап, ишегене бикләп кереп китә торган иде. Килгән кешеләрнең йомышлары зур булмаганда, яхуд күрешергә килгән кеше бик зур игътибарлы адәм булмаганда, өенә алып кереп тынычлыгын бозмыйдыр иде.
Бу көн бу ярлы мөсафирдан да бик зур йомыш чыгуны фараз кыйлмадыктан, аны да ишек төбеннән генә җибәрергә уйлаган иде.
Шул ният илә, ниһаять, мөсафир төрекнең ни йомыш илә үзенә килгәнлегене сорады. Эченнән «Бу мөсафир инде өенә кайтырга юллык өчен миннән бераз ярдәм сорый торгандыр» дип уйлады. Гөнаһ шомлыгына каршы, гәрчә хәзрәт никадәр иҗазәтле зур

шәехләрдән булса да, күңеленә килгән илһамнарының һичберсе тугъры килмәде. Төрек, сүзене кеше ишетүдән курыккан шикелле, як-ягына караганнан соң, үзенең эчендә бик зур һәм яшерен бер сер барлыкыны, ул серне сөйләргә шәһәрдә хәзрәттән башка зур һәм инабәтле кеше таба алмаганлыгыны вә ул серне бу урында, ишек төбендә генә сөйләргә җәсарәт итә алмаганлыгыны хәзрәткә аңлатты.
Төрекнең агызларыны кыйшайтып, акрынлык илә һәм тәвазигъ илә сөйләүләре хәзрәткә тәэсир итте. Әллә кайдан, чит мәмләкәттән килгән бер кешенең агызыннан да үзенең бер зур кеше идекене ишеткәч, хәзрәтнең яхшы йомшак һава һәм татлы агач исләре илә йомшаган хәлим табигате яңадан йомшарып китте. Үзе бераз эчкәрәк кереп, төреккә дә эчкә керергә юл бирде. Төрек, хәзрәтнең мөбарәк ханәсене былчыратудан куркып, аякларының очлары илә генә басып, эчкә керде, аның артыннан хәзрәт тә ишегене ябып, дикъкать илә бикләп, күздән югалдылар.
II
Эчтә һәм йортның югарыгы катында караңгылык иде. Гәрчә вакыт сәгать унберләр булса да, хәзрәт икътисадка бик ригая кыйла торган кеше булганлыктан, хатын-кыз ягыннан башка бүлмәләрдә ут яндырылмаган иде.
Хәзрәт, ишекне бикләгәннән соң, барып югарыга менә торган баскыч янындагы электрик лампасыны кабызып, үз артыннан югарыга менәргә төреккә юл күрсәтте. Югарыга менгәннән соң, кунак бүлмәсенә төрекне утыртып, үзе хатын-кыз ягына чишенергә кереп китте. Бер-ике дәкыйкадән соң күлмәк өстеннән эре юллы бикасап чапан һәм гадәттә кия торган күк хәтфә түбәле бохар кәләпүше урынына, бүгенге кунагы төрек булганлыктан, анларга бер изһары мәхәббәт булсын өчен, кызыл фәс киеп, кунагы янына чыкты. Озак тормады, бер биш-ун дәкыйка соңында, янә дә төреккә ригая уларак, гадәттәге берәр стакан чәй урынына берәр финҗан каһвәләр дә килде.
Бераз сүзләр сөйләшенеп, хәзрәтнең хаж юлында төрекләрдән күргән ихтирамнары вә анда күрелгән гаҗаиб вә гараиблар бәян иделеп тәмам булганнан соңра, яшерен сохбәтләр башланды.
Төрек сүзгә кереште. Үзенең вә иптәшенең, Трабзоннан килеп, бу шәһәрдәге Лимонадовка бакчачылык хезмәтенә керешкәнлекләрене яңадан бер мәртәбә тәкрар кыйлганнан соңра, яңадан бер мәртәбә әтрафына карап алып чит кеше юк икәнлеккә күңеле кәмаль карар тапкач, бик ихтият белән эчке куен кесәсеннән төйнәлгән бер яулык чыгарып чишеп, өстәл өстенә дүрт-биш данә күгәргән алтын һәм җиде-сигез данә күгәргән көмеш акчаларны чыгарып салды.
– Менә бу алтыннар һәм көмешләр – рус алтыннары һәм рус көмеш акчаларыдыр. Фәкать бунлар җир астында ятып бераз ушбу рәвештә күгәргәннәр. Без буның ни кыйммәткә торганлыгыны белмимез. Без буннарны иптәшемез илә икәү җир казыган вакытта бакчадан таптык. Буның бундай алтыннары биш мең данә, көмешләре өч мең данәдер. Без үземез, чит җир кешесе булганлыктан, бу алтыннарны кайда куярга да белмимез. Үземез илә бергә сакласак, тотылып җавапка калуымыздан куркамыз. Киңәш итәргә дә һичбер ышанычлы кешемез булмадыкыннан, сезнең олугъ идекегез безгә күптән мәгълүм булганга күрә, җәсарәт итеп, сезгә киңәшкә килдек. Зинһар, сез безнең серемезне кешегә фаш итә күрмәңез. Безгә бу алтыннарны кайда куярга булса да бер киңәш биреңез. Әгәр бер инабәтле һәм безне алдамаслык бер кеше табылса, без бу алтыннарны дүрт-биш мең сумга булса да сатып, мәмләкәтемезгә китеп, гомеремез буенча сезгә хәер-дога кыйлыр идек, – диде.
Алтыннарны күргәч һәм анларның күплегене вә арзанлыгыны ишеткәч, хәзрәтнең хәлим табигате яңадан да бераз йомшарды. Пенснәне кесәсеннән алып, ак яулык илә сөртеп, күзлекнең бер дә табы калмаганлыгыны ут яктысына тотып бик дикъкатьләп карап кигәннән соң, алтыннар гына тотарга сәляхиятле булган, керсез, ак асылзадәләр кулы кеби кулларының бармаклары илә алтыннарны тотып, әйләндереп карап тамаша кыйлырга кереште.

Алтыннар вакыйгъдә бер тарафында ике башлы каракош сурәтләре төшерелгән, икенче тарафына «пять рублей» дип язылган борынгырак рус алтыннары иде. Ләкин бераз тышкы яклары балчык илә катып күгәргәннәр иде.
Хәзрәт, алтыннарны туйгангача карап тамаша кыйлганнан соң, әүвәлгедән берничә кат йомшаклык күрсәтеп, төрек илә мөшавәрәгә кереште. Төрекнең серене кешегә фаш кыйлмаска сүз бирде. Нинди булса да инабәтле бай бер кешегә әйтеп, васита булып, алтыннарны саттырып, төрекне баетып мәмләкәтенә җибәрергә вәгъдәләр кыйлды. Яңадан берничә финҗан каһвәләр китереп, төрекне сыйлап, байларга күрсәтер өчен алтын вә көмешләрдән берәр данәсене алып калып, урамга кадәр төрекне артыннан озата чыгып, кадер-хөрмәт күрсәтте. Хәзрәтнең бу илтифаты да бик сирәк кешеләргә генә мөяссәр була торган иде. Әксәрдә хәзрәт кунакларын югарыдан, баскыч башыннан гына озатып калып, ишек бикләргә хадимәне генә куша торган иде.
III
Кунак чыгып китү илә, хәзрәтнең мәгыйшәтендә яңа дәверләр башланды. Гадәттә хәзрәт ястүдән соң берәр сәгать китап карагач, ятып, иртә намазга кадәр хили истирахәт кыйла, мөнәббиһ сәгатьнең шалтыраган тавышына уянып, иртә намазына китә, аннан кайткач, янәдән, иртәге чәйгә чакырылган булмаса, сәгать тугызларга кадәр истирахәт итә торган иде.
Бу көн алтыннарны күргәч һәм алтын хәбәрләрене ишеткәч, хәзрәтнең йокысы качты. Гәрчә вакыт соң булып, гадәттә ята торган вакыты узганга бер сәгать булса да, һәм икенче бүлмәдә абыстайның мышлап йоклаган тавышлары ишетелә башлаганга бик күп вакытлар үткән булса да, хәзрәтнең күзенә йокы керми иде. Кунакны озатып тын калганнан соң, хәзрәтнең күзенә бер-бер артлы өем-өем акчалар, байлыклар күренә башлады. Йортлары әллә нинди зиннәтләнгән төсле күренә иде, дөньяда рәхәтлек хис кыйладыр иде. Ләкин бер читен мәсьәлә бар: бу алтыннарны ничек итеп кулга кертергә кирәк? Бу кадәр күп алтыннарны кулга кертү өчен дүрт-биш мең сум акчаны кайдан алырга кирәк?
Хәзрәтнең ике-өч җирдәге зур таш йортларда иштираке булып, хили сумасы булса да, анлар акчалата сума булмаганлыктан, хәл бераз мөшкил иде. Бу йортларны рәһенгә салып акча табу мөмкин исә дә, аңарга шәрикләреннән ризалык алырга кирәк булачак. Ризалык алып йөрсәң, сернең сизелү ихтималы бар. Ул ихтималлардан котылырга да, бәлки, юл табылыр иде, ләкин алганнан соң ул алтыннарны тәмизләп, сатып бетерергә кирәк булачак, сәүдәгәр булмаган кешегә бу да бер читен эш. Соңра бу алтыннарны алтын бәрабәренә алмаштыруның риба булу ихтималы да юк түгел.
Шуларны уйлап утыра торгач, хәзрәт таң атканны сизми дә калды.
Көн шактый яктыра башлаган иде. Хәзрәтнең өендә бу вакытта да яктылык булганлыктан, халыкның шөбһәгә төшү ихтималлары да юк түгел иде. Шул сәбәптән хәзрәт тиз генә кунак як утларыны сүндерде һәм, намаз вакыты бик җиткән булганлыктан, тәһарәт алып мәсҗедкә китте. Барганда, кайтканда һәм намаз эчендә дә күңелендә һаман шул йөзе сары алтыннар иде. Намазда кушкан сүрәсендәге «вәннәҗмес-сакыйб» дигән сүздәге йолдызлар да күзенә алтын булып күренеп, кыйраәтендә бераз ялгышып та алды. Кайткач, бу эшнең үзеннән генә булмаячагыны исәпләп, мөрид байларыннан берсенә серене ачып, аның илә бергә алтыннарны алып, яхуд аннан алдырып та, үзенә хезмәт хакы берничә мең сум гына алып калырга фараз итеп, чишенеп урынга ятты. Ятканнан соң да бу акчаларның риба булмавыны күңеленнән мөхакәмә кыйлып, ниһаять, кәгазь акча биреп алган тәкъдирдә риба булмаячагына күңеленнән карар биреп, кояш чыгар алдыннан салкынайган һавада абыстайның җылысы илә эреп йокыга китте. Төшендә дә һаман алтыннар, көмешләр вә байлыклар күреп саташты.
IV
Хәзрәт йокыдан уянганда, сәгать тугызлар булган иде. Абыстайның «Тор, мулла, тор! Чәй булды инде» дигән сүзләренә уянып китте. Төшендә күргән татлы хыяллары бүленде. Гүя алтыннар, кулына керәм дигәндә генә, төшеп югалган шикелле булды. Аның өчен абыстайга бераз ачулана язып та калды. Ләкин анларның төш икәнлегене белгәнлектән,

өнендә дә алтыннарга кавышу дәрте илә тиз генә урыныннан торып, тәһарәт алып киенде. Хадимне җибәреп, мөрид байны базардан чакыртып менгерде. Башка көннәрдә иртәге чәйне абыстай илә сохбәт итеп, кәефләнеп эчә торган булса да, бу көн, алтыннар хөрмәте өчен, ул ләззәтне фида кыйлып торырга мәҗбүр булды.
Мөрид бай хәзрәтнең бик якыннарыннан һәм хәзрәт тирәсендә йөри торган байларның иң зирәк вә ачык фикерлеләреннән иде. Асыл сумасы атасыннан калган булса да, үзенең бик зирәклеге аркасында сумасыны арттырып, бик тиз баеган иде. Бу көндә хәзрәтнең болай бик иртә чакыртуыннан, нинди дә булса харикыльгадә бер эш бар идекене «зирәк» бай бик тиз сизенеп алды. Шул сәбәптән, хәзрәтне озак көтәргә мәҗбүр итмичә, тиз генә килде һәм, тугъры югары менеп, кунак бүлмәсенә керде. Хәзрәт, байны гадәттәгедән дә ачык чырай илә кабул итеп, чәй эчәргә утыртты. Бераз базар хәлләрене сорашканнан соң, «мөһим мәсьәлә»не хәл итәргә керештеләр.
Хәзрәт иң әүвәл файданың биштән берсенә үзене керештерүне шарт кыйлып, бай тарафыннан бертөрле ризалык алганнан соң, кичә төректән нәмүнә өчен алып калган алтын илә көмеш акчаны байның алдына куеп, кичә төрек илә ике арада булган эшләрнең һәммәсен дә байга сөйләде. Бай да, күп файданы күргәч, бик кәефләнеп, биш мең данә алтынның хәзерге базарда – утыз җиде мең ярым сум, өч мең көмеш – өч мең сум, җәмгысы кырык мең биш йөз сум булачагын «зирәк»леге аркасында тиз генә хисаплап алды. Ләкин файданы күбрәк итү мәкъсуды илә, никадәр арзан булса да, бундай хәвефле эштә надан төрекләргә биш мең сум бирү тиеш булмаганлыгыны, анларга ике мең сум биргәндә дә бик рәхәтләнеп сатачакларыны бәян кыйлды. Хәзрәт тә байның «зирәк»легене тәхсин кыйлып, ике мең сум илә төрекләрне ризалатырга карар бирделәр. Хәзрәт, төрек килгәч, аны байның үзенә җибәрергә вәгъдә кыйлып калды. Алтын хыяллары илә дәртләнеп, бай да үзенең магазинына чыгып китте.

V

Берничә көннәр узды. Ушбу узган көннәрдә дикъкать кыйлып караган кешеләргә ике төрекнең «зирәк» бай магазины тирәсендә киләп сарганлыкларыны күрергә бик мөмкин иде. Бай кереп чыккан көнне кич, төрек, иптәше илә хәзрәткә килеп, яңадан күренеп киткәннәр иде. Хәзрәт бунларга байның кибетене үгрәтеп, бундан соң шул бай илә эш күрергә кушып, төрекләрне озатып калган иде. Шул көннән бирле төрекләр «зирәк» бай тирәсендә киләп сара башладылар. Бай илә берничә кәррәләр күрешеп, хак тугърысында да сөйләштеләр. Бай, берничә алтын нәмүнәләрне алып, кислоталарга салып һәм төрле дарулар тиереп карап, алтынның чынмы, ялганмы идекене тәфтиш кыйлып карады. Алтынның алтынлыгында һичбер шөбһә юк иде. Бай, үз күзенә генә ышанмаганлыктан, серне приказчикларыннан берсенә ачты. Алтын тануга маһир булган бу приказчик та, алтыннарны төрле дарулар илә юып карап, чын алтын идекләренә шаһадәт бирде. Бу тарафтан да күңел тынычланды. Фәкать бу эшнең хәерле булып-булмавыны тәфәәәл кыйлып карау өчен хәзрәттән истихарә кыйлып карарга үтенде. Гәрчә хәзрәтнең мөкаррәбләрдән икәнлегенә игътикады бик кәмаль исә дә, ихтият өчен, шәһәрдәге башка «зур» кешеләргә мөраҗәгать кыйлып, анлардан да истихарәләр кыйлдырды. Истихарәләрнең һәркаюсы яхшы чыкты. Хәзрәт төшендә бик шәп бакчалар, бик һәйбәт ялтырап аккан чишмәләр күрде. Башка «зур кешеләр»нең дә күргән төшләре бик әһәмиятле иде. Бересе – байның бик әгъля тройка атлар илә йөргәнене, икенчесе байның - йорты өстенә бик биек манара үскәнлегене күрде.
Истихарәләрнең һәркаюсы эшнең хәерле булачагын күрсәтәләр иде.
Бай алтыннарны алырга карар бирде, ләкин ничек булса да файдалырак рәвештә алырга юллар табарга кирәк иде. Шуның өчен бай алтыннарны алу тугърысында бик сабырлык күрсәтте. Төрекләр байга көненә берничә мәртәбәләр килеп, алтыннарны сакларга курыкканлыкларыны сөйләп, бу газаптан тизрәк котылдыруны байдан үтенсәләр дә, бай да, үзенең ул кадәр алтыннарны урнаштырырга урын таба алудан курыкканлыгыны һәм аның илә үзенең дә эләгү ихтималы барлыкыны бәян итеп, назлана иде. Иштә шул сәбәпләрдән иде ки, төрекләр көненә берничә мәртәбәләр байның кибете тирәсендә киләп

саралар иде. Сатулашулар һаман дәвам итә. Һәрбер килгән саен төрекләр алтынның бәһасеннән берәр йөз сумны төшерәләр, бай да килгән саен иллешәр сум арттыра иде. Шул рәвешчә сөйләшә һәм сатулаша торгач, ниһаять, өч мең сумга килештеләр.
Өч меңнең ике мең сумы – төрекнең иптәшенә (чөнки ул алтыннарны элек күргән), бер меңе үзенә булачак булды. Алтыннарны китереп тапшыру илә ике мең сумны байдан алып, иң әүвәл иптәше шәһәрдән китәчәк. Берничә көннән соң калган мең сумны алгач, төрек үзе дә ватанына сәфәр итәчәк иде.
Ихтият тәдбирләренең һәркаюсы ижраэ ителде. Төрекләр алтыннарыны байның өенә кич илә, кеше күрмәгән вакытта гына китереп тапшырачак булдылар. Төрек алтыннарны салыр өчен яхшы бер тимер сандык хәзерләп куярга һәм үзе дә, йөзәр сумлык кәгазь акчалардан башканы хисаплап белергә бик маһир булмадыкыннан, акчаларның һәркаюсыны йөзәр сумлык итеп хәзерләргә байдан үтенде. Һәм политсәгә беленү хәвефе булмасын, сер дә чит кешеләргә беленмәсен өчен, алтынны тапшырган вакытта бер приказчиктан башка әүдә һичбер кеше булмаучылыгы да шарт ителде.
Алтыннарны икенче көн кич сәгать унбер тулганда китереп тапшырырга карар бирелде.
VI
Икенче көн булды. Иртәдән үк алтыннарны кабул итәр өчен хәзерлекләр башланды. Йортта хатын-кыздан һичкем калмады. Бай һәркаюсын дачага җибәрде. Хәтта, төрекләрнең кереп чыкканлыкларыны күрмәсеннәр өчен, дворник илә кучерга да бу көн дачага барып, бикәләрне саклап кунарга әмерләр бирелде. Әүдә һичкем калмады. Кич кибет япкач, бай приказчикны үзе илә әүгә алып кайтты. Яңадан һәртөрле ихтият тәдбирләре кыйлынды. Йортның урам ягына караган бүлмәләрнең һичберсенә яктылык кертмәделәр. Фәкать ишегалды ягына караган бүлмәләрдән берсенә генә бик якты итеп утлар яндырып, ике кат пәрдәләрне төшереп, тыштан һич күренмәслек итеп тәрәзәләрне томаладылар. Хәзерлекләр тәмам булды. Төрекләрне тавышсыз-тынсыз, шыпырт кына алып керү өчен, приказчик та капка төбенә чыкты.
Сәгать ун тулды. Сәгатьнең суккан тавышы бүлмә эчендә ялгыз калган байның күңеленә тәэсир итте. Алтыннарга кавышу шатлыгы илә политсәгә эләгү, яхуд серне кешегә беленү хәвефләре бергә катышканлыктан, изтирабка төшеп, байның йөрәге сикерә иде. Күнелене әллә нинди үзе белмәгән хәвефләр ишгаль кыйлып, курка иде. Гүя бер җинаять эшләргә хәзерләнгән кеше шикелле каушап, куллары, аяклары калтырый башлады. Башлары да әйләнгән шикелле һәм күз аллары караңгыланган төсле булды. Тынычсызлыгыннан урынында утырып тора алмас булды. Торып, бүлмә буенча йөри башлады. Берничә мәртәбәләр урам янындагы караңгы бүлмәләргә чыгып, бик ихтият илә тәрәзәләрдән карады. Вакытлар бик акрынлык илә генә уза иде. Эч пошканлыктан, вакыт кичерү өчен китап укымакчы булып, атасы заманыннан ук калып, бу көнгә кадәр ара-тирә тузаннарыны сөрткән вакытларда асраулар тарафыннан тотылудан башка кеше кулы тимәгән вә һичбер кәррә беркем тарафыннан да ачып укылмаган китаплар янына килеп, берәр-берәр китапларны актара башлады. Куллары китапларны актарса да, зиһене һаман алтыннар илә мәшгуль булганлыктан, һичберсене аңлый алмый иде. Актарып-актарып та, укырга бернәрсә дә таба алмагач, китап шкафы яныннан китте. Аякларында тәмам куәт беткән иде, хәлсезлектән, язу өстәле янындагы урындыкка утырды. Шул вакытта сәгать унберне дә суга башлады. Бер сәгать тын торганнан соң суккан бу сәгать тавышлары алтыннарның якынлашуыннан байга хәбәр бирәләр иде. Бай, урыныннан сикереп торып, урам янындагы тәрәзә янына барды. Күкне кара болыт каплаган булганлыктан, гәрчә җәйге төн булса да, яктыдан чыккан күз илә урамдагы нәрсәләрне күрү мөмкин түгел иде. Шул вакыт ерактан яшен яшьнәгән яктылык күренде. Күз ачып йомганчы ялтырап киткән бу яктылыкта урамнар бик мәһабәт вә куркыныч булып күренде. Бай, «ля хәүлә» укып, тиз генә башыны тәрәзәдән алып, ут яндырган бүлмәгә кереп китте. Куркуы артканнан-арта вә аның бәрабәренә үзендә куәтсезлек барганнан-бара көчәя иде. Бичара бай, куәтсезлектән вә арыганлыктан чыдый алмыйча, турецкий диванга егылды. Шул заман, бик каты күк күкрәгән тавыш ишетелеп, артыннан ук тәрәзәләргә бәреп, бик каты шыбырдап ягъмур

ява башлады. Байның куркуы тәмам чиктән ашты. Ниһаять, бундай куркулы вә тынычсыз алтыннардан ваз кичеп, алтыннарны алмаска уйлый башлады, ләкин бу фаразы нәтиҗә чыгарырлык дәрәҗәгә килеп җитмәде, парадный ишегенең шалтырап ачылганлыгы вә аның артыннан ук ихтият илә ябылып бикләнгәнлеге һәм ике-өч аяк тавышының югарыга менгәнлеге ишетелде.
Димәк, алтыннар килә. Байның изтирабына һич чама юк. Байның әүвәлге куркулары таралып, аның урынына күз ачып йомганчы алтын гыйшкы урынлашты. Тышта яшьнәгән яшеннең тавышы яңадан байны бер мәртәбә дерелдәтте. «Йа Алла! Бу алтыннар никадәр куәтле нәрсәләр! Нинди зур тавышлар вә нинди куәтле шаптырдау һәм ялтыраулар илә киләләр!» Бай тәмам каушап төште. Аптыраганлыктан ни эшләргә дә белми иде.
Бундай бәйнәлхәүфи вәрриҗа булган агыр бер заманнар да кичте. Ишектә, зур капчыкны кочаклап, ике төрек илә приказчик килеп керделәр. Капчыклы алтынны күрү илә байның йөрәге гөп итеп бер секунд эчендә башыннан аягына кадәр бер-бер артлы кайнар һәм, боз кеби салкын су койган шикелле, эсселе-суыклы булып китте. Яңадан тышта яшен чатырдады. Һәркаюсының куркудан күзләре шар кеби ачылды. Бунлар һәркаюсы да куркалар, һәркаюсы да, бер җинаять кыйлырга хәзерләнгән кешеләр шикелле, дерелдиләр иде. Сүз сөйләргә һичберсендә җәсарәт юк. Бер сания кадәр һәркаюсы аяк өстендә катып калдылар. Ниһаять, карт төрек, җәсарәт кыйлып, калтыраган тавышлары илә сәлам бирде. Сәлам биреп бетергәнче, каушавыннан ике-өч мәртәбә сулу алырга мәҗбүр булды. Карт төрек, капчыкны ныгытып кочаклаган көенчә, идәнгә утырды. Башкалар да аңа мотабәкать кыйлдылар. Идәнгә утыру илә һәркаюсында бераз җәсарәт хасыйл булды. Карт: «Сез тәмам хәзермесез?» – диде. Буңа каршы бай да көч-хәл илә: «Хәзермез», – диде. «Зирәк» бай һаман да ихтиятта иде. Алданмау өчен, алтыннарны яңадан бер мәртәбә карарга лязим күрде. Җәсарәт итеп, алтыннарны күрсәтүне карттан сорады. Эшләр бик тизлек илә бара иде ки, гүя бер җинаять эшләнә иде. Карт төрек байның алдавыннан бик курка, шул сәбәптән капчыкны бер дә кочагыннан җибәрми иде. Бай сорагач, бик саклык илә генә, дерелдәгән куллары илә капчык авызыннан ике-өч данә алтынны алып бирде. Алтынның чынлыгында шөбһә юк. Бай: «Әйдә бушат»,– диде. Зур һәм таза тимер шкатулканы чалтыратып ачты. Буңа каршы төрек: «Кайда акчалар?» – диде. Бай әүвәлдән хәзерләнеп куелган егерме данә йөзәр сумлык кәгазь акчаларны, кесәсеннән чыгарып, төреккә бирде. Төрек, куллары калтырый-калтырый акчаны санаганнан соң, кесәсеннән бер кызыл яулык чыгарып акчаны төрде. Куен кесәсенә эчкә салды. Йөзләре тәмам яктырды. «Инде сез дә игелегене күреңез, тот сандыкны», – диеп, капчык эченнән алтыннарны шкатулкага койды. Бикләп ачкычны байга бирде, соңра яңадан бер исәп төшкән кеби булып, кинәттән кесәсенә кулыны тыгып, бая төреп салган яулыкны кесәсеннән чыгарып: «Без хәзер китеп, дүрт мең данә көмеш акчаларны китерәмез, аны алып килгәнче бу акчалар да бунда торсын»,– дип, байдан ачкычны сорап алып, ачып, яулыкны шкатулкага салып бикләп, ачкычны үзенә алды. «Без хәзер ярты сәгатьтән килеп җитәрмез», – дип, урыннарыннан кузгалып чыгып киттеләр. Чыкканда йөзләре бик якты иде, ләкин шатлыкларыннан бик каушаганнар иде. Приказчик ишекне бикләп озатып калды.
Тышта ягъмурлар да туктаган, һавалар да ачылган һәм ничә вакытлардан бирле вөҗданны газаплап торган агыр бу эшнең иң зур бер кыйсме берничә дәкыйка эчендә узып киткән иде. Бу эшләр бары да төш эчендә кебек кенә узып китте. Байның өстеннән агыр бер йөк төшкән шикелле булды. Байның күңелендә хәзер шатлыктан башка һичнәрсә калмаган иде. Приказчик кергәч тә, татлы мөсахәбәләр башланды. Бай приказчикка да бик яктырып сөйли иде. Шатлык сәгатьләре гадәттә бик тиз уза бит. Болар, сөйләшеп утыра торгач, сәгатьнең бер булганын тоймый да калганнар. Фәкать сәгать берне сукканны ишеткәч кенә, бай илә приказчик, йокыдан уянган кеби булып, төрекләрнең киләчәкләрене хәтерләренә китерделәр. Төрекләр ярты сәгатьтән килергә тиеш иде, ләкин анлар чыгып китүгә ике сәгать узган булса да, һаман күренмиләр. «Әллә капка төбенә килеп көтеп торалармы икән?» – дип чыгып та карадылар, анда да юк. Янәдән бер ярты сәгать

көттеләр, төрекләрдән һичбер нам-нәшан юк. Бай хафага төште. Бичара төрекләрне кызгана башлады. Мескеннәрнең эшләренең сизелүе һәм көмеш акчаларны алып килгән вакытта юлда политсә тарафыннан тотылып эшкә эләгүләре һәм анлар аркасында байның да кулыннан алтыннарның китүе, аның өстенә байга үзенә дә берәр төрле эш булуы ихтимал иде. Гәрчә бай алтыннарны акчага алган булса да, яшереп алган мал булгач, закон буенча, бәлки, ул да, кем белсен, гаепле була торгандыр. Шул сәбәптән бай үзеннән дә курка иде. Иштә шундый куркулар илә яңадан берәр сәгать вакыт уздырдылар. Алтыннарны яшерергә дә, яшермәскә дә белә алмадылар. Сәгать ике тулды, һичбер килгән-киткән кеше күренмәде. Ниһаять, Ходага тапшырып, чишенеп яттылар. Приказчикка да бу көнгә бай өендә иптәш булып кунарга тугъры килде. Алтыннарның файдасы да, зарары да үзенә гаид булмаганлыктан, приказчикның зур кайгысы юк иде. Ул, сәгать икегә кадәр тартылган файдасыз агыр хезмәттән котылганлыктан, урынга башы тию илә бик тиз гырылдап йокыга китте. Фәкать бай гына бик озак борчылды. Буның колагына капка шылтыраган, яхуд ишек каккан шикелле тавышлар ишетелгән төсле тоела иде. Гяһа политсә килеп, алтыннарны алып киткән шикелле була да, хафалана, гяһа бөтен алтыннар илә шкатулка эчендәге үзенең акчалары да үзенә калган шикелле булып, һичбер тиен акча сарыф кыйлмыйча, шулкадәр алтыннарга малик булганлыгыны исәпләп шатлана иде. Шундый фикерләр илә башыны ватып, урынында әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп күп маташа торгач, бай да сәгать дүртләр тирәсендә йокыга китте.

VII

Иртә сәгать җиде иде. Бай, төшендә алтыннарның шкатулкасы илә ишектән чабып чыгып барганыны күреп, саташып, куркуыннан уянып сикереп торды. Тиз генә шкатулкага барып ябышты. Шкатулканың кичәге урынында бикләнгән көенчә торганлыгыны күргәч, җаны тынычланды. Төнге вакыйгаләрне бер секунд эчендә күз алдыннан кичереп алды. Кич илә политсә дә, фәлән дә килмәгәнлегене белгәч, шатланды. Кичә кич илә килергә төрекләр, бәлки, шикләнеп калганнардыр. Калган көмеш акчаларыны, бәлки, бу көн китереп бирмәкче була торганнардыр дип, җанын тынычландырды. Тәһарәт алды, киенде, приказчикны да уятып, аннан самавыр куйдырып, чәй эчеп, шкатулканы зур бер сандык эченә салып бикләп, кибеткә чыктылар. Көн узды, һичбер килгән-киткән кешеләр күренмәде. Төрекләрнең политсәгә эләккән булуларында байның һичбер шөбһәсе калмады. Булган эш булган, сабыр итүдән башка һичбер чара юк.

Шул рәвешчә бай өч-дүрт көнгә кадәр сабыр итте. Бер һәфтә дә үтте. Төрекләрдән дә, политсәдән дә һичбер төрле хәбәрләр булмагач һәм төрекләрнең эләккәннәре тугърысын-да да бер сүз ишетелмәгәч, ни эшләргә кирәклеге хакында хәзрәт илә киңәш итте. Хәзрәт тә бу хакта мәгълүм көн узганнан бирле бик зур хафада иде. Хәтта үзе русча укый белмәсә дә, укый белгән кешеләрдән гәзитәләр укытып, төрекләр хакында гәзитәдә берәр хәбәр юкмы икәнлекне белер өчен, акрын гына, белмәгәнгә салышып, шәһәр хәбәрләрене тикшертә иде. Бер атна кадәр вакыт эчендә бунлар хакында һичбер төрле хәбәр булмагач, хәвеф-хәтәр юк идекенә аның да күңеле карар тапкан иде. Шул сәбәптән байга шкатулканы ватып ачарга фәтва бирде. Бай, кич шкатулканы ватарга карар биреп, көндездән үк бүлмәсенә төрле кораллар хәзерләп куйды һәм, үзенә булышыр өчен, кич илә өенә барырга мәгълүм приказчикка да әмер итте.

Кич җитте, бай кайтты, приказчик та килде. Эшкә шөругъ кыйлдылар. Мең бәла илә шкатулканы ваттылар. Шкатулканы ачкач, бай, акча төргән яулыкны алып: «Мескеннәргә бу акча да насыйп түгел икән», – дип, кесәсенә салып куйды.

«Бисмилла» дип, алтыннарның күгәргән вә каткан яшел балчыкларыны пәке илә кыра башладылар. Беренче алтында ук приказчикның кулында пәке очы алтынның уртасындагы бер тишеккә кереп, икенче яктан чыкты. Яхшылап карасалар, «алтын» дигән нәрсәләрнең һәммәсе дә атларның шлеяларына тезә торган җиз тәңкәләр булып чыкты. Бай шөбһәгә калды. Йөрәгенә гөлт итеп ут кабынган төсле булды, тиз генә кесәсенә кулыны салып, төргән яулыкны алып ачты. Яулык эченнән йөз тәңкәлек формасында итеп төрелгән кәгазьләр чыкты. «Зирәк» бай эшне сизде. Үзенең алданганлыгында һич шөбһә

юк иде. Төрекләр, мәһарәтләре аркасында, җизләрне һәм берничә данә алтыннарны күгәртеп, нәмүнәгә яхшы алтын күрсәтеп, байга берничә мең данә җиз тәңкәләр сатканнар һәм чыгып киткән вакытларында акча төргән яулыкны үз кесәсенә салып, шуның төсле итеп төргән икенче яулыкны шкатулкага бикләп, байны алдап киткәннәр иде. Бай, эшне аңлагач, теге «мескен төрекләр»гә ләгънәтләрне яудырса да, анлардан нам-нәшан калмаган, бу көнгә кадәр анлар күптән шәһәрдән чыгып сызганнар иде. Бай «алтыннар»ны бәдрәфкә түкте. Вакыйгане дә үзләре генә белеп, эчләреннән тындылар. Бай да, хәзрәт тә алтынның күгәрми торган нәрсә идекене алданганнан соң гына белделәр. Истихарәләр яхшы төсле күренгән булса да, тәгъбирендә хаталык булган икән дип үзләрен җуаттылар.

VIII

Вакыйгадән тәмам өч ел узган иде, көннәрдән бер көн мөселман гәзитәләренең берсендә ушбу рәвештә бер хәбәр күренде:

«Алдаучылар

Өченчекөн кич берсе Нури, икенчесе Хәмид исемле ике көрд Михайлов нам бер адәмгә, җирдән таптык дип, бер капчык «алтын» сатып, биш йөз сум акчасыны алып чыгып киткәннәр. Анлар чыгып китү илә, Михайлов, «алтыннар»ның ялганлыгыны белеп, политсәгә хәбәр биргән. Политсә, бунларны Балык базарындагы3 бер йорттан барып табып, хәбес иткән».

Гәзитәдә язылган көрдләр өч ел бундан мөкаддәм байны алдаган «төрекләр» иде.

Мәкаләләр

Рецензияләр

Истәлекләр

1905

Кем гаепле?

«Казан мөхбире»нең сигезенче номерында бер ханымызның мөтәфәррәкасен укып гаять шатландым. Ул ханымыз үземезнең артка калганымызның сәбәпләрен бик яхшы аңлатып вә белдереп язса да, мин дә үземезнең артка калуымыз тугърысында берничә кәлимә язарга батырчылык кыйлдым.

Ханымнар! Безнең барчамызга мәгълүм һәм дә күз алдымызда: башка милләтләрнең хатын-кызлары өчен ничә төрле мәктәпләре вә көтебханәләре вар. Анларның хатын-кызлары ничә төрле һөнәрләргә үгрәнгәннәр һәм дә үгрәнәләр. Башка милләтнең хатын-кызлары барчасы бертөрле эш белә. Мәсәлән, бәгъзесе челтәр бәйли, бәгъзесе машина илә оек бәйли, бәгъзесе кием тегә, бәгъзесе һәртөрле кыйммәтле материяләр суга, әлхасыйль, һәрбересе үзләренең тамакларын үзләре туйдырырга кадирләр.

Әмма безнең Казан шәһәрендә мөселманнар өчен мәктәп тугърысында агызын ачкан адәм бармы? Мөслимәләр! Безгә барчамызга мәгълүм, безнең өчен Казан шәһәрендә мәктәп юк, булса да, исемнәре генә, көтебханә тугърысында әйткән дә юк!

Ләкин мәктәпләремез булмаса да, ничек улса да үземез бераз укырга һәм язарга өйрәнәмез, ләкин тиз заман татар агаларымыз, белмим, хөседлектән, белмим, бездән һөнәрләрен кызганганлыктан, хатын-кызны күп укытсаң, аза башлый, күпне белә башлыйлар, хатыннарны күп укытырга ярамай, чөнки ирләрне тыңламый башлыйлар, ан-

ларга бераз булса җитәр, хатыннарның сачләре озын, гакыллары кыска вә башка төрле сүзләрне ишетә башлыймыз.
Ирләремез тарафыннан кысанлыклар булса да, бәгъзе ханымнарымыздан безнең арада галимәләр дә бар дигән сүзләрне дә ишетәмез, дөрестән дә, безнең галимәләремез бармы? Безнең галимә дигәннәремез укымак һәм язмактан башка һөнәр беләләрме? Укымак, язмак безгә җитәме? Юк, ханымнар, ялгышамыз! Безгә укымак һәм язмак кына җитми. Безгә кирәк уку-язу; бигрәк тә артыграк кирәк һөнәр, ягъни кул эшләре. Шулай, ханымнар! Хәзерендә безә кирәк мәктәп, безә кирәк көтебханә, безә кирәк кул һөнәрләрен үгрәтә торган мәктәпләр – укыр да идек, һөнәр дә үгрәнер идек, ләкин мәктәп юк диеп агызыгызны ачып тормыйк, мәктәп юк диеп боргаланып-сыргаланып йөрмик, хәзерендә андаен вакыт түгел.
Бер төстә торды дөнья ничә гасыр... илх*.
Шулай, ханымнар, егъламаган балага имчәк бирмәсләр, хәзерендә безә дә вакыт мең еллар йоклаган йокыларымыздан уйганырга! Хәзерендә безгә дә вакыт май числосының хуш исле сачәкләренең хуш исләрен иснәргә, хәзерендә безә дә вакыт мәктәп вә көтебханәләр тугърысында мәшәкатьләр күрергә. Ләкин үземезгә кирәкле улган шәйләрне без мәшәкатьсез таба алмамыз. Без ишетик төрле-төрле сүзләр, без күрик төрле-төрле мәшәкатьләр. Әмма ирешик үземезнең мәкъсудымызга!
Артка калуымызга үземез сәбәпче улган кеби, алга китүемезгә дә үземез сәбәпче улаек! Алга китүемез – үземездән, артка калуымыз – үземездән. Бу көнгә кадәр артка калуымызның сәбәпләре үземездән; дөрестән дә, без үземез гаепле. Ничек? Сөалемә каршы җавап бирим. Ханымнар! Тарихларда укыганыгыз бармы бер-бер кавем хөрриятне көрәшмичә алганын? Әлбәттә, юктыр. Безгә дә хәзерендә минут килеп җиткән. Мәшәкать минуты күз алдымызда.
Онытмагыз! Мәшәкатемез үземезгә кирәкле улган мәктәп өчен мәшәкатькә керешмәстән, әүвәл бәгъзе ханымнар кеби, безә мәктәпләр салырга иганә идеңез! Безне ничек булса да үзеңезнең ярдәмеңездән куймаңыз дип, череп беткән, таякны әлиф дип белмәй2 торган байларымыздан ярдәм сорарга тормаек! Анларның ярдәме безгә файда бирмәс. Байларымыз безә яхшы мөгаллимәләр табып бирмәсләр. Бу гасырда безә иҗек укыта торган әбиләр кирәк түгел. Безә байларымыз: «Мөгаллимәләр мөслимәләр улсын», – диярләр. Әмма мөслимәдән мөгаллимә улырдай кызлар җитешмәймеш, алай булса да өч-дүрт сәнәдән соң гимназияне укып чыгачак ханымнарымыздан өмид итәмез.
Күземез алдында: хөкүмәт башка милләтнең хатын-кызлары өчен һәртөрле мәктәпләр бина итә. Әгәр дә без дә башка милләтнең хатын-кызлары кеби мәшәкатьләнсәк, хөкүмәт, әлбәттә, безгә дә мәктәп салачак һәм дә салмый калмас.
Дөресендә, һөнәр мәктәпләре безә хөкүмәттән кирәк. Чөнки хөкүмәт безгә яхшы-яхшы мөгаллимәләр табар. Безнең өчен хөкүмәт мәшәкатьләнер һәм дә тырышыр. Шулай булса да, хөкүмәткә дә бөтенләй ышанып бетмик, ягъни хөкүмәттән үземезне алдатмыйк. Ханымнар! Башланган эшемезне ташламыйк! Ничек булса да тырышыйк. Мәсәлән, уйлап карыйк: әгәр бер шырпыны яндырып идәнгә ташласаң, әүвәл бер-бер киемгә кабынып, соңра бөтен өйне ут алу ихтималы бар. Ханымнар! Без дә әүвәле бер генә янып тора торган шырпы кебек булырмыз. Соңра, зураеп-зураеп, бөтен шәһәрне, бөтен илемезне яктырту ихтималымыз бар.
Шуның өчен дә, вакытымызны кичермәенчә, үз араларымызда җәмгыятьләр ясап, үземезә кирәкле улган эшләр тугърысында сөйләшик. Җитмәсме тәкәбберлекемезне бетерергә, җитмәсме бер-беремезне гаепләргә! Җитмәсме җәмгыятьләремездә үземезнең киемнәремез илә мактану! Җитмәсме русча белгән мөслимәләремезгә генә русча кием кирәк дигән сүзләремезне кую! Бетсен артка калуымызның сәбәпләрен ирләремездән, кәнеҗләремездән, остазбикәләремездән вә башкаларымыздан күрү!
Туганнарым, ханымнарым! Уйганыйк ничә мең гасырлар йоклап үткәргән һәлакәт йокыларыннан! Уйганыйк, уйганыйк һәм уйганыйк!
Хәмиятле каһарманнар түгеп, милләт өчен күп кан... илх*.

Яшь кәнежләремезгә бер сүз.
Яшь кәнежләремез! Хәзерендә сез татар агаларымыз илә күрешергә тотындыңыз. Ләкин яшь ханымнарыңызның хөрриятлекләре турысында бер кәлимә сүз дә ычкындырганыңыз юк.
Сез уйламыйсызмы без бер гасырда торачакымызны? Сезнең ишеткәнеңез бармы үлек илә тере адәм бергә торганын? Сез уйламыйсызмы бер укыган кыз җиде-тугыз укыган кәнеждән артык икәнен?
«Екетләргә җитмеш төрле һөнәр аз» дигән мәкальне яңлыш аңламыйсызмы?
Екетләргә җитмеш төрле һөнәр җитә, әмма кызлара җитмеш җиде дә аз, чөнки кызлар – киләчәк аналар. Анлар, үзләренең җиде-тугыз баласын тәрбия итеп, үзләренең белгәннәрен балаларына өйрәтәчәк адәмнәрдер.
Бетсен иске гасыр, яшәсен яңа гасыр!
Кем гаепле?

Хөрмәтле укучыларым! Әүвәлге мөтәфәррәкамнең башы «Кем гаепле?» улса да, бу мөтәфәррәкамнең дә башын, әгәр дә мөмкин улса, киләчәк мөтәфәррәкамнең дә башын «Кем гаепле?» куярга тырышырмын.
Хөрмәтле ханымнар! Кайбер ханымнарымыз артка калуымызның сәбәпләрен ирләремездән вә кәнежләремездән күрсәләр дә, мин үземезнең «Кем гаепле?» дигән сөалемә каршы, «Үземез гаепле!» дип җавап бирәм.
Ханымнар! Үземез гаепле дими, ни әйтәем? Чөнки түбәндә әйтелгән адәмнәрнең факт булган гаепләрен күрсәтүче юк. Әмма үземезнең гаепләремез барчамызга мәгълүм һәм дә барчамызның күз алдымызда.
Ханымнар! Мин ишеттем, һәм дә сез дә ишеткәндерсез: ирләремез вә кәнежләремез ноябрь вә декабрь числоларында ниндәен олугъ җәмгыятьләр ясап, үзләренең хаклары тугърысында сөйләшкәннәр. Әмма без, ханымнар, ирләремез җәмгыятьләрендә нә сөйләгәннәрен барчасын белеп, һәм дә заман кушылуның куәтлеген күрсәтсә дә, без һаман күземезне йомып тордык.
Ханымнар! Хәзерендә безгә дә кирәк җәмгыять1, һәм дә шул җәмгыятьләремездә ирләремез үзләренең җәмгыятьләрендә үзләренең хакларын аңлаган кеби, безгә дә шул җәмгыятьләремездә үземезгә кирәк булган мәктәп вә көтебханәләр тугърысында сөйләшеп, безгә дә үземезнең хакларымызны сорарга тиеш.
Ханымнар! Безнең араларымызда укыган ханымнар булмаса да, җәмгыятьләр күргән ханымнар күп. Сентябрь-октябрь числоларында дарелфөнүндә булган җәмгыятьләрдә һәрвакыт биш-җиде мөслимәне күрдем һәм дә «Яңа клуб» җәмгыятьтә иптәшем мөслимәләр икәнлеген әйтте.
Андаен җәмгыятьләргә барырга бәгъзеләремезнең ирләре дә тыйсын. Ләкин дарелфөнүндә вә башка җәмгыятьләрдә улган ханымнарны, әлбәттә, тыючы булмагандыр. Шулай ук шундаен җәмгыять күргән ханымнар, ун-егерме ханымны җыеп, анларга үз ишеткәнен сөйләргә зиһене җитми?
Шулай ук безнең арамызда хатын-кызга кирәкле улган сүзләрне сөйләүче ханым юкмы? Шуның өчен дә безгә кирәк җәмгыять! Безгә кирәк кушылу! Ләкин ул мәртәбәләрдә без аз вә көчсез булырмыз, әмма соңра бөтен шәһәрне, бөтен илне яктыртуымызның ихтималы бар...
Юк! Юк! Уку-язу вә җәмгыять күрмәгән ханымнар, мин сезне гаепләй алмаймын. Әмма гаеплимен шундаен ханымнарны, кайсылары, мин фәлән хизебтән, дип, күкрәкләрен сугып йөриләр.
Ах... ниндәен хәсрәт, ниндәен кайгы вә ниндәен хурлык, үземез гаепле ула торып, башка милләт ханымнары каршында башкаларымызны гаепләп торучылык!

1906

Кире фикер

Русиянең олугъ шәһәрләрендә һәм дә Казанда башка милләт ханымнары барчасы хатыннарның берләшү җәмгыятьләре һәрвакыт ясыйлар. Һәм дә безнең татар ханымнары да, йокыларыннан торып, «Казан мөхбире» гәзитәсенең берничә номерларында, хосусән егерме өченче номерында, хатыннарга берләшү кирәклеген яхшы гына бәян кыйлганнар иде1. Ләкин барчамыз шул яхшы фикерләрне укыймыз да, берләшсәк бик яхшы булыр иде диеп, гәзитәләрне өстәлгә куямыз. Алай булса да безгә берләшү өчен гәзитәләрдәге мәкаләләр җитмәс. Без мәкаләләр илә һич берләшә алмамыз. Чөнки һәрбер ханымның мәкаләсе башка-башка фикердә. Бәгъзе ханымнар «Безгә хәзерендә ун сум, биш сум алып укыта башларга кирәк, шулай итәргә кирәк, болай итәргә кирәк» диеп язалар. Ләкин, минем фикеремчә, андаен сүзләр барчасы карт ишан хәзрәтнең сүзләредер.
Шулай ук без хәзерендә бай кызларын гына укытырга тырышаекмыни? Шулай ук без фәкыйрьләр тугърысында уйламыйкмыни? Безнең бай кызлары, ун сум, биш сум биреп, әүвәл дә укыйлар иде. Безнең фәкыйрь кыз балаларымыз абыстайларга сәдака бирә алмаган өчен укый алмаганны, хәзерендә ун сум, биш сум биреп анлар ничек укысыннар? Шулай ук безнең фәкыйрәләремез әүвәлге кеби надан калсыннармыни? Без шул фәкыйрәләр өчен тырышмаекмыни? Хуш! Бай кызларын биш сум, ун сум акча илә укытып, без кайчан акча җыеп, кайчан мәктәп салырмыз? Шулай ук, мәктәп салыңыз диеп, байларымыздан сорап торырмызмы? Без байлардан сорамыйк. Байлар үзләре салсыннар, үзләре мөгаллимәләр яллап укыттырсыннар. Акча кайдан алырмыз соң? Менә акча кайдан алырга: мәсәлән, Русия халкыннан ясак вә гайре налог акчасы җиде йөз миллион җыела. Һәм дә Русиядә торгучыларның җидедән бер өлеше мөселманнар. Һәм дә халыктан җыелган акчаның да җидедән бер өлеше мөселманнар акчасы булырга тиешле. Хөкүмәт халыктан акча җыя. Ул акчаны кая куя? Дөресендә, хөкүмәтнең чиновниклары халыктан җыелган акчаның берничә өлешен югалтса да, берничә өлешен мәктәпләргә вә гайре урыннарга сарыф кыйлалар. Шул халыктан җыелган акча илә хөкүмәт ун дарелфөнүнне, берничә йөз ир вә кызлар мәктәпләрен тәрбияли.
Бу көннәргә кадәр утыз миллионлы мөселманнар өчен ике-өч дарелфөнүн, сиксәнгә якын ирләр вә кызлар гимназияләре булырга тиеш иде. Кайда соң безнең гимназияләремез һәм дә дарелфөнүннәремез? Анлар нә өчен юк? Безнең ул мәктәпләремез Гани агай, Гали агайны сез мәктәп салыңыз, диеп торган өчен юк. Шулай, мәктәп салыр өчен безгә балалардан акча җыярга кирәк түгел икән. Чөнки үземезнең акчамыз берничә мәктәпкә җитәрлек. Безгә хәзерендә хөкүмәттән мәктәп өчен акча сорарга тиешле. Хөкүмәт чиновниклары бу көнгә кадәр безнең бик күп акчамызны ашаганнар. Шул акчаларны безгә анлардан ашатмаска тиешле. Ул акчаларны без сорап алырга бурычлы.
Шулай, ханымнар! Үземезнең никадәр акчамыз була торып, саилчегә калырга җиткән халкымызны безгә таларга оят! Юк, без халкымызны таламыйк! Безгә үземезнең акчамызны алырга вакыт! Онытмаңыз! Без барчамыз ул акчаны сорарга бурычлы!!!
Бәгъзе ханымнар «Мин үзем фәлән дәрестән укытырмын, фәләнә-фәлән дәресне, фәләнә-фәлән» диеп язалар. Ләкин тел илә әйтеп, күңел илә уйларга кирәк. Һәм дә тарих, җәгърәфия һәм хисап вә гайре фәннәрдән укытып өйрәнмәгән ханымнар андаен фәннәрдән дәрес бирә башласалар, ничек булыр? Билгеле, әгәр дә, әйтик, тегүче күмәч пешерергә тотынып, күмәч пешерүче, әйтик, итек тегәргә тотынса, итекче – онны, күмәч пешерүче материяне харап итәр.

Безнең ханымнар яшь кызларымыз[ны] шулай итмәсләрме соң? Хөкүмәт безгә мәктәп салыр. Безгә, ничек булса да, тарих, җәгъръфия, хисап вә гайре фәннәр өчен гимназияне укып чыккан ханымнарны карарга кирәк була.
Бездә гимназияне укып чыккан ханымнар аз түгел. Иншалла, анлар да мөгаллимә булырга разый булырлар. Гимназиядән укып чыккан мөгаллимәләребез дә һәм ике-өч елдан укып чыгачак ханымнарымыз да бар, диеп ишетәмез. Әлхасыйль, мөгаллимәләремез хәзер. Итекчене күмәч пешерергә, күмәч пешерүчене итек тегәргә кушмасак та мөмкин. Шулай, ханымнар! Безгә мәкаләләр илә берләшү мөмкин түгел. Безгә кирәк җәмгыять! Җәмгыять ясаганда, безгә берьюлы йөз ханым җыярга мөмкин түгел. Әүвәл булыр биш-ун. Соңра көннән-көн артып, йөз-өч йөз булыр.
3 ноябрь манифесты ни бирә?

Безнең крәстияннәремезгә 3 ноябрьдә олугъ манифест булды. Шул олугъ манифестның файдасы яки зарары булачагын аңлар өчен, без рус тарихыннан берничә вакыйгаләрне укып караек: XIII, XIV һәм дә XV гасырларда кнәзләргә хезмәт иткән адәмнәр бояр диеп аталганнар.
Шул боярлар үзләренең хезмәтләре өчен Мәскәү падишаһларыннан җир алып, XVII гасырларда бөтен хөкүмәт җире боярлар кулында кала башлаган. Каю крәстияннәрнең җирләре аз улып вә каюларының һич улмадыкта, крәстияннәр боярлардан өч яки яки биш сәнәгә җир сатып алып, крәстияннәр җир хакын боярларга икмәк яки акча илә түләп торганнар.
Соңра боярлар Мәскәү падишаһларыннан крәстияннәргә хөкем итәргә права алгач, боярлар крәстияннәргә җир хакын (яки оброкны) никадәр теләсәләр, шулкадәр түләткәннәр. Әгәр дә боярлар сораган акчаны крәстияннәр түли алмасалар, боярлар крәстияннәрне шул җирдән җибәрмәскә хөкем итеп куйганнар. Боярлар крәстияннәрне акрын-акрын кыса башлаганнар. Һәм дә хөкүмәт тарафыннан крәстияннәргә боярлар илә хөкемләшергә мөмкин улмай торган законнар чыга башлаган.
Шулай итеп, боярлар крәстияннәрне бөтенләй үзләренең коллары итеп тойганнар. Крәстияннәр: «Без ник бу боярларга кол булып торамыз? Без нә өчен анларга буш хезмәт итеп, анларга һәр урында гаепле булып торамыз? Безнең бу җиремез ник үземезнең кулымызга бирелмәй? Бу җирне безнең аталарымыз, бабаларымыз үзләренең кыйммәтле җаннары, тәннәре вә тирләре илә тапмаганнармы? Безнең аталарымыз, бабаларымыз, шулкадәр каннарын түгеп, бу җирләрне алганнар; әгәр дә без аның өстенә акча түләп һәм дә кол булып торсак, безнең аталарымыз, бабаларымыз бездән ничек разый улсыннар?» – диеп, крәстияннәр төрле-төрле фикерләргә төшә башлаганнар.
Соңра 1860 сәнәдә, Русиянең һәр губерналарында крәстияннәр арасында төрле-төрле каршылыклар була башлагач, император Александр II крәстияннәрне бер колач җиргә боярлардан азат иткән.
Соңра хөкүмәт, боярлар илә килешеп, егерме миллион крәстиянгә йөз утыз миллион дисәтинә алпавытларның җирен бик кыйммәт бәһа илә сатып, шул җир хакын хөкүмәт крәстияннәрдән кырык тугыз ел эчендә алып бетермәкче булган. Ләкин крәстияннәр, азат ителенгән вакытта егерме генә миллион улып, хәзерендә йөз миллионнан артык булсалар да, кырык дүрт ел эчендә крәстияннәргә бер дисәтинә дә җир бирелмәгән.
Безнең крәстияннәремез вакыйгъдә азат улдылармы? Юк, юк! Анлар азат улмадылар. Хәзерендә безгә бик яхшы күренеп тора: анлар азат ителмәгән. Фәкать бер хуҗадан икенчесенә генә күчкән. Безнең крәстияннәремез боярларга түли торган оброкларын яңа хуҗаларына түләгәннәр һәм түлиләр. Крәстияннәрнең әүвәлге хуҗалары урынына куәтле, көчле хуҗалар пәйда булган. Крәстияннәр җәберләргә түзделәр.
Бик озак түзделәр, йөз миллионлы крәстиян йөз утыз миллион дисәтинә җиргә ничә еллар сабыр вә канәгать иттеләр.
Әмма бәгъзе боярлар, җирләрен крәстияннәргә сатуны һич уйламыйча: «Безгә, берничә мең адәмгә, йөз утыз миллион дисәтинә җир аз, безгә ашлыкны яхшы уңдырырдай җир

кирәк», – диеп, берничә гакылга таманрак булган чиновникларымызны котыртып тордылар. Боярларның планнары да бушка китмәде. Менә шул берничә чиновникларның сүзләр илә 1904 сәнәдә һич кирәкмәгән җир өчен хөкүмәт япуннар илә сугышка тотынды. Ни өчен без япуннар илә сугышырга тотындык? Япуннар безгә бер-бер зарар китерделәрме? Бәлкем, без япуннарга бер-бер зарар китереп, анлар сугышырга тотындыларммы? Юк! Без, крәстияннәр, япуннарга һичбер зарар китермәдек, һәм дә аларның зарары безгә тимәде, хәтта япун дигән сүзне сугышка кадәр ишеткәнемез дә юк иде.
Юкса безнең җиремез юкмы?
Безнең җиремез күп, ләкин җаннарымыз, тәннәремез илә тапкан җиремезнең күбесе халык кулында түгел.
Бер ел сугыштык, бер ел кан түктек, әмма җиңүнең исе дә килмәде.
Халкымызның җире артмады! Халкымызның недоимкасы көннән-көн артты, халкымыз көннән-көн кысылды, халкымыз көннән-көн фәкыйрьләнде.
Крәстияннәремезгә җир аз!
Сачкән ашлыклары ашарларына җитмәй. Халык, ачка зарлана-зарлана, озын елларны үткәрәләр. Алай булса да һәр эшләрен, аталарына тапшырган кеби, чиновникларга тапшыралар иде. Ләкин сугыш халыкның күзен ачты. Халык, үзләренең чиновниклары аркасында голүм, мәгърифәт җәһәтеннән иң артка калганлыкларын һәм дә чиновникларының да бер эшкә ярамаганлыкларын сизенеп, 9 гыйнвар көненнән бирле хөкүмәт эшенә халык үзе катышуны тели башладылар. Шул көннән бирле олугъ Русиянең һәрбер губерналарында рабочийлар эшләрене ташлап, крәстияннәр хәрәкәткә килеп, төрле вәҗһе илә һәр сәгать саен хәзерге хәлгә разый улмадыкларын аңлаталар.
Чиновниклар буны бик яхшы аңладылар, ләкин үзләренең икмәкләрен югалтасылары килмәенчә, төрле вәгъдәләр биреп, рабочийларның разый улмакларын теләделәр. Шуннан соң рабочийлар бераз хәл җыярга теләсәләр дә, чиновниклар, бәхетсезлекләренә каршы, бөтен Русия халкы, аякларына басып, үзләренә файдалы улган төрле-төрле нәрсәләр сорый башладылар.
3 ноябрьдә крәстияннәрнең ясакларын бераз киметергә, 1906 ел башыннан ясакның яртысын гына алып, 1907 сәнәдә ясакны бөтенләй алмаска вәгъдә кыйлынды. Аз җирле крәстияннәргә җир алыр өчен банкылар акча бирүне вәгъдә кыйлды. Җир алыр өчен безгә банкы акча биргәч, безне, Александр II вакытындагы кеби, бер хуҗадан чыгарып, икенче хуҗага кертмәсләр микән?
Дума, Дума, Дума

Гәзитәләрдә һаман бер балык башын чәйниләр, һәрберсендә Государственный думаны язалар дип, һәмишә бу мәсьәлә тугърысында язудан туйган кешеләр ишетелгәлидер. Һәрнәрсә һәр эш вакытына карап була. Тимерне кызуында сугалар. Бу вакытка кадәр язылганнар йөз мәртәбә, мең мәртәбә язылса да, һәмишә аз, һәмишә җитми, һәмишә халык аңгарып җитә алмый, һәмишә халык эшкә тотына алмыйдыр. Февраль башына кадәр бер ай эчендә избирательләрнең санын, сайлау эшенә катышырга теләгән кешеләрнең хисабын җыйдылар, шул вакытта да кайсы берсе, мондай үз кесәсенә файда килми торган эшкә вакытын уздырасы килмәенчә, иренеп, бер-ике адым җиргә барып, үзенең сайлау эшенә катышасы килгәнлеген белдермәенчә, игълан кыйлмаенча калдылар. Бәгъзе берләре, наданнарның котыртуы вә үзенең наданлыгы сәбәпле, анда әллә нәрсәгә кул куйдыра торганнардыр, кулың кайда булса, башың шунда дип, бөтенләй кире торучылары да булгалады. Инде ни булса да булды. Тәгаен кыйлынган вәгъдәсе узды. Буннан соң никадәр үкенсәң дә, файдасы юк.
Аңлаган кешеләрдән азмы-күпме барып язылгалаган кешеләр булды.
Хәзердә киләчәк көннәремезне исәпләргә вакыт җитте. Бу язылган кешеләр, сайларга хакы булганнар, бер көн булыр, әлбәттә, сайлау эшенә катышырлар, ягъни сайлаучыларны сайларлар1.

Бу беренче сайлауда кемнәрне сайлаячакмыз, анлар ниндәй кешеләр булачак?
Беренче, өченче, дүртенче частьлардан2 мөселманнан берәр кеше сайлата алырмызмы? Икенче, бишенче, алтынчы частьлардан3, мөселманнарның күбрәк булган җиреннән, мөселманнардан ничә кеше сайлата алачакмыз? Вә анларның кемнәр булуын халык мәгъкуль күрәләр? Әгәр дә бу сайлаучыларның күбрәген мөселманнан сайлата алмасак, ул вакыт хәлемез ничек булачак, ул безнең ышанып шар салган4 кешеләремез үзләренең кулларында булган шарларны кемгә салачаклар? Казаннан ниндәй кешене Петербургка җибәрәчәкмез? Ул җибәрәчәк кешемез кайсы партия кешесе булачак? Мөселманнарның, гаммәнең файдасын кайгыртачак кеше булачакмы? Ул кешемез бергә кушылган «Унҗиденче Октябрь»5, «Торгово-промышленный партия»ләренең6 башларында йөри торган итекче Софроновмы? Яхуд Карякинме? Әллә бер дә булмаса (шуны сайлаңыз, бик яхшы кеше ул дип, игъланнар бастырып таратылган), «Русь православная самодержавная» гәзитәсенең мөхәррире А.Т.Соловьевны7 сайлыймызмы? Яисә «Царский-народный партия»8 башында йөри торган профессор Залесский9, яхуд Соколовскийнымы10? Моннан башка «Конституционная демократическая партия»11 тарафдарлары профессор Шершеневич12, адвокатларда Бать13, Венециановлар14 да бар.
Шунлардан берәрсен сайларгамы?
Әгәр, үземезнең мөселманнан булдырырга тырышырга кирәк дисәк, Петербурга барырга яраклы Сәедгәрәй мирза Алкин15 бар. Кулымыздагы шарларны шуңар салыйкмы?
Бу тугърыда иҗтиһад итәргә бик вакыт. Мөселманнарның файдасын үзләре кадәр, әлбәттә, һичкем белмәүчелеге билгеледер.
«Үзеңнеке – үзәктә, кешенеке – кештәктә» дигән бер мәкаль бар, бик тугърыдыр.
Шуның өчен үз эшемездә үземез иҗтиһад кыйлу бик тиештер.
Бер Казан берлә дә эш бетми, әтрафтан киләчәк вәкилләр арасында да мөселманнарны күбрәк сайлатырга вә, алардан да аз булганда, бер-ике кешене Петербурга җибәрергә тырышырга тиешледер. Казан, Уфа, Самар кеби мөселман күп булган җирләрендә без күбрәк вәкилләр җибәрә алмасак, Думада мөселманнарның тавышлары бик аз булып, һич тәэсире калмас.
Заман – хокукымызны үземез мөхафәзә кыйлырга лязим булган замандыр

Хокукны сакларга һәркем үзенең инсаниятгә улан хокукыны белмәенчә булмайдыр. Аны белмәк ләкин гыйлем вә уку берлән генә хасил буладыр. Гыйлем вә уку да мәктәп вә мәдрәсәләргә йөрү берлә буладыр, һаман укытучыга мохтаҗ буладыр. Мәктәп, мәдрәсә вә укытучы, мөгаллим, мөдәррисләремез әгәр дә яхшы, мөкәммәл булса, укуымыз да яхшы буладыр. Әгәр дә начар булса, укуымыз да начар улып, хокукларымызы белмәгемез дә бик зәгыйфь булып, һич тә мәхафәзә кыйла алмамыз. Чөнки мәктәп, мәдрәсә, мөгаллим вә мөдәррисләремез – укуның коралыдыр. Корал начар булса, аның берлән эшләнгән эш тә начар булмагы табигыйдер. Имди бакалем мәктәп, мәдрәсә, мөгаллим вә мөдәррисләремезнең хәленә: әүвәлән мәктәп вә мәдрәсәләремезне ислях безгә лязим вә вөҗүбтер. Чөнки исляхка гаять тә мохтаҗлардыр. Мәктәп вә мәдрәсәләремезнең мөкәммәл булмадыгы сәбәпле, мөгаллим вә мөдәррисләремез дә зиммәләренә лязим булган эшне кәма йәнбәгый әда кыйлудан гаҗизләрдер. Чөнки мөгаллим вә мөдәррисләремезнең кәсире, мәктәп вә мәдрәсәләрнең җәһәте тыйббиясе төзек улмадыгыннан, сәламәтлекләре зәгыйфь, төрле әмраз илә мөбтәляләрдер, хосусән йөткерүчеләрдер.
Икенче, гомумән мөгаллим вә мөдәррисләремезнең мөгайян программасы улмадыгыннан һәм дә эчендә укылган фәннәрнең күбесе дөнья вә ахирәткә файдасы улмай торып та, ул фәннәрдә тасниф ителгән файдасыз китапларны укыган булып һәм дә анларга безнең мәдрәсәләремездә дин гыйлеме генә укыла дип ялганнан исем куеп, биһүдә унбиш-егерме сәнә гомерне тәзйигъ вә сарыф кыйлудан гына гыйбарәттер. Имди без мөселманнар берләшеп иҗтиһад кыйлышырга да лязим вә фарыз булган гыйлемнәрне тәхсыйль итеп, һәммә мөселманнарның вә ахирәт сәгадәтенә сәгый вә иҗтиһад идәлем, соңра да һәммә хокукларымызны белеп, мәхафәзәсенә дә чалыйшалем! Мәктәп вә мәдрәсәләремезне,

тәгассыбны ташлап, һәммәмез берлектә иттифакъ берлә мадди вә мәгънәви ислях идәлем! Бу хосуста «Азат»ның мәкъсуды: бикадәри әт-тәкать кай тугърыда носканаты барлыгын тәфсилән күрсәтеп торып, исляхына гыйлаҗларыны эзләмәктер. Аллаһы муафикъ әйләя! Иннәһү хәйрү муаффикыйн вә могаййин*.

Кнәзләр заманында истикъляль

Әүвәлге вакытларда гарәб, грек, рус вә башка төрле кавемнәр һәрберсе, үзләренең хөкүмәтләре эченә бае-фәкыйре, ярлысы-купецы бер җиргә җыелып, солых, сугыш тугърыларында киңәш итеп, ягъни һәрберсе үзенең фикерен сөйләп һәм дә шул җыелган урыннарында һәрберсенең ризалыгы илә үзләренә кнәз сайлап, үзләренә файдалы булган законнар төзеп, һәрбер вилайәтләрендә халык төзегән хөкем илә хөкем иткәннәр.
Шулай әүвәлге вакытларда халык үзләре, бергә җыелышып, үзләренә хөкем төзегәннәр һәм дә кнәз сайлаганнар.
Әгәр дә халык илә төзелгән хөкемгә бер-бер адәм каршы килсә, аңарга каты җәза булган. Әгәр дә кнәз халык теләгән вә кушкан эшне эшләмәсә, ул кнәзне шул көндүк тәхетеннән төшереп, аның урынына икенче бер адәмне кнәз итеп куйганнар.
Соңра, халык кнәзгә иркенлек бирә башлагач, кнәзләр үз угылларыны кнәз итеп куя башлаганнар. Шул тарика кнәзләрнең хөкеме йөри башлагач, гректан укып кайткан папаслар да халыкны буйлә өйрәтә башлаганнар: «Һәрбер өстенлек – Ходадан, һәрбер өстенлек Хода илә өйрәтелгән, шуның өчен дә өстенлеккә каршы килгән адәм Ходага каршы килә. Ходадан куркыңыз, кнәзне олугълаңыз, олугълаңыз кнәзне! Әгәр ул иң начар адәмдер, начар улса да, чөнки шундаен кнәзләрне Хода халыкның гөнаһысына күрә күндерәдер».
Папасларның шундый сүзләре Мәскәү кнәзләренә бик татлы улып, үзләре дә гректан укып кайткан папасларны олугълап ала башлаганнар. Чөнки анлар һәрвакыт анларның файдаларына тырышканнар.
Соңра кнәзләр, тамыр җәя башлагач, татар ханнары кеби, үзләренең хөкүмәт эшләрен халык илә бергә тәкъсим итәселәре килмәенчә, берүзләре хөкем итә башлаганнар. Кнәзләр ныгып җиткәннәр. Әүвәлге вакытларда кнәзләр: «Мин халыкка тугърылык илә хөкем итәрмен», – диеп ант биргәннәр, хәзерендә Мәскәү кнәзләре мөстәкыйль булгач, ягъни хөкем эше үзендә була башлагач, мин халыкка тугърылык илә хөкем идәрмен диеп ант итмәй, халык: «Мин кнәземез хәзрәтләренә бер кашык каным калганчы тугърылык илә хезмәт итәрмен», – диеп ант итә.
Берничә сәнәләрдән соң Мәскәү кнәзләре үзләрене «Алланың мәрхәмәте илә хөкем сөрүче» диеп атый башлаганнар. Алай булса да Иван IV1 вакытында бу эшләргә адәмнәр бик разый улмаенча, аңар каршы чыгып, үзләренең куәтләрен күрсәткәч, Иван IV халыкның аягына егылып, халыктан ярлыкауны сораган. Һәм дә халыктан вәкилләр сайларга кушкан. Ләкин халыктан килгән вәкилләр хөкүмәт эшләрен бер дә карамаганнар, чөнки халыктан сайланмыш вәкилләр күбесе байлардан вә боярлардан улдыгыннан, һичберсе дә халык файдасын карамаган. Хөкемдар һәм аның назыйрлары ни әйтсәләр, шуңар риза булып, анлар каршысында әттәхияткә ултырган адәм кеби, ике кулларын тез өстләренә салып тик торганнар.
Соңра Иван IV, халыкта куәт беткәнен сизенеп, аның законына каршы килгән адәмнәрнең башларын кистерә башлаган.
Хөкүмәткә каршы адәмнәрне белер өчен, хәзерге атлы казаклар кеби, Мәскәү урамнарында атлы казаклар йөреп, шул казаклар Иван IV кә «фәлән шөйлә-буйлә» диеп нә ялганласалар да, Иван IV һич гөнаһсыз адәмнәрнең дә башларын кистергән.
Шул Земский Собор2, янә Екатерина II вакытында да бер мәртәбә булып, ул вәкилләр эченнән Екатеринаның яратмый торган адәмнәре – папас вә башкалар барга, крепостной крәстиян сораганы һич булмаган.
* * *

Иркенчелек кадәр дөньяда дәхи дә бер тәмле, ләззәтле нәрсә бар микән? Бу ләззәт безнең Казанда 19 октябрьдә1 иде. Ул көн һәркем үзендә бер шатлык, бер җиңеллек табадыр иде. Чөнки ул көндә падишаһ хәзрәтләренең биргән иркенчелекләре тәмам җирендә иде. Һәрбер төрле кысанлыклар беткән иде. Манифестта диндә, басмада иркенчелек, иттифакълар, җыеннар ясарга ихтыяр бирелгән, кешенең үзенең иркенлеге бәян ителгән иде. Бердән-бергә тарлыклардан котылган халык сөенеченнән ни эшләргә дә белми иде. Кешенең йөзендә нурлар балкып тора иде. Халык тәмам рәхәттә иде, шатлыгыннан ашавын, эчүен, сатуын тәмам оныткан иде.
Бу шатлыклар кешенең хыялында һәмишә йөридер. Төшендә тәмле тәгамнәр күреп уянып киткәч, янында күргән нигъмәтләре булмагач, яңадан күзен йомып, кулын сузып яткан Хуҗа Насретдин шикелле, халык та: «Бу күңелле, бу рәхәт көннәр яңадан кайтыр микән?» – дип, һәмишә нәфесен сузып йөрмәктәләрдер.
Бу нигъмәтләр бу кадәр тәмле көенчә кулымызда бик аз торды. Шикәрле дигән нәрсәләремезгә тоз катышты.
Падишаһ хәзрәтләренең бу кадәр әгъля нәрсәне безгә һәдия итүенә эчләре пошкалаган кешеләр булды. «Тәңре малын шайтан кызганган» дигән төслерәк булып китте, фәкыйрьгә бирергә кушкан нәрсәне үзенә алып калып, үзенең артыгын гына фәкыйрьгә биргән приказчик шикелле булды. Бирелгән хөрриятләргә никадәр шәрехләр иттеләр, хөррияте дин, иҗтимагъ вә иттифакълар өчен никадәр шартлар куелды. Бу көнгә кадәр падишаһ хәзрәтләренең биргән нәрсәләрен һәмишә барсын да халыкка тапшырып бетерә алганнары юк. Инде, бәлки, бераздан хөррияте шәхсияне бирерләр, тапшырырлар. Ансын ни төслене бирерләр. Хәзергә мәгълүм түгел.
Соңра нәүбәт китапларымызга каладыр. Китаплар басуда иркенчелек ни рәвештә булачак? Бичара безнең бәгъзе бер цензорның кәефе өчен генә корбан ителгән, һич гаепсез, нә сәясәт вә нә диянәт җәһәтеннән асла гөнаһсы булмаган мескен «Бәдәвам»2 вә «Тәкый гаҗәб»3ләремез яңадан беркөн терелерләр микән? Яңадан терелеп кайтканын күреп, дустларының шатланганын күрермез микән? Бу көнгә кадәр җәмигъ китапларымызның гомере, җаны бер кешенең кулына тапшырылган иде. Ул кеше, теләсә, китапларымызга дөнья йөзен күрсәтә, теләмәсә, мәңгегә «архив» исемле зинданына салып куя иде. Котылып чыкканнарының да әксәре кызыл каралар илә мәҗрух булып чыга иде. Петербур цензорының кызыл карасыннан кәләме кадимнәремез дә котылмады.
Башкаларына кыйлган тәҗавезләре генә җитмәгән шикелле, Коръәнемезгә кадәр җөрьәт итә башлады. Бу көндә дә Коръән Кәримнең бөтененә тәҗавез кыйлмаса да, кәләме шәрифтән алынып китапларга язылган аятьләр һәмишә золымыннан котылганы юк. Гүя, аның фикеренчә, бу бозылган аятьләр насарый дине өчен хурлык, имеш. Ул тәкъдирдә безнең исламның бөтен әсасе диярлек насарый диненә хилаф. Димәк ки, асыл максаты, бөтен әсасе исламны дөньядан бетермәк икән. Хәзердә кәләме кадимне бастырырга рөхсәт бирелә дә, ни өчен аның тәфсирен басарга ярамый?
Хөсәен хәзрәтнең4 «Тәфсире фәваиде» бер мәртәбә басылган иде, ансы бетеп, икенче мәртәбә рөхсәт сорарга җибәргәч, тәмам арыды. Садыйк хәзрәтнең5 тәфсире әүвәлге мәртәбәсендә үк тәмам тыны да чыкмады. Коръәннең гарәпчәсен укырга ярагында, тәрҗемәсен ник белергә ярамый икән?
Бу эшләр һәр кешегә мәгълүм булган шикелле, басмада иркенчелекнең дә безнең өчен кирәклеге бик заһирдер. Җәнабе Хак тиз көндә насыйп әйләсен!
Белек һәм тереклек

Белек берлә тереклек арасында ни мөнәсәбәт бардыр? Ушбу сүзнең җавабында, әлбәттә, «Белек – тереклеккә ярдәмчедер» дигән сүзне ишетәсемезгә күңелемез инанадыр. Әмма «Белек эштән биздерә», «Укыган бала атасына эшче түгелдер», «Укыган кеше – чукынган кеше» дигән сүзләрне дә ишетергә тугъры киләдер. Бу соңгы сүзләрне гавамның белеккә каршылыгыннан, аның фикеренең кыйшыклыгыннан дип кенә исәп итсәк тә, төбендә гавамның бу сүзләре төпсез вә нигезсез үк түгелдер.

«Укыган кеше атасына эшче түгелдер». Буңа барчамыз да канәгать итәмез. Ләкин укыган кеше, атасына йомыш кыйлмаса да, үзенә яхшы кыйла, вә атасына да изгелек иткәннәре бардыр. Һәрхәлдә, укыган кеше укымаган кешедән бәхтиярдыр дигән игътикадымыз бәхәс кабул итмәслек булып күңелләремезгә урнашкандыр.
Без бу тугърыда фикерне төпкәрәк салып караек вә бу сүзләрнең мәгънәләрен ипләбрәк тикшерәек; безгә табыш булыр: без укуны бер кабат өчкә бүлеп куялым. Бер төрле уку бардыр ки, ул укуны укыган кеше, башкаларга ярдәм вә йомыш кыйлып, үзе дә бәхетле чыгар. Мәсәлән, мәктәп укытучысы – дәрес әйтүче кеби...
Янә бер төрле уку бардыр ки, ул укуны укыган кеше башкаларга йомыш кыйлмас, бәлки уку аркылы үзенең фикерене үткәргән, вә зиһенене шаярткан, вә шомарткан булыр; вә үзенең шомалыгы илә укымаган вә шомармаган кешеләрне ота белер, вә анларның эшләп вә мәшәкатьләнеп тапкан табышларыны үзенә таба тарта белер. Мәсәлән, мәхыз көн итәр өчен указ алган муллалар вә укып та мулла булмай калган мәхдүмнәре кеби. Бу нәүгъ уку укыган кешенең үзенә табыш бирсә дә, төбендә дөньяның төзеклегенә вә халыкның бәхтиярлыгына сәбәп түгел, бәлки күп кемсәләрнең бәхетсезлегенә сәбәптер. Чөнки бу нәүгъ белеклеләрнең бар һөнәрләре оту (алдау) вә башкаларның талканлыкларын да үзенә тартудыр.
Укуның өченче бер төрлесе дә булыр ки, ул укуны укыган кеше үзенең эшене төгәлрәк вә яхшырак кыйлыр, вә аз имгәк берлә күп табыш күрер, әмма табышны кеше кулыннан тартып алмас, Тәңренең хәзинәсеннән чыгарып алыр; мәсәлән, игенчелекне укып, иген игәр, багъчәванлыкны укып, бакча ясар.
Безнең торган җиремез булган Русиядә халык, мотлакан, тәүге укуларыны гына укыйлар; ягъни, кирәк, рус, кирәк, татар булсын, яхшы эш эшләр өчен укымай, бәлки башкаларны ота белер өчен генә укыйдыр. Буйлә булганда, «Белек эштән биздерә», «Укыган кеше – чукынган кеше» дигән сүзләр кирәгенчә мәгънәле һәм төпле чыгалар.
Нәтиҗә. Башка милләтләр табышны үзләренә тартыр өчен укыгач, безгә дә, «эт тешенә – эт теше» диеп, анлардан алдатмас өчен, бәлки анларны отар өчен уку, әлбәттә, лязим буладыр. Ләкин башка милләтләргә каршы торыша алмай, ялгыз үз халкымызны отып бетерергә генә уку, әлбәттә, аздыр.
Мадам ки, милләтләр бер-берсене изеп, юк итмәк арзусыннан ваз кичмәюрләр, безгә кем мокабәлә кыйлышырлык корал лязимдер. Аның өстенә эшләрне беркатлы кыйла торган зирагать, багъчәванлык укулары мәйдан алса, бердән, руслардан узар идек, икенчедән, «Укыган кеше – чукынган кеше» дигән сүзләргә урын калмас иде. Мәсьәләнең төбе тирәндер.

## Табышлы талаш

Ышанычлы заттан ишетүем буенча, Бөгелмә тирәсендә муллалар зарарына бәгъзе бер кагыйдәләр (прокламация) таралган. Әнә шул кагыйдәләр буенча, гавам халкы, үзләренең имамнарына инабәт итмәс булып муллалар безне сата икән, безне түрәләргә чагып, үзләренә акча алалар икән, бу теге икән, бу икән, дию аякланганнар.
Әлмәт ярминкәсендә муллаларга бик кызу килгән. Хәтта бәгъзе авылларда муллаларын кыйнаганнар да!.. Хасыйль катлам, гомумән, муллалар, гавамның аралары кирәгенчә ачылган. Бу хәбәрне сөйләтүче бу эшкә үкенеп вә хафа булып сөйләде. Вәләкин бән фәкыйрь бу талаштан бер табыш үмәнәмен, чөнки гавам мулланы ригая кыйла-кыйла, мулла илә гавам тату тора-тора, һәр ике як тәмам эшкә яраксыз булып куркакланганнар иде. Һичбер төрле тавыш вә дәгъвалаш юлына кермәс булганнар иде. Хәлбуки тәбәдделате сәясия көннәрендә вә хәрәкәте сәясия мизгелләрендә кеше талаштан анча куркак булырга тиеш түгел. Табигый, бераз рәхәтсезлеккә вә кычкырышуга көчләнү кирәктер. Муллалар илә гавам талашырлар да, килешерләр дә. Бундай вакытларда вак-төяк эшләр генә була да, кичә дә. Бунда исә табышлы булганы – тик тормауга үгрәнүдер.

Килер заман, ул заманда тик тору вә тавышка катнашмау хәрам булыр. Һәркем вә һәр мәхәллә, һәр кавем үзенең икътисади вә сәяси арзуларына иярмәк өчен аякланыга вә талашуга мәҗбүрият күрер. Әнә шул көннәр өчен бер микъдар ирлек вә баһадирлык, вә җаучылык мотлак лязим булачактыр. Һәр шәр һәр хәердән хали түгел. Ягъни һәр явызлыкта бер изгелек бардыр. Тавыш-талаш үзе мәгъсуд түгел исә дә, тавыш-талаш бәгъзе мәкъсудларны тәхсыйль өчен юл вә коралдыр. Бераз булганы да ярый.

Тугъры мәкъсудка әйләнгеч юл берлә җителсә дә ярар

Яки әйтәек: «Мәкъсуд тугъры булса, аңа ирештерүче әсбабларның кыйшыклыгы кичереләдер».
Күп чагында төрле фирка вә төрле хизеб, бер үк мәкъсудка җитәр өчен, төрле әсбабка тотыналар. Вә шулай итеп бары нәзарда бер-берсеннән аерылган төрле фиркаләр зоһур итә, вә бу фиркаләрнең көнләшеп талашкан чаклары да күп буладыр. Хәлбуки, ипләп вә төпкә төшеп караганда, фиркаләр арасындагы талаш-низагы ләфзы дигән бер акылсыз талаш булып чыгадыр. Бу тәфтишне бән хосусый мәкъсуд сартын гына әйтмәймен, бәлки берничә мәкъсуд сартын бердән әйтәмен. Менә, мәсәлән, хәзерге сәяси кузгалышларга күз салаек: безнең Русия мөселманнарыннан ук бары нәзарда (өске карауда) берничә фирка килеп чыкты. Бу фиркаләрнең берсе иске ысул вә карт хөкүмәтне яклый вә шул искелек күләгәсендә дин вә диянәтне дә үзгәртүдән сакламак була. Бунда мәкъсуд исә әллә ниткән бер милләтнең нигез вә төбене саклап асрамак түгел, бәлки үзгәртергә ярамаган динне үзгәртмәй тотуга сәбәп булганлыгы (?) өчен ул милләтнең иске нигезе якланадыр. Ләкин бу фирканең мәкъсуды тугъры булса да, юлы яңлыш булмак ихтималы бардыр.
Мөселманнардан ук килеп чыккан фиркаләрнең янә бертөрлесе, «һәр эшнең уртачасы изгедер» дигән асылга тотынып, сәяси хизебләрнең уртачасына кушылалар. Бунларның да мәкъсуды шул ук бернәрсә, ягъни дин вә диянәтне үзгәртүдән сакламактыр. Чөнки: «Ул әллә ниткән милләт, бу көнгәчә дин вә диянәтне саклап асраса да, үз ирке берлә асрамады, бәлки үзгәртергә кулыннан килмәгәнгә калдырды. Бундан соң иске көч вә иске ысулында калса, әлбәттә, үзгәртер», – диярләр.
Мөселманнардан ук азатлык вә тигезлек фиркасе дә бардыр. Бунлар диярләр ки: «Иске хөкүмәт иске көче берлә калса, әлбәттә, үзенең сәяси планы буенча мөселманларның диянәтләренә тиячәк. Әгәр урта хизебнең дигәннәренчә, хөкүмәтнең көче вә эше чикләнеп куелса да, эш башында утырган иске хөкүмәт бу «чик»ләрне юк итеп кенә иске көчене кайтарачак. Бәс мәкъсудка җитү өчен, ягъни дине исламны саклап асрау өчен, нигезне үзгәртүдән башка чара юктыр».
Мәкъсуд бер булып та, мәкъсудка ирдергән әсбабның башкалыгыннан гына туган әхзаб, хосусый моталәбе сәясиаттә генә түгел, бәлки хосусый вә гади эшләрдә һәм бер-береннән аерылып талашкалыйлар. Менә, мәсәлән, кием-салым.
Бер фирка, иске кием саясендә динне искечә саклау касдын кыйлып, яңа кием вә яңа тотышларны тоткын кыйладыр. Дигәр фирка исә, дин һич үзгәрмәс бер нигездә корылганлыгыннан, кием вә торыш үзгәрүләренә генә һич биренмәй һәм бирешергә тиеш тә түгел дип, динне бигрәк нык вә бигрәк ышанычлы бер мәртәбәгә куялар.
Нәтиҗә. Бәнем бунда әйтәсем килгәне будыр ки, бундай фирка вә әхзабның киң юлда булганнары алдарак вә белеклерәк булырлар. Әмма болай фирка вә хизебләргә аерылып талашудан дәхи киңрәк бер юл бардыр ки, һәр фиркане алып, һичберсене какмай, һәрберсене мәкъсудка күндерү юлыдыр. Ул юл исә һичбер фирка илә шаярылмай вә көчләтелмәй тугъры мәкъсуд илә чын ихласдан аңлашу юлыдыр.

Кыргыз1 илә татар

Татар илә кыргыз арасында хәзер дә бер нәүгъ аермалык бар исә дә, бу аермалык бик аз улып, ике кавем бер-берсенә бик якындырлар. Татарның нан йимәке вә мунча кермәке

кыргызга да хуш киләдер. Шуның өчен кыргызлар татарда татарча кунак булырга бик яраталар.
Ушандак кыргызның киез өе, күчә-күчә ит ашап йөрмәке татарга бик килешәдер. Татар бер кабат кыргыз җиренә чыгып йөрсә, җаны-тәне берлә кыргызга биреләдер. Үзенең өенә кайткач та, кыргызча утыра, анынча әңгәмә суга, анынча согындырышадыр. Дин вә иманны кыргызлар татардан үгрәнгән кеби, тел вә гадәтне татар кыргыздан үгрәнәләр.
Бу сүз гаҗәп тоелмасын! Оренбур, Җаек, Троицки кеби кыргыз берлән күп катнаша торган шәһәрләргә баргач игътибар итсәк, күрерсез ки: татарлар кыргыз мәкальләрене әйтә-әйтә иңемә сугалар. Кыргыз кеби вәкарьле вә аһәстә булалар. Кыргыз кеби вәкарьле дигәнемез кинә гаҗәп тоелмасын: кыргызлар бик ипләп, бик исәпләп сөйләшәләр. Кыргызның сүзе, сохбәте һәркайчан хәкиманә вә кәбиранә буладыр.
Фәсахәт вә бәлягать бабында кыргызлар татарлардан кат-кат өстендер. Фәкать кыргыз әдәбияты язылып, әдәбият базарына кермәгәндер. Әгәр дә кыргыз әдәбияты, аз-аулак эшләнеп әдәбият базарына куелса, татарларга кыргыз әдәбияты берлән шөгыльләнеп аңлашмак тиеш булыр.
Безнең мәктәпләр хәзергә кадәр шунча фәкыйрь вә юксылдыр ки, безнең мәктәпләрдә төрек әдәбияты вә кыргыз әдәбияты улмак торып торсын, хәтта татарның үз әдәбияты да укылмайдыр. Көйләп «Мөхәммәдия» вә «Әхмәдия»2 уку, әлбәттә, әдәбият уку дәгелдер.
Чыгътай төркисенә бу көнгәчә исәп тоткан берничә данә газиз китаплар бардыр ки, бу җөмләдән Насретдин Рабгузинең «Кыйсса...»сы3 вә Заһретдин Бабурның «Бабурнамә»се4 вә бундан башкалардыр.
Бәс мәктәпләр төзелгәндә, мәктәпләремездә үземезнең чыгътай төркисе кергәндә, төрек вә кыргыз әдәбияты да керсә, бик гүзәл булыр иде.
Кыргыз әдәбиятыннан хәзергә Акменла5 мәрхүмнең рисаләләре һәм Әбүбәкер мелланың рисаләләре6 һәм башкалар да бардыр.

## Фас мәмләкәтенең кызганыч хәлләре

Фас мәмләкәтенең Яурупаның мәгъмур мәмләкәтләре өчен тешкә йомшак-татлы бер нигъмәт урынына каим булганлыгын вә бундан тәнавел итү өчен, вакыты килгәндә, һәрберсенең тамгысы бар икәнлеген гәзитә укучылар, шаять, бу көнгә кадәр барысы да белгән булсалар кирәк.
Яурупалылар өчен файдалы рәвештә бундан бер-ике һәфтә мөкаддәм бу Фас мәсьәләсенең хасыйль ителгәнлеген дә һәркем ишеткән булса кирәк. Яурупаның милке булып беткән бу мәмләкәт һәмишә үзенең йоклавында дәвам итмәктәдер. Күз алларына никадәр вакыйгаларне китереп күрсәткәннән соң да, һәмишә бунлар ул эшләргә инанырга теләмәйләр, даим үзләренең тәгассыбларында даимнәрдер. Мисырда нәшер ителмәктә улан мөгътәбәр «Төрек» гәзитәсенең Фас мөхбире Фас тугърысында түбәндәге сүзләрне язмактадыр:
«Фаста шулкадәр гаҗәеп эшләр бардыр ки, анларны зикер итү, шаять, файдасыз булмаса кирәк. Кешегә кыска гына булса да бер фикер бирер. Мәсәлән, монда, мәтбага ачып, акча табарга мөмкин булса да, хезмәт итә алу өмидләре бик зәгыйфьтер. Күп кеше мәтбаганы бидгатькә саныйлар. Бунда (ягъни мәтбагада) насарыйларның катышы бар дип уйлыйлар. Бер гәзитә басу да мөмкин түгелдер. Истанбул өчен «динамит» дигән сүз никадәр куркыныч бер сүз исә, бунда да гәзитә дигән сүз шулай уктыр. Шулай да булса Танҗәдә чыга торган «Әс-сәгадәт» исемле бер гәзитә бардыр ки, бер җәзаирле тарафыннан француз политикасын котлап язылыдыр. Бу гәзитә, солтан һәм хөкүмәтнең хилафына, хаклы булсын, хаксыз булсын, каты-каты язмактадыр. Шул сәбәптән бу гәзитәгә каршы мөдафәга өчен гәзитә чыгару касдында булган вәзирләрдән бәгъзеләре дә юк түгелдер. Фәкать гәзитә булганлыгыннан гадәттән тыш курку илә куркалар.
Мәтбагада басыла торган китапларга килсәк, һәммәсе – фикъһе... Бунда гыйлем һәм фән фәкать фикъһедән генә гыйбарәттер.

Бундан башка нәрсәләрне карау һәм өйрәнү, хәтта бер Мисыр гәзитәсен, мәсәлән, «Әл-лива»ны[1], «Әл-мөәйяд»не[2], «Әл-мәнар»ны[3] өстән генә карап чыгу-укулар да мәмнүгъдыр, хәрамдыр.
Ибн Халдун[4], Мөхетдин Гарәби[5] вә бунлар кеби ислам голямасының олугълары бунлар каршысында мәзһәбсезгә саналадыр. Бунларның мохаләфәте вә башкаларның да фикъһедән башка тугърыда язылган әгъля талифәтләре дә бунлар каршында «көфер»дер. Имам Газалине[6] дә нәкъ шул югарыда язылганнар шикелле мәзһәбсез саныйлар. Шунлыктан аның китапларын да уку түгел, кулга алу да харамдыр.
Бер кеше сәясәттән, мәдәнияттән, мәгърифәттән, машиналардан бәхәс итәргә керешсә, күп вакытта сөйләүченең диваналыгы илә хөкем итеп, гакылсызлыгына хәйран булып көләләр.
Бунлар өчен кеше маймыл сыйфатлы булу тиештер. Башка мәмләкәтләрдә чын-чыннан кеше көлкесе булырлык сурәткә кереп бер кеше йөри торган булса, бунда файда итәдер. Мәсәлән, башына бик зур тау кадәр чалма киеп, муенына әчтерхан чикләвеге эрелегендә төймәле тәсбихләрне өчәр кат тезеп, кулына да чүпрәкләргә төреп бетергән интизамсыз бер таяк тотарга тиеш. Ул таягының да башына кулына ни әләкте, шуны тагып, һәрвакытта һич тәртипсез, әллә нинди тузга язмаган сүзләр сөйләп, чын-чын тиле бер кеше шикелле булып: «Кичә фәлән сәхабәне төшемдә күрдем, бүген Истанбулга барып, солтан берлә күрешеп кайттым. Әлҗәзаир мәмләкәтендәге чит мәмләкәт вәкилләренең йөзләренә хәзрәте Идриснең төкергәнен күрдем», – дип сөйләмәк тиештер.
Әлхасыйль, шул рәвешчә йөреп, мәсәлән, бер тарикать чыгарып, әтрафка ничә мең кешеләр ияртеп, анларга шәех, хәлифә, хәтта солтан булып, банкларга акчалар җыю бик җиңгелдер. Менә, мәсәлән, үзен солтанның карендәше Мәүлаи Мөхәммәд дип атап, ничә еллар Гаребнең астын өскә китергән. Бу Хамәрә исемле гасый да шундай адәмнәр җөмләсеннәндер.
Әр-Рәсүли дигән кеше дә шундай баш тарткан бер кеше иде дә, соңыннан, үзен мәхзан Танҗә тарафына вәли (губернатор) итеп куйгач кына, бераз басылды. Шулай булса да һәмишә ул тарафларның беренче хакиме исемен күтәреп тормактадыр. Бунларның арасында бигрәк гаҗәбрәге: Гаребнең сахра тарафларында Җәзаирдән гаскәрилектән качып чыккан булып, кабиләләр арасында йөреп, анларның гореф вә гадәтләрен, әхлак вә телләрен үгрәнеп белгән Шарль исемле бер кеше үзенә сахра короле исемен бирә, имеш. Бу адәм йөргән чагында тәхетрәван өстендә кешеләрнең җилкәләрендә гизә, имеш. Үзенең гаскәрләре, вәзирләре дә бар, имеш. Хәтта узган елларда гына Англиядән бераз корал да китерткән, имеш. Әлхасыйль, ул тарафларга хәзер дә хәкыйкый бер солтан булган.
Әлхасыйль, бундай кул үткенлеге илә эшләнә торган һәртөрле фокусларга кәрамәт-могҗиза дип ышанырлык наданнар, бундай бер кешенең солтан булуы да, хәтта бердән иҗат итүче булуы да бик мөхаль түгелдер.
Фасның казыйсы, мәтбагада басылачак һәрнәрсәне үзе карап чыкканнан соң бастыра алу өчен, бер канун кую берлә маташа. Фәкать канун дигәч тә, гәзитәгә язылган, тасдикъ ителгән рәсми бернәрсә түгел, затән аның рәсми дигәне дә ниндәй булыр – буны бастырмассың диячәк, вәссәлам! Шул канунын сөйләгән чагында көлә-көлә эчләр катып бетәрлектер, җөда кыйлынадыр. Шул ук казый мәгариф назыйрлыгы (министры) хезмәтен дә күрәдер. Әмма үзенең, тикшереп карасаң, башка мәмләкәтнең, мәсәлән, Истанбулның мәгариф назыйрының капучысы (швейцары) булырга да ярарлык гыйлеме юк...
Менә бик әгълячы, мөселман, фатиха берлә генә тора торган мәмләкәтнең хәле шулдыр. Бичаралар, мәмләкәтләре тәмамән кулларыннан китеп беткән вакытта да һәмишә аңлыйсылары килми.
Мөселманнар кайда булса да бердер, ахры. Төркиядә ачлыктан хадисли алмай йөргән, һични белмәй торган Анатул сәдакачыларына, мөҗавир исемен күтәреп йөри торган Хиҗаз-Сурия кортларына бездә дә игътибар бик зурдыр ки, гәрчә хак булса да, әйткән өчен әйтүчене, язган өчен мөхәррирне гаепле итеп, кыямәткә кадәр кулларындагы акчаларын исраф итәчәкләрдер. Әксәренә бирелгән акчалар Истанбулның юксәк

калдырымнарыннан узмаенча, Җөддәгә бушлай барыр өчен, [алар] пароход теләнергә тотыналар.
Безем Русиядә андай солтан булырга нәфесләрен сузарга юл булмаганлыктан, ул тарафтан тынычмыз. Әмма аннан башкаларына безнең Русия мөселманнары да тырышырлар, артка калмаслар. Анда булган шикелле, безнең Русия голямасының да бәгъзеләре Имам Газали, Ибн Халдун кебиләрне, әгәр исемен әйтергә телләре күнсә, фасыллардан бик кирегә калмайлар. Әлхасыйль, «Төрек» гәзитәсенә язган әфәнденең әйтүенчә, солтан була алмасалар да, безнең Русиядәге мөселманнар арасында шул әфәнде әйткән кыяфәтләрдә йөреп, гәрчә гыйлеме булмаса да, шулай ук акчалы, бай шәех була алучылар юк түгел.
Искелек сакчыларына ачык хат

Ушбу көндә бөтен Яурупа вә бәгъзе Азия кавемнәре хокук вә эснаф хосусларында алышып көрәшерләр икән. Русия татарлары да шактый талашып тартыша башладылар. Бу талашу айдан-айга кызыша бара, вә ике якның ачигълары көннән-көнгә арта бара. Талашып-тартышкан татарларны бәян итүгә лязим дә юктыр ки, буйлардан яшьләр фиркасе1 кием-салым вә кыяфәткә һичбер диянәт вә коддусият ябыштырмый, кямил азатлык берлә милләтнең күз ачмакына тырышалар. Егетләр ни кисәләр дә кисеннәр, ничек йөрсәләр дә йөрсеннәр, мәгәр белекле вә һөнәрле булсыннар, дип баралар. Әмма картлар фиркасе2, яшьләрнең кием-салымнарына вә йөреш-торышларына, вә гәзитә укуларына, вә гәзитәләргә хәбәрләр язуларына тарыгып, гаять ачигъланалар. Зыяфәтләрдә сүзләр чыгарып, берәм-сәрәм очраган яшь фикерлеләргә каты һөҗүмнәр кыйлалар, вә искелек сакчылары, җиңгел генә вә кыска гына уйлап, садә сугыш вә йөз ерткычлык берлә төрки якташларыны гәзитә укудан вә хәбәр язудан мәнгы итмәк хыялыны кыйлалар. Мәсәлән, «Вакыт» гәзитәсенең унтугызынчы номерында3 «Шәкертләр чүбек чәйниләр, кызлар «Мөхәммәдия» җырлыйлар» дигән сүзләр бар. Ушбу сүзләрне күргән бәндәнең үзен вә бернисен карамый вә аңламый, берничә кышкарилар мөхәрриргә каршы аякланып, кыямәтләр кубардылар. Бичара муллалар. Инсаф итеңез! Тәгассыб вә тәһәүвер берлә тәрәккъкый юлына аркылы ятмаңыз!
Ялган вә ифтира вә әгъразый нәфсания илә хаклыкның күзенә чүп атарга уйламаңыз! Сез ислам диненең күркәмлекләрен татлы тел вә үтемле гыйбарәләр илә аңлатыңыз. Сезгә аңламак лязимдер ки, һади Мәһди вә моктәда биһ булган кемсәләр һичбер заман сезнең кеби гаҗиз, сезнең кеби дәлилсез, сезнең кеби җәяүле, сезнең кеби тәмсез телле булмадылар. Җитәкче, өндәүче, мөгаллим булган кемсәләрне даимән җитәкләнмеш сукырдан артыграк күрергә кирәк.
Сезгә бер генә юл бардыр ки, хәзрәтләр, ул исә – белү юлыдыр. Әгәр дә сезнең белүеңез төгәл булса, ниятеңез көчле булыр. Төшенеңез, уйланыңыз! Сезнең кулыңызда сәяси көч юктыр ки, зынҗыр вә каһәр берлә яшьләрне изкяр итеңез! Бу көнгәчә сезгә сәяси көч бирелмәде, бундан соң һәм бирелмәячәктер. «Сөзә торган сыерга Тәңре мөгез бирмәс» дигән бер мәкаль дә бардыр. Бәлки, ишеткәндерсез? Әгәр сезнең кулыңызга сәяси көч бирелсә иде, әмир Хәйдәр4, Габдулла Әссафахның йөзләрен агартырлык эшләр кыйлыр идеңез. Килеңез, хәзрәтләр, инсаф идәлем вә күркәм мөҗадәлә кыйлалем. Гакыл үзенең дәлилләрен китереп, хаклык өскә чыксын!

Крәстияннәр һәм Дума

Самар губернасының Бозаулык өязендә Любимовка авылы крәстияннәре әйтәләр, имеш: «Без, крәстияннәр, Думаның тикшереп хөкем кыйлганын көтәмез. Безнең көтүемезнең чиге исә – Думаның хөкем итүе. Инде, әгәр дә хөкүмәт Думасына җир мәсьәләсен тикшереп вөҗүдкә чыгарырга ихтыяр куймасалар, бу вакытта без бүтәнчә көрәшермез. Әмма безнең бу сүзләремездән чиновниклар уйламасыннар ки, без алар берлә көрәшү өчен пычаклар да талаулар һәм помещикларның мөлкәтен җандыруны корал итәрмез дип. Юк, бу эшкә, бу көрәшкә безнең бөтенләй башка коралларымыз кулымызда: рекрутлар да

безнең кулымызда, имана түләүләр дә безнең кулымызда, кара көч тә безнең кулымызда. Инде моннан да ары без өстемезгә йөкләгән авырлыкларны күтәреп йөртергә безнең көчемез юк.
Без җирләремезнең азлыгы сәбәбеннән нинди авырлыкларга төшеп, нинди җәфалар чигәмез. Бу җирләремезнең азлыгыннан каннарымыз һәм тирләремез берлә коенамыз. Безнең бу хәлләремезне чиновниклар күреп торалар, әмма бу авырлыкларны безнең өстемездән алырга уйлап та карамыйлар, гәрчә безне бу җәфалардан коткарырга аларның кулларыннан килсә дә».

Бер каз өчен тәртипсезлекләр

Курский губернаның Тимский уездда Аринкин утарында бер крәстияннең бары бер казы өчен бик аздан гына әллә нинди зур эшләр чыкмый чак кына калган.
Бер крәстияннең казы югалган... Мужик, казын югалткач, барин казны тотып япмадымы икән дип, иң әүвәл помещикның ихатасы эченә барып: «Минем казымны түрә тотып япмадымы?» – дип сораган. Әмма мужикка: «Юк, бариннық япканы күренмәде», – дип җавап биргәннәр.
Шулай булса да мужичок бу сүзгә бик ышанып бетмәгән, чөнки барин һәрвакытта шундай кошларны япкалаштыра, имеш, шуның өчен дә мужик бик иҗтиһад берлән күзәтә башлаган. Менә бервакытта төнлә берлән бариннның ишегалдыннан каз тавышы ишетелгән... Мондый вакыйгагә мужиклар бик гаҗәпләнгәннәр.
Шул хосуста иртәсен мужиклар, җыелышып, казны эзләү өчен, бариннның ихатасына кереп киткәннәр.
Шул рәвештә, шул мәкъсуд берлән мужиклар, бариннның ихатасына кергәч тә, каз йоннары күргәннәр. Моннан соң азрак баргачтын, салам эченнән башы киселгән казны да тапканнар.
«Бу нинди эш!» – дип, мужиклар шаулаша башлагач, бариннның пешекчесе: «Барин казны суярга кушты», – дип мәгълүм кыйлган. Шуннан соң мужиклар шаулашып баринга кереп киткәннәр. Әмма барин, баштан азрак танмакчы булып булашса да, мужиклар бик шаулаша башлагач, танарга бер дә хәйлә таба алмаган. Ахырда барин, мужикларга каз өчен биш тәңкә акча биреп, мужикларны чыгарып җибәрсә дә, мужиклар озак та тормыйча гөж итеп бариннның ихатасына казны күтәреп яңадан килеп кергәннәр. Ул арада бариннның йортыннан ике мәртәбә мылтык аткан тавыш та ишетелгән.
Шуннан соң мужиклар, кямил гайрәтләнеп, башта тәрәзәләрен ватып, бариннның йортына кереп китсәләр дә, йорт эчендә бариннның кәкрәеп, катышып беткән атасыннан башка һичкемне таба алмагач, карт бариннны бераз җиңгел генә башсыз каз берлән төрткәләп чыгып киткәннәр.
Инде хәзер казаклар килгәнен көтәләр икән. Менә бер мужикның казы аркасынданиләр булган.
Борчылырмыз

«Каспий» гәзитәсенең язуына караганда, 1906 сәнә 1 гыйнварга кадәр мәмләкәтебезнең бурычы 7 миллиард та 681 миллион да 395 мең дә 928 сум булган. Аның өстенә бу ел апрель аенда 348 миллион да 750 мең сум яңа карыз алынды. Узган август аенда ачларга ярдәм итү өчен 50 миллион сумлык 4 процентлы государственный ренталар чыгарылды. Бу ел августның 23ендә мәмләкәтнең бар бурычы 8 миллиард 575 миллион 145 мең 928 сумга җитте.
Бурычны киметү вә процентларыны бирү өчен, ел саен 386 миллион да 400 мең сум түләү тиеш буладыр.
Бу бурычлар өстенә дә хосусый кешеләр кулында булган тимер юлларының бурычларыны вәгъдәләрендә түли алуларын да мәмләкәткә кайгыртырга тиеш буладыр. Чөнки хөкүмәт бунларның бурычларына да кәфил булып торадыр. Шуның шикелле үк хөкүмәт дворяннар

банкысы крестьянский земельный банкыларның закладной листларына да кәфилдер. Чөнки бу банкылар да мәмләкәтнең ссуда мәхәлләре булып күренәләр. Хосусый (частный) тимер юл обществоларының алган карызлары – 1904 ел 1 гыйнварга кадәр 1 миллиард 110 миллион да 500 мең сум.
Һәм дворянский вә крестьянский поземельный банкыларның закладной листлары 1905 сәнә 1 декабрьдә 1 миллиард 105 миллион 890 мең сум иде.
Бу ике маддәнең процентларыны түләү вә бурычларыны киметү өчен, ел саен 98 миллион да 100 мең сум лязимдер. Әлхасыйль, мәмләкәтнең үзенең вә кәфил булган бурычларының мәҗмугысе10 миллиард 791 миллион 445 мең 968 сум микъдарындадыр. Бунларның барысының проценты вә бурычны киметү өчен түләнә торган микъдары 484 миллион 579 мең 871 сум чамасындадыр.
Әгәр дә төгәл генә рәкымнәр берлә әйтсәк, мәмләкәтнең 11 миллиард бурычы бар, вә бунын проценты өчен халыкның ел саен ярты миллиард кадәр түләү түләве лязимдер. 1897 елдагы перепись буенча бөтен Русиядә халык 125 миллион да 668 мең дә 190 кеше хисап ителәдер.
1897 дән соңгы елларда, әгәр дә Финляндияне истисна кыйлсак, Русия эчендә ул кадәр кеше күп артмады. Чөнки йә ачлык, йә сугыш, йә болганулар, йә погромнар һәмишә булып торды. Шунлыктан хәзерге көндә Русиядәге бар халыкны тәкърибән 150 миллион чамасында дияргә мөмкиндер.
Әгәр дә мәмләкәтнең бурычларыны Русиядә булган һәрбер халыкның санына карап бертигез итеп бүленсә, һәрбер кеше башына 73 1/3 сум микъдарында бурыч төшәдер. Вә бу бурычның проценты өчен һәркем ел саен 3 сум да 33 1/3 тиен микъдарында процент түләргә тиеш буладыр.
Әгәр дә моның өстенә күптән түгел Япуния берлә булган сугыш өчен тотылган 200 миллион микъдарындагы расходны да егерме елга тәкъсим итеп кеше саен таратсак, ул да кеше башына 1 сум 33 1/3 тиен микъдарында төшәдер ки, җәмгысы кеше башына 4 сум да 66 2/3 тиен тиядер.
Шул микъдарны Русиядә торучы яңа туган баладан башлап йөзьяшәрлек картка кадәр һәркемнең ел саен түләве лязимдер.
Мәзкүр гәзитә бу микъдарны язып кына да калмаган. Аның өстенә шул сүзләрне дә гыйлавә итәдер.
Бөтен дөнья йөзендә акча булып йөри торган алтын 20 миллиард сумлыктыр, димәк ки Русиянең бурычы бөтен дөнья йөзендәге алтын акчаларның яртысыннан да артыграктыр. Араларында алтынны акчага хисап ителеп йөри торган 23 мәмләкәтнең бөтен бурычы 1903 сәнә 1 гыйнварга кадәр 45 миллиард чамасында булган. Буңар караганда, бөтен 23 мәмләкәтнең бурычының чиреге Русия өстендәдер. Җирдә алтынның булуының бәрәкәтендә ел саен 300 миллион микъдарында алтын акча артадыр. Әмма Русиягә бурычларының процентларыны түләү һәм бурычларны азлап киметү өчен генә дә елына 500 миллион сум лязимдер.
«Ислях» гәзитәсе

Безнең Ягъкуб әфәнде шатлыгыннан тиресенә сыя алмый иде. Чөнки аның бүген базардан сатып алып кергән нәрсәсе «Ислях» гәзитәсенең беренче номеры иде. Ягъкуб әфәнденең йөзләре бик якты иде, шат иде. Шатланмыйча хәле юк, чөнки Ягъкуб әфәнде мәдрәсәләрнең ислях ителүене, милләтнең тәрәкъкый итүене бик тели иде.
Ягъкуб әфәнде, базардан мәдрәсәгә кайткач та, тәбәнәк өстәл янына мендәрене китереп салып, арка өстенә ятып, «Ислях» гәзитәсене моталәгә кыйлырга тотынды.
Ягъкуб әфәнденең минуттан минутка йөзе яктыра бара иде. Шатлыгы арткannан-арта иде. Чөнки гәзитәне укыган саен укыйсы килеп тора иде. Гәзитәнең эчендә язылган нәрсәләр барысы да шәкертләрнең мәкъсудлары, шәкертләрнең мөдәррисләреннән сорый торган нәрсәләре, шәкертләрнең милләттән көткән бөтен өмидләре иде.

Фәкать Ягъкуб әфәнде бара-бара күзенә дә, үзенә дә ышанасы килми башлады. Һич мөмкинме? Шәкерт исемендә булган татар баласы, бер эшкә керешеп тә, аны вөҗүдкә чыгарсын, татар шәкерте булып та, керешкән эшене дәвам иттерсен! Узган кыш «ислях», «ислях» дип йөрделәр, җыелып-җыелып сөйләштеләр, кычкырыштылар, пыялалар ваттылар, мәдрәсәләрне ташлап чыгып киттеләр1, хәтта сугыштылар, әмма берсене-берсе, үзләрене үзләре кыйнадылар.
«Әгәр дә мәдрәсәләр ислях ителмәсә, тәртипкә салынмаса, киләчәк көзгә мәдрәсәгә килмимез», – диделәр.
Көз җитте. Мәдрәсәләр һәмишә искечә, һич үзгәргән җирләре юк. Фәкать шәкертләр дә һәмишә искечә, һич үзгәргән җирләре юк. Һәмишә искечә мәдрәсәләренә кереп ултырдылар. Берәр мәдрәсәбез аз ислях ителгән шикелле булды. Әмма төзәлмәде.
Ягъкуб әфәнде һаман да күзләренә ышанасы килмәде. Бармаклары берлә гәзитәләрне тотып карады. Вакыйган, кәгазе шытырдый. Димәк ки, хыял түгел, чын гәзитә – «Ислях» гәзитәсе чыккан! Фәкать бу чыкканда Ягъкуб әфәнде кайда калган?
Ягъкуб әфәнде фикерләргә кереште. 10 майда булган исляхның съездыны2 вә шул съездда шәкертләргә мәхсус бер гәзитә чыгарырга3 карар бирелгәннәрене, гәзитәне чыгарыр өчен иганә җыймакчы булганлыкларыны, Мәкәрҗәдәге мөселманнар съездына доклад хәзерләгәнлекләрене, әмма съездда һичбер докладларыны-фәләннәрене күрсәтә алмаганлыкларыны хәтеренә китерде. Җәй буена «Ислях» һичбер эш эшләмәде, гәзитә чыгарыр өчен акча да җыя алмады. Соң, алай булгач, бу гәзитә үзеннән-үзе кайдан килеп чыкты да, ул чыкканда «Ислях»ның иң уртасында йөрүче Ягъкуб әфәнде кайда калды?..
– Торыңыз! Сәхәр ашарга вакыт җитте, торыңыз!
Кизүнең шулай дип кычкырган тавышына Ягъкуб әфәнде уйганып китте.
Гәзитәнең хыял икәнлегене белгәч:
– «Ислях» дип йөрүчеләр үзләре шәкертләр булсыннар да, анлардан нинди эш вөҗүдкә килсен! – диде.
Урыныннан торып, чаршау баганасында эленеп тора торган сөлгесене муенына урап, бишмәтене җилкәсенә салып, шүрлектән резинкасыны сузылып алып, вәкарь берлә тәһарәткә чыгып китте. Өйалдына чыгып, резинкасыны кия башлагач, бик мәэюсият берлә күзләрене уып алды.
Зур сүз вә зур вакыйга

– Бу эшләр бары да синең тәрбиясезлегеңнән, баланы яхшы, кеше төсле итеп тәрбия кыйлмаганлыгыңнандыр!
Әхмәтгали бай бу кадәр зур, бу кадәр күңелсез сүзне хатынына гомерендә беренче мәртәбә әйтүе иде. Бу көн бу кадәр зур сүзне әйтерлек бик зур эш вакыйгъ булган иде. Әхмәтгали байның унтугыз яшәр кызыны бу вакыйгадән биш-алты көн мөкаддәм генә Галим байның угълына бирергә вәгъдә куелмыш иде. «Кыз бирәмез», – дип шатланып йөргән вакытта гына, бу көн бөтен тәдбирләре тар-мар килмеш, җибәргән вәгъдә бүләкләрене Галим байлар кире кайтармышлар иде.
Әхмәтгали бай үзе Казан арты ягындагы бер сала кешесенең угълы иде. Унике яшендә авылдан чабата илә килеп, бер байга йомыш-юлга йөрергә йорт хәзмәтенә кермеш, бераз зураеп, хатын-кыз арасында йөрерлектән узгач, кипләр бәйләр өчен кибеткә төшеп, әүвәл кибетче булып, соңра, дәрәҗәсе күтәрелә-күтәрелә, доверенный приказчик дәрәҗәсенә җитеп, байдан чыгып, үзеннән хуҗа булып сату итә башламыш, хәзерге көндә яхшы гына «бай» исемен алмыш иде.
Бикә абыстай да Әхмәтгали бай берлә бер байда бергәрәк үсмеш кыз иде. Яшьтән үк бер-берсене сынашып барганлыктанмыдыр, һәрвакыт бик дуст торалар, бик тыныч гомер итәләр иде. Шунлыктан бикә абыстайга бу көнге сүзне ишетү бик агыр тоелды. Үзенчә, ул бердәнбер кызыны бик яхшы тәрбия кыйлып үстермеш иде. Аңар һичбер вакытта каты сүз әйтеп күңелене калдырмый, һичвакытта аны йорт эшләренә кушмый, кызның йоклаган вакытларында өй эчендә һичбер тавыш чыгартмый иде. Кызы уянмасын өчен, һәркем аяк

очы берлә генә басып йөри иде. Кызның кәефене җибәргән, ул теләгән вакытта курчак уйнашмаган, аның сүзене тыңламаган асрауларны бер минут та тотмый иде. Иртә торгач, сачләрене дә үзе генә бик һәйбәтләп майлап үрә, һичбер ят кешенең кулыны тидертми иде. Кызларыны шәһәрдә беренче дәрәҗәдә мәшһүрә Гаян остазбикәгә салып, бик күп еллар укытмышлар иде. Фәкать кызның уналтынчы яшендә вакытында, тиречe Хәлим байлардан яучы килгәч кенә: «Инде сабакка йөрергә зур булган», – дип, остазбикәгә йөрүдән туктатканнар иде. Остазбикәгә йөргәндә дә, бикә абыстай кызыны тәрбияләүдән һич арымады, сабакка барганда эче селкенмәсен дип, һәрвакыт йомшак пролеткаларга гына утыртып йөртә иде. Кызның өст-баш җәһәтеннән дә тәрбиясе тәмам килгән иде. Ничә-ничә асыл күлмәкләре, ничә кат муен энҗеләре, ике кулына кул энҗеләре, алка, беләзек, йөзекләре – һәммәсе дә җитешкән иде. Быел Мәкәрҗә ярминкәсеннән1 генә, атасына әйтеп, бик һәйбәт бриллиант брошка илә муенга асарга алтын цепочка алдырган иде. Алтын сәгате дә һәммә бай кызларыннан артык иде.
Шулкадәр һәр җәһәттән тигез килгән, һәр җәһәттән җитешкән тәрбияле кызны Галим байның угълы: «Мин андай тәрбиясез, надан кызны алмыйм!» – дип рәд кыйлган, вә шунлыктан Галим байлар вәгъдә бүләгене бу көн кире кайтарганнар иде.
Шулкадәр фәрештә шикелле гүзәл, тәрбияле кызына «тәрбиясез» дип әйткән сүзне ишеткәч, бикә абыстай ачуыннан ярылып үләргә җитеште. Аның өстенә гомер иткән иреннән дә: «Бу эшләр бары да синең тәрбиясезлегеңнән», – дигән сүзне ишетү бикә абыстайга җан бирүдән дә агыр тоелды. Бикә абыстайның үләчәге исендә иде, әмма кызы өчен иреннән бундый күңелсез сүзне ишетермен дип һич исендә юк иде.
Хосусән бу көннәрдә бикә абыстай, бик шатланып, кызыны шулкадәр дәрәҗә яхшы тәрбия кыйлганлыгының мөкяфәтенә әллә ничә кат асыл җефәк күлмәкләр киячәгенә, әллә никадәр бүләкләр алачагына бик ышанып йөри иде.
Кодалары Галим бай илә кодагый булачак бикә абыстайлар Әхмәтгали бай берлә бикә абыстайга бик муафикъ кешеләр иде: анлар да, Әхмәтгали бай илә бикә абыстай шикелле үк, авылдан чабата берлә килеп, байда торып баеган кешеләр иде. Фәкать угыллары гына начар кеше булып чыкты. Атасы никадәр Әхмәтгали байның хатыны шикелле итеп тәрбияләп, үзенә аерым бер хәлфә китертеп, угълыны өендә генә укыткан булса да, угълы бераз бозык фикерләргә авышып китмеш иде. Кибеткә төшеп, приказчиклардан күрмәкче, яңа чыккан китапларны анасыннан яшереп укый-укый хили үзгәрмеш иде. Бер елдан бирле чыга башлаган гәзитәләр дә егеткә бик күп тәэсир итмеш, фикерене алыштырмыш иде. Караган китаплары, укыган гәзитәләре аркасында дөньяда адәмчә мәгыйшәт кыйлу өчен алачак хатынының да укымышлы, үзенә иптәш булырлык бер кеше булуы тиешлекне аңларлык дәрәҗәгә җитмеш иде. Әхмәтгали байның кызыны, ничә еллар остазбикәгә йөргәнлектән, укымышлыдыр дип алырга риза булса да, соңыннан тугыз ел укып йөреп тә, «Мөхәммәдия» көйләүдән уза алмаганыны ишеткәч, дәрте бөтенләй сүнмеш вә Әхмәтгали байның кызыны алудан тәмам кайтканлыгыны әнкәсенә белдермеш иде. Әткәсе берлә әнкәсе, балаларыны никадәр үгетләп, хәтта орышып карасалар да, һич тәэсир итмәгәч, ниһаять, вәгъдә бүләгене кире кайтарып җибәрергә мәҗбүр булмышлар иде.
Вәгъдә бүләгене кайтаргач, Галим байның бикәсе дә Әхмәтгали байның бикәсеннән ким хафаланмады. Кода-кодагыйлары бик бай кешеләр булганлыктан, угълы аркасында ул да ничә кат җефәк бирнәләр киюдән мәхрүм калмыш иде. Икенче тарафтан, Әхмәтгали байлар Галим байларның әүвәлдән үк йөрешкән кешеләре иде. Хәзердә кызларыны алмагач, алмагач кына да түгел, бәлки, вәгъдәләрене кире кайтару сәбәпле дошманлашкач, ел тәүлегенә ничә аш-сулардан калышырга, хәтта берсе барган мәҗлескә икенчесе бармаска тугъры килә иде. Әхмәтгали байның хатынына әйткән сүзе бик зур сүз, Галим байларның вәгъдә бүләгене кире кайтарулары да бик зур вакыйга булды.
Ләкин ике айга кадәр бу вакыйга, өйдән өйгә, мәҗлестән мәҗлескә йөреп, шәһәр хатыннары арасында сөйләнде.
Инде бүген бернәрсә дә сөйләмиләр. Бары тик кеше арасында ара-тирә:

– Инде хәзер укымаган кызга, миллионщик булса да, егетләрнең исләре китми, – дигән сүзләр генә ишетелмәктәдер.

Тел бәхәсе

Тел бәхәсе иң кирәкле бер бәхәс исә дә, бу бәхәсне берәр җәгъли кагыйдә илә вә яхуд һичбер кагыйдәсез-нисез чишеп бетермәк дәгъва вәхлиясенә төшкән кемсәләрнең итенеше җөмләмез өчен игътибар ителерлек бер хәлдер.
Күптән түгел Мөхәммәд ага дигән бере, гарәп хәрефләре арасына берничә һинди рәкымнәр кертеп, эш бетермәкче улган иде1. Озакламай үзе бетте. Хәлбуки Мөхәммәд аганың «Шәркы рус»та күрсәткән имля вә тарыз ифадәсе бик гүзәл вә пәк татлы иде. «Шәркы рус»ның иң кирәкле бер көндә сүнеп киткәненә чук үкенәмез.
Шул ук вакытларда Максуди һаи рәсмиягә ябышты2 вә сүзләр эченә күбрәк һаи рәсмия кертү берлә эшне бетермәкче улды. Аның җәгъли кагыйдәсенчә, имән әкәләсе берлә хәрәкәттә – бәрәкәт. Шулай хәрәкәт иткәндә, Бәләбәй әтәчләре3 үсмәк мөхтәмәл улачак иде...
Бунлар кызык-кызыкләтыйфә мәртәбәсендә улып калмышлардыр вә хәзер дә исә тел бәхәсенең пәһлеваны – «Тәрҗеман»дыр. «Тәрҗеман» Казан шивәсенә зиядә тыгызлана вә тарланадыр. Вакыйган, Казан шивәсе «Тәрҗеман»ның башына бер бәла улды. «Тәрҗеман»ның егерме елда ала алмаган юлыны Казан шивәсендә чыккан гәзитәләр бер-ике айда ала белделәр. Казан шивәсенчә язылмакта улган гәзитәләр бер елның эчендә гаять кул әфкяр бирделәр.
Яңа тугъмыш гәзитәләр, «Тәрҗеман»га ияреп, аның теленчә каләм йөртүгә көчләнсәләр иде, гәзитәләрене бер ай кадәр яшәтә алмаган булырлар иде. Ул чагында йә бөтенләй чыкмауга вә яки чыккач та ябылуга көчләнерләр иде.
Вакыйган, «Тәрҗеман» пәк гүзәл яза. Әфкяр вә тарыз ифадәсе пәк гүзәл, вәләкин нә сәбәптәндер мәдрәсәләрдә ятып дәрес укымаган кемсәләр «Тәрҗеман»ны һич тә аңламайлар вә төшенмәйләр, бәлки, дәрес күргән кемсәләрдән вә меллалардан да пәк күбесе «Тәрҗеман»ны төшенә алмайлар.
«Тәрҗеман»ның мәсләке, әлбәттә, яхшыдыр, чөнки аның теленчә укып язган кемсәләр госманлы төрекчәсенә һәм якынлашачак, вәләкин тәрҗеманчы улмак өчен, мотлакан, ислам мәдрәсәләрендә сәнәләрчә ятып, дәрес күрмәгә ихтыяҗ вардыр.
Төрекчә «Тәрҗеман» кадәр язарга икътидары вә көче җиткән «Вакыт» вә «Фикер» мөхәррирләре нә өчен төрекчә язмайлар?
Бунның җавабы табигый вә билгеледер ки, ул чагында «Вакыт» илә «Фикер»не алучы вә аңлаучы улмаячактыр.
«Тәрҗеман»ның янә бер куркыныч җире бардыр ки, «Тәрҗеман» шивәсендә чыгътай теленең4 көе вә аһәңе юклыгыннан, «Тәрҗеман» шивәсене мәктәп теле итмәк вә аны бер нәүгъ кагыйдәләр илә балаларга үгрәтмәк мөмкин түгелдер.
«Тәрҗеман» садәләшсә, вә, садәләшеп, Казан шивәсенә якынлашса, гәрчә ул чагында хәзерге госманлы төркисеннән ераклашса да, үзе өчен вә милләт өчен яхшы итмеш улыр иде. Чөнки госманлы шивәсенең үзен тазартып көйгә китерүгә үзекле ихтыяҗ вардыр.
Бу мәкаләнең азагында әйтәчәк сүзем будыр ки: мең яшәгән чыгътай телене мәктәп балаларына үгрәтерлек кагыйдәгә салырга кирәк иде. Һәркаю телләр елларча үгрәнелүгә вә укылуга ихтыяҗда улдыклары беленмәле иде.
Вә буйлә улса, әнваг, төрле ясалмыш вә һәртөрле төскә буялмыш тел илә язылмакта улган бозык рәсем-хат вә яңлыш имлялардан сакланылмалы иде.
Төрле җирдә укытучылар җыелыш улмакта вә төрле җирдә дарелмөгаллимин мәктәпләре ачылмактадыр. Хәлбуки һичбересендә телгә вә телнең кагыйдәләренә тиешле рәвештә игътибар ителмәйдер.

Һич кулдан килмәгән бәләнд арзулар илә зәвекъләнеп, җилгә вакыт үткәргәнче вә юкка акча туздырганчы, тел тикшерүгә вә һәмишә шул эш берлә шөгыльләнергә махсус һәйәт ясалмак вә бу хосуста күп вакытлар уздырмак вә күп акчалар тотмак тиеш иде. Мәхәммәд агалар, Һади Максудилар, «Тәрҗеман»нар биш-ун данә һинди ишарәт илә вә бер данә «ә» илә вә егерме яшькә җитеп, зифа буйны күрсәтмәк илә тел бәхәсене чишмәк хәйләсене кыйлсалар да, тел бәхәсе алай җиңел генә төгәлләнәчәк түгел. Бу турыда һәр җирдә вә һәрвакытта тикшереп вә мәгълүмат җыеп, бер мәркәзгә мая китергүче күп тырышларга ихтыяҗ вардыр.

Ислам матбугаты

<...>

«Әлгасрелҗәдид» журналының уникенче номерында бер гаҗәеп сүзгә тәсадеф ителде. Мәзкүр журналның һәйәте тәхририясе тарафыннан язылмыш «Әхвәлемезә бер нәзар» нам мәкаләсендә «Әлгасрелҗәдид» яңа чыккан гәзитәләрнең һәммәсенең дә мөкаллидләр идекене дәгъва кыйладыр. Гүя мәзкүр журналның сахибе, милләтнең гәзитәләргә ихтыяҗы бик зур идекене иң әүвәл аңлап, мәзкүр журналны нәшер итәр өчен рөхсәт алган, имеш тә, аннан күрмәкче башкалар да, мәймүн кеби, тәкълид итеп «Әлгасрелҗәдид» журналына язарга вәгъдә кыйлган кешеләрнең барысы да үзләре гәзитә нәшер итәргә башлаганнар, имеш. Әгәр дә бу сүзне гәзитә мөхәррирләре исемендә булган кешеләр сөйләмәенчә, базар чатларындагы наданнар сөйләсә, бәлки, мәгъфу да улыр иде. Русиянең Волга буе шәһәрләрендә гәзитә чыгармак фикере ничә еллардан бирле бар иде. Никадәр кешеләр рөхсәт алу өчен хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп бактылар1, фәкать һәммәсе рәд ителде. Ул вакытларда «Әлгасрелҗәдид»нең сахибе гәзитә чыгару касдына керү түгел, бәлки, Мисыр сәфәренә дә китмәмеш иде2.

Гәзитәләрнең дөньяга чыгуларына сәбәп «Әлгасрелҗәдид»ме, яхуд 17 Октябрь көнендә туган гасры җәдидме идекене укучыларның һәммәсе дә белмәктәләрдер. Никадәр заманнар сөальләр кыйлып йөргәннән соң, С.Алкин җәнабләренә «Казан мөхбире»не нәшер итәргә рөхсәт ителде. Шул вакытта да, гәрчә 17 Октябрь тәмам ишек төбенә килеп җитешкән булса да, русча перевод илә нәшерне лязим ителмеш иде. Агыз сөйләгәнне колак та ишетмәк лязим.

1907

Гәзитә эчендә гәзитә

«Заман» гәзитәсе. Быелгы ел. Гадәттә чыга торган нөсхә.

Баш мәкалә

Инде бер җылдан бирле һәрбер номер калмыйча язып киләбез дә, алай да әле һәмишә үзебез кешеләргә бюрократиянең бик начар икәнен аңлатып булмый. Ай, шул бюрократияне нишләтәсе? Хәер лә... яңлыш әйттем. Әгәр бюрократия төзәлсә, баш мәкалә язар өчен сүз калмый. Күп гәзитәнең баш мәкаләсе язылыр өчен бюрократия бик кирәк. Чөнки ул йорт салганда известкага катыштырылган ком шикелле. Бюрократ дигән материалны халык хәле берлә бергә катыштырдың исә чат итә дәябыша, һәм бик килешле, бик матур да була һәм бик арзанга да төшә. Чөнки аны язар өчен материаллар һәрвакытта башта туп-тулы була. Кеше дә бик яратып укый. Ач кеше һичвакытта, хосусән быел начар диме, тәмсез диме, пешмәгән диме, хәтта саламлы, чүпле диме, ни бирсәләр, шуны ашый бирә. Безнең халык әле «бюрократия начар» дигән сүзләрне узган елдан бирле генә ишетә башлады. Бюрократның начарлыгы хакында ни күрде, шуны карынына,

ялгыш әйттем, башына тутыра бирә. Кайсы вакытларда, эш ашыгыч булып язарга җитешмәгәндә, ярты газитәне ак итеп, буш урын калдырып чыгарырга да ярый. Мондый булса, халык каршында, һәмишә ялгыш сөйлим, Печән базары1 каршында бигрәк мәкъбүл була.
«Ә менә бу төштә бигрәк шәп нәрсәләр язылган булган да, рөхсәт бирмәгәннәр, шуның өчен болай буш чыккан», – диләр.
Баш мәкалә язып барган чакта гына әллә кайда кереп киткәнмен. Хуш, мәкъсудка килик. Ай, нишләтәсе шул бюрократияне? Нишләтергә кирәк шул бюрократияне? Берни дә эшләтеп булмый шул, берни дә эшләтеп булмый!

Сәяси мәсьәләләр
Булмый?
Һичбер эш эшләргә тотынган юк, әмма булмый.
Була!
Әйе, әйе, эшләдең исә – була.
Көтәмез!
Көтми кайда бармакчы буласың, әлбәттә, көтәмез.
Дахили хәбәрләр
Киевта үтерәләр... Одессада талыйлар... Казанда йоклыйлар... Әстерханда төш күрәләр... Оренбургта эш күрәләр... Варшауда бомба... Вильнода динамит... Петербургта портманет... Мәскәүдә Лидваль2...
Хариҗи хәбәрләр
Персиядә тәхет... Төркиядә бәхет... Әфганстан куәтле... Мисырдан инглизне чыгаралар... Фаста тынычлык... Һиндстанда тәрәкъкый...
Казан хәбәрләре
Вәли сөйли... Әхмәтҗан көйли... Печән базары чатында гайбәт сатмыйлар, тәсбих саныйлар, кеше сайлыйлар...
(Мәтбагада эш ташланып китә язганлык сәбәпле, бу нөсхәбез ярты гына чыкты. Әгәр игълан күп булса, яңа ел алдыннан, ихтимал, алты гына бит түгел, сигез, хәтта ун бит тә чыккан булыр иде. Гафу боерылсын.)
Мөхәррире мин, әмма язучысы башка кеше.

Эләкми калынды
(Кечкенә фельетон)

Бик уңай түгел.
Ничә еллар гомер иткән, яхшы-яманны күргән, дөньяның ачы вә төчесен татыган. Ничә еллардан бирле кара халык эчендә гомер уздырып яткан. Шулай да булса Думага эләгеп булмады.
Никадәр тырышып карадым.
Шулай да сайламадылар.
«Сезнең өчен бик тырышачакмын», – дидем. Кулымнан килмәслек булса да: «Һәрбер төрле бидгатьләрне, яңа укытуларны бетерермен», – дидем.
Шулай да сайламадылар.
Йөзе кара мужик: «Миңа җир кирәк», – ди.
«Җир дә булыр, бар да булыр», – дип тә карадым, ышандырып булмады. «Безгә закон белгән кеше кирәк», – диделәр.
Сайламадылар.
«Мин дә закон беләм бит, ничә мәртәбә мировойларда булдым, окружной судка эшем төшкәне бар, һәммәсен дә җырып чыктым», – дип тә карадым. «Безгә русча яхшы белә торган кеше кирәк», – диделәр.
Йөзе каралар! Сайламадылар.

«Мин русчаны кайсыгыздан ким беләм. Становойга, земский нәчәлниккә переводчик алып барганым юк бит», – дип тә ялынып карадым.
«Син картайган инде, дәүләтең дә бар. Хәзрәт, инде сине беравыздан хаҗга барырга сайлыймыз», – диделәр.
Ахмак нәрсәләр!
Мин алардан башка хаҗ юлын белмимме?
Бары тик әле халык Петербургны бик мактаганга күрә генә нәфес кузгалып киткән иде.
Дворецны да бик яман димиләр1.
Йөзе кара мужикның надан булганы яхшы.
Итагатьле була.
Ни әйтсәң, шуны тыңлый.
Гәзитә укыган булып, бозылып беттеләр.
Шулкадәр волостька гәзитә керттермәскә тырышып карадым, писергә дә әйткән идем, туктатып булмады.
Йөзе кара мужик: «Хәзрәт гәзитә ала икән, без дә аламыз», – дип ала бирә.
Үзем алмас идем, нәфесне җиңеп булмый. Ничек тә булса бераз дөньяны белеп торасы килә.
Ахмак нәрсәләр! Мине: «Русча белми, закон белми, көн саен ун тәңкә акча алыр өчен генә кызыга»2, – дип, исем чыгардылар.
Русча белми, закон белми дип тә әйтсеннәр. Алары өчен ул кадәр дә ачуым да килми. Минем шикелле берни белмәгән муллалар узган Думага барып кайттылар3. Анысы ул кадәр зур эш түгел. Акча алыр өчен генә дигәннәренә бик ачуым килә. Һич акча өчен түгел. Эстәрсәләр, алган жалуниямнең бер тиенен дә тотмыйча, үзләренә алып кайтып күрсәтермен. Картайган көнемдә «Дума члены» исемен күтәрү күңелле бер эш булганга күрә генә иде.
Акчасы да зарар итмәс иде итүен...
Хәерле булсын!
Бу Дума да, бәлки, таралыр әле4.
Өченчесенә ничек тә барырга тырышырмын.
Тыңлап тордым, соңра яздым.
Язылды быел. Ай башында.

## Кытайда ислам вәкилләре

Вакыт бик иртә иде.
Шулай да булса баш вәзир – икенче король Юань Шикай1 күптән йокысыннан тормыш иде.
Һәр тарафтан лапас шикелле күләгәләп алган балконнарның эчендә урта бер җиргә кертеп салынган сарайда һаман да караңгылык иде.
Ләкин Юань Шикай йокысыннан тормыш иде. Бүген, махсус киемнәрене киеп, бизәнергә, үзен мәһабәтрәк күрсәтергә бөтен һиммәтен сарыф кыйлмакта иде.
Дүрт вершок озынлыгындагы агарган мыекларын, мәһабәтрәк күренү өчен, карага буяды. Кытайларның кибарлыгына дәляләт кыйла торган бер ярым сантиметр озынлыгындагы тырнакларын, бик тәмизләп әрчеп, махсус ясалган лак берлә ялтыратты.
Сарай эчендә һаман караңгылык иде. Бер-ике мәртәбә гыйбадәт кыйлып алды. Бик озаклап мәгъбүдләреннән шәфәгать үтенде.
Юань Шикай төннән бирле хәзерләнмәктә иде. Бик хафалы иде. Төн буена күзләренә асла йокы кермәде. Чөнки ул бүген үзенең хәсыймнәре илә йөзгә-йөз, кара-каршы киләчәк иде. Анлар каршысында җәсарәтле булмак лязим иде.
Укучының, шаять, хәтерендәдер.
1896 елда кытайлар берлә япуннар арасында сугыш2 булып, Кытай мәмләкәте җиңелмеш иде. Шул көннән бирле Кытайда һәрбер төрле «Зур йомрык», «Боксер», «Хунхуз» вә быел

гына «Зур бот» фиркаләре заһир булды3. Бу фиркаләр һәммәсе дә хөкүмәтләреннән һәрбер төрле нәрсәләр сорый башладылар:
– Безнең арада яурупалылык булмасын, – диделәр.
– Мәмләкәт ислях кыйлынсын, – дигәннәре дә булды.
Кыйсы берсе төрле хөрриятләр дә сорадылар.
Кытай мәмләкәтендә ничә миллион мөселманнарның барлыгы да һәркемгә мәгълүмдер4. Болар да, кайсы «Хунхуз», кайсы «Боксер», кайсы «Зур йомрык», кайсы «Зур бот» фиркаләренә кереп, хөррият таләпләрендә асыл мәҗүси кытайлар илә бергә хәрәкәт кыйлдылар, Лихон-Чангтан башлап Юань Шикай вә богдыханнарга кадәр бик күп гаризалар бирделәр. Бирелгән гаризалар йөздән артты. Биш йөз булды, хәтта меңгә җитте. Югарыдан түбәнгә кадәр сузылып-сузылып төшкән икешәр аршын озынлыктагы ефәк кәгазьләргә язылган бу гаризалар һәрбер диваннарны тутырып бетергән иде. Буннарның һәрберсендә төрле-төрле хөрриятләр таләп кыйлынган иде.
Бу кадәр күп гариза вә таләпнамәләренә илтифат кыйлмый калдыру мөмкин түгел иде. Бервакыт җәмигъ мандариннар, бер арага җыелып, сиксән биш маддәле, тәмам биш аршын ярым да ике вершок чирек озынлыгында бер ляихә тәртип иттеләр. Бу ляихәдә дунганнарга бик күп җиңеллекләр вәгъдә ителмеш иде. Ляихә шул көннәрдә тасдыйк ителәчәк иде. Шулай да булса дунганнар ул ляихә тасдикъ кыйлынып чыкканчы сабыр итмәделәр. Далай-лама берлә Юань Шикайның шул көннәрдә көрәшәчәкләрен вә алар янына далай-лама белән бер дәрәҗәдә хисап ителмәктә улан дунган голямасының да барачагын ишетеп, дунганнар Кантоннан, Фио-Чио-Жиодан5, дәхи башка бер тарафлардан сайлап, ун кадәр озын сыйраклы, нечкә мыеклы картларны Юань Шикай янына җибәрделәр иде. Юань Шикай бүген төннән бирле шуннарны каршы алырга хәзерләнә иде.
Юань Шикай өчен болар бик хәвефле кешеләр иде. Чөнки араларында «боксерлык»ка күп хезмәт иткән «Зур йомрык»ларның да иң зур йомрыклысы, «иттифакъ»ларны куәтләүче фамилияләрнең барлыгы Юань Шикайга бик мәгълүм иде. Шуның өчен анларның каршына чыкканда, бик җәсарәтле, бик куәтле, бик мәһабәт күренү лязим иде. Гәрчә Юань Шикай, югарыда әйтелгән тәмам биш аршин ярым да ике вершок чирекле ляихәне күрсәтеп, аларны тынычландырачак иде. Шулай да булса аны күрсәткәнгә кадәр серне бирмәү лязим иде.
Юань Шикай хәзерләнеп тәмам булды. Киң кырпулы зур эшләпәсен киде. Тәхет шикелле ясалган урындыкка кәмаль сөкүнәт илә менеп утырды.
Бик тәкәллефләнгән вакытта гына истигъмаль итмәктә улан куркурына әфиун берлә катыштырылган тәмәкене тутырткан. Гәрчә өй эчендә булса да, кибарлыкны дәхи дә бераз арттыра төшү өчен, баш очында зонтик тотып торырга да әмер итте. Якындагы игъваны да вакыйган кибар булганлыгына шәһадәт бирделәр.
– Эш тәмам җирендә, инде кереп күрсеннәр! – диде.
Сарай ишеге ике тарафка ачылды. Бер-бер артлы ун кеше, ике кулларына яна торган шәм тоткан кыяфәттә дүрт бармакларын йомарлап, шәһадәт бармакларын күккә таба каратып, күкрәкләре тугърысында кулларын тотып, аякларын сыгылдырып-сыгылдырып атлап, кыр казлары кеби тезелеп керделәр. Ярты даирә шәкелендә түгәрәкләнеп тезелделәр. Гәүдәләрен бер дә хәрәкәтләндермичә, идәнгә тезләнделәр. Соңра, торып, башка җирләрен бер дә хәрәкәтләндермичә, кул кушырдылар.
Юань Шикай, кәмаль җәсарәт илә:
– Ни эшкә килдегез? Юань Шикайның куәте беткән, һичнәрсә кыйлырга хәле калмаган, бугазына ябышып, мәкъсудларымызны алырмыз дипме? Ю-у-ук! Юань Шикайда әле куәт бетмәгән, алай тиз генә җиңә алмассыз! Хәзер аяк табаннарыңызга йөзәр таяк ордырырмын, – диде.
Дунганнар, куркуларыннан калтырап, тез чүктеләр:
– Әстәгъфирулла! Без һичбер андый эш өчен килмәдек. Бәлки, сезнең мәрхәмәтеңезне өмид...

– Беләм, беләм, мин сезнең һәммәңезне дә, эшләгән эшләреңезне дә үземнең биш бармагымны белгән шикелле беләм. Мин сезнең «Боксер»ларыңыздан, «Зур йомрык»-ларыңыздан, «Зур бот»ларыңыздан асла курыкмыйм!
Дунганнар, бер аваз илә көйләп:
– Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, Ходай күрсәтмәсен, Ходай сезгә ярдәмдә булсын, дошманнарыңыз мәкъһүр булсыннар, дәүләтеңез, куәтеңез артсын. Бәндәләреңез һич андай фиркаләрдән түгелмез, безнең анларга асла катышымыз юк, анлар безгә бөтенләй башкалардыр. Без сезнең гасры сәгадәтләреңездә дөньяга килдек, сезнең күләгәңездә яшәдек, сезнең кулыңызда үләчәкмез, сезнең юлыңызда корбаннармыз. Ул фиркаләрнең Нижнг-Наун шәһәрендә җыелып ясаган хыянәтле җыеннарыннан вә анда төзегән програмнарыннан без камилән пакьләрмез. Без анлар сораган нәрсәләрнең һичберсен дә таләп кыйлмыймыз. Әгәр сез, мәрхәмәт кыйлып, безгә кытай теленнән ике мең сүз бикләүне, безнең дунганнарның дин башлыкларын гаскәргә бирүне бетерсәңез, безнең балаларымыз укый торган йортларны кытайлы хакимнәрдән тәфтиш иттерүне бетереп, безнең башлыгымыз нәзаратенә бирсәңез, китапларымызны кытайча бастырырга тәклиф итмәсәңез, безнең ярлы гаиләләремезгә ачлык булган елларда бераз дөге биреп туйдырсагыз, без бик мәмнүн булачакмыз. Безгә башка һичбер нәрсә дә кирәкмидер. Әгәр сез безнең ушбу мәкъсудларымызны бирсәңез, без гомер буена сезгә дога кыйлачакмыз, – диделәр.
Юань Шикай бик иркен бер сулу алды.
Игъваннарга әмер итте. Дунганнарның һәрбересен урындыкларга утырттылар. Кулларына берәр касә хуш исле әгъла чәйләр тоттырдылар.
Юань Шикай тәмам шатланды. Дунганнарга:
– Сезнең мәкъсудларыңыз бары да булыр, – диде. – Безнең хакимнәремезне һәм Хан-Ман-Чуны (ягъни диннәр башлыгы) да күреңез, мин анларга да хәбәр итәрмен. Анлар сезне кунак итәрләр, – диде.
Бик тәвазигълык илә вәкилләрне озатты. Вәкилләр чыгып китте.
Юань Шикай, диван тарафына кереп, хәзер шул дәкыйкадә кятибләрнең табаннарына йөзәр камчы орырга әмер итте.
– Ах сез, ахмаклар, җаһилләр! Бөтен дөнья шау килә, дунганнар да тәмам кузгалганнар, әлләниләр сорыйлар диеп, биш аршын ярым да ике вершоклы ляихә ясатып, әллә нинди имтиязлар бирдерә яздыңыз. Ә анларның бар сораган нәрсәләре вершок ярым, ике вершок кадәр нәрсә икән! Анлар «Боксер»лар, анлар «Хунхуз»лар, анлар «Зур бот»лар, анлар «Зур йомрык»лар диеп куркытып бетердеңез. Чынлап карасаң, алар кечкенә бармак башы да түгел, имеш. Егерме мең сүз бикләгән көенчә, мин монда сезгә жалуния биреп туйдырып ятам. Дөньяның хәленнән, галәмнең рухыннан һич хәбәреңез юк. Гыйлемеңезне егерме бер мең сүзгә җиткергәнче, егерме бер мең хәреф таныганчы, минем хезмәтемә килмәңез. Сезнең наданлыгыңыз аркасында биш аршын ярым да ике вершок чирекле ляихәне күрсәтеп харап була яздым, – диде.
Бу сүзләрне бик ачу берлә сөйләде.
Биш аршын ярым да ике вершок чирекле ляихә утка ягылды. Аның урынына ике вершоклы, биш маддәле ляихә язылды һәм нәшер ителде.
Дунганнар, ике көпчәкле гүзәл арбаларга утырып, бер хакимнән икенче хакимгә чабып йөреп, берничә көн кунак булдылар. Соңра шатланып өйләренә кайтып киттеләр. Бары тик ике жерда өстенә ясалган тәхеткә утырып, кытайларның җилкәләренә атланып йөрүләр генә боларга насыйп булмады... Хафаланырга тиеш түгел, бәлки икенче бервакытта анысы да булыр әле.
Кытай хикәяте ушбу урында тәмам булды. Казан хикәяте, бәлки, икенче бер фельетонда язылыр әле5.
Депутатлар озату
Петербург юлында. Беренче урын

Вагонда егерме дүрт урын. Шулай да күп урыннар буш. Бәлки, киләчәк стансадан янә берничә депутатлар керерләр. Ул урыннарга да ия чыгар.
Эшне баштан башларга кирәк. Ишектән кергәч тә бер урында бер социалист1 арка өстенә яткан. Җүеш исле төтеннәрне әтрафка өреп-өреп җибәрә.
«Хәкыйкатән бәхетлемен: Думага әгъзалыкка сайландым. Думада үткәрәчәк гомеремнең бүген беренче көнедер. Дума галәме бик ләззәтле бер галәм булырга охшыйдыр. Бу көннән башлап җәннәттәмен, кара менә, төтеннең никадәр хуш бер исе бар? Бу җәннәт нигъмәте булмаенча нә булсын? Бер генералның агызына гына насыйп булырлык бу нигъмәт бу көн минем кулымда!
Бу гүзәл хәтфәләр белән түшәлгән койкалар (ятаклар) никадәр матур. Бу да, әлбәттә, җәннәт нигъмәтләреннән бер җөзьә түгелме? Бу көнгә кадәр бундай хәтфәләрнең өстләренә яту түгел, бәлки хатынымның жакет якасына куярга да юк иде. «Хатыным» дидем. Бу сүз аның дәрәҗәсене төшерү булмыймы? Дума әгъзасының иптәше булгач, аңар «зәүҗә мөхтәрәмә» дип хитабе мөнәсәбәт булса кирәк.
Һәр эш җирендә икъбалем! Бәхетем ачылды. Фәкать бу аяктагы тузган штиблетларның гына бундай гүзәл хәтфә урыннар өстендә ятарга истихкакы юк.
Зарар юк.
Петербургка баргач та алмаштырырмын. Аның иң яхшысыны алырга бер көнлек вазыйфә акчасы җитә. Бу өстәге киемнәр дә бераз почымсызрак. Зарар юк. Анларын да алмаштырып булыр. Анларга күп акча кирәкми. Бер айлык вазыйфә илә барысын да тәкмил итү мөмкин булачак. Икенче айның вазыйфәсе барысы да «зәүҗә мөхтәрәмә»нең хакыдыр. Дума вәкиле булган кешенең «зәүҗә мөхтәрәмә»ләренә җыртык күлмәкләр киеп, садә бер «рабочий» хатынына охшап йөрү, сасы өйләр эчендә яту нәкыстер. Чөнки мин бу көннән кадер-хөрмәттәмен. Минем иптәшем булганнан соң, аның да хөрмәтле булуы лязимдер. Мөсавәт, гадәләт шуны моктәзыйдыр. Бу кулларның сырлары арасында урынлашкан фабрик тузаннары бу көннән соң булмаска тиешледер. Чөнки «ташлыйк, туганнар, иске дөньяны, китсен аяктан аның тузаны»2 – бу минем мәсләкемдер. Әлбәттә, мин анларны һәйбәтләп сабынлап җуып тәмизләячәкмен.
Аһ! Бу социализм нәкадәр мөкаддәс нәрсәдер! Гадәләт, мөсавәт – бу мәзһәбнең мәкъсудыдыр.
Иштә бу көндә бу вагонның эчендә бер профессор, бер бай, бер доктор, бер мулла бар. Һәммәбез дә бәрабәр, һәммәбез беренче класcның эчендә. Беренче класс?! Бу ни дигән сүз?
Дөньяда ничә төрле класс булу мөмкинме? Мин бу урында, беренче класста, рәхәт-рәхәт бараем да, анда, өченче, дүртенче классларда эш эзләп икенче шәһәрләргә баручы минем рабочий кардәшләрем тыгыз, сасы урыннарда бер поездда бер сәфәрдә булсыннар. Ахирәт сәфәренә бара торган бу дөнья кәрванында бер адәм бәхетле вә рәхәт-рәхәт яшәсен дә, икенче бер адәм мәшәкать вә михнәтләр эчендә сәфәр кыйлсын. Бу һич мөмкин түгел! Бу эшкә Маркcның рухы, әлбәттә, ачигъланачактыр.
Һич кабул итмәм!
Думага баргач та, иң беренче эшем кардәшләремне буржуаларның кулыннан коткару булачактыр. Кадетлар анлар да «вак буржуалар». Анларга да һичбер агыз ачып сүз сөйләргә ихтыяр бирмәячәкмен. Дөньядан эксплуатациянең, капитализмның нигезене куптарып ташлау вәҗибтыр. Кардәшләремне азат кыйлу өчен җанымны-тәнемне фида итәчәкмен. Кардәшләрем дә минем кеби мәсгуд булсыннар. Буның кеби җәннәт эчендә анларның да минем кеби рәхәт, мәсгуд улып яшәүләре лязимдер. Буның өчен бөтен иҗтиһадымны сарыф итәчәкмен. Маркcның рухы шат булсын!
Фәкать бу эш булачакмыдыр?
Мәкъсудыма җиткәнче Дума куылса, ни эшләрмен? Думаны халык химая кыйлырмы? Бу – бераз шөбһәле. Буржуалар да дөньяда бик күп. Бар эшне дә без теләгән кадәр үк итеп эшләргә ирек бирмәячәкләр. Фәкать ни зарар?
Бөтенләй булмаса, һич югында, бераз булып торса да ярар.

Ул тәкъдирдә кәмаль мөсавәт вә гадәләт вөҗүдкә килмәсә, ягъни кардәшләрем анлар минем кадәр мәсгуд булмасалар, минем бу гүзәл урыннарда ятуым, тәмле ашап, тәмле эчүем, яхшы киемнәр киенүем кешеләрнең хезмәтеннән истифадә булып бер нәүгъ буржуалык булмыймы?
Булса, ни эшләмәк кирәк? Дөньясы шулай булгач, аның өчен мин һич гаепле түгел. Думаның таралуыны һич кабул итү ихтималым юк. Биш ел бик тырышып хезмәт итәчәкмен3. Фәкать шул биш ел эчендә мәсарифтән арткан акчамны ни кыйлачакмын?
Бер дә хафаланмыйм. Ул кадәр ахмак түгелмен. Урамга чыгарып ташламам. Картлык көнемдә ярар әле. Яшәсен социализм! Аның аркасында никадәр бәхетлемен! Ул булмаса, минем һич тә Думага керү ихтималым юк иде, дидер.
Социалистның фикере беленде! Дума әгъзаларының фикерләрене белү бик әһәмиятледер. Инде икенче урынга күчик.
Икенче урын.
Бу урында бер октябрист профессор җирләшмештер. Хәер, бу көнгә җитеп торыр, ахры. Күп булгач, тәме китәр. Аның фикерене икенче вакыт язармын.
Хәзергә шуны укып торыңыз әле!
Гәзитә караклыгы

«Бәянелхак» гәзитәсенең йөз утыз беренче нөсхәсендәге1 «Кая китте иркенлек?» нам мәкаләнең цензор тарафыннан сызылу сәбәпле берничә юл буш калдырылмыш2 улдыгы дикъкатемне җәлеп кыйлды. Мәкаләнең сәрләүхәсенә, соңра имзасына күземне төшердем. Мәкаләнең Камил Сатламышский тарафыннан язылуы дикъкатемне дәхи дә артыграк җәлеп итте. Цензор тарафыннан сызылган мәкаләләрнең әксәре, гадәттә, сәяси вә мөһим мәсьәләләрдән гыйбарәт булмактадыр.
Бу көнгә кадәр Камил Сатламышский тарафыннан язылган берничә шигырьләр мәнзурым улса да, мәзкүр «шагыйрь» әфәндинең нәсер уларак язылган сәяси әсәрләрен бу көнгә кадәр күргәнем юк иде.
Бу яңа мөхәррирнең нәсердәге икътидары нә дәрәҗәдә идекен күрү һәвәсе илә мәкаләсен укымага башладым. Фәкать укыдыкча, тәгъзим артмага башлады. Мәкаләнең гыйбарәләре бәңа бик якын күренде. Бераз укыгач, кайчандыр минем дә бу мәфһүмдә бер мәкалә язганлыгым хәтеремә килде. Янә бераз дәвам иттем. Ахырына кадәр укыдым. Ниһаять, бу мәкаләнең «Азат» гәзитәсенең кайсы номерындадыр язмыш улдыгым, бу мәкаләмнең гаяны идекенә канәгать хасыйль иттем. Гыйндемдә мәүҗүд «Азат» нөсхәләрен актармага башладым. Күп зәхмәт чикмәдем, таптым. Сатламышскийның бу мәкаләсе «Азат» гәзитәсенең 7 февраль, 1906 сәнәдә чыкмыш өченче номерында язмыш улдыгым баш мәкаләЗ, имеш. Сатламышский җәнабләре нәкадәр мәшәкатьләрне тәхмил идәрәк күчереп язып, ахырына үз имзасын куеп, «Бәянелхак» идарәсенә вирмеш. «Күчереп язып» дидем, чөнки әгәр күчереп язмаса, бәлки, басма нөсхәсенең кәгазен генә идарәгә илтеп вирсә иде, ахырына имзасын җирләштерә алмас һәм гәзитәдә басылган бер нәрсәгә имза куюга идарә дә разый булмас иде. Угырланган бер кием базарга чыкканда, эксәрдә, төймәләре вә гайре бер әһәмиятсезрәк җирләре аслына нәсбия бераз үзгәртелгән буладыр.
Сатламышский да бу сәнгатьне яхшы белә икән: мәкаләнең ялтыраганрак җирләренә каралар сөртеп, күчергән вакытында бәгъзе бер кәлимәләрне бераз авыштырмыштыр. Җөмләдән берсе: мин үземнең мәкаләмдә «Иркенлек кадәр дөньяда дәхи дә бер тәмле, ләззәтле нәрсә бар микән?» димеш идем. Сатламышский ни өчендер минем «дәхи дә» дигән сүземне «янә» дип төзәтмеш. «Манифестта: диндә, басмада иркенлек, иттифакълар, җыеннар ясарга ихтыяр...» дигән сүзләр ни өчендер «иттифакълар» кәлимәсен төшереп калдырмыш. Бәлки, ашыгыбрак күчергәндер, ихтимал шул сәбәпле төшеп калган булуы. Сатламышскийның үзгәрткән вә төшереп калдырган сүзләренең мәҗмугы утызлап бар. Танымасын дигәч тә, минем мәкаләмне ул кадәр мәсхәрә кыйлу кирәкмәс иде. Хосусән минем «Шикәрле дигән нәрсәләремезгә тоз катышты» дигән сүземне «Баллы дип әйткән тәмле нәрсәләремезгә борыч төште» дип үзгәртүенә асла разый дәгелмен, чөнки мин бу

урында укучыларга бик тәмсезлекне аңлату өчен бу гыйбарәне язмыш идем. Минем карашымда иң тәмсез нәрсә – шикәр белән тозның бергә катышуы иде. «Тоз шикәргә катышса, бик тәмсез була», – диләр иде.
Минемчә, бал илә борыч ул кадәр үк тәмсез нәрсәләрдән түгелдер. Хәтта Бохара тарафларында борыч илә бер тәгамдәрәк булган имбирдән мөрәбба (варенье) кайнаталар, бик ләззәтле буладыр.
Соңра Сатламышскийга бигрәк кәефем киткән җире шулдыр ки, «асла гөнаһысы булмаган мескен «Бәдәвам» вә «Тәкый гаҗәб»ләремез яңадан бер көн терелер микән?» сүзен төзәтмәгән, кирәксез җирләрен төзәтеп, кирәклесен калдырган. Чөнки мин язган вакытта «Бәдәвам» вә «Тәкый гаҗәб»ләргә басарга рөхсәт бирелми иде. Китаплардан цензор алынмаган иде4. Ул вакыттагы 7 февраль илә бу елның 20 февраль арасында бер елдан артык вакытлар узып китте. «Бәдәвам» вә «Тәкый гаҗәб», кабердән терелеп чыгып, Русиянең һәрбер тарафларына күптән таралдылар. Әгәр мәкаләнең шулкадәр җирен калдырган булса, гүзәл булган булыр иде.
Бу көнгә кадәр бәгъзе бер адәмнәрнең, төрек теленнән китап тәрҗемә итеп тә, «мөхәррире фәлән» дип язмакларын күргәнем бар иде. Әмма бер ел мөкаддәм бер гәзитәдә язылган мәкаләне угырлап, өстенә үз исемен куеп, икенче бер гәзитәгә биреп бастырганны күргәнем юк иде. Дөнья булгач, андый эшләр дә була икән. Сатламышский җәнабләре! Вакытыңыз булганда, безнең идарәмезгә бер кереп чыгыңыз. Идарәдә мин сезнең өчен мәхсус берәр нөсхәдән илле алты номер «Азат» гәзитәсен хәзерләтеп куйдым. Шунларны биреп чыгарырмын. Кирәк саен мәкаләләрен алып-алып, гәзитәләргә дәрҗ кыйлып торыңыз. Анларның сезгә шөһрәт җибәрергә яраклы мәкаләләре, бәлки, күп табылыр. Фәкать ахырына һичбер вакытта Сатламышский дип имза кыйлырга разый дәгелмен. Мәкаләләрнең сүзләрен дә үзгәртмәссез. Үз кулым берлә биреп чыгаргач, угырланган нәрсә булмыйдыр. Ул вакытта иясе танымасын өчен үзгәртергә хаҗәт булмыйдыр.

Депутатлар озату
Петербург юлында. Икенче урын

Беркөн мин беренче урында яткан социалистның фикерләрене язган идем1. Ул мәкаләмне укыгач, бер таныш социалистым миңа бик ачуланды: «Ул сүзләрең илә син социализмны тәхкыйрь кыйлгансың», – диде.
Әстәгъфирулла!
Миндә һичбер андый явыз ният асла булганы юк. Мин бары анда бер вагондагы бер социалистның гына фикерләрене бәян иттем.
Әгәр Думада бу фикердә булган бөтен бер вагон социалист булса да, социализм өчен анлардан һичбер зарар килү ихтималы юктыр. Башка вагондагы социалистлар, шаять, яхшы кешеләрдер. Анлар, шаять, чын социалистлардыр. Бның өчен ул дустымның ачулануы хаксыз дип беләмен.
Йә, ярар ла! Ачуланса ачуланыр инде. Ачуланса да, мин үз эшемдә дәвам итәчәкмен. Икенче урынга бер октябрист профессор2 җирләшмеш иде.
Бу да татлы төтеннәрне үрмәктә исә дә, социалистның төтеннәре илә бунң төтеннәре арасында истә дә, төштә дә аерма бар. Профессор кимиядән хәбәрдар адәмдер.
Шул сәбәптән, зәһәрле агулары эчкә кермәсен өчен, агызлык эченә «гавана» мамыгы тутырып, төтенне шуның аркылы гына суырмакта иде. Социалист илә буның арасында башка җәһәттән дә аерма бик күп. Профессорның, Петербурга баргач, сабынлап кул җуасы, яңа шиблит, яңа киемнәр аласы да юк. Фикер җәһәтеннән аермалары дәхи дә күбрәк. Профессор: «Мин Думага сайландым. Әгәр Дума бөтенләй булмаган булса, һәмишә искечә торылган булса, бигрәк яхшы булган булыр иде, әмма ни эшләмәк кирәк? Бу елларда халык бик котырып китте. «Безгә һичбер хөррият юк, һәр тарафтан кысалар, чәчәргә җир юк, җирдән хасыйль булган ашлыклар ашарымызга җитми», – дип гауга чыгардылар. Бернәрсә дә бирмичә бунлардан котылып булмас төсле күренә. Аз-маз биргә-

ләргә кирәк шунда, агызлары тыгылсын. Шулай да бик күп ычкындырып бетерергә ярамый. Хосусән җиргә яхшы бәһа бирмәсәләр3, мужикларга бер дисәтинә4 бирергә дә разый булачак түгелмен.
Социалистлар вә, белмим, әллә нинди кызыллар дәгъва кыйлганга карап, үз милкемдәге җирләрне кеше кулына бушлай гына җибәрә алмам. Бирсеннәр акчаны күп иттереп! Әгәр бүген имениеләремнән килә торган доход кадәр процент китерерлек акча бирсәләр, ник сатмаска? Ул вакытта тып-тыныч, килгән процент берлә рәхәтләнеп ашап тик ятасың. Һичбер баш авырттырып, мужиклар берлә кычкырышып йөрисе булмый.
Эшне мәкъсудча итеп эшләргә Думада фикердәшләремез генә азрак күренә күренүен дә5, шулай да булса күп зарары булмас. Кызыл агызлар күп җикеренә башласалар, барыбер дәхи дә һичбер эш булдыра алмаслар. Дума таралыр. Таралса, бәлки, яңадан җыелмас6, эшләр искечә калыр. Һәмишә әүвәлге шикелле рәхәт-рәхәт яшәрмез.
Мин Думага сайландым. Бер яктан караганда, бу минем өчен зарарлы да. Думада көненә бары ун тәңкә генә вазыйфә бирәләр. Профессор булып торганда, мин күбрәк төшерә идем. Шулай да булса «Берсенең куесы, берсенең сыегы» дигәннәр. Ике бәхет бер кешегә җыелып бетмидер. Думага барырга мин дә разый булмасам, башкасы да илтифат итмәсә, анда әллә нинди кызыллар җыелып, җиреңнең көлене күккә очырып бетерерләр. Бер яктан, зарар булса булыр инде. Икенче яктан, килгән файдасы булгач, шул җитәр.
Белер хәл юк. Бәлки, ике тарафтан да файдалы булыр. Бу көнгә кадәр әһле гыйлемдә һичбер шөһрәтем чыкмады. Бәлки, бундан соң зур кеше икәнемне белерләр дә, эшләрем алга китәр. Ул кадәресе булыр, йә юк. Әмма ничек булса да, кулымдагы милкемне кешегә бирмәм».
Профессор янында күзгә рәтле эш күренмәде. Тизрәк өченче урынга – мулла абзый янына сызарга кирәк. Ул ни фикердә икән?
Дахили хәбәрләр

Гаибтән хәбәр бирүләренә караганда, киләчәк Дума тиз көннән шәһәр идарәсе низамнарыны тәфтиш итәчәк вә яңа низам буенча авырлыгы җиде поттан артык булган кешеләрне һичбер шәһәрдә, хосусән Казанда гласныйлыкка кабул ителмәячәк, имеш. Фәкать бундый кешеләрнең ибтидаи тәгълимне бетереп язу таныганлыгына кулында шаһәдәтнамәсе булса, бу низамнан мөстәсна булачактыр.
(Бу хәбәр бик күңелле түгел. Чөнки бу закон тасдикъ ителә калса, мөселманнардан да бер өч-дүрт кешенең гласныйлыкка сайлана алмый калу ихтималы бардыр.)
*
Ишеттекемезгә күрә «Җәмгыяте хәйрия» мәктәбендәге балаларны тәрбия итәргә өстләренә алган байлар, әгәр дә сабак укыячак балалар яңадан бер-ике ел сабыр итсәләр, вәгъдә кыйлган акчаларыны бирәчәкләр, имеш.
*
Әгәр дә чын сүз булса һәм ышанырга да яраса, тиз көннән Казанда канализация салачак*, һәм мөселманнар икамәт кыйлмакта улан Иске бистә вә Яңа бистәләр кабахәт вә начар исләрдән котылачаклар, имеш.
Бу эшне булдырырга мөселман гласныйлары бик зур сәбәпче булган, диләр.

Депутатлар озату
Петербург юлында

Бу вагонда егерме дүрт урын. Шулай да күп урыннар буш. Бәлки, киләчәк станцада янә берничә депутат керерләр, ул урыннарга ия чыгар.
Эшне башыннан башларга кирәк. Ишектән кергәч тә беренче урында бер социалист1 арка өстенә яткан. Хуш исле төтеннәрне әтрафка өреп-өреп җибәрә...
Икенче урын. Бу урынга бер октябрист профессор2 җирләшмештер.
Өченче урын...

Хәзрәт бик шат3. Берүзенә дүрт кешелек урынны алып, тәмам хозур кыйлып, кәефләнеп бара. Бер яктагы койкага нәрсәләрен җирләштереп, икенче тарафтагы койкага сузылып ятмыш иде.
Вагон эчендә һичбер тавыш юк. Вагон көпчәкләренең монтазамән тыкырдап баруы фаразга чуму өчен хәзрәткә бик зур ярдәм бирмәктә иде.
Хәзрәт тәкъва адәмдер. Төтен кеби нәрсәләрдән камилән пакьтер. Мондый нәрсәләргә акча исраф итүчеләр токымыннан дәгелдер. Шулай да булса кәефе бик яхшы, күңеле шат иде.
Вагон көпчәкләренең алга таба тәгәрәгән тавышлары Петербурга бармакта идекен хәзрәтнең хәтеренә китерде... Вагонның эченә күз гиздереп чыкты. Һәр җиренең бик мөзәйян идекен күреп, рәхәтләнеп киерелеп бер сулу алды:
– Шөкерләр булсын, халыкның җәфалауларыннан котылдым, – диде.
Үзенең хәлен тикшермәгә башлады: «Мин хәзер инде Думага сайландым, бер-ике көннән Петербурга барып җитәчәкмен. Гүзәл, мөзәйян сарайларының эчләрендә утырып, бөтен Русиягә хөкемнәр йөртәчәкмез. Бу дәрәҗәләр ахуннарга, карыйларга, хәтта мөфтиләргә дә бу көнгә кадәр мөяссәр булганы юктыр. Хәзердә минем мәртәбәм болардан бик күп дәрәҗәдә галидер. Чөнки анлар безнең ясап чыгарган низамнарымыз буенча эш йөртәчәклрдер. Анлар безнең әмеремезгә мотыйгъ булачаклардыр. Бән бу дәрәҗәгә Алланың миңа ярдәме саясендә генә ирештем. Үземнең иҗтиһадым да булмады түгел, булды. Бик күп тырыштым, бик зур мәшәкатьләр күрдем. Авылдагы иң түбән дәрәҗәдәге мужиклардан башлап шәһәрдәге иң зур байларга кадәр тарелка тотарга мәҗбүр булдым. Фәкать ансыз һич мөмкин түгел иде. Ул кадәр кешегә үзеңне яраттыру да бик мөшкил эш. Картларны ышандыру ул кадәр бик читен булмаса да, арада «яшьләр» дигән нәрсәләр бар. Йөзе каралар, анларны кулга алуы бик мөшкил булды. Шулай да булса кулда куәт юк түгел. Ничек тә булса җиңдем. Мужиклар минем кулымда, анларны ничек тә бөгеп була. Менә шулар аркасында мин Думага эләктем дә.
Фикерем яхшы булды әле. Яшьләргә әйттем:
– Мужиклар бары да минем кулымда, анларны мин теләсәм нишләтәм. Әгәр сез мине сайларга разый булсаңыз, мин аларны сезгә каратачакмын, – дидем. Бик разый булдылар. Шулай иттереп «сагыйрә»ләрне, «көбра»ларны бик нык беркетеп куймасаң, нәтиҗә чыгаруы бик читен булачак. Хәзерге яшьләрнең авызларына шайтан төкергән шикелле, әллә нинди без моңа кадәр исемнәрен дә ишетмәгән фәннәрне белеп, халыкны тәмам үзләренә каратачаклар. Иске осталыгым аркасында көчкә генә эләгеп калдым. Муллалардан минем шикелле нәфесләрен сузып, хәмлә кыйлып караучылар бик күп булды. Шулай да берсе дә минем кадәр эшләрне булдыра алмадылар. «Әлхәрбе хәдәгатен»дер. «Хәйләсез – дөнья файдасыз», – дигәннәр. Бу – бер сугышта җиңү шикелле. Монда бер дә хәйләсез мөмкин түгел. Әмма үзләрен кызык иттем соң! Сайлау вакытында яныма бер рус килде дә колагыма гына:
– Сез әсирме? – ди.
– Мин нишләп әсир булыйм4, мин азат кеше, һичбер кешегә кол булганым юк. Нишләмәк кирәк, аздан гына эшне калдырырга ярамый. Башымны селкеп:
– Ун, ун, – дидем5.
– Алай булса, сезгә шар салам, – диде.
– Бик яхшы булыр, салыңыз! – дидем.
Аның артыннан икенче бер рус килде дә:
– Кнәз, сез эздикме?6 – ди.
Измәдек түгел инде, дөнья булгач, төрле вакытлар була. Изгән чаклар да юк түгел иде. Кайвакытларда куерта да торган идек. Шулай да булса серне биреп бетерергә ярамый, кешенең кәефе китүе ихтимал. Аңар да:
– Ун, ун, – дидем.
Йөзе караларның әллә никадәр партияләре бар. Шайтан да белеп бетерә алмас.
Аның артыннан дәхи дә бер чибәррәк кенә киенгән бер мөселман, килеп:

– Хәзрәт, сез «Мөселман иттифакы» партиясеннәнме?7 – диде.
Аңар да ялгышлык белән:
– Ун, ун, – дип ычкындырып җибәрдем. Әле ярый мәгънәсен аңламады.
– Хәзрәт, сез русча гына сөйләшәсез икән, – ди.
Ничек тә булса сайлаулар бик яхшы узды. Кулдан килгән кадәр хәйләләрне кыйлдым. Әмма һичбер вакыт ялганламадым.
«Ун» дип әйтмәенчә, ничек дип әйтим? Ун булгач, аны унбер дип әйтиммени?
Унбер сум булган булса, дәхи дә яхшырак булган булыр иде дә бит, ни хәл итмәк кирәк, артыгын бирмиләр. Писер быел унбиш тәңкә биреләчәк икән дип бәйләгән иде дә, тугъры булып чыкмады. Барына канәгать кыйлырга кирәк, көненә ун тәңкә дә бик аз акча түгел. Ул бит, әгәр Дума куылмаса, биш елга кадәр ничә меңтәңкә була. Узган ел барган бер мулла җитмеш ике генә көн торып кайтты8. Алай да, кайткач та, яңа капкалар ясап, өйләрен тазартты, диделәр. Көненә ун тәңкә генә булса да, биш ел торып кайтсаң, капка ясау гына түгел, җәннәт сарае шикелле йорт салырга, менә дигән тройка атлар алырга мөмкин була.
– Ярабби Хода!!! Барган юлы Думаның дәвамын гына насыйп әйлә!
Мужиклар:
– Анда баргач инде, хәзрәт, зинһар, безгә файдалы законнар чыгарырга тырышыгыз, – диделәр.
Акчасы акча да, менә шул «закон чыгару» дигән сүзләре бераз кәефне җибәрә төшә. Нинди закон чыгарырга кирәк? Аны кайдан алып чыгарасы? Хәер, аның өчен хафаланырга ярамый, анда минем шикелле кешеләр дә күп булыр. Рәтен белгән кешеләр табылыр әле. Узган ел барган мулла минем кадәр дә аңламый иде. Алай да исән-сау, сәламәт йөреп кайтты».
Хәзрәт яныннан китәргә кирәк булыр, ахры.
– Хуш, хәзрәт, хәерле юлга!
Депутатлар озату
Петербург юлында. Дүртенче урын

Белмим, буның янында күп рәт булыр микән. Битләре дә яхшы ук кызарган. Борынының кызыллыгы дәхи дә артыграк. Хисабына күрә, Петербургка барып кергәннән соңра өч-дүрт көнгә кадәр ашарга җитәрлек зур, юан бер колбасаны янына куйган.
Мин янына килеп җиткәндә, стаканында һичбер нәрсә күренми иде. Шулай да булса, мин күргәнчегә кадәр, бер стаканны бушаткан булырга охшый иде. Чөнки борынының градусы бик югары булуы өстенә күз алмалары да ике катлы булган шикелле күренә иде.
Кулларыны да бер йомарлый, бер ача. Зур-зур гына колбаса кисәкләре дә, булка илә бергә төрелеп, бик шома гына агызына кереп гаиб була иде.
Вагонда бундан рәхәт, бундан да шат һичбер кеше юк. (Шат дигәч тә, ачык чырайлыдыр диеп хәтереңезгә китерә күрмәгез, буның шатлыгы үзенә нисбәт иләдер. Юкса чәһрәсе бик дәһшәтле, хәтта каршысына килгән безнең шикеллерәк вак-төяк кешеләрне колбаса урынына йотар төсле күренәдер.)
Буның шатлыгы бөтенләй үзенә башка бертөрле шатлык. Буның сабынлап кул юуда, штиблет алуда, яңа кием алмаштыруда һич кайгысы юк. Хәтта кайгысызлыгыннан булырга кирәк дип уйладым, өеннән күлмәк алмаштырып чыгуны да хәтеренә алмаган. Шулай да колбаса онытылмаган.
Бу зур кешенең фикерене белү дә бик җиңел булмас төслерәк тоела.
Хәерле булсын, бераз сабыр итәргә мөмкин. Әле минем төшәчәк стансама барып җитәргә вакыт күп. Фикеремдә ялгышмадым.
Күп вакыт узмады, депутатым йомшады. Хәтта бераздан тәмам эреде.
Бәлки, эремәс тә иде, ләкин барган саен градусның кызулыгы артты. Мин тикшермәс борын, серләрене чишәргә башлады: «Әмма Думага да сайландым бит! Шаярырга ярамый,

бу бит колбаса сатып көненә илле тиен, бер тәңкә генә файда итү түгел. Суйган иттән генә ясаганда, ул кадәр дә файда итеп булмый.
Шөкер әле, эшләр һаман уңайга таба китеп бара. Бу арада погромнар да булмагач, мин, Думага әле кереп булмас, йөзе кара жидләр җиңәрләр, диеп курыккан идем. Жидләр дә, бер мәртәбә сабакларыны укыганнан соң, батырчылык кыйла алмадылар, ахры.
Минем сайлануыма каршы тавыш чыгара алмадылар.
Көненә ун тәңкә!
Тәмам шартлаганчы эчсәң дә бетәрлек түгел. Көн саен нәкъ кеше зурлыгында бер бутылкалык була. Менә рәхәт! Менә чын-чын куәт!
Менә моннан соң кызыл чүпрәкләрне агач башына элеп күтәреп йөрүчеләр минем каршыма килеп карасыннар! Бирермен кирәкләрен!..»
Поезд туктады. Черносотенец үзалдына: «Жидләрнеме? Анларны!..» – дип гайрәтләнә калды, мин төшеп киттем.
Ачларга ярдәм эшләре

Бу сәнә эчендә булган ачлыкның хәвефле бер микъдарда улдыгын нәзари игътибарә аларак, Казан шәһәрендәге әфкяр сахибе адәмнәр, фәкыйрь бичараларга аз булса да бераз ярдәмдә булу өчен, үзара иттифакъ илә, бер комитет тәшкил итмеш иделәр. Башында комитетның сумасы бик аз иде. Шул сәбәптән башында фәкать ике мең кешегә һәр көн аш вә икмәк бирелде. Соңра әтрафтагы мөселманнар да ярдәмгә иштиракь иттеләр1. Һәр тарафтан иганәләр килмәгә башлады. Бу иганәләр илә комитетның сумасы артты. Сумасының артуы нисбәтендә, комитет та үзенең ярдәмен көннән-көн арттырды. Әүвәлдә фәкать ике мең кешегә ителмәктә улан бу иганә хәзерге көндә сигез меңгә җитте. Комитет хәзерге көндә кулында булган сумасы илә 1 июльгә кадәр һәр көн сигез мең кешене ашатып тора алачактыр. Бу көннәрдә читтән иганәләр килүе туктаганлыктан, 1 июльдән соңра иганә итәргә комитетның сәрмаясе калмаячактыр. Апрель, май айларында көннәрнең салкын булып торуыннан, июльнең егермеләренә кадәр ашлыкның өлгермәве тәхмин ителәдер. Хәзинә тарафыннан җибәрелә торган паеклар да июнь башында фәкать июнь ае өчен генә биреләчәктер. Июнь ахырына кадәр ул ашалып бетәчәктер. Димәк, июньнең егермеләреннән башлап июльнең егермеләренә кадәр халык янә ачлыктан бик зур мәшәкатьләр чигәчәкләрдер. Иганәнең иң кирәк вакытлары ушбу ике арада булган бер ай микъдары вакытлардыр.
Әгәр ингам вә ихсан ияләре булган мөселманнар, халыкның бу ихтыяҗларын игътибарга алып иганәләр итәрәк мескен-бичараларны мәсрур кыйлсалар, бик гүзәл улыр иде.
Татарча театр

Өченчекөн кич Аркадий бакчасында1 Ильяс бәк Кудашев тәсаррыфында татарча «Галимнәр илә наданнар» исемле комедиянең2 ике пәрдәсе илә Чеховның русча «Хи-ругия» исемле әсәре уйналды. «Шәригать һәм заман» исемле әсәр, уйнала башласа да, Кудашевның тавышы беткәнлек сәбәпле тәмам булмаенча, пәрдә төште... Шул ук сәбәп илә уйналачагы игълан ителгән «Злоумышленник»3 та уйналмый калды.
Театрда халык бик күп, салоннан башка бар урын да тулы иде. «Галимнәр илә наданнар» комедиясе зарарсыз чыкты. Уйнаучылар арасында истигъдадлы кешеләрнең барлыгы күрелде. Низаметдин бай ролен уйнаучы4 адәм яхшы, гүзәл чыгарды. Уен гәрчә нәтиҗәсез һәм мөселманнар мәгыйшәтеннән ераграк, сүзләре дә әксәре бик килешсез исә дә, әтъвар вә хәрәкәтләре илә халыкны көлдереп, күңелне ачтылар. Икенче уен да бертөрле зарарсыз иде. Ләкин, халык аңламаганлыктан, сәерчеләргә тәэсире булмады. «Шәригать һәм заман» бик татсыз иде. Ахырына кадәр дәвам итеп вакыт уздырмаганлыклары өчен халык бик мәмнүн булды.
Гомумән әйткәндә, Ашказарскийның уенчыларында истигъдад күренәдер. Икенче дәфгаләрдә яхшырак уеннарны тамашага куйсалар, гүзәл булыр иде.

«Бәянелхак» һәм «вакыт»

Гәзитәмезнең йөз кырык бишенче номерында бер «Игълан» дәрҗ ителмеш вә бу игъланда гәзитәмезнең эше бу көнгә нәшер җәһәтеннән һичбер мөшкиләткә очрамаганлыгы язылмыш иде1. Ибтидаи нәшер ителмәгә башландыгы вакытта, һичбер гәзитә үзенең кыска гомерле булачагыны фараз кыйлмыйдыр. Һәрбересе, үзенең озын гомерле булып, халыкка күп хезмәт кыйла алуыны арзу итәдер. Ләкин һәркаюсының да мәкъсудлары хасыйль улмаенча, әксәре төрле сәбәпләр аркасында дөнья йөзеннән югалырга мәҗбүр булдылар.
Русиядә хөррият игълан ителгәннән бирле кырык кадәр төркичә гәзитә вә журналлар зоһур итте. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында күбесе тукталды. Бәгъзесе хөкүмәт тарафыннан туктатылды. Бәгъзеләре алучы юклыгыннан туктарга мәҗбүр булды. Һәртөрле мәшәкатьләргә тәхәммел итеп, арада берничә генә гәзитә сәламәт көенчә калды. Шул җөмләдән безем гәзитәмез «Йолдыз»дыр. Шулкадәр гәзитәләремез вафат итеп тә, берничә гәзитәнең һаман да терек хәлләрендә калуларына без, табигый, шатланамыз. Үземезнең игъланымызда да бу шатлыгымызны изһар кыйлдык. Без башка гәзитәләрне дә үземез шикелле шатланалар дип белә идек. Үзләреннән башка булган гәзитәләрнең дөньяда яши алуларына тарсына торганнардыр дип белми идек. Ләкин, ни тәәссефдер ки, андый гәзитәләр дә бар икән. «Йолдыз»ның дөньяда рәхәт-рәхәт көн күрүене тәхәммел итә алмаучылар юк түгел икән.
Без игъланымызны дәреж кыйлгач та, «Бәянелхак» идарәсенең бөтен идәннәре урыныннан кузгалды.
Әллә нинди Кырыкаяк Кырыкаяковлар зоһур итеп, безгә каршы һөҗүм итә башладылар. Без «Бәянелхак»ка дөньяны тарайтамыз, анларның дөньяда тора алулары өчен безнең дөнья йөзеннән югалуымыз кирәк дип белми идек. Ләкин вакыйгъдә эш башкача икән. Безнең сөбат вә гайрәт илә дәвам итәчәгемездә шөбһәсе калмагач, «Бәянелхак»ның кәефе китте. Хәсрәтеннән теленә ни килде, шуны сөйләргә тотынды.
Хәстә адәмнең саташып сөйләгән сүзләренә каршы җавап бирелү гадәте булмаганлыктан, вакытында без буңа каршы сөкүт иттек. Аның илә чәйнәшүне мөнасиб күрмәдек.
Соңра эшләр башкарды.
Бу көнгә кадәр без «Вакыт» гәзитәсене җитди бер гәзитәгә хисап итеп ихтирам кыйлмакта идек. Ләкин ул да чыдый алмады. Никадәр вәкарьле маташкан булса да, ахырында үзенең вәкаре җәгъли идекене күрсәтте. Соңгы йөз туксан тугызынчы номерында безгә каршы тешләрене ыржайтты2. Безнең гәзитәдән күрәчәк файдаларымыздан бәхәс иткән булып, бездән истиһза кыйлмакчы булды.
Һәркемгә көләргә дә, егъларга да, шатланырга да, кайгырырга да хөррият бирелгән. Ләкин мәктәбе ибтидаи балалары да белә торган хисап гамәлене ялгыштырырга һичбер кемгә хөррият юктыр. Әгъмале әрбәга кагыйдәсе буенча бер баладан: «Бер елда җиде мең алты йөз сум табыш ителсә, ун елда күпме була?» – дип сөаль ителсә, бала: «җитмеш алты мең сум», – дип; «Йөз елга күпме була?» – дип соралса, «җитмеш алты мең сум», – дип; «Мең елда күпме була?» – дип соралганда, «җиде миллион алты йөз мең сум», – дип җавап бирә торган иде.
Ләкин ни сәбәптәндер «Вакыт» гәзитәсендәге «курс тутырган бухгалтерлар», бераз ялгышып, йөз елга «җиде миллион алты йөз мең сум», мең елга «җиде миллиард ярымнан да артыграк» була дип хисап иткәннәр.
Борадәрләр, бундан соң, зинһар, алай ялгыш хисаплый күрмәңез, юкса «буларның акчалары бик күбәйгән икән дип, сезнең сүзеңезгә карап, «Йолдыз» идарәсенә «экспроприация» ясый башларлар.
«Мәдрәсәи галия»

Голүме диния илә бәрабәр фөнуне җәдидә дә тәхсыйль итәрлек вә шул саядә мөкътәдир имамнар җитештерерлек мәдрәсәи галияләрнең булуы милләтнең иң арзу кыйлган нәрсәләремнән beредер.
Буннан бер-ике ел мөкаддәмдә Һиндстанда ничә еллар укып кайткан Минһаҗетдин Йосыф намендә бересе1, шундый бер мәдрәсәи галия (хәтта дарелфөнүн) бина итү фарызы илә йөреп, берникадәр иганәләр җыймыш иде. Ләкин бу соңгы ел эчендә бу әфәнденең исеме бөтенләй ишетелмәс булды. Җыелган акчадан дарелфөнүн бина кыйлдымы яхуд авылына бер мәктәп салдырдымы – һич мәгълүм түгелдер.
Соңра Зыя әл-Кәмали әфәнденең дә бер мәдрәсәи галия ачу фикере илә мәшгуль булганлыгы узган ел ишетелмәгә башлады. Хәтта Зыя әл-Кәмали әфәнде, берничә шәкертләр җыеп, бер фатирда дәресләр дә бирә башлаганлыгы вә узган кыш буена шул дәресләрендә дәвам кыйлганлыгы да ишетелмеш иде.
Зыя әл-Кәмали җәнабләренең иҗтиһадыннан мәмнүн булганлыкларыннан булырга кирәк, бәгъзе бер байларның, көллиятле микъдарда иганәләр итеп, буның өчен бер мәдрәсәи галия бина итәргә шөругъ кыйлганлыклары бу ел яз башларында ишетелде. Мөхтәрәм «Тәрҗеман» гәзитәсенең иң соң килгән нөсхәсендә2 яздыкларына караганда, бу мәдрәсәнең бинасы үктәбер башларында тәмам булачактыр. Мәдрәсәнең иншасы өчен утыз өч мең сарыф ителмештер.
Мәзкүр гәзитәдә язган игъланларына караганда, бу мәдрәсәгә үктәбер башына кадәр шәкертләр имтихан илә кабул ителеп, 1 үктәбердән бәдәэ илә дәресләр башланачактыр.
Мәдрәсәдә укылачак дәресләр ушбулардан гыйбарәттер:
Тәфсир, хәдис, мосталәхәт, әхадис, фикъhе, кәлям мантыйк, бәлягате гарәбия, әдәбияте гарәбия, фәлсәфәи диния, ысуле тәгълим, тарих, җәгърәфия, хисап, һәндәсә, һәйәт, җәбер, кимия.
Нәкадәр гүзәл дәресләр!
Бу кадәр гүзәл фәннәрне тәгълим итәргә шөрүгъ кыйлдыклары өчен мөбаширләренә әз дил вә җан тәшәккер итәмез.
Җәнабе хак могыйннәре улсын!
Ләкин шаян тәәссеф шукадәресе вардыр ки, «Тәрҗеман» гәзитәсенә дәреж итдекләре игъланда мәдрәсәгә шәкерт кабул итү өчен булган җәмигъ шартлар, мәдрәсәнең ысуле идарәләре һәм укылачак дәресләр мөфассал язылдыгы хәлдә, югарыда мәзкүр гали фәннәрдән дәрес бирәчәк гали мөдәррисләрнең кемнәр икәне язылмамыштыр.
Зыя әл-Камали җәнабләрене беләмез. Яхшы мәгълүматлы, гүзәл фикерле, җитди, галим вә фазыйль бер адәмдер.
Ләкин «Мәдрәсәи Галия»дә бу кадәр күптөрле гали фәннәрдән дәрес бирү өчен бер Зыя әфәнде генә кифая кыйлмас. Буның өчен берничә гадәд микъдар мөдәррисләр лязимдер.
Безнең арамызда бу көнгә кадәр гали тәхсил күргән адәмнәр бик мәгъдүдтер. Шул сәбәптән бу мәдрәсәдә дәрес итәчәк гали мөдәррисләрнең кемнәр идекене белергә һәркем арзу итәр.
Анларның һәрбер шартларына разый булып, мәдрәсәгә керүче һәм гали тәхсилгә кызыгучы шәкертләр күп табылыр. Ләкин, исеменә алданып кереп тә, артык бернәрсә дә тәхсил итә алмаенча мәхрүм калу бик читен бер хәлдер. Тәзйигъ гомер өчен Русия шәкертләренә башка мәдрәсәләр дә бик күптер.
Вакыт узмастан мөкаддәм мөдәррисләрнең дә кемнәр идеке игълан кыйлынса гүзәл улыр иде.
Юкса исеме «Галия» улу илә генә мәдрәсә һичбер вакытта да галия ула алмас. Һәмишә «иске хәммам, иске тас» улыр калыр.
Думаны истикъбаль

Бу көннәрдә миңа Зөя өязендәге бер мөселман карьясендә булырга тугъры килде. 7 сентябрь җомга көн иде. Һәр нә кадәр шинбә көн – 8 сентябрьдә волостьлардан вәкилләр сайлау көне идисә дә, мәсҗедтә бу тугърыда һичбер сүз ишетелмәде.

Әүвәлге ике Думага сайлаулар алдыннан һәр җирдә хәрәкәтләр, һәркемдә Думага игътибарлар камил иде. Сайлау алларында, кирәк кем улсын, ике кеше бергә килсәләр, Думага кемне сайлаячакларыны вә кемне сайларга тиеш идекене мөзакәрә итәләр иде.
Һәрбер волостьларда һәр өч елда бер мәртәбә старшина сайлаулар буладыр. Бу вакытларда да авыл халкы, хәрәкәткә килеп, кемне сайларга тиешлеге хакында киңәшләр итешеп, алдан хәзерләнеп куялар. Думага әгъза сайлауның халык кашында шул старшина сайлау кадәр дә әһәмияте калмаганлыгыны күреп тәгаҗҗеб иттем. Һичкемнән бу хакта һичбер сүз ишетергә муафикъ ула алмадым.
Карьягә пәнҗешәмбе көн кич илә генә барып кергән идем. Шул сәбәптән, бәлки, мин ишетми калганмындыр.
Бәлки, бунлар, үзара бер карар биреп, бу хакта авыл халкы алдан киңәшеп куйганнардыр өмиде илә карьянең могтәбәр кешеләреннән берсеннән:
– Нихәл? Бу ел Думага әгъза сайлау өчен волостьтан кемне вәкил итеп җибәрмәкче буласыз? – дип сорадым.
Бу сөалемә каршы ул кеше:
– Ник әле, ул Думага яңадан тагы кешеләр сайланачакмыни? – диде.
Мин буннан соңра Русиянең Думасыз тормаячагыны, һәрбер Дума таралганнан соңра икенче Дума җыелачагыны вә буның өчен бу ел волостьлардан вәкилләр сайлау һәрбер өязләрдә иртәге көнгә (8 сентябрь) тәгаен ителдекене сөйләгәч, бу кеше, бик гаҗәпкә калып:
– Безгә һичбер әйткән кеше юк. Әле бу көннәрдә старостамыз да авырый. Аның урынына калган кешегә писер иртәгә дисәтникләрне җыеп, волостька килергә кушкан, волостьта сход була, дигән. Үзе ни өчен икәнен әйтеп җибәрмәгән. Алайса, ул шуның өчендер инде, – диде.
Соңра сүзнең ахырындарак бу кеше, янә үзләренең Думага бик хәтерләре калганлыкларыны белдереп:
– Без старшина сайлап куямыз, ул да бер куйгач өч ел хезмәт итә. Думага ике мәртәбә нәкадәр мәшәкатьләнеп сайладык. Икесен дә җибәрделәр. Кемне сайласаң да, һаман шул булыр инде. Адәм һичбер вакыт фәрештә булмас, – [диде].
Аңлашыла ки, халыкта сайлау эшләренә әһәмият бик уртадыр.
Хәерле булсын!
Гәзитәләрдән

Мөхтәрәм «Тәрҗеман»ның соңгы нөсхәсендә «Бәянелхак»ның яздыгына күрә, бу ел Казан гимназияләрендә мөселманнан бер таләбә вар, имеш. Хәлбуки Казанда илле мең кадәр мөселман вардыр.
Казанда җөмләсенең «социал-демократ» булганлыкларына гимназияләр шаһидтыр. «Азат», «Азат халык», «Таң йолдызы», «Тавыш» мөхәррирләре, кардәшләремез бу хәлгә дикъкать боерсыннар... дигән бер сүз күрелде1.
Заныма күрә, бу хакта мәзкүр гәзитәләрнең һичберенең кабахәте юктыр. Буңа казанлыларның тәгассыблары сәбәптер. Юкса кызыллар укуны инкяр итмиләр. Хәтта шаһид уларак шуны да белермәкә, бу көндә «таңчы» вә «тавышчы»лардан һәрбересе, гәзитәләрене ташлап2, һәртөрле курсларга кереп укырга башладылар.
Гимназиядә мөселманнан таләбә бер генә булса да реальный вә тиҗарәт мәктәбендә укучыларның мәҗмугъсыны санасак, таләбә әүвәлгедән артыграктыр. Гимназия таләбәләреннән дә бәгъзеләре тиҗарәт мәктәпләренә чыктылар. Бу рәвешчә тиҗарәт мәктәбенә күчү социалистик дәгел, бәлки бер нәүгъ буржуалыктыр. «Казанда илле мең кадәр мөселман бар» дигән сүзеңез дә бераз яңлыштыр. Казанда беренче кыйсем сайлаучы мөселманнар йөз алтмыш ике, икенче кыйсемнәр җиде йөз микъдарындадыр3. Үз исеменә аерым бер ханә истиҗарә итмәгә икътидары булмаган кеше, сайлаучы була алмаган шикелле, баласыны гимназиядә дә укыта алмаячактыр.
Үз тарафымнан җавап

Кичә Сәйдәшевләр минем хилафыма «Бәянелхак» гәзитәсенә «гыйлавә» исемендә бер кәгазь бастырып тараттылар. Сәйдәшевләр бу кәгазьләрендә миңа берничә төрле ифтиралар язганнар.
1) Гүя мин үз-үзлегемнән үземне выборщиклыкка тәгаен иткәнмен, имеш. Сәйдәшевләрнең бу сүзләре сарих ифтира вә ялгандыр.
Казандагы икенче сыйныф сайлаучылар арасында булган кешеләрдән берникадәр кешеләр минем сайлануымны мәгъкуль күрделәр. «Мөселман иттифакы» җәмгыятенең идарә әгъзаларыннан булган кешеләр дә минем сайлануыма хилафлык күрсәтмәделәр.
Шул сәбәпләргә бинаән, минем исемемнең «Йолдыз» гәзитәсендә язылуына мин хилафлык күрсәтмәдем.
2) Сәйдәшевләр, минем игътибарымны төшерү һәм халыкны шөбһәдә калдырыр өчен, Галиәсгар Камалетдиновның сайларга катышырга хакы булмаска кирәк дип язганнар. Бу сүзләре Сәйдәшевләрнең сайлау законыны яхшы аңламаганлыкларыны күрсәтәдер. Әгәр дә мин Казан өязе крәстияне булсам, сайлауга катышуым булмас иде, ләкин мин, Мамадыш өязе крәстияне булганым өчен, сайлауга катышырга хаклымын. Сайлаучылар спискәсендә 2444 нче номерда язылганмын. Шул сәбәптән Сәйдәшевләрнең мине җәрех кыйлырга хаклары юктыр.
3) Сәйдәшевләрнең кәгазьләрендә «Сайлаучылар! Сезнең кайсыларыңыз бу адәмне мәгъкуль күрдеңез? Кайда җыен ясап буңар карар кыйлдыңыз?» дип язалар. Сәйдәшевләрнең бу сүзләре дә халыкны икегә аеру өчен булган сүздер. Чөнки миңа җыен ясап карар кыйлынмаган шикелле, Сәйдәшевләр язып чыгарган кешегә дә һичбер җирдә карар бирелгәне юктыр. Кеше теләсә кемне сайларга ихтыярлыдыр.
4) Сәйдәшевләр «Йолдыз» гәзитәсендә «мине сайларга карар кыйлдылар» дип игълан кыйла, дигәннәр. Сәйдәшевләрнең бу сүзләре дә ялгандыр. Чөнки «Йолдыз» гәзитәсендә карар кыйлынды дип язылганы юк. Бәлки, мәгъкуль күрәләр дип кенә язылган.
Иске спискәдә 2444 нче, яңа спискәдә 554 нче номерлы избиратель
Галиәсгар Камалетдинов
Сайлау алды
Шершеневич!
Капустин!
Бунлар әүвәлге вә Икенче Дума әгъзалары иде. Бунлар Казаннан сайланып киткән берәр генә кешеләр иде.
Бөтен Казанга бер генә кеше! Узган елларда эшләр башкача иде. Губернадан сайлана торган кешеләр арасына бармак тыгарга бабайга1 мөмкин түгел иде.
Бу ел эшләр башкарды.
Бабайга бармак тыгарга түгел, аяк тыгарга да юллар ачылды.
Бу ел Казан вә губернаның мәҗмугысыннан ун кеше китә. Бу ун кешенең берсе бабай булырга ник ярамый? Аннан ары да бит әле анда Капустиннарга урын кала. Бары тик юлга аркылы төшәрлек бүрәнәләр генә булмасын. Бу ел, әлбәттә, сайланам! Эш тәмам.
– Бабай! Анда второй куриядән Галиәсгарне сайламакчы булалар, ди.
– Ә?! Аны сиңа кем әйтте?
– Гәзиттә күрдем!
– Ах, йөзе каралар икән! Аны сайлатырга ярыймы соң? Ул бит безнең балтага сап булырга һич ярый торган кеше түгел. Чыгарыңыз гыйлавә! Сүгеңез үзен! Анлар нахал, диген! Анларның сайланырга хаклары да юк, диген! Ул – мужик, без әйткән кеше – дворян, диген! Ух Алла! Харап була яздым!..
– Эш тәмам! Гыйлавә таралды.
– Ярабби, шөкер! Кешеләр инде, шаять, анларның сүзләрен тыңламаслар. Бәдбәхетләр. Аз калды – эшне боза яздылар...
– Бабай, алар да гыйлавә чыгардылар!2
– Ә?! Булмас! Кая, нәрсә язганнар?
– Анларның сүзләре ялган, сайланырга правасы бар, дигәннәр.

– Аның правасы бар икәнен мин үзем дә беләм дә бит, башкача гаеп табып булмагач, ни әйтмәк кирәк. Ай, бәдбәхетләр икән! Языңыз тагы иртәгә чыга торган гәзиткә, сүгеңез үзен!
– Нәрсә дип языйк? Язачак сүзләребезнең барын да язып бетердек ич инде.
– Һай, уңмаган нәрсәләр! Мин монда сезгә акча түләп тамагыңызны туйдырып торам, шул эшкә дә ярамыйсыз. Барыңыз, чакырып алып килеңез шунда, бардыр әле берәр сатлык көнлекче мөхәррир.
– Кемне алып килик соң? Таңчылардан бик «усал» бер мөхәррир бар3, шуны алып килсәк ярармы?
– Менә-менә! Нәкъ үзе! Акча бирсәк, Галиәсгареңезне генә түгел, бөтен милләтеңне, хәтта ата-анасын да эт итеп сүгәр. Чакырыңыз шуны!..
Эш тәмам, гәзитә язылды. Сүгеләчәк кешеләр сүгелде. Биш йөзе сылтау белә буш таратылып, халык күзенә дә күренеп калды.
Кәеф җирендә!
– Беренче куриядән – үзем, икенчедән ул сайлансак, эшләр яхшылана4.
Киттек сайланырга!
Сайлау залында
Бабайның шарлары саналды. Тәмам илле ике. Нәүбәт муллага килде. Саныйлар. Кырык сикез, кырык тугыз, илле, илле бер, илле ике, илле өч...
– Пуф! Әйдә, Нигъмәтҗан, кайтыйк! Икенче куриядән теге сайланды. Сайланудан әмма ни файда?
Сабы булды, ләкин балтасы юк!
Бабай да сайланды сайлануын да, ләкин Дума сараена түгел, холера барагына.

Яңа әсәрләр
(«Мирза кызы»1)

Әдибе мөхтәрәм Фатих әфәнде Кәримевнең беренче язылган әсәрләреннән улан бу хикәя буннан берничә еллар мөкаддәмдә оренбурглы Шәрәфетдин Шәһидуллин тарафыннан нәшер ителгән әһали исламия календарена дәреҗ ителмеш иде. Ләкин ул календарь халык арасына күп таралмадыкыннан, бу гүзәл әсәрне күрү күп кенә кешегә мөяссәр булмагандыр. Ушбу көннәрдә бу әсәр, яңадан китап шәкелендә табгы ителеп, Казанда «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан нәшер ителде.
Бер бакчачы егет илә мирза кызының мөнәсәбәте гыйшкыяларыны тасвирдан гыйбарәт булган бу хикәя, Кырым мирзаларындагы дворян булмаган кешеләргә тәхкыйрь нәзары илә карау кеби начар гадәтләрне тә-мамилә бәян итәрәк, бу гадәтнең файдасызлыгыны җанлы уларак әнзаре галәмгә күрсәтәдер. Бу хикәядә, гәрчә Кырым мирзаларыннан бер генә кешене тасвир ителгән булса да, бундый гадәтләр һәр җирдәге мирзаларда бертөрледер. Шул сәбәптән һәркем өчен дә моталәга итеп чыгу истифадәле вә гыйбрәтледер. Лисан җәһәтенә канча Фатих әфәнденең лисаныны тәгъриф итәргә хаҗәт юкдыр. Гүзәлдер.
Фәкать шулкадәресенә тәәссеф ителәдер ки, Фатих әфәнде гүзәл бер каләмгә малик улдыгы хәлдә бундый әсәрләр язудан бу елларда бөтенләй тукталып китте.
Рисаләнең яхшы җәһәтләрендә узып кимчелекләренә килсәк, мәтбагачы казанлы Кәримевләрнең гаепләрене әйтергә тугъры киләдер. Бу әфәнделәр мәтбагаларыны башка кешеләрнең мәтбагалары рәтенә кертергә аз гына булса да ни өчен бер дә иҗтиһад кыйлмыйлар икән?
Китапның нәшерләре никадәр гүзәл кәгазьгә китапларыны табгы кыйлдырсалар да, Кәримевләр, буяуның потына берәр сум артык бирүне кызганып, китапны бозып чыгаралар. Заманга бераз гына булса да илтифат кыйлсалар, Кәримевләргә дә, шаять, гөнаһ булмас иде.
*

Бу көннәрдә китап базарына чыккан әсәрләрнең икенчесе янә шул ук «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан нәшер ителгән «Хат болгатты»2 нам бер пәрдәлек көлкеле театру рисаләседер. Югарыда зикер ителгән «Мирза кызы»ның мөндәриҗат җәһәте макталырга тиеш булса, бу соңгысының табгысының гүзәллеге макталырга лаектыр. Табгысы вә кәгазе хәкыйкатән фәүкыльгадә диярлек дәрәҗәдә гүзәлдер. Мөндәриҗат җәһәтенә кәленчә, максат, театрудагы сәерчеләрне көлдерү улганлыктан, матлубка муафикъ улу мөмкин исә дә (ул да уйнаучыларының кәефенә табигъ), ләкин мәгънәле көлү дәгелдер. Көлгән тәкъдирдә үз арамызда булган килешмәгән гадәтләрдән көлү артыграк булса кирәк. Көләргә мөстәхикъ булган гадәтләрне, Петербургтагы бер уч мөселманнар барып эзләгәнче, үземезнең Казаннан гына яхуд мөселманнарның күбрәк җирләре булган Оренбург, Уфа, Әстерхан мөселманнарының тормышлары арасыннан эзләнсә, дәхи дә яхшырак булыр иде.
Язган сүзләремез хәтергә килгән фикерләремезне генә бәяндан гыйбарәттер. Юкса бундан бу рисалә укырга да яраклык бер нәрсә түгел икән дигән сүз акланмасын.

Бер-ике сүз

Буннан унбиш-уналты ел мөкаддәмдә «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»нең ярты иске, ярты яңа ысул илә идарә ителгән заманнарда, шәкертләрдә гәзитә уку һәвәсе бик аз иде. Ул вакытка кадәр һәр нә кадәр «Тәрҗеман» гәзитәсе ун сәнә кадәр дәвам иткән булса да1, мәзкүр мәдрәсәдә фәкать ике гадәд мөштәрисе бар иде. Соңра елдан-ел шәкерттә гәзитә моталәга кыйлу һәвәсе артты. Бервакыт «Шәркы рус» гәзитәсе вөҗүдкә килде2. Шәкертләр ара-тирә буны да укымага башладылар. «Хәят» гәзитәсе чыга башлаганнан соңра3, шәкертләрдәге һәвәс ике өлеш артты. Ул заманнарда Габдерәшид әфәнде Ибраһимовның шәкертләргә хитабән язылган нәсихәтләрене шәкертләр сөенә-сөенә укыйлар иде4. Соңра «Казан мөхбире», аның артыннан «Азат», «Йолдыз» һәм «Өлфәт» гәзитәләре мәйданга чыкты. Шәкертләр бу гәзитәләрне бик шатлык илә истикъбаль иттеләр.
«Казан мөхбире» вә «Азат» гәзитәләре бер «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә икешәр йөз нөсхә тарала иде. «Өлфәт» кәзалик шәкертләр арасында берзаман бик рәваҗда булды. Ләкин соңра һәркайсының да тиздән ихласлары кайтты, чөнки шәкертләр бу гәзитәләр эченнән үзләренең дәртләренә дәрман эзлиләр иде. Бу гәзитәләрдә үзләренең ихтыяҗларыннан бәхәс итәрләр дип өмид итәләр иде. Ләкин өмидләре бушка чыкты.
«Мөхбир» 5, «Азат» гәзитәләре сәясәттән бәхәскә керешеп киттеләр. Әүвәлдә шәкертләрнең йакәнә хамисе булып күренгән Габдерәшид әфәнде «Өлфәт» гәзитәсендә бөтенләй муллалар вә байлар тарафдары булып китте. Шәкертләрне химая итүче вә анларның ихтыяҗларыннан бәхәс итү вә анларның мәгълүматларыны арттырырга сәгый итүче гәзитәләр калмады.
Читтән һичбер төрле химая күрмәгәннән соңра, үз-үзләрене химая вә бәгъзе мөстәбидләрнең җәбер вә золымнарына каршы мөдафәга итүче бер гәзитәнең кирәклегене шәкертләр хис кыйлдылар.
Ел ярым кадәр хәзерләнгәннән соңра, бүгенге көндә ушбу «Әлислах» гәзитәсе вөҗүдкә чыгарылды6. «Әлислах» гәзитәсе, башкалар кеби, сәясәттән күп бәхәс кыйлмаячактыр. «Әлислах» гәзитәсе шәкертләр өчен булганлыктан, аның хезмәте шәкертләрне химая, анларның мәгълүматларыны арттыру вә анларның ихтыяҗатыннан бәхәс итү вә анларга кулыннан килгән кадәр тәрәкъкый юлларыны күрсәтү улачактыр.
Үз гәзитәләре улдыгы өчен, «Әлислах»ны химая кыйлу шәкертләрнең бурычыдыр.
Бөтен сәхифәләрене шәкертләр өчен тәхсыйс кыйлган бундый бер гәзитәне шәкертләр әздил вә җан тәбрик илә истикъбаль итәрләр өмидендәмен.
«Әлислах» гәзитәсене чын күңелемнән тәбрик итеп, озак елларга кадәр гомер итеп, шәкертләргә вә алар васитасы илә милләтемезгә зур хезмәтләр кыйла алуыны арзу итәмен.
Мулла булмагач, чибәр җирдән кыз
алып булмый

(Әүвәлге заман хикәяте)

Риваяне әхбар вә накыйляне асарь шөйлә риваять вә буйлә хикәят идәрләркем, безнең Казанда әүвәлге заманда Бохарада тәхсыйле гыйлем кыйлып кайткан «бик галим» бер дамелла җуан манаралы мәсҗедкә имам булмыш. Үзе бик галим, имеш.
Ләкин дәрес әйтергә кувәсе, дәрес, намаз укытырга кыйраәте, сүз сөйләргә кувәи ноткыясе, вәгазь сөйләрлек мәгълүматы гына юк, имеш тә, әхвале галәмнән, дөньядан бераз гына хәбәрдар түгел, имеш. Шулай да булса дәрес әйтү касды илә бер мәдрәсә салдырмыш, ләкин егерме биш елдан зиядә гомере эчендә мәдрәсәсенә хәмел ташыр өчен килгән биш-ун кадәр шәкертләрне дә чеп-чи надан калдырмыш. Егерме биш ел михраб сакчысы, бәлеш ялчысы булып гомер иткәннән соңра, бу дамелла картаеп киткәч, бик хафага калмыш. Егерме биш елдан бирле чын күңеленнән сөйгән михрабыны, үзенең шулкадәр яхшы варидатлы, савым сыгыр мәнзилендә булган урыныны ятлар кулына калдырып китәргә күңеле һич тә разый улмамыш. Шул кайгы-хәсрәт илә берничә вакытлар уздырганнан соңра, беркөн «илһам» иләме ни берләдер кылт итеп күңеленә Бохарадагы бер кәвешчедә көнлекле хезмәт итүче икедән бер угылы – мәхдүме хәтеренә төшмеш.
Дамелла, бик кәефләнеп: «И Илаһым! Сиңа ни рәвештә генә шөкерләр кыйлыйм! Мине тәмам кайгы-хәсрәттән азат кыйлдың. Гәрчә угылым укымаган, надан булса да, аны имам кыйлырга син кадирсың, һич укымаган көенчә галим кыйлып, илһам тарикы илә күңеленә гыйлем илка кыйлырга да моктәдирсең. Салих пәйгамбәргә таштан тәвә чыгардың1, Муса пәйгамбәрнең кавеменә таштан су чыгардың, күктән «мән» белән «сәлва»лар ягдырдың2. Миңа да мәрхәмәт кыйлып, угылымны да үземнең урыныма михраб сакчысы итеп калдыр. Беләмен, угылым укымаган, надандыр.
Шулай да булса Бохараи шәрифтә, яхшы җирләрдә торган, яхшы җирләрдә гомер иткән булгач, шаять, яхшы булыр әле. Мин үзем дә бу урыннарга мөстәхикъ түгел идем дә, ничә еллар сагъ-сәламәт тордым. Зинһар, мине дуст-дошман арасында хур кыйлма», – дип, наз вә нияз кыйлмыш. Соңра кулына каләм алып, ушбу рәвешчә хат язмыш: «...Угылым, үзем бик картайдым, мәсҗедне кеше кулына калдырып китәсем килми, гәрчә мөстәхикъ кешеләр күп булса да, үзем исән вакытымда сине бәхеткә ирештерәсем килә.
Бу мәктүбем илә сиңа юл мәсарифына һәм чалма-чапан алырга акча җибәрәмен. Өстеңә яхшы чапан киеп, башыңа чалма чалып, голяма кыяфәтендә булып, Казанга кайт. Ләкин яхшы кара, чалманы килештеребрәк чалырга өйрәнебрәк кайт, юкса, монда кайткач, кеше арасында рисвай булып калмыйк, тизрәк кайт, сине мулла итәм...»
Бу кадәр сөенеч хәбәрне ишеткәч, мәхдүм тиз-тиз генә Казанга әйләнеп кайтмыш. Карт хәзрәт яшь дамелланы, бик зур тәгъзимнәр илә истикъбаль кыйлып, мәхәллә кешеләре илә күрештермеш вә шул көннән башлап мәхдүмне имам итәргә тамгалар җыя башламыш.
Мәхәллә халкы һәрнә кадәр:
– Тәкъсир, мәхдүмнең гыйлеме ничек икән, бераз дәрес әйтеп, имам торып, вәгазьләр сөйләп карасын. Гыйлеме булса, аннан ары да вакыт узмас, – дисәләр дә, карт хәзрәт:
– Ахмак нәрсәләр, ул ничә еллардан бирле Бохарада дәресләр әйтеп ватылып кайткан. Сез тагы аны монда кайткач та, ял итәргә ирек бирмәенчә, дәрес әйттереп борчымакчы буласыз, хәзер әле аңар ял итәргә кирәк. Аны хәзер менә өйләндерергә кирәк. Өйләндерер өчен әүвәл мулла итәргә кирәк. Аннан соң дәрес тә әйтер, бары да булыр. Мулла булмас борын, чибәр җирдән кыз бирмиләр, – димеш.
Мәхәллә халкы янә:
– Хәзрәт, син үзең дә, ахры, шул Бохарада бик күп дәрес әйтеп таушалгансыңдыр, ахры, хәзер син дә шул егерме биш елдан бирле һәмишә ял итә торгансыңдыр, югыйсә дәрес әйтер идең, – димешләр.
*
Мин бу хикәяне бик иске бер китаптан күчереп яздым. Мин күчергән нөсхәнең буннан соңгы сәхифәләре ертылып төшкән, шуның өчен мәхдүмнең мулла булып-булмаганы бик

мәгълүм түгел. Әгәр ахырыны таба алсам, яңадан язармын. Бер китап арасыннан чыккан бер кисәк кәгазьдә: «Хәзрәт, кайсыны бәддога берлә куркытып, кайсыны хәер-догалар илә сыйлап, яучылар яллап, фатир торучылардан тамга җыйды», – дигән сүз күренә күренүен дә, моның илә генә һичбер нәрсә аңланмый, хәзрәтнең догасы мәкъбуль булганмы-юкмы – һич беленмидер, чөнки икенче бер кисәк кәгазьдә: «Йорт хуҗалары хәзрәтнең хилафына кире тамга җыйганнар», – дигән сүзләр күренәдер. Минем заныма күрә, бу кеше мулла була алмаса кирәк. Чөнки мәхәллә халкы арасында ак берлә караны аера белерлек кешеләр, шаять, ул заманда да булгандыр.

Габдулла Тукаев шигырьләре

Бу көннәрдә шул исемдә Шәрәф мәтбагасы тарафыннан нәшер ителгән шигырь мәҗмугасы идарәмезгә килде. Мәзкүр әсәр әдәбияте җәдидәбездә күрелгән әсәрләрнең яхшыларыннан саналырга яраклы булдыгыннан, бу хактагы фикер вә тәәсирләремне бераз язуны мәгъкуль күрдем.

Бер мәкаль бардыр ки, чыпчыкның да үзенә күрә бизмәне була, диләр. Башка милләт әдәбиятына, башка милләт шагыйрьләренең шигырьләренә кыяс кыйлып үлчәгән тәкъдирдә, безнең матбугат галәменә вөҗүдкә чыккан әсәрләрнең һичберсе дә әһәмиятле хисап ителерлек булмаса да, һәркемнең үз баласы үзенә матур күренәдер. Шуңар күрә бу әсәр әдәбиятымызның бик гүзәл баласыдыр. Безгә хәзергә үземезнең милләт балалары арасында чыккан әсәр илә генә мокайәсә кыйлып тору вә шул саядә язучыларымызның күңелләрен күтәрә төшү тиештер. Шулай да булса әдәбиятымызны төрекләргә, яхуд башкаларга кияүгә бирүдән ихтираз лязимдер.

...Хөрриятләр игълан кыйлынган көннән башлап, берничә гәзитәбез вөҗүдкә килгән шикелле, анлар илә бәрабәр берникадәр назыймнарымыз да дөньяга килделәр. Һәркемдә язуга һәвәс артып китте, кайсы көйләп, кайсы көйсез генә язарга тотындылар. Гәзитә идарәләренә «шигырь» исемендә төрле әсәрләр язып җибәрә башладылар. Кайсы берсе – язган нәрсәләре басылмаганга үпкәләп, бәгъзеләре, шагыйрь димәгән өчен ачуланып, язудан туктадылар. Арада фәкать өч кеше калды. Болардан берсенә (Нәҗип Думавига) нинди тамга (проба) сугарга хәзергә мин булдыра алмыйм. Минем каршымда Габдулла әфәнде илә Габделмәҗид әфәнделәр1 алга чыктылар. Хәзерге көндә шагыйрь исемен итлак кыйлырга шул икесе лаектыр. Габдулла әфәнденең язган нәрсәләре арасында хәкыйкатән шигырь итлакына мөстәхикъ булган гали тасвирлар, гүзәл тәрсимнәр күренәдер. Шуның өчен Габдулла әфәндене бу әсәре илә тәбрик итәмез. Әдәбият бабында хәзергә без мөбтәдиләремез гарәбиләрнең пишкадәм шагыйрьләре илә кыяс кыйлу2 бик урынлы булып җитмәс. Тора-бара без дә, шаять, тәрек итәрмез әле.

Ишмиләр – түнтәрәләр

Бигрәк явыз булды бу «Йолдыз»ның җәяүле хәбәрчесе! Гласныйларның йоклауларыны, казанлыларның һичбер нәрсә укымауларыны карап йөрүләре генә җитмәгән, аның өстенә, һәрбер мәхәлләләрне карап йөреп, кайда ни эшлиләр дә кайда нәрсәне ишмиләр, кайда кемне күтәрәләр, кайда нинди менланы түнтәрәләр – һәммәсеннән идарәгә хәбәрне биреп кенә тора.

Казан кешеләре арасында «Шәригатьтә бер иргә дүрт хатын алырга ярый, әмма бер мәсҗедкә дүрт имам алырга низамда ник ярамый?» дип йөрүчеләр бик күп икән.

Әгәр дә бер мәхәлләдә бер генә мулла булып, ул мулла байгуралардан берәрсенең кәефене җибәрсә, аның өстеннән хәзер икенче мулла алалар. Әмма икесе дә кәефне җибәрсә, ачуны кайтарырга урын калмый. Шулай итеп, бу көнгә кадәр, муллалары байгураларының кәефләрене җибәргән саен, көндәш мулла алына-алына, мәхәлләләрнең күбесендә икешәр мулла булган иде. Бу көнгә кадәр ике малласы булмаган мәхәллә Казанда бары ике генә калган иде. (Бишбалтаның бер мәхәлләсе илә Пурхавайның бер мәхәлләсе бу хисапка дәхел түгел.) Җәяүле хәбәрчемезнең риваятенә нәзарән, хәзердә шул калган ике мәхәлләнең берсенең мулласы да күптән түгел вәгазендә артык сүзләр ычкындырып җибәргән.

«Мәхәллә байлары»ның моңар кәефләре киткән. Менә инде ачуны алалар. Мулланың янына көндәш китереп куялар. Мөмкин кадәр көндәше усалрак та, дәхи, белмим, ниндәйрәк булсын дип бик эзлиләр. Моның янына кемне куярга йөргәнлекләрене бик яхшы белсә дә, җәяүле хәбәрчемез яңа мулланың исемене әйтми. Әмма иске мулланың янына яңа мулланы китереп сөяп ишми-түнтәрәчәкләреннән хәбәр бирә.
– Ничек соң, әүвәлге муллалары намазга йөрмимени?
– Йөри.
– Вәгазь сөйләмиме?
– Сөйли.
– Мәдрәсәсене карамыймы?
– Карый.
– Соң ни өчен яңаны алалар?
– Мулладан үчләрене алып калалар...
1908

## Бәйрәм ашы

Безнең бабай никадәр саран кеше, шулай булса да, эстәсә, богъдай оны ике сум җитмеш биш тиен урынына җитмеш алты тиен булсын, эстәсә, Мәхмүд байның, яңлыш әйттем, куй мае кадагы егерме өч тиен булсын, эстәсә, таш яусын, эстәсә, ягъмур, эстәсә, көн аяз булсын, эстәсә, быелгы күк буран, эстәсә, утынның сажины гына түгел, аршыны алты тәңкә булсын – һичбер вакытта бәйрәмгә бәйрәм ашы пешертми калмый. Бәйрәм бит! Ансыз калырга һич ярамый.
Бәйрәм бит!
Бәйрәм хөрмәтенә, гәрчә чәршәнбе чыгу гадәте булса да, «Йолдыз» да сишәнбе чыга.
Бәйрәм бит!
Бәйрәмдә башка милләт гәзитәләрендә фельетоннар язылгач, мөселман гәзитәләрендә дә языла.
Бәйрәм бит!
Бәйрәм хөрмәтенә, гәрчә һичбер эчәсең килмәсә дә, өйдән өйгә йөрелеп, иллешәр чынаяк чәй эчелә. Арада кайсы берсе илле берне дә эчә.
Бәйрәм бит!
Бәйрәм хөрмәтенә ашарга акчасы булмаган кеше дә яңалык хәзерли.
Бәйрәм бит!
Бәйрәм булгач инде, гаедтән сәгать ничәдә чыгуларны, гаедне мәсҗедтә укылганмы, тыштамы, хәзрәт вәгазьне яхшы сөйләгәнме-юкмы, корбанлыкның мае күп чыкканмы-юкмы, – сорашмыйча калырга ярамый.
Бәйрәм бит!
Бәйрәм булгач, инде шул бәйрәм ашы пешерми дә калырга ярамый, шунсы гына бераз читен. «Бәйрәм ашы – кара-каршы» диләр.
Тәсәлсел мөхаль, бәс, бу да мөхаль!

Петербургтан телеграм: «Мәктәп вә мәдрәсә мәсьәләләре хакында киңәш итү өчен 9 февральгә кадәр бер кеше җибәреңез!»
Казанда мәҗлес.

– Берлек – Ходай Тәгаләнең сыйфатларыннан, шуның өчен бер генә кеше җибәрү мәгъкуль түгел, шуның өчен, җәмәгать, ике кеше җибәрергә кирәк. Җәмәгать, ике кеше җибәрелсен!
– Мәгъкуль, мәгъкуль!
– Юк, ярамый, ике-өчне мөстәлзим, шуның өчен өчне җибәрергә тиеш!
– Юк, юк, ярамый, һич ярамый.
– Бу тәслият була. Бәс, өчне җибәрү дә ярамый. Шуның өчен дүрт кеше җибәрү мәслихәт булыр.
– Соң, алайса, дүрт булсын! Ни истихалә? Бара бирсеннәр.
– Юк имди, ул да ярамый. Бая әйткән идек бит инде, ике-өчне мөстәлзим дип, инде бунда да шул бәхәс килә, дүрт-бишне, биш-алтыны вә һәләммә җәрра... мөстәлзим булып китәрдер дә, әле гайрел-ниһая китеп... китеп тәсәлсел буладыр.
Тәсәлсел исә, үзеңезгә мәгълүм, мөхаль. Бәс, бу да мөхаль буладыр да, шулай итеп, февральнең тугызы да, унысы да, егермесе дә узып китәдер дә, казанлы хәзрәтләремез үз урыннарында утырып, Петербурга бармыйча калалар да, эш тәмам була. Бәс, мөддәга сабит!
Яңа шагыйрь

Зариф Бәширинең «Әхбар»дагы әдәби шигырьләрен күргәннән бирле минем дә дәртләрем кузгалып китте. Шигырь язу һәвәсе көннән-көн артып бара. Шуңа күрә сабырларым тәмам төгәнде.
Кулыма каләмемне алып, Зариф әфәндегә тәкълидән, хәзерге вакытка карап, әдәби шигырьләр яза башладым. Шигырьләрем бик шәп булачаклар. Бу урында мисал өчен берсене дәрҗ итәм:
Шыгыр-шагыр!
Милләтемез йоклый һаман безнең: гыр-р-р! гыр-р-р-р!
Йөткерә чахотка күк һаман: кыр-р-р! кыр-р-р!
Уян, милләт, йоклама инде, тор-р! тор-р-р!
Юк исә мыраулармын һаман: мыр-р-р! мыр-р-р!

Күрәсезме, никадәр шәп язылган бит! Әгәр дә инде бу шигырьне дә яратмасаңыз, гомерегездә шигырь чырае күрмәссез.
Яңа әсәрләр
[«Кыямәт»]

Көннән-көн артып бармакта улан яңа әдәбият китаплары арасында ушбу көннәрдә «Яшьләр» һәм «Кыямәт» исемле ике яңа китап дөньяга килде.
«Яшьләр» Ф.Әмирхан тарафыннан, «Кыямәт» Гаяз әфәнде Исхаков тарафыннан язылмыштыр.
«Кыямәт» кәзалик берничә еллар мөкаддәмдә Казанда булып узган көленеч бер вакыйгане көленеч сурәттә тасвир иткән ике пәрдәлек бер театр рисаләседер.
Гаяз әфәнде ушбу көленеч җирлекне, бик күптөрле чуар буяуларга буяп, әүвәлдә булып кичкәнгә караганда йөз өлеш көленеч сурәткә кертмештер. Комедиядә тасвир ителгән хатын-кызлар сценасы, һәм аяныч, һәм көленеч булу өстенә, кәмаль məһарәт илә тасвир ителмеш. Фәкать муллалар сценасы, кирәгеннән артык көлү илә мөзах вә һөҗүдән чыгып, тәхкыйрь дәрәҗәсенә килеп җитеп, хикәяне бераз тозсызландырып җибәрмештер.
«Кыямәт» Хөсәен Әбүзәров тарафыннан нәшер ителмештер. Бәһасе – 30 тиен.

Татарча театр
[«Алдым-бирдем»]

Җомга көн кич Новый клуб1 залында Гаяз әл-Исхакый җәнабләренең «Алдым-бирдем» нам пьесасы тамашая куелды. Театрларны тамаша итүгә һәвәс вә театр илә ләззәтләнүгә мәел көннән-көн арта барганлыктанмыдыр, яхуд, булмаса, театр хилафында сөйләнгән вәгазьләрнең тәэсире бик куәтле булганлыктанмыдыр, нидәндер сәерчеләр гадәттәгедән күп артык иде. Зал тәмам халык илә тулган иде. Билет җитешмәгәнлектән, кире кайтып киткән кешеләр дә бик күп иде. «Хәзер инде Новый клуб залы гына җитешми, бик тыгызлык, бундан соң Шәһәр театрында уйнарга кирәк иде» дигән сүзләр халык агызында сөйләнмәктә иде.
Уен, гомумән, зарарсыз чыкты. Беренче вә икенче пәрдәләр бик рухсыз иде исә дә, уен соңга таба җанланды. Өченче вә бишенче пәрдәләр парлак сурәттә әда ителде. Уенның тәтиммәсеннән гыйбарәт улан алтынчы пәрдәдә сәерчеләргә тәэсир итәчәк һичбер хәл күренмәде. Юкарыда язылган өч пәрдәнең рухсыз вә тәэсирсез булуының асыл сәбәбе – Ибраһим ролене уйнаучы кешенең үзенә муафикъ булмаган рольне алуыннандыр. Бу әфәнде үз ролене уйный белмәве илә генә калмаенча, башкаларның начар уйнауларына да бик зур сәбәп булды. Мәсәлән, башка пәрдәләрдә рухлы уйнаучылар арасында үз ролене тәмам җанлы итеп, тиешенчә әда кылган (Морадова)2, Ибраһим илә бергә булган пәрдәләрдә Ибраһимның гаять суык һәм рухсыз уйнавы аркасында, уенының мәһарәтене изһар итәргә муафикъ була алмады, җансыз баганага каршы изһары хиссият кыла алмау табигыйдер. Сорур һәм Наташадан башка хатын-кыз рольләре, гомумән, гүзәл ижраэ ителде. Ирләрдән Әхмәди, Садыйк һәм Әхмәтсәгыйрь һәм карт хәзрәт рольләре гүзәл иде. Хәлил кыяфәте урынсызрак иде. Ләкин рольне зарарсыз чыгарды.
Бунлар уенчылыкны һөнәр иттихад кыйлган артистлар булмадыкыннан һәм араларында бәгъзесенең беренче мәртәбә уйнаулары булдыкыннан, бундан артык интикад кыйлу урынсыз булачактыр.
Шулай булса да тәрәкъкыйның юлы бикләнмәгән булса кирәк...
«Помада мәсьәләсе»

(Харитонов мәтбагасы, «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» нәшриятыннан)

Язылганына ничә вә ничә еллар узып киткән булса да, Гогольнең язган комедияләреннән «Ревизор» илә «Женитьба» нам комедияләре әдәбият вә театр галәмендә һәмишә онытылмыйдыр. Заныма күрә, бунларның онытылмавы тасвир вә лисанында гадәттән тыш ихтирагъларның барлыгыннан түгел, бәлки заманындагы интикад итәргә лязим булган кыяфәтләрне бер арага кямил мәһарәт илә җыеп кертеп, һәрбер кыяфәт иясенең килешмәгән җирләреннән көлә белеп көлгәнлеге өчендер.
Яңа мөхәррирләремездән Идрис әфәнде Багдановның язган «Помада мәсьәләсе» исемендәге комедиясе дә минем каршымда шуңар мөшабиһдер. Бу комедиядә, кеше көлдерү өчен диеп, һичбер урынсыз көлке сүзләр язылмаган. Ләкин комедиядә тасвир ителгән кыяфәтләрнең һәрберсенең табигать вә кыйланышлары һәм шул кыйланышлары өстенә үзләренең үзләренә бик зур хөсне заннары илә сөйләгән сүзләре һәм гарыз кыйлган фикерләре, хәкыйкатән, көленечтер. Комедиядә тасвир җәһәтеннән һичбер хәкыйкать хариҗенә чыккан урын күренмидер. Тасвир ителгән кыяфәтләр һәркаюсы урынлы, һәрбересе заманыбызда мәүҗүд каһарманнарныкыдыр. Мәсәлән, комедиядә тасвир ителгән Сәлим байдан алып муллалар, бәдәлчеләр, шәкертләр һәм Касыйм кеби маклерларга кадәр һәрбересе ушбу көндә мәүҗүд кыяфәтләрдер. Заманнар узган саен, халыкның табигате, әлбәттә, башкачарак. Бу көндәге кыяфәтләр бетеп, аның урынына икенчеләр киләчәктер. Узган заманда халыкның ни табигатьтә булганлыгыны белү өчен бундый әсәрләр бик зур хезмәтләр күрсәтәчәкләрдер. Шул сәбәптән Идрис әфәнденең бу рәвешчә тугъры вә җанлы итеп тасвир кыйлган әсәре көннән-көн игътибарга керә барачактыр. Әсәрнең җитешмәгән җире фәкать бу көндә татар әдәбиятында мәкъбуль

булып бара торган әдәби төрки телендә булмавыдыр. Сүзләрнең тәртибе афакый мишәр лисаны тарзында булуы күркәмлегене бераз югалтадыр.

«Хәкыйкатьме, хыялмы?»
(Ф.Кәримев әсәре, Әхмәд әл-Исхакый нәшере)

Галәмдә хыял диңгезе кадәр һичбер диңгез юктыр. Никадәр тирән диңгез булса да төпсез түгел.
Әмма хыялның һич ниһаяте юк.
Хыялларның арасында бик ләззәтсезләре, ачылары да буладыр. Ачы хыялны тасвир кыйлган чакта, рух бик мөгаззәб була, димаг арып хәлдән тая, өмидсезләнә, хәтта һәлак булыр мәртәбәгә килеп җитәдер. Татлы хыял каршысында рух үзенең асылына кайта, бетмәс-төгәнмәс ләззәтләр илә ләззәтләнәдер.
Һәркем үз хыялы илә хыялланып яткан вакытта, нәфес өчен бик зур тәэсире булмый. Чөнки үз хыялыңның хәкыйкать түгел икәнлеге бик мәгълүм. Икенче бер кешенең димагыннан чыккан хыялый хикәяләрне укыган вакыттагы ләззәтләр бөтенләй башка була. Әгәр дә бер хыял гүзәл каләм иясе булган кеше тарафыннан язылган булса, рухлы, нечкә вә нәфис каләмнәр илә хыялый бер тасвирны тамаша кыйлган вакыттагы зәвекъ вә ләззәтләр бөтенләй башка буладыр.
Фатих әфәнденең язган «Хәкыйкатьме, хыялмы?» исемендәге хыялый хикәясе ушбу соңгы җөмләдәндер. Фатих әфәнденең язган хыялый Дума әгъзасы, депутат әфәнденең хәрәкәт вә кыйланышлары вә анык фикерләре бик тугърылык һәм осталык илә тасвир ителмештер. Хыял уларак тасвир ителгән ханым әфәнде дә милләтне үз гыйндендә кыйммәт күргән һәрбер кешеләрнең җан вә дил илә арзу кыйла торган ханымнарыдыр.
Бундый ханымнар бу көндә, табигый, хыялдан гына гыйбарәттер. Киләчәктә шул дәрәҗәдә ханымнарның булуы арзу ителәдер. Ләкин бу тиздән хәкыйкатькә әвереләчәк түгел. Икенче Дума вәкиле каршысында хыял булган бу галәм, бәлки дә 20 нче Дума әгъзасы каршысында да һаман да хыялдан гыйбарәт кенә булып калыр. Татар галәмендә бу көндә бундый хыялларны хәкыйкатькә алмаштыруга тырыша торган хәрәкәтләр һич күренми. Тиздән шундый хәрәкәтләрнең булуыны өмид итәргә дә урын юк.
«Хәкыйкатьме, хыялмы?» хикәясе туя алмаслык ләззәт илә укылачак әсәрдер. Ләкин һәркем өчен түгел, бәлки миллият сәүдаэсендә булган кешеләр өчен.
Бу әсәр хакында кыска гына ушбу сүзне әйтәсем килә: Фатих әфәнде аз яза, ләкин матур яза.
«Үги балалар»

Бу көннәрдә кулыма төшкән яңа әсәрләрдән берсе – Габделмәҗит Гафури тарафыннан язылган мәзкүр исемдәге бер хикәядер.
Габделмәҗит әфәнденең әүвәлдәрәк язган әсәрләре ни өчендер миңа яхшырак күренә иде. Ләкин бу әсәрендә, никадәр тырышып укысам да, ул кадәр ләззәт таба алмадым.
Габделмәҗит әфәнде бу әсәрендә, хикәясенең вакыйгъга татбигы мөмкин булып-булмаячагын һич фараз кыйлмыйча, тасвир кыйлган вакыйгаләренең һәммәсен үзенең фаразына ияртәдер. Габделмәҗит әфәнде, хикәяне тизрәк тәмам кыйлу кирәк булганлыгы өчен булырга кирәк, һичбер катил дә җөрьәт итә алмаслык өч җинаятьне бер-бер артлы бер хатын кулыннан кыйлдыра ала. Шушындый ашыгычлык аркасында хикәянең ләззәте тәмам югала да кала.
Аның өстенә Габделмәҗит әфәнде үзе дә һәм наширләре дә хикәяне, бер мәртәбә булсын, табгыга биргәнче укып чыкмаганнар булырга кирәк. Чөнки хикәянең әүвәлендә балаларын дөньяда калдырып, никадәр хәсрәтләр чигеп үлгән Зөһрә хикәянең ахырында, янәдән кайтып булса кирәк, балаларын үги ана булып җәберли. Латыйфа исемле үги ана хикәянең ахырында Зөһрә исемендә була1. Җәбер күргән Фатыйма исемле кыз Латыйфа була2.

Игътибарсызлыклар хикәянең ләззәтен янәдән бер кат югалтадыр. Хикәя хикәялектән бигрәк «Милли шигырьләр»3 шикелле подряд эшләнгән нәрсәгә бик охшыйдыр.
Гипнотизм мәҗлесендә

Гәзитәмезнең узган нөсхәләреннән берендә Ситников1 исемле бер русның гипнотизм илә бәгъзе бер авыруларга дәва кыйлуы хакында һәм гипнотизм илә кешеләрне йоклатуы тугърысында мәзкүр Ситниковның мәҗлесендә хазир булган бер кешенең мәкаләсе дәрҗ ителмеш2 иде.
Гипнотизм әрбабы бу эшнең үзенә махсус бер фән идекене, тәгълим саясендә һәрбер инсанда да бу куәтнең хасыйль булуы мөмкин идекене дәгъва кыйлалар. Арада бу хәлне инкяр итүчеләр дә юк түгелдер. Шул сәбәптән бу тугърыда дөрест бер мәгълүмат алу һәвәсе миндә хасыйль булган иде.
Беркөн әхбабларымнан паралич илә хәстә бер әфәнденең мәзкүр Ситниковка барганлыгыннан хәбәр алдым.
Ситниковның куәте ни дәрәҗәдә идекене үз күзем илә күрер өчен, мәзкүр әфәнде3 илә бергә бардым. Без барган вакытта һичкем юк иде. Мәзкүр хәстә әфәндене күтәреп кертеп креслога утырттык.
Ситников, хәстә әфәнденең аяк киемнәрене салдырып, бер дә хәрәкәт кыйлмый торган аякларыны акрынлап уа башлады вә шул әснада йомшаклык илә генә әфәнденең кәефенең ничеклегеннән сөаль итеп, сорашып, тиздән сихәт табачыгыны сөйләп, күзләренә карап акрынлык илә генә: «Рәхәтләнеп йоклаңыз», – диде. Шул аньда (ике арада биш секунд кадәр дә вакыт үтмәгәндер) әфәнденең күзләре йомылды, мышлап йоклый башлады.
Мин башта бер-ике дәкыйка кадәр, бәлки, йоклавына зарар килер диеп, тавыш кузгатмыйча, тын гына утырдым. Соңра Ситников, кычкырып: «Хәзер инде сезнең аягыңыз хәрәкәткә килә башлаячак, каннарыңызның йөрүе тәмам әүвәлгечә тәртипкә керәчәк», – мәфһүмендә сүзләр сөйли башлагач, яннарына бардым.
Ситников, аякларыны уган хәлдә: «Менә инде хәзер аягың җылыныр», – дигәннән соң, вакыйгъдә әүвәлдә, тәмам үлгән шикелле, салкын аяклары акрынлап җылына башлады. Ситников ара-тирә әфәндедән сүзләр сорады, әфәнде дә, уягъ хәлендәге кеби, җаваплар бирде.
Мин дә бәгъзе нәрсәләр сорадым. Миңа да тугъры җаваплар бирде. Соңра: «Ач күзеңне! Уян!» – дип әмерләр бирдем. Күзене ачарга тырышып караса да, кашларының югары таба хәрәкәтеннән башка нәрсә булмады. Күзләре ачылмады.
Әмма Ситниковның әмерләренә кямаль итагать күрсәтә иде. Ситников: «Кулыңны күтәр!» – дип әмер кыйлды, электрик илә мөтәхәррик машина шикелле, дәфгатән күтәрелде. «Аяк бармакларыңны селкет!» – диде, анларны да кузгатты. Ләкин «Аякларыңны күтәр» дигән әмеренә, ничә мәртәбә кушса да, итагать кыйла алмады. Тездән югарыгы урыннары күтәрелеп, тездән түбәнге хәстә кыйсемнәре хәрәкәтсез калды. Аякларыны сылап, каннарыны хәрәкәтләндерү һәм төрле әмерләр бирү илә егерме дәкыйка кадәр вакыт узды. Без никадәр кычкырып сөйләсәк тә, әфәнде уянмады. Соңра Ситников, күзләренә өреп, уянырга әмер итте. Әфәнде уянды. Бик татлы йокыга китеп уянган кеше кеби, күзләре кызарган иде. Әфәндедән йоклаган вакытта үзенең нинди хәлләр хис кыйлганын сорадым. Фикере, зиһене тәмам уяу булганыны, безнең сөйләгән сүзләремезнең һәммәсене ишетеп аңлаганыны, сораган сүзләремезгә аңлап җавап биргәнлегене, ләкин күзене ачарга һичбер куәте калмаганыны бәян итте.
Соңра, әфәндене икенче урындыкка утыртып, башка кешеләрне йоклатканыны тамаша кыйлыр өчен, бүлмәдә калдык. Әфәндедән соң эч пошу һәм нервный авыруларга мөбтәля бер рус егете бүлмәгә керде. Буны һәм бик тизлек илә йоклатып, егетнең битләрене, күкрәкләрене сыйпап, биш дәкыйка кадәр һәртөрле күңел җуата торган сүзләр сөйләп, тынычландырып, соңра уйгатты. Бунның һәм күзләре әфәнденеке кеби кызгарган иде. Егетнең бик тиз итагать кыйлып йокыга китүе әфәнде илә һәр икемезгә бик гаҗәп тоелды, һәр икемез дә бик читенлек илә генә көлмәенчә чыдадык. Әфәнде дә, рус егете шикелле

үк, бик тиз йокыга киткән иде, ләкин ул вакытта аның йокыга киткәнлеге миңа мәгълүм булмый калганлыктан, бик гаҗәп тоелмаган иде.
Бу егет артыннан гакылына зарар килгән, егерме елдан бирле шул авыруга мөбтәля булу аркасында вакыт-вакыт бик кызганыч хәлләргә кереп, төрле ямьсез тавышлар илә кычкырып авырган бер рус карчыгы керде. Саташканлык, диваналык әсәрләре карчыкның йөзләрендә заһир иде. Буны йоклату бераз озаккарак барды.
Иң әүвәл карчыкны якты, ялтыравыклы бер ноктага каратып тотты. Соңра, бераз күзләре талчыккач, үз күзенә каратып, бармаклары илә ишарә кыйлып, кулыны карчыкның күзләренә таба акрынлап китерде. Бармак очлары күзләренә килеп җитәр алдыннан күзләре йомылып, карчык йокыга китте.
Йоклаганнан соң, һәртөрле өмид бирә торган сүзләр илә бераз җуатты. Соңра әүвәлдәге һәммә начар холыкларыны, начар гадәтләрене онытырга әмер итте. Бераздан: «Синең ул начар авыруың сиңа нинди халәтләр китерә иде, шуннарның барысыны да чыгарып бетер, сиңа биш дәкыйка мөһләт бирәм, шул мөһләт эчендә һәммә начар авыруларың чыгып бетсен!» – дип әмер итте. Шул әмердән соң карчыкның гәүдәләре, башлары дерелдәргә, агызыннан һәртөрле начар тавышлар чыгарга башлады.
Бераз кычкыргач туктады. Соңра янә: «Ул сине кычкырта торган нәрсә нинди нәрсә ул? Аның исеме ничек?» – дип, карчыктан сорый башлады. Карчык янә дерелдәргә башлады. «Һай, куркыныч, бик куркыныч!» – дип әйтмәскә теләде.
Ахырдан, күп иҗбар кыйла торгач, «мальчишка» диде. «Мальчишка»ның исемене сорагач, бик уңайсызланып бераз мыгырдады, соңра «Яфимкә» диеп җавап бирде.
Бу сүзне ишеткәч, Ситников яңадан: «Чыгар шул Яфимкәне, китсен ул бундан! Чыгар, чыгар, чыгар! Әйдә тизрәк! Бер генә минут калды! Ә, менә, менә, менә! Чыга, чыга! Ә менә инде чыкты!» – кеби сүзләр сөйләде.
Карчык һаман Ситниковның сөйләгән вакытында бар куәте илә ямьсез тавышлар илә кычкыра-кычкыра аргач туктады. Соңра өч дәкыйка кадәр тирләп йоклап, ахырдан күзенә өргәч, уянды. Үзенчә догаларны укып чыгып китте.
Ситниковның әйтүенә караганда, ушбу карчык: «Эчемә җен керде, мине сихерләделәр, боздылар», – дип игътикад кыйлып, саташып йөргән, имеш.
«Яфимкә»гә чыгарга әмер кыйлу кеби безгә көлке тоелган фәрманнары да карчыкның зиһененә җирләшеп калган җен барлык хыялыны күңеленнән чыгарту өчен икән. Шундый әүһамнарны башларыннан чыгарту илә ничә кешеләрне сәламәтләндергәнлекне Ситников үзе дәгъва кыйладыр.
Ушбу хакта авыруларның язып биргән шәһадәтнамәләре дә күп. Шифасы бармы-юкмы, ул кадәресенә тәмам ышанып бетә алмасам да, гипнотизм куәте илә кешене йоклатуның мөмкин идекене үз күзем илә күрдем. Шуның өчен бу кадәресенә ышанамын.

«Яшь гомер»
(Драма биш пәрдәдә, мөхәррире – Габделгафур Коләхмәтев.
Наширләре «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе»)

Ушбу соңгы ай эчендә китап базарында берникадәр яңа әсәрләр күзгә күренде. Яңа туган ушбу балаларның һәммәсен дә әдәбиятка нисбәт бирергә яраса, бер ай эчендә әдәбиятымыз хили баеды. Ләкин арада бәгъзеләре тик сикыт көенчә туган булганга күрә, чын балага хисап итү мөшкилрәктер.
Арада иң сәламәт туганнарыннан берсе – «Яшь гомер» исемендәге драма рисаләседер. Драманың тасвир җәһәтләре хили гүзәлдер. Икенче, өченче вә бишенче пәрдәләре бик маһиранә тасвир ителгән. Хосусән икенче пәрдәнең, гәрчә уенга тәгаллекы бик аз исә дә, хикәядәге каһарманнарның хәрәкәтләренә даир бу пәрдәдә һичбер нәрсә булмаса да, тасвиры бик табигый һәм вакыйгъга мотабикъ рәвештәдер. Беренче вә дүртенче пәрдәләрнең бәгъзе урыннары вакыйгъдән хили озактыр. Бишенче пәрдәдә хәкыйкатьтән

бик бәгыйд эшләр юк түгелдер. Мәсәлән, үзен һәлакәттән коткарырга йөргән егеттән Зөләйханың алты-җиде айлар кадәре һичбер хәбәрсез ятуы гакылга сыя торган нәрсәләрдән түгелдер. Хосусән Зөләйханың Мостафадан күргән җәфалары моны хәтердән чыгармаска тиеш иде. Беренче пәрдәдәге Мостафа иптәшләренең дә кыйланышлары һәм алар илә Мостафаның мөгамәләсе дә гайре табигый чыгалар.
Кыяфәтләрне сайлап алуга килсәк, хикәядә икенче дәрәҗәдәге кешеләр һәммәсе бик яхшы табигый кыяфәтләрдә алынган булса да, хикәянең ике каһарманы – Гали илә Зөләйха кыяфәтләренең дә дөньяда булуы бик бәгыйд күренәдер. Чөнки егет бер интеллигент, бер сыйныф халкының хадиме һәм хамие. Кыз исә, хикәядә күрсәтелгәнчә, үз файдасын үзе аңламас дәрәҗәдә аңгыра, һәртөрле хорафатларга ышана торган яхшы гына җитәрлек надан бер кыздыр. Бундый ике кыяфәтнең дөньяда аерым-аерым ике җирдә табылуларын мин һич инкяр итмим. Әмма бундый гакыл, фикер, гыйлем вә мәсләк җәһәтеннән бер-берсенә тәмам зыйд булган аерым ике табигатьтәге кешеләрнең арасында бер галяканең хосулына һәм егетнең шул рәвештәге, фикер җәһәтеннән үзеннән бик ерак булган бер кызны тәхлисъ итәргә йөрүенә һичбер төрле гакылым ирешмидер. Егет нидән буңа мәҗбүр булды икән? Заныма күрә, хикәя йә бер мәкъсудка мәбни уларак язылырга, яхуд хикәядә хәзерге көндә мәкъбуль күрелмәктә улан тугърыдан-тугъры мәгыйшәтнең копиясе кеби вакыйга тасвир ителергә кирәк иде. Китапны кулга алып укыганнан соң, бәнем белүемчә, яшь гомер тасвир ителгән китаптан яшь гомер, фотограф рәсеме кеби, күз алдында күренеп тора торганы булырга тиеш иде.
Икенче дәрәҗәдәге кыяфәтләрдән Вәли илә Йосыфның кыяфәтләренең яхшылыгына һич сүз юк. Бунлар тәмам-тәмамына бер сыйныф халыкка хезмәт итүчеләрнең кыяфәтләренең җанлы сурәтләредер. Йосыфның бакчадагы, участкадагы кыйланышлары, Гали өендә вакытта урамда үзләренә дошман берәүнең кыйналуын күргән вакытта шатланулары, вакыйган, бик урынлы, бик табигыйдер.
Әгәр дә мөхәррир әфәнде кыз кыяфәтенең дәрәҗәсен интеллигент бер ир илә араларында галяка хасыйль булырлык итеп югарырак күтәргән булса, яхшырак булган булыр иде. Ләкин нишләмәк кирәк, бик югарыдан егылдырып төшерү дә бик ансат эш түгел шул. Ул вакытта, бәлки, драманың бөтен планын үзгәртергә кирәк булган булыр иде.
Мин бу язган сүзләрем илә әсәрнең кадерен киметүне уйламыйм, бары тик үземнең ушбу хакта мәгъкуль күргән фикерләремне генә әйтәм. Шул җәһәтләре игътибар кыйлынган булса, мөкәммәллеге дәхи дә арткан булыр иде дип уйлыйм. Ялгыш исә, гафу ителсен.
«Ачлык кушты»
(Ярулла әл-Вәли әсәре,
«Шәрекъ көтебханәсе» нәшере)

Эстәрсә, драма булсын, эстәрсә, комедия, язган вакытта әсәрнең сәхнәгә куелачагыны фараз итеп язган нәрсәсе сәхнәгә кую шартларына муафикъ булып-булмаячагыны игътибар итү мөхәррирнең вазифасыдыр. Фараз итик, бер әсәр тамашага куелса да, куелып пәрдә күтәрелсә, сәерчеләр урыннарына килеп җирләшкәнче, тамашага куелган әсәрдәге хәрәкәтләр илә танышып җиткәнче пәрдә төшсә, икенче пәрдәләре дә кәзалик бере-береннән кыска булып һәр пәрдәсе биш дәкыйка зарфында тәмам була торган булса, тамашага килгән кешеләр буннан нинди ләззәт ала белерләр! Зан идәрсәм, мөхәррир әфәнде үзе шундый бер уенда хазир булса, тамашаханәдән, әлбәттә, мәэюс булып кайтачактыр. Шуның өчен тамашага куелачак әсәрләрнең пәрдәләренең күплегеннән бигрәк эчендәге хәрәкәтләренең канәгать хасыйль итәр дәрәҗәдә күбрәк булуына иҗтиһад итәргә тиеш.
Мәсәлән, Ярулла әфәнде ушбу әсәрендә һич кирәкмәгән урында ике пәрдә ясаганчы, беренче вә икенче пәрдәләрне берләштереп, икесеннән бер пәрдә ясаган булса, мөкәммәл булачагы бик әшкярәдер. Бу ике пәрдәне берләштерү мөхәррир өчен бик асат бер эштер. Өченче пәрдәдә кәзалик хикәянең каһарманы санарга ярый торган Маһсылуның хәрәкәтләре, аның мәзлумлекләре һичбер төрле тасвир иделмәдекеннән, Маһсылу үзенең

тәэссоратларыны һичбер төрле кирәгенчә изһар кыйлмадыгыннан үзенә бер пәрдә итеп тасвир кыйлуның лөзүме һич күренмидер. Дүртенче пәрдәсе янә, заныма күрә, артыктыр. Чөнки нинди дә булса бер мөнәсәбәт илә Идрисне Морат аганың куышында күрештерү мөмкиндер. Иштә бу җәһәтләрене караган вакытта бу хикәя өч пәрдә эчендә хәзергегә караганда да мөкәммәлрәк итеп тасвир ителә алачактыр.
Соңра әсәрнең уйналачак сәхнәләрене дә бераз игътибар итәргә тиешледер. Татарча язылган театр рисаләләре, әлбәттә, Париж, Лондон вә гайре пайтәхет шәһәрләрендә куелачак түгелләрдер. Бунларның куела торган җирләре кечкенә генә клублар илә, бик уза китсә, шәһәр театрларыдыр. Хикәядәге көтүләрне тасвир итү өчен, зур шәһәр театрларында булганда да яңадан-яңа декорацияләр ясарга лязим булачактыр ки, бу эш бик күп мәсарифка мохтаҗдыр.
Шул сәбәптән китапта күрсәтелгән бу нәрсәләр вөҗүдкә китерелмәдектән соңра, аннан башка да кыска булган хикәя яңадан да рухсыз булып чыгачактыр.
Ярулла әфәнденең бер әсәре Казанда тамашага куелган иде.1 Ушбу вакытта да әсәрнең техника җәһәтеннән җитешмәгән җирләре бик күп булганга күрә, уйнаучылар үз тарафларыннан әллә никадәр сүзләр арттырырга мәҗбүр булганнар иде. Мәзкүр рисалә Ярулла әфәнденең беренче әсәре булдыкыннан, бераз мәгъфу иде. Бу икенче әсәрендә янә шундый җитешмәгән урыннар күренәдер. Ярулла әфәнде икенче әсәрене язган вакытта, әүвәлгегә караганда тәҗрибәсен арттыру урынына, яңадан бераз киметә төшкән икән. Бунлар фәкать әсәрнең техника җәһәтеннән килеп җитешмәгән җирләре.
Хикәянең рухи җәһәтенә килсәк, анда да ноксаннар җитәрлектер. Әүвәле драманың каһарманы булырга тиешле Маһсылу бик җамид күренә. Мәзлумә бер хатынның буңа караганда күп хәрарәтле булуы лязимдыр. Хосусән үзләренең мәзлумиятьләрене, тәэсирләрене кешегә аңлатуда ирләргә караганда күп дәрәҗә өстен булган хатын-кыз таифәсенең бу кадәр суык тасвир ителүе урынсыздыр. Сөйләгән урыннарның да күбесендә Маһсылу тәэссоратыны карьяле бер кыз кеби дәгел, мәктәп күргән тәрбияле бер кызның хиссият изһар кыйлганы шикелле сөйлидер. Бу да, табигый, урынсыздыр. Соңра аңлашылдыгына күрә, кызның анасы Рәхимә үги ана түгел. Үги ана булмаганнан соң, һич кирәкмәгән урында аны үги ана кеби рәхимсез итеп тасвир кыйлу тиешсездер. Рәхимле, шәфкатьле итеп тасвир ителсә дә, хикәянең асылы бозылмас иде. Бәлки кызыны төрекмәнгә сатып җибәргән вакытта егълый-егълый озатып калса, ачлыкка тәхәммел кыйла алмаганлыктан биреп җибәрергә мәҗбүр булганлыгы яхшырак аңлатылса, хикәя бозылу урынына, бәлки, берничә кат төзәлгән булыр иде һәм ахыргы пәрдәләрдәге шәфкатьле Рәхимә илә беренче пәрдәдәге Рәхимә арасында мөнәсәбәт тә кямилләнгән булыр иде. Рәхимәнең дә мөхаверәләрендә табигый булмаган җирләр бар. Мәсәлән, Хәйдәр аганың каршысында сүз сөйләгән вакытта: «Мин – арыслан, татар баласы», – дигән кеби мактанулары сала карчыгының агызына бер дә килешми2. Карчык бигрәк сознательный националистка икән диясе киләдер. «Милләтче» сала карчыклары илә философ дворниклар дөньяда күренгәне юк. Булмагач, язмаска да кирәк.
Мәзкүр әсәрне театр рисаләсе түгел, бәлки бер хикәя китабы дип игътибар иткән вакытта хили гүзәл бер хикәядер дияргә мөмкин. Шул җәһәтне мөляхазә кыйлып укып чыкканда, мәзкүр китап хили гыйбрәтле бер әсәрдер.

«Гыйльме әшья»
(Мөтәрҗиме Харис Фәйзи,
нәшере «Мәгариф көтебханәсе»)

Харис әфәнде буннан мөкаддәм ушбу исемдә мәктәпләрдә тәгълим өчен бер китап язып чыгармыш иде1. Бу соңгысы исә шул әүвәлге китапның тәкмиләсе, яхуд икенче җөзьэдер. Мөндәриҗаты җисемнәрнең хәлләре, мәсахә вә хәҗемнәре, сакыйләт һәм вәзеннәре, хәрарәт тәэсире берлә инбисатлары, хәрарәт вә һава бәхәсләреннән гыйбарәтдер.

Бу китап хакында булган фикеремезне беренче җөзьэ чыккан вакытта язган идек2. Ул вакытта да лисанының төрекчәлегенә бераз бәхәс кыйлган идек. Бу икенче җөзьэндә Харис әфәнде, гыйнадыннанмыдыр яхуд матбугатта язылган сүзләргә һичбер илтифатсызлыгыннанмыдыр, китабының бу җөзьэндә төрекчәлекне дәхи дә арттыра төшкән. Башкача яңадан сөйләячәк сүземез юктыр.
Китап рөшди мәктәпләрдә укытыр өчен яхшы бер әсәрдер. Әүвәлге җөзьэндә булдыгы кеби, бу җөзьэ һәм җитмеш кадәр рәсемнәр илә мөзәйяндер.

«Уку көтебханәсе»

Ушбу исемдә «Сабах» көтебханәсе тарафыннан бер-бер артлы кечек-кечек рисаләләр нәшер ителә башлады. Бунлардан биш җөзьэ бу көннәрдә идарәмезгә килде. «Көтебханә»нең төрлесе төрле бабтан улдыкы кеби, язылулары, тәрҗемә ителдекләре дә төрлечә булдыкыннан, һәрберсе хакында аеруча бер фикер бирү мәгъкуль күрелде.
1) «Алла хаклыкны белә, ләкин тиз әйтми»1. Бу китап Толстойдан тәрҗемә ителгән кечек, ләкин гыйбрәтле бер хикәядер. Тәрҗемәсе дә хили гүзәл күренәдер. «Сабах» көтебханәсе» исемендә буйлә кечек вә арзанлы рисаләләр нәшер ителүеннән мәкъсуды ярлы халык һәм яшьрәк балалар арасына әхлак вә бераз мәгълүмат тарату булса кирәк. Әгәр дә мәкъсудлары шул исә дә, бу беренче җөзьэ мәкъсудларына бик муафикъ һәм файдалыдыр.
2) «Гыйлем вә җәһел»2. Язучысы Х.Зәбири.
Бик күп кимчелекләр илә язылган күңелсез һәм кызыксыз гына бер хикәядер. Эчендә укучының дикъкатене җәлеп итәрлек һичнәрсә күренмидер. Зан идәрсәм, бу хикәя бервакыт «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган иде шикелле. «Язылган нәрсә юкка югалмасын инде», – дип, Зәбири әфәнденең бастырырга теләгән булуы бик карибтер.
3) «Сигнал яки ишарә»3. Югарыдан бирелгән әмерләргә сукыр көенчә итагатькә өнди торган бер хикәядер. Шулай да булса тәэсире гүзәл һәм маһиранәдер.
4) «Тунгатай»4. Кыргыз тормышыннан бер-ике тиенлек мәгълүмат бирә ала торган бер хикәя кисәгедер. Әгәр дә моктәдир мөтәрҗимнәр тарафыннан тәрҗемә ителгән булса, бәлки, кыйммәте бераз арткан булыр иде. Китапның бәхетсезлегенә каршы, телгә бик ярлы тәрҗемәчеләр тугъры килмештер.
5) «Томас Эдисон кем?» Исемендә мәшһүр мохтәригъның тәрҗемәи хәлләрене һәм аның мәдәниятькә кыйлган хөрмәтләрене тәкъдир иткән гүзәл бер китаптыр. Ләкин бунын да тәрҗемәсе бик начар. Шулай булса да, яшьләргә һәм балаларга гайрәт һәм җөрьәт бирсен өчен, укытып чыгарырга яраклы һәм файдалы бер китаптыр.
«Уку көтебханәсе»нең киләчәк җөзьэләрене табгы кыйлдырган вакытларда рисаләләрнең телләрене игътибарга алуларына тәүсыя итәмез.
Татарча театр

14 июльдә Панаев бакчасында1 «Яшьләр» труппасы2 тарафыннан «Хуҗа һәм приказчик»3 нам комедия илә «Кияү эзләү»4 исемле бер водевиль тамашага куелды. Сәерчеләр гадәттәгедән азрак иде.
Уен гүзәл чыкты. Галимҗан бай, Садыйк бай кыяфәтләренә тәкълид итүчеләр үзләренең тәкълидләрене бик урынлы чыгардылар.
Приказчик ролене тәкълид итүче әфәнде беренче пәрдәдә йомшаграк уйнаса да, соңгы пәрдәләрендә зарарсыз чыгарды.
Хатын-кыз рольләрене уйнаучылардан кыз анасыны тәкълид итүче ханым бик начар һәм зәгыйфь уйнады. Сафия ролене уйнаучы Морадова5 гадәттәге уйнавы кеби һаман үзенең рольләрендә илтифатсызрак кыйланды. Арада Бибиҗамал илә яучы ролене уйнаучы ханымнарның тәкълидләре бик урынлы чыктылар. Хатын рольләрене уйнаучылар даимән утырып торуларыны ташлаган булсалар, дәхи дә мөкәммәлрәк булачак иде. Гомумән, комедия бик яхшы чыкты.

Сәерчеләр бик разый булдылар. Уенның бик соң башланып, сәгать икегә кадәр дәвам итүе генә сәерчеләрне бик ялыктырды. Соңыннан уйналган водевиль татар мәгыйшәтеннән алынган нәрсә булмадыкыннан һәм уйнаучыларның да бик акрын уйнадыкларыннан бик рухсыз чыкты. Хәрарәтле уйналырга тиеш булган бу уен, уйнаучыларның суфлерны озаклап көтеп торулары аркасында, бик салкын чыкты. Хосусән Чиркәс ролене уйнаучы кеше хәрарәтлерәк булып күренергә тиеш иде. Ләкин йомшак чыгарды.
Тел берләштерәләр

Бер учитель. Как хотите, брат, мин бу турыда с вами не согласен. Безнең татарлар бик отсталый народ. Телләре дә до невозможной степени начар. Татар теле шикелле бедный тел не может быть на свете. Безнең тел белән никакой мысльне выразить итү невозможно.
Төркиядән кайткан бер әфәнде. Әвәт, әфәндем, фәкыйреңез дә зате галиләреңез илә фикердәем. Затән бән дә безем милләтебезнең тәдәннисенә чук тәәссеф идәрем. Фикер гаҗизанәмә күрә, безем тәрәкъкыемез ичүн иң зиядә лязим улан шәй... шәй... әлбәттә, лисан берлекедер.
Карап торучы татар. Амин! Амин! Йа, мөҗиббес-саилин! Бу әфәнде бик гыйлем кеше булырга кирәк, доганы бик матур кыйла икән.

Игъланчылар ничек шаяралар

Пайтәхет вә әтраф шәһәрләренең гәзитәләрендә күптөрле алдавыч игъланнар заһир була. 1–2 сум бәрабәренә 25–30 сумлык нәрсә җибәрергә вәгъдәләр кыйлалар.
Мәсәлән, бер фирма 5 сум бәрабәренә 35–40 сум тора торган граммофон җибәрәмен дип игълан тараткан. Арзанлыгына алданып, акча җибәрүчеләргә яңасы 10 тәңкә тора торган ватык, эшкә яраксыз граммофоннар килгән.
Бундан башка да шундый алдавыч игъланнар гәзитәләрдә бик күп күренәдер. Хосусән Варшау фирмаларының арзан мал вәгъдә кыйлучылары шул җөмләдәндер. Бу көнгә кадәр бу фирмалар никадәр халыкка зарар итсәләр дә, артык акчалы баерак кешеләргә зарар итәләр иде. Бераз мөддәттән бирле гареб тарафындагы губерналарның берсендәге бер фирма бик күп ярлы кешеләрнең акчаларыны ашады. Бу фирманың алдавы ушбу рәвеш-тәдер.
4 сум акча җибәргән кешегә бер дәфтәр күндерәдер. Дәфтәрнең эчендә берәр сумлык 4 билет була. 4 сум акча җибәргән кеше ушбу билетларны берәр сумнан 4 кешегә сата. Ул кешеләрдә алган берәр сумлык билетлары илә бергә мәзкүр фирмага 4 сумлык акча җибәреп билет алдыргач, әүвәлге кешегә 20 сумлык мал килә. Соңгы 4 кеше дә үзләренә килгән билетларны сатып бетереп акчалары барып җиткәч, анларга да 20 сумлык мал килә. Фәкыйрь кешегә нинди зур шатлык!
Бары 4 сум сума бер-ике атна кадәр генә бәйләнеп тора да ахырдан сумалары үзләренә кайта. Аның өстенә бөтенләй буш 20 сумлык мал килә.
Ярлы кешеләр бу эшкә бик кызыгалар. Барлы-юклы 4 сум акчасыны күндереп, билетларны саталар, 1–2 һәфтә узуга, мал килеп тә җитә.
Малда һич алдау-фәлән юк. Мал бик яхшы.
Күрше хатыны Гайниҗамал абыстай тун тышлык плүш алдырган, күрсәң, исең китәр. Кибеттән чыгып алганда, аршыныны өч тәңкәдән кимгә һич бирмәсләр.
Моны күреп, Бәдигылҗамал абыстай да тиз генә акча җибәрә. Аңар плүш кирәкми, палас кирәк. Бик матур хәтфә палас килә. Фәхрелниса моңар бик кызыга. Аның башка кирәк нәрсәсе булмаса да, буш килә торган булгач, алып калу өчен, алтын брошка соратып, тиз генә акча җибәрә. Беренче җибәргән кешегә 4 билет килгән иде. Ул сатты 4 кешегә, анларга да 4 әр билет килде. Булды 16 билет. Бу 16 кеше дә акча җибәрделәр, анларга да 4 әр билеттан 64 билет килде. Анлар да сатып бетерделәр. Анлардан алган кешегә килде 256 билет. Анлардан алган кешеләргә килде 4 әр билеттан – 1024 билет, аннан алган кешеләргә килде 4 әр билеттан – 4096 билет. Берзаман билет илә бөтен Казан шәһәре

тулды. Абыстайлар бер өйдән бер өйгә билет сатарга йөри башладылар. Буш мал алу һәвәсе һәрбер абыстайларда һәм абыстай табигатендә булганрак абзыйларда бик күбәйде. 4 әр сум акча җибәрүченең һичбер исәбе-хисабы юк. Почтаханәдә һич нәүбәт тими, көненә 100 әр, 150 шәр перевод китә. Акча җибәрү эше әле һаман да дәвам итә. Ләкин мал килүе бик сирәкләнде. Акча җибәргән кешеләргә билетлар бик тиз килсә дә, мал килми башлады.
Ушбу көннәрдә почтаханәдә вакытымда бер абыстай кечкенә баласыны ияртеп килеп керде. Ул русча белмәдекеннән, миңа тәрҗеман булырга туры килде. Бичара абыстай сентябрь аенда үзеннән билет алган абыстайларның акчаларыны (16 сумны) үз кулы илә китереп почтага салып җибәргән булса да һәм ул абыстайларга билетлар күптән килеп җиткән булса да, мал һаман юк. Шул сәбәптән почтаханәгә шикаять итәргә килгән.
Почта мәэмүрләренең сөйләүләренә караганда, бундый шикаятьче абыстайлар почтаханәгә бик күп киләләр икән. Почта мәэмүрләре бу эштән тәмам гаҗиз булганнар. Акча җибәрүчеләргә никадәр алдан тәнбиһ кыйлсалар да, сүзләрене тыңламыйча һаман күндерәләр икән.
Бу безнең Казан абыстайларының гына башларына килгән хәлдер. Башка шәһәрләрдәге абыстайларның җибәргән акчалары бу хисапка дәхел түгелдер.
Бу эшнең алдау касды илә, алдау булмаганда да зур файдалар итеп, акча җыю мәкъсуды илә эшләнгән бер эш идекеннән һәркем хәбәрдар булырга тиешле.
Бичара ярлы кешеләрнең кул көче илә мәшәкатьләнеп тапкан акчалары җилгә китеп әрәм булмасын!
Яңа әсәрләр

«Сабах» көтебханәсе1 тарафыннан мөрәттиб уларак, «Уку китапханәсе» исеме тәхтендә нәшер ителеп килмәктә улан китапларның алтынчы вә җиденче җөзьэләре бу көннәрдә басылып китап базарына чыкты.
Бу алтынчы һәм җиденче җөзьэләрнең һәр икесе рус философларыннан граф Лев Толстой тарафыннан язылган гыйбрәтле хикәяләрдер.
«Уку китапханәсе»нең алтынчысы улан «Кешегә күпме җир кирәк?» исемле рисаләдә2 граф Толстой, үз кул көче илә аз җир өстендә хезмәт итеп, тамагыны туйдырып тора торган бер мужикның нәфесенә булышып җир артыннан ерак җирләргә барып йөгерә торгач, ахырында канәгатьсезлегеннән егылып һәлак булганлыгыны бик рухлы бер рәвештә тасвир итәдер.
«Уку китапханәсе»нең җиденчесендә Толстойның ике кечкенә әсәрләре дәрҗ ителмештер3. Берсе Ассурия падишаһларыннан Асархадонның башына килгән бер эшене тасвир итә. Толстой бу тасвирында кешенең хәяты илә һәркемнең үзенең хәяты бер идеке, гайрегә золым кыйлу үзеңә золым кыйлу илә бәрабәр бер эш идекене аңлатадыр. Икенчесе бер падишаһның: «Эшне кайвакыт башлаганда яхшы? Кемнәр илә дуст булырга? Эшләрдән кайсы эш әһәмиятле?» – дигән сөальләренә каршы бер заһид тарафыннан бирелгән җаваплардан гыйбарәттер.
Китапларның һәр икесе дә хили гыйбрәтле һәм истифадәле нәрсәләрдер. Бу ике рисаләнең тәрҗемә вә лисаннары да ярыйсы гүзәлдер.
Укып чыгуны һәркемгә тәүсыя итәмез.

Яңа әсәрләр
(«Балалар дөньясы», беренче китап –
«Кечкенә Рәшид»)

Әдәбияте җәдидәгә иң бай еллар узган ике ел иде. Узган елларда бер-бер артлы һәр көн диярлек яңа китаплар нәшер ителеп тора иде. Бу 1908 ел эчендә яңа чыккан китаплар әүвәлгегә нисбәтән азрак булды. Бу ел эчендә чыккан китапларның икенче бер җәһәттән әүвәлгегә нисбәтән артыклыгы да бардыр. Быелгы китапларның әксәре мәктәпләр һәм

балалар өчен әһәмиятле китаплардыр. Араларында шәкертләрнең һәм ибтидаи мәктәпләрдә укучы яшь балаларның мәгълүматларыны арттыру өчен хили гүзәл әсәрләр бардыр. Буннан берничә көннәр мөкаддәмдә «Сабах» көтебханәсе тарафыннан балаларга махсус Габдулла Тукаевның әсәрләреннән «Җуаныч» нам бер китап1 нәшер ителеп, китап базары тәзәйен ителмеш иде. Бу көннәрдә «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан, «Балалар дөньясы»ның беренче җөзьэсе уларак, «Кечкенә Рәшид» исемендә бер хикәя нәшер ителде. Бу хикәядә зур гаиләгә мәнсүб Рәшид исемле бер баланың бишектә вакытында качкыннар тарафыннан угырланып, җир астында иске һәм ташландык тимер мәгъдән коеларыннан берсендә берничә ел тәрбияләнеп, соңыннан кинәттән якты дөньяга чыгуы, дөньяга чыкканнан соң, бу баланың дөньяның яктылыгына һәм галәм мәнзарасының күркәмлегенә хәйран булуы бик яхшы тасвир ителмештер.
Сабый Рәшид, дөньядагы һәрнәрсәгә тәгаҗҗебләнгәнлектән, һәрберсе хакында үзенең тәрбиячесеннән төрле садә сөальләр илә сорашып, мәгълүматыны арттырадыр.
Хикәяне укыган вакытта балаларның да башларына кечкенә Рәшиднең фикеренә килгән сөальләр киләчәк һәм үзләренең сөальләренә каршы җавапларны ушбу китапта күреп ләззәтләнәчәкләр һәм шул саядә үзләренең мәгълүматларыны арттырачаклардыр. Хикәя гүзәл сурәттә табыгъ ителмештер. Арада балалар өчен агыр килерлек гарәпчә сүзләр катышмаган булса, үз дөньясында беренче китап булган булыр иде.
Гласныйлык һәвәскәре

– Сиңа әйтәм, бу ни эшләвең инде бу? Бер көннәрдә ялкаулыгыңнан, урыныңнан күтәрелә алмавыңнан гаҗиз идем. Хәзер инде берничә көннән бирле ашыгуыңнан гаҗиз булдым. Һич утырган урыныңда тора алмыйсың.
– Хатын, хатын! Син белмисең, хәзер утыра торган заман түгел.
– Ни булган да ни туган? Зинһар, аңлат!
– И хатын, синең бер дә дөньядан хәбәрең юк ла.
– Ни эшләп?
– Белмисеңмени, сайланырга берничә генә көн калды бит!
– Калса соң, бу кадәр ашыкмасаң да ярар, өлгерерсең әле.
– Җаным, син әле һаман минем хәлемне белеп җиткерә алмыйсың, сайлану дигән нәрсә бик җиңел эш түгел ул. Иртәдән башлап көндезгә кадәр телефон төбендә әле аңар, әле моңар шалтырата-шалтырата тәмам арып бетәм. Телефон идарәсендә хезмәт итүче илә дә ничә мәртәбә сүзгә килешеп беттем инде. Сайлаучыларның күбесенә телефон белән сөйләшеп гаҗиз булдым. Берсенә шалтыратасың – җавап килә, ләкин тугърыдан-тугъры сайлану тугърысында сүз чыгарып булмый. Һәркайсына үзенә күрә әүвәл бер йомыш табып, ахырдан гына сайлау бабына күчеп, үзеңә тавыш бирүене үтенергә тугъры килә. Күп сайлаучыларның телефоннары юк. Анларга, өйләренә барып, мәхсус визитләр ясап, ризалыкларыны алмыйча булмый. Сайлауга берничә генә көн калган, әле сайлаучыларның яртысыны да йөреп чыгып булмый. Арада төрле халык бар, берсе бер фикердә, икенчесе икенче фикердә; сайлану өчен яңаракларына – яңача, искерәкләренә искечә сүз сөйләргә кирәк була. Үзеңә мәгълүм бит, кода-кодагыйларның да тиз генә кәефләрене табып булмый. Бу кадәр күп кешенең күңелене табу бик читен эш. Күбесенең үзенең сайланасы килә. Андыйлары илә эш кыйлу тагын да читенрәк була. Картларның да кәефләрене табарга кирәк, яшьләрне дә бәреп җыгып булмый. Арада телле-тешлеләре дә бар.
– Ул кадәр читен эш булгач, сайланмассың!
– Сөбханалла, ул ни дигән сүз? Бервакытта да, синең сүзеңә карап, Дәүләт Думасына сайланмый калдым.
– Мин сиңа начар сүз әйтмим бит!
– Бик яхшы сүз дә түгел. Мин дә читен эш дип сайланмый калсам, башкасы да сайланмаса, ул вакытта кем генә гласный булып калыр?
– Булмаса, ни зарар, синең сайлануыңнан кемгә файда?

– Милләткә файда, җаным, милләткә файда. Безнең мөселманнарыбызның урамнары пычрак, караңгы. Җыен начар исле нәҗесләр безнең урамнардан уза, һәрбер начар нәҗесләр безнең тирәгә түгелә. Шәһәр акчасыннан бик аз гына безнең өчен сарыф кыйлына. Без мөселманнарның хакларыны химая кыйлырга тиеш, юкса эшемез харап!
– Син һаман минем сүземне аңламадың, бу эшләрне эшләргә ник син генә кирәк, ник башка кеше ярамый? Бу вакытка кадәр гласныйсыз калмадык бит әле. Бу эшкә ник синең генә эчең поша? Барсын, башка кешеләр сайлансын. Эш эшләрлек кешеләр күптер әле!
– Һи, җаным! Һаман аңламыйсың, минем үземнең бик сайланасым килә шул.
– Мин дә шуны әйтәм шул, ни өчен синең генә бик сайланасың килә?
– Җаным, кил инде алайса, колагыңа гына әйтим, кеше ишетә күрмәсен. Мин, гласный булып сайлансам, үзем управа члены булып, шәһәр акчасыннан бераз мәгашлек алып булмасмы дим.
– Һә, шулаймыни? Соң син аны күптән әйтергә кирәк иде. Бар алайса, бар! Тизрәк күрәсе кешеләреңне дә күр! Кеше янына барганда чибәррәк булсын, икенче киемнәреңне дә биримме? Бар, җаным, бар, тизрәк бул, тизрәк сайлан! Сайлансаң, мин бер-ике табын кунак та уздырып алырмын, җәме?

1909

## Яңа әсәрләр

Бу көннәрдә китап базары хили баеды. Бердән, берничә төрле әсәрләр мәйданга чыкты. Арадан интикад өчен идарәмезгә җибәрелгәннәре хакында бераз сөйләп китүне мәгъкуль күрәмез.
Китаплар арасында иң әһәмиятле урыннар мәктәп китапларына бирелергә тиештер. Мәктәп китаплары никадәр гүзәл тәртип ителгән булса, баланың фикере тәрәккый итүгә шулкадәр ук ярдәм бирер. Шул сәбәпләрдән балаларга укытылачак китапларның телләренең җиңеллегенә, өслүбе ифадәләренең садәлегенә бик дикъкать ителергә тиешледер.
Бу көннәрдә идарәмезгә килгән китаплар арасында берсе – «Милләт»1 көтебханәсе, икенчесе – Оренбургтагы «Кәримев-Хөсәенев ширкәте»2 тарафыннан нәшер ителгән ике мәктәп китаплары күземезгә күренде. «Кәримев-Хөсәенев ширкәте» тарафыннан нәшер ителгәне – «Җәгърафия мөгаллиме»3 исемендә кыскача җәгърафия рисаләседер. Наширләренең китап өстенә язып куюларына караганда, бу рисалә балаларга ибтидаи мәктәпләрдә укыту өчен тәртип ителмештер. Әмма китапның эчендәге мөндәриҗатына тәфтиш итеп караганда, ибтидаи мәктәпләрдә укый торган сигез-ун яшьлек балаларның фикере җитешерлек дәрәҗәдә садә мәгълүмат һич юктыр. Балалар өчен лисаны бик агыр булу өстенә тәфсыйлән язган вакытта зур бер җилд китап булачак мәгълүматларның һәммәсене кыска агыр тәгъбирләр илә бер арага җәмгъ ителмештер.
Бу китап – күп сатып акчасыннан файда итү максаты илә башка китапчылар тарафыннан нәшер ителгән китапларның берседер. Наширләр һәрвакыт халык файдасыннан бигрәк үз кесәләренә якын күргәнлектән, башка кешеләрнең яхшы, күп китә торган китапларына тәкълид кыйлуны бик яраталар. Бу китапның яхшы бер җәһәте дә юк түгел. Башкаларга караганда бер хасияте шулдыр ки, китапның ахырына мәсьәләгә тәгаллекъле бик күп рәсемнәр һәм хариталар дәрҗ ителмештер. Бу рәсемнәре илә истифадә бераз җиңелрәк булуы ихтималдыр.
Китапларның икенчесе – Казандагы «Милләт» көтебханәсе тарафыннан нәшер ителгән «Тарихы ислам»4 намендә тарих рисаләседер. Мөхәррире – Төркиянең мәшһүр

голямасыннан Мәхмүд Әсгать әфәндедер. Лисаны төрекчәдер. Һәр ни кадәр мөхәррире госманлы исә дә, лисаны төрекчәнең бик җиңелләреннәндер. Рөшди мәктәпләрдә укытыр өчен яхшы бер әсәрдер.
«Милләт» көтебханәсенең үз мәтбагасында бик гүзәл рәвештә табигъ ителмештер.
Урыны чыкканда «Милләт» мәтбагасы хакында да бераз сүз сөйләп китүне мәкъбуль күрдек.
Буннан бер-ике ел мөкаддәмдә Казанда «Милләт» намендә яңадан бер мөселман мәтбагасы артты. Мәтбага ачу сәрмаясе булган кеше өчен гади бер тиҗарәтханә ачу илә бәрабәр исә дә, «Милләт» мәтбагасының башкалардан мөмтаз икенче бер тарафы бар. Башка мәтбагачылар әүвәлдә мәүҗүд мәтбагалардан хәзер хоруфат җәлеп итеп, бер-ике көн эчендә мәтбаганы ачып, эшкә керешәләр. Хәрефләрнең матурлыгына, яхуд ямьсезлегенә әксәрдә һич илтифат кыйлмыйлар. Ушбу соңгы елларга кадәр, ягъни Казанда Харитонов мәтбагасы5 ачылганга кадәр, мөселман хоруфатыны гүзәлләндерү өчен һичкем сәгый кыйлмады. Йөз ел әүвәлдә, беренче кәррә мөселман хоруфаты илә мәтбага ачылган вакытларда, хоруфат ни рәсемдә булса, шул көенчә дәвам итеп килделәр. Ниһаять, Харитонов, мәтбага ачканнан соң, үзе һәм аның хезмәтендә улан Ибраһим Юзиевнең6 иҗтиһады аркасында хәрефләр хили гүзәлләнде һәм төрле эрелектә, төрлечә хәрефләр мәйданга килде. Ушбу көндә Казанда «Үрнәк» мәтбагасы7, Оренбургта Кәримев-Хөсәенев, «Вакыт» һәм «Дин вә мәгыйшәт»8 мәтбагалары илә дәхи берничә мәтбагалар ушбу Харитоновның гүзәл хоруфаты илә китап вә гәзитәләрне табигъ итмәктәләрдер. Бу көнгә кадәр бу хакта тырышучы фәкать Харитонов иде. Икенче уларак «Милләт» мәтбагасы дөньяга килде. «Милләт» мәтбагасының сахибе Ибраһим Идрисов җәнабләре, мәтбага ачмастан әүвәл, угълы Мөхәммәд әфәндене Москвага җибәреп, мәтбагачылык һәм хәреф коючылык сәнгатенә өйрәттереп кайтарды. Соңра үзләреннән хәреф кисеп, коеп, мәтбага ачып эшкә керештеләр. Мәтбагалары хили зәхмәтләр соңында вөҗүдкә килде. Ләкин мәшәкатьләре бушка чыкмады. Икенче уларак бунларда хили гүзәл хоруфат мәйданга чыкты. Бу хезмәтләре өчен «Милләт» мәтбагасының сахибләренә тәшәккер итәмез.
Тәмсилләр
1
Крылов бабайның баснялары1 һәрвакыт һәркемнең кыйланышын тәмсил итеп күрсәтер өчен кыяматкә кадәр ярарлык бер көзге дисәң, ялган түгелдер.
Шул сәбәпле без әхвале хазирәмездәге әшхасны бераз Крылов баснялары илә үлчәп карыйбыз.
Филгә ничектер арыслан тарафыннан вәзирлек дәрәҗәсе бирелгән2.
Бу хәбәр урманга таралуы белән, барча хайваннар, бер җиргә җыелып, фил хакында бәрвәҗһе ати мөхакәмә кыйлырга башлыйлар.
Бер хинзир3, алпавытның ишегалдында, ат абзарларында, көл базларында туйганчы аунаганнан соң өенә кайтып барганда, аңар көтүче очрап: «Җә, каты борын, син алпавытта ниләр күрдең? Мин алпавытта энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш бик күп дип ишеткән идем», – дигәч, хинзир җавабында: «Хәер, мин абзарларда, көл базларында туйганчы аунадым, әмма син әйткән байлыкларның берсенә дә очрамадым», – ди, имеш.
*
Бездә бик «усал» бер критик4 (интикадчы) бар. Син ул критикка: «Мин фәлән китапны укып чыктым. Гаять гүзәл мәфһүмнәре бар яки фәлән кешене күреп сөйләштем, гаять мәгълүматлы вә гакыллы кеше таптым», – дисәң, ул критик: «Юк, мин ул китапны да укып чыктым, син әйткән кешене дә күрдем. Ләкин мин китапта да, кешедә дә яхшы хасиятләр тапмадым», – диячәк.
Ул критик, бичара, һичкемнең вә һичнәрсәнең яхшы тарафын күрә алмый.
Аңа шул сәбәпле гомер буена сүгенеп торырга гына тугъры килсә, гаҗәп булмас шул.
2

Бер кечкенә курнос көчекнең филгә каршы һичтуктаусыз өреп5, филне куркыта алмаганлыгына хурланып, өрә-өрә тәмам гыжылдап хәлдән тайганын күргәч, көчектән: «И мескен! Шул гомердән бирле аяк астында өргән булып тәмам хәлдән тайдың, әлсерәдең, әмма филнең синнән хәбәре дә юк, үз юлы белән бара бирә», – дип көлгәннәр икән. Көчек җавабында: «Көлмәгез, мин филне куркыта алмаганымны үзем дә беләм, миңа тик шунысы кирәк: читтән карап торучылар, ай-яй, безнең көчек гайрәтле икән, филгә дә өрә бит дип уйларлар. Менә мин ни өчен өрәм...» – диде.
*
Хатирә дәфтәремдә ялгыш калмаган булса, бер сәнә инде «Әлислах» идарәсе ишеге төбендә, шул ук курнос көчекнең мәкъсуды илә булырга кирәк, бер «Оренбург көчеге» өрә6.
Бу көчек тә бик гайрәтле күренә. «Яшен» чыга башлаганнан бирле, безнең «Яшен» капка төбендә «Тәф! Тәф!» итеп өргән тавышлары ишетелә.
Без моңар берзаман арыр вә хәле бетәр дә туктар әле дип кенә карыйбыз.

«Явызлыкның җәзасы»
(«Гасыр» көтебханәсе нәшриятыннан)

«Гасыр» көтебханәсе тарафыннан ушбу көннәрдә «Явызлыкның җәзасы» исемендә бер роман нәшер ителде. Китапның тышындагы «милли роман» һәм «Оренбургтагы мөсабәкаи әдәбиядә беренче мөкяфәтне алмыштыр» дигән сүзләренә караганда бу китап үз мәгыйшәтемездән алынган гүзәл тасвирларны шамил бер әдәби әсәр булырга тиеш иде. Китапны ачып укырга керештем. Укый башлагач та, теленең һәм тасвирларының гүзәллегенә карап, бу әсәрнең хәкыйкатән беренче мөкяфәтне алырга мөстәхикъ бернәрсә икәнлегенә хөкем иттем. Буны язган кешенең бик әгъля каләм сахибе икәнлегенә тәмам ышандым. Хәтта безнең арабызда бундый моктәдир әдипләрнең барлыгын күреп хәйран калдым. Ләкин шулкадәресе бар, укыган саен романның башына язылган «милли» дигән сүз йөрәгемне тырный бара иде. Хикәядә тасвир ителгән әшхасның татар арасында мисле табылмаячагы кәефне җибәрә иде. Бара торгач, хикәянең милли түгел икәнлегенә тәмам ышану өстенә, мөхәрриренең милли мөхәррирләрдән булуына да ышанасым килми башлады. Бу хикәяне кайчан булса да бер укыган төсле булдым. Романның ахырына килеп җиткәч, романның үзе дә, язучысы да милли түгел идекен тәмам аңладым. Бу романның аслы ни исемдә идекен эзли башладым. Ниһаять, Франциянең моктәдир әдипләреннән берсе тарафыннан язылып, «Мәшьүм чифетлек» исемендә төрекчәгә тәрҗемә ителеп, аннан «Явызлыкның җәзасы» исемендә татарчага тәрҗемә ителгән бер роман булып чыкты.
Бу роман милли түгел һәм мөхәррире дә М.Галими дигән кеше түгел. М.Галими Франция мөхәррирләреннән берсенең гүзәл әсәре өстенә үз исемен язган бер кеше генәдер.
Роман бик гүзәл һәм бик тәэсирле, ләкин милли түгел. Романның язучысы да бик кямил мөхәррир, ләкин милли түгел. Мөхәррире М.Галими дигән кеше түгел. Һәрнә исә, бик гүзәл әсәр булганлыктан, һәркемне буны укырга тәүсыя итәмен.
Яңа китаплар

Ушбу көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде. Берсе – Габдулла Тукаев җәнабләре тарафыннан назым илә язылган «Алтын әтәч» нам бер хикәядер. Габдулла әфәнде бу әсәрен яшь балалар өчен язмыш вә китапның мәфһүмен Пушкинның «Золотой петушок» нам әсәреннән алмыштыр. Назымы гаять җиңел булу өстенә тасвирлары да гаять шагыйранәдер.
Китап, «Сабах» көтебханәсе тарафыннан мосаувәр уларак, бик яхшы кәгазьдә, гүзәл сурәттә табгы ителмештер.
Яңа әсәрләр
(«Җир йөзе»)

Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдшакир Габдерәхими1 әсәре.
Ушбу соңгы елларда бер-бер артлы фәнни китаплар мәйданга чыга башлады. Арада иң хуп күрелгәннәре тарих вә җәгърафия фәннәренә мөтәгалликъ китаплардыр.
Бу көнгә кадәр нәшер ителгән җәгърафия китапларының һәммәсе дә җәгърафияи сәяси яхуд җәгърафияи сәяси илә җәгърафияи табигыядән мөрәккәб китаплар иде. Җәгърафияи табигыядән генә бахис бер китап юк иде.
Ушбу соңгы әсәр илә җәгърафия китапларының ушбу ноксаннары тәкмил ителде.
Мәзкүр әсәр, җирнең һавасы игътибары илә, эссе, мөгътәдил һәм салкын тарафларның әхваленнән вә ул тарафлардагы хайванат, нәбатат вә агачлардан бахистер. Лисаны гаять җиңел һәм гүзәлдер. Рөшди мәктәпләргә дәвам итүче шәкертләр һәм мәктәпләргә озак дәвам итә алмаган кешеләр өчен бик яхшы һәм истифадәле кыйраәт китабыдыр.
Китапның ахырына сахра вә чүлләр, тагълар, диңгезләр, җирнең асты һәм һаваи нәсими хакында да бик гүзәл мәгълүматлар дәрҗ ителмештер. Китап җитмеш дүрт кадәр рәсем һәм бер гадәд харита илә мөзәйяндер. Бәһасе – егерме биш тиен.
Бу китап киләчәктә әдәбиятымызга хили зур хезмәтләре күрсәтүе мәэмүл булган кәнеҗ мөхәррирләремездән берсенең әсәредер.
Китапның язучысы Казандагы тиҗарәт мәктәбенең өченче сыйныф таләбәсеннән уналты-унҗиде яшьлек яшь бер шәкерттер.
Китапның язылуына, гыйбарәләренең гүзәллегенә, ифадәсенең садәлегенә караган кешенең Мөхәммәдгали әфәнденең кабилиятенә тәхсин итәчәгенә һәм киләчәктә Мөхәммәдгали әфәндедән әдәбиятымызга зур хезмәтләрене өмид итәчәкендә шөбһә кыйлмыймыз.
Мөхәммәдгали әфәндене тәхсыйльләренең беренче җимеше улан ушбу китабы илә тәбрик итәмен.

Яңа әсәрләр
(«Безнең Казан». Казан выставкасының рәһбәре)

Ушбу ел июнь, июль һәм август айларында хили зур бер выставка ачылачагы әүвәлдән бирле гәзитәмездә язылып килмәктәдер.
Выставканың вакыты якынлашу илә, бу эшкә әһәмият биргән кешеләр бик ашыгып хәзерләнәләр. Выставкага үзләренең малларыны кую ниятендә булган кешеләр гүзәл нәрсәләр хәзерләмәктә идекләре көн саен ишетелә. Башка кешеләр илә бергә мәтбагачылар вә китапчылар да хәзерләнмәктәләр. Мәтбагачыларның мәшһүрләреннән Харитонов выставка өчен бик гүзәл китаплар табигъ итеп чыгармакта вә берничә төрле гүзәл рәсме хатлы мөселман хәрефләре дә куеп чыгармактадыр.
Бу көннәрдә выставканың әһәмиятле булачагыны игътибарга алып, читтән килгән кешеләргә укып файдаланыр өчен, «Заман календаре» мөхәррир вә нашире Шәрәфетдин Шәһидуллин җәнабләре дә «Безнең Казан» исемендә хили бер зур рисалә бастырып чыгарды.
Бу әсәрдә выставканың мәбдәэ тарихы, выставканың файдасы, выставканың һөнәр, тиҗарәт, санагать вә фәннәрнең тәрәкъкыйсенә нинди зур файдалар китергәнлеге, выставка мәдәниятнең алга китүенә нинди зур ярдәмнәр биргәнлеге, Казанда булачак выставканың шөгъбәләре, анда куелачак мал вә әшьяның әнвагы һәм выставкага нәрсә куюларның шартлары бик тәфсыйлле рәвештә бәян ителмештер. Выставка хакында тәфсыйлле мәгълүматлар аласы килгән кешеләр өчен укып чыгуы файдалы бер китаптыр.
Китапның лисаны гүзәл булу өстенә табгысы да бик матур. Выставка рисаләсенең хә-кыйкатән выставка өчен эшләнгәнлеге күренеп тора.
Рисалә Харитонов мәтбагасында басылмыштыр. Бәһасе – егерме биш тиен.
Җәйге мәктәпләр, яхуд мәктәпләрнең җәйләүләре

Авыл балаларының – шәһәр балаларына, авыл кешеләренең шәһәр кешеләренә нисбәтән ничә өлеш таза һәм куәтле булганлыгы һәркемгә мәгълүмдер.
Бунларның тазалыклары кырларда, болыннарда яхшы, саф һава астында эшләүләреннән, эш аркасында сеңерләре һәм итләре ныгудан киләдер. Иртәдән кичкә кадәр кырларда, урманнарда эшләү вә саф һава сулау илә бунларның үпкәләре ныгый, әгъзалары хәрәкәтләнү илә гәүдәләре тазара.
Кыш буенча мәктәптә укыган авыл баласы да, яз җитеп, мәктәптән чыгу илә, һәрдаим кырда, урманда саф һава астында була.
Бераз яшьлерәк балалар аталарының кыр эшләренә ярдәм итеп эшләү илә, яшьрәкләре кырларда уйнау илә үзләренең кыш буенча мәктәпнең начар һавасыны сулап зәгыйфьләнә төшкән үпкәләрене яхшы һавалар сулап тазарталар. Һәртөрле табигый гимнастикалары илә гәүдәләрене ныгытып, көзгә кадәр яңадан каннарыны арттырып, буйларыны үстереп, тазарып куялар.
Шәһәр мәктәпләрендә укыган балалар бу сәвабларның һәркаюсыннан мәхрүмнәрдер. Чөнки күп халыклы шәһәрләрнең һавалары кышын-җәен һәрвакыт бозык була. Шәһәрләрдәге даими җүешлек һәм төтен һәрвакыт һаваны бозып тора. Җәй көннәрдә һәртөрле черек нәрсәләрдән чыккан зарарлы газлар һаваны бигрәк тә начарландырадыр. Шул сәбәптән шәһәр халкы арасында авырулар карьяләргә нисбәтән бик күп була.
Кыш буенча гомеренең күбрәгене мәктәптә уздырып, андагы начар һаваны сулап, үпкәләрене зәгыйфьләткән вә шуның аркасында каны азайган шәһәр баласы яз вә җәй көннәрендә, мәктәптән чыккач та, һаман да үзенең сәламәтлегене арттыра алмыйлар. Бер-ике ел ушбу рәвештә йөргәннән соң, нинди булса да берәр авыруга мөбтәля булып, дәваланырга мохтаҗ була.
Мәктәп балаларының шул хәлләрене игътибарга алып, горфән, Яурупадагы мәмләкәтләрнең халыклары шәһәр балалары өчен шәһәрдән читтә һәм яхшы һавалы, урманлы-сулы җирләрдә җәйлек мәктәпләр, яхуд мәктәп җәйләүләре ясап, балаларыны шунда биреп, тәрбия иттерә башлаганнар. Балалар бу җәйләүләрдә яхшы һава астында торып ял итәләр. Яхшы мөгаллимнәр, балаларның дәрәҗәсенә карап, анларны һәртөрле кул эшләре илә мәшгуль кыйлып ял иттертәләр һәм вакыйган да бик яхшы файдасыны күрәләр. Балаларның табигый хәлләре өч-дүрт мәртәбә, үлчәүләре бер-ике мәртәбә, күкрәкләренең киңәюе биш-алты дәрәҗә арта.
Яурупада бу эш күптәннән башланып, бу көнгә кадәр хили тәрәккъкый иткән. Халкы йөз мең микъдарында булган шәһәрләрнең мәктәп җәйләүләрендә ел саен иң күбе ун мең кадәр (Гамбургта), иң азы сигез йөз кадәр (Химнис шәһәрендә) бала ушбу мәктәп җәйләүләрендә тәрбия ителәләр.
Берничә еллардан бирле Русиянең бәгъзе бер шәһәрләрендә бундый җәйләүләрне ясый башладылар һәм мөмиин булган кадәр һаман да арттырырга иҗтиһадлар сарыф ителәдер. Шулай да булса Русиядәге мәктәп җәйләүләре, хосусый кешеләр кулында хосусый сума вә иганәләрдән генә ясалганга күрә, бик тиз тәрәккъкый итә алмыйдыр. Яурупада исә бу яхшы эшкә хөкүмәтләре дә иштиракь итеп ярдәм кыйлганлыктан, көннән-көн тәрәккъкыйдәдер. Русиядә бу эшнең иң тәрәккъкый иткән җире – Варшавададыр. Ләкин анда да, Яурупага нисбәт илә караганда, эш бик зәгыйфь. Җәйләүгә чыккан балаларның микъдары Варшавада мең кешегә – дүрт ярым, Петербургта меңгә – өч, Лодзьда меңгә – өч, Одессада меңгә – ике мең биш йөз, Харьковта меңгә – ике мең биш йөз, Киевтә меңгә – ике мең, Мәскәүдә меңгә мең биш йөз микъдарында гынадыр.
Мәскәүнең бу җәһәттән артка калганлыгыны игътибарга алып, Мәскәүнең шәһәр мәктәпләрене караучы табиблары шәһәр идарәсеннән җәйләүләрне арттыру өчен акча таләп кыйлалар иде.
Хәмед улсын, бу көндә әһле ислам арасында мәктәпләр вә мәктәпләрдә укучы балалар көннән-көн артмактадыр.
Башка милләтләрнең мәктәпләрдә укый торган балаларының башларына килмәктә улан бу хәл безнең балаларымызның башларына артыгы илә килгәнлегендә һич шөбһә юктыр.

Чөнки безнең мәктәпләремездәге һаваның башкалар мәктәпләренә караганда азрак икәнлеге һәркемгә мәгълүмдер.
Мәктәптә баласы булган кешеләрнең бу эшне игътибарга алулары лязимдыр. Берничә кеше иттифакъ итеп, бер җәйләү ясап, балаларыны шунда куеп, идарәсене бер мөгаллимгә тапшырып, тәҗрибә ясап каралса, бик гүзәл бер эш булыр иде. Файдасы күренгәннән соң, икенче елларда бу яхшы эшкә иштиракь итүчеләр күп табылса кирәк. Моның мәсърафы да бик зур түгел. Уртача хисап илә бала башына җәенә 23 сум кадәр мәсъраф чыгадыр.
Бу эш мөмкин булмаган тәкъдирдә дә, мәктәп балаларыны шәһәрнең начар һавалары эчендә тоту тиеш түгел. Башкача мөмкин булмаган тәкъдирдә, баланы җәй буена яхшы һавалы авылларның берсенә җибәреп ял иттерү лязимдыр.
Иван Николаевич Харитонов
(1859 –1909)

Кичә, 24 июньдә, Иван Николаевич Харитонов җәнабләренең мәтбагa эшләренә керешкәнлегенә кырык ел тулды. Шул мөнәсәбәт илә Иван Николаевичның шәрәфенә бәйрәм ясалды.
Ислам матбугатына якын кешеләрнең һәркаюсына Иван Николаевич җәнабләренең матбугатымызга никадәр зур хезмәтләр кыйлганлыгы мәгълүмдер. Без бу мәкаләмез илә бу көнгә кадәр мөшар иләйһинең әхваль вә әүсафыннан хәбәрдар булмаган мөштәриләремезгә бераз мәгълүмат бирү ирадәсендәмез.
Буннан кырык ел мөкаддәмдә Казанда, дәгел мөселманча, бәлки русча мәтбагалар да бик фәкыйрь иде. Ул заманда Казанда фәкать биш данә мәтбага бар иде ки, бунларның да иң зуры һәм мәшһүре Тилле мәтбагасы улып, ул да вак-төяк дәфтәрләр вә кечек рисаләләр эшләү илә генә мәшгуль кечек бер ханәдән гыйбарәт иде. Буннан кала Университет һәм Чиркова мәтбагалары1 зур мәтбагага хисап ителә вә бу икесендә мөселманча китаплар да басыла иде.
Шул көннән башлап Иван Николаевич җәнабләре мәтбага ачканга кадәр Русиядәге мөселманнарның мәтбага эшләре күп тәрәкъкый итә алмады. Гәрчә мөселман мәтбагаларының гадәде артса да, хоруфат җәһәтеннән һичбер төрле алга китү күренми иде. Харитонов мәтбагасы ачылып, хәреф кою эшләре юлга салынганга кадәр, мөселман китаплары фәкать ике төрле – уналты һәм егерменче хәрефләр2 илә табгы ителә иде. Бу хәрефләр дә гүзәл рәсме хатлар күргән кешеләрне канәгать иттерерлек дәрәҗәдә түгел иде.
Харитонов җәнабләре, мәтбага ачып, рус эшләрен юлга салганнан соң, мөселманнарның бу ихтыяҗларын игътибарга алып, мөселман хоруфаты койдырырга шөругъ кыйлды. Соңгы ун ел эчендә мөселман матбугатын бөтенләй яңа бер юлга салып, мәдәни милләтләрнең мәтбагалары хәленә китерде. Казан шәһәрендәге хаттатларның ярдәме илә хәрефләрне яхшылатырга иҗтиһад итеп, Русиядә гүзәллектә бу көнгә кадәр һич күрелмәгән егерме кадәр төрле-төрле гүзәл мөселман хоруфатлары вөҗүдкә китерде. Киләчәктә яңа-яңа хәрефләр вөҗүдкә китереп, ислам мәтбагаларын баетуы өмид ителәдер.
Харитонов җәнабләренең бу гүзәл хезмәтләрен тәкъдир итеп, мөшар иләйһине чын күңелемездән инсаният вә мәдәнияткә кырык ел хезмәте галияләре илә тәбрик идәрәк, киләчәктә дә ничә вә ничә еллар бөек хезмәтләрен өмид итәбез.
Иван Николаевич Харитонов җәнабләренең
тәрҗемәи хәле
Иван Николаевич җәнабләре 1859 ел, 20 июньдә Казан шәһәрендә дөньяга килмештер. Атасы Казанда экипажлар ясаучы бер кеше булып, Иван Николаевич җиде яшендә вакытта вафат итмеш. Иван Николаевич ун яшенә кадәр Михайловский мәктәбендә тәхсил итеп, аны тәмам иткәннән соңра, мәтбагачылык эшенә күңел куймыш. Шул сәбәптән апасы аны Тилле мәтбагасына бирмеш.
Тилле мәтбагасында бераз вакыт эшләгәннән соң, Университет мәтбагасына күчеп, 1881 елга кадәр анда хезмәт итеп, мәтбагачылык эшендә хили тәрәкъкый итмеш. 1881 елда

губернский мәтбагасына баш наборщиклыкка чакырылып, 1888 елга кадәр анда хезмәт кыйлганнан соң, Вечеслав мәтбагасына мөдирлеккә кереп, 1896 елга кадәр, ягъни үз мәтбагасын ачканчы, шунда хезмәт итмеш. Вячеслав үзе брандинтендант мәэмүре булдыгыннан, мәтбага эшеннән һичбер хәбәре юк, шул сәбәптән мәтбаганы тәрәкъкый иттерү мәсьүлияте Иван Николаевичка гаид иде. Иван Николаевич мәтбагага кергән заманда мәзкүр мәтбаганың бөтен еллык обороты фәкать җиде мең сум микъдарында булып, Иван Николаевич кергәннән соң, аның армый-талмый иҗтиһады аркасында, эшләре ун кат тәрәкъкый итте. Мәтбага хуҗасы Иван Николаевичның хезмәтеннән бик мәмнүн булганлыктан, мәгашлекләрен арттырып, ниһаять, мәтбаганы саткан вакытта, Иван Николаевичка дүрт мең сумлык мөселман китапларын һәдия кыйлып биргән. Хезмәтеннән чыкканнан соң, Иван Николаевич җәнабләре Казанның Пассажындагы бер нумер кечкенә кибетендә үз сумасыннан мәтбага ачып, эшкә кереште3. Ул заманда Харитоновның мәтбагасында фәкать алты кеше хезмәт кыйлмакта иде. Үзенең мәһарәте саясендә бик тиз тәрәкъкый итеп, унике ел эчендә мәтбагасын Казанда гына түгел, бөтен Волга буендагы мәтбагалар арасында беренче ясады. Ушбу көндә Харитонов җәнабләренең мәтбагасында йөз утыз кадәр кеше эшләмәктәдер. Типография, литография4, мөҗәллидханә, хәрефханә вә гальванопластика5 эшләре зурлык, яхшылык вә гүзәллектә этраф һәм вилайәтләрдәге мәтбагалар арасында беренчедер.
1910

Мөселман студентларымыз

Ничә еллардан бирле тәрәкъкый пәрвәрлек иддигаэсендә булган кешеләремез: «Яшьләремездә укырга рәгъбәт юк, хөкүмәт мәктәпләренә, гимназия вә университетларга кереп укымыйлар. Яшьләремез мода әсирлегеннән башка нәрсәне белмиләр», – дип, яшьләр өстенә гаеп йөкләп киләләр иде. Ул заманнарда бунларның сүзләрен турыга хисап итәргә дә ярый иде. Чөнки, вакыйган дә, укучыларымыз бер дә юк мәнзилендә аз, университетта да өч-дүрттән артык мөселман студенты юк иде. Инде хәзерге көндә яшьләргә ни димәк кирәк? Анлар тәрәкъкый пәрвәрләрнең сүзләрен игътибарга алып укырга керештеләр. Гимназияләрдә, тиҗарәт мәктәпләрендә укучыларымыз була башлады. Бунларның микъдары елдан-ел артып бара һәм барачак. Быел бер мәктәптә ун бала укыса, киләчәк елда егерме, утыз булачагында һич шөбһә юк, чөнки бер Казан шәһәрендә генә гимназиягә, реальный вә тиҗарәт мәктәпләренә керергә хәзерләнүчеләр бик күп булган шикелле, университетка керергә хәзерләнүче шәкертләремезнең дә күплеге күз алдыбыздадыр.
Хәмед улсын, быел әүвәлдәге дүрт-биш студент урынына университетта егерме кадәр мөселман студентлары бар. Бунлар заманның уку заманы идекен белеп, иҗтиһад итеп университетка кергәннәр.
Укыйлар, кеше булып чыгарга чын күңел илә тырышалар. Ләкин укыр өчен акча лязим. Хосусән университетта уку өчен хили акча кирәк. Шәкертнең үз-үзен тәрбия өчен күп мәшәкатьләр илә акча таба алуы өстенә, уку хакы уларак, университетка елына йөз сум кадәр акча түләргә кирәк.
Күз көнендә уку хакының беренче нисфын түли алмаганлыклары өчен җиде йөз кадәр студент университеттан чыгарылганнар иде. Ул вакыт анлар арасында мөселманнардан чыгарылучы күрелмәгән иде. Хәзер дә мартның унбишендә янәдән бу елның икенче нисфы өчен акча түли алмаган кешеләрдән берникадәресен чыгарачаклар. Бунларның гадәде никадәр идеке безгә мәгълүм дәгел исә дә, арада ике мөселман студенты барлыгы

ишетелде. Бунларның берсе уфалы Мөстәкыймев җәнабләредер ки, моның, пәдәре вафат булганлыктан, ярдәмгә җитешәчәк кешесе юктыр. Үзенең тамагын да балалар укытып, - шуннан килгән аз-маз акчалар илә генә туйдырып тора аладыр.
Икенчесе Габдерахман Мостафин1 җәнабләредер ки, бу егет, мәдрәсәдә тәхсил кыйлганнан соң, үз иҗтиһады илә укып, гимназиядә имтихан биреп, быел гына университетка кергән иде. Габдерахман әфәнденең атасы сәламәт исә дә, улының уку хакларын түләрлек дәрәҗәдә байлыгы юктыр. Габдерахман әфәнденең атасы бер мәдрәсәдә шәкертләр укытып торучы бер мөдәрристер. Угълын укыта алу түгел, угълының укыганлыгына разый булып торган өчен мөтәгассыйблар тарафыннан хили шелтә вә сүгешләр ишетте. Ихтимал, шуның өчен, бәлки, үзенең мадди җәһәтләреннән күп зарарлар да күрде.
Иштә бу әфәнделәр укыйлар һәм укырга да телиләр. Ләкин һичбер тарафтан ярдәм күрә алмыйлар. Тәрәккъый пәрвәрләремез укырга димлиләр, әмма акча белән ярдәм итәргә нәүбәт килеп җиткәч, һичберсенең тавышы чыкмый...
Айлар, еллар узып торачак, балалар, шәкерт, гимназия шәкертләре студент булачак. Вә ел саен ничә кеше, уку акчасын түли алмыйча, университеттан чыгып торачак. Әхмәт бай2 мөтәвәллиләренең буңа һичбер эчләре пошмаячактыр. Эш шулай барып торса, бер яктан, мөтәвәллиләр үзләренең ялкаулыкларыннан әһле хәйратның калдырып киткән стипендияләрен кирәк урыннарына бирмәсәләр, икенче тарафтан, тәрәккъый пәрвәр исемендә йөргән кешеләремез дә акчага нәүбәт килгән чакта эчләреннән тынып калсалар, безгә нинди истикъбаль көтәргә дә, киләчәктә зыялыларымызның күбәюен вә шул саядә милләтемезнең тәрәккъыен ничек итеп өмид итәргә кирәк?
Биш көннән мартның унбишедер. Кая, кем дә булса бармы шул мөддәт эчендә үзенең егетлеген күрсәтеп кала алучы?
Күрше тавыгы күркә булып күренә!

Бу сүз бабайлар заманыннан бирле сөйләнеп килә. Мин моның мәгънәсен бу ел гына бик яхшы аңладым.
Дүрт йөз сиксән алтынчы «Йолдыз»да Г.Кәрам җәнабләре, «Шәрекъ клубы»нда лекция укырга кеше табып булмаудан зарланганнан соң: «Казан мөгаллимнәре, Казан яшьләре! Кая сезнең гайрәтеңез? Һич булмаса, сезгә Оренбург голямасыннан гыйбрәт алу кирәк иде. Оренбургның Хәйрулла хәзрәтләр вә Ризаэтдин казыйлар1 кеби иң атаклы голямасы вә мөнәүвирәл-әфкяр бәгъзе яшьләре йөзләрчә халык хозурында файдалы дәресләр укып, меңнәрчә рәхмәтләр алдылар. Иштә сезгә бер нәмунәи имтисал!..» – дип язган иде.
Ул вакытта мин Оренбургта идем. Мәзкүр гәзитәне укыгач, Г.Кәрам әфәнденең күзенә Оренбург тавыкларының күркә булып күренүләреннән көлеп җибәрдем. Чөнки казый Ризаэтдин әфәнденең лекция укыганы юк. Хәйрулла Госманов намендә берсе укыса да, аның атаклы голямадан икәненә дәляләт кыйлырлык әсәрләрене бу көнгә кадәр күрә алганым юк. Бәгъзе бер әсәрләре илә шөһрәт казанган Хәйрулла хәзрәт Госманов нам Каргалыда бер имам бар. Г.Кәрам әфәнде, бәлки, шуны ирадә кыйлгандыр, ләкин аның лекция укыганы юк. Лекция укучы Хәйрулла хәлфә Госмановтыр. Бу кешенең шөһрәте зур булмаса да, бәлки, гыйлеме зурдыр? Ләкин ул кадәресе безгә мәгълүм түгел. Чөнки укыган бер-ике лекциясеннән генә кешенең дәрәҗәсене бик яхшы аңлап бетеп булмый.
Оренбург җәмгыяте исламиясе2 йортында һәфтә саен бер кеше тарафыннан сөйләнә торган сүзләрне лекциягә хисап итеплә торган булса, Г.Кәрам әфәнденең дә лекциядән мәкъсудлары шундый уку кичәләре исә, бундый лекцияләрне укырга кеше табу урынына, укырга теләүчеләргә көн вә урын табуы читенрәк булыр. Оренбургтагы кеби укырга теләгән кешеләргә акчасыз фатир табып бирүче булса, кереп тыңлаучылардан акча алмаса, ул вакыт укучылар күп табылыр.
Зан идәрсәм, бәйрәм көннәрендә, эш юк вакытларда вәгазь сөйләргә, яхуд тарихтанмы вә башка берәр китаптанмы бер-ике сәхифәне укып чыгарга һичбер хәлфә вә һичбер хәзрәт авырсынмас. Керү өчен акча алынмагач, эшсез көнне «бесплатный» вәгазьне тыңлап

чыгарга һичкем иренмәс һәм, сөйләнгән сүзләр өчен халыктан һичбер бәдәл алынмагач, «лекция»не интикад кыйлучы да булмас.
Оренбургта укылмакта улан «лекция»ләр ушбу хасиятләрнең һәркаюсыны җәмегъдер. Укыган өчен укучыдан акча алынмый һәм үзенә дә бирелми. Кергән өчен халыктан да акча соралмый. Буш булгач, бәйрәм көннәрдә эш тә булмагач, халык та күп килә, алдан күп хәзерләнәсе булмагач, хәзрәт тә гадәттә сөйли торган дәресләрене халык алдында янәдән бер мәртәбә тәкрар итеп чыгарга читенсенми, бәлки, билгакес, халыктан бесплатный рәхмәтләрне ишетеп мәмнүн була, гәзитәләре дә мактап күңелене күтәрәләр. Оренбург гәзитәләре, безнең кеби күрше тавыгыны күркә итеп күрүдән бигрәк, үз тавыкларыны күркә итеп күрсәтүне яратарак бирәләр.
Инде килик «Шәрекъ клубы» лекцияләренә.
Бунда да шундый лекцияләр укыла һәм укучылардан шундый лекцияләр генә таләп ителәме?
Мин узган пәнҗешәнбе көн Гайнетдин әфәнде Әхмәров тарафыннан укылган «Сөембикә тарихы»ны тыңларга бардым вә Оренбург «лекция»ләре илә бундагы лекцияләр арасындагы аерманы бер-берсенә кыяс кыйлып карадым. Оренбургтагы татар тарихы лекциясене сөйләү өчен Хәсәнгата казыйның3 мәшәкатьләр чигеп, ничә еллар хәзерләп, язып, бастырып чыгарган тарихыннан бер-ике сәхифәсен ятлап чыгу бик кяфи иде. Әмма Гайнетдин әфәнденең Сөембикә хакында сөйләгән лекциясене тәртип итү өчен бик күп китаплар актарырга, бик күп әсәрләрне карарга, анларны бер арага җыеп, чүпләрене арчып, сафландырып, нәтиҗәләрене чыгарганга кадәр бик күп мәшәкатьләр күрергә лязим идеке күрелде.
Гайнетдин әфәнде бу мәшәкатьләрне, әлбәттә, күргән һәм башыннан кичергән.
Ул үзенең ушбу кичәдә халыкка сөйләгән тарихыны вөҗүдкә китерү өчен «асаре гатика җәмгыяте»нә4 әгъза булып, ничә еллар асаре гатика тәфтишләре илә мәшгуль булган, никадәр иске китаплар актарган, никадәр рус тарихлары укып чыккан һәм шуның соңында гына ушбу лекциясене сөйләргә ярарлык дәрәҗәгә китереп чыгарган. Буңа кадәр сөйләнгән лекцияләрнең дә һәркайсында хәл шул рәвешчәдер.
Су хакында, һава хакында һәм мәгъдәннәр хакында сөйләнгән лекцияләрнең һәркаюсы һәфтәләр илә хәзерләнүгә һәм хили мәсарифларга мохтаҗ булынган лекцияләрдер. Шуның өчен бундый мәсарифлы лекцияләрне укырга теләүчеләрне бик тиз табып булмыйдыр. «Шәрекъ клубы»нда бер фәннән лекция уку өчен шул фәннең мөтәхассыйсларыннан булу лязимдыр.
Юкса тыңлаучылар алдында мәсхәрәгә калу ихтималдыр. Чөнки Оренбургның «мәшһүр лекция»ләре илә Казан лекцияләре арасында аерма булган шикелле, тыңлаучылары арасындагы аерма да хили зурдыр.
Оренбургта тыңлау акчасыз булдыкыннан, эше юк кеше һәммәсе керә. Укыганрак кешеләр һәм шәкертләр бик аз була. Тыңлаучыларның әксәре йә һич язу танымаган яисә аз гына сәвадлы кешеләрдән гыйбарәт була. Сөйләнгән лекцияләр дә, югарыда әйтелгәнчә, аңлау өчен тыңлаучының мәгълүматлырак кеше булуларыны таләп кыйлмый. «Шәрекъ клубы» лекцияләрене аңлау өчен, тыңлау өчен бераз мәгълүмат өстенә акча да таләп кыйлына.
Әнә анда, «Шәрекъ клубы»нда, сез әйткәнчә, Оренбург кешесе шикелле, язу танымый торган бер кеше бар, ягъни бер татар бутышнигы, җәмгыятьтәге тәртипне саклар өчен килгән, лекция татарча сөйләнгәнлектән, башта бераз тыңлап торса да, һичбер нәрсә аңлый алмаенча, ахырдан йокыга киткән.
Аннан башка кешеләрнең һәммәсенең күзләре лекция укучыга текәлгән. Колакларының бөтен куәтләре, сөйләнгән сүзләрнең һичберсене ишетми калмасын өчен, сөйләүче тарафына сарф ителгән. Бунлар тыңлыйлар, сөйләүченең һәрбер җөмләләренә дикъкать итәләр һәм сөйләгән сүзләрне үзләренең әүвәлдәге аз-чук мәгълүматлары илә чагыштырып мөхакәмә кыйла баралар.

Бунларның вакытларыны әрәм итәселәре килми. Чөнки килүчеләрнең әксәре бу көнгә кадәре укыган, яхуд хәзер дә укымакта улан кешеләрдер ки, анлар, «Шәрекъ клубы»на акча түләп, үзләренең мәгълүматларыны тәүсигъ итәргә килгәннәр. Әгәр дә бунларга үзләренең түләгән акчалары мокабиленә торырлык яхшы яңа мәгълүматлар бирелмәсә, хәзер низагъ чыгарачаклар һәм һич мәрхәмәтсез: «Шәрекъ клубы» үзенең юк-бар нәрсәләре илә безнең кесәләремезне бушатырга тели»,– дип, интикадка керешәчәкләр. Менә инде шул шартларны күз алдына китер дә, аннан ары Оренбург тавыклары күркәме-түгелме идекене фараз ит.

Яңа әсәрләр

[«Яшьләр», «Кыямәт»]

Көннән-көн артып бармакта улан яңа әдәбият китаплары арасында ушбу көннәрдә «Яшьләр» исемле китап дөньяга килде.

«Яшьләр» Фатих әфәнде Әмирхан тарафыннан язылмыштыр. «Яшьләр» – өч пәрдәлек бер театр мәҗмугасыдыр. Бунда тормышыбызның алмашыну көннәрендә яшьләрдә булган тәбәдделат күз алдына китереп күрсәтеләдер. Хикәянең каһарманы уларак бер байның ике улы илә бер кызы тасвир ителмештер. Байның угыллары әүвәлдәрәк адрес яза белерлек дәрәҗәдә русча белү өчен укырга бирелгәннәр. Заманның икътизасы буенча бунлар уйганып, русчаны ныклап укуның кирәклегене аңлап, ибтидаи тәгълим илә генә калмаенча, гимназия вә университетларга кереп уку һәвәсенә төшкәннәр һәм шуңар тырышалар. Һәмширәләрене дә үз араларына алып, үзләренә иш ясаганнар, аны да укыталар. Башта балаларының аз гына укуларына разый булган ата балаларының еракларга кадәр китәргә ниятләре барлыгыны күреп курка башлый, базар халкының котыртуларына ияреп, балаларны укудан мәнгъ кыйла. Укытучы мөгаллимәләренә акча түләүдән туктый. Яшьләр аның ул эшене игътибарга алмыйлар, укыр өчен үзләреннән акча табарга тырышалар. Акчаны тыю илә генә балаларыны укытудан тыю мөмкин булмаслыкны күргәч, аталарына карышырга ярамаганлыкны, аның җәзасы бик зур идекене күрсәтү һәм калган ике баласыны «гыйбрәтләндерү» өчен бай олугъ улыны йортыннан куып чыгара.

Хикәя шуның илә тәмам була.

Хикәянең тасвиры хили гүзәл һәм анда тасвир ителгән яшьләрнең типлары бүген дә Казанда мәүҗүд типлардыр. Хәтта һәрбер язылган әсәрләрне «бу фәлән кеше хакында язылган икән» дип тәэвил кыйлырга яраткан кешеләргә «бу да фәлән бай балалары хакында язылган икән» дип әйтерлек дәрәҗәдә якын тормыштан алынган типлардыр.

«Яшьләр» «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан нәшер ителеп, Казанда «Үрнәк» мәтбагасында басылмыштыр. Бәһасе – егерме биш тиен.

< ... >

Миссионерлар фикере

Гәзитәмезнең узган номерында ушбу сәрләүхә илә Казанда миссионерлар тарафыннан нәшер ителмәктә улан бер журналның Садри әфәнде Максудов нотыгыннан зарланып язган мәкаләсен дәрҗ иткән идек. Бу журнал Казанда узган ел көз көненнән башлап нәшер ителә башлаган булса да, бу көнгә кадәр һичбер илтифат кыйлынган юк иде. Ниһаять, ушбу көннәрдә үзенең мөселманнарга нинди күз илә караганлыгы бик мәгълүм булган «Казанский телеграф» гәзитәсе бундый «яхшы» журналның халык арасында таралмавыннан шикаять кыйлганнан соң, бу журналны алып карадым. Вакыйган, мөселманнар арасындагы салам кадәр эшне бүрәнә итеп күрсәтә торган бер журнал булганлыктан, «Казанский телеграф» язганча, «макталырга» тиешле нәрсә икән. Журнал баштанаяк мөселманнар галәйһенә нәшер ителә торган бер нәрсә икән. Журналның максаты хөкүмәт гыйндендә мөселманнарны дошман күрсәтеп, күздән төшертеп, мөселманнарның һәртөрле тәрәккыйләренә сәд чигү булса кирәк. Чөнки һәр нөсхәнең

һәр сәхифәсендә мөселманнар арасындагы чебен канатының селкенүе кадәрле җөзьи иҗтиһадлар – зилзилә кадәр зур, чүп кадәр генә бер төрки әсәре Каф тагы кадәр биек итеп күрсәтеләдер. Бу журнал сәхифәләре, мөселманнарның һәрбер җөзьи иҗтиһадларында да иттихаде ислам фикере күреп, аны үзләренең хыялларында зур итеп, бөтен русларны вә хөкүмәтне мөселманнар илә куркытырга телиләр булырга кирәк. Чөнки һәрбер язган сүзләреннән шул аңлана. Мөселманнар тарафыннан кечкенә генә бер мәктәп ачылу – иттихаде исламнан, төркичә җөзьи генә бер китап нәшер ителсә – иттихаде исламнан, хасыйле генә, бер җирдә бер гәзитә, яхуд журнал нәшер ителсә, бер китап язылса, бер җәмгыять ясалса, бер мәкруһ исламияткә кайтса – һәммәсе дә иттихаде исламнан. Бунлар мөселманнардагы һәрбер тәрәккъкыятьне, һәрбер уйгануны вә мәдәнияткә таба үрләүләрне иттихаде исламга хисап кыйлалар. Бунларча, мөселманнарның аз гына күзләре ачылуы, мөселманнарның аз гына язу танулары, аз гына фән вә мәдәнияттән хәбәрдар булулары – һәммәсе бик зур зарардыр.

Бу эшләрнең бер-бер кешегә зарар итдекендә без бер дә шик кыйлмыймыз, ләкин кемгә зарарлы? Бәгъзе миссионерлар мөселманнарның тәрәккъкыйләрен хөкүмәт өчен зур зарар итеп күрсәтергә тырышалар. Гүя, анлар фикеренчә, мөселманнар укыйлар, имеш, вә тәрәккъкый итәләр, имеш тә, берләшеп, хөкүмәткә әллә нинди зарарлар китерәләр, имеш. Вакыйгъдә эш һич анлар фикер кыйлганча түгел, бәлки, гаксенчә. Мөселманнарның аңлы булуларыннан, мөселманнарның агаруларыннан вә анларның мәдәниятеннән хөкүмәткә файда гына хасыйль булачактыр.

Мөселманнарның мәдәниятләре артуы саясендә Русиянең сәүдә, тиҗарәт, һөнәр вә санагатьләре дә артачактыр. Һичбер нәрсә аңламаган мужик солдатлар урынына Русияне дошманнан химая итү өчен аңлы гаскәриләр җитешәчәктер. Мөселманнарның укуларыннан, адәм сурәтенә керүләреннән зарар булса, бәлки, миссионерларга булыр. Чөнки анлар өчен мөселманнарның дин вә дөньядан хәбәрсезлекләре эш йөртергә уңайлырактыр. Мөселманнар укысалар, теләгәнчә эш йөртү мөмкин булмаячак, миссионерларның әһәмияте бетәчәктер.

Миссионерлар барыннан да бигрәк татар теленең тәрәккъкый ителүеннән, вә аның Русия мөселманнары арасында гомумиләшеп китүеннән, вә шул саядә Русия мөселманнарының татарлашуларыннан куркалар. Мәктәпләрдә төрле фәннәрнең укытылулары вә ул фәннәрне бәян кыйла торган китапларның татар телендә булулары бунларны бигрәк куркытадыр. Бунлар шунда ниндидер бик зур хәвеф күрәләр. Хәлбуки анда һич хәвеф ителәчәк урын юктыр. Бу мәсләк миссионерларның моктәда биһләре булган Ильминский мәсләгенең мисалыдыр.

Ильминский, христиан динен, дога вә гыйбадәтләрне һәрбер инородецка үз телендә өйрәтү яхшы, шулай булганда, анлар бик тиз төшенәләр вә дингә дә мәхәббәт багълыйлар, ди торган иде.

Мөселманнар да, татарлар өчен дәрес китаплары татарча язылса, мәктәпләрдә дәресләр үз телләрендә укытылса, балалар вә шәкертләр тиз төшенәчәкләр, фәнгә мәхәббәт багълаячаклар икән, дигәннәр дә, китапларны үз телләрендә яза башлаганнар. Кирәкле дәрес китапларын башка телләрдән күчерергә тотынганнар. Һәм хәзергә яхшы дәрес вә әдәбият китаплары бик фәкыйрь хәлдә исә дә, файдасын күрә башлаганнар.

Хуш, миссионер әфәнделәр, мөселманнарның бу эшләреннән, сезгә димим, хөкүмәткә нинди зарар? Сез, бәлки, мөселманнар үз телләрендә укыйлар да хөкүмәт теле булган рус лисаныннан качалар, мөселманнар арасында рус лисаны тәрәккъкый кыйла алмый дип белә торгансыздыр? Зинһар, хафаланмаңыз, ул да, сезнең фаразыңызның хилафына уларак, вөҗүдкә киләчәктер.

Әүвәлдә, татарча тәхсыйльләр юк вакытларда, русча укулар да юк иде. Хөкүмәт халыкка сүз аңлатудан гаҗиз иде. Соңыннан мөселманнар арасында укулар башлангач, үз телләрендә укып, фән кирәклекне аңлагач, һичкем тәклиф итмичә, мөселманнар үз-үзләреннән русча укырга башладылар.

Башта Казандагы Учительская школада1 хәзинә хисабыннан укый торган утыз шәкерттән башка кеше булмый иде. Хәзердә шәкертләре йөздән артып китте. Ел саен никадәр кеше керергә теләсәләр дә, урын юклыктан керә алмый калалар. Учительский институт2 вә городское училищеларга керәләр. Начальное училищеларның һәркаюсында балалар тулып ята.
Казанның шәһәр Думасы бу ел мөселманнарга ничә ибтидаи мәктәпләр ачарга карар бирде. Зан идәмен, анларның да һичберсе буш тормаячак, бәлки урыннар җитешмәячәктер. Гимназия, реальный вә тиҗарәт мәктәпләренә кереп укулар да көннән-көн артып бара. Һичбер җирдә Русия мәдәниятеннән вә рус лисаныннан читкә таю мөселманнарда күренмидер.
Бәгъзе миссионерлар өчен хәлнең бу рәвешчә баруы, әлбәттә, күңелле түгелдер. Анлар өчен мөселманнарның укымаулары, ачылмаулары әһәмиятледер.
Һәрбер язган сүзләреннән шул аңлана. Мәсәлән: «Рәсми бер җәгърафия басылган. Андый фән китапларының мөселманнар арасына таралуы бик зарарлы булыр иде, шөкер әле, мөселманнар арасында ысул кадимчеләр бар. Анлар тараттырмыйлар, татарлар мәктәп илә дөнья тутырырлар иде, шөкер әле, араларында укуга каршы торучы картлар бар», – дигән мәфһүмдәге сүзләр бунларның мәкаләләрендә күп очрый. Гомумән, хәзерге миссионерлар ысул кадимчеләргә үзләренә дуст кешеләр шикеллерәк итеп карыйлар. Ләкин анларның да тиздән бетәчәкләрен уйлап, тәәссеф кыйлалар. Миссионерларның укыган мөселманнарга, мөселманнарның тәрәккъкыйләренә тырышкан кешеләргә үпкәләре бик зур.
Әгәр дә мөселманнар арасында бер дә шундый кешеләр булмаса, мәктәпләрдә дәресләр ана теләндә булмаса, мәктәп назыйрләре һәммәсе дә миссионерлардан булса (мәзкүр журналда бу хакта проектлар барлыгы да күрелде), балалар христиан рухында тәрбия ителсәләр... әлхасыйль, Русиядә христианлыктан башка дин калмаса, анлар бик мәмнүн булачаклар. Әмма мөселманнар арасында тик тормаучыларның барлыгы эшне харап итә. Менә миссионерларның фикере шуннан гыйбарәт. Мәзкүр журналның төймәне тәвә итеп күрсәтеп язган мәкаләләреннән бәгъзеләрен гәзитәмездә тәрҗемә кыйлып күрсәтүне икенче бер вакытка калдырып, хәзергә сүземне тәмам итәм. (Чүлмәк ташка бәрелсә дә, таш чүлмәккә бәрелсә дә, вай чүлмәкнең хәленә!)

«Мөгаллим»

Җомга көн кич Панаев бакчасының1 ябык театрында «Сәйяр труппа» артистлары тарафыннан Гаяз Исхакыйның «Мөгаллим» нам биш пәрдәлек пьесасы тамашага куелды. Тамашага баручылар хили күп иде. Уенның өч пәрдәсе бик яхшы, икенче пәрдәнең ахыры илә бишенче пәрдәләр рухсыз чыкты. Болай чыгуда артистлардан килгән гаеп булмыйча, мөхәррирнең үзеннән килгән кимчелектер. Икенче пәрдәнең язылуы асылда рухлы түгел. Бишенче пәрдәсе бөтенләй мәгыйшәттән ерак булганлыктан табигый түгел.
Гаяз әфәнде бу пәрдәсендә мөгаллимнең рухында бер яңару вә уйгану вөҗүдкә килүне күрсәтмәкче була һәм күрсәтә, ләкин бик җәгъли булып чыга. Мәнзарәне тизрәк бетерү кирәк булганлыктан, бер фикердән икенчегә интикальләрне бик тиз йөртеп, эшне боза. Аңа кадәр булган дүрт пәрдәдә мөхәррир әфәнде үзенең икътидарын күрсәтә. «Мөгаллим» сала кызы, сала кешесе, сала карчыгы һәм сала егетләренең әхваль руханияләрен һичбер таснигъсыз, табигый рәвешләрендә бик җиңел һәм матур итеп тасвир итә. Бу пәрдәләр табигый булдыкларыннан, уйнаучыларга җиңел булган шикелле, тыңлаучылар өчен дә бик күңелле. Актык пәрдәдә җәгъли бер халәт тасвир ителдекеннән вә ул да кирәгенчә эшләнмәдекеннән уйнаучыларга да бик ватылырга кирәк була, сүзләрнең ябышмаулары, кыланышларның урынсызлыкларын карап тору сәерчеләргә начар тәэсир калдыра. Әүвәлге пәрдәләрдән хасыйль булган нәшьә вә тәэсирләрне тәмам югалтадыр. Уенчылар, гомумән, үзләренә гаид вазифаларында кимчелек күрсәтмәделәр.
«Хисап мәсьәләләре»
(1, 2 нчеләре)

Бу көннәрдә мәгъруф мөгаллимнәремездән Мөхетдин Корбангалиев тарафыннан тәртип ителмеш «Хисап мәсьәләләре» намендә 1 нче вә 2 нче китап, Казанда «Үрнәк» мәтбагасында нәфис рәвештә басылып, «Мәгариф» тарафыннан нәшер ителде. Мөхетдин әфәнденең бу әсәрләре, педагогиядән зур мәгълүматы барлыгыны һәм ысулы тәгълим кагыйдәләрене тиешле урыннарында иҗра кыйла белгәнене ачык күрсәтеп, өстләрендә язылган исемнәре берлән генә булмаенча, бәлки мәфһүмнәре берлән дә ибтидаи гавам мәктәпләре өчен тәгаен кыйлынмышлардыр. Боларның эчләрендәге морады тәхсилиясе педагогиянең нәзарыйдан зиһенигә, якыннан еракка, мәгълүмдән мәҗһүлгә, хастан гамгә вә башка мөһим кагыйдәләренә һәм матлубларына тәмам муафикъ рәвештә тәртип ителмештер. Бердән унга кадәр һәм уннан бергә кадәр кире нәзарән һәм, зиһеннән санарга өйрәтелеп, шул гадидләрне балалар аңлаганнан соң, гамәлләрне дә аңлап, мәгыйшәтләрендә иҗра кыйла һәм файдалана белсеннәр өчен мәсьәләләр чыгартырга керешелгән. Мәсьәләләрнең шартлары тәгъриф кыйлырга зарур булырдай һәм сабый балалар аңламастай ят шәйләрдән алынмаенча, бәлки балаларның мәктәпкә кергәнчә күргән вә белгән һәм мәктәп эчендә һәр көнне күреп торган нәрсәләреннән алынганнар. Мәсьәләләр исә тәдриҗне тәмам ригая кыйлып, берсене мөгаллим үзе чыгартса, икенчесене бала үз иҗтиһады берлән дә чыгарырга кадәр булырлык итеп тәртип ителмешләр. Бу исә баланы зәвекъләндерә, рәгъбәтләндерә, иҗтиһадыны арттыра һәм киләчәктә үз-үзеннән эш башларга батырчылыклы кеше итеп чыгарырга зур васита буладыр. Әлхасыйль, бу китапларның мәфһүмнәрендә педагогия җәһәтеннән, безнең белүемезчә, һичбер ноксанаты юктыр, бәлки басылганда мәтбага тарафыннан булган бераз хаталар гына бардыр; болар да китапларның ахырында дөрестләп бастырылмышлар. Шуның өчен без бу китапларның милли мәктәпләремезнең һәрберсендә булып, укытылуларыны үз тарафымыздан тәүсыя итәмез.

1911

## Мәктәп вә мәдрәсәләремез

Һәр көн диярлек карьяләрдә мәктәп вә мәдрәсә вә укытулар юклыктан зарланып язган мәктүбләр идарәгә килеп торалар. Бундый мәктүбләр бер-бер артлы килеп торганлыктан һәм анларның саннары бик күп булганлыктан, гәзитәгә дәрҗ ителми калалар. Анларны гәзитәгә язудан да файда күреп булмый. Чөнки гәзитәдә мәктәп юклыктан зарланып язу илә генә ул карьяләрдә мәктәпләр вөҗүдкә килми. Бундый мәктүбләр күбесенчә гавам халкы тарафыннан язылган мәктүбләр буладыр. Имамнар тарафыннан язылган мәктүбләр идарәдә күп күренми. Чөнки, әгәр дә имам әфәнделәр укытуны идарә кыйлсалар, карья халыклары мәктәп салырга вә балаларын укыттырырга каршы тормыйлар. Әллә нигә бер укытуга каршы торган авыллар булса да, анлар да күрше-тирәдәге бер ишан яки мулланың котырыгы илә буладыр.

Ишан яки мулла балаларны укытырга теләгән имамның дошманы буладыр да, имамның эше алга китеп, мәхәллә халкының күз алдында игътибары артмасын өчен, гавамны котырталар. Ләкин бундый вакыйгаләр бик сирәк булалар. Әксәрдә имамнар үзләре укытырга иренгәнлекләреннән, авылда мәктәпләр вөҗүдкә килми тора. Бу көннәрдә Мамадыш өязендәге мәсҗедләре тузган вә мәктәпләре бөтенләй булмаган бер карьядән Хәсән Мостафин исемендә берсе мәзкүр өяздә Яңа Чүриле волостенда Иске Му һәм Казаклар исемле карьяләрдә1 мәктәп вә укытучы юклыктан, балаларның урамда көн буе уйнап көн уздыруларыннан зарланып яза.

Бу кешенең язган сүзләренең дөрестлеген тасдикъ кыйлу өстенә мин бу хакта янә берничә сүз гыйлавә кыйлмакчы булам. Минем ата вә бабаларым мәзкүр волостьтагы бер карьянең кешеләредер. Мин атам илә бергә мәзкүр тарафларда мөсафир булганым бар. Хәсән әфәнде мәктүбендә фәкать Иске Му карьясеннән вә аннан ике чакрым җирдәге Казаклар карьясеннән генә бәхәс итә. Бу әфәнде Казаклардан фәкать ярты чакрым җирдә генә булган Сикертән карьясеннән вә шул тарафлардагы Гөберчәк, Чөмә-Елга, Өчиле, Симетбаш, Курса Почмак2 вә анларга күрше булган карьялардән ник бәхәс ителми икән? Мәзкүр волостьта унбиш кадәр мөселман авылы бар, бу авылларның һичберсендә мәктәп юк. Кешеләре балаларын Казан өязендәге3 Казанбаш, Курса һәм Казиле карьяләрендәге мәктәпләргә җибәреп укыталар. Мәзкүр өч авылдан башка, бу тарафларда һичбер авылда тәртипле мәктәпләр юк. Бундан егерме биш ел мөкаддәмдә Иске Масрада, мәрхүм Исмәгыйль хәзрәт бар заманда, гәрчә иске ысул илә булса да, мәктәп тә бар иде, һәм ул бик иҗтиһад илә укытадыр иде. Ләкин ул тизлек тә вафат булды. Аның заманында укыган балалар язу танып калдылар. Әмма аннан соң килгән имам янә «иске хәммам, иске таш» улдыкыннан, укудан мәхрүм калдылар. Карьянең хәзерге имамы укытамы-юкмы, аннан хәбәремез юк. Югарыда мәзкүр Сикертән карьясе – мең җанлы бер карьядер. Бундан берничә ел мөкаддәмдә мәзкүр карьянең аңлы мужиклары, имамнарының укыту илә эше юклыкка эчләре пошып, яңа бер имам алырга һәм, мәктәп салып, яңа имамнан яңа ысул илә балаларны укыттырырга теләгәннәр иде, ләкин ул вакытта, иске имам тарафдары булган куштаннарның эшкә катышулары аркасында, мәкъсудлары вөҗүдкә чыкмый калды. Хәзерге көндә укыту тарафында булганнар яңа мәсҗед салырга вә мәктәп бинасына рөхсәт алдылар. Әгәр дә мәсҗед бина итәрлек кеше таба алсалар, бәлки, тиздән мәкъсудларына ирешерләр. Бу югарыда язылганнар фәкать бер волостьтагы карьяләрнең хәледер. Буннан башка мәзкүр өяздә ничә вә ничә волостьлар бардыр ки, һәркаюсының хәлләре шуннан гыйбарәттер. Бу тарафлардагы карьялардән гавамны укымаулары илә һич гаепләп булмый. Бунда бар гаеп имамнарның үзләрендәдер. Анлар үзләре укытуга каршы торалар. Имамнарның да үзләренең генә ихтыярынча түгел. Бунларга да тәэсир итүчеләр бар. Мәзкүр тарафларда берничә ишаннар бардыр ки, үзләренең уку вә укыту эшләренә дошманнары һәм ялган донослары илә бөтен Русиягә мәгълүмнәрдер.

Сабан туе

Сабан туе Казанда җәй көне һавалар бик яхшы, гүзәл көннәрдә кырда бер һәфтә буе күңел ача торган бер җир булганлыктан, әүвәлге заманнарда буңа бик күп кешеләр барып ирек ачып кайталар иде. Соңга таба сабан туеның идарәсе, төрле кулларга керү сәбәпле, начарланып игътибардан төшкән иде. Игътибарлырак кешеләр бунда барудан тартына башлаганга, сәрмаясы да елдан-ел азая барып, хәле тәмам начарланганлыктан, җаны чыгарга якынлашкан иде. Ахыр инде, бөтенләй бетәр дип торганда гына, узган ел игътибарлы вә инабәтле адәмнәрдән берничә кеше буны ихъя кыйлырга керештеләр. Борын заманнардан бирле гадәт булып килгән бу тамаша урынының җанлануына күп кешеләр, яхшы күз илә карап, кулларыннан килгән ярдәмнәрне кыйлудан кире чигенмәделәр. Шул сәбәптән сабан туеның сәрмаясы да узган ел яхшук артты. Акчасы күп булганлык сәбәпле, күңел ачарлык тамашалар да күбәйде. Аның өстенә мәсарифыннан артып калган акчалардан Казан «Җәмгыяте хәйрия»сенә дә йөз сиксән сум кадәр өлеш чыкты. Бу микъдар, «Җәмгыяте хәйрия» өчен зур бер сума булмаса да, һич юкка караганда ярарлык акчадыр. Узган ел сабан туен җанлы итеп ясаган кешеләр бу ел да бу гүзәл эшне әүвәлдәгедән дәхи дә берничә кат яхшырак һәм җанлырак итеп вөҗүдкә чыгарырга тырышып йөриләр. Бу ел көрәш мәйданы зур һәм киң итеп цирклар формасында эшләнәчәктер. Мәйданлыкның эчендә тамашачылар өчен төрле дәрәҗәдә урыннар ясалган шикелле, вәли хәзрәтләре вә башка фәхри миһманнар өчен дә махсус ложалар ясалачактыр. Көрәш мәйданы брезент илә өртеләчәк, бинаэн галәйһи көрәшчеләрнең киемнәренең буялу хәвефе булмаячактыр. Шул сәбәптән быел көрәш мәйданына киләчәк пәһлеваннардан яхшы һәм тәмизрәк киемнәр киенеп килүләре үтенеләдер. Көрәш өчен

мәхсус начар киемнәр киеп килгән пәһлеваннар мәйданга кертелмәячәктер. Көрәшләрнең тәртипле булуы өчен лязим булган кагыйдәләр сабан туе рәисләре тарафыннан хәзерләнмәктәдер. Мәйданлыкта һәм ат килгәндә вә мөкяфәтләр бирелгәндә, һәр көн военный музыка оркестры уйнап торачактыр. Гадәттә була торган көрәшләр, ат узыштыру, кешеләр чабышлары өстенә быел француз көрәшләре, таяк тартышу, озын баганага үрмәләү, капчык кигән хәлдә йөгерешүләр, велосипед һәм каек узышлары, ике яшәрлек тайларның узышлары вә гайре шуңа охшаш мөсабәкаләр булачактыр. Узышуга иштиракь итәчәк атлардан башка еллардагы шикелле акча алынмаячактыр. Бу ел мөсабәкагә катышачак атларның гадәттән тыш күп булуы ихтимал тотыладыр. Чөнки бу көнгә кадәр үк берничә ат язылган. Бу ел көрәшү өчен читтән дә берникадәр мәшһүр пәһлеваннарның киләчәкләреннән хәбәр бирәләр. Көрәшәчәк пәһлеваннарның киемнәре тәмиз булуы лязим булган шикелле, ат өстендә чабачак балаларның да киемнәренең матуррак булулары һәм мөмкин кадәр төрле ачык төсләрдә булулары тиештер.
Сабан туе 20 нче майда җомга көн башланып, бер һәфтә дәвам итәчәктер.
Бу ел да, узган елдагы кеби, сабан туеннан артып калган акчалар «Җәмгыяте хәйрия» файдасына биреләчәк, сабан туеның хисабы низамга муафикъ рәвештә йөртеләчәк, иганә кыйлган кешеләрнең кулларына мәтбугъ һәм нумерлы сәнәдләр биреләчәктер. Мәсарифлары да җәмгыятьнең пичәте илә шнурланган дәфтәрләргә язылып барачактыр. Шул сәбәптән иганә кыйлучыларның акчалары һичбер урынсыз урыннарга китмәячәктер. «Җәмгыяте хәйрия»мез бу көндә иганәгә бик мохтаҗдыр. Аның яңа бина кыйлган вилядәтханәсен ачу һәм гыймарәт вакытында алган бурычларын түләр өчен хили акчалар лязимдер. Җәмгыять файдасы өчен ясалачак бу тамашага җумартларымыз күбрәк иганә кыйлуда косур кыйлмаслар дип уйлыймыз.
Мәтбага исляхаты

Мәтбагаларда тормаган, яхуд андагы эшләрдән хәбәрдар булмаган кешеләр гарәп хоруфатының мәтбага эшендә нинди кыенлыклар тудырганлыгын белми торганнардыр һәм белә дә алачак түгелләр. Яурупа хоруфаты илә кәлимәләрне җыю гарәп хоруфаты илә җыюга караганда бик күп асат. Әүвәлдә анларда да бу эшләр бик асат булмаган, ләкин соңыннан бара-бара ислях ителеп җиңелләшкән.
Эшне ачыктан-ачык күрсәтү өчен сезгә бер мисал күрсәтик: бундан ун ел мөкаддәм гарәп хоруфаты арасындагы хәрефләрдән [ , , , ] хәрефләренең кәлимә уртасында куела торганнары [ , , , ] рәвешендә булганлыгы, шаять, һәркемнең дә хәтерендәдер. Хәзерге көндә гәзитә вә китаплар баса торган уналты, унике, сигез, утыз алты, алтмыш дүртенче кегель исемендә йөртелә торган хәрефләр арасыннан бу хәрефләр чыгарылды. Анлар урынына хәзер [ , , , ] сурәтендәге хәреф-
ләр истигъмаль ителә. Бу хәрефләрнең уку һәм тану өчен әүвәлгедән һичбер аермалары юк. Шул сәбәптән күп кеше бу исляхны һичбер сизми калды һәм аз заман эчендә буны кабул иттеләр. Бу ислях заһирән бик кечкенә генә бер үзгәреш шикелле күренсә дә, мәтбагалар өчен бу бик зур җиңеллек ясады, ягъни әүвәлдә дүрт йөз тартмалы хәреф кассасы кирәк була торган урынга хәзерге көндә ике йөз тартмалы касса кифая кыйлырлык дәрәҗәгә килде. Бу мисал, шаять, аңлангандыр, инде хәзер сезгә мәтбага эшләрендә сөһүләт булсын өчен яңа ихтираг кыйлган ысулымыздан бәхәс итик. Сез сызыклы бер кәгазьне алыңыз да «гыйльме тәшрих» дигән сүзне язып караңыз. Бу сүздәге [ , , , , ] хәрефләренең сызыкның өстендә [ , , ] хәрефләренең сызыкның астында язылганлыкларын күрерсез. Хәреф уналты кегельле булса, сызыкның өстендә булган [ , , , , ] хәрефләренең ун кегель, түбәнгә төшкән [ , , ] хәрефләренең алты кегель урын алганлыгын күрерсез. Чын гына әйткәндә, бу хәрефләр алты кегельгә дә сыеп бетмичә, койрыклары асылынып кала. Мондый хәрефләргә мәтбага исляхында подрезкалы (астыннан киселеп кергән) хәрефләр диләр.
Бунларның койрыклары күп вакытта сынып-ватылып бетә. Шул сәбәптән хәрефләрне әледән-әле яңартып торырга кирәк була, һәм дә ике юлның арасына, хәрефләрнең

койрыклары бер-берсенә бәрелеп тормасын өчен, шпон дигән нәрсәләр кыстырырга туры килә. Әгәр дә хәрефләрнең шундый салынып тора торган койрыклары булмаса, бундый мәшәкатьләргә һичбер ихтыяҗ булмас иде, һәм мәтбагалар өчен бик зур сәһүләт булыр, һәм китап нәшер итүчеләр өчен бик зур икътисад та булыр иде.
Иштә шундый уңайсызлыкларны уйлый торгач, без хәзерге көндә буны җиңеләйтер өчен яңа бер юл таптык. Безнең ысулымыз илә хәрефләрне эшләгәндә, югарыда әйтелгән рәвешчә койрыклары асылынып тора торган хәрефләр булмаячак. Бу ысулда башлары, койрыклары сына торган хәрефләр калмаячак. Хәрефләрнең һичберсе, сызыкның түбән ягына төшмичә, бер хат өстендә бертигез булып барачак. Югарыда әйтелгән зарарлар бетү өстенә мәтбагачылар вә китап наширләре өчен икенче җәһәттән дә файдалы булачактыр. Чөнки хәрефләрне без күрсәткән ысулда эшләгәндә, уналтынчы кегель исемендә йөри торган хәреф эрелегендәге хәрефләр унике кегельгә сыячак. Хәрефләрнең сурәтләре дә хәзерге көндә истигъмаль ителә торган сурәтләреннән үзгәрмәячәктер. Бу ысул илә хәрефләрне эшләгән тәкъдирдә хәзерге көндә мең дүрт йөз сәтыр сыя торган гәзитәгә ике мең бер йөз сәтыр сүз сыйдыру мөмкин булачактыр. Башка кегельдәге хәрефләр дә шул рәвешчә эшләнгәндә, ун кегельле хәреф сигез кегельгә, егермеле – ундүрткә, егерме дүртле – уналтыга, утыз алтылы – егерме дүрткә вә илә ахириһи сыячактыр.
Хәрефханәләре булган мәтбага ияләренең бу эшкә игътибар итүләрен риҗа итәмез. Бу хакта лязим булган тәфсыйлатны бирергә һәм хәрефләрне тәрсим кыйлып күрсәтергә без һәрвакытта хәзермез.
Имля вә хоруф мәсьәләсе

Гарәп хоруфатын вә төрки имляны ислях итүнең лөзүме инкяр ителмәячәк бер хәкыйкатьтер. Гарәп хоруфатының шәкелләренең күплеге мәтбагалар өчен бик уңайсыз булган шикелле, язуда да хоруфы саутияләренең житешсезлеге сүзләрне тиешле тавышлары илә язуга уңайсызлык кыйладыр. Агыздан ишетелгән тавышларны язуда тиешенчә әда кыйлу өчен яңа тавышлы хәрефләр ихдас кыйлу, бәлки, мөмкин дә булыр иде, ләкин аның илә генә җиңеллек хасыйль булмаячак, бәлки, билгакес, имлямыз агырлашачак һәм шуның аркасында, хәрефләрнең шәкелләре күбәйгәнлектән, мәтбага кассаларында әүвәлдәге хисапсыз күп күзләр арасына яңадан берничәне арттыру лязим булачактыр. Гарәп, төрек вә татар әлифбасында асыл хәрефләр утыз дүрт-утыз биш төрле шәкелләрдән генә гыйбарәт булса да, бу хәрефләрнең һәркаюсының аерым, башта, уртада һәм ахырда языла торган махсус сурәтләре булганлыктан, хәрефләрнең шәкелләре асылыннан дүрт-биш мәртәбә артадыр.
Балага утыз биш хәрефне таныту бернәрсә дә түгел. Әмма аның төрле сурәтләрен тәкрар өйрәтеп, мәләкәләндерү бик читен. Шулай ук зурлар өчен дә утыз биш хәреф илә язу йөз кырык, йөз илле шәкел илә язуга караганда күп җиңелдер. Мәтбагаларда буларның җиңел вә агырлыгы дәхи дә тиз сизеләдер. Буе вә иңе икешәр аршын зурлыгындагы хисапсыз күп касса күзләреннән үзгә кирәкле хәрефне эзләп табуга караганда, ярты аршын мәрбәгында улан кечкенә генә кассаның утыз биш-кырык күзләре арасыннан кирәкле хәрефне эзләп таба алуның җиңел икәнлеген дә һичкем шөбһә итмәсә кирәк. Иштә бер хәреф шәкелләрен киметеп, агыздан ишетелгән авазларны кямаль мәүзугъсы илә кәгазь өстенә язу мөмкин улырлык хәрефләр ихдас итү юлында ничә еллардан бирле күп кешеләр башларыны ватып иҗтиһад кыйлмакталардыр. Русия мөселманнары арасында безнең өчен тырышучылар булган шикелле, башка ислам мәмләкәтләрендә дә буның өчен кайгыртучылар бик күптер.
Төркиядә ушбу исляхы хоруф вә исляхы хоруфә, вә исляхы имля мәсьәләләре зур мәгънәләрдән саналмактадыр. Хәтта «Санин» гәзитәсе идарәсе гарәп хоруфатын аерым язу өчен муафикъ бер юл күрсәткән кешегә зур мөкяфәтләр бирергә вәгъдә дә кыйлган. Гарәп хоруфатын аерым рәвештә язу өчен юл табу, асылда, бик читен бер эш түгелдер. Бераз фикер сарыф кыйлган кеше буны таба алачактыр. Ләкин эш анда гына түгел. Бәлки бу хезмәт кыйлынган хәрефләрнең ничә гасырлардан бирле дәвам итеп килгән гарәп

хәрефләреннән күп аермасы булмавы шарттыр. Бер кеше яңа бер хәреф ихдас итәр, һәркем бер иттифакъта булып, ул хәрефләрне өйрәнер. Һәркем шул хәрефләр илә язар, мәтбагалар киләчәктә басылачак китапларны шул хәрефләр илә басарлар. Һәркем буңа бик тиз төшенер, ләкин бу вакытта безнең әүвәлдән бирле язылып вә табгы ителеп килгән иске имля вә иске хәрефле китапларымызны кем таныр да кем укыр? Ул вакытта безнең иске язуларымызны уку, тану вә анлардан истифадә итү өчен икенче мәртәбә балаларга иске хоруфат тәгълиме бирергә кирәк булачактыр, вә бу әүвәлге бер читенлек өстенә икенче читенлек булачак. Ушбу көннәрдә Мөхәммәдшакир вә Мөхәммәдзакир әфәнде Рәмиевләр тарафыннан табгы  өчен ихдас ителгән хоруфатларның нәмүнәләре вөҗүдкә чыкты1. Буларның ихдас иткән хәрефләренең иске гарәп хоруфаты шәкелләреннән күп аермасы юк, шәкелләре дә бик гүзәл, игътибар кыйлып караган, иске хоруфатны таныган кешеләрнең һәркаюсы бер көн эчендә бу хәрефләр илә табгы ителгән китапларны укырга моктәдир булачак. Ләкин әлифбаны башлап шул хәрефләр илә өйрәнгән кешеләрнең һичберсе иске хат илә табгы ителгән китапларны укырга моктәдир булмаячактыр. Шул сәбәптән бу хәрефләрнең мәкъбүлияткә кичүен өмид итеп булмый.
Ушбу көннәрдә идарәмезгә килгән «Санин» гәзитәсендә Рәфикъ Шәүкәт исемендә бер мөгаллим үз тарафыннан имляларны язу өчен бер ысул тәкъдим итә. Буның тәкъдим иткән ысулы шуннан гыйбарәттер: «Имля хәрефләреннән а, у, и хәрефләре гарәпчә вә фарсыча булмыйча, саф төрек телендә булган сүзләрдә күп истигъмаль ителергә тиеш. Мәсәлән, бундан соң төрекчә «кпу»ны – «капу», «сндалия»не «сандалия» язарга тиеш. Соңра исем вә фигыльләргә тоташа торган әдатларның һәркаюсы асыл кәлимәдән аерым язылырга, мәсәлән, «килдем, килдек, килүр» сүзләренең асыллары «кил» булганлыктан, «кил дем, кил дек, кил үр» сурәтендә, «китапның тышы» дигән сүз «китап нның тыш ы» сурәтендә язылырга тиеш», – ди.
Мөсәлләм булдык, шулай язылсын. Әдатның аерым язылуыннан гына нинди файда хасыйль булачак та язуларымыз өчен нинди җиңеллек булачак? Мәкаләне дәрҗ иткән «Санин» гәзитәсе бу хакта үз тарафыннан һичбер сүз әйтми. Бу кеше, занемә күрә, «Санин» идарәсе тарафыннан мөкяфәт вәгъдә кыйлынганнан соң эшкә керешкән һәм «Санин»нең асыл мәкъсудын аңлап җиткермәгән бер кеше булырга кирәк.
Безнең фикеремезгә күрә, «Санин»нең мәкъсуды аерым хәрефләр вөҗүдкә китереп, хоруфатның шәкелләрен азайту һәм бәгъзе бер тавышлар өчен мәхсус галәмәтләр иҗат итеп, имлямызны төзәтү булса кирәк. Юкса әдатларның аерым язылуларыннан нә имлямыз төзәләчәк вә нә дә бик күп әшкялләрдән гыйбарәт булган хәрефләремезнең гадәдләре азаячак. Әдатларның аерым язылуларыннан гына имлялар вә хоруфатымызның төзәлүе өчен һичбер файда юктыр.
Эч пошканда

Гыйззәтле укучылар!
Сезнең үзегезгә дә бик мәгълүм, Казанда, Казанда гына түгел, Русиянең һәрбер җирендә ничә һәфтәләрдән бирле эсселәр булып килде. Әле менә бары кичәге көннән бирле генә бераз салкынча булып, һавалар җиңеләеп тора. Ягъмурлар явып, һавалар яхшыланып китте. Эссе вакытларда сезнең илә бергә без дә һава урынына саф тузан йотып утырдык. Инде хәзер генә бераз үпкәләремезгә саф һава керә башлады. Эссе һава кешене бик ялкауландыра икән, бер дә урыннан кузгаласы килми икән. Кешенең үзенең ихтыярында булса, бундый вакытларда һичкем эш эшләмәс иде. Һәркем урманнарга, дачаларга чыгып, су буйларында, агач күләгәләрендә рәхәтләнеп бераз юешрәк һәм бераз салкынчарак һава иснәп, салкын су эчеп, морожный ашап, су коенып, рәхәтләнеп кенә ятар иде. Ләкин ни чара? Һәр эш тә кешенең үз ихтыярында гына түгел. Дөнья, ихтыярсыз, кешене үз артыннан ияртеп йөртә. Эссегә дә карамый, салкынга да карамый – һаман эшкә куша бирә. Әле менә шуны әйтәсем килә: мин бер дә мәшәкатьләнеп бу яза торган юлларны язып утырмас идем. Мин, үземезнең күршедәге пенсия алып, ашап ята торган чиновник шикелле, дачага чыгар идем дә, көндез агач күләгәсендә йоклап, иртә-кич башыма бик зур

салам эшләпәне киеп, балык тотып тик утырыр идем. Ул чиновникның инде хәзер һич кайгысы юк. Балык эләгәме- юкмы – ул аны бер дә кайгыртмый. Эләксә, бик кәефләнеп, күтәреп дачасына алып кайтып, хатын вә балаларына күрсәтеп мактана. Эләкмәсә: «Балыгы булмаса, шурпасы да бик яхшы әле», – дип, Идел суы эчеп канәгатьләнә. Ә безгә алай ярамый, гәзитә чыгарасы бар. Мөштәриләр көн эссе икәнлеккә карамыйлар: «Көн эссе булмагае, инде теләсә нәрсә булсын, без акча түләгән, кая безгә гәзитә?» – диләр. Гәзитә язу безнең өчен бик зур эш түгел, кулында каләм, алдында кәгазь булгач, язасың да чыгасың. Иң читен җире менә аның кайда. Хәзер Русиядә нә Дума бар, нә Совет бар1. Анлар бар чагында сүзне күп табып буладыр иде. Йә берәр мөселман депутаты нотык сөйлидер иде, йә булмаса мөселман фракциясенең2 бер мәҗлесе буладыр иде дә, анларның анда нинди киңәшләр кыйлганнарын язадыр идек. Һич булмаганда, Пуришкевич3 Думада җәнҗал чыгарадыр иде дә «ут ягып» кычкырышадыр иде. Хәзер инде анларның һичберсе юк. Дума әгъзалары һәммәсе төрлесе төрле якка таралып беттеләр, авылларында, дачаларында ял итеп тик яталар. Ә безгә бунда, гайрәт орып, мәкаләләр язарга бернәрсә дә юк. Анда, Балкан ярым атавында, төрекләр белән арнаудлар сугышып яталар4, бунда Франция, Испания һәм Германия Фас мәмләкәтенә кергәннәр дә аны бүлмәкче булалар5 дигән хәбәрләр барын бар да, без инде аны бик күптән бирле язып киләмез. Яза-яза да арып беттек. Сез дә, шаять, укый-укый да туеп беткәнсездер. Башка нәрсә хәбәр язарга кирәк? Һичбер төрле яңа хәбәрләр юк. Хәбәр юклыгына без гөнаһлы түгел, аны үзлегемездән генә ничек итеп чыгарыйк?! Көн эссе, көн эссегә күрә, халык һәммәсе дә үз эше илә мәшгуль, җәмәгать вә халык эшләренә һич катнашмыйлар. Көз җитсен әле, менә шул вакытта күрерсез сез хәбәрләрне! Ул Думада шау-шулар дисеңме, ул чит мәмләкәтләрдә кузгалу дисеңме, ул мөселманнар арасында вакыйгалар дисеңме – яңа хәбәрләр бер-бер артлы килеп торыр. Әле хәзергә, гәзитәгә биргән акчамыз әрәм китмәсен дип, шушы язганнарны, начар булса да, укый торыңыз. Ни хәл итмәк кирәк, җәй көне шулай була инде. Фәлән җирдә бик зур янгын булган, фәлән җирдә боз яуган, фәлән җирдә фәләнчә кеше суга баткан, фәлән кеше, көн эссе булганлыктан, тәрәзә ачып яткан икән, өенә караклар кергән, фәлән җирдә эссе сугудан фәләнчә кеше вә фәләнчә хайван үлгән дигән хәбәрләрдән башка хәбәрләр булмый. Анлар өстенә фәлән авылның хәзрәте җәй көне кунакка бик күп йөри икән фәлән авылның җыенында фәләнчә кеше сугышып башларын ярышканнар икән дип язсаң ярар иде дә, ләкин алар бик гади, хәтта һәрбер авылда да була торган эш булганлыктан, укырга кызыклы түгел.
Йә ярар, күп сөйләдем, җитәр инде.
Ашыгып эшләнмәс!

Бездә билгеле инде: «Ашыккан ашка пешкән, сабыр иткән – морадына җиткән», – диләр. Каргалы1 янында бер күпер бар. Шул күпернең башындагы тактага «Күпер земский2, чабып йөрелмәс!» дип язып куелган. Аның янына бер шаян кеше килгән дә астына «Дело татарский, ашыгып эшләнмәс!» дип язып киткән.
Бик тугъры әйткән. Уйлап караңыз, дөрестән дә шулай бит! Оренбургта «Җәмгыяте хәйрия»3 файдасына сабан туе ясаганнар иде4, ике көннән соң ук җәмгыять сабан туеннан килгән файданы гәзитәләрдә язып игълан кыйлды. Бу эш бер дә ярый торган эш түгел. Чөнки, «дело татарский» булгач, ашыгып эшләнмәскә тиеш иде. Менә сез безнең Казаннан гыйбрәт алыңыз. Бездә дә бит, сезнең шикелле үк, «Җәмгыяте хәйрия» файдасына сабан туе ясалган иде. Инде аның үткәненә ай ярым булды. Әле һаман хисабын карап бетерә алганнары юк.
Безнең Казан кешеләре бик яхшы беләләр шул: «Дело татарский, ашыгып эшләнмәс!»
Казан «Җәмгыяте хәйрия»се вилядәтханә ачарга карар биргән иде. Ничә ел булды инде, әле һаман ачылып җитә алмый. Ник? Чөнки: «Дело татарский, ашыгып эшләнмәс!»
Тиздән көз җитә, клублар ачарга кирәк. Ә безнең «Шәрекъ клубы»ның фатиры юк. Фатир эзләргә дә ашыгырга ярамый, чөнки: «Дело татарский, ашыгып эшләнмәс!»

Тиздән Русиядә тәгълиме гомуми булачак, яңа мәктәпләр ачылачак. Ул мәктәпләр өчен мөгаллимнәр җитештерергә кирәк булачак. Мөгаллимнәр җитештерү өчен дарелмөгаллиминнәр лязим булачак. Инде дарелмөгаллимин ачарга карар бирелде. Ләкин, шаять, тиздән вөҗүдкә килмәсә кирәк. Чөнки: «Дело татарский, ашыгып эшләнмәс!»
Казанның трамвайлары да ташбака шикелле үрмәләп кенә йөри. Монда да трамвайлар гаепле түгел. Чөнки: «Шәһәр татарский, ашыгып йөрелмәс!»
Казанның һавасы начар, Татар бистәсенә бакчалар салырга, шәһәргә канализацияләр ясарга кирәк. Шулай ук шәһәр урамнары караңгы – фонарьлар кирәк. Күп урамнар пычрак – мостовой кирәк. Эчә торган сулар бик начар, эчәргә яхшы су җитми – яхшы водопровод кирәк. Бунлар да, шаять, тиздән булмас. Чөнки: «Дума татарская5, ашыгып карар бирмәс!»
Татарча театр

Киләчәк җомга көн «Новый клуб»1 залында «Сәйяр» труппа2 артистлары тарафыннан «Күз яше»3 нам драм илә «Дачада»4 нам бер водевильнең тамашага куелачагыннан хәбәр бирәләр. Труппаның мөдирләреннән Г.Кариев берничә яңа әсәрләргә цензурдан рөхсәт алып кайту өчен Петербургка киткән5. Бу труппаның театр эшләренә чынлап керешкәнлекләре күренәдер. Узган җомгада булган спектакльләрендә дә бик зур мәһарәтләр күрсәттеләр. Шул ук әсәр, узган ел куелганда, бу елгыдан күп йомшак чыккан иде. Бу елгы куелышта беренче кәррә уларак сәхнәгә чыккан Сәлимова үзенең мәһарәте илә халыкны гаҗәпкә калдырды. Сәлимовада фәүкыльгадә бер истигъдад күреләдер. Бундан соң да тәкрар сәхнәгә чыгып мәләкә хасыйль итсә, үз арасында мисальсез бер уенчы булуы көтеләдер.

1912

Мәтбагачылыкта тәрәккый

Мөселманча мәтбагачылыкта иң зур тәрәккый иткән мәмләкәт – Русиядер. Бу көнгә кадәр Русиядәге шикелле мөкәммәл ислам мәтбагалары башка мәмләкәтләрдә күренгәне юк. Төркиядә мәтбага эшләре яхшы тәрәккый иткән булса да, анлар һаман да Русиядәге ислам мәтбагалары артыннан җитә алганнары юк. Русия ислам мәтбагаларында булган шикелле төрле һәм гүзәл хәрефләр Төркиядә һич юк. Бездәге ислам мәтбагаларының һәркаюсы диярлек Төркия мәтбагаларында булган хәрефләргә малик булу өстенә үз тарафларыннан ижат ителгән төрле гүзәл хәрефләргә маликтерләр.
Бу көннәрдә Казан мәтбагачыларыннан Харитонов унике кегельдә яңа бер хәреф хәзерләгән. Бу хәреф күренештә нәкъ хәзерге көндә китап вә гәзитәләр басыла торган хәрефләр күренешендәдер.
Бунын хасияте урынны аз алуындадыр. Бу яңа хәреф илә китап басылганда, әүвәлдә дүрт табак чыга торган китаплар өч табак, хәтта аннан да кимрәк чыгачактыр. Әүвәлдә мең ике йөз юлдан гыйбарәт гәзитәләрдә мең алты йөз юл материал булачактыр. Димәк, бу хәреф саясендә бик зур икътисад булу мөмкиндер.
Соңгы елларда ислам хоруфатын азайту мәсьәләсе кузгалган иде. Берникадәр кешеләр бу хакта төрле фикерләр йөртеп, төрлечә хәрефләр ихтираг итеп карадылар. «Йолдыз» тарафыннан да «хатты касыйр» исемендә бертөрле аерым хәрефләр ихтираг ителде. «Йолдыз» ихтираг иткән хәрефләр «Милләт» мәтбагасында эшләнде. Хәзерге көндә игъланнар басуда истигъмаль ителә башлады. Кәримевләр мәтбагасында1 да

Габделмәннан әфәнде Рәхманкулов2 тарафыннан ясалган бер нәүгъ кыска хәрефләр эшләнеп ята. Соңра оренбурглы Закир вә Шакир әфәнде Рәмиевләр тарафыннан «Хатты табагать» исемендә бертөрле аерым хәрефләр иҗат ителгән иде. Рәмиевләр үзләре бу хәрефне иҗат итү илә кифаяләнеп калдылар. Аны истигъмальгә кертү өчен иҗтиһад сарыф кыйлмадылар. Хәзерге көндә югарыда зикер ителгән мәтбагачы Харитонов җәнабләре Рәмиевләрнең шул хәрефләрен вөҗүдкә чыгару өчен иҗтиһад сарыф кыйла. Харитонов мәзкүр хәрефләрне үзенчә яңадан ислях итеп койдырган, Рәмиевләр хәрефендә күрелгән ноксаннар тәкмил ителгән. Тиздән Харитонов балаларга һәдиягә бирү өчен мәзкүр хәрефләр илә бер-бер артлы китаплар нәшер итә башлаячактыр. Мәзкүр хәрефләрнең нәмүнә вә әлифбасыннан гыйбарәт булган гүзәл бер китап Харитоновның үз мәтбагасында басыла башлаган. Һәр хәреф тугърысында үзенә муафикъ гүзәл рәсемнәр куелган.
Бу хәрефләр, күрер күзгә ятрак төсле тоелса да, асылда, гарәп хоруфатыннан, әсасән, һичбер үзгәртелмәгән, бәлки әүвәлгедән гүзәлрәк бер кыяфәткә генә куелган. Хәрефләремезне ислях итәргә күптән вакыт иде. Хәзер инде берничә төрле яңа хәрефләремез булды. Бунларның кайсы мәкъбулияткә кичәр, анысын заман күрсәтер.

Әдәби бәхәсләр
Кичә минем дустларымнан берсе миңа түбәндәге мәгыйши бер хикәяне сөйләде. Ул әйтә: «Казан губернасыннан, Зөяме, Сивилме өязеннән, бер егет үзе яраткан бер кызны алган. Ата-аналары буның андый кызга өйләнүләренә кырын күз илә караганнар. Бу кызга өйләнгәнлеге өчен бу егетне яратмаганнар. Ниһаять, ата-анасы, ул кызга өйләнгәнлеге өчен, бу егетне хатыны илә өйләреннән куып чыгарганнар. Егет үзенең хатыны илә ата-анасының өеннән чыгып киткәннәр. Үзалдына көн күрә башлаганнар.
Бу егетнең мәзкүр хатыннан ике баласы (ике кызы) булган. Бунлар яхшы гына, тыныч кына гомер итеп торган вакытта, ачлык еллар килеп җиткән. Егет үзенең гаиләсен тәрбия итүдән һәм анларны тук итеп асраудан гаҗиз калган. Соңра егет үзенең хатынын вә балаларын тәрбия итәр өчен читтән эш эзләргә мәҗбүр булган. Шул мәкъсуд илә егет, өеннән чыгып китеп, Пермь губернасына бер приискага барган. Анда баргач та, үзенә эш таба алмаганлыктан, аннан ераграк бер шахтага киткән. Анда да үзенең вә гаиләсенең тамагын туйдырырга җиткерә алырлык акча хасыйль итә алмаганлыктан, һаман ераккa китәргә мәҗбүр булган. Ниһаять, бу кеше бара-бара еракларга китеп, Америкага (Аляскага) барып чыгарга мәҗбүр булган. Анда баргач, бу кеше үзенә эш табып хезмәт итә башлаган. Һәм бик яхшы акча да табарга тотынган. Шул вакытта аңар үзенең якташларыннан бер кеше очраган. Ул кеше, бу җирләрдә берничә вакытлардан бирле эшләп, яхшы гына акча хасыйль итеп, үзенең авылына кайтып китәргә хәзерләнеп йөри торган бер кеше булган. Бу егет аңа ышанган, аның инабәтле кеше булуында һич бертөрле шөбһә дә кыйлмаган. Мәзкүр адәмнең үз ватанына кайта торган бер кеше булганлыгын белгәнлектән, үзенең гаиләсенә тапшыру өчен, ул кеше артыннан үзенең бөтен хасыйль иткән акчаларын биреп җибәргән. Мәзкүр адәм кайтып киткән. Ул киткәч тә, бу егет, бик яхшы тырышып эшләп, күп акчалар хасыйль иткән. Берзаман теге кешедән: «Мин сагъ-сәламәт кайтып җиттем. Сез җибәргән акчаларны гаиләңезгә тапшырдым, анлар бик сагъ һәм сәламәт торалар, синең акча җибәрүеңә бик шатландылар», – дип язылган бер мәктүп килгән. Бу мәктүп килгәч, мәзкүр егет, бик шатланып, кулында җыелган акчаларны янәдән мәзкүр кеше исеменә җибәреп, яңадан ул акчаны үзенең гаиләсенә тапшыруны илтимас кыйлган!
Эшнең башы шуннан гыйбарәт. Ләкин эш вакыйгъдә бөтенләй башкача булып чыккан. Егеттән акчаны алып киткән мәзкүр адәм акчаны алган, үз кесәсенә салган, акчадан бер тиенне дә мәзкүр егетнең гаиләсенә бирмәгән.
Асылда, эш ушбу түбәндәге рәвештә булган. Егет өйдән чыгып киткәнгә биш ел кадәр вакыт узган. Егеттән һичбер төрле дә хәбәр булмаган. Егетнең хатын вә балалары тәмам мохтаҗлыкта калганнар. Шул заманнарда авылның байгураларыннан берсе бу хатынга күз

сала башлаган. Хатын да үзенең ихтыяҗы аркасында бу байгурага якын килергә мәҗбүр булган. Мәхкәмәи руханиянең карары буенча хатын, үзенең югалган иреннән аерылып, байгурага хатынлыкка барган һәм аның илә көн күрә башлаган.
Егет Аляскада көн-төн эшләгән. Хезмәтеннән килгән һәрбер акчаларны үзенең әүвәлдә белешләнгән кешесе аркылы хатынына җибәрә торган. Соңра, берникадәр акча җыйганнан соң, үзенең ватанына кайту өчен юлга чыккан. Юлда казаи асманигә очрап, пароходлары баткан. Егет, ул вакыйгадә сагъ-сәламәт калып, бер атауга чыккан. Анда үзенең күргән вакыйгаләреннән мөтәэссир булып, гакылдан шашкан. Берничә мөддәтләр шифаханәдә ятканнан соң, сәламәтләнеп, ватанына кайтырга ният кыйлган. Егет авылына кайтып киткән. Бөтен шатлык һәм гаиләсенә кавышу хиссияте илә авылына кайтып җиткән вакытта, басу капкасы төбендә аңа ике кечкенә кыз бала очраган. Бу егет мәзкүр кыз балалардан авылдагы хәлләрне, андагы кешеләрне һәм анларның сәламәтлекләрен сораша башлаган. Шул ук заманда үзеннән, үзенең хатыныннан һәм бала-чагаларыннан хәбәр алуны да онытмаган. Мәзкүр кыз балаларга: «Сез фәлән кешене, фәлән абыстайны һәм аның ике кыз баласын беләсезме?»– дип сөаль биргән. Буңа каршы бу балалар: «Безнең әти биш елдан бирле югалган, анамыз фәлән кеше. Хәзер ул фәлән байга хатынлыкка барды», – дип җавап биргәннәр. Бу сүзләрне ишеткәч, егетнең йөрәгенә ут кабынган. Ә балаларның үз балалары идекен белгәнлектән, анларны егълап-егълап һәм кочаклап үпкән. Ләкин анларга үзенең серен белдермәгән. Соңра ул балалардан өйләренең кайда идекен сораган. Балалар йортларын күрсәткәннәр. Мәзкүр йортка барганда, әүвәлдә үзенең торган йортына күзе төшеп, аңа караган. Йорт искергән, диварлары җимерелгән, тәрәзә капкачлары капланган, йорты тәмам харап булган иде. Егетнең күзеннән ихтыярсыз яшьләр коелды. Балаларны яңадан бер мәртәбә кочаклап үпте. Күзләреннән яшьләр түкте. Шул вакыт анлар байгураның йорты янына барып җиттеләр. Балалар: «Әнә без шул йортта торамыз», – дип йөгерешеп киттеләр. Егетнең аякларында һичбер куәт калмаган иде. Ул ихтыярсыз үзенең баскан урынында катып калды. Берзаман күз алдылары караңгыланды. Аякларының куәтләре югалды. Аяклары сыгыла башлады. Егет шул торган урынында изелде. Җиргә утырды. Күз алдыннан әллә нинди кара күбәләкләр очып йөри башлады. Күзләре йомылды. Берзаман бөтен куәтен сарыф кыйлып күзен ачты. Күз алдында җәелеп агып бара торган киң бер су күренде. Егет тырышты, тырмашты. Көч-хәл илә суның читенә барып җитте. Агымсуга карады. Аның гомере илә бу агымсуның арасында һичбер аерма юк иде. Аның гомере дә бу агымсуда, һичбер вакыт кире кайтмаска дип, мәңгегә агып баралар иде. Егетнең кальбендә яңа бер хис кузгалды. Ул ушбу суның агымы илә бергә үзенең гәүдәсен мәңгегә агызып җибәрергә фараз кыйлды. Шул заманда буның башына яңадан бер фикер килде: «Бу су агымына ияреп, минем мәңгегә китүемнән кемгә файда булачак?» – диде. Бу сөальгә каршы үзендә бер җавап хәзерләнгәнлектәнмедер, нидәндер, куенындагы кесәсеннән кырыкка бөкләнеп тузып беткән бер паспорт кәгазен алды да суга ыргытты. Шуның артыннан егеттән: «И, минем кешелегемне һәм кемлегемне белдерә торган зур шәһадәтнамәләр, сез хуш, сагъ булыңыз! Мин бундан соң бер исемсез, шәһадәтнамәсез бер бродяга булып калдым», – дигән сүзләр ишетелде.
Миңа бу хикәяне нәкыль иткән иптәшем миннән:
– Безнең татарларда шундый вакыйгаләр, шундый хасиятләр, шундый тәэсирләр һәм шундый драм вә трагедияләр булырга мөмкинме? – дип, бер сөаль бирде.
Мин буңа каршы үз тарафымнан һичбер төрле җавап бирә алмыйм, белгән кешеләр булса, буңа каршы бер сүз сөйләсеннәр!
Дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең намен таәбид итү хакында

Гәзитәләрдә һәм дә зыялы мөселманнар арасында мәрхүм дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәте илә аның намен таәбид итү мәсьәләсе кузгалган иде1. Казан яшьләреннән бәгъзе бер кешеләр шул көнгә Шиһаб хәзрәтнең иң зур тәэлифләреннән вә бу көнгә кадәр нәшер ителмәгән әсәрләреннән

«Вафиятел-әсляф»2 нам берничә җилдлек зур әсәрен нәшер итү ирадәсендә булганлыкларын ишеткән идек. Соңгы көннәрдә килгән «Идел» гәзитәсендә Мәүлед бәйрәме мөнәсәбәте илә булган бер мәҗлестә Әстерхан мөселманнары арасында ушбу көнгә иштиракь итү өчен киңәшләр булганлыгы күренде3.
Ул мәҗлестә Шиһаб хәзрәтнең намен таәбид итү өчен:
1) Әстерхан мәктәпләреннән бер мәктәпне зурайтып, програмын тәүсигъ итеп, шул мәктәпкә Мәрҗани исеме бирергә;
2) Шиһаб хәзрәт исеменә Әстерхан шәһәрендә бер кыйраәтханә ачарга;
3) Әстерхан шәһәрендәге урта мәктәпләрнең берендә (гимназия, реальный, яхуд тиҗарәт мәктәбендә) Шиһаб хәзрәт исеменнән бер шәкерт тәрбия итү хакында фикерләр сөйләнгән икән.
Бунлар, әлбәттә, бик гүзәл һәм бик тиешле эшләрдер. Ләкин ул эшләрне вакытында һәм тиешле көндә эшләргә тиеш. Шиһаб хәзрәтнең намен таәбид итү мәсьәләсен Казан яшьләреннән берничә кеше мәйданга куйганнар иде. Ләкин анлар Мәрҗани җәнабләренең вафат тарихы тугърысында бераз яңлышканнар икән.
Без дә үз тарафымыздан ул көнгә иштиракь итәргә теләгәнлекемездән, шул хакта бераз мәгълүмат алу өчен дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең мәхдүме (бу көндә Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең михрабы вә мөнбәренә һәм мәдрәсәсенә варис) мулла Борһанетдин хәзрәт4 җәнабләренә мөрәҗәгать кыйлган идек һәм бу тугърыда берникадәр истифсар да кыйлган идек. Сөалемез соңында яшьләрнең тарих хакында бераз хата кыйлганлыклары күренде. Мәхдүмнең бәянына күрә, Шиһаб хәзрәт 1889 елның апрель аенда вафат булган икән. Апрельнең ничәнче көнендә вафат булганлыгын ул безгә хәбәр итәргә вәгъдә кыйлды. Бу хисап буенча Шиһаб хәзрәтнең вафатына 1914 ел апрель аенда егерме биш ел тулачактыр. Әгәр дә дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең намен таәбид итәргә теләүчеләр сәнәи камәрия5 илә эш йөртергә теләсәләр, ул тәкъдирдә аның намен таәбид итү көнен бер ел кадәр алга китерү мөмкин булачактыр. Ләкин ул тәкъдирдә дә ул җәнабе галинең намен таәбид итү көне быел булмаенча, 1913 елның май яхуд июнь айларында булырга тиешледер. Дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең кайсы көндә һәм кайсы числода вафат булганлыгын әйтергә мәхдүм мулла Борһанетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре вәгъдә кыйлды. Аннан хәбәр алганнан соң, янә гәзитәмездә хәбәр бирермез6.

## Хөсәен әфәнде Ямашевның җеназа
## Мәрасиме

Өченчекөн Хөсәен әфәнде Ямашевны дәфен кыйлдылар. Хөсәен әфәнде ничә еллардан бирле университетка керер өчен тырышып йөргән, ахыр гомерендә шул мәкъсудына ирешеп, университетның хокук шөгъбәсенә кергән иде. Мәрхүмнең җеназасы да шул университеттан чыкты. Хөсәен әфәнденең иптәшләре, аны ни рәвештә озату хакында киңәш итеп, ахырдан, аның үзенең иң яраткан җире университет булганлыктан, җеназасын да шуннан чыгаруны мәгъкуль таптылар.
Өченчекөн тәшрихханәнең мәетләрне тәкфин өчен тәхсыйс ителгән залы таңнан ук халык илә тулган иде. Һәркем аның илә актык мәртәбә күрешеп калу, саубуллашу өчен килгәннәр иде. Сәгать уникегә таба Хөсәен әфәндене озатырга килгән кешеләр шулкадәр күбәйде ки, тәшрихханәнең кечкенә залы гына түгел, университетның зур ишегалды да тыгыз күренә башлады.
Беренче сәгать башланды... Хөсәен әфәндене махсус ясалган гүзәл рәшәткәле җеназа агачына салып, өстен зәңгәр хәтфә илә өреттеләр. Аның өстенә үзенең иптәшләре һәм дустлары тарафыннан тәкъдим ителгән чын чәчәкләр вә гөлләрне тезделәр.
Җеназаны күтәреп чыктылар. Университет ишегалдында бөялеп торган халык дәрьясы хәрәкәткә килде. Җеназа артыннан бу дәрья капкага таба агыла башлады. Дарелфөнүннең киң капкаларына халык сыймый, бер-берсен тыгызлап чыгалар иде. Мәйданга барып җиткәнче, озатучылар дәхи дә артты. Юл буенда тугъры килгән һәрбер йортларның

тәрәзәләре һәммәсе җеназаны карап торучы хатын-кыз башлары илә тулган иде. Мәйданда җеназа укылган вакытта һичшиксез ике мең кадәр кеше бар иде.
Җеназа укылганнан соң, озата баручыларның бәгъзеләре мәйдан ягында калдылар. Яртыдан зиядәсе мәкъбәрәгә кадәр озата бардылар.
Дәфен ителеп догалар кыйлынганнан соң, Хөсәен әфәнденең дустларыннан Габдерахман әфәнде Мостафин Хөсәен әфәнде хакында бик гүзәл һәм хәрарәтле бер нотык ирад итте. Габдерахман әфәнде нотыгында Хөсәен әфәнденең һәрбер яхшы фигыль вә әхлакый бәян итеп, аның яшьләй заигъ булуына тәхәссерләр изһар кыйлды.
Хөсәен әфәнденең җеназасы өстенә яшьләрдән, иптәш студентларыннан һәм хатыны тарафыннан ленталар куелган иде. Иптәшләре тарафыннан куелган лентада «Вакытсыз киткән мәңге онытылмаслык дустымызга!», юридический кружок идарәсе тарафыннан куелган лентада «Ул үз халкының якты истикъбале булачагына ышану һәм өмид илә китте» дип язылган иде.
Берникадәр фотографлар төрле урыннарда – тәшрихханәдә, университет алдында һәм мәйданда җеназа мәрасименең сурәтләрен төшереп алдылар.

Татарча театр

Өченчекөн «Новый клуб»1 залында татарча театр ясалып, тамашага Ярулла әл-Вәлинең «Ачлык кушты» нам2 драма илә Кәбир Бәкернең «Чөн там» исемле водевиле куелды. Уенчылар үзләренең рольләрен яхшы иҗра кыйлдылар. Ләкин тамашага килүчеләр бик аз иде. Хәтта «Сәйяр» труппасы артистлары бу көнге театрдан зарар да иттеләр. Ишетелүенә күрә, бу зарарның булуына «Шәрекъ клубы» идарә әгъзаларыннан бәгъзе бер кешеләрнең агитацияләр ясап йөрүләре сәбәп булган, имеш. Бу кешеләр, труппаның «Шәрекъ клубы»нда уйнаган заманнарында3 «Ачлык кушты» нам драманы тамашага куймауларына шикаять итеп: «Труппа артистлары ул әсәрне соңыннан үз файдаларына куеп, күп махсул алу өчен «Шәрекъ клубы»нда куймадылар», – дип сөйләп йөргәннәр икән.
Мин, «Шәрекъ клубы»нда дүрт ай мөддәтендә режиссер булып торганлыгымнан4, артистларда андый бер фикернең булмаганлыгын бик яхшы беләмен. Мин, ул пьесаны ничә мәртәбә куярга тырышып карасам да, пьеса өчен лязим булган декорацияләрнең клубта булмавыннан, тәэхир итәргә мәҗбүр булдым. Хәтта берничә кәррәләр лязим декорацияне ясату хакында идарә әгъзаларына мөрәҗәгать кыйлып карасам да, ни өчендер идарә әгъзалары кабул итмәделәр. Шул сәбәптән ул әсәр тамашага куела алмыйча калды. Мин бу хакта «Сәйяр» труппасы гаепле дип белмим.
Кыз сату

Кичә генә «Новый клуб» залында «Ачлык кушты» исемле бер пьесаны тамашага куйганнар иде1. Бу драмда намәгълүм бер карьядәге фәкыйрь бер гаиләнең, ачлыкка тәхәммел итәргә кодрәтләре калмаганлыктан, «кияүгә бирәмез» исеме илә үзләренең җиткән бер кызларын бер төрекмәнгә сатып җибәргәнлекләре тасвир ителгән иде. Бичара кыз, Төркстанның эссе сахраларына кәнизәк булып барып, бик күп михнәт вә мәшәкатьләр күргәннән соң һәлак була.
Мин бу урында ул драм хакында сүз сөйләячәк түгелмен. Театр китаплары анлар – каләм ияләре тарафыннан уйланып язылган хыялый әсәрләрдер. Язучылар һәрвакытта дөньяда булган вакыйгаләргә күзләрен салалар да, шуннан бер фотограф аппараты шикелле сурәтне төшереп алып, вакыйгане халык күзенә кызганыч бер рәвештә итеп күрсәтергә тырышалар. Үзләренең тасвир кыйлган пьесалары илә анлар халыкны кызгандырырга, анларның күңелләрен йомшатып, начар фигыльләрене ташлатырга иҗтиһад итәләр. Мин кичә генә «Ачлык кушты» драмын карап мөтәэссир булып кайткан идем. Бу көн гәзитә идарәсенә килеп, читтән килгән мәктүбләрне карый башлагач, кичәге хыялый драмга караганда да кызганыч һәм вакыйгый бер драмчы күз алдымда күрдем.

Мөштәриләремездән Юныс әфәнде Идрисов җәнабләре бәгъзе бер җанвар һәм кансыз кешеләрнең Төркстанга кызлар китереп сатуларыннан зарланып яза. Аның язган нәрсәләре әһәмиятле булдыкыннан, мин аның мәктүбенең бәгъзе җирләрен бу урында нәкыль итеп китүне муафикъ күрдем.

Юныс әфәнде яза: «Узган ел Дәүләт Думасы әгъзаларыннан берничә кешеләр бәгъзе бер адәмнәрнең Русия эчендәге авыллардан кызлар алып китеп, Төркстан эчендә сатуларыннан бәхәс кыйлганнар һәм бу тугърыда халыктан истифсар да кыйлганнар иде. Аңар каршы без җавап уларак Казаннан бер карчыкның кызлар алып килеп сатканлыгын язган да идек. Хәзер инде тәкрар шул хакта язарга тугъры килә. Бу ел мин бу карчыкның кем һәм нинди кеше вә кайдагы икәнлеген бик яхшы тикшердем. Бу карчык үзе асыл Казанга якын Сәрдә авылының2 Мәфтуха исемле бер карчык икән. Мәхәлләи икамәте Казанда Печән базарына якын бер урында икән. Мәзкүр карчык һич булмаганда егерме елдан бирле кыз сату илә мәшгульдер. Төркстанда бу карчыкны белмәгән бер кеше юктыр дисәм дә хата булмас. Ташкент шәһәреннән башлап Хоҗанд, Хоканд, Иске Мәргилән, Нәмәнган, Әндиҗан һәм Ош шәһәрләренә кадәр – һәрбер шәһәрдә сартларның һәркаюсы бу карчыкны беләләр. Сартлар иң әүвәл буның илә белешәләр, аңар заказ бирәләр дә, ул, Казанга китеп, анларга кыз китереп сатадыр. Кыз гына түгел, хәтта сораучылар булганда, сакал-мыек чыкмаган ундүрт-унбиш яшәрлек матур ир балаларны да сартларга китереп тапшырадыр.

Бу карчык бу тарафларга елына дүрт-биш мәртәбә килеп китә. «Буйдагы сартлар, Казан халкы (нугайлар), үзләренең кызларын һәм балаларын тәрбия итә алмаганлыктан, анларны арзан бәһаләргә сатып кәсеп итәләр икән» дип, татарларны мәсхәрә кыйлалар. Төркстанда торучы татарларга бу хакта сүз сөйләргә дә ирек бирмиләр. Бу карчык баштанаяк безнең өчен зур афәттер. Бу карчык бу ел 12 апрель пәнҗешәмбе көн Хоҗанд шәһәреннән Ташкентка китте. Әгәр дә гәзитәләремез бу бәдбәхет карчыкның хәлен гәзитәләргә язып игълан кыйлсалар, ихтимал, халыкка бер тәнбиһ булыр иде», – ди.

Юныс әфәнденең сүзен мин бик нык тасдикъ итәм. Ул әфәнде безнең идарәгә күптән бирле мәгълүм бер кешедер. Аның сүзләрен тасдикъ кыйлганнан соң, үз тарафымнан берәр сүз әйтмәкче булам.

Төркстанга кызлар алып китүче кеше бунда әйтелгән Мәфтуха карчык кына түгел, бунларның ишләре бик күп. Бу көннәрдә Казан шәһәренә «өйләнергә» дип килүче төркстанлылар күренә башлады. Хәтта бу көннәрдә бер-икесе Казаннан өйләнеп тә киттеләр. Бунларның нинди кешеләр икәнлеген без белмимез. Бәлки, анлар яхшы кешеләрдер. Бәлки, анлар кызларны үзләре өчен гомерлек рәфыйка итеп ала торганнардыр.

Шулай да булса бундый кешеләрдән яучы йөргән вакытларда сакланыбрак эш кыйлырга ата-аналарга нәсихәт итәмез. Бу ел ачлык ел булганлыктан, фәкыйрь ата вә аналар, үзләренең кадерле кызларын һич белмәгән бер кешегә биреп җибәреп, аның бәхетсезлегенә сәбәп булмасыннар. Бу серләрне халыкка аңлатуны мөхтәрәм имамнарымыздан риҗа итәмен.

Русча мөселман гәзитәсе

Берничә еллардан бирле мөселманнарның мәнафигын химая итү өчен мөселманча бер гәзитәнең кирәклеге халык арасында сөйләнә иде.

Соңгы елларда уңлык тарафдары булган рус гәзитәләрендә язылган ифтиралар чиктән тыш күбәйгән иде. Бунларга каршы тору һәм мөселманнарның хокукларын химая итү өчен русча бер мөселман гәзитәсе, әлбәттә, лязим иде. Менә нәкъ шул ихтыяҗ заманында Петербургта мөселманча бер гәзитәнең чыгачагы ишетелде. Башта халык бу яхшы хәбәрдән сөенде. Аңа бик зур өмидләр илә карады. Башта мөселманнар бу гәзитәне кулларыннан килгән кадәр химая итәргә фарыз кыйлдылар.

Ләкин аз берзаман соңында бу гәзитәнең кыяфәте тәмам мәгълүм булды. «В мире мусульманства» исемендә булган бу гәзитә үзенең берьеллык гомере эчендә мөселманнарның хокукларын химая итү хакында бер сүз дә язмады дисәк тә, ялган

булмаслык хәлгә килде. Аның берьеллык гомере эчендә ислам галәмендә нинди зур вакыйгаләр булып узды, һәм шул бер ел эчендә уң тараф гәзитәләрендә мөселманнарга каршы нинди зур ифтиралар кыйлынды. Шул мөддәт эчендә мәзкүр гәзитә анларга каршы (әгәр «Земщина» гәзитәсенә каршы ярым-йорты язган бер мәкаләсен истисна кыйлсак) бер сүз дә язмады дияргә дә ярыйдыр. Шул сәбәптән халык ул гәзитәгә илтифат итмәде. Мәзкүр гәзитә үзенең бер яшен тутырган көндә вафат булды. Бу көн килгән номерында гәзитәнең мәсьүл мөхәррирләреннән Датиев җәнабләре халык берлә исәнләшә һәм, гәзитәне химая кыйлмаганлыклары өчен, мөселманнарга үпкәләп, гәзитәсенә җан бирде-рәдер. Безнең уйлавымызга күрә, «В мире мусульманства» гәзитәсенең вафатына халык гаепле түгел, бәлки гәзитәнең башында торучы кешеләрнең ислам галәменә илтифатсызлыклары гаепледер. Әгәр дә ул гәзитә, ислам галәменә яхшы илтифат итеп, аның ихтыяҗы һәм аны химая итү хакында күбрәк иҗтиһад кыйлган булса, гомере, бәлки, ул кадәр үк кыска булмаган булыр иде дип фараз кыйлынадыр. Шул сәбәптән гәзитә сахибләре мөселманнарга үпкәләү урынына үзләренә үпкәләргә тиешледер.

Яңа әсәрләр

Бу көннәрдә безнең өчен иң кыйммәтле булган ике әсәр дөньяга килде.
1) «Харитон бабай»1 (ул үзен шул исем илә тәсмия кыйла) «Ак чәчәк» бәйрәме көненә2 телсезләр өчен бер әлифба чыгарды. Бу көнгә кадәр Яурупада телсезләр өчен бармаклар васитасы илә сөйләшә торган әлифбалар бар иде. Ләкин анларның һәркаюсы да Яурупа телләренә генә махсус иде. Ул әлифбалар илә татарча, фарсыча, гарәпчә һәм төрекчә сөйләшергә мөмкин түгел иде. Яурупа телләрендә бездә истигъмаль кыйлына торган «җ», «з», «д» вә шуңа охшашлы хәрефләрнең юклыгы һәркемгә мәгълүмдер.
Халык чахотка илә көрәшү илә мәшгуль бер заманда Харитонов телсез мөселманнарны үзләренең телсезлекләреннән коткару өчен мөселманнарга махсус телсезләр әлифбасы чыгарды. Харитоновны бу эше өчен тәбрик итмәскә ярамый.
Ул бу хакта гына түгел, мөселман хәрефләрен гүзәлләтү хакында да мөселманнарга бик зур хезмәтләр күрсәтте. Әүвәлдә мөселман хәрефләре Русиядә фәкать ике генә төрле иде. Харитонов үзенең мәтбагасын ачканнан башлап бу көнгә кадәр ислам мәтбагаларын баету өчен бик күп мәшәкатьләр чикте һәм бу көндә мөселманнарга бик күп гүзәл хәрефләр һәдия кыйлды.
Харитонов телсезләр өчен булган бу яңа хәрефләрен Истанбул һәм Мисырга да җибәрмәкче була. Төркиядә бу көнгә кадәр телсезләр өчен хосусый мәктәпләрнең булып-булмавы хакында безнең хәбәремез юк. Әгәр дә анда бундый мәктәпләр бу көнгә кадәр булмаган булса, «Харитон бабай»ның бу әлифбасы, һичшиксез, анларга ярдәм итәчәктер. Бу эше өчен «Харитон бабай»га чын күңелемездән тәшәккер итәмез.
2) «Африка харитасы». Бу көнгә кадәр Казанда мөселманча хариталарны иң яхшы итеп чыгаручы «Милләт» китапханәсе идеке мәгълүмдер. Аның бу көнгә кадәр чыгарган көррәи мөсаттаха, Яурупа, Азия хариталары һәркем каршында мәкъбуль булган иде. Соңгы көннәрдә мәзкүр китапханә Африка харитасын мәйданга куйды. Харита зур формада, бик ачык хәрефләр илә язылган, һәрбер мәмләкәт бик ачык буяулар илә бүленгән. Мөселман мәктәпләренә һәм ислам китапханәләренә мәзкүр хаританы алырга тәүсыя итәмез.

Хәрефләр исляхы

«Тәрҗеман» гәзитәсенең соңгы номерларыннан берсендә хәрефләр исляхыннан бәхәс итеп, үзләренең бу фикергә иштиракь итмәгәнлекләрен бәян итә: «Әле хәзергә бу мәсьәләне кузгатуның заманы килеп җитмәгән, безнеңчә, бу мәсьәләдән бөтенләй бәхәс итмәскә тиеш. Инглизләр илә япуннарның тәрәккъыйләренә хәрефләренең читенлеге уңайсызлык кыйлмады», – ди.
Өстән генә караганда «Тәрҗеман»ның бу сүзләре дөрест шикелле күренә. Әмма эшне яхшылабрак тәфтиш итеп каралса, хәл бөтенләй башкачадыр. Әүвәлән, инглизләрнең

хәрефләре безнеке кадәр күп һәм читен түгел. Шул сәбәптән аның илә игътиразга урын юк. Саният, япуннарның тәрәккъыйләре үз хоруфатлары илә укып түгелдер. Япуниядә фәннәрнең әксәре инглиз лисанында укыла. Димәк, япуннарның тәрәккъыйләре үзләренең озын вә гайре мөтәнаһи әлифбалары илә түгел, бәлки кыска инглиз хоруфаты иләдер. Салисән, «Тәрҗеман»: «Безнең китабымыз Коръән иске гарәби хоруфат илә язылган булганлыктан, иске хоруфат безнең өчен лязимдер», – ди. «Тәрҗеман» бу фикерендә хаклыдыр. Ләкин исляхчылар хоруфатны билкөллия тәбдил итү тарафында түгелләрдер. Бунларның мәкъсудлары иске гарәп хоруфатына мөшабиһ һәм якын сурәттә җиңгел һәм аз хоруфат вөҗүдкә китереп сәһүләт ясаудыр. Ике йөз ел буннан мөкаддәмдә русларда славян хәрефләре мөстәгъмәл иде. Петр Великий аның урынына гражданский хәрефләр кертте1. Аннан руслар һич зарар күрмәделәр. Бәлки файда гына иттеләр. Славян хәрефләре дә дини бер хәреф уларак мәйданда калды. Шул сәбәпләргә бинаән, хәрефләрне ислях итүгә каршы торырга урын юктыр. Хәрефләрне ислях итү илә мәшгуль кешеләр, иҗтиһад итеп, эшләрен мәйданга куйсыннар, әгәр мәгъкуль күрелмәсә, аннан соң да рәд кыйлырга вакыт табылыр.

Бакча-шәһәр

Шәһәрләрдә йортлар тыгыз, урамнар тар, һавалар начар була. Шул сәбәпле шәһәр халкы сәламәтлек җәһәтеннән карья әһалисенә караганда күп дәрәҗәдә зәгыйфь булалар. Шәһәр халкы арасында үлем-җитемнәр дә карьялардагыдан күп артык була. Шәһәрләрдә табиблар, санитарлар, шифаханәләр карьяләргә караганда ничә вә ничә өлеш күп булса да, анлар һаман да хасталыкларны җиңеп бетерә алмыйлар. Авыру һәм үлем карьяләргә караганда шәһәрләрдә күбрәк була. Бунын сәбәбе һаваларның начарлыгы, тора торган өйләрнең тыгызлыгыдыр. Мисал өчен Казан шәһәрен генә алыйк. Казан шәһәрендә, хосусән мөселманнар тора торган тарафның һавасы һич кабул итмәслек дәрәҗәдә начардыр. Бер тарафтан сасы Болак, чергән Кабан күле шәһәрнең һавасын бозган шикелле, икенче тарафтан ике бистә арасындагы сазлыклар Казанның һавасын тәмам бәрбад итәләр. Аның өстенә бөтен Казанның нәҗасәтләр вә тиресләр түгә торган урыннары да шул мөселманнар тора торган тарафларда икәнлеген игътибарга алсак, бу тарафларда инсаннар ничек тәхәммел кыйлып торалар икән дә ничек үлмичә яши алалар икән дип хәтергә киләдер. Җәй көннәрендә, хосусән эссе көннәрдә, мөселман мәхәлләләренең һавасы шулкадәр бозыла, ул тарафлар шулкадәр сасы исләр илә туладыр ки, бу сасылыкның эчендә корт шикелле яшәп үсмәгән кешеләр тын ала алмыйча буылып үләргә җитәрлек дәрәҗәдә буладыр. Әүвәлге заманнарда шәһәрләр бик тыгыз итеп ясалганнар. Бунын сәбәбе һәркем мәркәзгә, базарга якын булуны теләгәнлектән килмештер. Һәркем үзенең базарга һәм мәркәзгә якын булуын теләгән, шул сәбәптән анлар бер җиргә тыгылганнар һәм бер җиргә килеп укмашканнар. Хәзерге заманда, хосусән хәзерге электрик гасырында, бу рәвешчә укмашуга лөзүм калмады. Хәзерге заманда өч, биш тиен мәсариф илә озак җирләрдән трамвайларга утырып мәркәзгә килү мөмкиндер. Шунлыктан хәзер халыкка начар һавалы урыннарга оешып торуны бетерергә вакыт килеп җитәдер. Чит мәмләкәтләрдә инде халыклар күптән сасы һавалы тыгыз шәһәрләрдән читләргә качып китә башладылар. Шәһәрнең мәркәзеннән никадәр читкә кителсә, һава шулкадәр яхшы, сәламәтлек өчен файдалы була бара. Заграницада урта хәллерәк кешеләр, шәһәрдән читкә китеп, арзанлы урыннарда, агачлык вә яшеллекләр арасында һәм яхшы һавалы җирләрдә йортлар салып, шунда икамәт кыйла башладылар. Көннән-көн тәрәккъый итеп килмәктә улан электрик трамвайлары, халык читкә таралган саен, анларның артларыннан бара башлады. Хәзерге көндә шәһәрдән тышка таба унар, унбишәр чакрым озынлыгында сузылган трамвай сызыклары Яурупа шәһәрләре тирәсендә бик күптер. Шәһәрдән читтә торучыларның әксәре хезмәткәр адәмнәр вә һөнәрмәндләр булалар. Бунлар, кышын-җәен шәһәрдән читтә яхшы һавалы урыннарда яшәп, үзләренең сәламәтлекләрен саклыйлар. Көндезен трамвай илә шәһәргә эшкә килеп,

кичләрдә үзләренең дача шикелле яхшы һавалы фатирларында, бакчалык вә агачлыклар эчендә яшиләр.
Заграницадан үрнәк алып, безнең Русиядә дә шул рәвештә шәһәрдән читтә бакча-шәһәрләр ясау фикерләре туа башлады. Озакламыйча бундый фикерләр безнең Казан шәһәре тирәсенә дә килеп җитәр. Бундый вакытта безнең начар һавада торучы мөселманнар гафил булып калмаска тиеш. Казан тирәсендә бундый бакча-шәһәр ясарга яраклы яхшы һавалы җирләр аз түгелдер.
Аңлы вә фикерле мөселманнардан бәгъзе кешеләрнең эшкә хәзердән үк тәшәббес итә башлаганлыклары күренәдер. Мәсәлән, Казаннан ерак түгел Кизический слободаның[1] аргы башында удел идарәсе милкендә зур бер урман бар. Удел идарәсе бу урманны, участкаларга бүлеп, йорт салып урынлашу өчен иҗарәгә бирә башлады. Өч-дүрт ел чамасында гына башланган бу эш хәзерге көндә хили тәрәкъкый итеп бара. Мәзкүр җирләр хәзерге көндә бик гүзәл дачалар кыяфәтенә керде. Бик күп кешеләр, мәзкүр урманнан җирләр алып, урман эченә йортлар салып яши башладылар. Шәһәрдән ераклык сәбәпле, әүвәлдә бу урыннардан җәяүләп шәһәргә килү уңайсызрак иде. Хәзер ул уңайсызлыклар да бетеп бара. Ул тарафларда торучыларның күплеген игътибарга алып, бер кеше, мәзкүр тарафларга арзан хак илә кеше ташу өчен, дилижанс арбалары йөртергә шәһәрдән рөхсәт алды. Әгәр дә йөрүче күбәйсә, тиздән ул тарафларга трамвай хутының сузылуы да ихтималдыр. Бер бу гына түгел, Казан этрафында бундый бакча ясау өчен муафикъ булган урыннар күптер.

## Мөселман рәссам

Буннан ике ел мөкаддәмдә Казанның мәшһүр мәтбагаларыннан И.Н.Харитоновның мәтбага эшендә хезмәт итә башлавына кырык ел тулу мөнәсәбәте илә ясалган юбилейда[1] Харитоновның намен таәбид итү өчен Казанның сәнаигы нәфисә мәктәбендә мөселманнардан бер шәкертне тәрбия кыйлырга карар биргәннәр иде. Шул вакытта мөселман матбугаты, мәзкүр мәктәптә бер мөселман шәкертен укыту өчен, стипендия ясарга да карар биргән иде. «Йолдыз» идарәсе шул вакытта, мәзкүр стипендиягә әсас уларак, илле сум акча тәгъйин итте. Аның артыннан ук «Вакыт» гәзитәсе идарәсе тарафыннан, мәзкүр сумага гыйлавә уларак, илле сум килде. Аның өстенә Казандагы көтебханәләрдән «Сабах» көтебханәсе үз тарафыннан «Мәтбагачылык тарихы» исемендә бер китап нәшер итеп, аның файдасын мәзкүр сумага катыштырырга вәгъдә бирде. Шул заманнан бирле берничә еллар узып китте, мәзкүр стипендиягә җитәрлек акча да җыелмады. Аның өстенә Казанның сәнаигы нәфисә мәктәбенә керергә теләгән бер мөселман да күренмәде. Шулай итеп, гомерләр узганнан-уза барды. Ниһаять, быел, 1912 елда гына, харикыльгадә бер вакыйга вөҗүдкә килде.
Быел, август аеның ахырында, Оренбург губернасы Верхний Урал өязе Суер авылының катай башкортларыннан Сабит Габделбасыйр угълы Яхшыбаев исемендә егерме ике яшьлек яшь бер башкорт Казанга килеп чыкты һәм үзенең сәнаигы нәфисә мәктәбенә керергә ирадәсе барлыгын игълан итте. Бу башкорт, мөселманча ибтидаи мәктәпне тәмам иткәннән соң, городской школага кереп укыган. Анда ике классны тәмам иткән. Мәктәптә укыган заманнарында һәрвакыт рәсем дәресләрендә беренче дәрәҗәне алып килгән. Соңра мәзкүр шәкерт, мәктәптән чыгып, Оренбург губернасы Авзяно-Петровский заводында, Тамяно-Танговорский товариществосының алтын приискасында машинист могавине булып хезмәт итә башлаган. Хәзерге заманда ушбу егет мөселман зыялыларыннан бер кешенең дәляләте илә Казанга килгән[2]. Өченчекөн без мәзкүр егетне Казанның сәнаигы нәфисә мәктәбенә алып бардык. Аны мәзкүр мәктәпкә шәкерт итеп кайд кыйлмакчы булдык. Ләкин, безнең ирадәмезә каршы буларак, анда приемнар беткән икән. Мәктәпнең канцеляриясенә Сабит әфәнденең эшләгән рәсемнәрен күрсәттек. Мәктәп идарәсенең әгъзалары, җыелып, Сабит әфәнденең эшләгәнен карадылар һәм аның эшләгән эшләренә хәйран калдылар. «Хәзер бездә вакансия беткән, шәкертләр алынган. Әгәр дә сез алданрак килгән булсаңыз, без сезне һичбер сүз әйтмичә мәктәпкә алган булыр идек, ләкин сез

соңга калгансыз икән. Шулай да булса сез хәзерге көндә безнең якшәмбе дәресләренә бушлай дәвам итеп торыңыз, һәм без сезгә комплект хариҗендә уларак мәктәп дәресләренә дәвам итәргә дә ихтыяр бирермез. Соңра, 1913 елның башында, мәктәптән чыгачак шәкертләр бар. Шунлар урынына сезне алырмыз», – дип вәгъдә бирделәр. Анларның сүзләренә ышанып, Сабит әфәнде хәзер Казанда калды. Сәнаигы нәфисә мәктәбенең якшәмбе дәресләренә дәвам итәчәк. Ләкин Сабит әфәнде җәнабләре бик фәкыйрь һәм иганәгә мохтаҗ бер адәмдер. Әгәр дә безнең милләт карендәшләремездән шундый сәнгатькә игътибар итүче кешеләр булса, Сабит әфәндегә аз гына булса да ярдәм итәргә тиештер.
Сабит әфәнде исеменә күндерелгән иганәләр «Йолдыз» идарәсендә мәгалмәмнүниять кабул ителер. Сабит әфәнденең эшләгән рәсемнәрен «Йолдыз» идарәсендә һәрвакыт күрергә мөмкин.

Үз хәлемез
Безнең иң кайгыртырга тиешле булган мәсьәләмез – уку мәсьәләседер. Ел саен, көз җитү илә, уку эшләренә күз төшермичә һәм аннан бәхәс итмичә узу мөмкин түгел.
Узган ел, ачлык булу сәбәпле, мөселманнар арасында уку һәм укыту эшләренә әһәмият бирелмәде. Бик күп мәктәпләр ачылмыйча калды. Ачылган мәктәпләрнең күбесендә йөз, хәтта йөз илле баланы имамнар үзләре генә укытып чыктылар. Чөнки мөгаллим алырга һәм аны тәрбия итәргә акча һәм азык юк иде.
Быел, шөкерләр булсын, һәр җирдә игеннәр яхшы булды. Халыкларның ихтыяҗлары бераз сүнде. Быел һәр җирдә уку эшләренә узган елдагыдан артыграк әһәмият бирер төсле күренәләр. Күп җирләрдән мөгаллимнәр сорап мәктүбләр килә. Мөселманнар арасында мәктәпләр елдан-ел арта бара. Елдан-ел мөгаллимнәргә ихтыяҗ күбәя бара. Ихтыяҗ зураюга карап, мөгаллимнәрнең дә саннары арта барса, бик яхшы булыр иде. Ләкин ул тарафтан алга барган эшләр күрелми. Мөфти хәзрәтнең юбилее шәрәфенә дарел-мөгаллимин вә дарелмөгаллимат ачарга карар бирелгән иде1. Хәтта бәгъзе кешеләр берникадәр иганәләр вәгъдә кыйлганнар иде. Бу вакыйгагә инде ел ярым кадәр заман узып китте. Шулкадәр озак заман эчендә дарелмөгаллиминне вөҗүдкә чыгару өчен ясалган комитетның бер хәрәкәте дә күренмәде диелсә, җаиздер. Комитет ел ярым эчендә өч-дүрт мәртәбә мөзакәрә мәҗлесе ясаудан артык бер эш тә эшләмәде. Комитетка әгъза булып сайланган кешеләрнең милләт эшенә бу кадәр салкын карауларына һичбер мәгънә бирер хәл юк. Әгәр дә эшләр шул рәвештә акрынлык илә барса, дарелмөгаллимин исемендәге нәрсә яңадан ун елларсыз вөҗүдкә килмәс. Башка милләтләр укып, елдан-ел тәрәкъкый итеп барганда, безгә һаман да артта калырга туры килер. Бөтен дөнья сәвадлы булган заманда бер безнең халкыбыз гына караңгылыкта калыр. Бу эшләр бер дә дөньяда торуны уйлаган кешеләр өчен гафу ителерлек эш түгелдер. Дарелмөгаллимин эшен үз арамыздан сайланган комитетымыз ел ярым, хәтта ике ел яшел пустау астында яткырса, бичара ул мәсьәлә башка яшел пустау астыннан кайчан котылып чыгар?..
Үз хәлемездән
(Укучыларымызга ярдәм)

Арамызда гали мәктәпләр бетергән кешеләремез күбәймиче торып, башка милләтләр илә бер дәрәҗәдә була алмаячагымыз көн кеби заһир бер эштер, һәм бу хәкыйкать һәркаюмызга күптән бирле мәгълүм бер мәсьәләдер. Укыган кешеләремез күп булмаганда, уку җәһәтеннән башка милләтләрне куып җитмәгәндә, безнең хокукта анлар илә бер дәрәҗәгә барып җитешә алмаячагымызны да һәркем белә. Бездә, кайсы гына бер эшкә килеп тотынсак та, арада укыган кешемезнең юклыгы, укыган кешеләргә ихтыяҗ күзгә күренәдер. Мәсәлән, сезгә Думага сайлау мәсьәләсен генә мисал итеп күрсәтим. Һәркем: «Думага сайлаганда, һәрнәрсәдән хәбәрдар, мәгърифәтле, мәгълүматлы, зыялы һәм Дума мөнбәренә чыгып, милләтемезнең ихтыяҗын мәҗлескә аңлата алырлык кеше сайларга

кирәк», – дип сөйли, ләкин эзли башлагач, кайда сайлау, сайламыйча гына тотып күрсәтергә ике-өч кеше табып булмый, һәм шуның аркасында, мәсәлән, Казан шикелле зур Казан мөселманнары депутатсыз кала. Руслар безгә урын биргәндә дә, без кеше таба алмыйммыз. (Бу сүзнең хаклыгында шөбһә булмаса кирәк, чөнки табып булган булса иде, бер урын бирә торып, бер кеше дә сайланмый калмас иде.) Мин буны мисал өчен генә әйтәм. Бундый мөселманнан депутат сайлый алмый калган губерналар бер без генә түгел, Сембер, Әстерхан, Кырым кеби җирләрдән дә сайлана алмады.
Бездә хәл шул рәвешчә. Укыган кешегә ихтыяҗ бик зур: адвокаты кирәк булган шикелле, мөселманнан табибы да кирәк, мөһәндисе дә кирәк, архитекторы да кирәк, агрономы да кирәк, байтары да, учителе дә вә гайреләре дә кирәк. Мөселманнар һәр җирдә үз телләрен белгән, мөтәхәссыйс, укыган вә зыялы кешеләргә мохтаҗлар, бунларның һәммәсенең кирәклекләрен белә торып, без уку эшләренә әһәмият бирмимез. Укучыларга ярдәм итмимез. Укучыларның иң күп кыйсьме истикъбальләре тәэмин ителмәгән, укырга үзенең сумасы җитәр-җитмәс яхуд бөтенләй сумалары юк кешеләр буладыр. Әлхасыйль, укучыларның әксәре тар куллы кешеләрдер. Шул сәбәптән ярдәмгә иң лаек вә мөстәхикъ булган кешеләр укучылардыр.
Мөселманнар икамәт кыйла торган шәһәрләр арасында иң зурысы, укуханәләре күплек җәһәтеннән иң беренчесе – Казан шәһәредер. Шәһәрдә генә түгел, укуханәләренең һәрберсендә русларның вә башка милләтләрнең үз мәктәпләрендә укучы мохтаҗ шәкертләргә ярдәм өчен ачылган вә ясалган җәмгыятьләре вә ул җәмгыятьләрнең үзләренә махсус кассалары бар. Мәктәптә укучы шәкертләрдән берсе мохтаҗлыкка төшсә, аңа шул кассадан ярдәм бирәләр һәм аның өчен уку бәдәлләрен түлиләр. Бездә исә укучы шәкертләргә ярдәм итү өчен нә бер җәмгыять бар, нә бер касса бар.
Укучыларга ярдәм итү өчен күптән түгел Оренбургта бер җәмгыять ясалып, рәсми сурәттә ачылды һәм эшкә керește. Оренбургта хөкүмәт мәктәпләрендә укучы шәкертләр нәкадәр аз булса да, оренбурглылар бундый бер җәмгыятьнең лөзүмен хис кыйлдылар. Бундый хосусларда оренбурглылар һаман бездән алга чыга баралар. Без һаман артка кала барамыз. Үземез башлап эшне вөҗүдкә чыгарырга кулымыздан килми икән, һич булмаганда, күршеләремездән гыйбрәт алып, анларга ияргергә кирәк иде. Анларның хәзерге көндә уставлары хәзер губернатор тарафыннан тасдикъ ителгән. Күңел куеп эшләгән тәкъдирдә, бу эш безнең өчен дә бик мөмкин бер эштер. Яшьләремез, бу эшләрне игътибарга алып, бераз хәрәкәттә булынсалар, бик гүзәл булыр иде.

Мәрхүм Әхмәд Мидхәд әфәнде

Төркиянең, бәлки дә бөтен ислам галәменең иң зур мөхәррир вә әдипләреннән һәм дә философларыннан Әхмәд Мидхәд әфәнде шимбә көн, 15 декабрь кич, ахшамга бер сәгать калганда вафат итте. Якшәнбә көн, 16 декабрьдә, өйләдән соң Солтан Фатих җәмигъсендәге төрбәләрнең берсе янына дәфен иттеләр. (Бу мәкъбәрәләргә фәкать зур галимнәр генә, падишаһтан хосусый изен илә генә дәфен ителәләр.)
Әхмәд Мидхәд әфәнде шул көн дарелшәфәкада булган бер мәҗлестә рәис булып, мәҗлесне дәвам иттергән. Мәҗлес тәмам булып, халык таралгач, үзендә бер кәефсезлек хис кыйлган. Доктор чакырып китергәннәр. Доктор, никадәр иҗтиһад кыйлса да, бичараны әҗәлдән коткара алмаган.
Әхмәд Мидхәд әфәнде унсигез яшендә мөхәррирлеккә башлаган. Җитмеш еллык гомере эчендә һәртөрле фәннәр вә фәлсәфәләргә даир ничә вә ничә җилдләр илә китаплар язган. Бик күп мәэмүриятләрдә булган. Күп мәктәпләрдә мөгаллимлек кыйлган. Бик күп җәмгыять вә мөәссәсәләрдә рәис булган. Ахыр гомерендә дарелфөнүндә иң яхшы мөдәррис иде. Бик күп кешеләр аңа шәкерт иделәр. Ләкин, мәгаттәэссеф, җеназасында кеше бик аз иде. Хәтта, ике йөздән зиядә дарелшәфәка таләбәләрен хисапка алмасак, бик күп булса, бөтенләе егерме-егерме биш кадәр адәм вар иде, диләр. Әгәр Мидхәд әфәнде шикелле бөек бер зат вафат итсә, башка милләтләр дөньяны кубарырлар, җеназасына ничә

вә ничә мең халык җыелыр иде. Төрекләрнең үзләренең бундый иң газизә бер кешеләренә бу рәвешчә илтифатсыз кыйланулары шаян тәәссефтер. Хәтта мөшар иләйһинең кайда дәфен иделәчәгеннән түгел, вафатыннан хәбәр алган кешеләргә дә аз очрадым. Кайда дәфен иделәчәген белү вә җеназасында хазир булу өчен мөшар иләйһинең мәхәле икамәте улган Бәккүзгә киттем. Мин шул тирәдә дәфен ителә торгандыр дип фараз кыйлган идем. Фатихта дәфен ителәчәк, диделәр. Бәккүзгә, аннан пароход илә күпергә, аннан да Фатих җәмигъсенә барганчы, ике ярым сәгатьтән артык вакыт узды. Мин Фатихка барып җиткәнче, дәфен кыйлып, халык таралган иде.

Зур кешеләргә илтифатсызлык бер Мидхәд әфәнде хакында гына түгел, башкалар хакында да шулай ук. Мәсәлән, моннан ике ай әүвәл монастырлы Исмәгыйль Хаккый җәнабләре вафат иткән. Бу зате гали бөтен ислам галәменә исеме танылган мөхтәрәм бер зат иде, аның кеби гүзәл бер вагыйз бөтен Төркия мәмләкәтендә юк иде. Галәмдә яд тулы сахибе иде. Язган тәфсире һәркем гыйндендә мәкъбуль иде. Көнһтә Истанбулның иң зур мәктәпләрендә мөгаллим иде. Сөйләүләренә караганда, аның да җеназасында әкърабларыннан башка һичкем булмаган.

## Истанбул мәктүбләре

### I

### Истанбул юлыннан

Русиянең йөрәге тәгъбир ителгән Мәскәү шәһәренә килеп җиттем. Бунда килеп җиткәнче язарлык дәрәҗәдә әһәмиятле нәрсәләр күренмәде. Егерме вагоннан гыйбарәт озын поездда мөселманнардан бары ике генә кеше булганлыкны язмасаң, башка язарлык нәрсә күренми. Бу эш безнең мөселманнарның хәрәкәтсез ята торган халык икәнлеген бик ачык күрсәтәдер. Поезддагы башка халык гомумән руслардан гыйбарәт иде.

Казаннан китеп Идел аркылы чыккан заманда тимер юл күперен күрергә никадәр иҗтиһад итсәм дә, кич караңгы булган сәбәпле, күрү мөмкин булмады. Тимер юл мәэмүрләренең сөйләүләренә караганда, күпер көз көненә кадәр өлгерә алмаячак икән. Казаннан ераклашкан саен, Русиянең йөрәгенә якынлашканлык хис кыйлына. Юлда һичбер мөселман очрамый.

Мәскәүдә туктап торган сәгатьләрдән истифадә итеп, күп җирләрен карап йөрдем. Гәрчә якшәнбә булу мөнәсәбәте илә магазиннар ябык исә дә, һәр җирдә хәят һәм рух күренә, һәр дәкыйка саен төрле тарафларга чабып йөри торган трамвайларның эчләре халык илә тулы. Юлда, Арзамас стансиясенә килеп җиткәнгә кадәр, матбугаттан аерылып торырга тугъры килде. Вокзалларның һичберсендә дә гәзитәләр илә сату ителми икән. Фәкать Арзамаска килеп җиткәннән соң гына гәзитә алырга муаффәкъ булдым. Бу гәзитәләрдә Төркия илә Балкан хөкүмәтләре арасында вакытлы мосаләхә булганлык язылган иде. Буны күргәч, минем Истанбулга баруым габәс бер эш булып чыкмаса ярар иде дип уйласам да, солых соңында да әле язарлык вакыйгаләр күп табылыр, сугыш заманында булып узган картиналар да гәзитә укучыларын озак заманнарга канәгатьләндерергә, шаять, җитәр әле дип, күңелемне тынычландырдым.

Мәскәүдә хәят – фәкать рус хәятыдыр. Мөселманнардан һич нам вә нишан юк. Шаулап һәм гөрләп торган Мәскәү урамнарында бер-ике халатчы һәм төенчек күтәреп йөреп сату итүче мишәрләрдән башка кешеләр күренми.

### II

Мәскәүдә берничә сәгатьләр калып, шәһәрне бераз тамаша кыйлганнан соң, 27 ноябрьдә Одессага килеп җитдем. Одессага килеп җиткәнче, язарлык әһәмиятле хәбәрләр булмады. Одессага килгәч, бәгъзе бер кешеләр илә сөйләшеп, Истанбул вә Болгария хакында хәбәрләр алдым.

Иң әүвәл Төркиядә холераның булып-булмаганлыгы хакында сораштым.

– Истанбулда холерадан куркырлык бернәрсә юк. Бөтен гаскәр илә шәһәр халкы арасында кырык-илле кешенең холера илә авыруын Истанбул кеби ике миллионлы халык өчен һәм ничә йөз меңле гаскәр өчен бу кадәр микъдар күп нәрсә түгелдер, – дип җавап бирделәр.
Сөйләнгән сүзләргә караганда, холераның иң куәтле җире Болгария гаскәрләре арасында, ләкин аны яшерәләр икән. Одессада нәшер ителә торган «Южная мысль» гәзитәсе һәм «Южная неделя» журналында Гали бәк Тамарин исемендә польшалы бер мөселман мөхәррирлек итә икән. Бу әфәнде илә күрешеп, Төркия һәм Русия мөселманнары хакында бераз мөзакәрәдә булындым. Бу әфәнде дә Төркия тугърысында Болгария мәнбәгъләреннән чыккан хәбәрләрнең зур итеп язылганлыгын тасдикъ итте, һәм хәкыйкатьтә эшнең анлар сөйләгәнчә булмаганлыгын бәян кыйлды.
Тамарин Русия мөселманнарының истикъбальләренә өмид илә карый:
– Русия мөселманнарында хәзер укуга әһәмият күренә. Укуга һәвәс тәрәккъкыйнең беренче сәбәпләреннән идеке һәркемнең мәгълүмедер, – диде.
Паспортны кайд кыйлырга барганда, Төркия консулы Гатуф бәк илә күрешеп:
– Бер гәзитә мөхбиренең Сездән ишетеп гәнеж төрекләр хакында сөйләгән сүзләре хакмыдыр? Сез, вакыйган да, Төркияне бәрбад итүчеләр «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасе әгъзаларыдыр мәфһүмендә сүз сөйләдеңезме? – дидем.
– Минем андый мәфһүмдә сүз сөйләгәнем юк. Безнең һәлакәтемезгә, әгәр дә уку һәм исляхат илә шөгыльләнмәсәк, җәһаләтемез сәбәп булачактыр, – диде.
Максудым Одессадан әүвәл Болгариягә, аннан Истанбулга китү иде исә дә, муаффәкъ була алмадым. Варна порты ябык булганлыктан, һичбер пароход анда мал да һәм юлчы да алмый икән. Шул сәбәптән тугърыдан-тугъры Истанбулга китәргә мәҗбүр булдым.
Одессада «Һилал әхмәр»дә хезмәт итү өчен Петербургтан бара торган Габдулла әфәнде илә күрешкән идем. Мәзкүр әфәнде илә пәнҗешәмбе көн русский обществоның «Афон» исемле бик зур пароходы илә Истанбулга таба карап сәфәр кыйлдык.
Пароход алты сәгать кадәр сәфәр кыйлгач, чыбыксыз телеграм илә хәбәр итеп, киредән Одессага кайтырга әмер булды. Бу хәбәрне ишетеп, юлчылар тәшвишкә төшә башладылар. Ләкин соңыннан мәгълүм булды ки, бу әмер безгә түгел, бәлки бездән артта килә торган бер пароходка икән. Ул пароходта чыбыксыз телеграм булмаганлыктан, безнең пароходка хәбәр биргәннәр икән. Мәзкүр пароход та Истанбулга барачак иде. Шул сәбәптән аның кире кайтуында нинди булса да бер әһәмият юк микән дип, капитан мәгавинен күреп сораштым.
– Безгә сәбәбен белдермәделәр. Без ни кушсалар шуны эшләргә мәҗбүрмез. Сәбәбен тикшерергә безнең хакымыз юк, – диде.
Соңра капитан илә ике арада ошбу түбәндәге мөзакәрәләр булды.
Мин:
– Бу ел Хиҗазга баручылар күпме булды?
Ул:
– Узган елдагыннан биш мең чамасы артыграк булды. Узган ел хаҗ мәүсиме килер алдыннан Төркия вә Италия мәхарәбәсе башланган иде, азрак булуга шул сәбәп булган булса кирәк. Сугышның дәвам итүе безнең өчен уңайсызлык кыйла. Мәсәлән, бу пароходка беренче вә икенче классларга – йөз егерме, өченче класска ике мең кеше сыя. Хәзер исә илледән артык юлчы юк.
Мин:
– Сугыш заманында сезнең общество пароходлары гаскәр ташу өчен Төркиягә хезмәт кыйлмадылармы?
Ул:
– Юк, хәзер анларның гаскәр ташу өчен үз пароходлары да җитәрлек.
Мин:
– Сугыш башында төрекләрнең гаскәр ташырга пароходлары юк дип язганнар иде бит!
Ул:
– Сугыш вакытында андый ялганнар күп языла. Барсына да ышанырга ярамый.

Пароходта кешеләрнең бер кыйсеме Истанбулга, калганнары Измир, Греция вә Искәндәриягә бара торган халыклар иде. Истанбулга баручылар арасында Петербургтан Истанбулга «Һилал әхмәр»гә хезмәт итәр өчен бара торган бер фельдшерица яһүдия дә бар иде.
Истанбулга барып җиткәнче әһәмиятле бер вакыйга дә булмады. Бер тарафтан Анатолий, икенче тарафтан Рум иле сахилләре күренә башлагач та, палубага чыктым. Күзем Рум иле тарафына тегәлде. Ул җирләр һәр ике тарафның гаскәрләренең бер-берсенә каршы күптән түгел гаять шиддәт илә мөхарәбә кыйлган Чаталҗадан ерак түгел иде. Бәлки, бу тирәләрдә гаскәр чатырларын яки Төркия флотын күрермен дип, бик тегәлеп карый башладым. Бер җирдә ерактан төтеннәр күренсә дә, ул да, якынрак баргач, гади бер сәүдә пароходы булып чыкты. Әтрафта сөкүнәттән башка һичбер нәрсә юк иде. Истанбул бугазыннан керә башладык. Бугазның күреп туя алмаслык гүзәл мәнзаралары бер-бер артлы күз алдыннан уза башлады. Һаман да һәр җирдә сөкүнәт. Фәкать бугаз эченә дошман гаскәре керә башласа, анларны батырыр өчен хәзерләнеп куелган дәһшәтле туплар гына ике тарафларда күренә. Бундый сөкүнәтне күргәннән соң, әллә юк исә Төркиянең эшкә яраклы һәммә кешесе сугыш мәйданына китеп бетеп, шәһәрдә фәкать картлар илә балалар гына калдылар микән дигән фикер хәтергә килде. Ләкин киткән саен манзара алмашына барды. Барган саен халык күбәя, арлы-бирле чабып йөри торган пароходлар арта бара. Сабикъ солтан Габделхәмиднең мәхбүс булып ята торган бәкләр бәге сараен сул тарафта калдырып киттек. Буны күргәч, кем белсен, бәлки, Габделхәмид бугаздан узган пароходтагы кешеләрне тәрәзәдән күреп, анларның иркенлектә булуларына көнләшеп кала торгандыр, дидем. Аннан узып бераз баргач, әүвәлдә Истанбулның иң гүзәл һәм кыйммәтле сарае вә Төркиянең Беренче Мәҗлес Мәбгусаны булган һәм янгын сәбәпле хәрабә хәленә килгән Чараган сараен күрдек. Сарай тәмам вәйран булып ята.
Бу җирләргә җиткәч, алга таба бару кыен була башлады. Пароход тәмам акрынлады. Истанбулда үз тәбагаләрен сакларга килгән чит мәмләкәт крейсерларын берәм-берәм тамаша кыйлып, Рихтем буена килдек. Пароход туктап җиткәнче, Рихтем буендагы халыкны тамаша кыйла башладым. Рихтемдә халыкның күплеген һич тәгъриф итеп бетерү мөмкин түгел. Халык тәмам дәрья шикелле дулкынлана, кырмыска шикелле кайный иде. Халыкның һичберсенең йөзендә кайгы галәмәте юк, һәркаюсы шат. Күптән түгел, буннан егерме көннәр генә мөкаддәм, бу тирәләрдә дәһшәтле сугышлар булгандыр дип уйларлык та түгел. Һәркаюсы яхшы, тәмиз киенгәннәр. Гүяки бәйрәм итәләр.
Рихтемгә аяк басмас борын ук, яңа идарә илә иске идарәне чагыштыра башладым. Истанбулга берничә ел мөкаддәм килешемдә, иске идарә заманында, пароход килеп туктар-туктамас, берникадәр тупас һәм гаять начар киенгән хәммаллар килеп, «мин алып китәм» дә «мин илтәм» дип тарткалашып, миңа һич сүз сөйләргә ихтыяр бирмәгәннәр иде. Бу дәфга, өсте-башы пакь, зарарсыз киенгән бер кеше килеп, үзенең номерын күрсәтте. Нәрсәләремне алып таможняга китерде, анда нәрсәләремне таможняга күрсәтеп, номерга илтеп куйды. Гарәбә илә китәргә эстәдем исә дә, якында гарәбә вә фаэтон таба алмадык. Чөнки Истанбулдагы атларның күбесе гаскәргә алынып беткән. Хәтта, атлары гаскәргә алынган булганлыктан, шәһәрдә трамвайлар да йөрми.
Таможнядагы мәэмүрләрнең мөгамәләләре башкарган, нәзакәт арткан. Номерга барып төшкәнче һәрнәрсәгә дикъкать итә бардым. Иң әүвәл күзгә күренгән нәрсә – гаскәрләрнең кыяфәтләре булды. Хәзер гаскәр һәркаюсы, Яурупаның башка дәүләтләрендәге шикелле, сорыга маил яшел төстә киемнәр киенгәннәр, башларында да әүвәлдәге кызыл фәс урынына фәскә охшатып тегелгән яшелгә маил бүрекләр. Әүвәлдәгегә нисбәт гаскәрләрнең киемнәре дә яхшырак.
Иске заманда үтәргә-сүтәргә юл бирмичә, тирә-якны камап ала торган урам этләреннән һичбер нам вә нишан юк.
Әүвәлдә таяк яки аяк сындыра торган начар күпер урынына хәзер тәмиз һәм гүзәл күпер салынган. Тышкы яктан караштa Истанбулда үзгәреш күп, хасыйле, Истанбулның заһири күренеше миңа начар тәэсир калдырмады.

Номерга барып төшеп урынлашкач та, беренче эш хәбәр җыю мәсьәләсе булды. Истанбулга кичкырын гына килгән булганлыктан һәм Истанбулда идарәи горфия (военный положения) булганлыктан, кичләрдә чыгып йөрү мөмкин булмадыкыннан, күп хәбәр җыю мөмкин булмады. Шулай да күргән кешеләрдән бәгъзе бер хәбәрләр алдым. Мәсәлән, Истанбулның зур мәктәпләреннән һәркаюсында укулар тукталган. Анлар һәммәсе хастаханәгә әйләндерелгәннәр. Зур мәсҗедләрдән Айя Суфия, Солтан Әхмәд, Баязид, Солтан Фатыйх җәмигъләры кеби мәсҗедләрнең һәркаюсына гаскәрләр куелган. Бунларның бәгъзесенә Кырык Кәлисә мөхарәбәсеннән качкан гаскәрләрне куйганнар. Бунда сөйләүләренә караганда, Кырык Кәлисә һәм Салоник шәһәрләренең алынуларына «Иттихад вә тәрәкъкый» тарафдары улан афисәр һәм гаскәрләр илә «Хөррият вә иэтиляф» тарафдарлары арасындагы ихтиляф сәбәп булмыштыр. Гүя «Иттихад вә тәрәкъкый» афисәрләре, хәзерге хөкүмәткә ачу итеп, дошманга каршы тормыйчы кире чигенгәннәр. Салоникны да сугышмый биргәннәр. Бу сүзләрнең дөрест булып-булмавы хәзергә мәгълүм түгел. Икенче бер кешеләрнең сөйләүләренә караганда, гаскәрнең кире чигенүләренә атлар аз булу сәбәп булмыштыр. Ат аз булганлыктан, вакытында сугыш мәйданына азык һәм сугыш яраклары китереп җиткерү дә мөмкин булмаган. Шул сәбәптән анлар кире чигәргә мәҗбүр булганнар. Истанбулда атларның гаять дәрәҗәдә аз калуы бу сүзләрнең бер дәрәҗә дөрест булуын ихтимал тотадыр. Икенче көнне иртән торып, Истанбулдагы мәнзараларны карау һәм сугыш мәйданына баруның мөмкин булып-булмаячагын белү өчен чыктым, берникадәр кешеләрне күрдем.
– Чаталҗага барсаңыз да, анда тубыктан югары чыккан балчыкларны күрүдән башка бернәрсә дә күрә алмассыз. Чөнки хәреб мәйданына һичкемне җибәрмиләр, гәзитә мөхбирләреннән һәммәсе дә хәзер Истанбулга кайтарылдылар. Анлар сугыш мәйданы хакында ни язсалар да, Истанбулда торып, үзләреннән чыгарып язалар, – диделәр.
Гәрчә мосаләхә булса да, Төркия үзенең Чаталҗага гаскәр китерүендә һәмишә дәвам итә икән. Сөйләүләренә караганда, мосаләхә булган көннән хәзергә кадәр Төркия йөз мең кадәр яңа гаскәр китергән, имеш, диләр. Хәзер дә һәр көн яңа гаскәр килеп тора.
Яңа килгән гаскәрләр Чаталҗага күндерелеп, анда озак торып арыган гаскәрләр арттагы сафка күчерелә бара, имеш.
Яңа килгән гаскәрләр бик таза һәм куәтле күренәләр. Һичберсе дә үләргә китә торган кешеләр кыяфәтендә түгел. Һәркаюсы да ачык йөзле һәм үзләреннән мәмнүн күренәләр. Истанбулның урам маҗаралары бик тәэсирле, урамнарда халыклардан һич үтеп-сүтеп йөрергә мөмкин түгел дисәң дә ярарлык. Бөтен урам һәртөрле кыяфәттәге гаскәрләр илә тулы. Бунларның берсе бер тарафка, икенчеләре икенче тарафка йөреп тора. Айя Суфия һәм Солтан Әхмәд җәмигъләры янына бардым, ләкин эчләренә керү мөмкин түгел, чөнки читтән һичбер кешене кертмиләр.
«Һилал әхмәр»дә хезмәт итү өчен Петербургтан Кәбир Бәкерев, Фатыйх Рәхимов, Шәриф Әхмәтҗанов һәм дүрт ханымның Истанбулга киткәннәрен ишеткән идем. Анлардан Кәбир Бәкерев һәм Фатыйх Рәхимовны дарелфөнүн хастаханәсенә китеп күрдем. Хастаханәгә кереп хасталарны карау мөмкинме икәнлеген сораштым. «Бу көн мөмкин булмаячак. Буның өчен Хариҗия вәзарәтеннән рөхсәт алу лязим», – диделәр.
Бу көн артык мәгълүмат җыю мөмкин булмады. Затән, извозчиклар булмаганлыктан, Истанбулның бетмәс-төгәнмәс урамнарын көн буе җәяү йөреп арып та беткән идем. Номерыма кайтып яттым. Иртәгесен, ягъни бу көн, торып янә дә бәгъзе кешеләрне күрү касды илә берничә җирләргә киттем. Һичберсен өйдә тугъры китерә алмадым. Аннан «Һилал әхмәр» мәркәз идарәсенә китеп, мөдир әфәндедән хастаханәләрне кереп карау өчен рөхсәт сорадым.
– Теләсәңез, кереп караңыз, ләкин анда карарлык ул кадәр әһәмиятле нәрсәләр юк, – диде.
Дарелфөнүн хастаханәсенә киттем. Тәсадефи уларак узган көн эзләп тә таба алмаган «Төрек йорды» журналының идарәханәсе күземә чалынды. Эчкә кердем. Йосыф әфәнде Акчуринны сорадым. Ул анда юк иде. Без аннан-моннан бәхәс иткән арада, журналның баш язучыларыннан Кязим нами әфәнде килде, аның илә хили озак мосахәбәдә булдым.

Әдәбият вә лисаннан бәхәс иттек. (Буны икенче мәртәбә язармын.) Соңра, хастаханәгә барырга соңга калуны мөляхәзә итеп, аннан чыктым.
Хастаханәгә бардым. Фатыйх әфәнде Рәхимов эчкә алып керде, анлар илә мосахәбә итдек. Петербургтан килгән өч ирне – дарелфөнүн хастаханәсенә, дүрт ханымны Кадерга хастаханәсенә җирләштергәннәр икән. Бераз мосахәбәдән соң, нәүбәттәге табибның мөсагадәсе илә хасталарның ята торган бүлмәләрен карап йөрдек. Бунда мәҗрух һәм хаста уларак дүрт йөз кадәр кеше ята икән. Мәҗрухлар үзләрен бик яхшы хис кыйлалар. Хасталар исә үзләренең хасталыкларының дәрәҗәләренә карап төрлесе төрле дәрәҗәләрдәдер.
Хастаханә бик тәмиз, хасталарның һәм ята торган урыннары да пакь һәм ак. Хастаханәдән чыккан вакытта миңа дезинфекция ясап кулларымны сүләмә илә юдырып чыгардылар. Бунда Чаталҗа һәм аннан әүвәлдәге мөхарәбәләр хакында бик күп тәфсыйлатлар бар. Анларны киләчәк мәктүбтә, шаять, язармын.
Һавалар салкын исә дә, агачларда яшеллек бетмәгән. Бездәге сентябрь аена охшый.
III
Өченчекөн кич Бәхре сәфид тә Төркия флотының Греция флотлары илә сугышып, Грециянең иң зур һәм яңа дредноутларыннан улан «Аверов» нам дредноутына Төркия флотыннан атылган өч туп тиеп мәҗрух булуы һәм дә Бәхре сәфидтә төрекләрнең бер җилкән көймәсен тотып, артына тагып алып бара торган бер юнан миноносының кулга алынуы хакында хәбәрләр алынды. Бу хәбәр төрекләрне бик шатландырды. Шатланмаслык та түгел. Чөнки бу дредноут Грециянең иң куәтле сугыш пароходларыннан саналадыр. Әгәр дә ул сугыш сафыннан чыкса, Грециянең башка сугыш пароходлары илә көрәшү Төркия өчен җиңел булачактыр. Хәтта аннан соң Төркиягә Салоник тирәләренә гаскәр төшереп тә, Греция илә сугышырга мөмкин булачактыр. «Аверов» дредноуты – буннан бер сәнә элек эшләнеп тәмам булган, гаять мөкәммәл бер сугыш пароходыдыр. Гаять зур булуы өстенә, Төркия пароходларына караганда, сәгатенә алты чакрым микъдарында тизрәк тә йөридер. Бу сугыш көймәсен Америкада сәүдә кыйлып баеган Аверов намендә бер грек үз сумасыннан эшләтеп Грециягә һибә кыйлмыштыр.
Пароходның «Аверов» дип аталуының сәбәбе дә шуннандыр. Истанбул халкы хәзер сугышны сабырсызлык илә көтәләр. Әгәр дә солых гакыйд ителмәсә, сугышырга җан вә күңелләре белә хәзер торалар. Бу дәфгада үзләренең болгарларга галиб киләчәкләренә тәмам ышаналар. Чөнки хәзерге көндә сугыш мәйданына яңа китерелгән гаскәрләрнең әксәре – мөкәммәл тәгълим күргән низамлы гаскәрләрдер. Әүвәлге сугыш заманнарында сугыш мәйданында гаскәрләр бөтенләй дип әйтерлек рәдиф гаскәрләреннән гыйбарәт булганнар. Сугышта булган афисәр вә гаскәриләрнең сөйләүләренә караганда, Кырык Кәлисә, Лүләбургас һәм хәтта Чаталҗа мөхарәбәләрендә дә гаскәрләрнең йөздән туксаны рәдифләрдән гыйбарәт булмыштыр. Низамлы гаскәрләр ул заманнарда Анатолийнең төрле урыннарында итальяннарга каршы куелган булганнар.
Мәҗрух һәм сугыштан кайткан гаскәрләрдән берникадәр кешеләр илә күрешеп сөйләштем. Бер гаскәри Кырык Кәлисә сугышы хакында ушбу сүзләрне сөйләде:
– Без Истанбулдан чыгып киткән вакытта безгә ике тәгаен (ике көнлек) кадәр икмәк бирделәр. Хәзер, сугыш вакыты булганлыктан, шуның илә кифаяләнеп торырсыз, диделәр. Шул икмәк илә Кырык Кәлисә җиварына барып җиттек. Анда баргач, янә ике көнлек кадәр сохари бирделәр. Без никадәр: «Безнең буннан артыкны күтәреп йөрергә дә көчемез җитә, күбрәк итеп бирегез»,– дип сорасак та, аннан артык бирмәделәр. «Хәзер шуның белән кифаяләнеп торыңыз, азыкны артыңыздан күндерермез», – диделәр. Бу җирләрдә азык берничә йөз мең кешегә берничә айларга кадәр җитәрлек иде. Кырык Кәлисә алынганнан соң, бу азыклар бары да дошман кулына калды. Безне алдагы сафка җибәрделәр. Анда барып, бик уңайлы һәм бик яхшы бер тау башына менеп җирләштек. Бу урыннан дошманга каршы торырга бик уңайлы иде. Соңыннан ни өчендер безгә бу урыннан кире чигенергә әмер бирделәр. Без таудан төштек. Безнең урынымызны

болгарлар ишгаль иттеләр. Без бөтенләй ут астында калдык. Аннан көч-хәл илә котылып, икенче тау башына җирләштек. Бунда да безгә дошманга каршы тору өчен бик уңайлы иде. Сугышлар башланды. Озак заманнар атыштык. Пүләләремез бетте. Арттан азык та, пүләләр дә килеп җитмәде, шул сәбәптән качарга мәҗбүр булдым, – диде.
Бу солдат арка тарафыннан җәрәхәтләнгән бер кеше иде. Гаскәр арасында аркадан җәрәхәтләнү зур гаепкә саналадыр. Чөнки ул аның сугыш мәйданыннан качып киткәнлеген күрсәтәдер. Бундый кешедән иптәшләре дә истиһза кыйлып көләләр. Шулай да булса мәҗрухлар арасында бундый аркадан җәрәхәтләнгән кешеләр күп күренәдер.
Гаскәр арасында мәрхәмәтсез кешеләр дә булгалаган. Мәсәлән, Мисырдан үз ихтыяры илә килгән бер гарәп афисәре ушбу сүзләрне сөйли:
– Мин сугышта мәҗрух булып егылдым. Лазаретка алып китүләрен көтеп, сугыш мәйданында ятам. Берзаман ерактан патруль килде. Мин төрекчә сөйләшә белмим. Гарәпчә яки инглизчә бер сүз әйтсәм, мине үтереп китү ихтималлары бар. Башкача юл тапмагач, мин шәһадәт кәлимәсе әйтеп кычкыра башладым. Патруль килеп минем кесәләремне актарды, – ди.
Төрекләр башта Балкан дәүләтләре тарафыннан сугыш башлануны һич көтмәгәннәр, шул сәбәптән анлар хәзерләнә алмый калганнар. Шуның өчен анлар бу сугышта җиңелүдән үзләрен гаепсез санарга тырышалар.
Чаталҗа мөхарәбәсендә төрекләр болгарларны бик нык җиңгәннәр. Хәтта, сөйләүләренә караганда, бу сугышта болгарлардан илле мең кадәр кеше һәлак булган, имеш.
Ике тарафтан атылып торган флот туплары болгарларга зур һәлакәтләр биргән. Соңра флотлардан дошман өстенә төшерелгән электрик прожекторлары дошманнарны һәлак итүгә зур ярдәм биргән. Прожекторлар саясендә төрекләр дошман гаскәрене күреп, анларга атканнар. Болгарлар исә караңгыда яткан төрек гаскәрләрен күрә алмаганнар.
Төркиягә ярдәм итү өчен төрле тарафтан үз ихтыярлары илә сугышка килгән кешеләр хили күп. Бунлар арасында Русиядән (Кырымнан вә гайре җирләрдән) килгән кешеләр дә өч йөз кадәр бар. Мәскәүдә гали тиҗарәт мәктәбендә укыган Гариф әфәнде Кәримев берничә кәррәләр сугышта булып, ахырында сул кулыннан җәрәхәтләнгән. Хәзерге көндә сәламәтләнеп килә.
Хастаханәләрдә мәҗрухлар азайды. Хәтта берничә хастаханәләр тәмам бушадылар. Калганнарында да мәҗрухлар аз. Гаскәр арасында ваба хасталыгы һич юк. Ара-тирә холерина дигән бер авыру булса да, бу авыру кешенең хәяты өчен зарарлы бер нәрсә түгел.
Истанбулга гаскәр килү һаман дәвам итә. Килгән гаскәрләрнең һәркаюсы бик тазалар һәм яшьләр.
Чаталҗа мөхарәбәсе заманында ашарга икмәк җитешмәгән дип гәзитәләрдә язылган сүзләр бер дәрәҗә тугъры икән. Истанбул халкы да ул заманнарда ике көн кадәр икмәксез калганнар. Бу сугыш көннәрендә атылган туп тавышлары Истанбулда бертоташтан ишетелеп торган, ике көн кибетләр ачылмаганнар. Күп кешеләр, Истанбулның алынып, дошман кулына калуыннан куркып, Анатолий тарафына качып киткәннәр. Хәзерге көндә Истанбулда башына фәс кимәгән кешеләр бик аз очрыйлар.
Истанбул алына калса, төрек гаскәрләре тарафыннан катле гам булудан куркып, христианнарның да һәркаюсы башларына фәс кигәннәр. Ләкин андый христианнарга тәгъриз кеби эшләр һич булмаган. Хәтта бер кешенең дә борыны канамаган.
Үз тәбәгаләрен саклау өчен дип крейсерлардан чыгарылган чит мәмләкәт гаскәрләре яңадан крейсерларга кайтканнар. Крейсерларның бу көннәрдә үз мәмләкәтләренә кайтып киткәннәрен сөйлиләр.
Истанбулда гадәттәге хәят тәмам урынлашкан, каһвәханәләрнең һәркаюсы халык илә тулы.
Ашау нәрсәләре гадәттәгедән күп дәрәҗә кыйммәт. Бу хакта сугышның хили зур тәэсире күренә.

Бу көннәрдә генә Призреннән кайткан бер дарелфөнүн шәкерте илә күрештем. Бу әфәнде кайткан заманда Салоникта да булган. Аннан андагы хәлләр хакында сораштым.
– Призренне һичбер сугышмыйчы бирделәр. Чөнки Призрендә Төркиянең гаскәре фәкать ун мең кешедән гыйбарәт иде. Туплар да юк иде. Әгәр дә Сербиянең кырык мең гаскәренә каршы сугышып маташкан булсалар, зур ахмаклык эшләгән булырлар иде. Ләкин арнаутлар Сербиянең башына бик зур бәла булдылар. Арнаутлар – ниһаять дәрәҗәдә сугышчы адәмнәрдер. Анларның уналты яшьтән башлап алтмыш яшенә кадәр булган адәмнәре – һәркаюсы гаскәрләрдер. Арнаутлыкта эш күрү серблар өчен бик авыр булды. Анлар бунда үзләренең ничә вә ничә мең гаскәрләрен югалттылар. Арнаутлык эченә никадәр серб гаскәре керде исә, һәммәсе шунда батты, һич сәламәт кайтмады. Серблар арнаутлык эчендә үзләренең бик күп тупларын да югалттылар. Ул заманнарда ул тирәләрдә тәхминән бер аршын калынлыгында кар яуган иде. Серблар үзләренең тупларын кире өстерәп алып чыгарга мокътәдир булмадылар. Сербларның арнаутларга дошманлыклары хәзерге көндә хәддин тыштыр. Үзләре алган җирләрдә анлар арнаутларга каршы зур инсаниятсезлек күрсәтәләр. Үз тәхте тәхәккемләрендә булган җирләрдә серблар арнаутларны катле гам илә кател итәләр. Зурмы, кечкенәме, олугъ кешеме, баламы, ирме, хатынмы – һичберсен тикшермичә үтерә бирәләр. Мин, башымны коткарып, бу тарафларга чыгуымны үзем өчен бер могҗиза дип беләм. Аз калды – мине дә арнаут дип үтерәчәк иделәр.
Призреннән Салоникка килдем. Анда янәдән җан ачынырлык хәлләр күрдем. Бөтен Салоник шәһәре читләрдән качып килгән мөһаҗирләр илә тулы иде. Гәрчә Салоникта фабрикаларда эшләр башланган булса да, эшсез аптырап, ач-ялангач йөрүчеләрнең һич хәдде-хисабы юк иде. Читтән килгән кешеләр ун тиен яхуд бер кисәк икмәк өчен бөтен көн буена хезмәт итәргә хәзерләр, ләкин һичбер җирдә эш таба алмыйлар. Буйга җиткән кызлар, бала-чагалар кулларын сузып, бер кабар икмәклек өчен булсын, сәдака сорап тилмереп йөриләр, ләкин анларны кызганган һичбер кеше юк. Бичаралар ачлыктан үләләр. Һәр көн урамнардан ачлыктан үлгән утыз-кырык кешене җыеп алалар, – диде.
IV
Бундый качып килгән ач-ялангач мөһаҗирләр Истанбулда да бик күп булган. Ләкин анлар бу дәрәҗәдә мохтаҗлык күрмәгәннәр. Анларны мәсҗедләргә җирләштереп, хәзинә тарафыннан ашарларына биреп, Анатолий тарафына урынлаштырганнар. Хәзерге көндә дә Истанбулның берничә урыннарында бундый мохтаҗларга акчасыз чәйләр эчертеп, тамакларын туйдыралар.
Яңадан сугыш булса да, булмаса да, солых гакыд ителсә вә ителмәсә дә, Истанбулда тиздән тынычлыкларның булу ихтималы юктыр. Чөнки солых булмаса, ул вакытта бик нык сугышлар, солых булса, бундагы фиркаләр арасында бик зур көрәшләр башланачактыр. Хәзерге көндә эш башында булган «Ихтиляф» фиркасенең әгъзалары бар куәтләре илә «Иттихад вә тәрәкъкый» әгъзаларын эштән чыгарырга, «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркаләре исә иэтиляфчыларны күздән төшерергә тырышачаклардыр. Аннан башка, бу көннәрдә бунда янәдән өченче яңа бер фирка вөҗүдкә килергә торадыр. Бу фирканең мөәссисе – әүвәлдә «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасендә булып та, анда вөҗүд казана алмагач, үзеннән «Ихтиляф» фиркасе тәшкил иткән вә берничә заманнар аның башында торган, соңра янә ул фиркадән куылган, хәзерге көндә «Тәнзыймат» гәзитәсенең мөхәррире булган Лотфи Фикри исемендә бер заттыр. Бу кеше Мәҗлесе Мәбгусан әгъзасы да булган. Сөйләүләренә күрә, парламентта низаглар кубаруда бу кеше безнең Русиянең Пуришкевиченнән ким дәрәҗәдә түгелдер. Шул сәбәптән бу кешене рус матбугатыннан хәбәрдар булган бундагы кешеләр Төркия Пуришкевиче дип тәгъбир итәләр. Иштә бу адәм Төркиядә яңа бер партия ихдас итәргә йөридер.
Гәрчә бу кешене күрдем исә дә, максуды ни идекене вә аның партиясенең программы нидән гыйбарәт идекене кямилән аңлый алмадым. Бәгъзе бер әхбабларының сөйләүләренә караганда, ул адәм хөррият тарафдары һәм хатыннарга да хөррият бирү тарафында, имеш.

Иштә хәзерге көндә төрекләр арасында өч партия бар. Сугыш бетү илә бу өч партия арасында зур ихтиляфлар чыгуы һәм шуның аркасында зур үзгәрешләрнең вөҗүдкә килүе ихтимал, диләр.
Минем, монда килгәннән соң, бер нәрсә дикъкатемне җәлеп итте. Мин буңа кадәр үземезнең татарларымызны артта калган, эшкә яраксыз кешеләр дип хисаплап йөри идем. Хәлбуки эш алай түгел икән. Төркиядә һичбер даирә юктыр ки, анда татарларның катышы булмасын.
Истанбулда иң яхшы хатиб саналган кеше – татардыр. Гәзитә идарәләрендә иң яхшы язучылардан саналган мөхәррирләр – татарлардыр.
Төркиянең әркане хәрб (военный штаб) әгъзалары арасында да бер татар бар. Төркиянең игъдади мәктәпләреннән берсендә бер татар – мөгаллимдер. Буннан магада башка даирәләрдә дә татарлардан эш башында булган кешеләрне күрергә мөмкиндер. Шул эшләрне күргәннән соң, әгәр дә тырышсалар, безнең татарларның да кулларыннан эш киләчәк икән дигән фикерләр башыма килде.
Хәтеремә төшкәнлектән, янә дә сугыш хакында бер-ике сүз язам. Бу көнгә кадәр төрекләр сугышта җиңелергә өйрәнмәгәннәр. Һәрвакыт дип әйтерлек анлар сугышларда галиб булып килгәннәр. Шул сәбәптән анлар җиңелүне һичбер уйламаганнар. Мәсәлән, афисәрләрдән берсе бер дөкяндә ике грошлык төтен сораган. Дөкянче буңа: «Сез мөхарәбәгә китәсез, күбрәк алыңыз»,– дигәч: «Зарар юк, кирәк булса, тагы София шәһәрендә алырмын», – дигән. Хөкүмәттә дә шуңа охшашлы бер фикер булган. Анлар үзләренең җиңелүләрен һич тәсаувыр да итмәгәннәр һәм Истанбулда мәҗрухлар өчен лязим булачак хастаханәләр дә хәзерләмәгәннәр. Ниһаять, Истанбулга поездлар тулы мәҗрухлар килә башлагач, аптыраште калганнар. Хастаханәләрнең берсендә хезмәт иткән бер тыйббия шәкертенең сөйләвенә караганда, әгәр дә шул көннәрдә бөтен Истанбул халкы эшкә тотынып, хастаханәләр өчен лязим булган нәрсәләрне хәзерләп биргән булмасалар, эшләр начар булачак икән. Истанбулга мәҗрухлар килеп тула башлагач та, бөтен Истанбул халкы, бердән аякка калкып, мәҗрухларга ярдәм итәргә яраклы булган һәммә нәрсәләрен хастаханәгә ярдәм өчен биреп, мәҗрухларны үлемнән коткаруга сәбәп булганнар.
Вакыты килгәндә шуны да әйтеп китәргә кирәк: хастаханәдә авыруларны караучы табиб, фельдшер, фельдшерицалар һәм хаста багучыларның әксәре Германия, Австрия һәм Румaниядән килгән кешеләр иде. Хәзер Румания илә Австриядән килгән табиблар, үзләренең хөкүмәтләренең таләп итүләре буенча, мәмләкәтләренә кайтып киттеләр.
Соңра, сугыш башында христианнар, Болгариягә каршы торудан имтинагь итеп, Болгария тарафына качканнар дигән хәбәрләр гәзитәләрдә күренгән иде. Бу хәбәрләр дә ялган булып чыкты, чөнки хастаханәдә ята торган мәҗрухлар арасында әрмәннәр вә гайреләрдән бик күп кешеләр бар.
Мин килгән көннәрдә Истанбулда хили суык бар иде. Ике көннән бирле көннәр җылынды. Халык һәммәсе җәйге киемнәр илә йөриләр.

## V

Солых ишек төбендә торса да, төрекләр буңар ышанырга теләмиләр. Югары даирәләр нәкадәр солых тарафдарлары булсалар да, халык вә гаскәр һаман да сугыш тарафдарларыдыр. Бунлар, яңадан болгарлар илә сугышып, үзләренең йөзләренә ягылган пычракларны юарга телиләр. Мин килгән заманнарда Истанбул шәһәренең эче бөтенләй гаскәр илә тулы иде. Хәтта, безнең тәгъбирчә әйткәндә, инә ыргытсаң, җиргә төшмәслек иде. Хәзер гаскәр сирәкләнде, һәммәсен урыннарына озатып бетерделәр. Хәзер хастаханәләр дә бушый башлады. Берничә вакытлы хастаханәләрнең берничәсе бөтенләй капланды. Сан-Стефанус вә гайре ул тирәдәге хастаханәләрне дә бушатып, андагы мәҗрухларны да Истанбулга китерделәр. Айя Суфия вә аңа охшашлы зур мәсҗедләр дә хәзер тәмам бушадылар. Бер-ике көннән соңра бу мәсҗедләрдә, гадәттәгечә, азаннар укылып, намазлар дәвам итә башлаячактыр. Хәтта берничә көн соңында мәктәпләрнең ачылып, дәресләрнең дәвам итә башлауларын көтәләр. Фәкать Баязид мәйданындагы

дарелфөнүн шөгъбәсе илә Кадерга мәктәпләре генә тиздән ачылмаячак. Чөнки бунлар бөтенләй хастаханәгә әйләндерелгәннәр. Бу хастаханәләр баштанаяк читтән килгән табиб һәм хаста багучылар кулындадыр. Бунларга төрекләрнең үзләре өчен бер хезмәт юк диелсә дә җаиздер. Дарелфөнүн хастаханәсендә һәр милләттән кешеләр бар. Мәсәлән, монда, Русия эченнән килгән татарлар булган шикелле, руманияле, германияле, англияле, мисырлы, хәтта болгарияле мөселман доктор һәм фельдшерлар бар. Кичә генә ошбу хастаханәгә Һиндстаннан алты мөселман доктор, ун тыйббия студентлары һәм дүрт хаста багучылар килделәр. Һәркаюсы инглизчә бик яхшы сөйләшәләр, гарәпчә дә яхшы ук беләләр. Ләкин төрекчә бернәрсә дә аңламыйлар.
Өченчекөн Төркиянең иң мөкәммәл мәктәпләреннән улан тыйббия мәктәбенә киттем. Тыйббия мәктәбе Үскүдар тарафында Хәйдәрпашада иң гүзәл бер урында яшеллекләр арасына салынмышдыр. (Яшеллек, дидем, чөнки хәзер Истанбулда безнең сентябрь аеның беренче көннәре шикелле һәр җир яшелдер. Хәтта бакчаларында гөл агачлары чәчәктә утыралар.) Тыйббия мәктәбенең бинасы – иң соңгы осуле мигъмаридә мәрмәр ташларыннан салынган гаять зур бер йорттыр. Дүрт почмаклы итеп салынган бу мәктәпнең бинасының әйләнәсе тәхминән ярты чакрым кадәр бар. Тыйббиядә укый торган русияле Сибгатулла әфәнде илә, Дахилия мөдиратыннан рөхсәт алып, һәрбер җирләрен карап йөрдек. Мәктәп бинасы хариҗи тәртипләре җәһәтеннән гүзәл булган шикелле, дахили тәртипләре җәһәтеннән дә бик гүзәлдер. Мәктәпне бундый яхшы дәрәҗәгә ирештерү өчен, Төркиядә генә түгел, бәлки Яурупада исеме танылган мәшһүр хирург Җәмил паша бик күп иҗтиһадлар сарыф итмештер. Мәктәптә хәзер дәресләр юк. Мәктәп хастаханәгә әйләндерелгән. Өч йөз кадәр мәҗрух һәм хасталар дәваланып яталар. Биш йөз кадәр кешелек яңадан буш караватлар да бар. Операция заллары бик гүзәл, китапханәсе дә бик мөкәммәл. Мәктәпнең янында ботаника бакчасы бар. Бакча нәбататка бай. Оранжереясенең эченә кергәч, үзеңне гүя җәнүбтәге мәмләкәтләрнең берсендә шикелле хис итәсең. Һәр тарафтан хөрмә һәм пальма агачларының яфраклары башка төшеп торалар. Мәктәпнең каршысында, юлның икенче ягына клиника салынган. Буның бинасы бик гүзәл. Мәктәпнең үзе шикелле мәрмәрдән салынган. Эчендә төрле авырулар илә авырып ята торган ике йөз кадәр хасталар бар. Хасталарны караучылар арасында әрмән вә грек хатыннары булган шикелле, мөселманнардан да берникадәр ханымнар бар. Клиника кечкенәлек кыйлганлыгыннан Җәмил паша, аны зурайту өчен, янына яңадан бер бина салдырырга башлаган булса да, үзе эш башыннан төшү сәбәпле, тәмам итәргә муаффәкъ булмаган.
Дарелфөнүннән бераз гына читтәрәк яңа салына торган зур бер казарманы эшләп яталар. Буны да Мәхмүд Шәүкәт паша салдыра башлаган икән. Монда килгәннән соң биналарны күреп инсан хәйранга кала. Чөнки казармаларга кадәр һәрбер биналар мәрмәр яки гранит ташыннан салыналар. Бу таш Истанбулда шулкадәр очсыз бер нәрсәдер ки, гади бер өйнең бәдрәфләренең идәннәренә кадәр мәрмәрдән ясалмыштыр. Хәйдәр пашадагы вокзал да игътибарга алыначак бер бинадыр. Немецлар акчаны бер дә кызганмаганнар. Читтән карап сокланып торырлык гүзәл бер бина вөҗүдкә китергәннәр.
Җомга көн «Русияле таләбә җәмгыяте»нең гомуми мәҗлесләре булды. Мәҗлескә мине дә дәгъват иткәннәр иде. Бардым. Әүвәлдә бу җәмгыять Русия эченнән килгән Казан татар шәкертләренең дә җәмгыяте булган икән, хәзер бунлар Кырымнан килгән таләбәләрне үз эчләренә алып, яңа бер гомуми җәмгыять тәэсис иткәннәр. Шул мөнәсәбәт илә мәҗлестә үзләренең дүртеллык хисапларын һәм тарихларын күрсәттеләр. Докладларыннан аңлашылдыгына күрә, дүрт ел эчендә җәмгыять берникадәр шәкертләргә лөзүм күрелгән заманнарда карзга акчалар биреп торып, ярдәмдә булган һәм илле кадәр шәкертне билбәдәл төрле мәктәпләргә кабул иттерергә муафыйк булган. Җәмгыятьнең хәзерге көндә йөз илле кадәр әгъзасы бар, кыйраәтханәләрендә Русиядә чыккан гәзитәләрне күрергә мөмкин.
Хөррият каһарманы Әнвәр бәкне һаман да Траблиста сәнүсиләр илә бергә итальяннарга каршы сугыша дип сөйлиләр иде. Ул сүзнең асылы юк икән. Әнвәр бәк өченчекөн

Истанбулга килде. Кичә өенә килеп үзен күрергә теләгән идем, ләкин муаффәкъ ула алмадым. Өйдә юк иде. Иртәгә яки берсекөнгә килеп күрермен дип өмид итәм. Бу көн Айя Суфия мәйданындагы гаскәри музәханәне барып күрдем. Хөррият соңында гына вөҗүдкә килгән бу музәханә хакыйкатән күрергә лаек бер нәрсә икән. Бундагы байлык, бундагы коралларны бер көн генә түгел, бер һәфтәдә дә карап бетерергә мөмкин түгел. Музәханәнең назыйры Мохтар пашадан визитный карточка алып килгәнлегемездән, безгә аерым илтифат күрсәттеләр. Янымызда бер забит, даим безнең илә бергә гизеп, безгә күп тәфсыйлатлар бирде. Көндез сәгать уникедән башлап кояш баеганчы (музәханә ябылганчы) карап йөрсәк тә, һаман да андагы байлыкларның һәммәсен карап бетерә алмадык. Бунда мөхарәбәи талибия заманыннан башлап хәзерге көнгә кадәр хөкем сөргән никадәр дәүләт бар исә, һәркаюсының үз заманнарында истигъмаль иткән кораллары, өстләренә кигән киемнәре, башларына кигән «касәләре», байраклары – һәммәсе дә бар. Бер данә әүвәлге заман баһадирлары истигъмаль иткән, безнеңчә гөрзи дип атала торган бер чукмар бардыр ки, һичшиксез, пот ярым авырлыгындадыр. Гөрзине бер кул илә генә түгел, ике кул илә дә көчкә генә күтәрдем. Ул гөрзи илә сугышка китү өчен кешенең мотлакан Сәетбаттал булуы лязимдер. Соңра да, Истанбулны алган заманда солтан Фатыйх гаскәре тарафыннан мәнҗәникъ илә Истанбул өстенә атылган йомры ташлар бар. Бер ташны карышлап үлчәп карадым. Әйләнәсе нәкъ унсигез карыш иде. Авырлыгы да, һичшиксез, утыз биш-кырык пот булыр. Кемнеке икәнлеге хәтеремдә юк, бер данә платиннан ясалган бер хәнҗәр бар. Шулкадәр кыйммәтле бер нәрсәнең өстәл өстендә футляр эчендә ачыктан-ачык ятуына тәгаҗҗеб иттем. Кораллар арасында солтан Фатыйхның заманында истигъмаль иткән кылычы булган шикелле, солтан Габделхәмиднең револьвер, кылыч, электрик лампалы таяк һәм борын яулыкларына кадәр бар. Арада иң кыйммәтле вә иң кадерле бер нәрсә бар исә, ул да – Айя Суфия мәсҗеденең каланчаларында кайсарлар заманында асылып торган чаңлардыр (колоколлардыр). Хәзерге замандагы колоколлар илә бунларны чагыштырырга һич мөмкин түгел. Айя Суфияның бинасы никадәр зур булса, бу колоколлар ул нисбәттә кечкенәләрдер. Гади бер карья кәлисәләренең чаңнары бунларга караганда күп дәрәҗә зурдыр.
Арада дикъкатьне җәлеп итәчәк нәрсәләрнең берсе дә – яңа чирү гаскәрләре заманында истигъмаль ителгән барабаннардыр. Барабан дигәч тә, бунлар гади бер барабан дип фараз кыйлынмасын. Бунлар гакыл ирешмәслек дәрәҗәдә зур нәрсәләрдер. Бу барабаннарның эченә утыз чиләк су койсаң да тулып җитмәс. Тупларга килсәк, янә дә хәйранга калырлыктыр. Дөньяда инсанны үтерү өчен шулкадәр кораллар ихдас ителгән булуына һич гакыл ирешмәс.
Төрекләр үзләре буның шикелле мөкәммәл һәм бай гаскәри музәханәнең Яурупада сирәк икәнлеген дәгъва итәләр. Мондагы байлык, мондагы асаре гатиканы күргәннән соң ышанмаска да мөмкин түгел. Асарләрнең бик күбесе Габделхәмид ханның «Йолдыз» сараендагы хосусый музәханәсеннән китерелгәннәр. Сөйләүләренә караганда, мәзкүр әсәрләр Габделхәмид өчен берничә миллионнарга төшкән, имеш. Бу музейга китерелгән нәрсәләр кыйммәтләре җәһәтеннән бераз түбән дәрәҗәдә булган нәрсәләрдер. Төркиянең иң кыйммәтле нәрсәләре һәм мөҗәүһәратлары Андрон музәсендә, хәзинәи хазәда саклана икән. Бу җирләргә кешене никадәр акча бирсә дә кертмиләр. Бунда керү өчен йә падишаһтан ирадәи мәхсусә яхуд да зур бер протекция булырга кирәк. Мин бунда керү өчен дә юл тапкан идем, ләкин хәзергә кереп күрү мөмкин булмады. Чөнки сугыш заманнарында болгарлар Истанбулга якынлашканлыкларыннан, бундагы байлыклар анлар кулына төшмәсен дип куркып, нәрсәне җыештырганнар икән. Әгәр солых булып та тынычлыклар килсә, ул заман, иншалла, килеп күрермен.
VI
Төркия илә Балкан хөкүмәтләре арасындагы солых мөзакәрәләренең вакытлары кичкән булса да, янәдән бу көнгә кадәр кичектерелде.
Бүген, бу мәкаләне язган вакытта, бәлки, Лондондагы мөрәххәс бер-берсе илә кычкырышып таралышкан булырлар яхуд да солых могаһәдәсенә кул куйганнардыр. Бу

мәкалә анда барып җиткәнче, телеграм васитасы илә хәбәрләр, бәлки, мәгълүм булган булыр. Ләкин бунда солыхның ясалуына ышана алмыйлар. Һаман да сугыш булыр дип фараз кыйлалар. Сугышка хәзерләнү бик нык бара. Истанбулдан һәр егерме дәкыйкадә бер мәртәбә Чаталҗага поезд китеп тора, бу поездларда көндез гаскәргә азык һәм сугыш ярагы, кич илә гаскәр ташыйлар. Аннан кайткан вагоннарда хаста гаскәрләрне китерәләр. Кичә Истанбулдагы беренче урдуның да сугыш мәйданына күндерелдекен сөйләделәр. Ләкин тугърысын тәхкыйк итә алмадым. Хастаханәләрдә мәҗрухлар бетте. Хәтта күп хастаханәләрне бушаттылар. Калганнарында да хасталар илә зәгыйфьләр генә җирләштерелгән. Әүвәлдә гаскәрләр җирләштерелгән мәсҗедләр тәмам бушатылдылар. Гаскәриләр вә шәһәр халкы арасында холера хасталыгы да илтифат ителәчәк дәрәҗәдә түгел. Хәзерге көндә Чаталҗада төрекләрнең тәхминән ике йөз ун мең мокабил тарафларның да йөз илле биш мең гаскәрләре булганлыгы сөйләнә. Төркиянең яңадан сугыш мәйданына күндергән гаскәрләре йөз илле мең микъдарындадыр. Бу гаскәрләрнең дә әксәре – низами, гүзәл тәгъзыйм күргән яшь адәмнәрдер. Әүвәлдәге рәдиф гаскәриләрнең һәммәсе диярлек кире кайтарылганнар. Гәнеҗ төрекләр хәзер гомумән сугышу тарафындалардыр. Бунлар, үзләренең әүвәлдәге сугышларда югалткан игътибарларын кире кайтарып, үзләренең намусларын сакларга телиләр.

Соңгы көннәрдә гәнеҗ төрекләр фиркасе илә иэтиляфчылар арасында куәтле көрәшләр дәвам итә. Хәтта берничә көннән Камил паша кабинетының югалуы вә анлар урынына гәнеҗ төрекләр кабинетының ясалуы ихтималдыр.

Бу көннәрдә Төркия гаскәре арасында бик зур фетнәләр булганлыгы һәм Мәхмүд Шәүкәт пашаның диктатор итеп тәгаен ителгәнлеге рус гәзитәләрендә язылган икән. Бу хәбәрләр асылсызлар. Төркия гаскәре арасында андый эшләр һич юк.

Хәреб мәйданына гаскәри булмаган һичбер кешене вә һичбер гәзитә мөхбирләрен җибәрмиләр. Һичкемгә бөек хөкемчәдән ары барырга билет бирмиләр.

Соңгы көннәрдә Болгария үзлегеннән генә эш күрмәкче була икән. Савов илә, Дмитриев Бабыгали илә сөйләшү өчен Истанбулга киләләр икән дигән хәбәрләр таралган иде. Бу хәбәр соңыннан рәд ителде.

Төркия Әдернәне бирергә теләмәдекеннән, Болгария дә аны катгый сорау итдекеннән солыхның булмавы бик карибдер.

Бундан әүвәлдәге мәктүбләрнең берсендә Әнвәр бәкнең Истанбулга килгәнлеген язган идем. Әнвәр бәк бунда килеп ике көн торып, аннан Чаталҗага барып килгән. Бу көн янәдән Чаталҗага китәчәк. «Тасвире әфкяр» гәзитәсенең мөхбиреннән башка һичбер мөхбирне хозурына кабул итмәде. Мөхбирләрдән берсе әгәр аны күрде-фәлән дип язса, ул да «Тасвире әфкяр» гәзитәсеннән алып, тәртип итеп язган булачактыр.

Истанбул бугазы эчендә тора торган чит мәмләкәт сугыш пароходлары китеп бетәләр. Хәзер бугаз эчендә фәкать дүрт данә сугыш пароходы калды.

Төркиянең сугыш пароходлары Греция пароходлары илә сугышу өчен Ак диңгезгә чыгып киткәннәр иде, һаман да шуннан килгәннәре юк. Анда анларның «Аверов» брониносын имгәткәннән соң, бер генә су асты көймәсен батырганлыкларыннан хәбәр алынды. Аннан соң бу ике флот арасында сугышлар булдымы-юкмы, һичбер хәбәр юк.

Төрекләрнең берничә данә тара бар икән. Бунлар Чаталҗадан очып Истанбул өстенә кадәр килеп китәләр. Истанбулда идарәи горфия һаман да дәвам итә. Кичке сәгать уннан соң урамнарда йөргән кешеләрне тотып хәбес итәләр. Истанбул халкында матәм галәмәтләре һаман да күренә, һичбер җирдә музыка вә уен тавышлары ишетелми. Истанбулда һичбер төрле болгану вә туглану әсәрләре күренми. Төрек хөкүмәтенең кулында хәзергә сарыф итәргә акча булганлыктан, гаскәрләр, афисәрләр, мәэмүрләр, мөгаллимнәр вә гайреләргә айлыклар вакытында түләнеп килгәнлектән, һәркаюларының күңелләре хуштыр. Кирәк, халык арасында вә кирәк, хөкүмәт даирәләрендә булсын – һәр җирдә алтын акча илә хисаплар күреләдер. Киләчәк ай башыннан башлап кәгазь акчаларның чыгарыла башлануы сөйләнә. Әгәр дә хөкүмәт кулында акча азаеп, мәгашлыклар да вакытларында бирелми башласалар, ул заманда берникадәр чуалуларның булуын ихтимал тоталар.

Бу көнгә кадәр Төркиянең малиясе зарарсыз бер хәлдә булып килгән. Әгәр дә сугышлар булып, артык мәсарыфлар тотарга мәҗбүр булмасалар, бу ел мөддәте тула торган тәмәке монополиясен үз кулларына алырга төрекләр карар биргәннәр икән. Ләкин зур сугыш аркасында күп зарарлар күреп, акчага мохтаҗлык күрелгәнлектән, янә дә ул монополияне Рәже компаниясенә бирергә ниятлиләр.
Төркиянең бу көнгә кадәр вөҗүдкә китергән һәм вөҗүдкә китерергә якын булган, ләкин сугыш сәбәпле тукталып калган берникадәр мөәссәсә вә лаихәләре бар. Төрекләр хөррият игълан ителдектән соң уку вә укыту эшләренә бик зур әһәмият биргәннәр. Күп җирләргә мәктәпләр ачканнар һәм хәзер дә солых булу илә бу эшкә шөругъ итәчәкләр, Истанбулда вә аның әтрафларында инглизләр, нимесләр, әмриканнар, җөзүит вә гайреләр тарафыннан ачылган зур һәм мөкәммәл школалар бар. Габделхәмид заманында игътибарга алырлык яхшы програмлы мәктәпләр булмадыгыннан, үзләренең балаларын, хәтта кызларын, инглиз вә гайреләр генә түгел, җөзүитләрнең дини максат илә ачылган школаларына да биреп укытырга мәҗбүр булганнар. Гәнеж төрекләр заманнарында әҗнәбиләрнең бу боендырыкларыннан котылу өчен, анларның мәктәпләренә каршы үзләреннән мәктәпләр бина кыйла башлаганнар. Бунларның Казыйкүйендәге җөзүит мәктәпләренә каршы Хәйдәр паша салдырган бер мәктәпләрен китеп күрдем. Бинасы гүзәл һәм нәзафәте дә мөкәммәлдер. Ләкин дәрес вакыты улмадыкыннан, тәгълим рәвешләрен күрә алмадым. Минем илә бергә барган иптәшемнең сөйләдегенә күрә, дәресләре дә яхшы програм үзәренә тәртип ителгән, имеш. Биредә урта вә гали мәктәпләрдә укый торган шәкертләр өчен зур бер пансион ясарга керешкән булсалар да, сугыш башланганлык сәбәпле, вөҗүдкә чыгара алмый калганнар.
Уку эшләреннән кала, төрекләрнең иң зур әһәмият биргән нәрсәләре – сугыш көймәләредер. Бунлар, мәктәпләрне вөҗүдкә китерүгә иҗтиһад итү илә бәрабәр, флотларын да куәтләндерергә тырышачаклар. Хәзердә төрекләрнең Англиягә ясарга биргән ике дредноутлары бар икән. Анлар 1913 елда тәмам булачак, диләр. Соңра да анлар тарафыннан итальяннарга эшләргә биргән бер дредноутлары булган икән, ләкин Италия, сугыш башлану сәбәпле, төрекләргә бирмәгән, бәлки ул көймәне төрекләргә каршы истигъмаль иткән (әлгөһдәтү галә әррави).
Төрекләрдә лаихәләр бик күп, ләкин анларны вөҗүдкә чыгару өчен заман лязимдер. Төрекләр шәһәрләрне тәгъмир итү өчен дә бик зур иҗтиһад итәләр. Истанбулда урамнарның гаять тар икәнлеге һәркемнең мәгълүмедер. Анлар бу урамнарны мөмкин кадәр киңәйтергә һәм яхшы планга куярга телиләр. Урамнарның тигезлек вә киңлегенә уңайсызлап тора торган урыннарны хөкүмәт үз хисабына сатып алып, биналарны ваттыра һәм бунлар өчен хили кыйммәт бәһаләр түли. Мәсәлән, Яңа җәмигъ каршында тыгызлап тора торган биналарны ваттырып, урамны киңәйтү өчен, бинасыннан башка, фәкать җире өчен генә дә бер мөрәббәгъ сажинга биш мең дүрт йөз сум кадәр, Диван юлында ике рәтле трамвай юлы салырга уңайсызлап тора торган кечкенә генә өч йортны ваттыру өчен кырык биш мең лира (лира – сигез сум алтмыш дүрт тиен) түләгән. Истанбулда узган елларда бик зур янгыннар булып, ничә меңләп йортларның янганлыгы укучыларның мәгълүмедер. Иштә бу җирләр тәмам планга салынганнар, канализация юллары тәртипкә куелган, урамнар киңәйтелгән, тигез ташлар түшәлгән, тротуарларына да асфальтлар куелган. Йорт ияләре дә бина тәгъмир итәргә башлаганнар. Янгын булган бәгъзе җирләр тәртипкә салынып җитмәгән булса да, анларга янә сугыш зарар итмештер.
Истанбулда ат вагоннары һаман да йөрми, фәкать Бәк угълыннан Шешлигә омнибус автомобильләре генә йөриләр. Бундан соң ат вагоннарының кирәкләре дә улмаячактыр. Чөнки Истанбул вә Галата тарафларының һәр җирендә электрик трамвайларын бик ашыгып эшләп яталар. Бер-ике айдан бу юлларның өлгерүе өмид ителәдер.
Төрекләрнең пароходчылыкка да әһәмият бирә башлаганлыклары күренәдер. Төрекләрнең гаскәр ташу өчен җитәрлек пароходлары бар икәнлеген язган идем. Сөйләүләренә күрә, Төркиянең йөз ун кадәр йөк һәм юлчы пароходлары бар, имеш.

Бунлар сугышка кадәр Истанбулдан Искәндәрия һәм юл өстендәге башка портларга йөргән булсалар да, хәзерге көндә, дошман кулына әсир төшүдән саклану өчен, Чанаккалга бугазыннан чыкмыйлар, шул ике ара илә Кара диңгез портларына гына йөриләр икән.
Игенчелек эшен алга җибәрү хосусында да тырышып маташалар. Төркиянең Анатолий кыйсемендә зирагатькә сәляхиятьле, гаять бәрәкәтле һәм бу көнгә кадәр бер дә эшләнмәгән җирләр, балта күрмәгән урманнар бик күптер. Зирагать вәзарәтендә хезмәт итә торган бер бәк әфәнденең сөйләвенә караганда, Истанбулдан ерак та түгел бер җирдә, Анатолий тимер юлына якын бер урында, ике йөз мең дисәтинә кадәр бер урын бар икән. Бу урыннар никадәр бәрәкәтле булсалар да, бу көнгә кадәр бу җирләргә халык урынлашмаган. Әгәр бер компания чит мәмләкәттән килеп эшләргә алачак булса да, биреләчәктер. Ләкин читтән килгән кешенең мөселман булуы шарттыр. Бу җирләрнең елына ничә йөз мең сумлар файда китерәчәген тәхмин итәләр. Хәзерге көндә Анатолий тимер юлы өстенә читтән килеп ике йөз авыл кадәр мөһаҗирләр җирләшкән. Бунлар арасында җирдән яхшы истифадә итә белүчеләр – Кырымнан күчеп килгән татарлардыр. Бунлар башкаларга нисбәтән бик яхшы баеганнар.
Төркиядә, гомумән, татарлар тырышлыклары вә эш күрә белүчелекләре илә мәшһүрләрдер. Хәтта яхшы эш күрә белгәнлекләре илә шөһрәт казанган мәэмүрләр дә – татарлардандыр. Мәсәлән, бу көндә Малия вәзире Габдрахман паша – татардыр, зарбханәнең (монетный дворның) мөдире Габдрахман бәк – татардыр. Пашалардан, мәэмүрләрдән, мөгаллимнәрдән бик күп кешеләр – Кырымнан яки Кавказиядән килгән татарлардыр. Төректер дип фарыз кыйлган, күзгә күренгән бер кешене бераз тәфтиш итеп карасаң, асылы яки үзе татар булып чыга. Төрекләр үзләре – гомумән, рәхәтне яратучан халыклардыр. Анлар күбрәк каһвәханәләрдә иртәдән кичкә кадәр сәясәттән, вакыйгалардән вә башкалардан бәхәс итеп утыруны башка бертөрле эш, мәшәкать яки хезмәт илә мәшгуль булудан артыграк яраталар. Истанбулның бетмәс-төгәнмәс хәдсез каһвәханәләре көндезләрдә дә халык илә тулы була. Кичкә кергәч, кешегә кереп утырырга да урын булмый. Мичсез, салкын өйләрендә туңып, калтырап утырудан каһвәханәләрдә җылынып утыруны бунлар, табигый, артык күрәләр. Өйләренә фәкать ятып йокларга гына кайталар. Мөбаләгә булмасын, кичләрдә ирләрнең уннан берсе дә өйләрендә утырмыйлар, имеш. Бунларны күргән адәм бу тирәләрдә күптән сугыш булгандыр, шәһәрдән егерме биш чакрым җирдә дошман гаскәре бардыр, иртәгә сугыш башлану ихтималы бардыр, дип уйларлык та түгел.
Истанбулда һавалар җылы. Көндезләрдә җылылык ун, хәтта унике градусларга җитә. Үләннәр безең Русиядәге апрель аендагы шикелле яшел. Себзеват бик күп.
Кырым мөселманнарыннан берничә кешеләр, үз араларыннан җыелган иганә акчаларына йөз егерме караватлык хастаханә ачарга җитәрлек әсбаблар алып, фельдшерлар, хаста караучылар илә бергә юлга чыксалар да, Төркия сәфире: «Хәзер мәҗрухлар калмады, «Һилал әхмәр җәмгыяте» хастаханәгә мохтаҗ түгел»,– дигән. Шул сәбәптән берничәсе кире кайтып киткәннәр. Фәкать арадан икесе, җыйган иганә акчаларын һәм әсбабларын урынына тапшыру өчен, Истанбулга килгәннәр.
VII
Бу көннәрдә таралган хәбәрләрдән берсе икенчесенең хилафындадыр. Бүген кичкә таба «Балкан хөкүмәтләре илә Төркия арасында солых ясалган, имеш» дигән хәбәрләр таралган шикелле, «чаталар илә Төркия гаскәренең алдагы фиркаләре арасында сугышлар башланган, имеш» дигән хәбәрләр дә таралды. Хәтта кичә кич илә Чаталҗадан туксан кадәр мәҗрух килгән дигән хәбәрләр дә ишетелде.
Шунлар илә бәрабәр бу көн иртә илә һәм кичә кич чыккан гәзитәләрдә Төркия тарафыннан Лондонга киткән мөрәххәсләрдән: «Без бунда дәхи унбиш көнгә кадәр калып солых хакында мөзакәрә итәчәкмез», – дигән хәбәрләр дә күренде. Истанбул гәзитәләрен укып, хәлнең хакыйкатеннән хәбәрдар булу һич мөмкин түгел. Гәзитәләрдә бер-берсенә хилаф булган хәбәрләр бик күп.

Хәзерге көндә һич шик кыйлмыйча сөйләнәчәк бер сүз бар исә, ул да гәнеж төрек «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасенең галәбәседер. Хәзерге көндә әфкяре гомумия гәнеж төрекләр тарафына авышкан шикелле, хөкүмәт тә анлар тарафына күчә башлады.
Арада бер өченче фирка тәшкил итәргә теләп йөргән Лотфи Фикринең «Тәнзыймәт» исемле гәзитәсе туктатылып, үзе хәрби хөкемгә бирелде. Кичә солтан Мөхәммәд, Сәгыйд пашаны үзенең хозурына дәгъват итеп, берничә сәгатьләр киңәштә булды. Бу эшкә төрекләр, Камил паша кабинетының игътибардан төшеп, яңа кабинет тәшкил итүнең ишарәсе дип карыйлар. Сөйләүләренә караганда, вәли гаһед шаһзадә Йосыф Гыйззетдин илә Камил пашаның аралары тәмам бозылган. Әгәр дә Камил паша садыре- әгъзам булып калса, Йосыф Гыйззетдин вәли гаһедлеген ташлаячакыны игълан иткән. Халык арасында хәзерге көндә Камил пашаның бер кыйммәте дә калмады. Һәркем аңар кырын күз илә карый.
Гәнеж төрекләр гомумән хәзер сугышны куәтлиләр. Һәм хөкүмәтне дә үз кулына алу өчен көн-төн иҗтиһад итәләр. Камил пашага һәркем мәмләкәтне сатучы бер кеше итеп карый.
Көзге вә кышкы көннәрдә Истанбулның һавасы никадәр тиз алмашынучан булса, Төркиянең сәясәт галәме дә шулкадәр үк тиз алмашынучандыр. Бүген иртә илә булган хәл кичкесенә охшамый.
Бу көн мин, Чаталҗадан кайткан бер йөзбашы забит илә күрешеп, андагы гаскәрләрнең хәлләрен сораштым. Минем сөальләремә каршы ул кеше ошбу түбәндәге сүзләрне сөйләде:
– Безнең Чаталҗадагы гаскәрләрнең хәлен бик яхшы дип әйтеп булмый. Чөнки бундагы безнең гаскәрләрнең иң күбесе истихкямнарда чатырлар астында яталар. Һавалар юеш, кичләр салкын, әтраф былчырак вә баткак. Чатырларның эчләре дә юеш. Хәзерге көндә гаскәрләрнең ашамак-эчемлекләре мөкәммәл, һәр көн Истанбулдан бер поезд илә яңа вә йомшак икмәк килеп тора. Шулай булса да суыклык һәм юешлектән гаскәрләр хили зәхмәт чигәләр. Гаскәрләрнең һәммәсен авылларга җирләштерү мөмкин түгел, чөнки Истанбул илә Чаталҗа арасында авыллар гаскәрләрне җирләштереп бетерерлек дәрәҗәдә күп түгел. Гаскәрләрнең сыйган кадәресе авылларга җирләштерелде, ләкин ике йөз ун мең гаскәрне бу авылларга җирләштереп бетерү мөмкин түгел, шул сәбәптән гаскәрләрнең күбесе чатыр астында яшиләр. Дошман тарафыннан булган гаскәрләрнең микъдары, бердән, безнекенә караганда аз, икенчедән, ул тарафларда карьяләр күп булганлыктан, дошман гаскәренең әксәре карьяләргә җирләштерелгән. Безнең тараф салкынлыктан зәхмәт чиккән шикелле, анларның гаскәриләре ашау начарлыктан зәхмәт чигәләр дип сөйлиләр, асылы ничектер, белмим, – диде.
Бу көнгә кадәр Төркия гаскәрләре эчендә вак-төяк сәүдәгәрләр ашамак-эчмәк нәрсәләре илә сәүдә кыйлып йөриләр иде. Бунлар полиция идарәсеннән иҗазәт алып китеп, анда иркенләп сәүдә кыйлалар иде.
Соңгы көннәрдә бунлардан берникадәр кешеләрнең болгар гаскәренә качырып азык ташыганлыклары мәгълүм булды, һәм Болгариягә азык ташучылардан тугыз адәм тотылып гаскәри мәхкәмәгә бирелде. Шул сәбәптән хәзер мөхарәбә мәйданына вак-төяк сәүдәгәрләр җибәрелми. Бундагы сәүдәләрнең һәркаюсы зур кулларга бирелде. Әгәр дә бер кеше бу җирләргә барып сәүдә кыйлу ирадәсендә булса, иң әүвәл өч йөз лира кадәр залук салып, главный штаб идарәсеннән рөхсәт алырга мәҗбүрләрдер. Бу рөхсәт тә әмниятле кешеләргә генә биреләдер. Болгария гаскәрләренә азык качыручыларның әксәре Төркия тәбагасы булган греклар икән, араларында Болгариядән качып килгән болгар гаскәриләре дә бар.
Кичә чыккан Төркия гәзитәләрендә Әдернәгә азык кертелә башланганлыгы язылды. Әгәр дә ике арада чаталар илә атышулар башлаганлык хәбәре дөрест булса, бу хәбәрләргә ышанып булмый.
Бу көн Солтан Ришад, мөхарәбә мәйданындагы гаскәрне карап кайту өчен, Чаталҗага китте. Кичкә таба чыккан хәбәрләрдә Сәгыйд пашаның садыре-әгъзам булып, Мәхмүд Шәүкәт пашаның бөтен гаскәргә командирлык итәчәге сөйләнде.

Венада сәфир Хөсәен Хилми паша Истанбулга кайтырга юлга чыккан. Бәгъзе кешеләр аның садыре-әгъзам булуын ихтимал тоталар.
Бүген Истанбулга берникадәр болгар әсирләрен китереп, Анатолий тарафына озаттылар, буңар караганда, ике арада аз-маз булса да мөсадәмәләрнең башланганлыгы ихтимал тотыла.
Чаталҗага гаскәр күндерү тукталды. Анда китә торган поездлар фәкать азык һәм сугыш ярагы ташу илә генә мәшгульләрдер. Хәзерге көндә килгән гаскәрләрнең һәммәсе дә дип әйтерлек Кәлибулигә озатыла. Кәлибулигә гаскәр булмаган кешене җибәрмиләр. Юлчылар фәкать Чанаккалага гына бара алалар. Көн саен дип әйтерлек Истанбулга хаҗилар кайталар. Отельләр (номерлар) һәм ханәләр һәркаюсы хаҗилар илә тулы. Одессага китә торган пароходлар хаҗиларны бик сайлап кына алалар. Хаҗиларның һәммәсе дип әйтерлек Төркестан, Кашгар, Иран вә гайре җирләрдән килгән кешеләрдән гыйбарәттер. Бунларның пычраклык, тәмизсезлек вә игътибарсызлыкларын һич сөйләп бетерерлек түгел.
Истанбулдагы дәллял вә симсарларның хаҗиларны талауларына тәмам искитәрлектер. Мәсәлән, Истанбулдан Одессага кадәр өченче класс билеты алты сумдыр. Хәлбуки симсарлар хаҗилардан унсигезәр сум каералар. Әле бу пароход билеты тугърысында гына шулай. Әгәр дә анлар Истанбулга чыкканнан соң берәр нәрсә алачак булсалар, анларның эшләре бөтенләй харап. Ике тиенлек тәсбих анлар өчен ике грош (уналты тиен), кырык тиен тора торган фәс бер сум егерме тиен, кырык тиен тора торган номер сиксән тиендер. Дәллялләр соңыннан сатучы яки номер тотучы илә файданы көлешә-көлешә бүлешәләр. Казан яки Кырым әтрафыннан килгән хаҗиларга дәлляләр ул кадәр илтифат та итмиләр һәм анларны үзләре теләгән дәрәҗәдә алдый да алмыйлар.
Әүвәл заманда Истанбулда акча алмаштыру мәсьәләсе дә зур бер бәла иде. Саррафлар халыкны теләгәнләренчә алдыйлар иде. Хәзерге көндә күзе ачык кешеләр каршында бунларның әһәмиятләре калмады. Чөнки хөррият булганнан соң гәнеж төрекләр вак акчаны бик күбәйткәннәр, әүвәлдә мәтәлик дип тәгъбир ителә торган вә язулары беленми торган бакыр акчалар урынына ак мәгъдәннән эшләнгән матур акчалар йөри. Дүртенче көн Төркиянең акчалар сугыла торган зарбханәне (монетный дворны) барып карадым... Бунда йөз кадәр кеше акча сугу илә мәшгульләрдер. Хәзерге көндә алтын вә көмеш акчалар сугылмыйча, фәкать ак мәгъдәннән бер грош (сигез тиен), егерме парә (дүрт тиен), ун парә (ике тиен) һәм биш парәлек (бер тиенлек) акчалар гына сугыладыр. Бу акчалар көненә өч йөз утыз мең данә микъдарында ясаладыр. Бунда акча суга торган унике данә машина бар, һәркаюсы электрик илә хәрәкәт итәләр. Әүвәлдә машиналарны Англия яки Франциядән китерәләр икән, хәзер төрекләр үзләре ясыйлар. Читтән килгән иске машиналарны таратып куйганнар, яңадан төзәтеп эшкә кертәчәкләр. Шунда хезмәт итә торган төрекләрдән берсе алтын үлчәр өчен бер үлчәү ихтираг иткән. Бу үлчәү мыскалның туксан алтыдан бер өлеше булган долянең дүрттән бер өлешеннән үлчи аладыр.
Зарбханәнең мөдире Габдрахман бәкнең (кырым татарының) сөйләвенә караганда, әүвәлдә бунда хезмәт итүчеләрнең һәммәсе дә әрмәниләр булганнар. Хәзерге көндә бунлардан фәкать өчесе әрмәни булып, калган һәммәсе дә мөселманнардыр. Әүвәл Истанбулның һичбер җирендә телефон юк иде, хәзер хөкүмәт даирәләре һәм политсә идарәләренең һәркаюсында телефоннар булган шикелле, зур тиҗарәтханәләренең дә һәркаюсында телефоннар бар. Хәзерге көндә дә һәр җирдә телефоннар эшләп яталар, Галатага чыга торган күпердән ерак түгел җимеш искәләсенә якын бер урында телефон мәркәзе өчен зур бер бина да салып яталар. Телефон чыбыклары һәр җирдә җир астыннан трубалар илә йөртеләчәктер.
Бу ел ук шәһәргә электрик утлары кертергә дә керешеләчәк, имеш.
Электә кояш баегач та бугаз эче, Хәйдәр паша, Казыкөй һәм Халиҗ пароходлары туктый, ул җирләрдә хәят тәмам бетә иде. Бу көндә бунларның һәрберсендә пароходлар кичке

сәгать ярымларга кадәр йөридер. Бу пароходларның һәркаюсына электрик прожекторлары куелган. Шуның васитасы илә юлны карап, үзләренең юлларында дәвам итә бирәләр.

VIII

Актык дәкыйкаләр якынлашты. Бу мәктүбне язган заманда Төркия илә Балкан хөкүмәтләре арасында яңадан сугышлар башлануга фәкать алты гына сәгать калды. Балкан хөкүмәтләре Әдернәне, Ак диңгездәге атауларны һичбер шарт һәм кайдсыз үзләренә алырга телиләр, төрекләргә бу хакта ультиматум бирделәр. Әгәр Төркия бу көн өйләдән соң сәгать дүрттә ризалык җавабы бирмәсә, сугышырга башлаячаклар. Төркиянең бу шартларга һичбер разый булу ихтималы юк. Хосусән гәнеж төрекләр Төркия өчен зур хурлык булган бундый солыхка риза булырга һич теләмиләр. Шул сәбәптән сугыш башлану ихтималы бик куәтледер.

Көн-төн һичтуктаусыз Чаталҗага гаскәр, азык һәм сугыш яраклары ташып торалар. Ике-өч көн бундан мөкаддәмдә Германиядән берничә батарея туп килде. Анларның да һәммәсен Чаталҗага озаттылар.

Төркиянең сугыш пароходлары да һәркаюсы эштә. Бер тарафтан Ак диңгездә Греция пароходларына каршы торган шикелле, икенче тарафтан да Болгариягә читтән ярдәм килмәсен өчен Варна лиманын саклыйлар.

Соңгы көннәрдә гаскәр өчен уңайсызлык баш күтәрде. Бу көнгә кадәр Истанбулда һавалар җылы һәм кояшлы иде. Егерменче декабрьгә каршы төндә һава бердән-бергә алмашынып китеп салкынланды. Егерменче декабрьгә каршы төндә дүрт дәрәҗә кадәр суыклык булып, сулар катты. Шул көннән бирле аз булса да суыклык дәвам итә һәм һәр көн дип әйтерлек ягъмурлар ява.

Һаваның начарлануы гаскәргә бик зур тәэсир итте. Гаскәр арасында авыруларның артуына сәбәп булды. Бу көннәрдә Чаталҗадан меңнәрчә хаста гаскәрләр Истанбулга килә башладылар. Соңгы көннәрдә бушап килә торган хастаханәләр яңадан гаскәриләр илә тула башлады. Һавалар суыклану сәбәпле, холера азайса да, ревматизм, дизентерия кеби хасталыклар көннән-көн артып бара.

Болгарлар Әдернәне куәт илә алмаганлыкларыннан, хәзер прокламацияләр таратып, халыкны үзләренә каратырга тырыша башладылар. Болгария аэропланнары, Әдернә шәһәренең өстенә килеп, төрле вәгазь һәм нәсыйхәтләрдән гыйбарәт булган прокламацияләр тараталар. Ихтиляфчылар соңгы көндә хили какшадылар. Анларның солых тарафдарлары булулары вә иттихадчыларның  сугыш тарафдары булулары аркасында, әфкяре гомумия бөтенләй гәнеж төрекләр тарафына авышты. Төрекләр Әдернәне кулларыннан ычкындырырга бер дә теләмиләр, ахыр сулуларына кадәр көрәшергә хәзерләнәләр. Төрекләр хәзер үзләрендә мөттәфыйк дәүләтләргә каршы торырлык куәт хис итәләр. Шул сәбәптән бу көн кич Истанбулда туп тавышларының ишетелә башлаулары ихтималдыр.

IX

Хәзерге көндә солых булачакмы-юкмы – Истанбулда һичкем белми. Шулай да булса яңадан сугышларның башлануын фараз кыйлып булмый. Истанбулда һавалар тәмам бозылды. Кичләрдә кар ява, көндезләрдә ягъмур явып бөтен урамнарны былчыракка батыра, һәр җирдә юешлек һәм салкынлык хөкем сөрә. Һаваның начарлыгы әһалигә дә бик начар тәэсир итә. Бундан берничә көн элек үзләрен бик нык һәм куәтле дип фараз кыйлган вә сугыш тарафдары булган төрекләр бу көн солых тарафдары була башладылар.

Безнең Русиядәге суыкларга караганда, бундагы суыклар бик аз булса да, бездәге шикелле таза итеп салынган мичле өйләр булмаганлыктан, суык өйләрдә яшәүче адәмнәрнең хәлләре бик начардыр. Суыклык аркасында инфлюэнция, дизентерия һәм ревматизм хасталыклары бу җирләрдә бик күптер. Һавалар соңгы көннәрдә бик бозылды. Бик каты шималь давыллары исә.

Берничә көн бундан мөкаддәм «Русское общество»ның пароходларыннан «Синийус» исемле пароход илә өч йөз илле кадәр хаҗи Феодосиягә киткәннәр иде. Истанбул бугазының агызында (Куакта) өч көн карантинда утырганнан соң диңгезгә чыкмышлар

исә дә, пароходлары дулкыннарга тәхәммел итә алмаган. Кайсының башлары ярылып, кайсыларының куллары имгәнеп, кире Истанбулга кайттылар. Хәзерге көндә бунлардан эксәре үзләренең Одессага дип алган билетларын ташлап, Румания юлы илә качып китәләр.
Одессага мөселманнан һичкем кабул ителми. Феодосиягә дә пароход китми. Шул сәбәптән хаҗиларның бунда калганнары Батумга китәргә мәҗбүрләр. Анда киткәндә дә хаҗилар үзләренең «обратно» дип алган билетларыннан файдалана алмыйлар. Чөнки «Русское общество» пароходларында хезмәт итүче берничә билетчы румнар илә Истанбулдагы симсар һәм номер тотучылар бер киңәштә булып хаҗиларны талыйлар. «Сезнең бу билетларыңыз эшкә ярамый», – дип, яңа билет алдыралар. Бундан өченче класс билеты биш сум сиксән тиен кадәр генә исә дә, анларны унсигез сумга, икенче класс билеты ундүрт сум гына исә дә, анларны егерме алты сумларга кадәр хаҗиларга саталар. Аның өстенә дә, «Бу көнге пароходта урын юк» дип, хаҗиларны берәр атна утыртып, номер хуҗаларына файда иттертәләр. «Русское общество»ның бундый эшләргә бер дә дикъкать итмәве тәәссеф бер хәлдер.
Югарыда Истанбул әтрафында һаваларның бик начар икәнлегеннән бәхәс иткән идем. Һаваның бундый начар булуы гаскәрләргә дә бик начар тәэсир итә. Гаскәр арасында хасталык көннән-көн артып бара. Өйләр эчендә, бераз гына булса да җылылык бирә торган мангаллар янында, утыра торган кешеләр арасында хасталыклар күп булганнан соң, салкын һавада, былчырак һәм юеш җир өстенә корылган чатырлар астында утыра торган гаскәр арасында хасталыкның күп булачагы табигыйдер.
Өченчекөн «Мәҗидия» крейсеры, томаннан истифадә итеп, Грециянең Шира атавына кадәр барган һәм анда Грециянең «Македония» исемле бер крейсерын батырып һәм андагы күмер деполарын (складларын) тупка тотып, хили тәләфат биргән. Бу муаффәкыять төрекләргә гүзәл тәэсир бирде һәм анларның рухларын күтәрде.
Мохарәбә мәйданына гаскәр, әрзак һәм сугыш яраклары күндерү һәмишә дәвам итә. Көн саен Истанбулдан Чаталҗага бер поезд икмәк китеп тора.
Кичә алтынчы урдуны пароходлар илә Бандырма һәм Кәлибулигә күндерделәр. Безнең номерда тора торган һәм гаскәр вә әрзак күндерү илә мәшгуль булган йөзбашы бер афисәрнең сөйләвенә караганда, хәзерге көндә Чаталҗада – ике йөз илле мең, Чанаккалгада – сиксән мең, Кәлибулидә дә йөз мең кадәр гаскәр бар. Дүртенче көн Чаталҗага Германиядән яңа килгән туплар илә өч поезд ат күндерделәр. Шулай ук кичә Чанаккалгага бер пароход илә сыгыр һәм үгезләр күндерелде. Анатолийдән һәр көн көтү-көтү атлар килеп тора. Әгәр бундан соң сугыш башланса, төрекләр үзләренең җиңәчәкләренә тәмам ышаналар.
Әдернәдән килгән телеграмнарда анларның бирешергә ниятләре юк икәнлеге аңлана һәм азык вә сугыш яракларына ихтыяҗлары юк икәнлеге күренәдер.
Истанбулда тәәссеф ителәчәк бер нәрсә бар исә, ул да – хөкүмәт идарәсен үз кулларына алу яхуд та үз кулларында калдыру өчен ике партия арасында булган көрәшләрдер. Хәтта өченчекөн кич садыре-әгъзам Камил пашаның җанына касд итү кадәр дә бер эш булган. Шул сәбәптән Истанбулда идарәи горфия (военный положения) дәхи дә куәтләнде. Әүвәлдә идарәи горфия кич сәгать уннан башлана иде, хәзер кич сәгать тугыздан соң урамнарда йөрү мәмнүгъдыр.
Төркиядә буның өстенә яңадан бер уңайсызлыклар вөҗүдкә килергә тора.
Соңгы көннәрдә Әрмәнстан һәм Сурия мәсьәләләре мәйданга чыкты. Бу вилайәтләрдә булган халыклар да үзләренә автономия телиләр. Шул сәбәптән Төркия, бу тарафларга да гаскәрләр күндереп, үзенең куәтен бүләргә мәҗбүрдер.
X
Истанбул гади күренешкә кереп бара. Әүвәлдәрәк христианнарга тәҗавезләр булу куркусы илә башларына фәс кигән кешеләрнең күбесе, фәсләрен салып, эшләпә, силиндр вә катилукләрен киделәр. Соңгы көннәрдә атлар да күбәйде. Анатолийдән бик күп атлар китерелде. Мин килгән көннәрдә күренгән камыт яки ияр илә җилкәләре чиләнгән атлар

хәзер бер дә күренми. Гаскәрләрнең атлары һәркаюсы таза. Бер-ике көннән бирле гаскәр күндерү эшләре дә азайды. Чөнки сугыш булган тәкъдирдә дошманнарга янә каршы торырлык гаскәр тәкмил ителде. Гаскәр арасында холера хасталыгы да тәмам бетте. Хастаханәләрдә мәҗрухлар бер дә калмады. Гаскәрнең мадди җәһәтләре яхшыланган шикелле, мәгънәви җәһәтләре дә бик яхшыланды. Хәзер гаскәрдә дә, халыкта да сугышка иштиһа бик зурдыр. Яңадан сугыш булган тәкъдирдә дошманнарны җиңәчәкләрендә төрекләр шөбһә итмиләр. «Хәмидия» пароходының Шира атаулары янында зур эшләр күрүе төрекләрне бик шатландырды. Төрекләрдә «Хәмидия» пароходының командиры Рәүф бәкне бик мактыйлар, аның берничә мәртәбәләр күрсәткән каһарманлыкларын бик мәдех итәләр. Узган шинбә Чанаккалга бугазының тышында булган диңгез сугышларында һәр ике тараф көймәләрендә дә хили һәлакәт һәм зарарлар булган. Грециянең бронинос, крейсер һәм минаносларында зур зарарлар булган шикелле, Төркиянең «Тургуд рәис» илә «Барбарос Хәйретдин» пароходларында да хили зарарлар булган. «Барбарос Хәйретдин»нең гүвәртәсе бераз җимерелгән, шулай да булса сугыш сафыннан чыгарлык дәрәҗәдә түгел. Һәр ике тарафтан да үлгән һәм җәрәхәтләнгән кешеләр күп булган. Мәҗрухларны «Рәшид паша» исемле хастаханә пароходы илә Терсанә хастаханәсенә китерделәр. Гәзитәләр «һәрнәкадәр җитмеш кадәр генә мәҗрух килде» дип язган булсалар да, асылда, мәҗрухлар ике йөздән зиядәдер. Бу сугышта ике тараф та, бер-берсен артыннан кумыйчы, кире чигенергә мәҗбүр булдылар. «Хәмидия» крейсере командирының каһарманлыгын һич мактап бетерә алмыйлар. Япа-ялгыз үзе генә Юнан суларына барып, андагы Шира лиманын тупка тотып, бер крейсерне батырды һәм күмер деполарына күп зарарлар китерде. Юнаннар, Салониктагы гаскәрләрен пароходларга төяп, диңгез тарикы илә Яния тарафларына күчермәкче иделәр, ләкин «Хәмидия» пароходының тәҗавезләреннән куркып, гаскәрен корыдан күндерергә мәҗбүр булды.

Төркия Әдернәне бирергә һич разый булачак түгел иде һәм сугышырга да тәмам хәзер иде, ләкин Русиянең эшкә килеп катышуы вә «Болгариягә Әдернәне бирмәсәңез, җөда эшкә керешәчәкмез» дип тәһдид итүе, аның өстенә Иэтиляфы мөсәлләс әгъзаларының Русиянең бу хәрәкәтенә разый булулары вә бу хәрәкәткә каршы иттифакы мөсәлләс әгъзаларының да сөкүт итүләре Төркияне хәвефкә төшерде. Төркия хөкүмәтен каушатты. Әүвәлдә сугыш тарафдары булып язып килгән һәм мөттәфыйк хөкүмәтләргә бер карыш җир бирергә разый булмаган гәзитәләр соңгы нота бирелгән көннән башлап солых тарафдары була башладылар. Кичә чыккан «Икъдам» гәзитәсе буны ачыктан-ачыкка язды: «Мадам ки Русия безгә каршы төште, мадам ки Иэтиляфы мөсәлләс әгъзалары аның тарафдарыдыр, Иттифакы мөсәлләс әгъзалары да безнең файдамызга тавыш бирмиләр, безнең өчен үзләренең кәефләрен бозмыйлар, безгә дустлык күрсәтмиләр, шулай булып торганнан соң, безнең ул кадәр куәтле зур мәмләкәтләргә каршы тору ихтималымыз булмаганлыктан, анларның сүзләрен тыңламый чарамыз юктыр. Әгәр без анларның киңәшләрен тотмыйчы сугышсак һәм ул сугышта галиб булсак та, дәвале могаззамә безнең файдамызга һичбер эш эшләмәячәк, һәммәдән дә үзләренең морадларына муафыйк рәвештә безгә хөкем итәчәкләр. Әгәр дә (Ходa күрсәтмәсен!) без җиңелеп куйсак, ул заманда безнең мөхалифләремез бездән дәхи дә артыграк нәрсәләр таләп итәчәкләрдер. Безнең хәзерге көндә һичбер дуст дәүләтләремез юктыр. (Әгәр булса, без анларга ышанып, бәлки, бер эш күрә алыр идек.) Дустларымыз булмаганнан соң, алты зур дәүләтләрнең кәефләрен җибәреп, яңадан сугыш башлау безнең өчен файдалы булмаячактыр», – ди.

Дәүләтләр тарафыннан тәкъдим ителгән нотага каршы Төркия хөкүмәте үзенең җавабын иртәгә бирергә тиештер. Бу нотага җавап бирү хакында киңәш өчен Төркия хөкүмәте Мәҗлесе әгъян әгъзаларыннан, шаһзадәләрдән һәм төрле эш башында булган зур мәэмүрләрдән гыйбарәт булган бер «Мәҗлесе миллия» ясады. Төрекләр бунларны хили тәнкыйть итәләр. «Бу эш кануны әсаси һәм мәшрутият кануннарына мохалиф бер эштер. Буңа итагать итү безнең өчен лязим булачак бер эш түгелдер», – диләр.

Ләкин хөкүмәт буңа карамады. Кичә «Мәҗлесе миллия» җыелды, ләкин хәзергә кадәр нәтиҗәсе мәгълүм булмады. Гәзитәләрнең язуларына караганда, нотага каршы биреләчәк җавап лаихәсенең мәтенендә Әдернә шәһәре хосусый бер идарә илә идарә ителә торган бер шәһәр булуга һәм дә Бәхре сәфид атауларының автономияле җирләр булып калуына ризалык күрсәтелә, имеш.
Истанбул вә этрафында һавалар гаять начар, юеш вә ягъмурлы булганлыктан, гаскәрләрнең хәлләре бик уңайлы түгелдер. Бу көнгә кадәр мөһаҗирләрнең Анатолийгә урынлаштырып җителә алмаганнары чатырлар астында яшиләр иде, хәзер анларның һәммәсе Әдернә капусы этрафындагы җәмигълар илә солтан Әхмәд җәмигъларына җирләштеләр. Мәйданда хәзер бунларның бала-чагаларын һәм йорт әсбабларын төяп, үгезләр җигеп килгән арбалары гына калды. Бунда килгәннән соң үгезләрен дә яхшы бәһаләргә сатып бетерделәр. Бунларга хөкүмәттән һәр көн икмәк һәм он бирелеп тора. Кырык Кәлисә, Лүләбургаз, Чиркәскөй, Чүрлү һәм Чаталҗа мөхарәбәләрендә булган бер меңбашының сөйләвенә караганда, Чаталҗаның аргы ягындагы авылларның һичберсендә һичбер мөселман калмаган. Һәркаюсы кайда качып киткәннәр. Мөселманнар калмаган шикелле, ул тарафларда һичбер хайван да калмаган. Әүвәлдә сөттән ясала торган нәрсәләрнең һәркаюсы шул тарафлардан, хәтта Болгариядән килә икән, хәзер ике араны мөхарәбә мәйданы булгәнлектән, бундый нәрсәләр һич килми. Әүвәлдә укасы җиде-сигез грошка сатыла торган пәйнирләр (сыръ) хәзерге көндә унсигез-егерме грошка җитте. Ул тарафлардан куй килмәү сәбәпле, итнең дә кадагы кырык тиен булды.
Бу көннәрдә Әнвәр бәкне күрү максаты илә ханәләренә киттем. Үзен өйдә тугъры китерә алмадым исә дә, атасы илә бер ярты сәгать кадәр мөзакәрәләрдә булындым. Әнвәр бәккә бер дивизия гаскәрне командовать итәргә биргәннәр. Әгәр сугыш булса, Чаталҗа мөхарәбәләрендә иштиракь итәчәк. Әнвәр бәкнең Шәех Сәнүси кызына никахланган дигән хәбәрләр ялган икән. Сәнүсинең һичбер кызы юк икән. Шулай да, гәрчә пәдәре тасдикъ кыйлмаса да, әгәр солых булса, Әнвәр бәкнең яңадан Траблискә китәчәген сөйлиләр.
Әнвәр бәк Наполеонга тәкълидне сөя торган бер кеше булса кирәк, чөнки без утырган бүлмәсендә Наполеонның төрле вәзгыятьләрдә төшерелгән кыяфәтләре бик күп.

## XI
## Төркиядә зур үзгәреш

«Мәҗлесе миллия» җыелганлыгы хакында узган мәктүбтә язган идем. Мәҗлесе миллинең дә Әдернәне һәм атауларны биреп килешү ягында булганлыгын да бераз аңлаткан идем. Мин ул мәктүбне почтага биргән заманнарда Вәзирләр шурасы киңәш мәҗлесендә иделәр. Бу мәҗлес актык мәҗлес иде. Анларның ни сурәттә җавап бирәчәкләре дә әүвәлдән үк билгеле иде. Ягъни анлар, Әдернә һәм атауларны биреп булса да, килешү тарафында иделәр һәм шул көн өйләдән соң сәгать дүрттә Австрия сәфиренә җавап та бирәчәкләр, эш тә бетәчәк иде. Гәрчә электән «Иттихад вә тәрәккъый» фиркасенә мәнсүб адәмнәр Вәзирләр кабинетын алмаштырырга тырышалар икән дип ишеткән булсам да, бу көн солыхнамәгә имза итәчәкләренә шөбһә итми идем. Шул сәбәптән узган мәктүбне рус почтаханәсенең ящигенә салган вакытымда, бу мәктүб инде минем актык мәктүбем булыр, киләчәк почта пароходы илә Русиягә китәрмен, дип хәтеремә килде. Почтаханәдән чыгып ашханәгә, аннан да номерыма килдем. Анда үземнең белгән бер аркадашым илә бер сәгать кадәр сөйләшеп утырдым. Утыра торгач, колагыма «садыре-әгъзам», «Әнвәр бәк» дигән сүзләр ишетелә башлады.
«Тукта әле, карыйк, нәрсә сөйләшәләр икән»,– дип тышка чыктым, анда: «Бабыгалидә хәзер кыямәт! Камил пашаны хәзер урыныннан төшерәчәкләр, Әнвәр бәк Мабежингә киткән»,– дидедер.
Тиз генә номердан чыгып Бабыгалигә йөгердем. Мин барганда, Бабыгали урамы һәм Бабыгали ишегалды бөтенләй халык илә тулы иде. Аздан ун мең кадәр халык бар иде.

Бабыгали бинасы баскычларының ике тарафларына ике мәшрутиять флаклары күтәргәннәр, хатиблар каты-каты нотыклар сөйлиләр.
Халыклар да «Яшәсен Әнвәр бәк!» дип кычкыралар. Бер-бер артлы тәкбирләр әйтәләр. Бер автомобиль килде исә, «Иштә Әнвәр бәк килер. Яшәсен Әнвәр бәк! Яшәсен милләт! Яшәсен мәшрутиять!» дип кычкыралар.
Мин бу вакыйганең тәфсыйлатын аңлату өчен, Әнвәр бәк илә Бабыгалинең эченә кергән кешеләрнең сүзләрен нәкыль итәчәкмен.
Мин бу вакыйгадән соң Әнвәр бәк илә эчкә кергән өч кеше илә күрешеп сөйләштем. Анлар миңа вакыйгане ошбу түбәндәге рәвештә хикәят иттеләр.
Төрек милләте Кырык Кәлисә мәгълүбиятеннән бирле хәзерге хөкүмәт ияләренең эшләреннән мәмнүн түгел иделәр. Ничек итеп булса да бу кабинетны күздән төшерергә уйлыйлар иде. «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасенең әсхабе дә бу фикер илә мәшгуль иде. Иттихадчылар бер айдан бирле бу кабинетны ничек итеп истигъфа кыйлдыруның юлларын уйлап, аның хакында тырыштылар. Соңгы һәфтә эчендә бу иҗтиһад дәхи дә куәтләнде. Хәтта узган һәфтәдә берничә фидаи садыре-әгъзам Камил пашага кереп, аның истигъфа итүен таләп иттеләр. Ул заман Камил паша үзенең хәйләкәрлеге илә котылып калды.
Аннан соң иттихадчылар, яңадан яхшырак уйлашып, үзләренә бер план тәртип иттеләр. Бабыгали әтрафында сакчылык ләвазимен әда кыйла торган гаскәриләрнең һәммәсен иттихадчылардан куйдылар.
Бабыгалигә якын йортларның тәрәзәләренең һәрберсенә дә тәмам коралланган дүртәр-бишәр адәмнәрне җирләштерделәр. Соңра бу эшләр тәмам булгач, бүген өйләдән соң ике ярым сәгатьтә Әнвәр бәк, Сабикъ дахилия вәзире Тәлгать бәк, Җамал бәк, хөррият вакыйгаләрендә Әнвәр бәк кадәр үк каһарманлык күрсәткән Мостафа Нәҗип бәк һәм Төркиянең иң мәшһүр хатибларыннан саналган Наҗи бәк, Нуры Госмания җәмигъсы якынындагы «Икъбал» кыйраәтханәсенә килеп, бер-берсе илә күрештеләр. «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасенә мәнсүб адәмнәргә дә әүвәлдән шифрлы телеграмлар илә хәбәрләр бирелгән иде.
Иштә, тәмам ике ярым сәгатьтә, Әнвәр бәк атка атланып, башкалары да җәяү уларак Бабыгалигә хәрәкәт иттек. Бабыгалигә барып җиттек. Аның ишегалдына кердек. Андагы гаскәриләр һәммәсе иттихадчы булганлыктан, безгә һичбер төрле мәмнугат күрсәтмәделәр.
Аннан уздык. Без, Әнвәр бәк илә унбиш кеше, баскычлардан югары чыгып, Бабыгалинең ишеген ачтык. Нәкъ шул заманда садарәт йәверләреннән Нәфиз бәк (арнауд гыйсъяннарында иң әүвәл башлап алга чыккан кеше) илә садарәт йәверләреннән Тәүфыйк бәк безгә каршы ата башладылар. Без дә аңгарга каршы аттык. Анларның икесен дә җиргә төшердек, фәкать анларның аткан җәдрәләреннән безнең хөррият каһарманнарыннан Мостафа Нәҗип бәк вафат булды.
Соңра без янә алга таба атладык. Шул заман револьвер тавышларын ишетеп тышка чыккан Бәхрия назыйры Назыйм паша, безгә каршы револьверын чыгарып, Әнвәр бәкне үтерергә теләде. Безнең програмымызда, үзләре модафәга итмәгән тәкъдирдә, һичкемгә җәдрә ашату маддәсе юк иде. Ләкин ни эшләмәк кирәк, әгәр без атмасак, ул атып Әнвәр бәкне үтерәчәк иде. Шуның өчен без сабыр итә алмадык, бердән атып, Назыйм пашаны үтердек. Ул үлгәч, башкалары йомшардылар. Әнвәр бәк анларның каршысына килде. Анлар да унике адәмнән гыйбарәт иде, шул дәкыйкадә Әдернә һәм атауларны биреп, солых ясарга имза итәчәкләр иде. Австриянең сәфире дә шунда җавап алуны көтеп тора иде. Әнвәр бәк килеп, солых могаһәдәсе хакында язылган бу кәгазьләрне кулларыннан алып җыртып ташлады, һәм үзләренә истигъфанамәләрен язарга әмер итте. Бичара картлар курыктылар, үзләренең истигъфанамәләрен яздылар. Әнвәр бәк, ул истигъфанамәләрне алды да тышка чыкты, соңра, Бабыгалине саклый торган командирны чакырып: «Хәзер һәммә эш бетте, сез рәхәт булыңыз, халыкны голуянга китермәңез. Мин хәзер килермен», – диде. Һәм дә, халыкка хитаб итеп: «Сез монда бераз мине көтеп торыгыз,

мин Мабеҗингә китеп, аннан сезгә яңа бер садыре-әгъзам китерәчәкмен», – дип, автомобильгә утырып, сарайга китте. Бу вакытта Бабыгалинең алдында берничә мең халык бар иде. Һәркаюсы иске вәзирләргә нәфрәт итәләр иде, хәтта Хариҗия вәзире Нурадунгян (?) әфәнденең яңагына да менеп төшкән кешеләр булгалады, дип сөйләде. Иштә шул вакыйгадән соң халык арасында яңа бер рух кузгалды. Һәр тарафтан тәкбир тавышлары ишетелә башлады. Халыкның кайсы җылый, кайсы шатлана. Төрле-төрле хатиблар баскычка чыгып хәрарәтле нотыклар сөйлиләр.

Берзаман «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасе тарафыннан тәнбиһнамәләр таратыла башлады. Ул тәнбиһнамәләрдә мохтәсарән ошбу сүзләр язылган иде: «Без Траблистә итальяннарны җиңеп сугышкан берзаманда Шимали Арнаутлыкта берникадәр явызларның хөкүмәт хилафына кабызган явызлык утларын сүндерер өчен җибәргән гаскәрләремез арасыннан бәгъзе бер афисәрләрнең ачыктан-ачык гасыйларга иярүләре һәм Җәнүби Арнаутлыкта шул ук максуд илә кораллары илә качып китеп, безнең хариҗи сугышларымыз эченә дахили сугышлар арттырулары безне хафага төшерде. Шул заманнарда Сәгыйд паша кабинеты куәтсез саналып, аның урынына Мохтар паша кабинеты тәшкил ителде. Бу кабинет ясалгач, һәркем рәхәтлек башланыр дип өмид иткән иде. Ләкин бу кабинет та гасыйларга каршы бер эш тә эшли алмады. Аның эш күрә алмавыннан файдаланып, гасыйлар, иң әүвәл Приштинә, соңыннан Эскүбкә кереп, хөкүмәт мәэмүрләрен урыннарыннан төшерү шикелле азгынлыкларда булдылар. Хөкүмәт бунларга каршы бертөрле тәдбирләрдә дә булмады.

Шул сәбәптән хөкүмәтемезнең бу йомшаклыгы анларның иштиһаларын тагын да бер кат арттырды. Әхмәд Мохтар паша кабинеты, бунларга каршы бер сүз сөйләмәү өстенә, мәшрутият кануннарына хилаф уларак Мәҗлесе Мәбгусанны да таратты. Хасиле генә, Төркиянең ул замандагы кабинеты үзенең дошманнары каршында куәтсез икәнлеген билфигыль күрсәтте. Ул заманнарда шундый гафләтләр эшләделәр ки, Балкан хөкүмәтләре безнең илә сугышлар өчен дип гаскәр хәзерләгән берзаманнарда безнең вәзирләремез йөз егерме мең кадәр низами гаскәрләремезгә Рум иленнән өйләренә кайтырга рөхсәт бирделәр.

Әгәр дә сугыш башында бу гаскәрләр илә дошманга каршы торган булсалар иде, безнең галиб булучылыгымызда һичбер шөбһә юк иде. Шул ук вакытта хөкүмәтебез яңадан бер ахмаклык күрсәтте: Рум иле рәдифләрен җыеп маневрлар ясап маташты. Русия Болгариягә язга кадәр сугыш башламаска киңәш биргән булса да, Болгария, без мондый уңайлы заманны тагын күрә алмабыз, бундый кабинет яңадан кайчан булыр, дип, сугыш башлады. Безнең әүвәлдән үк Балкан хөкүмәтләренә каршы хәзерләнеп куйган планнарымыз бар иде. Ләкин Мохтар паша кабинеты илә аннан соң килгән Камил паша кабинеты буңа игътибар итмәделәр. Анлар фәкать үзләренә мохалиф булган фирка кешеләрен тәүкыйф итү белән генә мәшгуль булдылар.

Габделхәмид заманындагы шикелле, хафияләрне вөҗүдкә китерделәр. Сугыш мәйданында да кулыннан бер эш килми торган командирлар куйдылар. Чаталҗа сугышында без галиб булган булсак та, анлар, аңа карамыйча, мөтарәкә ясап, солых гакыд итү өчен Лондонга вәкилләр күндерделәр. Лондонда булган мәҗлесләрдә дә безнең мөрәххәсләремез йомшаклык күрсәттеләр. Шул сәбәптән безнең дошманнарымызның күңелләре үсеп, бездән күп нәрсәләр сорый башладылар. Камил паша кабинеты да моңар ризалык күрсәтте. Әгәр дә без бераз сабыр иткән булсак, безнең Әдернә дә, атауларымыз да кулдан киткән булачак иде. Без буңа сабыр итә алмадык. Шуның өчен һәрбер бәлане күз алдымызга алып мәйданга чыктык».

Таратылган прокламация шуннан гыйбарәт иде. Халык буны бик яратып укыды. Һәр тарафтан хәзерге Вәзирләр кабинетына нәразыйлык изһар итәлә иде.

Берзаман автомобильләр тавышы ишетелә башлады. Әнвәр бәк килде. Халык аны тәмам күкләргә очырачак дәрәҗәдә күтәреп, кул чабып: «Яшәсен Әнвәр бәк!» – дип каршы алдылар.

Әнвәр бәк: «Шат булыңыз! Хәзер кабинет алмашынды, Мәхмүд Шәүкәт паша садыре-әгъзам булды, бундан соң дошманга арка бирмәмез», – дип, берникадәр сүзләр сөйләп, Бабыгалигә кереп китте. Аннан соң Мабеҗин кятибләре килеп, эчкә кереп, солтанның ирадәсен укыдылар. Анлардан берничә дәкыйкадән соң янә бер автомобиль илә Мәхмүд Шәүкәт паша Бабыгалигә килде. Халык аны янәдән бик зур шатлыклар илә каршы алдылар. Аны кочакладылар, үптеләр, кул өстендә Бабыгали эченә керттеләр. Соңра Шәүкәт паша янәдән чыгып, берникадәр халыкка кыскача бер нотык сөйләгәннән соң, анларның таралуларын үтенде. Халык та итагать итеп таралды. Халык таралганнан соң, Мәхмүд Шәүкәт паша төн буена кабинетны алмаштыру хакында киңәшләр илә мәшгуль булмыштыр. Бүген иртә илә чыккан гәзитәләрдә Вәзирләр кабинетының тәмам үзгәргәнлеге күренде.

Хәзерге Төркия кабинеты ошбу адәмнәрдән гыйбарәттер:

Садыре-әгъзам һәм хәрбия вәзире – мәшһүр Мәхмүд Шәүкәт паша;
Шураи дәүләт рәисе – принц Сәгыйд Хәлим паша;
Дахилия назыйры – Хаҗи Гадел бәк;
Хариҗия назыйры вәкиле – сабикъ Афина сәфире Мохтар бәк;
Бәхрия вәзире – Черексулы Мәхмүд паша;
Гадлия вәзире – сабикъ Истанбул вәлисе Ибраһим бәк;
Малия назыйры – диване мөхасәбәт рәисе Рәфгать бәк;
Әүкаф назыйры – Хәйри бәк;
Тиҗарәт һәм зирагать назыйры – сабикъ Айдин вилайәте вәлисе Җәлал бәк;
Почта вә телеграф назыйры – сабикъ Сарухан мөтасаррифы Шөкери бәк;
Нәфәка назыйры – Бәсария әфәнде;
Шәйхелислам фәтваи – Әмин Әсгад әфәнде.

Кабинет алмашынганнан соң, җәраян башланды. Төркия хөкүмәте Әдернә илә атауларның мохалифләр кулына китүенә һич разый булмыйлар. Әгәр дә мохалифләр бу җирләрне сорый торган булсалар, сугышырга да хәзерләрдер. Гаскәр арасында да рух күтәрелде. Кабинет алмашынганны ишеткәч тә, Чаталҗадагы гаскәрләр шенлекләр ясап бәйрәм иткәннәр. Гаскәрләр Мәхмүд Шәүкәт паша илә Әнвәр бәкне бик яраталар. Һәркаюсы анлар өчен җаннарын фида кыйлырга хәзерләрдер.

Соңгы көн хатирәләре

Миңа Истанбулдан сугыш башланыр көндә генә чыгып китәргә тугъры килде. Безнең пароходымыз кузгалып киткәндә, сугыш башланырга сигез сәгать кенә калган иде. Шулкадәр аз вакыт калган булса да, Истанбулда зур тәбдил күренми иде. Фәкать тимер юл стансиясе тирәсендә генә гадәттәгедән артыграк хәят күренә иде. Чөнки бу көнгә кадәр Төркия сугыш өчен кирәк булган нәрсәләрнең һәммәсен алдан хәзерләп бетереп куйган, кирәк булган ризыклар вә сугыш яракларын Чаталҗа сугыш мәйданы илә Кәлибулигә җибәргән иде. Анатолий тарафындагы шәһәр вә стансияләрнең һәрберсендә запас гаскәр вә әрзак бик күп булса да, бунлар – лязим булуларына карап, кирәк кадәр урыннарына озату өчен хәзерләнеп куелган нәрсәләрдер.

Соңгы көннәрдә булган инкыйлабтан соң Истанбулның күренешләре хили үзгәрде, һәр җирдә гаскәрнең йөзендә бер җиддият һәм өмид галәмәтләре күренә иде. Төркия гаскәренең хәзерге команданларына инабәтләре бик зурдыр. Анлар бу сугышта үзләренең галиб булуларына ышаналар.

Әҗнәби гәзитәләр Чаталҗадагы гаскәрләрне йөз алтмыш мең генә дип күрсәтсәләр дә, төрекләр гаскәрләренең ул микъдардан күп артык икәнлеген дәгъва кыйлалар. Бу дәгъваның хаклы булуын да уйларга мөмкин. Чөнки бу көнгә кадәр Истанбулдан Чаталҗага һәр көн бер поезд яңа пешерелгән икмәк җибәрелеп торадыр иде. Поездны егерме вагоннан гына һәм һәр вагонда ун мең укадан гына (бер ука – өч кадак) икмәк фарыз кыйлсак та, Чаталҗада ике йөз мең кеше булганлык күренеп торадыр. Шул сәбәптән бундагы гаскәрнең ике йөз мең кешедән артык булуы ачык аңлашыладыр.

Төрекләр соңгы көннәрдә тәмам сугыш тарафдары булып әверелделәр. Үзләренең әзерлекләренә тәмам ышаналар. Һичбер солыхтан бәхәс кыйлган кеше юк.
Сугыш акчасыз була торган нәрсә түгел. Аның өчен күп акча лязим. «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасенең комитетына якын адәмнәрнең ышандырып сөйләүләренә караганда, төрекләрнең хили заманнар сугышырга җитәрлек акчалары бар, имеш. Бер җәһәттән караганда, бу сүзләрнең дә тугъры булуы уйланадыр. Чөнки кулларында акчалары булмаса, солыхны ясарга бу кадәр каршы тормаслар һәм үзләрен дә бу кадәр хәвефле юлларга салмаслар иде.
Соңгы заманнарда төрекләр көн-төн туктамый Чаталҗадагы истихкямнәрене ныгыту илә мәшгуль булганнар. Бу җирләрдә гаскәрләрнең истирахәтләре өчен лязим булган әсбабларны хәзерләгәннәр.
Соңгы заманнарда бу тирәләрдә һавалар бик начар булганлыктан, гаскәрләрнең рәхәте өчен лязим булган тәдбирләрне кыйлганнар. Шул сәбәптән, һавалар никадәр бозык булса да, хасталыклар әүвәлдәгедән артык түгелдер.
Ләкин соңыннан килгән хәбәрләрдә болгарларның Чаталҗадан бик күп эчкә чигенгәнлекләре күренәдер. Төрекләр, әлбәттә, артларыннан анларны тәгъкыйб итәргә мәҗбүр булачаклардыр.
Арттан куып барганда, ул истихкямнәрне ташлап китәргә тиеш буладыр. Бу эш, әлбәттә, төрекләр өчен җиңел булмаячак.
* * *
Соңгы инкыйлабның гаскәргә ни рәвешчә тәэсир иткәнлеген югарыда язган идем. Бу эшләр гаскәрләргә гүзәл тәэсир итсә дә, төрекләрдән башка кавемнәргә агыррак тәэсир итте. Анлар солыхның тизрәк булуын телиләр иде.
Ләкин эш анларның теләгәннәренчә булып чыкмады. Төрекләр Әдернәне бирүгә һичбер төрле разый булмадылар. Төркия өчен нәкыс булган бу солыхны ясаудан үлү артыграктыр, диделәр. Соңгы көннәрдә булган кабинет алмаштыруга да халыкта булган шул рух һәм шул хис сәбәп булды.
Төрекләрдән башка кавемнәрнең тизрәк солыхны теләүләренең сәбәпләре дә бик мәгълүм. Чөнки анларның әксәре сәүдә вә тиҗарәт адәмнәредер. Сугыш булу аркасында тиҗарәт торган. Алыш-биреш начар, хариҗи тиҗарәтләр бик аз. Күп тиҗарәт фирмаларының шартлауларының сәбәпләре дә шуннандыр.
Мувәкъкать мосаләхә булу илә, үз ихтыярлары илә гаскәр уларак читтән килгән кешеләр, гаскәри киемнәрен чыгарып, үзләренең гади киемнәрен киенгәннәр иде. Солых киселгәнлек мәгълүм булгач та, бунлар яңадан гаскәр киемнәрен киеп, үзләренең хезмәт иткән полкларына китә башладылар.
Соңгы ике атна эчендә хастаханәләр бушаганнар иде, сугыш башланачагы мәгълүм булгач та, бик ашыгычлык илә яңадан килүләре ихтимал булган мәҗрухларны кабул итү өчен хәзерлекләр башланды. Соңгы көннәрдә генә бушатылган җәмигъләр, әгәр кирәк булса, яңадан хастаханәләргә әйләндереләчәкләрдер.
Кабинет алмашынганнан соң һәртөрле җәмгыять мөәссисләренең мөрәххәсләреннән гыйбарәт булган гомуми бер мәҗлестә «Мөдафәга миллия җәмгыяте» тәэсис ителеп, һәйәтләр интихаб ителде. Бу һәйәтләр һәркаюсы Төркияне коткару, аның мөстәкыйльлеген саклау өчен юллар эзләү вә аны вөҗүдкә чыгару өчен сума хасыйл итү һәм җыелган сумаларны милләтнең мохтаҗ урыннарына сарыф итү илә мәшгуль булачактыр.
Халыкның яңа вәзирләр вә яңа хөкүмәткә ышанганлыгы сугыш ихтыяҗы өчен иганәләреннән дә күренәдер. Яңа кабинет эш башына кичү илә иганәләрнең микъдары ике өлеш артты.
1913–1915

Яңа елда ни телисез?1
(Галиәсгар Камал җавабы)

Милли театрымызның мәдәни бер шәкелгә керүен, халкымызның театрга җитди күз белән карый башлавын, театр сәнгате гражданлык алып, уйнаучыларның да, театрга язучыларның да күбәюен һәм камилләнүен телим.
Идарәгә мәктүбләр

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде! Гәзитәңездә минем ушбу түбәндәге тасхихыма урын бирүеңезне үтенәм.
Г.Кәрам әфәнде, «Гроза» пьесасы хакында язган арада, мөтәрҗимне бераз эләктереп китә. Островскийның: «Зачем ты пришел? Зачем пришел, погубитель мой!» – дигән сүзен: «Син ник монда килдең? Син ник монда килдең, мәлгунь!» – дип тәрҗемә кыйлганга, мине гаепли. Хәлбуки минем тәрҗемәмдә ул сүз: «Син ник килдең? Нигә дип килдең син, мине харап итүче? Мин бит ир хатыны...» – дип тәрҗемә кыйлынган1.
Гаҗәп түгел, артистка, бәлки, суфлер сүзен ишетми калгандыр да шулай ялгыш сөйләгәндер. Ул кадәресендә мин гаепле түгел. Әмма Г.Кәрам әфәнденең, китапны күрмичә, артистның ялгыш сөйләгәненә генә ышанып, бер әсәрне тәнкыйтькә керешүе урынсыздыр. Шул сәбәптән мин Г.Кәрам әфәндедән, әсәрнең мөндәриҗатын тәнкыйтькә керешкәндә, китапны укып тәнкыйть кыйлуын үтенер идем.
«Саран» пьесасы хакында
(Изах)

Балкан сугышы вакытында «Йолдыз»ның мөхбире сыйфаты илә1 Төркиягә барган идем. Үзем театр китаплары язганлыгымнан, гомумән, театрга күңелемдә беркадәр мәхәббәт барлыктан, төрек театрларының ни төсле булганлыгын чынлап карарга зур арзу бар иде. Ләкин сугыш ул вакытта Истанбулның «ындыры» артында – Чаталҗада гына булганлыктан, халыкта рух бик төшенке, театрлар бер дә булмый иде. Театр тамашаларын күрү мөяссәр булмадыгымнан, мин, аларның театрларында уйнала торган әсәрләрен булса да карап чыгу уе белән, китап базарында булган төрекчә театр әсәрләренең һәммәсен дә җыйдым. Казанга кайтканнан соң, авырып яткан вакытымда, ул китапларны берәм-берәм укып чыктым. Ләкин арада дүрт-биш әсәрдән башкасы һәммәсе дә үзләренең инкыйлаб дәверләренә гаид гел сәясәттән бәхәс кыйлган, ашыгычлык белә генә хәзерләнгән яхуд заказ буенча гына язылган әсәрләр иде. Калган дүрт-биш әсәрдән «Дөхтәре һинд», «Әшбәр», «Тәзәр»2 исемендәге әсәрләре илә «Пенти Хәмид» дигән бер әсәр генә күзгә төшәрлек иде. Авырудан бераз терелгәч, югарыда мәзкүр әсәрләрдән «Пенти Хәмид» исемендәге бер комедияне тәрҗемә кыйлдым. Ләкин төрекләрнең үз араларында рус әдәбиятындагы Плюшкин3 кадәр мәшһүр бер исем булса да, «Пенти Хәмид»не «Пенти Хәмид» исеме илә тәрҗемә итмичә, аның баш каһарманының сыйфаты булган саранлыгыны игътибар итеп, аңар «Саран» исеме биргән идем. Мин тәрҗемә кыйлган бу китапның башында «Пенти Хәмид. Биш фасылдан гыйбарәт мозхикә, мөхәррире Теодор Касаб» дип язылган.
Төрекләрнең сәнәи миллияләре хисабы илә 1290 елда басылган. Икенче сәхифәсендә, комедиянең каһарманнарын санап чыкканнан соң: «Вакыйга Истанбулда, Пенти Хәмиднең ханәсендә улыр», – дип язылган иде. Ул вакытларда гына димим, хәзергә кадәр дә минем, мәгаттәәссеф, француз драматургларыннан Мольер әсәрләрен укыганым юк иде.
Әгәр дә К.Б. әфәнде «Вакыт» гәзитәсендә Оренбургта «Саран» пьесасы куелу мөнәсәбәте илә язган мәкаләсендә мине тәнбиһ кыйлган булмаса иде, бәлки, буннан соң да миңа

Мольерны уку насыйп булыр йә юк иде. Хәзер инде мине уйгатканы өчен К.Б. әфәндегә рәхмәт укыйм. Ахырдан шуны да әйтеп китәм, «Саран»ны урлаучы мин түгел, урлаучы – Истанбулдагы Теодор Касаб дигән бер кешедер. Һәрнәкадәр урлаган малны алучы кеше һәм гаепле булса да, мин аны белмичә алдым. Җитмәсә, тагы ул әсәрне бастырган вакытта тасхих итүче кеше «Т.Касаб» дигән сүзне «Касбар» дип төзәткән булып, асыл каракның исемен яшереп, аңар зур ярдәм иткән. Ничек булса да бу минем өчен зур сабак булды. Буннан соң сакланыбрак эш күрергә яхшырак булыр. Әле шунысына тагын бер мәртәбә шөкрана кыйлам, ничек әле мин, Касаб агага ияреп, исемен анынча калдырмаганмын, Мольерны үзенчә – «Саран» дип атаганмын, анысы зур бер тәсадефтер.
Мин «Саран»ны төрекчәсеннән тәрҗемә кыйлган булдыгымнан, бәгъзе бер урыннарында асыл нөсхәсеннән үзгәртелгән, кыскартылган яки арттырылган урыннары булса, ул ноксаннар миннән килгән ноксаннар түгелдер. Укучылар гафу итсеннәр, икенче табгысы вакытында ул ноксаннарын тәкмил итәргә, шаять, иҗтиһад итәрмен.
1919–1933

## Татар театры

Үткән җомга көн1 Кызылармиялеләр сараенда2 «Икенче кат яшьлек»3 исемендә русчадан тәрҗемә дүрт пәрдәлек драма уйналды. Башта уен кич сәгать җидедә башланачак дип игълан ителсә дә, ни өчендер соңыннан – көндез уйналды. Шул сәбәпле, әүвәлге игъланга карап, кич белән килгән бик күп кешеләр кире кайтып китәргә мәҗбүр булдылар.
Бу зур әсәр, әдәби кыйммәткә малик әсәрләрдән булмаса да, моннан берничә еллар әүвәл ул рус сәхнәләрендә күп мәртәбәләр муаффәкыять белән уйналган әсәрдер. Мондый психологический әсәрне уйнау өчен уйнаучылар үз рольләренә артыграк дикъкать итәргә тиеш. Ләкин үткән уенда, тәәссефкә каршы, бик күп дикъкатьсезлек күрергә тугъры килде. Уенның башлануы ук Галиеваның ролен белмәү һәм роленә төшенмәве аркасында гайре табигый башланып китте. Һәм башкаларга да шул гайре табигыйлек тәэсирсез калмады. Телегина ролендәге Әхмәрева4 сцена кыйлганда, уенчыларның күбесе шактый игътибарсызлык күрсәттеләр. Мин Готовцев ролендә Мутинның шулкадәр салкын уйнавының сәбәбен һичбер төрле аңлый алмыйм. Үзенең сөекле балаларын һәм хатынын ташлап китәрлек дәрәҗәдә икенче бер хатынны сөя торган бер кешедә, ул кеше гәрчә никадәр үзен вәкарь белән тотарга өйрәнгән кеше булса да, мәхәббәт мәнзарәләрендә темперамент күренергә тиеш. Хәлбуки Мутин баштан ахырга кадәр бертөрле салкынлык белән барды. Ул гүя мәктәп сыйныфында балаларга салкын кан белән әлифба укытучы бер мөгаллимә төсле иде.
Готовцевның хатыны ролендә Болгарскаяның гримы Виталий шикелле егетнең анасы булырлык түгел, апасы булырлык дәрәҗәдә яшь иде.
Гомумән, минем тәҗрибәләремә караганда, безнең артисткалар сәхнәдә картаюдан курыккангарак охшыйлар, ләкин, минемчә, бу эш алай «куркырлык» эш түгел: сәхнәдә үлгәнгә карап җан чыкмаган шикелле, гримны тиешенчә ясаганда да зарар килмәскә кирәк. Аннан соң шуны әйтеп үтәргә тиеш ки, Болгарская ханым озын монологларны байтак буташтырды: гадәттә озын монологларны тәҗрибәле режиссерлар галәмәсен генә калдыралар да артыгын сызалар. Мин бу монологларны тыңлаганда, үзең язган нәрсәне карауга караганда, кеше язган нәрсәне карап утыру рәхәтрәк икән дигән фикергә килә яздым. Сәхнә телгә дә хезмәт итә торган бер урын булганлыктан, артист вә артисткалар телне бик яхшы белергә, аның хосусиятен аңларга тиешләр. Ләкин, тәәссефкә каршы, хәзерге татар театрында уйнаучыларның күбесендә телгә сансызлык күренә. Бу эш гафу

ителергә тиеш түгел. Хосусән хәзерге совет хөкүмәтендә бик күп мәктәпләр ачылды. Мәктәпләрдә укыган өчен акча алмау гына түгел, хәтта көндезге аш һәм аяк киеме дә бирәләр. Шуның өчен мин күп артист вә артисткаларга, карт бер язучы булуым сыйфаты илә, самими рәвештә шул киңәшне бирер идем ки, атнасына фәкать бер мәртәбә генә сәхнәгә чыга торган артистлар өчен бу эш уңайсыз булмаска кирәк. Театр эшенә «ничек сөйләсәң дә, нәрсә сөйләсәң дә ярый, бары тик туктапып кына калма» дигән карашны күптән ташларга вакыт җиткән булса кирәк.
Бу көнге уенда, югарыда әйтеп узганча, иң муаффәкыятьле уйнаучы Әхмәрева туташ булды. Ул уенның рухына яхшы төшенгән һәм һәрбер хәрәкәтен, һәрбер сүзен уйлаган, шуның өчен аның Телегинасы төпле бер Телегина булып чыгуы илә караучыларга яхшы тәэсир калдыра.
Ситкина ролендә Арапова, гәрчә роле артык зур булмаса да, яхшук муаффәкыять илә уйнады.
Виталий ролендә Тинчурин ахырда бераз иҗтиһадын арттыра төшкән булса, уен бераз тулырак чыккан булыр иде. Бу уенда үз ролен яхшы аңлаган һәм ролен тиешенчә адаклаган бердәнбер кеше Колмәмәт иде дияргә ярый, ул чыннан да бүген чын добродушный бер «дядя» иде. Гомумән, Колмәмәтнең бу елгы уеннарында зур тәрәккъкый күренә.
Дингә хезмәт итүчеләр арасында

Кайсы гына диндә булса да, дин хезмәтчеләренең табигатьләре һәркайсыныкы да бертөсле. Кайсы гына диндә булсалар да, алар халыкны кыямәт, ахирәт, сират күперләре һәм тәмугъ белән куркыталар, сәдаканы күбрәк бирүчеләрне оҗмах белән сөендерәләр. Русиядә совет хөкүмәте, эшче һәм крәстиян хакимияте төзелгәннән соң, һәркайсы диннәр хезмәтчеләренең халык каршындагы игътибар һәм дәрәҗәләре төште. Аларга явып тора торган сәдака, зәкят һәм фидияләр1 кимеде. Шул сәбәптән алар хәзерге көндә үзләренә яңа килерләр табу өчен яңа юллар эзли башладылар. Ләкин эшләре, эзләнүләре һаман да муаффәкыятьле була алмый. Шул сәбәптән гавам халкына ачуларын көннән-көн арттыра баралар, көннән-көн бу турыдагы җәнҗаллар күбәя бара. Мисал өчен бу урында берничә вакыйгане күрсәтеп китәргә мөмкин.
Адескә2 Польшадан үз эшләре белән килгән Шнәйерсон дигән бер яһүди раввины бер атна эчендә ике эш белән халык мәхкәмәсенә эләккән. Ул үзенең «яхшы киңәшләре өчен» акча түләргә теләмәгән бер йөкле хатынны кыйнаган өчен, гавам күз алдында «дин – халыкның башын чуалта торган нәрсә» дигән өчен, бер эшченең унике яшьлек угълының яңагына суккан өчен хөкемгә бирелгән.
Минскидә бер көндә үзенә тиешле тәгъзыйм белән җавап бирмәгән өчен, хезмәтче хатынның битенә кайнар су сипкән.
Әстерханда бер Иран мулласы ниндидер дини бер хезмәте өчен сәдака бирмәгән бер мөселманның артыннан, пычак күтәреп, урам буенча куып йөргән.
Егоровский өяздә Шараповский мәктәбендә уйнаган вакытта бер крәстиян баласы дьяконның угълын төртеп җыккан өчен, дьякон баланы, урамда очратып тотып алып, һавага күтәреп җиргә бәргән. Бала, мие кузгалу сәбәпле аңын югалтып, берничә көннәргә кадәр акырып яткан.
«Һинд кызы»

Якшәнбә көн 26 октябрьдә Дәүләт татар театрында1 «Һинд кызы»2 уйналды. Казан сәхнәләрендә берничә мәртәбәләр куелган әлеге пьеса бу куелышында, режиссерның оста кулы белән шактый гына күп яңалыклар кертелүенә дә карамастан, йомшаграк чыкты. Әсәрнең йомшак чыгуына иң беренче сәбәп итеп бу ел дәүләт театрында яхшы «беренче гашыйк» («первый любовник») ролен уйнаучының юклыгын күрсәтергә мөмкин. Томсон ролен уйнаучы Шамильский, герой-любовник ролендә уйнаганда, яхшы, көчле артистлардан булса да, ул бүгенге хәйләкәр, җылан Томсон роле өчен тупасрак иде.

Уенның бозылмый баруына Әбсәләмов (Турумтур), Уральский (сэр Бортель) яхшы ук ярдәм иттеләр.
Шулай ук Муко тарафыннан куелган балетны да уңышлы дип әйтеп булмый. Ул «татарларга ярар әле» дигән уй беләнмедер яки бар көче шулмыдыр – бик көчсез балериналарны гына китергән иде.

«Ислам» журналы
Уфада Диния нәзарәте1 тарафыннан «Ислам»2 исемендә айлык бер журнал чыгарыла башлаган. Динчеләр тарафыннан ислам динен куәтләү өчен чыгарыла торган бу журнал бөтен күләме, язылуы, үзенең эчендә язылган бөтен мәкаләләренең мәгънәсезлеге белән диннең банкротлыгын күрсәтеп тора.
Диния нәзарәте булгач, аның башында торучы кешеләр диннән яхшы хәбәрдар, ислам диненең агып чыккан чишмәсе булган гарәп телендә мөтәхәссис кешеләр булырга тиеш иделәр. Әмма аларның чыгарган бу журналлары эчендә язылган мәкаләләренең мәгънәсезлеге, төпсезлеге өстенә гарәпчәдә неграмотный икәнлекләрен бик ачык күрсәтеп тора. Журналны ачып карау белән, иң башта ук аның «Диния нәзарәтеннән барча мөхтәсибләргә» дигән мөрәҗәгатендә үк журналны чыгаручыларның гарәп теленнән хәбәрдар кешеләр түгел икәнлекләре күренеп тора. Анда «нәзарәт» дигән сүздәге «за» хәрефе иске имля буенча нокталы «та» рәвешендә язылырга тиеш була торып та, «зат» белән язылган. Элекке заманнарда бер ысуле кадимче мулла бар иде, ул һәрвакытта өстенә тун, аның өстеннән чапан киеп йөри торган иде. Аннан аның ни өчен болай киенүенең сәбәбен сорагач: «Без шулай инде, мөхаләфәтән лилмөхалифин, тун өстеннән чапан киябез», – ди торган иде (безгә каршы кешеләргә каршылык өчен дигән сүз була инде ул). Шул ук журналның икенче бер урнында ислам диненең фәнгә бик муафикъ икәнлеген егерме биш елдан бирле исбат итеп йөри торган Зыя Кәмали3 үзенең исемен «зат» хәрефе белән язарга тиеш булса да (чөнки журнал баштанаяк иске имля белән язылган), «з» хәрефе белән яза. Шунда ук тагы вәгазьләр бүлегендә вәгазь өчен үрнәк итеп күрсәткән беренче номерлы вәгазьнең башында «Адәм – җирнең хәлифәсе» дигән мәгънәне аңлата торган «Адәм хәлифәтөл арзъ» дигән сүздә «арзъ» сүзен «зат» хәрефе белән язарга тиешле урында «за» хәрефе белән яза.
Менә боларның барысы да Диния нәзарәтенең башында утыручыларның дин һәм фән ягыннан гына түгел, нәхү (грамматика) ягыннан да неграмотный халыклар булганын бик ачык күрсәтәләр.
Хәзергә шулкадәр генә, өстән-өстән генә; журналның эчке ягыннан карагандагы мәгънәсезлеге турында, бәлки, яңадан да булыр әле.
Кучәр башы
(Кечкенә фельетон)

Бер крәстиян җегете, йорт тормышы өчен кирәк нәрсәләрне алыр өчен, ашлыгын төяп шәһәргә килгән. Ләкин, аның бәхетсезлегенә каршы, шәһәргә килгәндә, аның арба күчәре сынган. Авылдан шәһәргә килергә һәм аннан ашлык саткан акчасына бик күп кирәк-яраклар алуны өмид итеп килгән бу җегет зур бәхетсезлеккә очраган: аның искергән арба күчәре шәһәрнең каты ташлы, чокырлы урамнарының катылыкларына чыдый алмыйча шартлап сынган. Шуның белән бергә аның бар якты өмидләре дә сүнгән. Арбаны Казанда ташлап калдыру мөмкин түгел. Җегет ашлык саткан бар акчасына яңа арба күчәре алган да Печән базары1 аркылы яңа күчәрне күтәреп кайтып бара.
Бәхетсезлек бер килсә килә бит. Җегет ничә йөз мең сумнар белән сәүдә итә торган «Васита» ширкәтенең2 ике ишекле магазины каршыннан узып барганда гына, трамвайдан курыккан бер авыл аты җегетнең җилкәсендәге күчәрнең бер башын эләктерә, икенче башы, «Васита» ширкәтенең магазин алдына куелган фонарена эләгеп, аны бәреп төшерә.
Менә шунда инде яңа картиналар башлана.
Магазиндагы бөтен «Васита» кабиләсе, тузгып, урамга чыгалар:

– Фанарны ник ваттың? Түлә!
– Давай биш сум!
– Минем бер тиенем дә юк шул, актык акчама күчәр алдым. Бәхетсезлеккә очрадым, күчәрем сынган иде.
– Без ничава ни ызнаем, калдыр монда күчәреңне дә биш сумыңны китереп алып кит!
Җегет милиционерга да эшне аңлатып, ялынып карый, ләкин ул нишләсен?
Крәстиян җегетенең күзеннән яшьләр килә: «Йә күчәр, йә үлем! Күчәрсез, акчасыз, һичбер нәрсәсез авылга ничек кайтырга?»
– Анда ни булган? Нинди җәнҗал?
Бөтен Печән базары эспикүләнтләре шау килә, халык җыела. Билгеле инде, кайсы җегетне кызгана, кайберләре – байларның фонарен.
Шулай да крәстиян җегетенең җиргә тамган кайгылы күз яшьләре игътибарсыз калмый. Бер мәрхәмәтлесе, уйлап тормыйча, кесәсеннән яулыгын чыгара да:
– Әйдәгез, җегетләр, бичара җегеткә ярдәм итегез! – ди.
Озак та үтми, яулык бер тиен, ике тиен, биш тиен, хәтта ун тиенлекләр белән тула.
Акчаны җыйган бабай, килеп:
– Ал акчаңны, бирегез күчәрне! – ди.
«Васита» ширкәтенең кәкре аяклы эспикүләнтләре, һич оялмыйча, авызларын җырып көлә-көлә акчаларны санап, фонарь бәясенең ике өлешен алып, файда итеп, крәстиян җегетенә үз күчәрен яңадан акчага сатып җибәрәләр.

## Ислам, хәлифәлек мәсьәләсе һәм империалистлар

Европа империалист һәм капиталистларының күңелләренә эшче-крәстиян Совет җөмһүриятләренең булуы бер дә ошамый. Европа империалистлары үз кул асларындагы эшче-крәстияннәрнең каннарын суыру белән генә канәгатьләнә алмыйлар; алар өчен яңадан-яңа коллар кирәк, яңадан-яңа зур байлыклар кирәк.
Европа капиталистлары һәм империалистлары өчен бүгенгә кадәр тешкә йомшак урыннар Көнчыгыш илләре булып килде. Алар, бер-бер артлы Фас, Җәзаир, Траблис, Мисыр, Гарәбстан1, Иран һәм башкаларны үз кул асларына кертеп, аларны төрлечә имә башладылар.
Аларның бу комсызлыклары өчен югарыдагы мәмләкәтләрнең патшалар, шаһлар, солтаннар, хәлифәләр кул астында булуы кирәк. Шунлыктан алар Көнчыгыш якларын йә бөтенләй үз кулларында, яки үз теләкләренә буйсына торган хәлифәләр кулында тотарга телиләр. Бу теләкләрен җиренә җиткерү өчен төрле сәясәтләр йөртәләр. Мәсәлән, гарәпләрдән баш күтәртеп, аларны җөмһүриятле Төркиядән аертып, үзләреннән хәлифә куйдырырга котырталар; икенче яктан, көрдләрне котыртып, аларны Төркиядән аертып, үз кулларына кертергә телиләр. Бу эшләрнең һәммәсендә дә Англия бармагы килеп кысыла.
Англия хәзерге көндә, бөтен дөнья мәмләкәтләре өчен дигән булып, Мисырда бөтен дөнья мөселманнары съездын җыярга тырыша. Моның өчен чит илләрдә качып йөри торган сатлык социалист сатлык милләтчеләрнең көчләреннән дә файдаланыла. Алардан үзенә генә яраклы гәзитәләр чыгарта. Аларның чыгарта торган бер гәзитәләре турысында Бакуда чыга торган «Коммунист» гәзитәсе «Хәлифәлек тирәсендә яңа вырылдавыклар» дигән исемле мәкаләдә шушы түбәндәге сүзләрне яза: «Ислам феодализмының кайбер түбән, ялланып йөри торган представительләре бар; алар Англия империализмының кулында Көнчыгыш халыкларының азатлыкка чыгу кузгалышларына каршы берәр корал хезмәтендә әле һаман дәвам итәләр. Дин, шәригать һәм хәлифәлек битлекләре астында, җәберләнгән Көнчыгыш халыкларын инглиз империализмының аяк астына салырга теләгән бу группалардан берсенең планын ачып бирә торган бер җыентык кулыбызга төште. «Мисырда гомуми ислам хәлифәлеге съезды мәҗмугасы» исемендә гарәпчә чыгарылган бу җыентыкның теләге гүя «мөселманнарның бу көнге авыр хәлләренә чара

таба алачак» бу хәлифәлек съезды җыю өчен хәзерләнү һәм мөселманнарның шул турыда фикер алышуларына васита булу, имеш. Бу журналның алга куйган фикерләренә якын килүдән элек, аның кемнәр тарафыннан чыгарылганын әйтеп китик. Аның җаваплы мөхәррире – инглиз тәрилкәсен ялаучылардан тамгалы язучы Мөхәммәд Фәрраҗ Әлмөнәяди дигән бер бәндәдер. Мәкалә язучылары арасында иң күзгә бәрелә торган мәшһүр «Әл-мәнар» журналының мөхәррире Мөхәммәд Рәшид Ризадыр. Европа сугышының[2] беренче елларында гарәп-төрек багланышларындагы канлы хыянәтләрне эшләүчеләрнең кем икәнен һәм гарәпләрнең Антанта койрыгында сөйрәлүләренең тарихын белгән кешеләр өчен бу Мөхәммәд Рәшид Риза бик билгеле.
Гыйльмен, каләмен Көнчыгыш халыкларын куркуга төшерүгә хезмәт иттерү белән дан алган бу җүнсез адәм дә бөтен акылын, бөтен үткенлеген, бөтен хәйләләрен гарәпләр арасына Антанта империализмының урнашуы өчен кулланган бер вөҗдансыз. Журналга мәкалә һәм хатлары белән катышучыларның башкалары икенче дәрәҗәдәге кебекләр, мәсәлән. Нәҗеттә[3] инглизләрнең Әбу Сөгуд һәм ваһһабиләргә[4] каршы бер сукыр кораллары булган бер кечкенә кабилә шәйхенең улы Фәйсал бине Габделгазиз, бабасы да «Зираһе гыйзин» партиясе башлыгы фарсы Әс-Сөгуди, тагы берничә шундый билгесез кешеләр.
Журналның хәбәр бирүенә караганда, бөтен ислам дөньясының катнашуы белән (!) хәлифәлек мәсьәләсен чишү өчен мартта бер конгресс ясалачак, имеш. «Хәзерге заманда иң кирәкле, зур мәсьәләләр конгресс ысулы белән генә чишелгәнлектән, бу гомуми «мөэттәрәмә ислами» («мөселманнар съезды» дигән сүз) бик шәп һәм бик зур булачак, имеш. «Хәлифәлек мәсьәләсе турысында бик зур кайгы һәм тынычсызлыкта тора торган государстволарның бу конгресска каршы килмәүләре өмид ителә», имеш.
Мөхәммәд Рәшид Ризаның уйлавына караганда, хәзерге көндә ислам дөньясында хәлифәлек һәм солтанлык мәсьәләсе турысында өч төрле караш бар, имеш. Ул карашларның да берсе иске фикерле халыкларның фикере булып, заманның теләге белән исламият һәм хәлифәлекне берләштерүне белмәүчеләрнең карашы, имеш. Аның әйтүенчә, бу караш – электәге хәлифә һәм солтаннар ягында булган кешеләрнең карашы була. Икенчесе хәлифәлек һәм солтанлыкны юкка чыгаручы, аны кире кагучылар карашы булып, анысы «кәнеҗ төрекләр»[5], «иттихадчылар»[6] һәм «кәмалчы динсезләр»нең[7] карашы икән. Ә инде өченче караш – хәлифәлекне ислам конгрессы аркылы сайлау, имеш. Ләкин «динсез»ләр артыннан бара торган төрекләрнең бу карашны кире кагуларында Рәшид Ризаның бер дә шөбһәсе юк. «Дин мәсьәләләрендә аптырашта калган» хитталыларның[8] төрекләр артыннан китеп ялгышу ихтималларыннан Рәшид Риза хәзердән үк бик курка.
Әфганстан һәм Иран голямаларына килсәк, аларның да үз хөкүмәтләренең мәмләкәт эшләрен йөртүдә, икътисад һәм промышленность коруларында ирексез европалашуларына карап, бу мәсьәләдә дә ялгышмаулары, һәрхәлдә, күзләрен яхшы ачулары Мөхәммәд Рәшид Ризаның конгрессына «дини фарызлардан», имеш. Тагы шундый берникадәр эшләр...
Конгрессның кайда, кай урында ясалуы мәсьәләсенә килсәк, Мөхәммәд Рәшид Ризаның фикеренә күрә, Истанбул хәлифәлеге[9] бетерелгән булганга, конгрессны анда ясау мәгъкуль түгел; Мәккә[10] һәм Хиҗазда[11] ясау мәсьәләсенә килгәндә, аның уйлавынча, ул җирләр ике партия һәм ике хөкүмәт тартышы арасында аптырашта торганлыктан, конгрессны анда җыю да мәгъкуль түгел. (Чынлап караганда, ул урыннар инглизләрнең боендырыгы астына керүгә каршы булган гарәпләрнең тартыша торган сугыш мәйданнары булганлыктан мәгъкуль түгел.) Аның фикеренчә, конгрессны җыю өчен муафикъ булган урын – «Мисыр, ирекле һәм мөстәкыйль булган Мисыр», имеш.
Журналның биргән мәгълүматларына караганда, конгрессны хәзерләү комиссиясенә берникадәр ислам мәмләкәтләреннән бу эшне бик яхшы күреп җаваплар да килгән, һәм алар гәзитәләрендә бу эшне бик кирәкле һәм дөрес табып язганнар, имеш.

«Язганнар» дип күрсәткән гәзитәләренең дә нинди гәзитәләр булганын әйтеп китик. Санап күрсәткән гәзитәләр менә шушылар:
1) «Фәләстин» гәзитәсе инглиз күләгәсе астында, инглизләр акчасына, гарәпчә телдә чыгарыла;
2) «Әл кәрмәк» гәзитәсе, монысы Англиянең колония гәзитәсе.
Журналның язуына караганда, чит илләрдә чыга торган гәзитәләр «Каб» мөселманнары да12, голямалардан Әбу бәк Мөҗәледдиннең председательлеге астында җыелып, хәлифә сайлау конгрессына катнашырга карар бирделәр» дип язган, имеш. «Каб»ның кем колониясе икәнен белгән[нәр] бу сүзнең дә мәгънәсе нәрсә булганын бик яхшы аңларлар (Африкада Англия колониясе). Югарыда язылганнарның һәммәсе дә Англиянең берникадәр «голяма» маскасы [кигән] сатлык вөҗданнар аркылы Көнчыгыш халыклары арасында яңадан бер биеткеч биетергә теләгәнлеген күрсәтәләр. Ләкин алар бу эшләрендә дә теләкләренә ирешә алмыйлар. Асылда, бу кычкыручыларның сүз аңлатырга тырышуларында һәм пропагандаларында батырсызлыклары да, бигрәк тә Төркия, Һиндстан, Әфганстан һәм Иран мөселманнары турысында күрсәткән өмидсезлекләре дә шуны исбат итәләр.
Соңгы вакытларда килгән хәбәрләрдә ваһһабиләрнең шәех Сәнусине хәлифә итеп кую ихтималы барлыгы сөйләнә. Бу хәбәр, гәрчә барып чыгарлык бер эш булмаса да, түбәндә Көнчыгыш халыкларының күңелләрендә Антанта, бигрәк тә Англия империализмына каршы тору нияте барлыкны күрсәтәләр. Моңар караганда, шәех Рәшид Ризаларның лыкылдаулары никадәр кабахәтлек, җирәнгеч, түбән, никадәр үзләре файда итеп калу тойгыларыннан килгән булса, ваһһабиләрнең сагынып караулары да моның, киресенчә, һич булмаса, гарәплек намусын саклау, гарәплекнең барлыгын күрсәтергә теләү барлыгыннан килә. Соңгы көннәрдә килгән бу хәбәрләр, инглизләрнең хәлифәлек мәсьәләсе аркылы Көнчыгыш халкы арасында уйнарга теләгән бу уеннарының һичбер нәтиҗә күрсәтә алмавын белдерәләр, ди.
Хәлифәлек мәсьәләсе кузгалгач, инде бу турыда Советлар Союзындагы мөселманнарның да хәлифәлек мәсьәләсенә карашлары ничек булганын белдереп китик.
Бу турыда озын сүз сөйләп торуның кирәге юк. Ул хакта Оренбург округы мөселман руханиларының III съездында хәлифәлек мәсьәләсе турында чыгарылган карарын бу урында күчереп китсәк, Русиянең динле мөселманнарының ул мәсьәләгә карашларының ничек икәнен күрсәтергә җитсә кирәк. Ул карар менә шушы: «Төркия җөмһүриятенең карары белән хәлифәлекнең государстводан аерылуы, Габделмәҗиднең, хәлифәлектән төшерелеп, Төркиядән куылуы һәм шуннан соң Хиҗаз, Йәмән, Гыйрак һәм башка җирләрдә кайбер шәехләр һәм кабилә башлыкларының, мәйданга чыгып, үзләреннән хәлифә игълан итүләре, шуның аркасында ислам дөньясында талашлар, кан түгүләр туу мөселманнарның зиһеннәрен ишгаль итәрлек вакыйгалардәндер. Шуңа күрә без, бу съездыбызда бу мәсьәләләргә күз салып, үзебезнең аңар карашыбызны билгеләп китәргә тиешбез.
Хәлифәлек, асылда, ислам законнары буенча, ислам дөньясының дин мәсьәләләрен генә карап, аны чишә торган гына бер учреждение булса да, дөньяның төрле якларындагы сәяси, иҗтимагый, икътисади хәлләр һәм багланышлар үзгәрү белән, бу учреждение үзенең төп бурычыннан ераклашып, ислам дөньясында тоткан урынын һәм йогынтысын югалтты. Дини хәлифәлек, дөньяви хөкүмәт белән бергә бәйләнеп, үзенең рамкасыннан чыгып, төрле начарлыклар эшләде.
Хәлифәлеккә иң эшлексез кешеләр утырып, алар, үзләренең тоткан зур урыннарыннан файдаланып, төрле истибдад һәм әшәкелек юлларына керделәр.
Бигрәк тә соңгы гасырлардагы хәлифәләр, ислам файдасына хезмәт итүне бер якка ташлап, кул асларындагы мөселманнарны наданлык, караңгылыкта тотып, мөселманнарның империалистлардан талану һәм җәберләнүләренә риза һәм корал булдылар. Мәсәлән, соңгы заман хәлифәләреннән Габделгазиз, Европадан күп

миллионнар бурыч алып, аны үз кирәкләренә, төрлечә фарсит итүләргә генә тотты. Төркия халкын муеннан бурычка батырып, аларны Европа банкларына кол итте.
Габделхәмид, Төркиянең беренче милләт мәҗлесен куып, үзенең куркынычлы, канлы идарәсен урнаштырды. Үзенең утыз биш еллык канлы патшалыгы вакытында Төркиянең өчтән ике өлешен Европа империалистлары кулына бирде. Мөхәммәд Рәшад V, Европа сугышына катнашып, миллионнарча мөселманнарның һәлак булуына, каннары түгелүгә сәбәп булды. Ахырында Төркия, тагын да бүленгәләп, дошманнар аяк астында тапталды һәм Европа империалистлары кулына төште. Рәшадның бу сугышка катнашуы Германия империалистлары кулында корал булып торуыннан килде. Аннан соңгы хәлифә Вахидеддин13 Төркиянең бөтен ватанын, милләтен, мөселманнарын – барын да Европа империалистлары кулында калдырып, үзенең җанын, үз файдасын саклау өчен, шәйхелислам14 белән бергәләп, Төркиянең һәм бөтен ислам дөньясының иң зур дошманы булган Англия канаты астына кереп, Европага качты. Ахырдан иң соңгы хәлифә Габделмәҗиднең хәлифәлеге бетерелгәннән соң да Европа империалистларына корал булды, төрекләрнең иксез-чиксез зур корбаннар белән алынган хокук һәм азатлыкларының тамырына балта чабарга омтылганлыгы беленде. Шунлыктан Төркиянең милләт мәҗлесе аны, хәлифәлектән төшереп, Төркиядән читкә куарга тиеш тапты.
Инде хәзер Гыйрак, Йәмән, Мисыр шикелле җирләрдә мәйданга чыгып, үзләрен хәлифә дип игълан итүчеләргә килик. Беренчедән, ислам шәригате буенча аерым кешеләрнең үз-үзләрен хәлифә дип игълан итәргә хаклары юк. Шулай ук нинди дә булса бер гавам һәм кабиләнең бөтен дөнья мөселманнары өчен хәлифә куярга да хаклары юк. Икенчедән, мондый хәлифәлекне дәгъва кыйлып мәйданга чыккан бу кешеләр, үз файдалары өчен генә Европа империалистларына кол булып, мөселманнарны алардан издерергә, мәмләкәтләрен таланырга, мәмләкәтләренең калдыкларын да алар кулына төшерергә сәбәп булучы кешеләрдер. Ислам һәм мөселманнар өчен боларның зарардан башка һичбер нәрсәләре булачак түгел, һәм без аларны танырга тиеш түгел. Югарыда әйтелгәннәрне нигез итеп, съезд түбәндәге карарны чыгара:
1) Без, бу съездга килгән вәкилләр, Төркия милләт мәҗлесенең хәлифәлек турындагы карарына кушылып, һәртөрле фитнә һәм бозыклыклардан котылу өчен, Габделмәҗидне кууны хаклы табабыз.
2) Хиҗаз, Гыйрак, Йәмән һәм башка җирләрдә үзләрен хәлифә дип игълан итүчеләрне һичбер төрле юл белән [хәлифә] дип танымыйбыз.
Аерым кешеләрнең исламның нигезенә каршы хәрәкәтләре һәм Европа империалистларына корал булулары өчен протест бирәбез.
3) Без, Совет җөмһүриятендә яшәүче мөселманнар, мәзлум Көнчыгыш милләтләренең яклаучысы булган Советлар хөкүмәтенең дин эшләрен хөкүмәт эшләреннән аеруын кирәк дип табабыз.
Моннан соң дин эшләре һәрбер дин кешеләренең үз ирекләренә тапшырылуы аркасында, дин эшләребезне үзебез карарга мөмкин. Шуның өчен без империалистларга агент булган хәлифәлек һәм хәлифәләрнең кирәге юк дип карыйбыз».

Менә бу [Совет] җөмһүриятендә яшәүче мөселманнарның хәлифәлеккә карашы.
Инде килик хәлифәлек мәсьәләсенә ислам диненең карашына. Аңар күчсәк, ул турыда без менә шуны күрәбез.
Исламның беренче башлаучысы булган Мөхәммәд15 пигамбәрдән сәхабәләр16 үз урынына хәлифә калдыруны сорагач: «Бу минем эшем түгел. Вәмрәкем шура бәбәкем, – дигән. – Сезнең эшләрегез үз арагыздагы киңәш белән», – дигән. «Шура», безнеңчә әйткәндә, «совет» дигән сүз. Пигамбәр үлгәч, гарәпләр (мөселманнар) иң әүвәл Әбүбәкер17, аннан Гомәр18, аннан Госман19, аннан Галине20 хәлифә (пигамбәрнең урынбасары) итеп куйганнар. Галинең хәлифәлеге вакытында мөселманнар арасында икегә аерылулар башланган. Мөгавиянең21 хәлифәлек дәгъва кыйлуы белән башланган бу тартышулар аның улы Язид22 вакытында тагы да артык зураеп, зур сугышлар,

кырылышларга сәбәп булган. Шул вакыттан башлап мөселманнар, пигамбәр күрсәткән юлдан аерылып, хәлифәлек тәхетен үзләренең балаларына мирас итеп калдырып, самодержавие юлына кереп киткәннәр. Арада сугышлар чыгып, хәлифәлек өмәвиләрдән габбасиларга23, аннан сәлҗукиларга24, аннан госманнарга25 күчеп, ахыргы вакытларга кадәр госманлылар кулында килгән. Гарәпләр, хәлифәлек безгә тиеш [дип], берничә мәртәбәләр баш күтәреп килсәләр дә, көчәйгән төрекләргә каршы тора алмаганнар. Бу хәлләр соңгы заманнарга кадәр шулай дәвам итеп килде. Башта җөмһүрият белән башланган ислам дөньясы соңыннан деспотлыкка әйләнде. «Хәлифә» сайлау мәсьәләсен тудырып, Англия боендырыгы астында булган Мисырда, «Бөтендөнья мөселманнары съезды» исемен биреп, ялган съезд ясатырга уйлый башладылар. Хәзер бөтен империалистлар, кайсы ачыктан-ачык, кайсы итәк астыннанрак, шул эш артыннан йөриләр. Моның өчен миллионнарча акчалар түгәләр. Теләкләре – Көнчыгыштагы халыкларны яңадан үз боендырыкларына бәйләү. Ләкин никадәр генә тырышмасыннар, империалистлар бу теләкләренә ирешә алмаячаклар, бөтен Көнчыгыш халкы исеменнән эшләргә теләгән эшләре ахырда бер көн җимереләчәк. Озакмы, тиздәнме, бөтен дөньяда коммунизм байрагы җилпердәп, андагы халыклар якты дөнья тормышына чыгачаклар. Империалистларның хәйләләрен бөтен Көнчыгыш ярлылары аңлаячаклар.

Әзәрбәйҗан драматургы
мирза Фәтхегали Ахундов

Иртәгә Әзәрбәйҗанның һәм бөтен төрек-татар дөньясының беренче драматургы Мирза Фәтхегали Ахундовның дөньядан күчеп китүенә1 илле ел тула.

Драматурглыкта бөтен Көнчыгыш халкының бабасы булган бу карт драматург үз халкы, Көнчыгыш халыклары арасында гына түгел, бәлки Көнбатыш халыклары арасында да яхшы танылган әдип һәм драматурглардандыр. Чөнки аның комедияләре, Көнчыгыш илләрендә дөнья йөзен күргәнчегә кадәр үк, Көнбатыш илләрендә дөнья йөзен күргәннәр. Аның комедияләре, бөтен Европа телләренә тәрҗемә ителеп, берничә мәртәбәләр сәхнәгә куелганнар. Моның сәбәбе дә бар. Чөнки ул заманнар мөселманнарның иң надан һәм иң фанатик заманнарыннан берсе иде.

Көнчыгышны һәм, гомумән, ислам дөньясын яхшы таныган, Иран, Төркия һәм Һиндстанның күренекле язучылары белән хәбәрләшеп торган Вольтер, Жан-Жак Руссо һәм башка әдипләрнең язулары белән таныш булган бу Фәтхегали Ахундов мөселманнарның артта калганлыкларын һәм бөтен Көнчыгыш халыкларының изелүләрен күргән һәм, шуңар йөрәге ачынып, шул бәхетсезлекләрнең төбе-тамыры кайдан килгәнлеген бик нык тикшергән. Күп төрләнә торгач, аның үткен гакылы Көнчыгыш халыкларының артта калуларының иң зур сәбәпләреннән берсе таракан аягы җырмачлаган рәвешендәге иске гарәп әлифбасы икәнлеген, икенче бер сәбәбе һәртөрле дини хорафатлар, милли гадәт һәм җолалар икәнлеген эзләп тапкан һәм шуларга каршы көрәшкә бик ныклап керешкән. Ул гарәп әлифбасын үзгәртү мәкъсуды белән Истанбулга да барган, Иранга да әллә никадәр хатлар яудырган, ләкин үзенең тырышлыкларының җимешләрен күрә алмыйча, моннан нәкъ илле ел электә дөньядан китеп барган. Үз вакытында халкы арасында һичбер кадер һәм кыйммәте беленмәгән, халыкның фанатиклыгы аркасында үзенең туры фикерләрен халык арасына кирәгенчә тарата алмаган, яңа фикерләре өчен фанатик халыклар каршында дошманлык белән генә танылган бу бөек язучының кадере тик хәзерге ирек заманында гына – хәзерге Совет заманында гына танылды.

Хәзер (бүген) бөтен Әзәрбәйҗан, Советлар җөмһүрияте, аның үлүенә илле ел тулу уңае белән, аның истәлек бәйрәмен итә. Аның исемен мәңгегә калдыру нияте белән, аның хәзерге көнгә кадәр патша цензурларының рөхсәт итмәгән һәм Кавказ халкының гореф-гадәтләре аркасында, үзенең җанына касд кыйлынудан курку аркасында дөньяга чыкмый калган әсәрләрен бастыру юлы һәм башкалар белән аның илле еллык бәйрәмен уздыра.

Мирза Фәтхегали Ахундов үзенең комедияләре белән безнең төньяк татарлары2 өчен дә яхшы таныш булган әдипләрдән. Татар театры дөньяга килә башлаган чорларда аның әсәрләре безнең өчен шактый озак вакытларга кадәр зур азык булып килде. Безнең яшь театрыбыз Фәтхегали бабаның әсәрләреннән бик озак вакытларга кадәр файдаланып килде3. Шул сәбәпләрдән әзәрбәйҗанлы туганнарыбызның бу кадерле истәлек бәйрәменә без дә чын күңелдән катнашабыз.

Тыкшынмагыз!
(Редакциягә хат)

Редактор иптәш!
Минем шушы хатыма гәзитәгездә урын бирүегезне үтенәм. Минем утыз еллык хезмәт бәйрәме уңае белән бәйрәмгә катнашкан, мине тәбрикләгән оешмалар, аерым иптәшләр, театр һәм концерт кичләренә катнашкан артист, артисткалар һәм ул театр, концертларны оештырган иптәшләрнең һәммәсенә дә бердән тәшәккерләремне белдерәм.
Шуның белән бергә Германиянең Берлин шәһәрендә иректе Совет иленең дошманнары, контрреволюцияче татар ак эмиграциясе тарафыннан чыгарыла торган «Милли юл» журналы редакциясе тарафыннан җибәрелгән тәбрик телеграмының үзем өчен тәбрик түгел, бәлки хурлык санаганымны әйтеп үтәргә тиеш табам. Бигрәк тә телеграмның «иректе көннәр җиткәнгә тикле...» дигән урыннары бу телеграмның пычрак ният белән язылган икәнен күрсәтәләр.
Минем утыз еллык хезмәтемнең унике елы тулы иректе Совет дәүләтендә үтте. Бу унике елның киң мөмкинлекләр бирелү ягыннан башкаларга чагыштырмаслык аермалары бар. Шуңар күрә Гаяз әфәнделәр1 көткән «ирек»нең минем өчен һич кирәге булмаганын, үземнең андый «ирек»ләрнең дошманы булуымны белдерәм.
Галиәсгар Камал
Казан,
1929, 24 апрель

Тормыш юлым

Мин, Галиәсгар Галиәкбәр улы Камал, 1878 ел, искечә 25 декабрь, яңача 1879 ел, 7 гыйнварда1 туган. Атам Галиәкбәр Мамадыш кантоны Сикертән2 авылында туып, унике яшендә Казанга килеп, Фәтхулла Мамаев3 дигән кешедә егерме биш яшенә кадәр хезмәт итеп, кустар-мехчы булып чыккан, үлгәнчегә кадәр шул эшендә дәвам итеп килде.
Мин 1900 елга кадәр элек «Госмания»4, аннан «Халидия»5, аннан, 1893 елдан башлап, «Мөхәммәдия»6 мәдрәсәсендә һәм аның янындагы русский класста укып, яз һәм җәй көннәрендә Мөхәммәтгали Кадыйров дигән кешегә ялланып, Хан7, Мәкәрҗә8 һәм Буа ярминкәләренә барып, кышын шулардан алган хезмәт хакы акчасы белән укыдым. 1898 елда беренче тапкыр башлап «Бәхетсез җегет» дигән драманың беренче редакциясен яздым. 1899 елда Нәмикъ Кәмалнең «Зәваллы чуҗык»9 дигән драмын төрекчәдән тәрҗемә кылып, Ф.Әхмәтҗанов дигән ярым китапчы, ярым галантерчы бер сәүдәгәргә сатып бастырдым.
1904 елда М.Р. һәм Кәрим Хәнәфиевләр, борадәран Шәрәфләр10, Ә.Мостафин11, Мөхетдин Корбангалиев һәм Һади Атласовларның «Мәгариф» нәшриятының12 китап кибетендә 1905 елга кадәр ялланып хезмәт итеп, 1905 ел октябрендә Алкинның13 «Казан мөхбире» гәзитәсенә күчтем. Анда Йосыф Акчура улы14 һәм Борһан Шәрәфләр белән килешә алмаганлыктан, хезмәттән чыгып, 1906 ел башында Габдулла мулла Апанаевның «Азат» гәзитәсенә секретарь булып кереп эшли башладым, ләкин, озак та үтмичә, Апанаев, җыелган подписка акчасы белән үзенең залогтагы йортын түләп алып, акчасын тотып бетергәч, төрле сылтаулар табып, гәзитәне минем исемемә алмаштырды. Шуннан соң башта, берничә номерга кадәр, гәзитә бастырган өчен аз-маз акча биреп килсә дә,

соңыннан бөтенләй ташлап качты. Шуннан соң мин Хөсәен Ямашев, Габделгафур Коләхмәтевләр булышлыгы белән гәзитәне алып барсам да, озакка бара алмыйча, гәзитәне туктатып, Һади Максудовның «Йолдыз» гәзитәсендә секретарь булып эшләргә, аның гәзитәсе тукталганчы15 шунда эшләргә мәҗбүр булдым. Гәзитәнең ахыргы елында Максудовта хезмәт иткән хәлдә, Мөселман социалистлар комитеты16 исеменнән Мулланур Вахитов тарафыннан чыгарыла торган «Кызыл байрак» гәзитәсендә һәм «Совет Восточного фронта»ның17 нәшрият бүлегендә тәрҗемәче булып эшләп, Казан чехлар кулында вакытта эшсез йөреп, чехлар чykканнан соң, «Эш», «Эшче», «Кызыл көрәшче», «Безнең байрак», «Татарстан» һәм, беренче номерыннан башлап 1931 елның 20 июленә кадәр, «Кызыл Татарстан» гәзитәсендә хезмәт итеп килдем. 1898 елдан башлап хәзергә кадәр егерме оригинал әсәрләр язып, шул вакыт эчендә йөздән артык театр әсәрләре тәрҗемә иттем. 1924 ел язында, Совет матбугаты көнендә, «Хезмәт батыры» исемен алдым18.

Яза башлавым тарихы

Октябрьгә кадәр, көрәш ялкыны белән азыкланып, берничә әсәр язып ташланылган иде. Моны буржуа җәмәгать хезмәтчеләре бик начар каршы алдылар.

Гаяз Исхакыйның «Бәхетсез егет» драмасы басылып чыккач, «сине опера язган дип әйтәләр» дип көлеп сөйләвен гомергә онытасым юк.

Татар театрын нигезләүгә әсәр белән генә түгел, киемнәрем, уеннарым белән дә күп кенә ярдәм иткән идем. Татар буржуасы моның өчен мине кырый гына какты. Ул байгуралар театрны үстерүгә ярдәм итү түгел, бәлки һаман без башлаган эшләрне сүндерергә тырышалар иде.

Совет безнең эшләргә бик зур мөмкинлекләр ачты. Мин революциянең беренче көннәреннән башлап ук аңа каләмем белән катнаштым. Һаман язып килдем. Ләкин, минем язачак әйберләремә караганда, бөтен язган әйберләрем бер башлангыч төсле генә тора әле. Мин сезгә монда үземнең ничек яза башлавымны сөйләп китмәкче булам.

Минем язучылык, үземчә, кызык кына башланды.

Мин үземне белә башлаган вакытта, атам Казанда, хәзерге Тукай урамында «Госмания мәдрәсәсе» дигән мәдрәсә күршесендә тора иде1. Хәзерге көндә Колхоз базары дип аталган базар урынында элек Ашлык базары иде. Шул базарда ел саен Рождество, Масленица, Пасха бәйрәмнәре вакытларында балаганнар корып театр уйныйлар иде. Мин кызыгып карап тора торган театр «Курчак кәмите» иде. Анда кәмитнең бер почмагындагы тишектән карап торырга куркыныч та, күңелле дә: бик озын борынлы бер курчак чыга иде дә әллә нинди икенче бер «кыз» курчак белән бии, аның артыннан бер төрек чыга да аны кыйнап үтерә, аның артыннан яшел кәләпүшле татар чыга да, аны да кыйнап үтерә иде. Бу эшкә ни өчендер минем бик ачу килә, соңыннан бутышник чыгып ямьсез озын борынлы курчакны акыртып-бакыртып часка алып киткәч кенә, бераз кәеф килә иде. Шулай да, никадәр ачу килсә дә, көн саен ул курчакны барып карамый калмый идем. Соңыннан, май кәмите* беткәч, иптәш малайлар белән ул «озын борын»нан ачуны аладыр идек. Каткан бәрәңгеләрдән юнып – курчаклар, өйгән карларны казып «кәмит» ясап, «озын борын»ны туйганчы кыйната идек.

Бераз үсә төшкәч, кәмитнең эченә дә керә башладым. Анда, эчтәге уеннарны карап кайткач, безнең кәмит тә утын келәтләренә күчте. Анда таганнарда да уйный, фокуслар да күрсәтә идек.

Инде мин, тагы да үсә төшеп, язуны да яхшырак таный башлагач, ул заманның әдәбиятыннан «Белек»2, «Рисаләи Газизә»3, тагы шундый хикәяләр, К.Насыйри китапларын яратып укый башлаган вакытларда, Г.Ильясовның «Бичара кыз», Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз» дигән театр китаплары чыкты4. Ильясов китабын ничә кат укыганымны белмим, әмма «Рәдде бичара кыз»ны кырык-илле тапкыр укыганмындыр. Хәтта мин аны күңелдән, күрми укый да белә идем. Ул вакытларда Казанда, хәзерге көндәге Ирек мәйданында, түбәсенә таштан әллә нинди сыннар ясап куйган бик зур ташпулат бар иде5. Мәдрәсәдә укучы иптәшләремнең кайберләре әнә шул

зур пулатта мин укыган китаплар шикелле китапларны уйнап күрсәткәнлекләрен сөйлиләр иде.
Шул елларда мин, әтигә ияреп, Мәкәрҗә ярминкәсенә6 бара башладым. Бер елны анда, һәр көн эштән бушагач, әтидә өйрәнчек булып хезмәт итә торган малай белән капчык күтәреп, кибет рәтләренә чыгып, ташландык кәгазьләрне җыеп, потын егерме тиеннән сатып, үзебезгә бик «зур» сума ясадык. Ул сума ярминкәдәге кәмитләргә керүдән дә артып калды. Мин шул иптәш малайга Казанда аннан да зур кәмит барлыгын, анда атнага бер көндез дә уеннар булганын сөйләп, кайткач, шунда барырга аннан сүз алдым.
Мәкәрҗәдән кайттык. Аннан кайткач, безнең бәхеткә, әти бабай белән күрешергә авылга кайтып китте.
Малайның да эше юк, якшәмбе дә туры килде, көндезге уенны да куялар (хәтеремдә калган, «Ева» дигән уен куйганнар иде). Без, җидешәр тиен түләп галеркага билет алып, уенны карап кайттык. Икебезгә бер тиенлек русча белмәсәк тә, драманың кайгылы икәнен артистларның кыланышларыннан аңладык. Ул вакытта Мәрҗани мәдрәсәсендә7 укый торган Театр Шәех дигән берәү безнең белән танышты. Үзе белгән кадәр аңлатып та маташты. Тиздән бик матур, музыкаль уен башланачагын сөйләп, безне шуңа килергә димләде. Иптәшемнең күңеленә уен бер дә ошамады. Мин әле өй эче, әле бакча булып декорацияләр алмашуын яраттым һәм гаҗәпләндем. Менә бервакыт опера башланды.
Югарыда әйткән Театр Шәех мине онытмаган икән: мәдрәсәгә чакыра килде. Бәясе бик кыйбат (егерме җиде тиен иде бугай) булса да, билет та алып килгән. «Фра дьявол»8 дигән уен куелды. Шәех, үзе аңлаган кадәр, уенның мәгънәсен дә аңлатты. Уен күңелгә бик ошады. Шуннан без атна саен көндез театрга бара башладык.
Мәдрәсәдә мин Борһан Шәрәф белән күрше бүлмәдә торам, аның белән бергәләп Гаспринскийның «Тәрҗеман» гәзитәсен дә укый идек. Шуннан аның белән театрга да йөри башладык. Театр күңелле, ләкин русча белү начар, аңлап булмый. Менә бер көн «Садко»9 куела. Б.Шәрәф, каяндыр табып, илле тиенгә «Садко» китабын алып кайта да, без икәүләп, Насыйриның русча сүзлеген10 алга куеп, «Садко»ны моталәгә кылабыз. Мин ул вакыт Миргаяз Иманаевтан русча укыйм11. Белмәгән, сүзлектә булмаган сүзләрне аннан да сорыйм. Шулай итеп, ярты-йорты булса да «Садко»ны аңлап куям. Кайткач, «Садко»ны тагы укыйбыз, тагы укыйбыз, укыган саен аңлау арта бара. Җитмәсә, шул вакытларда М.Иманаевның энесе Шәехгаттарның12 студент вакыты. Ул «Фауст»ны13 укый. «Фауст» китабы бик калын кәгазьгә басылып, бик матур тышланган, кызыктыра. Ш.И.14 юк вакытта мин, качып-качып кына, китабын укып карыйм, кайбер сүзләрен аңлап та була. Һи, шундый китапларны, шундый театр китапларын язсаң иде! Шул уй бертуктаусыз башны вата.
Нәкъ шул вакытларда Бр.Кәримевләрдә15 приказчик булып торган И.Әхмәтҗанов дигән яшь җегет, агасымы, бабасымы бер картка иптәш булып хаҗга барып, кайтышлый, Истанбул толчогыннан берничә сандык (гәрчә ящик булса да, Истанбулдан мал китерүчеләр сандык дип йөриләр иде) һәртөрле тотылган төрек әдәбияты алып кайта. Без яңа әдәбиятка чумабыз. Арадан Нәмикъ Кәмалның таш басмада язылып басылган «Зәваллы чуҗык» дигән драмасы килеп чыга16. Нинди зур байлык! Җитмәсә, мин инде төрекчәне дә бераз сукалый башладым. Аны кат-кат укып аңлыйм. Нәкъ шул вакытларда минем үземнең башымда да бер тема йөри. Н.Кәмалның китабы мине кузгатып җибәрә дә, мин үзем уйлап йөргән «Бәхетсез җегет» дигән нәрсәмнең беренче редакциясен язып, укытучым Миргаяз Иманаевка күрсәтәм, ул бик күтәреп каршы ала да, китапның артына берничә юллык кыйссадан хыйсса язып, Петербурга, цензорга да җибәрә.
Хәзер миңа җил арттан! Китапның цензордан кайтканын көтеп тә тормыйча, үземнең аңлаган кадәрем белән «Зәваллы чуҗык»ны, «Кызганыч бала» дип тәрҗемә итеп, И.Әхмәтҗановның үзенә үк төшереп сатып, биш сум гонорар алып, ул гонорарга яңадан китаплар алам. Хәзер инде мин төрекчәне яхшы аңлыйм, рәхәтләнеп укыйм. Шул вакытларда «Бәхетсез җегет» тә цензордан кайта. Кәримевләр аны да бер табаклы китап итеп бастырып чыгаралар17.

Җитә 1900 ел. Мин инде «Мөхәммәдия»дә укып хәтме көтеб кылган бер җегет18, ләкин бик тәүфыйксыз, азган-тузган бер җегет: чөнки русча укырга да йөрим, театрга да барам. Җитмәсә тагы, Борһан Шәрәф белән бергәләп, юка кәгазь астына копировка кәгазьләре куеп, мәдрәсәдәге хәлләрнең җитмәгән якларыннан көлеп, «Телескоп», «Мәнзарател-галәм» дигән гәзитәләр чыгарып, төнлә белән җәмәгать сәкеләренә дә ташлыйбыз. «Тәүфыйксызлык чигенә җитеп», мин тәмәке дә тарта башлыйм. Хәлфәләр бу эшләрне бик яхшы сизәләр. Мондый тәүфыйксыз, бунтарь кешедән котылу өчен, мине мулла итү ягын каералар.

Г.Баруди19, хезмәте әрәмгә китмәсен өчен һәм шәһәрдә үзе яклы кеше арттыру өчен, әтине димләп, Казан байларыннан берсенең кызына өйләндереп, аннан иске зиярәт өстенә мәчет20 салдырып, мине мулла итәргә телиләр. Мин өйләнергә риза булам, өйләнәм, ләкин... мулла булмыйм. Атам мехчы булганлыктан, мине мех сәүдәгәре ясамакчы булалар. Аңа да риза түгел. Аптырагач, китапчы ясыйлар. Мин, Истанбулга барып, җыен яңа әдәбият, шулар җөмләсеннән оригинал, тәрҗемә, төрле театр китаплары төяп алып кайтам. Берәр ел вакыт уза. Кәримевләр үзләренә эне тиешле Мәхмүт Алмаевны Германиядән типография эшләренә өйрәтеп кайтаралар. Ул «Сарай» номерларында21 тора. Аның белән бергәләп, гектографиядә басып, «Тәрәкъкый» исемендә гәзитә чыгара башлыйбыз. Ул шул вакыт «Һай Дунай, вай Дунай» дигән бер куплет яза. Мин дә, аңар ияреп, «Приказчик» дигән бер куплет язам. Шул елны китап сәүдәсе белән Мәкәрҗәгә барып, Т.Соловьевның «Двухсветный» дигән гостиницасында22 ачык сценада рус артистлары белән аларны җырлыйм – шау-шу китә. Шуннан, үч иткән шикелле, миндә язу дәрте кузгала, ләкин белем сай, белгән гарәпчә, төрекчә белән эш чыгарып булмый, русчаны белмим, шулай да тырышып-тырмашып гәзитәләр укырга керешәм. «Нива» журналы алам, аңа кушымта булып килгән Чехов әсәрләрен укыйм.

Шулай маташа торгач, 1905 ел җитә. Шәһәрнең «азган-тузган» яшьләре театр артындагы урамда Приказчиклар клубында23 спектакль куялар. Менә шуннан соң миндә ничә ел томаланып яткан дәрт яңадан кузгала. «Беренче театр»ны язып24, үз тормышымны сәхнәгә чыгарып күрсәтәм.

Театр куюлар көчәя, ләкин пьесалар юк. Шуннан электә язылган кыска «Бәхетсез җегет»не киңәйтеп, сәхнәгә куярга яраклы хәлгә китерәм25, ул гына да җитми; аннан Төркиядән алып кайткан китаплар арасыннан алып «Пенти Хәмид» дигән нәрсәне «Саран» исеме белән тәрҗемә кылып, «Гасыр» көтебханәсе аркылы бастырып чыгарам26. Ул Т.Касаб дигән бер бәндәнең Мольердан алып төрек тормышына күчереп, үзенеке итеп язган бернәрсә булып чыга. Аның сере ачылгач, Мольерны укырга тотынып, аннан берникадәр нәрсәләр тәрҗемә кылам27.

Берзаман «Шәрекъ клубы» ачыла28. Мин клубта старшиналарның берсе. Клубны зурайтыр өчен, башында Г.Кариев, М.Иманский, Сәхипҗамал Гыйззәтуллиналар тора торган «Сәйяр»29 труппасын яллыйбыз. Бер куйган пьесаны ике куйсаң, халык килми. Сәгыйть Рәмиевләр, Ярулла Вәлиевләр, Идрис Богдановлар язган пьесалар гына җитми, халык һаман яңадан-яңа пьесалар сорый. «Уйнаш»ны да язып карыйм30. «Дәҗҗал» да языла31, башкалары да. Кариев һаман да туймый. Ул «Беренче театр»дагы Хәмзә бай ролен үзенеке итеп ала да һәрбер драма артыннан шуны куя. Уенны күргән, театрга кемнәр йөргәнен тикшереп, акчасыз контроль булып йөрүчеләр театрда нинди хәлләр булганын икенче көнне, түкми-чәчми, Печән базары чатындагы Шкафчы Хафизга сөйли генә торалар. Ул минем кайната булган Хәмзә байны32 (Кариев аны һәрвакыт шуның кыяфәтендә итеп уйный иде) котырта, ул өйгә кайтып хатынга, хатын миңа зарлана иде. Хафизның бу кыланышлары, русча әйткәндә, «наконец, мне надоело»! Шуннан соң, Хафизның бөтен кыланышларын өйрәнеп, бара торгач, ахырдан «Безнең шәһәрнең серләре»33 дөньяга килеп чыкты, һәм аның чыгуы минем өчен уңышлы да булды. Бердән, Хафиз миңа бәйләнүдән тукталып тынды, икенчедән, тамашачылар типларның тормыштан алына икәнлеген аңлап алып, мещан һәм татар сәүдәгәрләре арасындагы төрле яшерен серләрне миңа ташый башладылар. Яшерә алмыйм, язган нәрсәләремнең

күбесендә мин шулардан файдаландым, мещаннар һәм алардан күп аермалары булмаган купецлар тормышын, мещан табигатендәге семья аркылы аларның хатыннарының табигатьләрен шактый гына өйрәндем. Үзем мәдрәсәдә укып яткан шәкерт – пишкадәм булу аркасында, голямалар да миннән серләрен яшерә алмыйлар иде. Менә минем ничек язучы – театр язучысы булып китүемнең тарихы шуннан гыйбарәт.

Минем персональный пенсионер
булуымның тарихы

Мин, Галиәсгар Галиәкбәр улы Камал, 1878 ел, искечә 25 декабрь1, дүшәмбе көн, таң вакытында, Казанда, элекке Аркылы Тихвинский, хәзерге Фуксовский2 урамда, Суворов (хәзерге Хәйрулла Хәлиуллин, Сувор Хәйрулла дип йөриләр) йортында3 дөньяга килгән. Мин яшь, үз-үземне белмәгән бала вакытымда, әти, һичбер вакытта үз-үзенә карар таба алмыйча, бер квартирдан икенчесенә күчеп йөргәнлектән, ул заманның асламчы хатыннарыннан Мәгъри астай дип йөртелә торган бер хатын минем әти белән Кариев заманында артист булып озак вакытлар уйнап йөргән кешеләрдән Ишми дигән артистның атасы Кара Савыт Шаһи дигән кеше хакында:

– Кара Савыт Шаһига хатын ярамый, камчатчы Галиәкбәргә фатир ярамый, – дип шаяртып сөйли торган булган.

Шулай итеп без, бер фатирдан икенчесенә күчеп бик күп йөри торгач, элекке Тихвинский урам, хәзерге Тукай урамында Госманов мәдрәсәсе4 күршесендә Мазар Фазлый дигән кешенең йортына5 фатир күченгәнбез. Минем үз-үземне белә башлавым әнә шуннан башлана. Бу квартирга күчеп килгәндә, әле без күчәчәк квартирның таш йорты эшләнеп бетмәгән иде, шул сәбәптән безне вакытлыча гына капканың икенче ягындагы пулатның астындагы двор өенең бер почмагындагы бер бүлмәгә урнаштырып торганнар. Шунда торганда, мин пич алдында уйнап утырганда, ут кабынып китеп, күлмәгемнең алды ягы дөрләп яна башлаган, шунда хезмәт итүче Фазыл исемле дворник, мәллә чикмәне белән каплап алып, утны сүндергән, мин дә, корсакларым бераз пешү белән, янып үлүдән котылып калган идем. Әнә шул вакыйга беренче һәм һич онытылмый торган бер вакыйга булып исемдә калган.

Икенче онытылмаган вакыйга дә – шул көннәрдә, шул ук йортта булган яңа квартирга күчү мәсьәләсе. Без югары каттагы шул квартирга күчкән вакытта, квартирның өй алдысы эшләнмәгән, мостиклары сүтелмәгән иде. Мине шул мостиктан җитәкләп алып менгәндә, егылып төшәм дип бик курыккан идем. Үзем белмим, ләкин шул урамда торучылар мине, шул вакытларда син җырчы идең, дип сөйлиләр. Мине җырлатып, кәләвә ашарга бер тиен, ике тиен акча бирә торган булганнар. Җырлый торган җыруым:

Алты кыек тәрәзә, куйдырмыйсың бер ишек,
Бетәр микән, бетмәс икән [сиңа төшкән] бу гыйшык, –
дигән җыр белән:
Скрипка, думбыра, әти башка кундыра,
Өйгә кайтып кергәчтен, әни буран туздыра, –
дигән җыр булган.

Миңа биш яшь тулып алтыга чыккан вакытларда булырга кирәк, минем әнинең авылы булган Арча районы Казанбашы волосте Түбән Масра6 дигән сөннәтче бабайлар авылына Казаннан, Сәлах хәзрәт мәдрәсәсеннән Исмәгыйль дигән «бик гыйлем» бер пишкадәмне мулла итеп куйганнар. Әти мине, шул «гыйлем» кешедән укырга дип, Масрага җибәргән. Анда мин укыганмындырмы, юкмы – ул кадәресен белмим, – әмма, һичбер язу танымаган көйгә, мулланың, аркага камчылар төшергәләп, «әфтияк» сүрәләре бикләткәнен һәм кичке «сабак» кереп, шуларны тыңлатканын беләм һәм әнинең миннән берничә яшьләр олы энесенең «Иман шарты»ндагы7 «Вә һүә галә көлле шәйин кадир» дигән сүзне «вә һүә галә көнләшәдер Кадыйр» дип тыңлатканын беләм. Аның болай дип тыңлатуы бер дә гаҗәп түгел, чөнки аның гарәпчәне һич ишеткәне юк, әмма безнең каршыда Кадыйр исемле бер күрше бар, әбиләр аны «хатыныннан көнләшә» дип сөйлиләр иде, аның, аның гына түгел,

минем дә ул сүзне ишеткәнем бар иде. Шулай иттереп без, һич укымаган, язу танымаган көйгә, кыш буена күңел сабаклары бикләп, «бик гыйлем» хәзрәттән укып, кышны уздырып чыктык. Үземә бик күп эләкмәсә дә, шунда бергә укучы минем шикелле һәм миннән берничә яшь зур малайларның кушка (камчы) ашаганнарын күреп, кышны уздырып чыктык, кыш буена бер мәртәбә «убыр» күрү вакыйгасеннән башка истә калырлык һичбер вакыйга дә булмады. Ул вакыйга шуннан гыйбарәт: бер төнне (чөнки Исмәгыйль хәзрәт күңел сабагына ястүдән8 чыгышлый гына керәдер иде, ә без мәдрәсәгә караңгы төшкәч тә барадыр идек тә, кизүнең яндырган түшәм лампасы яктысында «Сукыр тәкә», «Дерен сугыш» уйнап гөр киләдер идек) шулай, күңел сабагыннан соң өйгә кайтып барганда, мәчет елгасында җылтыр-җылтыр янган ут күренә, очкыннары да чәчрәп куя. Шуны күрүгә, арадан бер малай: «Убыр!» – дип кычкырып та җибәрде, барлык малайлар дәррәү кире мәдрәсәгә кача башладылар. Мәдрәсәгә бардык, анда хәзрәт утны сүндереп кайтып киткән. Югары оч малайлары инде алар күптән өйләренә кайтып җиткәннәр. Безгә шәфәгать сорарга урамда бер олы кеше дә юк. Малайлар шүрләделәр, белгән күңел сабакларын гына түгел, арт сабакларын да укырга тотындылар, ләкин файда юк, «убыр» һаман кышкы җилдә авызыннан утларын чәчеп ята. Кышкы төн суык, урамда төн буе торып булмый, өйләрдә дә, теге «убыр»дан башка, җылтыраган ут юк. Мин курыкмыйм куркуын, чөнки һәрничек дөнья күргән «шәһәр малае». Шулай да иптәшләрең барысы да курыккач, никадәр батыр булсам да, минем дә шүрләми хәлем булмады.

Өс юка, җил өрә, курку да туңдыра, ни булса да булыр, батыр булырга кирәк: «Әйдәгез, малайлар, барыгыз да белгәннәрегезне кычкырып укыгыз, «әгузе бисмилла»дан җен-пәриләр качар, әйдә киттек!» Минем шикелле үк туңганнар булырга кирәк, малайлар да батырландылар, минем арттан курка-поса гына бара башладылар. «Догалар бәрәкәтендә» әле һаман теге «убыр» урыныннан кузгала алмый. Якынрак килгәч, кылт итеп, көндез бер әбинең елгага салам көле түккәнен күрүем хәтергә төште. Шуннан эчемә җылы кереп, батырланып йөгереп барып, утка тибеп җибәрдем дә, утлы салам көлләре тирә-якка чәчелеп китте. Инде мин герой, батырлык шәп, карга чумган, катып беткән киез итек белән калганнарын да басып, таптап сүндереп бетердем.

Бу геройлык вакыйгасе авыл малайлары арасында минем авторитетны бик күтәреп җибәрде. Көндез һәр көн безнең түбән оч малайлары белән якалашып сугыша торган югары оч малайлары каршысында да мин – «кала малае»ның дәрәҗәсе күтәрелде, мине дошман күрми башладылар, хәтта көндезләрдә япа-ялгыз югары очка менеп, алар белән бергәләп уйнау, алар белән бергәләп чана шуу хәленә килеп җиттем. Шуның белән бергә түбән очлар да мине дус күрәләр иде. Шулай итеп, кыш үтте. Кыш буена каладан кайтучылар артыннан берничә тапкыр этиләрдән күчтәнәчләр, пешкән мәмиләр, каткан-туңган алмалар да килде. Алардан да авыз иттергәләгәч, минем дуслар тагы да күбәеп китте. Кыш буена күп укый торгач, минем гыйлем дә зурайды, башкалар «Әләм тәрәкәйфә» сүрәсендә тукталып калсалар да, мин «Гаммә» сүрәсенә кадәр барып җиттем. Миңа күчтәнәч җибәргәндә этиләр, хәзрәтне дә «онытмыйча», аңар да берничә аршын ситса, сәдакалар җибәргәләгәч, әбиләр дә берничә тапкыр мунчаларга чакырып, коймаклар, кабартмалар белән чәйләр эчертеп сыйлаштыргалагач, минем дәрәҗә тагы да үсеп китеп, хәзрәт үзе белән мәчеткә алып кереп, «күрәсезме, мин ничек тырыштырам, балаларны ничек итеп кеше итәм» дигәндәй мактанып, бер җомгада «Вәлләйли иза ягъша» сүрәсен дә укытты. Авыл абыстайлары, карчык һәм киленнәре дә, минем шундый Коръән уку хәбәремне ишетеп: «Сабый баланың догасы кабул була икән аның», – дип, өйләренә алып кереп, Коръән укытып, йомыркалар, кабартмалар ашатып та чыгара башладылар. Тормыш зарарсыз иде, өс бөтен, тамак тук, тау шуарга чана бар, әнинең сеңлесе йомшак бәти йоныннан бәйләп, өстеннән киндер белән баш сапкан бияләй бик җылы. Әни авылыннан бер чакрым җирдә (хәзер күргәнем юк, икесе бергә тоташа язган, диләр) – Яңа Масрада – этинең сеңлесе, дүрт чакрым җирдә – Му казаклары авылында – әбинең тутасы (исеме хәтеремдә калмаганмы яки бөтенләй ишеткәнем булмагандырмы, анысын белмим, казаклар Бал тәтәй диләр иде), аннан ярты чакрым Сикертән авылында Сикертән бал

тәтәй, аның улы Гыйлаҗи абзый, әтинең анасы – Сикертән әби [тора иде]. Бабайның үләр алдыннан түшәктә ятканы гына бераз хәтеремдә, ләкин ни төсле кеше булганын белмим, әмма ике энесен хәтерлим, аларның берсе өйләнгән, берсе өйләнмәгән кешеләр иде. Шул елның көзендә иде бугай, өйләнде. Әтиләр туйга кайткач, туйга мине дә алып барганнар иде, миңа бер тустаган (әниләр авылында «җамъяк» диләр, пыяладан ясалган булса да, «җам аяк» дигән сүздән алынган булырга кирәк) бал эчергәннәр, шуның белән минем башым бик әйләнгән иде. Туй карарга җыелган малайлар: «Исергән, исергән», – дип, миннән көлгәннәр. Мин, ачуым килеп, үзләрен чыбыркы белән куып йөргән идем.
Масра9 белән Сикертән авыллары арасында халыкның типларында, бигрәк тә моннан кырык биш ел элекке вакытларда, аерма бик күп иде. Масра халкының үзләре сөйләүләренә караганда, Масра халкының ерак бабалары, Идел болгарлары мөселман булгач, Болгар ханнарының чакырулары буенча, халыкны «сөннәткә» утырту өчен Гарәбстаннан килгәннәр, имеш, алар үзләре Әнәс сәхабә10 нәселеннән, имеш. (Сөннәтче бабаларның әйтүләренә караганда, аларның кулларында бу дәгъваның дөреслеген исбат итә торган, нәселдән нәселгә күчеп йөри торган «шәҗәрә»ләре дә бар, диләр, ләкин минем күргәнем юк.) Менә ханнарның чакыртуы буенча килгән шул сөннәтче гарәпләрдән берникадәресе Казан ханлыгына килгәннәр дә, Казан ханы аларны икегә аерып, бер өлешен Тау ягына, Кошман11 дигән авылга, икенче өлешен яхшы урманлы, җирле, сулы урын булган хәзерге Масра авылы урынына урнаштырган; алар анда, Казан татарлары кызларына өйләнеп, авыл булып утырганнар да, гарәпчә «зур шәһәр» мәгънәсендә булган Мисырга охшатып, авылларына Масра дип исем биргәннәр; шуннан, балаларының телләре аналарына ияреп, татарлашып киткәннәр дип сөйлиләр һәм моның дөрес булуын исбат итәргә ярарлык татар һәм янәшә-тирәдәге башка халыкка бер дә охшамаган, ләкин гарәпкә охшаган, чәч-сакаллары чем-кара кешеләр, сирәк булса да, Масрада очрыйлар. Шуннан биш кенә чакрым җирдәге минем атамның авылы булган Сикертән авылының кешеләре баштанаяк дип әйтерлек вотякларга охшаган, ут янып тора торган кызыл-сары чәч-сакаллы кешеләр. Алар Казан ханлыгы заманында ардан12 мөселман булып, шуннан татар исеме астына кереп югалганнар булырга кирәк.
Ярый, ничек булган булса, шулай булыр, мин яңадан Масрага әйләнеп кайтыйм әле.
Шулай итеп, Масрада мин кышны үткәрдем. Кояш карап, көннәрнең күңелен йомшатып, мыскыл итеп көлгән йөзләре белән рәхимсез, каты күңелле кышны җиңеп, аны җылатып, өстенә ябынган ак юрганнарын чылатып, гөрләвекләрен агыза башлады. Тау башлары ачылып, кар астыннан чыккан тау башлары яшелләнә, ташулар ага, чит җирләрдән килгән сыерчыклар сайрый, күгәрченнәр гөрли, кыш буена боегып яткан чыпчыклар да чүкелдәшә башлады. Инде балаларны бау белән тарттырсаң да мәдрәсәгә китерү мөмкин булмагач, абзыкай да, мәдрәсәгә килеп, балалар кабыргасы санаудан туктады. Без дә, аяк асты юешләнеп, тишек киез итек белән урамда йөрергә мөмкинлек беткәч, кары китеп бетмәгән ала-кола кыр өстеннән, әбинең ачулануына, салкын тиереп авырырсыз, диюенә дә карамастан, яланаяк чатыр-чотыр чаба башладык. Баштан тәвәккәл бүрек төшмәсә дә, яланаяк чатыр-чотыр йөгереп, су җырып йөрүләр, һи, рәхәт тә икән лә соң! Ул, мин сиңайтим, әллә нинди чыр-чу килгән тавышлар чыгарып сулар ага, зур егетләр, үкчәләре белән тибеп-тибеп, яр буендагы астын су ашаган карларны ташу суына төшерәләр дә, кар, бултыйх суга чумып, аннан тагы башын калкытып, су буйлап түбәнгә таба ашыгып чаба да чаба, аннан каядыр китә дә югала. Бөтен инеш буе безнең шикелле бала-чага белән тулган. Алар да, зур егетләрдән күрмәкче, яр буендагы карларны суга тибеп төшермәкче булалар да, ләкин кар аларны тыңламый, таяк тыгып каерып карасалар да, кар урыныннан кымшанмый. Таяк тыккан урыны, каера торгач, җылак малайның авызы шикелле җырылса да, теге типкер егетләрнеке шикелле, булт итеп суга да барып төшми һәм, су китерүдән бигрәк, авыл егетләренең кылануларын, тап-таза егетләрнең шаяруларын карап торыр өчен башына кызыл француз яулык, тамбур белән чиккән сары алъяпкыч ябып, атлаган саен әле бер якка, әле икенче якка чалт-чолт итеп бәрелә торган чулпылар таккан яшь кызлар да (араларында шактый утырганнары да бар) рәхәтләнеп шаркылдап көлеп тә

җибәрмиләр. Һи! Исең киткән икән лә, алар көлмәсәләр, илтифат итмәсәләр, малаеңның аның икенче бер һөнәре юкмыни! Ул зур гына итеп бер [уч] җепшек карны йомарлап ала да башына кигән атасының зур, әле бер якка, әле икенче якка кыйшаеп төшә торган иске бүркен басыбрак киеп, шалт! йомарлаган карны суның уртасына тондыра. Суның, бөтенләй күзе чәчрәп чыккандай булып, тамчылары як-якка карый, ләкин анда да теге кызлар белән егетләрнең исләре китми, аларның язгы һава килү белән исләре китә торган нәрсә бөтенләй башка. Ишетмисеңмени, әнә анда, абзарда, бер ат нинди яңгыратып кешни! Язгы көнне сыерларның мөгрәүләре дә кышкы шикелле түгел, бөтенләй башка. А, харап булган, бик зур эш икән! Малайның шуларны уйлап авызын бүлтәйткәне әллә кайдан күренеп тора. Малайның мондый илтифатсызлыкка бик ачуы килә. Авызын күтәреп, аңгыраланып карап тора торган бер малайның башыннан бүреген бәреп төшерә. Ярый әле, малайның бәхете бар икән, бүрек былчыракка да, суга да төшми, сызып эреп ята торган ак кар өстенә төшә. Менә инде хәзер карап тор, бу ике малай арасында сугыш башлана. Кем кемне бүсәр? Юк, бәхеткә каршы, андый-мондый бәхетсезлек булмады тагы, нәкъ сугыш башлана дигәндә генә, бер малай, каяндыр бер көлтә саламны алып килеп, ут төртеп, суга ташлады. Көлтә, ялкыннар, төтеннәр чыгарып, су өстеннән агып китте. Җыелган бөтен халыкның күзе шунда төбәлде. Теге ике малай сугышны оныттылар. Бу эш минем өчен тагы да күңелле бер яңалык булды. Былтыр, Иделдә боз акканда, ишегалдындагы бер ломовой ямщик, хатынын һәм бала-чагаларын төяп, шулар арасына мине дә утыртып, Идел бозы акканны карарга алып барган иде. Шул вакытта бер пароход, морҗаларыннан төтеннәр чыгарып, сирәк кенә ага торган бозлар арасыннан безгә таба карап чыгып киләдер иде. Бу саламны күргәч, шул искә килеп төште. Аның артыннан Болак буе, аннан су агуы, анда көймәләр йөрү, ул йөрүчеләрне бик күп кешеләрнең Болак күпере өстеннән җыелып карап торулары, минем дә иптәш малайлар белән рәшәткә арасыннан карап торуларым күз алдыма килде. Аз гына сагынып җылап җибәрмәдем. Бәлки, җылаганмындыр да, илле еллар вакыт үткәч, аны инде каян беләсең. Менә шул илле ел вакыт узганнан соң да онытмаслык ташу суы агып бетеп, кырлар ачылуга, авыл егетләре, сабан туе ясыйбыз дип, атларга атланып, бер ел эчендә килен булып төшкән яшь хатыннардан, ат чаптырганда бүләк итеп бирү өчен, сөлге, эскәтерләр җыеп йөрделәр. Алар сабан туен Дау язы дигән урманга барыпмы шунда, әллә кая еракка барып ясадылар. Без малайларның күбесе анда бармадык, чөнки безнең үзебезнең бик зур эшебез – һәр өй саен кереп, йомырка җыеп йөрисебез бар иде. Тастымалдан теккән капчыкны күтәреп, малайлар белән бергә йөреп, өй саен дип әйтерлек кереп, суган кабыгы суына яки кызыл, яшел һәм башка төсләргә буяган пешкән йомыркаларны капчык тутырып алып кайтып, берничә көн ашадык.
Хәзер инде көннәр матурланды, тау башлары ямь-яшел, көне буе өйгә кайтып керәсе килми, элек аякка кими йөргәнгә ачулана торган әби инде, «аягым туңды» дигәнгә, ачуланырга гына тора. Кыш буе өстерәгән, асты тишелеп чыккан киез итекне дә әллә кая чормага менгереп җыеп куйды. Авыл эченнән ага торган су буенда ташлар арасыннан шалтырап ага торган боз шикелле салкын, йөз дән артык эреле-ваклы чишмәләр бар. Без көн буена шул чишмәләрне бөяп, таш араларын шунда була торган яшькелтрәк ак сутлы балчык белән сылап, тегермән бөяләре ясый, аңар чырадан чарыклар ясап, тегермәнне әйләндерәдер идек.
Тау башына ут ягып, көлдә бәрәңге пешереп ашыйдыр идек. Көннәрнең берендә ул бәрәңге пешерү минем башка бер бәла тудырды. Бәрәңгене гади рәвештә генә көлгә күмеп пешерү мине туйдырды да мин, үземчә яңалык чыгарып, юка, шома ак ташларны җыеп, шулардан мичкә охшашлы бернәрсә ясап, эченә ут ягып, бәрәңгене шунда пешерергә уйладым. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, минем инженерлыгым эшкә ашмады, хәтта аз гына бәхетсезлеккә очрамадым. Кем белә, мич тирәсендәрәк булсак, бәлки, бәхетсезлек тә булган булыр иде. Без читтәрәк бәрәңге пешкәнне көтеп уйнап йөргәндә, кинәттән бик каты, мылтык шартлавыннан да катырак бер шартлау булды. Мичнең стена ташлары, як-якка атылып, тетәләнеп бетте. Ул нинди таш булгандыр, анысын белмим, чөнки шул

вакыттан бирле сынап караганым юк. Хәзер яхшы, ачык белмим, шул вакыйга узгач укмыдыр, аннан бераз соңракмыдыр, ул бөя бөяү, бәрәңге пешерүләрне ташладык, чөнки яланаяк, гел сутлы юеш балчык эчендә йөреп, аяк-куллар ярылып, чебиләп беткән, аны бетерү өчен туң майны эретеп майлаган майның ачыттыруы йөрәгемә төшкән иде. Хәер, инде ансыз да безгә ул уеннарны ташларга, сулар җылынып торганлыктан, балык тоту белән шөгыльләнергә вакыт җитә башлаган иде. Без бөтен төркемебез белән, болынга төшеп, әбидән сорарга кыймыйча гына алган йомырканы биреп алган кармакларны юан соры тегәрҗепләргә бәйләп, кояш чыкканнан башлап кояш баеганчы, балык тота торган булдык. Әле хәзердә дә исем китә, алар нинди, шундый юан җепне дә күрми торган сукыр яки, Тукай әйтмешли, «җүләр балык» булганнардыр. Бик эре булмасалар да, көненә малай башына җитмеш-сиксән балык эләгәдер иде. Үзләре бер генә сорт та түгел бит тагын: ташбаш, бәртәч, шыртлака дигәннәре дә бар һәм булалар иде. Ул инде чуртанны сөйләгән дә юк: кармакны карамыйрак торсаң, кармакка эләккән ваграк балыкны йотып, өстәвенә ул да эләгеп чыга. Безнең кармакларны санга санамый торган «тәкәббер» балык – авыл теле буенча «жумба» дип йөртелә торган кечкенәрәк сом балыклары гына була торган иде. Балыкны тотуын тоту, анысы бик читен эш түгел, анысын тотып була, су буенда балыкны арчып, кырып, эшен бетереп, чистартып та алып менәбез. Ләкин анда менгәннән соң читенлекләр туа. Бабай, без аның улларына «Садыйк абзый» дип йөри торган олы улы – һәр икесе дә балыкны тоту, сөзү һәм табада шатырдатып куырып ашауны бик ярата торган кешеләр булсалар да, әби, аларның киресенчә, балыкның исен дә яратмый торган киребеткән бер халык иде. Бабай, старшина булганлыктан, күп вакыт волостьта эштә була. Садыйк абзыйның сүзен әби тыңламый, шул сәбәптән әби балык пешерергә бер аягы сынган өчаяктан башка савытны безгә бирми иде. Шул сәбәптән без, шул өчаякны су буена алып төшеп, учак ясап, балыкны суда гына пешереп ашыйдыр идек, янына бәрәңге дә турап салгач, яхшы гына, тәмле генә булып китәдер иде.
Шулай күңелле генә, тыныч кына яшәгәндә, кинәттән гадәттән тыш бер вакыйга булып алды. Көннәрнең берендә миңа Казаннан әтиләрдән шактый гына күп тәмле күчтәнәчләр килде. Тәмле күчтәнәчне шатланып ашап утырганда гына, минем ике сеңлемнең бер көндә, бер энемнең икенче көндә кызамык белән авырып үлеп, минем ялгызым гына калганлыкны әйттеләр. Казанда булган булсам, ихтимал, мин дә шул авыру белән ычкынган булыр идем. Бу хәбәрне ишетеп, туганнарымны кызганып бик еласам да, соңыннан тагы ияләндем. Шулай итеп, җыенга кадәр мин авылда калдым. Җыенга кадәр вакыт балык тоту, такыр басуга чыгып, Урыс капкасы, Кирәмән тавы (Кирәмәт тавы дигән сүздән үзгәртелгән булырга кирәк) буйларыннан җир җиләкләре җыеп, көненә дүртәр-бишәр тапкыр сулар коенып йөри торгач, бик тиз узды да китте.
Менә берзаман җыен җитте. Пар ат җигеп, кыңгыраулар тагып, әтиләрне җыенга алмага Казанга киттеләр, без дә малайлар белән утырып, басу капкасыннан чыкканчы атка утырып бардык.
Ике көн үтте, кече атна көн кичкә таба урам яңгыратып кыңгырау таккан пар атлар белән чит авыллардан кунаклар килә башлады. Без, басу капкасы янында саклап торып, җыенга килүчеләргә капка ачып кертәбез, алар безгә кәнфитләр, кызыл билле прәннекләр чәчәләр, без талаша-сугыша җыябыз. Менә берзаман әллә каян, тузаннар туздырып, узыштан, тройка ат, повозкалардан, Казанның Проломный13 урамындагы зур магазин хуҗасы Газиев Сәгъди белән шул ук Казанда җиде-сигез кеше яллап тегү тектерүче, камчат һәм кама мехлар белән сату итүче (Каюм Насыйриның бер китабында күргән идем шикелле), «Әсәт Валлаһи тегүче» дип вывескалар куйдырган Әсәдулла агай да үзенең кәнфит, кәләвә күп ашаганлыктан тешләре череп, кортлап, коелып беткән Лотфулла атлы улын утыртып кайтып җиттеләр. Алар кайтып җитү белән, басу капкасы төбендәге малайлар да су сипкән шикелле булды, беркем дә калмады, барысы да повозкалар артыннан йөгерделәр. Алар киткәч, берүзем генә мин нишлим, аның өстенә аларны кәнфит, прәннекне дә бик күп бирә, авылдагы барлык малайларга кәләпүш тә өләшәләр, дияләр. Һәм ул чыннан да шулай булды, бер уч кәнфит, прәннек белән читенә ак мишура ука

тоткан чуклы яшел миткальдән эшләнгән, башка чап итеп ябышып ята торган бер яшел миткаль кәләпүш миңа да эләкте. Алай гына да түгел, минем үзеннән камчат-кама алып эшли торган камчатчы Галиәкбәр малае икәнне белгәч, кәнфит, прәннекләр миңа башкаларга караганда мулрак эләкте. Аннан Газиев Сәгъдиләр кайткан өйгә йөгердек, ул да буш итмәде: кызыл билле прәннек, кәнфит, чикләвекләр бирде. Малайларның түбәләре күккә тиде. Барлыгы да Казанның Печән базары мәчетенең14 гөмбәзенә охшаган чуклы яшел кәләпүшләрдән урам буенча йөгергәләп йөри башладылар. Алардан кала икенче һәм өченче сорт кунакларга басу капкасы ачарга чыгучы малайлар шактый азайган иде. Миңа басу капкасы төбендә озак көтәргә туры килмәде, теге тройкалы повозкалар артыннан озакламыйча кайтып җитүчеләр голова Хәйбулланың (авылда волость старшинасына «голова» диләр иде) яхшы, таза контор (волость идарәсе) атларына утырып кайтучы этиләр булды. Мин инде, этиләрне каршы алырга дип басу капкасыннан чыгып, Казан юлы белән бер-ике җир буе каршы да барган идем. Менә берзаман этиләр күренде, алар да мине күрделәр. Атларны туктатып, мине тарантаска менгереп утырттылар, малайларга дигән кәнфит, прәннектән бер учны миңа тоттырдылар, өстәвенә басу капкасы ачарга чыккан малайларга да кәнфит, прәннекләрне мин чәчтем. Һи күңелле дә була икән соң прәннек чәчү! Һич сөйләп бетерерлек түгел!..

Габдулла тукай турында истәлекләр

1905 ел ахырларында Уральск шәһәрендә Камил Мотыйгый тарафыннан «Фикер» гәзитәсе, 1906 ел башында «Әлгасрелҗәдид» журналы чыгарыла башлагач, шул гәзитә һәм журналларда Г.Тукай имзасы белән җитмеш-сиксән проценты гарәпчә-төрекчә, калганы татарча сүзләрдән төзелгән шигырьләр басылып чыга башлады. Ул чакларда яңа темаларда, бик саф булмаса да, татарча язылган шигырьләр булмаганлыктан, Тукайның шигырьләре бик тиз күзгә бәрелде. Мин шул килгән гәзитә һәм журналлардан Тукайның язган шигырьләрен эзләп барып укый башладым. Шигырьләрен укыган саен, үз алдымда аның үземчә булган кыяфәтен дә күз алдымда гәүдәләндерә бара идем. Ул минем уемда ни өчендер солидный гәүдәле бер кеше булып урнашкан иде.

Шуннан, бераз вакытлар үтеп, 1907 елның көзе җитте. Ул вакытта мин Һ.Максудиның «Йолдыз» гәзитәсендә секретарь булып эшлидер идем.

Көннәрнең берендә кечкенә генә гәүдәле, өстенә, «абыйсының бишмәтен кигән» дигән шикелле, иңбашлары төшеп тора торган кием кигән, бер күзенә бераз ак та төшкән, җонсыз-төксез, өтек кенә бер малай редакциягә керде дә, тәкәллефсез-нисез генә редактор өстәле янындагы урындыкка утырып, өстәл өстендәге гәзитәләрне дә актара башлады. Малайның болай үзсенеп китүенә минем җаным кытыкланып китте дә, мин, әлбәттә, бик матур итеп булмагандыр инде, борылып карадым.

Малай, мин уйлаганча ук, аңгыра авыл малае булып чыкмады. Минем нинди күз белән караганымны сизенеп алды да:

– Һади әфәнде тиз килерме икән? – дип сүз башлады.

Аның теленең авыл малаеныкы шикелле булмавын, шактый гына шомалыгын ишетеп, баштагы фикеремне үзгәртеп, «атасының йомышы белән килгән берәр мәхдүм кисәге булырга кирәк» дип уйладым. Һ.Максуди голяма (мулла-мунтагай) нәселеннән булганга һәм үзе дә хәтме көтеб кыйлган кешеләрдән булганга, редакцияне зиярәт итүчеләрнең күбрәге шундый голямалар буладыр иде. Шул уйга килгәнлектән, мөхәррирнең килер вакыты җиткәнен әйттем. Бераз утыргач, мәхдүм, тагы сүз башлап:

– Безнең гәзитә-журналлар сезгә килә торгандыр бит? – диде.

– Сезнең нинди гәзитә?

– «Фикер», «Әлгасрелҗәдид», «Уклар».

Мәхдүмгә минем караш бөтенләй башкарды:

– Сез Уральскиданмыни?

– Ие.

– Алай булгач, сез анда гәзитә-журналларда шигырьләр яза торган Габдулла Тукайны да бик яхшы белә торгансыздыр?

Малай елмайды да:

– Ул Апуш мин булам, – дип әйтмәсенме.

Солидный гәүдәле Тукай турында исәпләп йөргән миңа аның бу сүзе бик начар тәэсир итте. Ирексездән гарәпнең «Төсмегы бил Мөгайди, хәйрен мин эн тәраһе» («Мөгайди турында ишетүең аны күрүеңнән хәерлерәк») дигән мәкале уемнан узып китте. Шулай да бу яңа Тукай белән бик тиз үзләшеп алдым. Үзе әйткәнчә, Апуш булмагае чорт булсын, миңа Тукай кирәк иде.

Шушы очрашудан соң ул, солдатка каралырга дип, авылга кайтып китте.

Иң кирәкле уң күзенә ак төшкән, ундүрт-унбиш яшьлек малай кадәр гәүдәле, солдат мылтыгын урыныннан кузгатып та күтәрә алмаслык балалар беләге күк нечкә беләкле малайны солдатка кем алсын соң?

Тукай авылында озак тормады, Казанга бик тиз әйләнеп килде. Ләкин инде «Йолдыз» тирәсенә килмәде.

Авылдан килгәч, Тукай бераз вакыт Шәрәфләргә[1] – «Мәгариф» көтебханәсенә саткан шигырьләреннән алган гонорары белән җан асрап килә.

Шуннан озак та үтми, либераль буржуа фикерле шәкертләр тарафыннан «мәдрәсәләрне ислях итү» лозунгысы белән эш күрә торган оешма төзелеп, аның тарафыннан «Әлислах» гәзитәсе чыга башлагач, Тукай шунда җиң сызганып эшләргә тотынды. Ләкин ярлы оешманың барлы-юклы гына акчасына чыгарыла торган «Әлислах»тан алган чирек-чорык гонорарлар гына Тукайның тормышын тәэмин итә алмыйлар. Шул вакытларда шул ук яшьләр тарафыннан «Китап» исемендә бер нәшрият ширкәте төзелеп, алар Московский урамында «Московские номера»да[2] кечкенә бер бүлмә алалар да, Тукайны шунда урнаштырып, аена егерме биш сум айлык белән экспедитор итеп куялар. Ул анда корректуралар да карый, посылкаларны да тегә, борын очларын тирләтә-тирләтә, почтага посылкалар да ташыйдыр иде. Тукайның аның ни хикмәттәндер, аз гына күтәрсә дә, бераз гына «төшереп» алса да, <...> хәзер борын очы тирлидер иде.

Яшьләрнең ул экспедицияләре дә озак гомерле булмады, таралды. Ул таралган вакытларда Фатих Әмирхан, Кабан күле тарлавыгында Ботаника бакчасы[3] каршындагы йорттан бер дача алып, редакциясен дә шунда күчерде, редакция белән бергә Тукай да шунда күчте. Тукайның үзенчә бик «рәхәтләнеп», үзе дигәнчә яшәгән вакыты шул дачада торган вакыты булды. Ул анда яланаяк, яланбаш, күлмәк-ыштаннан гына, тирләп-пешеп, ду күчереп, малайлар белән кузна уйный, бер сукканда берьюлы бер, ике, өч пар кузнаны аударса, нәкъ балалар шикелле шатланып, рәхәтләнеп шаркылдап көлә, җиң очы белән борынының тирләрен сөртеп ала иде. Бу вакытларда инде аның доходлары да арта башлаган, китаплары да ешрак чыга, гәзитәдән дә аз-маз төшем килә; аның димләве буенча мин чыгара башлаган «Яшен» журналында да эшләп, шуны сатудан килгән акчаны аның белән уртаклап бүлешәбез.

[...]

Г.Тукайның характерын сөйләгәндә, аның кайбер үзенә генә баекланган берничә төрле кызыклы табигатьләреннән берничәсен язып китәм. Г.Тукайның иң тарсынганы хатын-кыз җәмгыятендә була иде. Үзләренең шагыйрьләрен күрер, аның белән күрешү өчен читтән килгән хатын-кыз җәмәгатеннән берәрсе бүлмәсенә килеп керсә, Тукай, билгеле, «кермәгез» дип әйтә алмый, ләкин керү моментыннан башлап аның борыны тирли башлый, чыгып киткәнчегә кадәр тәмам шапырма тиргә төшәдер иде. Алар белән никадәр мөмкин булса, шулкадәр аз сөйләп, аларны тизрәк озату ягын карый, алар чыгып киткәч, өстеннән бик авыр бер йөк төшкән шикелле булып, иркен сулу алып, тирләрен сөртәдер иде.

Ничә ел бергә эшләп тә, мин Тукайны бер мәртәбә дә өйгә кунакка алып бара алмадым. Чакырган саен: «Нигә кирәге бар, сыйлыйсың бик килә икән, монда да сыйларга мөмкин. Анда синең хатының бар. Монда гына берәр порция котлет алдырасың да, шуның белән закускалыйбыз да, эше тәмам була да китә», – дидер иде.
Берничә тапкыр авылга кайтып килүләрен исәпләмәгәндә, Тукай, Казанга килеп тора башлаганнан башлап үлгәнчегә чаклы, бары өч тапкыр Казаннан читкә чыгып йөреп кайтты.
Берсесе – «Яшен» журналы чыккан вакытларда, мин күп димли торгач, минем белән Мәкәрҗәгә барып кайтты. Анда барып, Тимерша Соловьевның «Двухсветный» гостиницасына төштек.
Барган чагында яхшы гына дәрт белән барган Тукайның, барып керү белән үк ярмаркадагы ыгы-зыгыны күреп, ихласы кайтты. Бертуктаусыз йөреп тора торган извозчикларның тыгызлыгы, Казанда ерактан ат килгәнне күрсә дә, урам аркылы чыкмый торган Тукай өчен атларның болай күп йөрүләре уңайсызлады. Тукай бары тик кичен, ямщикләрнең йөрүләре басылгач, «Сәйяр» труппасының артистлары Кариевлар спектакль куя торган «Фо-ля-Бержер» бакчасына гына барып кайткалады.
«Сәйяр»ның эшләре бик шәптән түгел, театр арендасы бик кыйммәт – артистлар файдасына төшем калмый, шуңар күрә ачлар. Артистларның хәлен бик яхшы аңлаган Т.Соловьев, шуннан файдаланып, бер комбинация уйлап чыгара: әгәр дә эстрадага чыгып җырласагыз, сезгә обед белән ужин бесплатно, ди. Артистлар бу шартларга бик тиз күнәләр. Бу хәбәрне ишеткән Тукайның да, Уральскида Кариевлар белән ясаган әдәбият кичәләре исенә төшеп, дәрте кузгалып китә. Монда да шундагы кебек уңышлар казануны уйлап, Тукай җилкенә, артистларга программа төзеп бирә. Репетицияләр дә ясала. Соловьев, борадәран Кәримевләрдән4 фәсләр алдырып, шуларны артистларга киертеп, сәхнәгә дә чыгара. Тукай халыкка арты белән торып дирижерлык итә, ләкин – һәйһат! – «муаффәкыять»нең исе дә юк, хорны тыңлаучылар булган шикелле, шаулап утыручылар да, кайнар су китерергә кушып чәйнек шалтыратучылар да бар! Сәүдәгәрләрнең бу илтифатсызлыкларына Тукайның бик хәтере кала. Эшнең шулай булачагын алдан әйтеп төшендермәгән өчен, миңа бик нык үпкәли. Шуннан, Мәкәрҗәдән аның ихласы кайтып, без кайтып китәбез. Казанга кайтканнан соң да, озак вакытларга кадәр миңа үпкәсе язылмый, урыны чыккан саен белдерә бара.
Шулай да инде без килештек. «Яшен»не дә чыгарабыз. Шул вакытларда Казан циркына Карәхмәт дигән бер көрәшче килә. Казан мөселманнарының милли, дини рухлары кузгала. Мин, шуннан файдаланып, Тукайдан «Яшен» өчен берәр нәрсә язуын сорыйм. Тукай риза булып кала. Бер-ике көн узгач, Тукайдан язып-язмаганлыгын сорыйм. Тукай «Кисекбаш, яки Печән базары» дип бер нәрсә яза башлаганын, ләкин аның озынга киткәнен сөйли. Бер-ике көннән язып бетерә. Шул вакыт Тукай янына Г.Шәрәф керә, ул аңарга аны укып та чыга һәм аңарга сатып та куя, мин авыз күтәреп калам. Шәрәф аны бик кызу тотып бастырып та чыгара, һәм китап тиз арада сатылып та бетә. Кызулык белән язылып ташланган бу китап Тукайның күңелендә зур курку да тудыра. Менә Карәхмәт ачуланып килеп керер дә юан беләкләре, чиктән тыш зур йодрыклары белән үзен бифштекс ясап тетеп ташлар шикелле тоела. Цирк Казаннан киткәнче, Тукайның җаны уч төбендә генә тора, цирк киткәч кенә тынычлана.
Тукайның Казаннан икенче чыгуы аның Сембер губернасындагы фабрикант Акчуриннарга кунакка баруы була. Ул фабрикант Хәсән Акчурин, мөселманча зур укымышлы кешеләрдән саналып, яңа әдәбиятны да сөючеләрдән булганга, Тукайның шигырьләрен укый һәм аның үзен дә күрәсе килә. Казандагы дусларына Тукайны кунакка җибәрүләрен сорап хат яза һәм акча да җибәрә. Алар, Тукайның үзенә акча мәсьәләсен белдермичә, Тукайны барырга күндереп, аны баштанаяк киендереп озаталар. Тукай бик зур кунак булып кайта.

Тукайның кайтканын ишеткәч, мин аның янына менәм, ни күзем белән күрим, өстеннән яхшы киемнәрен, ак якаларын салып ыргыткан да эчке күлмәктән генә караватына сузылып яткан.
– Нихәл, бик шәп йөреп кайттыңмы, бик шәп сыйладылармы? – дигән сорауга каршы Тукай:
– Сыйлавын шартлаганчы сыйладылар, шулай да үземнең караватымны сагынып кайттым әле, безгә кул кешеләр түгелләр алар, әллә ничә горничный нәнкә шикелле ашаталар, нәнкә шикелле эчертәләр, нәнкә шикелле йоклаталар, үзең теләгәнчә йокларга ирек тә юк. Сыйлары да гел коньяк та шампанский, безнең шикелле кара корсакка кул нәрсәләрмени алар, – диде, ник барганына үкенгән көнгә төшкәнлеген белдерде.
Тукайның Казаннан читкә чыгуының өченчесе аның Троицк ягына кымызга китүе булды. «Яшен» туктагач, ул «Юл» көтебханәсе ияләреннән Әхмәт Урманчиев тарафыннан чыгарыла торган «Ялт-йолт» журналында берьялгызы эшли, мин тик ташка төшерү өчен карикатуралар гына эшләп бирә идем. Бу эш 1912 ел ахырларына кадәр барды.
1912 ел ахырына таба «Йолдыз» идарәсе, Балкан сугышы5 хакында хәбәрләр язып торыр өчен, мине Истанбулга җибәрде. Шунда мин нерва авыруы белән авырый башлап, 1913 елның февралендә Казанга кайтып атна-ун көн йөргәннән соң, бөтенләй аяк-кулдан калып, февраль ахырында нерва авырулары клиникасына кердем. Тукайны актык күрүләрем шул вакытларда булды. Тукай бөтенләй ябыккан, хәлсезләнгән иде. Күп тә үтмәде, Тукайны да Клячкин больницасына6 урнаштырдылар. Шуннан соң «Кояш» гәзитәсендә «Авыруларыбыз» дип яза баралар, мин Тукайның хәлен шул гәзитәдән укып һәм хәлемне белергә килгән кешеләрдән генә ишетеп беләдер идем. 1913 елның искечә 2 апрелендә Тукай үлә, ә мин, аяк-куллар тотмаган, күзләр дә күрмәгән көйгә, клиникада ятып калам. Ул үлгәннән соң да ел ярым түшәктә ятып терелгәч кенә, Тукайның каберенә барып сәламемне бирәм.
Габдулла Тукай хакында онытылмыйча хәтеремдә калган истәлекләр шуннан гыйбарәт.
Искәрмә һәм аңлатмалар

Г.Камал әсәрләре җыелмасының бу соңгы өченче томында әдипнең хикәяләре, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре һәм истәлек язмалары урын алды. Том әдипнең ике хикәясе белән ачыла. Боларның беренчесе – «Сабир хәзрәт» – әдип иҗатының әле башлангыч дәверендә, 1900 елларда ук язылып, 1903 елда «Сабир хәзрәт яки Гыйбрәт» исеме белән аерым китап булып басылып чыккан. Хикәянең исемендә үк яшь авторның идея-эстетик юнәлеше ачык күренә: хикәя мәгърифәтчелек рухы белән сугарылган. Хикәянең төп герое Сабир хәзрәт үзенең күп яклары белән шул чор мәгърифәтче язучыларының тискәре геройларына охшаган. Ул чиктән ашкан бозык характерлы, үз мәнфәгатен генә кайгыртучы адәм: илле яшенә җитеп егермеләп хатын алган, шуларның өчесе белән тора, калганнарын исә аерган, алардан туган күпсанлы балаларын тәрбияләү турында уйлап та карамый.
Аңа капма-каршы итеп уңай герой Габдулла мулла бирелә. Ул – керсез күңелле, яхшыны яманнан аера белүче, сабыр холыклы, күп укырга яратучы, хуш табигатьле кеше. Әмма бу мәгърифәтчеләргә идеаллаштырып бирелгән уңай герой автор тарафыннан аерым сюжет сызыгында үстерелми, бары тик тискәре геройның начар әхлагын фаш итү өчен эпизодик рәвештә генә китерелә.
Хикәянең финалында, мәгърифәтчелек реализмы әсәрләренең күбесенә хас булганча, үз кызына өйләнергә йөрүче тискәре герой – Сабир хәзрәт фаш ителә. Әмма мәгърифәтчелек реализмы кысаларыннан чыгып киткән бер деталь бар: Сабир хәзрәт фаш ителеп кенә калмый, дөрес юлга да иңдерелә; мал-дәүләтен мәчет һәм мәдрәсәгә тапшырып, хатыннарын аерып, авылыннан чыгып китә һәм дәрвишкә әйләнә. Хикәянең азагы тулысы белән диярлек урта гасыр романтик прозасындагы гыйбрәтле хикәят алымнарын искә төшерә. Сабир хәзрәт тарафыннан әйтелгән сүз дә моны раслый.

«Сабир хәзрәт...» хикәясендә, сәнгатьчә фикерләү ягыннан XIX йөз мәгърифәтче язучылары белән чагыштырганда, беркадәр алга китеш тә сизелә. Автор тискәре геройның психологиясен ачуга омтылыш ясый. Бигрәк тә Сабир хәзрәтнең Хикмәтулла байдан Мәрзияне сорау күренеше Г.Камал тарафыннан уңышлы тасвирланган.
«Күгәргән алтыннар» (1909) исемле икенче хикәя – авантюр сюжетка корылган, романтизмга тартымрак әсәр. Хикәянең татар җирлегенә яраштырып эшләнгән адаптация, ирекле тәрҗемә булуы да ихтимал (кулъязмасы да, язылу тарихына кагылышлы мәгълүматлар да сакланмаган). Мондый сюжетка корылган комедия, мәсәлән, XIX гасыр уртасы әзәрбәйҗан әдәбиятында очрый (Мирза Ахундовның «Хикәяте мелла Ибраһим Хәлил-кимиягир»е).
Хикәянең сюжет төзелеше һәм сәнгатьчә фикерләү алымнары – романтик әдәбияттан. Сюжет маҗаралы булып, үзәккә «күгәргән алтыннар»ны кулга төшерергә омтылган байның һәм бу эшкә арадашчылык итүче хәзрәтнең эчке кичерешләре куела. Моның өчен автор еш кына табигать күренешләрен тасвирлауга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, хикәянең башында май аеның матур көне, хуш исле һавасы гаять горур һәм кырыс табигатьле хәзрәткә уңай тәэсир ясый, аның күңелен йомшарта, шунлыктан ул газапланмый гына шәкерткә өенә кайтырга рөхсәт бирә, шикле билгесез кешене – «күгәргән алтыннар» тәкъдим итүче анатолияле төрекне өендә кабул итә. (Югыйсә ул өенә аеруча могтәбәр затларны гына аяк бастыра бит!) Хикәянең икенче өлешендәге биш мең алтын белән килергә тиешле төрекләрне көтү картинасы, алдым-бирдем вакытындагы байның психологик кичерешләре дә табигать күренешләре ярдәмендә ассызыклана. Аның «күгәргән алтыннар» кулга керер алдыннан төш юратулары, борчылуы, вәсвәсәләнүе кара болытлы, яшенле күк күкрәү фонында бирелә. Күк күкрәү хикәядә өч мәртәбә гәүдәләнә, һәм ул һәрвакыт геройларның психологик халәтенә туры килә.
Хикәядә романтик контрастларда еш очрый. Мәсәлән, хәзрәтнең «бикәләр кулы шикелле ак вә йомшак куллары» алдакчы төрекнең «күсәк кеби бармаклары, ...щетина мыеклы тупас иреннәре»нә каршы куела. Гаять горур хәзрәт белән гаять түбәнчелекле шәкерт образлары арасында да контрастлык бар.
Хикәянең азагында атның шлеясына тезә торган җиз тәңкәләрне алтын дип саткан көрдләрнең тотылуы, хәбес ителүе әйтелә. Кылган гөнаһ өчен бу рәвешчә җәза бирү – шулай ук мәгърифәтчелек әдәбиятыннан килә торган традиция.
* * *
Томның иң зур өлешен Г.Камалның Октябрь революциясенә кадәрге публицистик чыгышлары, әдәбият-сәнгать тәнкыйте били. Бу аңлашыла да. Әдип – татар вакытлы матбугатында аның иң беренче адымнарыннан алып даими рәвештә эшләп килгән күренекле журналист, редактор, публицист һәм тәнкыйтьче. Катлаулы иҗтимагый шартларда «Казан мөхбире», «Йолдыз» кебек либераль-буржуаз газеталарда үз фикереңне уздыру, «Азат», «Азат халык», «Яшен» һәм «Ялт-йолт» газета һәм журналларын чыгарышу Камалдан һәм аның фикердәшләреннән шәхси батырлык, профессиональ осталык сораган. Газеталарның аерым саннарын конфискацияләү, редакторларны, мәкалә авторларын хөкемгә тарту, газетаны чыгарудан туктату, цензураның аяк чалулары, сүз дә юк, Камалга тоткарлык артыннан тоткарлыкларны алып килеп кенә торган. Әнә шундый кыен шартларда да Камал үз уй-фикерләрен газета һәм журнал аша укучы күңеленә җиткерүнең үтемле ысулларын, чараларын эзләгән һәм тапкан.
Ләкин ул заманнардан бирле күп сулар агу, замандашларының бүгенге көндә инде исән булмаулары, ул чор вакытлы матбугатына караган документлар һәм архив материалларының өлешчә генә саклануы һәм башка шундый хәлләр, кызганычка каршы, әдипнең публицистик эшчәнлеген нечкәләп тикшерергә мөмкинлек бирми (әлегәчә әдипнең тулы фәнни библиографиясе дә төзелмәгән). Ул эшләгән, язышкан периодик басмаларда дистәләрчә мәкалә, рецензия һәм «Кечкенә фельетон»нарның аноним рәвешендә, байтагысы исә яшерен имзалар белән чыгуын да онытмыйк. Болар һәммәсе, билгеле, әдипнең публицистикасын, әдәбият һәм сәнгать тәнкыйтен хәрәкәттә, үсеш-үзгә-

рештә карауны, шулай ук бу томда – бер генә китап мәйданында – мөмкин кадәр тулы һәм дөрес чагылдыруны бермә-бер кыенлаштыра.
Әмма бу Г.Камалны публицист һәм тәнкыйтьче сыйфатында берничек тә бүген бәяләп булмый дигән сүз түгел. Авторлыгы ачык мәгълүм булган, дәлилләнгән мәкалә һәм рецензияләреннән чыгып, татар әдәбияты белгечләре һәм тарихчылар инде байтактан бирле бу турыда үз фикерләрен әйтә киләләр. М.Гали, Х.Хисмәтуллин, Р.Нәфыйгов, Б.Гыйззәт, И.Нуруллин, М.Гайнуллин, М.Мәһдиев, Ш.Хамматов, И.Абдуллин һәм башка галимнәрнең эзләнүләре нәтиҗәсендә, Г.Камал публицистикасы һәм тәнкыйтенең, гомумән алганда, милли рухта булуы, аның Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтев белән охшаш позициядә торып, билгеле дәрәҗәдә, Х.Ямашев кебек социал демократлар йогынтысында да эшләве исбат ителде. Ләкин бу эшчәнлекнең реаль эчтәлегенә килгәндә, аңа әле генә күрсәтелгән төп тенденцияләрдән тыш катлаулылык һәм тигезсезлек тә хас булуын әйтергә кирәк.
Г.Камалның беренче мәкаләләре 1905 елның ахырларында либераль буржуа органы – «Казан мөхбире» газетасында күренә. Аларда Беренче рус революциясе башланып киткән айлардагы рухи күтәренкелек, уяну-яңару пафосы чагылган. Авторны бигрәк тә татар хатын-кызларының иҗтимагый хәле борчый, ул аларны йокыдан уяныргa чакыра, бу хәлдән чыгу юлын да күрсәтә: ул – уку, мәгърифәтле, һөнәрле булу. Кемгә дә булса ышанып ятмаска, үзең тырышырга, хөрриятгән файдаланырга кирәк, ди ул, югыйсә бит «егъламаган балага имчәк бирмиләр». Иң мөһиме, автор, хөкүмәткә «ышанып бетмик, үзебезне алдатмыйк» дип, шактый кискен сүзләр дә әйтә. Бераздан аның «Казан мөхбире» редакциясендәге хәлләрдән риза булмый китүенә әнә шундый уй-фикерләрнең үсә, демократизмының тирәнәя баруы да сәбәпче булгандыр дип уйларга кирәк.
Озак та үтмәстән, ул Габдулла Апанаев белән бергәләп «Азат» исемле газета чыгару эшенә алына. Ике наширнең берсе (Г.Апанаев) уңгарак тартуы аркасында, газетаның һәрбер номеры демократик фикер белән үтәли сугарылып чыкмаса да, ул татар демократик матбугатының формалашу һәм ныгуында зур роль уйнады.
Кызганычка каршы, бу газета әдәбият һәм матбугатыбыз тарихын өйрәнүчеләр тарафыннан җентекләп тикшерелде дип әйтеп булмый әле. Шуңа күрә андагы байтак кына мәкалә һәм язмаларның авторлыгы мәсьәләсе бүгенгәчә хәл ителми кала бирә.
Г.Камал, бу газетаның нашире буларак, анда Г.Коләхмәтев, М.Корбангалиев кебек язучы һәм зыялыларга чыгыш ясарга мөмкинлек тудырган гына түгел, үзе дә «Г.Къ», «Зәйнәп К-ва», «З.Г-ва», «Саиб», «Һади» имзалары белән мәкаләләрен бастырып килгән. Аның мәкаләләре башка имзалар яисә аноним рәвештә дә чыгуы ихтимал. Мәсәлән, «Азат»ның 7 февраль (3) санындагы баш мәкалә үз кулы белән язылуын Г.Камал соңрак матбугатта да әйтеп узды. Кыскасы, Г.Камалныкы дип танылган унбишләп мәкаләгә генә нигезләнеп, аның «Азат»тагы публицистик эшчәнлеген нечкәләп күзәтү кыен. Шулай да кайбер яклары төсмерләнә.
Г.Камал халык мәнфәгатьләрен һәрвакыт күз алдында тотып эш итә, милләттәшләрен гыйлем-мәгърифәткә чакыру белән чикләнмәстән, чорының иҗтимагый каршылыкларын да күрә башлый. Ул, мәсәлән, властьларның башбаштаклыгын фаш итәрлек берәр төрле вакыйганы хикәяләп бирү алымын уңышлы куллана. «Әтраф хәбәрләре», «Крәстияннәр һәм Дума», «Бер каз өчен тәртипсезлекләр» исемле язмаларда китерелгән вакыйгалар үзләре үк, автор шәрех-аңлатмасыннан тыш та, чынбарлыктагы гаделсезлек күренешләренә укучы игътибарын юнәлтәләр.
Г.Камалның публицистик сөйләмендә вакыт-вакыт Россия тарихына караган фактлар, чит илләр тормышына бәйле детальләр урын ала, ләкин әсәргә алар бүгенгегә мөнәсәбәтле яклары белән килеп керәләр. «Кнәзләр заманында истикъляль», «Казан, 9 февраль» исемле язмаларда рус тарихына мөрәҗәгать итеп, ул урта гасырларда халыкның берара князьләрне сайлап куюы, аннан соң бу гадәтнең бетерелүе, крепостной крестьян сораганның тормышка ашмавы, халыкның хокуксыз булып калуы хакында сөйли һәм патша Россиясендәге бүгенге тигезсезлеккә, хокуксызлыкка ишарәли.

Г.Камалны иң борчыган нәрсә – татар халкының артталыгы. Бу хәлдән котылуда Дәүләт Думасына зур гына өмет баглаган автор депутатлыкка мөселманнардан вәкилләрне күбрәк сайлауны да яклый – бу урында Камал аңында конституцион иллюзияләр дә әле бетеп җитмәгәнлеге чагыла. Ләкин әдип моның белән генә чикләнеп калмый. Аның «Азат»тагы мәкаләләре халык көченә ышану, халык теләкләрен тормышка ашыру белән сугарылган. Ул артталыкка наданлык, милли изелү, шулай ук «тамак һәм корсак хәсрәте», кайбер имамнар, хәзрәтләр гаепле итеп саный, татарларның тартыша, активлаша башлауларын күрә, хаклык өскә чыгасына ышаныч белдерә.
Үзенең мәкаләләрендә әнә шундый демократик карашларны алга сөргән Камал белән мулла Габдулла Апанаев арасында каршылыклар барлыкка килә, бераздан Г.Апанаев газетаның материаль ягын тәэмин итүдән баш тарта. Ләкин Камал аптырап калмый: «Азат» урынына үз наширлегендә «Азат халык» исемле газета чыгара башлый. Патша самодержавиесе революцион хәрәкәткә каршы һөҗүмен, репрессияләрен көчәйтә барган шартларда ул, билгеле, озын гомерле була алмый, унбиш саны чыккач та туктатыла.
Бу газетада да күпчелек материаллар имзасыз яки яшерен имза белән дөнья күргән. Аларның шактый өлеше, әлбәттә, Г.Камалның үз кулы белән язылган булырга тиеш, – моны кайбер фактларга таянып та дәлилләргә мөмкин. Бер генә мисал китерик. «Азат халык»ның уникенче саны бер атна соңарып чыга, редакция исә моны мөхәррирнең (Г.Камалның) Нижний Новгородка «Иттифакы мөслимин»нең III съездына хәбәрче сыйфатында баруы, Казанда булмавы белән аңлата. Шулай булгач, газетаның уникенче, унөченче, ундүртенче, унбишенче саннарында чыккан, әлеге съездның барышын яктырткан «Мөселманнарның өченче җыелышы» исемле зур мәкаләнең авторы итеп Г.Камалны танырга тиеш булабыз.
1906 елның сентябреннән башлап Г.Камал «Йолдыз» газетасының мөдир һәм сәркатибе (секретаре) булып эшли башлый. Сул фикерле матбугат мәйданыннан либераль-буржуаз газетага күчүе ул заманның алдынгы карашлы эшлеклеләрендә (мәсәлән, Г.Тукайда) гаҗәпләнү һәм тискәре тойгылар да тудырган, бу аларга демократик позициядән читләшү булып күренгән. Хәлбуки реакциянең революцион-демократик матбугатка һөҗүме көчәйгәннән-көчәя барган шартларда бу күчү Г.Камалга актив журналистлык эшчәнлеген дәвам иттерергә мөмкинлек биргән! Һәм, әйтергә кирәк, әдип «Азат» һәм «Азат халык»та ачык чагылган идея принципларына «Йолдыз» чорында да тугрылыклы булып кала. Дөрес, бу елларда Г.Камалның вакытлы матбугаттагы эшчәнлегенең характеры күпмедер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерүе дә мәгълүм. Мәсәлән, аның иҗатында сатирик алымнарның урыны сизелерлек арта, «Кечкенә фельетон» исеме астында басылган мәкаләләре еш күренә. Аларда ул Дәүләт Думасына депутатлыкка сайланырга омтылучы буржуаз эшлеклеләрне, кайбер руханиларның шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүләрен, Ишми кебекләрнең кыйланышларын, милли матбугаттагы тискәре күренешләрне оста тәнкыйть итә.
Демократик карашларыннан чигенмәвен тагын бер нәрсәдә ачык күрәбез: «Йолдыз»да эшли башлаган айларда ук Г.Камал махсус сатирик журнал чыгару уена килә. 1907 елның гыйнварында ул «Йолдыз»дагы кайбер мәкаләләрен «Яшенче» имзасы белән бастыра. Шулай да бу теләкнең тормышка ашуы юлында шактый зур киртәләр торган, күрәсең. Бары тик 1908 елның августында гына «Яшен» журналы Г.Камал наширлегендә, Г.Тукай һәм Ф.Әмирханнар ярдәме белән чыга башлый. Унынчы саны чыккач та туктатылып, озак яши алмаса да, ул кыска гына вакыт эчендә үзен демократик идеаллар өчен кыю көрәшүче басма итеп танытып өлгерә. «Яшенче» (Г.Камал) журналда «Тел берләштерәләр», «Тәмсилләр» кебек үткен фельетоннары, күпсанлы карикатуралары белән катнаша. Әйе, Г.Камал талантының тагын бер ягы – сәләтле рәссам булуы ачыла. Кайбер замандашларының әйтүенчә, бу журналда һәм ул тукталгач чыга башлаган «Ялт-йолт» сатирик журналында Г.Камал кулы белән ясалган бихисап карикатура дөнья күргән.
Үзенең комедия һәм драмалары белән татар реалистик драматургиясенә һәм татар театрына нигез салган Г.Камал шул ук вакытта әдәбият-сәнгать тәнкыйтен

тудыручыларның берсе булып тора. Аның күпчелек рецензияләре сәхнә әдәбиятын, аерым татар театр труппалары уенын (аеруча «Сәйяр»нең) анализлауга багышланган. Театр ул чор татар дөньясында әле яңа гына яши башлаган сәнгать төре буларак һәрьяктан да игътибарлы карашка лаек иде. Шунлыктан Г.Камал бу өлкәдәге кечкенә генә уңышларга да шатлана, кимчелекләренә сызлана. Ул Г.Коләхмәтевнең «Яшь гомер»ен, Ф.Әмирханның «Яшьләр»ен, И.Багдановның «Помада мәсьәләсе»н уңай яктан бәяли, ә Я.Вәлинең «Ачлык кушты» исемле пьесасы кебекләрне тәнкыйть итә. Артистларның уеннарына бәя биргәндә дә, чынбарлык хәлләре белән чагыштырып карау һәм сәхнә таләпләрен, законнарын яхшы белү нәтиҗәсендә, спектакльләрнең тамашачылар тарафыннан кабул ителү-ителмәү сәбәпләрен ул дөрес билгели.

«Йолдыз» газетасы битләрендә Г.Камал әдәбият тәнкыйтьчесе сыйфатында да еш күренә. Аның «Яңа әсәрләр», «Яңа китаплар» бүлекләрендә басылган рецензияләренең саны дистәләрчә. Ул, мәсәлән, беренчеләрдән булып Г.Тукай әсәрләрен шатланып каршы ала, «Габдулла Тукаев шигырьләре» (Казан, 1907), «Алтын әтәч!» (Казан, 1909) исемле китаплары хакында дәлилле сүзен әйтә.

«Мирза кызы Фатима» (Ф.Кәрими), «Җир йөзе» (Г.Рәхим), «Хисап мәсьәләләре» (М.Корбангалиев), «Гыйльме әшья» (Х.Фәйзи), шулай ук рус, төрек һәм башка телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар турындагы рецензияләрендә Г.Камалның укучы ихтыяҗын канәгатьләндерерлек басмаларны таный, файдалы якларын, җитешсезлекләрен күрә һәм күрсәтә белүе ачык сизелә.

Атнасына өч мәртәбә чыгып килгән «Йолдыз»ны ышанычлы хәбәрләр, кызыклы мәкаләләр белән тәэмин итү җиңел генә бармаган. Шуңа күрә булса кирәк, газетаның мөдире һәм сәркатибе (кайвакытларда ул вакытлы редактор да) Г.Камал берничә мәртәбә Нижний Новгородка юнәлә. Аннан җибәргән язмаларында ул Мәкәрҗә ярминкәсендәге хәлләрне шактый нечкәләп тасвирлый, чит җирләрдән китерелгән товарларның бәһаләрен хәбәр итү белән генә чикләнми, бәлки төрле милләт кешеләренең үз-үзләрен тотышларына, яшәү һәм аралашу рәвешләренә, ярминкәдәге «культура» тормышына да игътибар итә. 1907 елның августында ул, мәсәлән, халыкның бик юашлыгын, «сәясәттән бәхәс кыйлган» кешеләр күренмәвен яза, ярминкәгә мөфти тарафыннан имам итеп җибәрелгән Сафиулла хәзрәт мәчеттә хотбә укыганда халыкның йоклавыннан, кайбер кешеләрнең «мәчет салырга дип акча җыеп йөрү»ләреннән көлә. «Мәктәп салып балаларны укыту кайгысында булганнары һич күренмидер», – ди Г.Камал, ачынып.

1912–1913 елгы Балкан сугышы чорында Төркия вә Болгария мәмләкәтләренә сәяхәткә киткән Г.Камалның «Йолдыз» газетасында унбишләп язмасы басылып чыккан. Боларда төп урынны Төркиядәге иҗтимагый тормыш хәлләре белән танышудан алган тәэсирләр били.

* * *

Г.Ибраһимов, М.Гафурилар кебек, Г.Камал да Октябрь революциясен берсүзсез, һичнинди икеләнүсез кабул итте һәм үзенең каләмен татар совет вакытлы матбугатының беренче адымнары белән тыгыз бәйләде. Гражданнар сугышы елларында эшче-крестьяннарны, кызыл армиялеләрне революция өчен изге көрәшкә рухландыруда большевистик татар газеталары, аеруча «Эш» зур эш башкарган икән, моңа Г.Камалның да көче күп кергән. «Кайвакыт мин бөтен редакциядә берүзем утырып калам. Редактор да, секретарь да, корректор да, экспедитор да үзем булам, кирәк була икән, курьер да булам, икешәр-өчәр көн өйгә кунарга кайтмыйча, көне-төне шунда эшләп уздырам», – дип язды Г.Камал бу еллардагы эшчәнлеге турында. Әледән-әле публицистик һәм сатирик шигырь, декламация һәм мәкаләләр язып-бастырып та торган ул, драматургик иҗатын да туктатмый дәвам иткән, татар совет театры һәм эстрадасының туу һәм формалашуында да башлап йөрүчеләр рәтендә булган.

Журналистлык эшеннән Г.Камал узган гасырның егерменче елларында да аерылмый. Бу чорда аның иң дәвамлы хезмәт урыны – «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе. Ул эшнең зурысын кечкенәсеннән аермыйча эшли, сәламәтлеге какшауга карамастан, булган

бар көч һәм сәләтен матбугат сүзенең җегәре артуга, пропаганда һәм агитация вазифасын мөмкин кадәр уңышлы үтәвенә җигә. 1923 елның язында, нәкъ менә совет матбугаты көнендә, Г.Камалга «Хезмәт батыры» дигән мактаулы исем бирелгән икән, бу аның драматургия һәм театр өлкәсендәге хезмәтләрен олылау гына түгел, бәлки журналист һәм публицист буларак күп еллар буе нәтиҗәле эшләп килүен дә тану иде.
Том Г.Камалның истәлек язмалары белән тәмамлана. Давыллы XX гасыр башы татар иҗтимагый тормышын, Г.Тукай һәм башка кайбер тарихи шәхесләрнең җанлы образларын күз алдына бастырулары белән бу язмалар да чорның кыйммәтле документлары булып саналырга хаклылар.
Зөфәр Рәмиев,
Мәгъсүм Хәбибуллин
Хикәяләр
8 бит.
Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт. 1903 елда «Гыйбрәт» (Казан : Харитонов матбагасы) исемле китапта басылып чыккан. «1900 сәнә, 15 февраль» дип язылу датасы куелган. Камал Г. Әсәрләр: шигырьләр, проза һәм публицистика / төз. М.Гали*. Казан : Татгосиздат, 1951. 2 т.
Текст «Гыйбрәт»тән алынды.

1 Бәнарис – юллы-юллы бизәкле ефәк тукыма (Һиндстандагы Бенарис шәһәре исеменнән алынган).
2 Тамак тун – төлкенең тамак асты тиресеннән эшләнгән кыйммәтле тун; тулы исеме: төлке тамак тун.
3 «Маштан катык» – ирония белән әйтелгән. Маш – борчакның бер төре, вак кына, яшел төстә.
4 Хаҗ – мөселманнарның Согуд Гарәбстанында изге дип исәпләнгән Мәккә шәһәренә, Кәгъбә мәчетенә барып гыйбадәт кыйлулары. Бу – Корбан бәйрәме көннәренә туры китерелә. Хаҗ кылган кеше «хаҗи» дип йөртелә.
5 Хиҗаз – Согуд Гарәбстанындагы Мәккә, Мәдинә шәһәрләре урнашкан өлкә.
6 «Кәлимәтен тайибәтен» – иске мәдрәсәләрдә дәреслек урынында йөргән «Иман шарты»нда әлифбадан соң башлана торган текстның беренче сүзләре. «Яхшы сүз» мәгънәсендә.
7 Зәкят – шәригать кушуы буенча еллык керемнең кырыктан бере күләмендә салынган дини налог.
8 Гошер – иген уңышының уннан бере күләмендә бирелә торган дини налог. Бу налог мәхәллә муллаларына түләнгән.
9 Зәмзәм сулары – Мәккәдә Кәгъбә мәчете ишегалдындагы кое суы. Шифалы дип санап, хаҗга баручылар аны алып кайтканнар. Зәмзәм бик кыйммәтле су булып исәпләнгән.
10 Төрбәи шәриф – Мөхәммәд пигамбәр кабере (төрбәсе). Мәдинә шәһәрендәге бу кабер мөселманнар өчен икенче изге урын булып тора. Мөхәммәд (570 тирәсе – 632) гарәп дөньясында дин һәм дәүләт эшлеклесе, ислам диненә нигез салучы пигамбәр – Алланың җирдәге илчесе дип исәпләнгән.
11 Гар шәриф – хаҗ кылучылар үтә торган изге тау куышы.
12 Гарәфәт – Мәккәдән егерме чакрым ераклыкта хаҗ йоласы үткәрелә торган түгәрәк тау.
13 Ихрам – хаҗ кылучылар бөркәнә торган кием.
14 Раузаи мотаһһәрә – изге кабер (Мөхәммәд пигамбәр кабере).
15 Тисбә (тәсбих) – утыз өч яки туксан тугыз төймәле элмәк. Шуны, Алла исемен әйтеп, берәмләп санаганнар (тартканнар). Әбнүс тисбе – Һиндстанда үсә торган кыйммәтле кара агачтан эшләнгән.
16 Фәхригаләм саллаллаһе галәйһи вәссәлам... – Аллаһы Тәгалә сәламләгән дөнья мактанычы (Мөхәммәд пигамбәрнең эпитеты).

17 Сембер кайтуга ... – автор Сембер ярминкәсеннән кайтуны күздә тотса кирәк. Бу ярминкә һәр елны гыйнвар аенда Сызраньда (элекке Сембер өязе) булган.
18 Пигамбәр сөннәте – Мөхәммәд пигамбәр сүзләре, аның эшләре.
19 «Мөхәммәдия» – XV гасыр төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләби (1451 елда үлгән) тарафыннан язылган көйле шигъри әсәр. Эчтәлеге Мөхәммәд пигамбәр һәм шәригать законнары турында дини-әхлакый үгет-нәсихәттән гыйбарәт. Китап Октябрьгә кадәр татарлар арасында киң таралган булган. Монда шушы китапның көе турында сүз бара.

25 бит.
Күгәргән алтыннар. Беренче тапкыр шул исемдәге китапка кертелгән. (Камал Г. Күгәргән алтыннар. Казан : «Үрнәк» мәтбагасы, 1909. Камал Г. Әсәрләр / кереш сүз авт. Ф.-Сәйфи Казанлы*. Казан : Яңалиф, 1930. 2 т.) Бу басмада әсәрнең текстын искерә төшкән формалардан арындырырга тырышу нык сизелә. Арада автор текстын бозуга илтә торганнары да бар, шунлыктан бу вариантта Г.Камалның үзе турыдан-туры катнашуына шик туа.
Әлеге томга текст беренче басмасыннан (1909) алынды.

1 Икенде – өйләдән соң, кояш баеганчы, урта бер арада укыла торган намаз.
2 «Тәгълимел-мөтәгаллим» – әхлак кагыйдәләре турында гарәп телендә язылган китап. «Укыту ысуллары» дигән мәгънәгә туры килә. Иске мәдрәсәләрдә югары сыйныфларда укылган.
3 Балык базары – хәзерге Тукай мәйданында булган.
Мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр
1905
42 бит.
Кем гаепле? («Казан мөхбире»нең ...) «Казан мөхбире» газетасының 1905 елгы 15 декабрь (13) санында «Зәйнәп Г.К-ва» имзасы белән басылган.
Мәкалә Зөһрә әл-Таһириянең «Казан мөхбире»нең 1905 елгы 28 ноябрь (8) санында басылган «Бәнем фикерем» исемле мәкаләсе уңае белән язылган.
1905 елгы рус революциясе тәэсире белән хатын-кыз азатлыгын яклап язылган бу мәкалә алдынгы хатын-кызларны кузгатып җибәрә. Газета-журнал битләрендә «Хатын-кызлар тавышы», «Хатын-кызлар дөньясы» дигән бүлекләр оештырыла. Бу бүлекләрдә басылган мәкаләләр татар хатын-кызларының патриархаль гаилә шартларыннан котылырга, иҗтимагый тормышка актив катнашырга омтылуларын чагылдыралар.

1 «Алмашыну» – Мәҗит Гафури шигыре, «Казан мөхбире»нең 1905 елгы 24 ноябрь (7) санында «Габделмәҗид Гафури» имзасы белән басылган.
2 ... таякны әлиф дип белмәй ... – Әлиф – гарәп алфавитында беренче хәреф, вертикаль туры сызык (таяк) формасында языла. Шуннан чыгып, надан кеше турында: «Әлифне таяк дип тә белми», – диләр.
3 «Мөсәррәт яки хөррият» – татар публицисты, укытучы, тәрҗемәче Фәхрелбәнат Сөләйманова (Сөләймания 1857 – ?) шигыре, «Казан мөхбире»нең 1905 елгы 21 ноябрь (6) санында басылган.

46 бит.
Кем гаепле? (Хөрмәтле укучыларым!..) «Казан мөхбире»нең 1905 елгы 26 декабрь (16) санында «Зәйнәб Г.К-ва» имзасы белән басылган.
1 1905 елгы революция барышында Казанда төрле оешма эшчеләренең профессиональ союзлары төзелә. Уставларында ирекне тик көрәшү юлы белән генә алып булуы хакында әйтелә. Г.Камал шул профсоюз оешмаларын күздә тоткан булса кирәк.
1906
48 бит.

Кире фикер. «Казан мөхбире»нең 1906 елгы 20 гыйнвар (27) санында «Зәйнәп Г. К-ва» имзасы белән басылган.

1 ... «Казан мөхбире» гәзитәсенең берничә номерларында ... хатыннарга берләшү кирәклеген яхшы гына бәян кыйлганнар иде. – Аерым алганда, мондый мәкаләләр бу газетаның 1905 елгы 28 ноябрь (8), 5, 15, 26 декабрь (10, 13, 16); 1906 елгы 2, 15 гыйнвар (19, 23) саннарында басылган.

50 бит.
3 ноябрь манифесты ни бирә? «Азат» газетасының 1906 елгы 1 февраль (1) санында «З. Г-ва» имзасы белән басылган.

«Азат» – Казанда 1906 елның 1 февраленнән 28 маена кадәр (барысы илле алты сан) чыккан газета. Галиәсгар Камал бу газетаны оештыручылардан һәм аның төп язышучыларыннан берсе булган.

53 бит.
Дума, Дума, Дума. «Азат» газетасының 1906 елгы 1 февраль (1) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.
Россиядә башланып киткән революциядән курыккан патша 1905 елның 17 октябрендә Манифест чыгарырга мәҗбүр була. Анда, аерым алганда, Дәүләт Думасына сайлаулар үткәреләчәге турында әйтелә. Мәкалә шул сайлауларга әзерлек көннәрендә язылган. Хокуклары бик тә чикләнгән I Дума озак яши алмый, патша манифесты белән таратыла. Большевиклар бу Думага бойкот ясарга чакырганнар.

1 ... сайлаучыларны сайларлар. – Дәүләт Думасына депутатлар турыдан-туры сайланмаган. Башта уполномоченныйлар, выборщиклар (сайлаучылар) сайланып, аннары алар Дума депутатларын сайлап куйганнар.
2 Беренче, өченче, дүртенче частьлар ... – Казанның ул чактагы бүленеше буенча татарлар аз яши торган урыннары (шәһәрнең үзәге тирәсе).
3 Икенче, бишенче, алтынчы частьлар ... – Казанның татарлар күбрәк яшәгән Болак һәм Кабан арты, Иске һәм Яңа бистә, Бишбалта һәм Казан елгасы аръягындагы бистәләре.
4 ... шар салган ... – ул чактагы сайлауларда теге яки бу кандидатурага ризалык шар салу юлы белән белдерелгән.
5 ... «Унҗиденче Октябрь» ... партиясе ... – «Союз 17 Октября» – Патша Манифестыннан соң уң карашлы либерал алпавытлар һәм эре сәүдә-сәнәгать әһелләре тарафыннан оештырылган монархистик партия («октябристлар»).
6 «Торгово-промышленный партия» – Сәүдә-промышленность партиясе – эре капиталистлар партиясе. Думага сайлаулар вакытында бу ике партия бердәм хәрәкәт итеп, революцион эшче һәм крестьяннарга каршы чыгалар.
7 А.Т.Соловьев – Казанда 1896–1917 елларда чыккан иҗтимагый-әдәби «Деятель» журналы, 1905–1916 елларда чыккан «Русь православная и самодержавная» газетасының мөхәррире.
8 «Царская-народная партия» – Казан монархистлары партиясе.
9 Профессор Залесский – Залесский В.Ф. (1861–?), Казан дәүләт университеты профессоры.
10 Соколовский – Соколовский А.Я., Казан протоиерее.
11 «Конституционная демократическая партия» – Конституцион-демократик партия (кадетлар), 1905 елның октябрендә барлыкка килгән либераль буржуазия партиясе. Кадетлар конституцион монархияне якладылар.
12 Профессор Шершеневич – Шершеневич Г.Ф., кадет, I Дәүләт Думасы депутаты, Казан дәүләт университеты профессоры.

13 Бать – Бать А.Г., присяжный поверенный, адвокат.
14 Венецианов – Венецианов М.С., присяжный поверенный.
15 Сәедгәрәй мирза Алкин (1867–1919) – җәмәгать эшлеклесе, адвокат (Казан университетын тәмамлаган), I Дәүләт Думасы әгъзасы.

55 бит.
Заман – хокукымызны үземез мәхафәзә кыйлырга лязим булган замандыр. «Азат»ның 1906 елгы 1 февраль (1) санында «Г(ъ)» имзасы белән басылган.

57 бит.
Кнәзләр заманында истикъляль – «Азат»ның 1906 елгы 5 февраль (2) санында «Зәйнәп Г.К-ва» имзасы белән басылган.

1 Иван IV – рус патшасы Иван Грозный (1530–1584). Рус дәүләте, Василий III 1533 елда үлгәч, аның улы Иван IV тәхеткә утырганчы (1547 елның 16 гыйнвары), төрле князьләр тарафыннан идарә ителеп, шактый көчсезләнә, ил эчендә таркаулык хөкем сөрә. Көчәеп киткән каршылыклар, халыктагы ризасызлыкның нәтиҗәсе буларак, 1547 елның җәендә Мәскәүдә феодалларга каршы восстание күтәрелә. Восстание гаскәр ярдәме белән бастырыла, оештыручылар һәм башлап йөрүчеләр җәзалана.
Иван IV идарә иткән елларда Россиянең тышкы сәясәтендә дә һәм ил эчендә дә туктаусыз сугышлар, рәхимсез кан коюлар булып тора. Биредә шушы вакыйгалар күздә тотыла.
2 Земский Собор – XVI–XVII гасырларда Русьта мөһим дәүләт эшләрен тикшерү өчен чакырыла торган учреждение. Ул өстен катлау вәкилләреннән генә торган.

59 бит.
«Иркенчелек кадәр...» «Азат»ның 1906 елгы 7 февраль (3) санында баш мәкалә урынында исемсез һәм имзасыз басылган. Мәкаләнең Г.Камалныкы булуы «Йолдыз»ның 1907 елгы 24 февраль (90) санында чыккан «Гәзитә караклыгы» исемле мәкаләсендә әйтелгән (99 битне кара).

1 19 октябрь – 1905 елның 17 октябрендә патшаның манифесты игълан ителә. Анда күп кенә иркенлекләр вәгъдә ителә. Ләкин алар, тормышка ашырылмыйча, кәгазьдә генә калалар. Тиздән манифестның, халык массаларын алдау өчен чыгарылганлыгы ачыклана, патша хөкүмәте революцион күтәрелешләрне бастыру сәясәтен үткәрә башлый.
2 «Бәдәвам» – хәзергәчә язылу вакыты тәгаенләнмәгән, авторы билгесез көйле әсәр. Беренче тапкыр Казан дәүләт университеты типографиясендә 1846 елда чыккан, аннары күп тапкырлар басылган.
3 «Тәкый гаҗәб» – тезмә белән язылган дини китап.
4 Хөсәен хәзрәт – Хөсәен Әмирханов (1814 – 1893), Казан мулласы, 1883 елда Коръән тәфсирен бастырып чыгарган.
5 Садыйк хәзрәт – Садыйк Иманколый (? – 1938), Казан мулласы, шагыйрь.

61 бит.
Белек һәм тереклек. «Казан мөхбире»нең 1906 елгы 17 февраль (38) санында «Саиб» имзасы белән басылган.
63 бит.
Табышлы талаш. «Казан мөхбире»нең 1906 елгы 22 февраль (40) санында «Саиб» имзасы белән басылган.
64 бит.
Тугъры мәкъсудка әйләнгеч юл берлә җителсә дә ярар. «Казан мөхбире»нең 1906 елгы 6 март (46) санында «Саиб» имзасы белән басылган.
66 бит.

Кыргыз илә татар. «Вакыт» газетасының 1906 елгы 11 март (5) санында «Саиб» имзасы белән басылган.
1 Кыргыз ... – Октябрь революциясенә кадәр казакъ, кыргыз халыклары уртак бер исем белән – кыргыз дип атап йөртелгәннәр. Мәкаләдә сүз казакълар турында бара.
2 «Әхмәдия» – XVIII гасыр төрек шагыйре Әхмәдинең 1879 елда Казан дәүләт университеты типографиясендә басылган зур күләмле шигъри дидактик әсәре.
3 Насретдин Рабгузинең «Кыйсса...»сы – XIV гасыр башы Алтын Урда язучысы Насретдин Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» (1311) китабы.
4 Заһретдин Бабурның «Бабурнамә»се – XVI йөз Урта Азия хакиме Заһретдин Бабурның (1483–1530) «Бабурнамә» исемле китабы. Бу китап Казанда берничә мәртәбә басыла.
5 Акменла (Акмулла, 1831–1895) – татар-башкорт-казакъ шагыйре. Бу урында аның татар тарихчысы, мәгърифәтче галим һәм педагог Шиһабетдин Мәрҗанигә атап язылган мәрсиясе күздә тотыла. (Казанда 1892, 1904 елларда басылган.)
6 ... Әбүбәкер мелланың рисаләләре ... – XX йөз башы казакъ шагыйре Әбүбәкер Кәпиевнең (Казанда басылган) шигъри дастаннары.

68 бит.
Фас мәмләкәтенең кызганыч хәлләре. «Азат»ның 1906 елгы 4 май (43) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.
1 «Әл-лива» – Мисырда Англия колонизаторларына каршы юнәлтелгән милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, публицист-оратор М.Кямил (1874–1908) тарафыннан XX гасыр башында чыгарылган газета (әл-лива – байрак).
2 «Әл-мөәйяд» – XX гасыр башында Мисырда Англиянең азатлыгы өчен көрәшүчеләр чыгарган газета (әл-мөәйяд – Алла тарафыннан якланган).
3 «Әл-мәнар» – XX гасыр башында Мисырда күренекле ислам реформаторы, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Габдеһ (1849–1905) тарафыннан нигезләнгән журнал (әл-мәнар – маяк).
4 Ибн Халдун (1332–1406) – гарәп тарихчысы, философ.
5 Мөхетдин Гарәби (1165–1240) – Мисырда яшәгән суфи галим.
6 Имам Газали (1058/1059–1111) – мөселман теологы, философ.

72 бит.
Искелек сакчыларына ачык хат. «Азат»ның 1906 елгы 25 май (54) санында «Саиб» имзасы белән басылган.
1 ... яшьләр фиркасе ... – автор биредә конкрет бер сәяси партияне түгел, бәлки яңалык, мәгърифәт яклы татар яшьләр төркемен күз алдында тота.
2 ... картлар фиркасе ... – сүз искелеккә ябышып ятучы, һәртөрле яңалыкка каршы чыгучылар турында бара.
3 «Вакыт» гәзитәсенең унтугызынчы номерында: «Шәкертләр чүбек чәйниләр, кызлар «Мөхәммәдия» җырлыйлар»,– дигән сүзләр бар. – Гәзитәнең бу санындагы «Оренбург, 26 апрель» дигән имзасыз баш мәкаләдә: «... мәктәп вә мәдрәсәләремездә һәмишә шул искечә чүбек чәйнәтүгә дәвам иттерелсә, ... кызларымызга хәкыйкый мәгърифәт вә тәрбия бирү өчен Бакудан башка җирдә һичбер данә мәктәбемез булмаса, аның юклыгы өчен һәм асла кайгыртылмаса, вә нәтиҗә, кызларымызга шулай әүвәлгечә «Мөхәммәдия» җырларга үгрәтеп вакыт үткәрелсә, күз аллары караңгыланып китәләр», – дигән юллар бар.
4 Әмир Хәйдәр – 1800 – 1826 елларда Бохара әмирлеге идарәчесе.

74 бит.
Крәстияннәр һәм Дума. «Азат»ның 1906 елгы 27 май (55) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.

Крестьяннарның I Дәүләт Думасыннан (1906 ел, 27 апрель – 8 июль) көткән өметләре хакында сүз бара. Бу Думада аграр мәсьәләләр буенча патша хөкүмәте һәм аның сәясәте беркадәр тәнкыйть ителә.

75 бит.
Бер каз өчен тәртипсезлекләр. «Азат»ның 1906 елгы 29 май (55) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.

76 бит.
Борчылырмыз. «Йолдыз»ның 1906 елгы 4 октябрь (42) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.
Мәкаләдә Россиянең чит ил капиталына бәйлелеге көчәю, дәүләт бурычларының бермә-бер артуы ачык әйтелгән. Бу фактларда патша самодержавиесе финанс сәясәтенең хезмәт ияләре мәнфәгатьләренә туры килмәгәнлеге чагыла.

78 бит.
«Ислях» гәзитәсе. «Йолдыз»ның 1906 елгы 17 октябрь (47) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр «Әсәрләр»дә (1951, 1982) урнаштырылган. Монда текст «Йолдыз»дан алынды.
1 ... мәдрәсәләрне ташлап чыгып киттеләр ... – Беренче рус революциясе алдыннан һәм революция елларында хәрәкәткә килгән татар шәкертләре кайбер иске мәдрәсәләрдәге тәртипләрдән, уку-укыту эшләреннән ризасызлыкларын белдереп, коллектив рәвештә чыгышлар, забастовкалар ясый башлыйлар. Аларның теләкләре канәгатьләндерелмәгәч, шәкерт садалары (җырлары) җырлап, мәдрәсәләргә яңадан аяк басмаска дип ташлап чыгып китәләр.
Беренчеләрдән булып 1906 елның 26 февралендә Казанның иң зур мәдрәсәсе «Мөхәммәдия» шәкертләре хәрәкәткә килә. Сәбәбе – революцион хәрәкәткә катнашкан дүрт шәкертнең мәдрәсәдән куылуы. Шуңа протест йөзеннән сиксән ике шәкерт мәдрәсәне бөтенләй ташлый. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә башланган бу хәрәкәт тиздән бүтән шәһәрләргә дә күчә.
2 ... исляхның съезды ... – 1906 елның 10–15 маенда Казанда бөтен татар шәкертләренең гомуми съезды үткәрелә. Бу съездда Оренбург, Троицк, Самара, Чистай, Сатыш, Буа, Буби һ.б. мәдрәсәләрдән егермеләп вәкил катнаша.
Съезд төп игътибарны шәкертләр хәрәкәтенең нигез бурычларына юнәлтә: шәкертләр бөтен көчләрен татар мәктәпләрендәге һәм мәдрәсәләрендәге укыту системасын яңартуга куярга тиешләр; укучылар арасында агитация эшләре алып барырга (җыелышлар, митинглар үткәрергә, прокламацияләр, листовкалар таратырга) тиешләр һ.б.
3 ... гәзитә чыгарырга ... – съезд шәкертләрнең легаль газетасын – «Әлислах»ны чыгарырга карар кыла. Аның беренче саны 1907 елның 3 октябрендә дөнья күрә. Бу газетаны чыгаруда татар әдәбиятының күренекле вәкилләре Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Камал, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев һ.б. актив катнашканнар.

80 бит.
Зур сүз вә зур вакыйга. «Йолдыз»ның 1906 елгы 21 октябрь (48) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

1 Мәкәрҗә ярминкәсе – Россиядәге иң зур ярминкәләрнең берсе. XVI гасыр урталарында Идел буендагы Макарьев монастыре янында барлыкка килгән, 1819 елда Нижний Новгород каршындагы үзәнлеккә күчерелгән. Ел саен июль-август айларында уздырылган.

83 бит.

Тел бәхәсе. «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 12 декабрь (12) санында «Саиб» имзасы белән басылган.

1 Мөхәммәд ага ... һинди рәкымнәр кертеп, эш бетермәкче улган иде. – Сүз Мөхәммәд Шаһтахтинский – «Шәркы рус» газетасының (1903–1904 елларда Тифлиста төрки телдә чыккан) мөхәррире турында бара. Ул шушы газетаның 1903 елгы 30 март, 2 һәм 4 апрель (1, 2, 4) саннарында «Мөхәммәд ага хатты» исемле мәкаләсен бастырган (1903 елда аерым китап та булып чыга). Анда ул төрки халыклар куллана торган гарәп алфавитына кайбер үзгәрешләр кертү кирәклеге турында яза.
Г.Камал бу газетаның Казандагы вәкиле булган.
2 Максуди һаи рәсмиягә ябышты ... – «Йолдыз» газетасының мөхәррире Әхмәтһади Максудига (1868–1941) ишарә. Ул сөйләмдә булып та, татар язуында кулланылмаган «ә» хәрефенә язылу хокукы бирә, аны «һаи рәсмия» дип атый, бу хәрефне «Йолдыз» газетасында куллана.
3 ... имән әкәләсе берлә хәрәкәттә – бәрәкәт. Шулай хәрәкәт иткәндә, Бәләбәй әтәчләре ... – болар «ә» хәрефе күп кергән сүзләргә мисал рәвешендә алынганнар. Бу сүзләрдәге «ә» хәрефен төшереп калдырсаң, мәгънәсезлек килеп чыга.
4 Чыгътай теле – Урта Азиянең борынгы әдәби төрки теле.

86 бит.
Ислам матбугаты. «Йолдыз»ның 1906 елгы 20 декабрь (66) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.
1906 елның 15 гыйнварыннан башлап (1907 елның 15 маена кадәр) Уральск шәһәрендә Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин тарафыннан чыгарылган демократик юнәлештәге әдәби, фәнни һәм иҗтимагый «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы декабрь (12) санындагы «Әхвалемезә бер нәзар» дигән мәкалә күздә тотыла.
1 Никадәр кешеләр рөхсәт алу өчен хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп бактылар... – татар теленДә газета чыгару өчен беренче омтылыш 1808 елда ук ясала. XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасырның беренче елларында К.Насыйри, Г.Ильяси, З.Бигиев, Ш.Әхмәров, Ш.Рәмиев, З.Рәмиев, Һ.Максуди һ.б.ларда газета чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәләр, ләкин патша хөкүмәте һәр очракта каршы килә. Татарча вакытлы матбугат бары тик 1905 елгы революция вакыйгалары тәэсирендә генә мәйданга чыгарга мөмкинчелек ала.
2 «Әлгасрелҗәдид»нең сахибе ... Мисыр сәфәренә дә китмәмеш иде. – Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин Истанбулда һәм Мисырда 1901–1903 еллар тирәсендә яши.

1907
87 бит.
Гәзитә эчендә гәзитә. «Йолдыз»ның 1907 елгы 12 гыйнвар (74) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.
Бу фельетон кайбер татар газеталарындагы шаблонны, сенсацион хәбәрләр басу белән мавыгуны тәнкыйтьләү формасында язылган. Ләкин чынында ул Россия иҗтимагый тормышында вакыйгаларның кискенләшүен («үтерәләр, талыйлар, бомба, динамит...»), чит илләрдә революцион, милли-азатлык хәрәкәтләренең көчәюен үзенчәлекле чагылдыруы белән әһәмиятле.

1 Печән базары – Иске Казанның хәзерге Мәскәү һәм Париж Коммунасы урамнары чатында урнашкан базар. Кадимчеләр, гайбәтчеләр оясы буларак «атказанган».
2 Лидваль ... – эре аферист һәм спекулянт; 1906 елда кайбер губерналарда булган ачлык вакытында патша хөкүмәте белән килешү төзеп, ун миллион пот ашлык китертүне өстенә ала, ләкин тиешле вакытка моның бик аз өлешен генә китертә. Бу вакыйга матбугат аша җәмәгатьчелеккә мәгълүм була. Лидваль эше (лидвалиада) патша хөкүмәтенең халык

интересларын якламавын тагын бер тапкыр фаш итүгә, II Дәүләт Думасына сайлауларда уң партияләрнең җиңелүенә китерә.

89 бит.
Эләкми калынды (Кечкенә фельетон). «Йолдыз»ның 1907 елгы 20 гыйнвар (76) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр «Әсәрләр»дә (1951) урнаштырылган. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Фельетон II Дәүләт Думасына сайлаулар барган көннәрдә язылган.

1 Дворецны да бик яман димиләр. – Дәүләт Думасының утырышлары Петербургтагы атаклы Таврида сараенда уздырылган.
2 ... ун тәңкә акча алыр өчен генә кызыга... – сайлаулар турындагы закон нигезендә Дәүләт Думасы депутатларына көн саен ун сум акча түләнгән. Акча өчен генә депутат булып сайланырга омтылу Г.Камалның «Бу ел Думага кемнәрне сайлаячакмыз?» дигән мәкаләсендә* дә тәнкыйтьләнә: «Әмма гыйлем вә мәгърифәттән бу кадәр хазы булмаган кешегә фәкать урын тутыру вә һәр көн саен ун сум жалуния алып кайтып баю өчен генә барырга тырышып йөрү бөтен ислам милләте каршында бик зур оятсызлык вә хәясызлыктыр».
3 ... муллалар узган Думага барып кайттылар. – I Дәүләт Думасына сайланган депутатлар арасында муллалар да булган.
4 Бу Дума да, бәлки, таралыр әле. – Чыннан да, II Дәүләт Думасын хөкүмәт 1907 елның 3 июнендә куып тарата.

91 бит.
Кытайда ислам вәкилләре. «Йолдыз»ның 1907 елгы 8 февраль (83) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) «Кытай хикәяте» исеме белән кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.

1 Юань Шикай (1859–1916) – кытай хәрби һәм сәяси эшлеклесе. 1898 елда либераллар хәрәкәтенә кушылса да, тиздән аларга хыянәт итә. 1901–1908 елларда Кытай башкаласы провинциясендә наместник. Маньчжурия династиясе хакимияттән бәреп төшерелгәч, эчке реакция һәм чит ил империалистлары булышлыгы белән Кытай президенты була, хәрби диктатура режимы урнаштыра. 1915 елның декабрендә үзенең император булачагын игълан итә, ләкин кинәттән үлә.
2 1896 елда кытайлар берлә япуннар арасында сугыш ... – бу сугыш 1894–1895 елларда булды.
3 «Зур йомрык», «Боксер», «Хунхуз» вә быел гына «Зур бот» фиркаләре ... – XX гасыр башында Кытай халкының чит ил империалистларына һәм монархиягә каршы көрәшен максат иткән яшерен оешмалар.
4 Кытай мәмләкәтендә ничә миллион мөселманнарның барлыгы да һәркемгә мәгълүмдер. – Ул вакытларда мөселманнар егерме биш миллион чамасы дип хисап ителгән.
5 Казан хикәяте, бәлки, икенче бер фельетонда язылыр әле. – «Йолдыз» газетасының 1907 елгы 17 март (98) санында «Кантон шәһәрендә имам Аң-Белек» имзалы «Кытайдан бер мәктүп» исемле бер мәкалә басылган (тәрҗемәче итеп «Яшенче» күрсәтелгән). Анда «Кытай хикәяте»ндәге дунганнар турындагы сүзләр Кытай мөселманнары өчен ялган, мәсхәрә дип бәяләнә, Россия мөселманнарының ислях итмәүләре, «вәзирләр» алдында тәлинкә тотулары, «бөек мәшәкатьләр, сарыф ителеп алынган Дума һәм һәртөрле хөрриятләр»дән файдалана алмаулары тәнкыйтьләнә. «Казан хикәяте» дип Г.Камал шушы фельетонны әйтә булса кирәк.

96 бит.

Депутатлар озату (Петербург юлында. Беренче урын). «Йол-дыз»ның 1907 елгы 20 февраль (88) санында «Яшенче» имзасы белән чыккан. Текст «Йолдыз»дан алынды. Мәкалә III Дәүләт Думасы эшли башлау көннәрендә язылган (ул 1907 елның 20 февралендә ачыла).
1 Г.Камалның «социалист»ы образында социал-демократлар партиясе әгъзасы түгел (II Дәүләт Думасында Казан губернасыннан социал-демократлар партиясенең вәкиле юк иде), бәлки сул фразалар белән эш итәргә яраткан, эшче һәм крестьян интересларын яклауда ныклык һәм эзлеклелек күрсәтмәгән депутатлар тәнкыйтьләнә. Мәсәлән, трудовикларның («Трудовая группа» – вак буржуаз оешма) Думадагы депутатлары шундый булалар. Аерым алганда, Казан губернасыннан II Думага депутат итеп сайланган Гариф Бадамшин әнә шул трудовиклар позициясен яклый.
Бу мәкаләдәге «социалист»ның чын социалист булмавын Г.Камал «Депутатлар озату. Петербург юлында. Икенче урын» исемле фельетонында да искәртеп үтә (Йолдыз. 1907. 27 февраль. № 91).
2 ... «ташлыйк, туганнар, иске дөньяны, китсен аяктан аның тузаны» ... – бу юллар XIX гасырның 80–90 нчы елларында рус революционерлары арасында киң таралган «Эшчеләр марсельезасы» җырыннан (народник Петр Лавров сүзләре) алынган:
Отречемся от старого мира,
Отряхнем его прах от наших ног, –
дигән өзекнең тәрҗемәсе.
3 Биш ел бик тырышып хезмәт итәчәкмен. – Дәүләт Думасына депутатлар биш ел срокка сайланганнар.

99 бит.
Гәзитә караклыгы. «Йолдыз»ның 1907 елгы 24 февраль (90) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.
«Бәянелхак» – Казанда 1906 – 1914 елларда чыккан иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Нашир һәм мөхәррире – Әхмәтҗан (1853–1912) һәм Мөхәммәтҗан (? – 1914) Сәйдәшевләр аталы-уллы сәүдәгәрләр, эшкуарлар.
1 «Бәянелхак» гәзитәсенең йөз утыз беренче нөсхәсе... – 1907 елның 20 февраль саны.
2 ... мәкаләнең цензор тарафыннан сызылу сәбәпле берничә юл буш калдырылмыш ... – «Бәянелхак»та мәкаләдәге: «Башкаларына кыйлган тәҗавезләре генә җитмәгән шикелле, Коръәнемезгә кадәр җөрьәт итә башлады» һәм «Димәк ки, асыл максаты белән әсасе исламны дөньядан бетермәк икән» дигән җөмләләр төшереп калдырылган.
3 ... баш мәкалә ... – «Азат»та имзасыз басылган (341 биттәге искәрмәне карагыз).
4 Китаплардан цензор алынмаган иде. – 1905 елгы революция вакыйгалары басымы астында самодержавие китапларны цензура аша уздырганнан соң гына бастырып чыгару тәртибен үзгәртергә мәҗбүр була. Ләкин гамәлдә патша хөкүмәтенең татар китабын, вакытлы матбугатын эзәрлекләве Февраль революциясенә кадәр дәвам итә.

102 бит.
Депутатлар озату (Петербург юлында. Икенче урын). «Йолдыз»ның 1907 елгы 27 февраль (91) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.

1 ... социалистның фикерләрене язган идем. – Г.Камал үзенең «Депутатлар озату. Петербург юлында. Беренче урын» исемле мәкаләсенә (шушы томның 96–98 битләрен карагыз) ишарәли.
2 ... октябрист профессор ... – II Дәүләт Думасына октябристлардан Казан университеты профессоры Капустин М.Я. сайланган. Г.Камал фельетонда шушы кешене күз алдында тотып яза булса кирәк.
Октябристлар («17 Октябрь союзы») – Россиядә либерализмның уң канаты булган, эре помещик һәм сәүдә-сәнәгать буржуазиясе вәкилләрен эченә алган партия.

3 ... җиргә яхшы бәһа бирмәсәләр ... – октябристларның аграр сәясәтендә помещик җирләренең бер өлешен крестьяннарга кыйммәт бәягә сату мөмкинлеге дә каралган булган.
4 Дисәтинә – Россиядә метрик система гамәлгә кергәнче кулланылган җир мәйданы үлчәү берәмлеге. 1,09 гектарга тигез.
5 ... Думада фикердәшләремез генә азрак күренә күренүен дә ... – октябрист юкка гына зарланмый. Сайлаулар революциянең җиңелүе вакытында уздырылса да, II Дәүләт Думасында (барысы биш йөз унсигез депутат) октябристлар фракциясе кырык дүрт депутаттан гына гыйбарәт була.
6 Дума таралыр. Таралса, бәлки, яңадан җыелмас ... – II Дәүләт Думасының составы да патша хөкүмәтен канәгатьләндерми, һәм ул 1907 елның 3 июнендә таратыла; социал-демократлар фракциясе, кулга алынып, хөкемгә тартыла. 1907 елның көзендә III Дәүләт Думасы җыела.
104 бит.
Дахили хәбәрләр. «Йолдыз»ның 1907 елгы 1 март (92) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.
105 бит.
Депутатлар озату (Петербург юлында). «Йолдыз»ның 1907 елгы 8 март (94) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
1 ... бер социалист ... – 347 биттәге искәрмәне карагыз.
2 ... бер октябрист профессор ... – югарыдагы искәрмәне карагыз.
3 Өченче урын... Хәзрәт бик шат. – II Дәүләт Думасына Казан губернасыннан депутат булып бер генә мулла сайланган. Ул – Казан өязе Күлбашы авылы мулласы Сафиулла Максудов (1860 – ?). Фельетонда сүз аның турында бара булса кирәк.
4 Мин нишләп әсир булыйм ... – мулла биредә «эсер» дигән сүзне шулай ишетә. Эсер – социал-революционерлар (с.р.) партиясе әгъзасы.
Сафиулла Максудовның русча укый да, яза да, сөйли дә белмәве мәгълүм була.
5 – Ун, ун, – дидем. – Дума депутатларына бер көнгә ун сум исәбеннән хезмәт хакы (вазыйфә) бирелгән.
6 Эздик – эсдек (с.д.). Ул елларда Россия социал-демократик эшчеләр партиясе әгъзаларын шулай дип тә атаганнар.
7 ... «Мөселман иттифакы» партиясе ... – «Иттифакы мөслимин», Россия мөселманнарының либерал-демократик булган партиясе. Ул мөселманнарның 1905 елның 15 августында булган I съезды карары белән төзелә. Партия, кадетлар тоткан сәясәткә кушылып, конституцион монархия идеясен яклады.
8 Узган ел барган бер мулла җитмеш ике генә көн торып кайтты. – Казан губернасыннан I Дәүләт Думасына Тәтеш өязе мулласы Фәйзелкотдус Миңлебаев сайланган булган. Бу Дума 1906 елның 27 апреленнән 8 июльгә кадәр генә яшәде, 9 июльдә игълан ителгән патша манифесты белән таратылды.

108 бит.
Депутатлар озату (Петербург юлында. Дүртенче урын). «Йол-дыз»ның 1907 елгы 10 март (95) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.

110 бит.
Ачларга ярдәм эшләре. «Йолдыз»ның 1907 елгы 16 май (120) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
1 ... мөселманнар да ярдәмгә иштиракь иттеләр. – «Йолдыз» идарәсендә «Мөдир Г.Камал» имзасы белән чыккан бер хәбәрдә идарәгә Россиянең төрле тарафларыннан (Курган, Әстерхан, Җидесу, Томск, Ташкент якларыннан) акчалар, иганәләр күндерелүе, аларның

ачларга ярдәм комитетына тапшырылуы турында язылган (Ачларга ярдәм // Йолдыз. 1907. № 106. (5 апрель.)

111 бит.
Татарча театр. (Өченчекөн кич ...) «Йолдыз»ның 1907 елгы 15 июль (145) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
1 Аркадий бакчасы – Иске Казанда Аргы Кабан күле буендагы бакча.
2 «Галимнәр илә наданнар» исемле комедия... – рус драматургы А.Н.Островскийның (1823–1886) «В чужом пиру похмелье» исемле ике пәрдәлек комедиясенең И.Кудашев-Ашказарский тарафыннан үзгәртеп эшләнгән тәрҗемәсе. «Галимлек илә наданлык» исеме белән дә уйналган.
3 «Злоумышленник» – А.П.Чехов әсәре.
4 Низаметдин бай ролен уйнаучы ... – И.Кудашев-Ашказарский турында сүз бара.

112 бит.
«Бәянелхак» һәм «Вакыт». «Йолдыз»ның 1907 елгы 28 июль (151) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.
1 Бу «Игълан» «Йолдыз»ның 1907 елгы 15 июль (145) санында баш мәкалә урынында эре хәрефләр белән имзасыз басылган.
2 Соңгы йөз туксан тугызынчы номерында безгә каршы тешләрене ыржайтты. – «Вакыт» газетасының 1907 елгы 24 июль (199) санында «Иршад»ның соңы вә «Йолдыз»ның киләчәге» исемле имзасыз мәкалә басылган. Анда «Йолдыз»ның үзен «Русиядәге татар гәзитәләре арасында иң бәхтияры» итеп санавы көлкегә алына.
114 бит.
«Мәдрәсәи Галия». «Йолдыз»ның 1907 елгы 26 август (161) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.
Мәкаләдә сүз педагог, дин галиме Зыя әл-Камали (1873–1942) тарафыннан Уфада 1906 елда оештырылган «Мәдрәсәи Галия» турында бара.

1 ... Минһаҗетдин Йосыф намендә бересе ... – Минһаҗетдин Кадермәтов (Һинди Минһаҗ, 1871–1925); Һиндстанда укып кайткан бу кеше, элекке Саратов губернасы Хвалын шәһәрендә Һиндстан мәдрәсәләре кебек югары уку йорты салдырам дип, халыктан акча җыйный, әмма ул акчаны үз кирәгенә тотып бетерә. Г.Тукай, М.Гафури һ.б.лар тарафыннан тәнкыйть ителгән кеше.
2 ... «Тәрҗеман» гәзитәсенең иң соң килгән нөсхәсендә ... – газетаның 1907 елгы 18 август (53) санында «Уфа мәдрәсәи галиясе» исемле имзасыз мәкалә басылган.

117 бит.
Думаны истикъбаль. «Йолдыз»ның 1907 елгы 12 сентябрь (167) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.
Мәкалә III Дәүләт Думасына сайлауларга әзерлек көннәрендә язылган.
119 бит.
Гәзитәләрдән. «Йолдыз»ның 1907 елгы 19 сентябрь (170) санында «Сабикъ «Азат халык» мөхәррире Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1 ... «Тәрҗеман»ның соңгы нөсхәсендә ... дигән бер сүз күрелде. – Әлеге сүзләр «Тәрҗеман»ның 1907 елгы 11 сентябрь (57) санындагы «Кәнде гәзитәләремездән» исемле мәкалә эчендә басылган.
2 ... «таңчы» вә «тавышчы»лардан һәрберсе, гәзитәләрене ташлап ... – эсерлар тээсирендәге яшьләр чыгарган «Таң йолдызы» (Казан, 1906) һәм «Тавыш» (Казан, 1907) газеталары патша властьлары тарафыннан туктатыла.

3 Казанда беренче кыйсем сайлаучы мөселманнар – йөз алтмыш ике, икенче кыйсемнәр җиде йөз микъдарындадыр. – Думага сайлаулар турындагы закон нигезендә, ул заман Казанда яшәгән берничә дистә мең татарның бик кечкенә өлеше генә сайлау хокукы белән файдаланган, сайлаучылар исемлегендә исә күпчелекне эре буржуазия (беренче кыйсем – беренче курия), вак буржуазия һәм шәһәр интеллигенциясе (икенче кыйсем – икенче курия) алып торган.

120 бит.
Үз тарафымнан җавап. «Йолдыз»ның 1907 елгы 23 сентябрь (172) санында басылган.

121 бит.
Сайлау алды. «Йолдыз»ның 1907 елгы 28 сентябрь (174) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.
1907 елның көзендә III Дәүләт Думасына сайлаулар уздырыла. Шул уңай белән выборщиклар сайлау буенча икенче куриягә – сыйныфка (андагы урыннар вак буржуазия һәм шәһәр интеллигенциясенә бирелгән) кергән Казан шәһәре татарларының (мөселманнарының) сайлау алды җыелышы уздырыла һәм анда выборщиклыкка кандидат итеп Г.Камал тәкъдим ителә. Бу турыда «Йолдыз» газетасының 21 сентябрь (171) санында басылган информацияне һәм «Мөселманнардан икенче сыйныф сайлаучылар Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдиновны сайларга мәгъкуль күрәләр...» дигән эре хәрефләр белән басылган белдерүне укыгач, «Бәянелхак» газетасының нәшир һәм редакторлары – аталы-уллы Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр – Г.Камалга яла ягып, үз газеталарына өстәмә – гыйлавә язып чыгаралар; газеталарында үз белдекләре белән выборщиклыкка кандидат итеп башка берәүне – Гайса мирза Еникеевне күрсәтәләр (Бәянелхак. 1907, 23 сентябрь, № 223). Билгеле, Г.Камал моңа каршы дәшми кала алмый һәм «Үз тарафымнан җавап» дигән мәкалә бастыра (Йолдыз. 1907. № 172 (23 сентябрь). Сәйдәшевләр сүзләренең ялган икәнлеген раслый.
Г.Камалның бу мәкаләсе шушы көннәрдә язылган. Ул «Чүкеч»нең (1906–1910 елларда Оренбургта чыгарылган татар сатирик журналы) 1907 елгы 7 октябрь (30) санында да аз гына үзгәрешләр белән дөнья күргән.

1 Бабай – Әхмәтҗан Сәйдәшев.
2 Алар да гыйлавә чыгардылар... – «Үз тарафымнан җавап» мәкаләсе турында әйтелә булса кирәк.
3 Таңчылардан бик «усал» бер мөхәррир бар... – публицист Фуад Туктаров күздә тотыла. Ул 1905–1907 елларда татар эсерларының лидерларыннан берсе була. Матбугатта «Усал» псевдонимы белән чыгышлар ясый. Думага сайлауларда «Бәянелхак» газетасы тоткан юлны яклап, шул газетада ике мәкалә бастырган (Бәянелхак. 1907. 29 сентябрь, № 226;  2 октябрь, № 227).
4 Беренче куриядән – үзем, икенчедән «ул» сайлансак, эшләр яхшылана. – 23 сентябрьдә булган беренче курия (сыйныф) сайлаучылары җыенында выборщиклыкка мулла Габдулла Апанаев үтә, аңа илле җиде ак шар куелган була. Әхмәтҗан Сәйдәшевкә илле ике ак шар куелып, выборщиклыкка үтми.

123 бит.
Яңа әсәрләр («Мирза кызы»). «Йолдыз»ның 1907 елгы 5 октябрь (177) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.

1 «Мирза кызы» – Фатих Кәриминең «Мирза кызы Фатима» исемле әсәре (роман, икенче табагы, 1907. «Әдәбият мәҗмугасы», икенче китап).

Башта бу әсәр (М.Фатих әл-Кәрими «Мирза кызы Фатима ханым») нашир вә мөхәррир Шәрәфетдин Шәһидуллинның «Алыш-вireш вә кәсеб адрес» календаренда (Оренбург, 1901) кушымта рәвешендә басылган.
2 «Хат болгатты» – Г.Ильяснең (журналист һәм нашир, «Аң» журналы мөхәррире Әхмәдгәрәй Хәсәни, 1883–1933) сәхнә әсәре, комедия бер пәрдәдә («Петербург татарлары тереклегеннән», 1907).

125 бит.
Бер-ике сүз. «Әлислах»ның 1907 елгы 12 октябрь (2) санында «Галиәсгәр Камал» имзасы белән басылган «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Әлислах»тан алынды.
1 ... ун сәнә кадәр дәвам иткән булса да ... – «Тәрҗеман» газетасы 1883 елда Кырымда Бакчасарай шәһәрендә чыга башлый. Нашире һәм мөхәррире – Исмәгыйль Гаспринский (1861–1914). Татар язучылары (шулар арасында Г.Камал да) еш кына бу газетаны тоткан юлы һәм чуар теле өчен кискен тәнкыйтьләгәннәр.
2 «Шәркы рус» газетасы 1903 елда Бакуда чыга башлый.
3 «Хәят» газетасы 1904 елда Бакуда чыга башлый.
4 Монда сүз публицист, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Габдерәшид Ибраһимовның (1853–1944) 1900–1903 елларда «Миръат» (Көзге) исеме белән бастырып чыгарган журнал тибындагы җыентыклары турында бара булса кирәк.
5 «Мөхбир» – «Казан мөхбире».
6 «Әлислах» гәзитәсе вөҗүдкә чыгарылды. – «Әлислах» газетасы демократик яшьләр тарафыннан, Г.Тукай һәм Ф.Әмирханның якыннан катнашы белән 1909 елның 3 октябреннән чыга башлап, 1909 елның 21 июленә кадәр дәвам итә.
127 бит.
Мулла булмагач, чибәр җирдән кыз алып булмый. «Әлислах»ның 1907 елгы 19 ноябрь (7) санында «Күчереп яздым: «Яшенче» имзасы белән басылган. Имзадан соң искәрмәсе бар. «Идарә: «Яшенче» әфәнденең күчергән хикәяте заманыбыздагы «Казани Хәбибулла мулла вә углы» исемле кыйссага охшый икән». «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән.
Текст «Әлислах»тан алынды.
1 Салих пәйгамбәргә таштан тәвә чыгардың ... – бу могҗиза турында Коръәннең җиденче һәм башка кайбер сүрәләрендә әйтелә.
2 Муса пәйгамбәрнең кавеменә таштан су чыгардың, күктән «мән» белән «сәлва»лар ягдырдың. – Муса пәйгамбәр һәм аның тирәсендәге кешеләр, Мисырдан чыгып, сахра кичкәндә, ач һәм сусыз калалар. Шулчак Муса таягы белән ташка (җиргә) орып су чыгара, күктән ашамлыклар (манна ярмасы) һәм кошлар (бытбылдыклар) яудыра. Муса пәйгамбәрнең кыйлган могҗизалары турында Коръәннең бик күп сүрәләрендә сөйләнелә.
130 бит.
Габдулла Тукаев шигырьләре. «Йолдыз»ның 1907 елгы 5 декабрь (201) санында басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Бу мәкалә Г.Тукайның «Г.Тукаев шигырьләре» исемле китабы (Казан : Шәрәф матбагасы, 1907. Беренче кыйсем) басылып чыгу уңае белән язылган.
1 Габделмәҗид әфәнде – шагыйрь Мәҗит Гафури.
2 Пишкадәм шагыйрьләре илә кыяс кыйлу ... – «Вакыт» газетасының 1906 елгы 9 декабрь (108) санында Морад (Риза Фәхретдинов) Г.Тукайны гарәп шагыйре Мәгарригә, М.Гафурины фарсы шагыйре Туграигә охшатуын язып чыга. Г.Камал шушы чыгышны күз алдында тота булса кирәк.
132 бит.
Ишмиләр – түнтәрәләр. «Йолдыз»ның 1907 елгы 12 декабрь (203) санында «Кечкенә фельетон» бүлегендә «Яшенче» имзасы белән басылган.
Түнтәр авылы (хәзер Татарстан Республикасының Балтач районы) мулласы Ишми ишан (Ишмөхәммәд Динмөхәммәтов, 1839–1919) татар тормышындагы бөтен прогрессив һәм демократик хәрәкәткә каршы чыгып торуы белән танылa. Фельетондагы «ишмиләр –

түнтәрәләр» гыйбарәсе, төп мәгънәләрендә кулланылудан тыш, әнә шул Ишми ишанның яман эшләренә дә ишарәле.
1908
133 бит.
Бәйрәм ашы. «Йолдыз»ның 1908 елгы 1 гыйнвар (210) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.
Газетаның бу саны Корбан гаете көнендә чыккан.

134 бит.
Тәсәлсел мөхаль, бәс, бу да мөхаль! «Йолдыз»ның 1908 елгы 22 февраль (230) санында «Кечкенә фельетон» бүлегендә басылган (аннан соң «Яңа шагыйрь» фельетоны урнаштырылып, икесенә бер имза – «Яшенче» куелган).

135 бит.
Яңа шагыйрь. «Йолдыз»ның 1908 елгы 22 февраль (230) санында (югарыдагы искәрмәне карагыз) басылган. Текст шуннан алынды.
Шагыйрь Зариф Бәшири «Әхбар» газетасының 1908 елгы 1, 21 гыйнвар, 6, 13 февраль (10, 17, 23, 26) саннарында «Дустыма», «Поезд», «Акчага», «Кешелектән чыгу ансат» дигән йомшак, эшләнеп җитмәгән шигырьләрен бастыра. Мәкаләдә шундый шигырьләр тәнкыйть ителә.

137 бит.
Татарча театр [«Алдым-бирдем»]. «Йолдыз» газетасының 1908 елгы 17 март (238) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.
«Яшенче» – Г.Камалның 1908–1909 елларда шактый еш кулланган псевдонимы.
14 мартта уйналган бу спектакльгә «Усал» (Фуад Туктаров) да бәяләмә язган («Казан мөхбире», 17 март (271). Аныңча, пьесада җитешмәгән җирләр бик күп; Тарханова, Девишев һәм Шәмсетдиновтан башкалары спектакльдә үз рольләрен начар башкарганнар.
1 Новый клуб – бу вакытларда Казанның хәзерге Горький урамындагы 3 нче йортка урнашкан була (1912 елда шул ук урамдагы 5 нче – хәзер К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры урнашкан йортка күчә).
2 Морадова – Суфия Коләхмәтева (1890–1972), драматург Гафур Коләхмәтев сеңлесе. Соңыннан табибә була.

138 бит.
«Помада мәсьәләсе». «Йолдыз»ның 1908 елгы 19 март (239) санында «Яңа әсәрләр» бүлегендә «Г.Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Мәкаләдә сүз драматург һәм тәрҗемәче Идрис Багдановның «Помада мәсьәләсе» исемле әсәре (Казан, 1908) турында бара. Комедия беренче мәртәбә «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1911 елның 15 гыйнварында сәхнәләштерелә.
140 бит.
«Хәкыйкатьме, хыялмы?» «Йолдыз»ның 1908 елгы 28 март (243) санында, «Яңа китаплар» бүлегендә, «Үги балалар» дигән рецензиясе белән бергә урнаштырылып, ахырында «Г.Камал» имзасы куелган.

142 бит.
«Үги балалар». «Йолдыз»ның 1908 елгы 28 март (243) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Монда текст «Йолдыз»дан алынды.
Мәкалә М.Гафуриның 1908 елның февралендә Казанда Шәрәфләр мәтбагасында басылып чыккан «Үги балалар» исемле китабына рецензия рәвешендә язылган.

1 Латыйфа исемле үги ана хикәянең ахырында Зөһрә исемендә була. – «Үги балалар» китабында, чыннан да, мондый механик хата киткән.
2 Җәбер күргән Фатыйма исемле кыз Латыйфа була. – М.Гафури китабында мондый хата табылмады.
3 «Милли шигырьләр». – Бу исем белән М.Гафуриның алты шигырь җыентыгы чыккан. Биредә сүз шуларның беренчесе – 1907 елда (Казан : Шәрәф мәтбагасы) басылганы турында бара. «Милли шигырьләр» һәм «Үги балалар» китапларына Ф.Әмирхан тарафыннан да тискәре бәя бирелде (Әлислах. 1908. 3 апрель. № 25).

143 бит.
Гипнотизм мәҗлесендә. «Йолдыз»ның 1908 елгы 29 май (268) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.

1 Гипнозчы Ситников 1908 елның апрель-май айларында Казанда гипноз сеанслары үткәрә. Бу хакта «Йолдыз»да игъланнар биреп барылган.
2 Бер кешенең мәкаләсе дәрҗ ителмеш иде. – «Йолдыз»ның 1908 елгы 22 апрель (252) санында «Берәү» имзасы белән басылган «Гипнотизм мәҗлесе» исемле мәкалә күздә тотыла.
3 Мәзкүр әфәнде – Фатих Әмирхан.

147 бит.
«Яшь гомер». «Йолдыз»ның 1908 елгы 5 июнь (270) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.

149 бит.
«Ачлык кушты». «Йолдыз»ның 1908 елгы 17 июнь (274) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.

1 Ярулла әфәнденең бер әсәре Казанда тамашага куелган иде. – Я.Вәлинең «Оят, яки Күз яше» исемле пьесасы (китап булып Оренбургта, Кәримевләр мәтбагасында 1902 елда чыккан) Казанда 1907 елның 24 августында һәм 1908 елның 25 апрелендә уйнала. 1908 елгы спектакльне караганнан соң, Ф.Әмирхан да үзенең тәнкыйть фикерен әйткән. «Әлислах»ның 1908 елгы 4 май (29) санында бастырган рецензиясендә ул «...пьесада нә әдәбият вә нә дә фикер җәһәтеннән тәкъдир ителерлек нәрсә булмаганы»н яза.
2 Ф.Әмирхан исә тагын да кискенрәк әйтә: «Ахыргы пәрдәдә татар халкының төрекмән йортына кызын эзләп килеп тә, бу баһадирлыгын үзенең татарлыгыннан дип, милләтчелек фәлсәфәсе сатуы миңа бик гаҗәп, бик көлке һәм наивный тоеладыр».

152 бит.
«Гыйльме әшья». «Йолдыз»ның 1908 елгы 24 июнь (277) санында «Яңа китаплар» бүлегендә «Уку көтебханәсе» исемле рецензия алдында урнаштырылып, «Галиәсгар Камал» имзасы белән бирелгән. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Педагог Харис Фәйзинең «Гыйльме әшья» исемле дәреслегенә (Казан, 1908) рецензия рәвешендә язылган.

1 Харис әфәнде ... бер китап язып чыгармыш иде. – Ул китап – 1907 елда чыккан: «Гыйльме әшья». Беренче җөзьэ. Мөхәррире – Мусков. И.Н.Харитонов мәтбагасы. «Мәгариф» көтебханәсе нашире. Мөтәрҗиме – Харис Фәйзи.
2 ... фикеремезне беренче җөзьэ чыккан вакытта язган идек. – «Йолдыз»ның 1908 елгы 1 гыйнвар (210) санында «Г.Ч.» имзасы белән басылган «Гыйльме әшья» исемле рецензиягә ишарә.

153 бит.
«Уку көтебханәсе». «Йолдыз»ның 1908 елгы 24 июнь (277) санында басылган.
Текст газетадан алынды. Г.Камал җыентыкларына беренче тапкыр кертелә.

1 «Алла хаклыкны белә, ләкин тиз әйтми». – Л.Н.Толстойның «Бог правду видит, да не скоро скажет (быль)» исемле хикәясенең тәрҗемәсе. Тәрҗемәчесе күрсәтелмәгән.
Бу хикәя 1875 елда чыгып, Толстойның үзе исән чагында егерме сигез мәртәбә басылган. «Новая азбука и русские книги для чтения» китабының «Третья русская книга для чтения» дигән бүлегеннән алынган.
2 «Гыйлем вә җәһел – нашир һәм язучы Хәбибрахман Зәбиринең «Гыйлем вә җәһел, яхуд Нури әфәнде вә Мөхәммәтҗан карт» (Казан, 1908. «Уку көтебханәсе» исемле әсәре. 4 нче китап).
3 «Сигнал яки ишарә» – авторы күрсәтелмәгән кечкенә хикәя (Казан, 1908).
4 «Тунгатай» – Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемәсендә чыккан хикәя (Казан, 1908. «Уку көтебханәсе». 4 нче китап).

155 бит.
Татарча театр. (14 июльдә Панаев бакчасында ...) «Йолдыз»ның 1908 елгы 16 июль (285) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.
1 Панаев бакчасы – Казанның хәзерге Горький урамында «Динамо» стадионы урнашкан урын.
2 «Яшьләр» труппасы – 1906 – 1910 елларда Казанда татарча спектакльләр куйган үзешчән яшьләрдән торган труппа.
3 «Хуҗа һәм приказчик» – 1907 елда Казанда басылып чыккан өч пәрдәле комедия. Бу комедия – Ф.Әмирхан тәкъдим иткән билгесез авторның кульъязма әсәренең Гариф Богданов тарафыннан татар тормышына яраклаштырып эшләнгән тәрҗемәсе. Бу фактны Г.Богданов Бәян Гыйззәткә 1954 елгы бер әңгәмә вакытында сөйләгән.
4 «Кияү ззләү» – 1907 елда Казанда басылып чыккан «Кияү эзләү, яхуд игълан бәласе» исемле бер пәрдәлек пьеса. Русчадан үзгәртеп тәрҗемә ителгән.
5 Морадова – Г.Коләхмәтевнең сеңлесе Суфия Коләхмәтева.

156 бит.
Тел берләштерәләр. «Яшен» журналының 1908 елгы 3 август (1) санында бер «Кечкенә фельетон» басылган. Аның беренче кисәге «Тәрәкъкый мөзакәрәләре» дип аталып, «Гади бер мәҗлес. Төрле сүз арасында нәүбәт милләтнең тәрәкъкыена килә. Мәҗлестә бохари бер мулла, Төркия күргән бер мөгаллим, русча мөкәммәл укыган бер мирза, ышкулдан укып чыккан бер ышкулник вә гайреләр бар...» дип башланып китә. Анда боларның һәрберсе, сүз алып сөйләп, үзләрен үзләре фаш итә. Бу кисәк «Шулай да булса бу тартышуыңыз да ярый, чөнки сез тартышуда гына табарсыз үзеңезнең хакыңызны» дигән, ул еллардагы эсерлар лозунгысына охшаш җөмлә белән тәмамланган һәм «Әхтәри» имзасы куелган. Аннан соң гына «Шул ук мәҗлестә тел берләштерәләр» дип аталган икенче кисәге басылып, «Яшенче» диелгән.
Гомумтөрки телне яклаучылар бу елларда, һәр милли телнең үзенчәлекләрен инкяр итеп, һәр милләтнең үз ана теленә нигезләнгән телен үстерүгә каршы чыгуларын дәвам иттерәләр. Фельетон шулардан көлеп язылган.
Текст «Яшен»нән алынды.

157 бит.
Игъланчылар ничек шаяралар. «Йолдыз»ның 1908 елгы 27 ноябрь (335) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.

159 бит.
Яңа әсәрләр. («Сабах» көтебханәсе тарафыннан ...) «Йолдыз»ның 1908 елгы 7 декабрь (343) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.
1 «Сабах» көтебханәсе – Казанда китап бастыру һәм сату өчен төзелгән сәүдә ширкәте. «Болгар» номерлары белән бер бинада урнашкан булган. (Хәзерге Мәскәү һәм Татарстан урамнарының кисешкән җире.) Хуҗалары – бертуган Вәли һәм Гали Әхмәдуллиннар.
2 «Кешегә күпме җир кирәк?» исемле рисалә... – Л.Н.Толстойның «Много ли человеку земли нужно?» (1886) әсәреннән Басыйр белән Каһир тәрҗемәсе (Казан : «Сабах» көтебханәсе, 1908).
3 ... Толстойның ике кечкенә әсәрләре дәрҗ ителмештер. – Л.Н.Толстойның 1903 елда басылып чыккан «Ассирийский царь Асархадон» һәм «Три вопроса» исемле әкиятләреннән Насыйх Мөхетдинов тарафыннан тәрҗемә ителгән «Ассирия патшасы Асархадон», «Өч сөаль» (Казан : «Сабах» көтебханәсе, 1908) исемле китап турында сүз бара.

160 бит.
Яңа әсәрләр. («Балалар дөньясы», беренче китап – «Кечкенә Рәшид».) «Йолдыз»ның 1908 елгы 11 декабрь (341) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Рецензиядә «Кечкенә Рәшид» дигән китапка (Мәктәп балалары өчен хикәя / тәрҗ. Ш.Мостафа. Казан : Әхмәдгәрәй Хәсәни көтебханәсе, 1908. 1 нче басма.) бәя бирелә.

1 «Җуаныч» нам бер китап... – Г.Тукайның «Җуаныч» («Мәктәп мөкяфәте»ннән беренче китап) исемле китабы Казанда «Сабах» көтебханәсе тарафыннан 1908 елның ноябре башында чыгарылган.

162 бит.
Гласныйлык һәвәскәре. «Йолдыз»ның 1908 елгы 21 декабрь (344) санында «Кечкенә фельетон» баш астында «Яшенче» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Монда текст «Йолдыз»дан алынды.

1909
164 бит.
Яңа әсәрләр. (Бу көннәрдә китап базары ...) «Йолдыз» газетасының 1909 елгы 26 февраль (369) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.

1 «Милләт» – 1908 елның сентябрендә Казанда оештырылган мәтбага һәм көтепханә (типография, китап сәүдәсе ширкәте. 1917 ел-га кадәр яши).
2 Кәримев-Хөсәенев ширкәте – 1901–1917 елларда Оренбургта эшләп килгән типография.
3 «Җәгърафия мөгаллиме» – Г.Җәгъфәревнең 1908 елда Оренбургта Кәримев-Хөсәенев мәтбагасында ибтидаи мәктәпләр өчен чыгарылган дәреслеге. Китап Оренбургта 1910, 1912 елларда кабат басылган.
4 «Тарихы ислам» (Казан : Милләт, 1908. 1 нче кисәк) – төрек галиме Мәхмүд Әсгатьнең төрекчә чыккан китабы.
5 Харитонов мәтбагасы – XIX йөзнең соңгы чирегендә Казанда ачылган типография. Бу типография 1902–1906 елларда татар китапларын бастырып чыгару буенча зур эшчәнлек күрсәтә. Хуҗасы – Иван Николаевич Харитонов (1859 – ?). Харитонов татар шрифтына реформа кертә, аны матурлый, нәфисли.
6 Ибраһим Юзиев (1865–1912) – И.Н.Харитонов типографиясендә эшләгән хәреф кою остасы.

7 «Үрнәк» мәтбагасы – 1906 елның 1 ноябрендә Казанда бертуган Шәрәфләр тарафыннан ачыла. Башта – «Мәтбагаи Шәрәф», 1908–1911 елларда исә «Үрнәк» исеме белән аталып йөри.
8 «Дин вә мәгыйшәт» мәтбагасы – Оренбургта 1906 елның 5 декабрендә ачылган типография. Хуҗасы – мулла һәм сәүдәгәр Мөхәммәдвәли Хөсәенев. Бу типографиядә күбрәк дини әдәбият басылган.

167 бит.
Тәмсилләр. «Яшен»нең 1909 елгы 2 март (7) санында «Барыйка» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Яшен»нән алынды.

1 Крылов бабайның баснялары ... – рус мәсәлчесе Иван Андреевич Крылов (1769 – 1844) мәсәлләре.
2 Филгә ... вәзирлек дәрәҗәсе бирелгән. – Бу урында И.А.Крыловның «Слон в случае» мәсәле күздә тотыла.
3 Бер хинзир ... – И.А.Крыловның «Свинья» исемле мәсәле.
4 ... бик «усал» бер критик ... – мәкаләләрен «Усал» имзасы белән бастырган Фуад Туктаров күздә тотыла.
5 Бер кечкенә курнос көчекнең филгә каршы ... – И.А.Крыловның «Слон и Моська» мәсәле күз алдында тотыла.
6 «Оренбург көчеге» өрә. – Сүз Зариф Бәшири турында бара булса кирәк. Ул 1908 елның җәеннән «Чүкеч»тә язышa башлый, ә илле җиденче саныннан башлап анда «мөдир вә мөхәррир» була. Үзенең шигырь һәм мәкаләләрендә, фельетоннарында ул Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал адресларына урынсыз сүзләр ычкындырып җибәргәли. Бу дорфа чыгышлар, әлбәттә, җавапсыз калмаган. Г.Тукай, мәсәлән, «Җавап» шигырендә З.Бәширине «агу йоткан көчек» дип атый.

169 бит.
«Явызлыкның җәзасы». «Йолдыз»ның 1909 елгы 9 март (373) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды. «Гасыр» көтебханәсенең мувәкъкать әсами көтебе»нең (Казан : И.Н.Харитонов мәтбагасы, 1909. № 2) хәбәр итүенә караганда, 1901 елда Оренбургта әдәби конкурс уздырыла һәм анда беренче премия «Явызлыкның җәзасы» исемле роман өчен бирелә. Бу әсәр «Дин вә мәгыйшәт» журналының 1906 елгы 1, 1907 елгы 2–8 нче саннарында хикәя дип басыла, авторы итеп Әш-Шәех әл-Галими күрсәтелә. 1909 елда исә бу әсәр Казанда «Гасыр» көтебханәсендә китап булып чыга. Г.Камал рецензиясендә сүз шуның турында бара.

171 бит.
Яңа китаплар. (Ушбу көннәрдә ...) «Йолдыз»ның 1909 елгы 9 март (373) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Габдулла Тукайның «Алтын әтәч» исемле китабы беренче тапкыр 1908 елда (Казан: «Сабах» көтебханәсе, И.Н.Харитонов мәтбагасы. Мәктәп мөкяфәте, 2 нче китап), икенче тапкыр 1909 елда («Сабах» көтебханәсе, И.Н.Харитонов мәтбагасы) басылган. Сүз 1909 елгы басма турында бара.
172 бит.
Яңа әсәрләр. («Җир йөзе».) «Йолдыз»ның 1909 елгы 19 март (377) санында «Яңа әсәрләр» бүлегендә «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.

1 Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдшакир Габдерәхими – Гали Рәхим. Аның «Җир йөзе» исемле китабы 1909 елда Казанда басылып чыга, титул битендә «Русча «Кругом света»

исемле китаптан вә башка әсәрләрдән икътибас идәрәк язылмыштыр» дип искәрмә бирелгән.

174 бит.
Яңа әсәрләр. («Безнең Казан». Казан выставкасының рәһбәре.) «Йолдыз»ның 1909 елгы 23 март (378) санында «Г.К.» имзасы белән басылган. Текст «Йолдыз»дан алынды.
1909 елның 3 июнь – 16 августында Казанда губерна земствосы тарафыннан әзерләнгән күргәзмә – «Областная выставка» үткәрелә. Анда Россия шәһәрләреннән, Казанның үзеннән, чит илләрдән төрле компанияләр, ширкәтләр катнаша, техника һәм промышленность яңалыклары күрсәтелә. Күргәзмәгә әзерлек көннәрендә нашир һәм редактор Шәрәфетдин Шәһидуллин «Безнең Казан» исемле игълан-реклама китабы чыгара (И.Н.Харитонов мәтбагасы, 1909). Анда халыкара күргәзмәләрнең тарихы, Казандагы төрле сәүдә ширкәтләренең, компанияләрнең игъланнары урын алган. Г.Камал рецензиясендә сүз шул китап турында бара.

175 бит.
Җәйге мәктәпләр, яхуд мәктәпләрнең җәйләүләре. «Йолдыз»ның 1909 елгы 28 апрель (392) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.

178 бит.
Иван Николаевич Харитонов. «Яшен»нең 1909 елгы 24 июнь (10), «Йолдыз»ның 1909 елгы 25 июнь (415) саннарында басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.

1 Университет һәм Чиркова мәтбагалары – рәсми рәвештә 1809 елда ачылган Казан дәүләт университеты типографиясе XIX гасыр дәвамында татар наширләренең күп заказларын үтәгән. XIX гасырның икенче яртысында татар китапларын күпләп бастыру буенча М.Чиркова варислары мәтбагасы Казан дәүләт университеты типографиясеннән генә калышкан.
2 ... уналтынчы һәм егерменче нче хәрефләр – басма хәрефләрнең зурлыклары гадәттә номерлап йөртелә (уналтынчы номерлы кегель, егерменче номерлы кегель һ.б.).
3 ... мәтбага ачып, эшкә кереште. – И.Н.Харитоновка типография ачуга рөхсәтне Казан губернаторы 1896 елның 13 февралендә биргән.
4 Литография – яссы таш өстенә төшерелгән рәсемнән басма ала торган ханә (предприятие, цех).
5 Гальванопластика – әйбернең төгәл металл копиясен алу өчен, электр тогы тәэсирендә металлны аның тозлары эремәсеннән аерып, шул предмет өстенә утырту ысулы.
1910
181 бит.
Мөселман студентларымыз. «Йолдыз»ның 1910 елгы 10 март (513) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
1 «Йолдыз»ның шул ук елгы 15 март (515) санында Габдрахман Мостафаның (Мостафинның, 1886–1916) 11 март көнендә язылган хаты бирелгән. Анда ул газетаның мөхәррире Һади Максудига мөрәҗәгать итә һәм болай дип яза: «Сезнең «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» шәкертләре исеменнән миңа ярдәм диеп җибәргән утыз ике сум алтмыш бер тиен акчагызны алдым. Иске иптәшләрем вә шәкертләремнең мине онытмай, минем өчен читтән генә булса да әйтелгән сүзне ишеткәч тә булышырга хәзер торуларына бик шатланам. Ләкин минем шикелле үк үзләренә ярдәмгә мохтаҗ булган шәкертләрнең акчаларын алып, үз кирәгемә тотуны вөҗданым тәхмил итмәгәнлектән, һиммәтләренә рәхмәт укып, акчаларын үзләренә кайтаруыңызны үтенәмен. Шаять, анлар бу акчаларын

башка файдалырак урынга сарыф итәрләр». Хатка өстәмәсендә автор яхшы теләктә булуы өчен Г.Камалга рәхмәт белдерә.
Г.Мостафин Х.Ямашевның якын дусты була. 1912 елда Х.Ямашевны күмгән вакытта, аның тормыш юлы, иҗтимагый эшчәнлеге турында зур речь белән чыга. «Кояш» газетасында «Хөсәен Ямашевны искә төшерү» дигән мәкалә дә бастыра (1913, 13 март, № 70).
Г.Мостафин, Казан дәүләт университетын тәмамлап чыккач, врач булып эшләгән.
2 Әхмәт бай – Әхмәт бай Хөсәенев, Оренбург сәүдәгәре.
184 бит.
Күрше тавыгы күркә булып күренә! «Йолдыз»ның 1910 елгы 10 март (513) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.
Мәкалә татар театр тәнкыйтьчесе Г.Кәрамның «Йолдыз»дагы 1910 елгы 3 гыйнвар (486) санында басылган «Шәрекъ клубы» исемле публицистик чыгышы уңае белән язылган.
1 Ризаэтдин казый – Риза Фәхретдинев.
2 Оренбург җәмгыяте исламиясе ... – Оренбург шәһәр мөселманнары җәмгыяте, ул культура-агарту эшләре, мәктәпләр, китапханәләр ачу, әдәби кичәләр уздыру белән шөгыльләнгән.
3 Хәсәнгата казый – Хәсәнгата Габәши (1863–1930); берничә тарих китабы авторы, төрле аң-белем тарату җәмгыятьләрендә һәм рухани идарәдә җәмәгать эшләре алып барган.
4 «Асаре гатика җәмгыяте» – Казан дәүләт университеты каршындагы «Археология, тарих, этнография җәмгыяте», 1878–1928 елларда эшләгән.
188 бит.
Яңа әсәрләр. [«Яшьләр», «Кыямәт».] «Йолдыз»ның 1910 елгы 14 март (514) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.
Фатих Әмирхан «Яшьләр. (Татар тормышының алмашыну көннәрендә)» пьесасын 1909 елның 24 июлендә язып тәмамлаган, һәм ул 1910 елда Казанда «Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан «Театру мәҗмугасе» сериясеннән 9 нчы китап рәвешендә басылып чыккан, шул ук елның феврале башларында сатыла башлаган.
Гаяз Исхакыйның 1909 елда язылган «Кыямәт» комедиясе Казанда (нашире – Х.Әбүзәрев) 1910 елның 18 февралендә дөнья күргән.

190 бит.
Миссионерлар фикере. «Йолдыз»ның 28 март (520) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.
Сәясәтче, хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, II һәм III Дәүләт Думалары әгъзасы Садри Максуди III Дәүләт Думасының 1910 елгы 20 февраль утырышында миссионерларга каршы чыгып сөйли. Аның бу нотыгы «Йолдыз»ның 1910 елгы 12 март (515) санында басылып та чыга.
Казанда миссионерлар тарафыннан 1909–1911 елларда чыгарылган «Сотрудник Братства св. Гурия» исемле атналык журналның 1910 елгы 20 март (16) санында «Русский» имзалы берәү, Садри Максудиның бу нотыгыннан зарланып, «Беспокойство С.Максудова» дигән мәкалә бастыра. «Йолдыз»ның 1910 елгы 24 март (519) санында «Миссионер фикере» исемле мәкаләдә «Русский»ның чыгышыннан өзекләр китерелгән. Г.Камалның бу мәкаләсе әнә шул мәкалә һәм чыгышлар уңае белән язылган.

1 Учительская школа – татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләре өчен татарлардан урта педагогик белемле укытучылар әзерли торган мәктәп. Казанда 1876 елда ачылган.
2 Учительский институт – Казанда 1876 елда ачылган уку йорты; Казан дәүләт педагогия институтының тарихы шуннан башланган.

194 бит.

«Мөгаллим». «Йолдыз»ның 1910 елгы 23 июнь (55) санында «Яшенче» имзасы белән басылган.

195 бит.
«Хисап мәсьәләләре». «Йолдыз»ның 1910 елгы 25 ноябрь (614) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.
Рецензиядә сүз Мөхетдин Корбангалиевнең «Хисап мәсьәләләре һәм гадәди мисаллар» (Казан, 1910) исемле китабы турында бара.
1911
197 бит.
Мәктәп вә мәдрәсәләремез. «Йолдыз»ның 1911 елгы 6 март (653) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

1 Иске Му, Казаклар исемле карьяләрдә ... – хәзерге Арча районына керә торган авыллар.
2 ... Сикертән, Гөберчәк, Чөмә-Елга, Өчиле, Симетбаш, Курса Почмак ... – хәзерге Арча районына керә торган авыллар.
3 Казан өязенә хәзерге Биектау, Питрәч, Лаеш, Балык Бистәсе районнары, Арча, Саба районнары, Яшел Үзән районының бер өлеше кергән.
199 бит.
Сабан туе. «Йолдыз»ның 1911 елгы 21 апрель (673) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.
201 бит.
Мәтбага исляхаты. «Йолдыз»ның 1911 елгы 3 май (678) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.
203 бит.
Имля вә хоруф мәсьәләсе. «Йолдыз»ның 1911 елгы 7 июнь (693) санында «Галиәсгар Камал, Гыймад Нугайбәк» имзасы белән басылган.
1 ... нәмүнәләре вөҗүдкә чыкты. – «Шура» журналының һәм «Вакыт» газетасының наширләре, алтын приискалары хуҗалары, җәмәгать эшлеклеләре, агалы-энеле Мөхәммәдшакир (1857–1912) һәм Мөхәммәдзакир (Дәрдемәнд. 1859–1921) Рәмиевләр, 1911 елда Оренбургта «Хатты табагать, яхуд аеры хәрефләр» исемле китап бастырып, гарәп хәрефләрен беркадәр үзгәртү буенча үзләре иҗат иткән хәреф рәсемнәрен тәкъдим итәләр. Ләкин җәмәгатьчелек бу хәрефләрне кабул итми.
206 бит.
Эч пошканда. «Йолдыз»ның 1911 елгы 30 июнь (703) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.
1 ... нә Дума бар, нә Совет бар. – Фельетон III Дәүләт Думасы һәм Дәүләт Советы (Россия империясендә законнар тикшерүче, ә 1906 елдан соң законнар чыгаруга хокукы булган югары учреждение) җәйге ялга туктаган чагында язылган.
2 Мөселман фракциясе – III Дәүләт Думасы әгъзалары арасында ун мөселман депутаты була. Мөселман фракциясенә исә шуларның сигезе кергән.
3 Пуришкевич В.М. (1870–1920) – монархист, II–IV Дәүләт Думалары депутаты, анда монархистик рухтагы нотыклары белән «танылган» кеше.
4 ... төрекләр белән арнаудлар сугышып яталар ... – 1910–1911 елларда албан халкының Төркия хакимлегенә каршы көрәше турында сүз бара.
5 ... Фас мәмләкәтенә басып кергәннәр дә аны бүлмәкче булалар ... – XIX йөзнең 40 нчы елларыннан алып Мароккода үзенең йогынтысы белән файдаланган Франция XX йөз башында бу йогынтыны тагын да көчәйтә. Марокконы бүлү өчен көрәшкә Франция белән бергә Испания, Германия, Англия дәүләтләре кушылалар. Әлеге вакыйга көчле халыкара конфликт китереп чыгара.
208 бит.

Ашыгып эшләнмәс! «Йолдыз»ның 1911 елгы 5 июль (705) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.
1 Каргалы – хәзерге Чистай районына керә торган авыл.
2 Күпер земский – земстволар – Россиядә 1864 елгы реформа нигезендә төзелгән җирле үзидарә органнары; юллар төзү, күперләр, больницалар салу, мәктәпләр ачу, уку-укыту шикелле җирле хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Хөкүмәт тарафыннан акча бүленмәгәнлектән, аларда эш халыктан җыйган салымнар хисабына гына алып барылган, җитәкчелек исә эре җирбиләүчеләр, фабрика-завод хуҗалары, сәүдәгәрләр кулында булган. Бу үзидарә органнары әкрен хәрәкәт итүләре белән «танылганнар».
3 «Җәмгыяте хәйрия» – Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр мәктәп-мәдрәсәләргә, укучыларга, авыруларга, картларга ярдәм итү максаты белән либераль позициядә торган кешеләр тарафыннан оештырылган җәмгыять. Мондый җәмгыятьләрнең эшчәнлеге Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендә дә тәнкыйть ителде.
4 «Җәмгыяте хәйрия» файдасына сабан туе ясалган иде. – 1911 елда Казанда сабан туе 20 майда башланып, бер атна дәвам иткән.
5 Дума татарская – Казан шәһәр думасының татар гласныйларыннан торган өлеше.
210 бит.
Татарча театр. (Киләчәк җомга ...) «Йолдыз»ның 1911 елгы 4 октябрь (739) санында «Яшенче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1 «Новый клуб» – Казанның хәзерге Горький урамында К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры урнашкан бина.
2 «Сәйяр» труппа – 1906–1907 елларда оеша башлаган беренче татар профессиональ театр труппасы. 1908 елдан «Сәйяр» исеме белән йөртелә башлый. 1907 елда Мәкәрҗәдә труппага Габдулла Кариев кушылганнан соң, бу труппа чын милли театр дәрәҗәсенә күтәрелә һәм тиз арада халыкның мәхәббәтен казана.
3 «Күз яше» – Ярулла Вәлинең «Оят яки Күз яше» исемле дүрт пәрдәлек драмасы.
4 «Дачада» – Гали Рәхимнең «Дача кайгысы» исемле ике пәрдәлек комедиясе. Комедия 1914 елда Казанда (Хөсәеневләр мәтбагасында) басылып чыга.
5 Г.Кариев ... Петербургка киткән. – Ул бу баруда Г.Камалның «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» пьесаларын сәхнәдә кую өчен рөхсәт алып кайта.

1912
211 бит.
Мәтбагачылыкта тәрәкъкый. «Йолдыз»ның 1912 елгы 3 гыйнвар (787) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.
1 Кәримевләр мәтбагасында ... – Казанда бертуган Кәримевләр тарафыннан 1900 елда ачылган.
2 Габделмәннан Рәхманкулов – соңыннан Кәримевләр типографиясе управляющие.

213 бит.
Әдәби бәхәсләр. «Йолдыз»ның 1912 елгы 5 февраль (789) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

216 бит.
Дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең намен таәбид итү хакында. «Йолдыз»ның 1912 елгы 26 февраль (798) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.

1 Гәзитәләрдә ... итү мәсьәләсе кузгалган иде. – «Йолдыз»ның 1911 елгы 20 сентябрь (733) санында, мәсәлән, Казан яшьләренең Ш.Мәрҗани вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәте белән аның шәрәфенә берәр эш эшләү турында сөйләшүләре, җыентык

чыгарырга карар бирүләре турында хәбәр басыла. «Идел» газетасында да шул рухтагы берничә мәкалә басылган (1912 елның 21 февраль, 2 март, 9 март саннарында).
2 «Вафиятел-әсляф» – Ш.Мәрҗанинең алты кисәктән (җилдтән) торган биобиблиографик әсәре. Басылмаган. Кулъязмасы Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсендә саклана.
3 «Идел» гәзитәсендә ... киңәшләр булганлыгы күренде. – Бу киңәшләр газетаның 1912 елгы 21 февраль (429) санындагы «Шиһаб хәзрәт Мәрҗани җәнабләренең юбилее мәсьәләсенә даир» исемле имзасыз мәкалә эчендә басылган.
«Идел» – 1907–1914 еллардагы Әстерханда чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета.
4 Борһанетдин хәзрәт – (1856–1916).
5 ... сәнәи камәрия ... – ай яңаруы буенча хисапланган ел; өч йөз илле дүрт яисә өч йөз илле биш көннән генә торганга, һәр елны узган елгыдан унике яки унөч көнгә иртәрәк башлана.

218 бит.
Хөсәен әфәнде Ямашевның җеназа мәрасиме. «Йолдыз»ның 1912 елгы 20 март (808) санында «Г.К.» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Мәкаләдә 1912 елның 17 мартында Хөсәен Ямашевны олылап күмү вакыйгасы тасвир ителә.

220 бит.
Татарча театр. (Өченчекөн «Новый клуб» ...) «Йолдыз»ның 1912 елгы 22 апрель (822) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.
Рецензиядә аталган пьесалар 1912 елның 20 апрелендә уйналган.

1 «Новый клуб» – 363 биттәге искәрмәне карагыз.
2 ... Ярулла әл-Вәлинең «Ачлык кушты» нам драма ... – Я.Вәлинең бу драмасы 1908 елда Казанда «Шәрекъ» көтебханәсендә басылып чыга.
3 ... труппаның «Шәрекъ клубы»нда уйнаган заманнарында ... – «Сәйяр» 1911–1914 елларның кышкы сезоннарын «Шәрекъ клубы» каршындагы стационарда эшли.
4 ... дүрт ай мөддәтендә режиссер булып торганлыгымнан... – 1911–1912 елгы сезонда Г.Камал «Сәйяр» труппасында режиссер вазифасын үти.
221 бит.
Кыз сату. «Йолдыз»ның 1912 елгы 22 апрель (822) санында «Үз хәлемездән» бүлегендә «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.
1 ... «Ачлык кушты» исемле бер пьесаны тамашага куйганнар иде. – Я.Вәлинең бу пьесасы «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1912 елның 20 апрелендә уйнала.
2 Сәрдә авылы хәзерге Татарстан Республикасының Әтнә районына керә.
224 бит.
Русча мөселман гәзитәсе. «Йолдыз»ның 1912 елгы 24 апрель (823) санында «Үз хәлемездән» бүлегендә «Г.Камал» имзасы белән басылган.
Мәкаләдә сүз 1911 елның 3 апреленнән 1912 елның 20 апреленә кадәр (барлыгы кырык дүрт сан) Петербургта «В мире мусульманства» исеме белән рус телендә чыккан атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета турында бара. Газетаның 1–31 саннарының редакторлары – Хаҗитләши М.Б. һәм Датиев А.Г., 32 нче саннан – Датиев А.Г.
225 бит.
Яңа әсәрләр. (Бу көннәрдә безнең өчен ...) «Йолдыз»ның 1912 елгы 13 май (831) санында басылган. Текст шуннан алынды.
1 «Харитон бабай» ... – И.Н.Харитонов, типография хуҗасы.

2 ... «Ак чәчәк» бәйрәме ... – революциягә кадәр кайбер шәһәрләрдә үпкә авыруына каршы җәмгыятьләр оеша. Казандагы шундый җәмгыять 1912 елның 5 маенда Ак чәчәк бәйрәме уздыра. Ул көнне хатын-кызлар ак чәчәкләр сатып йөриләр, үпкә авырулыларны савыктыруга ярдәмгә иганә җыялар. Г.Камал, бу эшкә татарларны да катнашырга чакырып, «Йолдыз»ның 1912 елгы 19 апрель (821) санында бер мәкалә дә бастыра (Ак чәчәк бәйрәме мөнәсәбәте илә).
227 бит.
Хәрефләр исляхы. «Йолдыз»ның 1912 елгы 10 июнь (845) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

1 Петр Великий ... гражданский хәрефләр кертте. – 1711 елда рус алфавитына беркадәр үзгәрешләр кертелә: искергән билгеләр юкка чыгарыла, яңа язылыштагы хәрефләр кертелә. Бу – чиркәү-славян шрифтын дөньяви (гражданский) басмалар өчен көйләү максатыннан чыгып эшләнгән.
229 бит.
Бакча-шәһәр. «Йолдыз»ның 1912 елгы 10 июль (855) санында басылган.
1 ... Кизический слободаның ... – революциягә кадәрге Казандагы бистә, Казан елгасының уң ярында урнашкан булган (хәзерге Иске Аракчино тирәләре).

232 бит.
Мөселман рәссам. «Йолдыз»ның 1912 елгы 6 сентябрь (877) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Йолдыз»дан алынды.

1 Буннан ике ел мөкаддәмдә ... кырык ел тулу мөнәсәбәте илә ясалган юбилейда ... – шушы томдагы «Иван Николаевич Харитонов» исемле мәкаләне һәм аңа бирелгән искәрмәне карагыз.
Юбилей «ике ел мөкаддәмдә» түгел, бәлки өч ел элек үткәрелгән. Монда ялгышлык.
2 Сабит Яхшыбаев Казанга Г.Кариевның чакыруы буенча килә һәм 1912–1913 еллар сезоныннан башлап «Сәйяр»дә рәссам булып эшли башлый, күп кенә спектакльләргә («Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Тигезсезләр» һ.б.) декорацияләр ясый.

234 бит.
Үз хәлемез. «Йолдыз»ның 1912 елгы 21 август (871) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1 Мөфти хәзрәтнең юбилее шәрәфенә дарелмөгаллимин вә дарелмөгаллимат ачарга карар бирелгән иде. – 1911 елның февралендә мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның егерме биш ел мөфтилек кылуының юбилеен билгеләп үтәләр. Шул мөнәсәбәт белән ирләр һәм кызлардан укытучылар хәзерләү мәктәпләре ачарга карар чыгарыла, ләкин бу карар тормышка ашмый кала, әлеге мәктәпләр ачылмый. Бу эш өчен җаваплы комитет әгъзалары да берничә җыелыш үткәрүдән артык эш эшләмиләр.
Дарелмөгаллимин комитеты Г.Камалның «Үз хәлемездән» исемле мәкаләсендә дә тәнкыйть ителә (Йолдыз. 1912. 30 октябрь. № 900. «Г.К.» имзасы белән).

235 бит.
Үз хәлемездән. «Йолдыз»ның 1912 елгы 1 ноябрь (901) санында «Г.К.» имзасы белән басылган.

237 бит.
Мәрхүм Әхмәд Мидхәд әфәнде. «Йолдыз»ның 1912 елгы 23 декабрь (921) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган. Мәкаләнең исеме астына «Хосусый мөхбиребездән» дигән искәрмә куелган. Текст «Йолдыз»дан алынды.

1912 елның ноябрендә Г.Камал «Йолдыз» газетасының махсус хәбәрчесе сыйфатында Төркиягә китә һәм Төркиянең шул чактагы хәлен чагылдырган «Истанбул мәктүбләре» җибәреп тора (бу мәкаләләр «Йолдыз»ның 1912 елгы декабрь һәм 1913 елның гыйнвар саннарында басылганнар). «Мәрхүм Әхмәд Мидхәд әфәнде» мәкаләсе дә Г.Камалның Төркиядән язып җибәргән шундый мәкаләләреннән булып, анда сүз төрек әдәбиятында роман һәм новелла жанрына нигез салучы әдип, мәгърифәтче, тарих, дин, философия, география мәсьәләләренә багышланган китаплар авторы Әхмәд Мидхәд (1844–1912) турында бара.

239 бит.

Истанбул мәктүпләре. Бу исемдәге мәкаләләр (репортажлар, очерклар) «Галиәсгар Камал», «Г.Камал» имзалары белән «Йолдыз» газетасының 1912 елгы 2 декабрь (912), 11 декабрь (916), («2 декабрь, 1912 сәнә»), 16 декабрь (918), 18 декабрь (919) («9 декабрь, 1912 сәнә»), 20 декабрь (920) («8 декабрь, 1912»), 23 декабрь (921) («17 декабрь, 1912 сәнә»), 30 декабрь (924) («19 декабрь, 1912 сәнә»), 1913 елгы 1 гыйнвар (925) («24 декабрь, 1912 сәнә»), 13 гыйнвар (930) («5 гыйнвар, 1913 сәнә»), 17 гыйнвар (932) («9 гыйнвар, 1913 сәнә»), 22 гыйнвар (934) («11 гыйнвар, 1913 сәнә»), 29 гыйнвар (937) саннарында басылганнар. Әнисә Алиева һәм Рәис Даутовлар тарафыннан әзерләнеп, алар «Казан утлары» журналының 1999 елгы дүртенче һәм алтынчы саннарында, «Галиәсгар Камал: әдип һәм заман» исемле, язучының йөз егерме биш еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгында (Казан, 2005) чыкты. Томга текстлар «Йолдыз» газетасыннан алынды.

«Йолдыз» газетасының 1912 елгы 25 ноябрь (909) санында «Мөхәррирләремездән Галиәсгар Камал Балкан вакыйгалары турындагы хәбәрләрне тәхкыйк кыйлу (яктырту) өчен Төркия һәм Болгария мәмләкәтләренә сәяхәткә китте» диелүгә нигезләнеп фикер йөрткәндә, Г.Камалның ерак сәфәргә Казаннан 24–25 ноябрьләрдә чыгып китүен әйтергә була.

«Казан утлары» журналы битләрендә текстлар Р.Даутовның түбәндәге кереш сүзе белән басылган иде: «1912 елның көзендә Балкан берлеге дәүләтләре (Болгария, Греция, Сербия, Черногория) белән Төркия арасында тарихта Беренче Балкан сугышы дип йөртелгән низаг башлангач, Казандагы «Йолдыз» газетасының нашире һәм мөхәррире Әхмәтһади Максуди газета идарәсендә сәркатиплек вазифасын башкаручы Г.Камалны Төркиягә махсус мөхбир (хәбәрче) итеп җибәрә. Русиядән әдип 1912 елның ноябрь ахырларында китеп (бу турыда «Йолдыз»ның 25 ноябрь санында хәбәр бирелгән), 1913 елның февраль башларына кадәр Истанбул шәһәрендә яши һәм Төркиядәге сугыш чоры вәзгыяте, халкының тормыш-көнкүреше, сугышка мөнәсәбәте, хөкүмәт даирәләренең эчке һәм тышкы сәясәте, төрле сәяси фиркаләр, аларның җитәкчеләре, үзара көрәшләре, Истанбул күренешләре, мәчетләр, музейлар, гаскәриләр һ.б. турында «Йолдыз» газетасына озын-озын мәкаләләр җибәреп тора. Әдип Төркиянең төрле даирә кешеләре белән очраша, алардан интервьюлар ала, гәнеҗ төрекләр (яшь төрекләр) фиркасе «Иттихад вә тәрәкъкый»ның лидеры Әнвәр пашаны күрү өчен аның өенә бара, әмма өендә тота алмый, фәкать аның этисе белән генә күрешеп сөйләшә. Г.Камал Русиянең Төркиягә булган янаулы сәясәте турында, Көнбатыш илләре (Англия, Франция, Италия) белән яшерен иттифакка кереп, авыр икътисади һәм сәяси хәл кичергән Төркияне бүлгәләү, Истанбулны үзенә буйсындыру хыялы белән әвәрә килеп йөрүен дә сиздереп уза.

Әсәрдә бик күп тарихи исемнәр, шәһәрләр, географик урыннар, сугышлар телгә алына. Журнал басмасында, табигый, алар хакында тәфсилле аңлатмалар биреп булмый. Ахыр чиктә кызыксынган укучылар алар турында теге-бу күләмдәге мәгълүматларны үзләре дә таба алырлар дип уйлыйбыз.

«Йолдыз» газетасында «Истанбул мәктүпләре» исемле мәкаләләр 1913 елның маена кадәр басылып торган, ләкин аларның авторы  инде башка кеше, газетаның хосусый мөхбире (хәбәрчесе) – Г.Әбүзәри (Әбүзәрев).

1913–1915
285 бит.
Яңа елда ни телисез? (Галиәсгар Камал җавабы.) «Аң»ның 1913 елны 17 ноябрь (22) санында басылган.
1 Мөхәммәднең Мәккәдән Мәдинәгә качуы вакытыннан исәпләнеп йөртелә торган ел хисабы буенча 1332 ел (милади белән 1913 елның 17 ноябренә туры килә) уңае белән «Аң» журналы редакциясе 1913 елгы 17 ноябрь (22) санында Казандагы татар журналистларына һәм язучыларына «Яңа елда ни телисез?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Җавап шушы уңай белән язылган. Әлеге санда Ф.Әмирхан, Г.Кариев, Г.Кәрам, Ф.Агиев, Г.Газиз, Г.Шәрәф, Һ.Максуди һ.б.ларның җаваплары да урнаштырылган.

286 бит.
Идарәгә мәктүбләр. «Кояш»ның 1 апрель (376) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган, имза янына «1914, 31 март» дип дата куелган.
1914 елның 21 мартында «Сәйяр» труппасы артистка Гөлсем Болгарскаяның бенефисына «Шәрекъ клубы»нда А.Н.Островскийның «Гроза»сын (Г.Камал тәрҗемәсе) сәхнәгә куя. Шушы уңай белән Г.Кәрам «Кояш» газетасының 1914 елгы 30, 31 март (374, 375) саннарында «Гроза» исемле зур мәкалә язып бастыра. Г.Камал мәктүбе Г.Кәрамга җавап рәвешендә язылган.
1 ... дип тәрҗемә кыйлынган. – Г.Камал дөрес әйтә. (Кара: Островский А.Н. Гроза. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1914.)

287 бит.
«Саран» пьесасы хакында. «Йолдыз»ның 1915 елгы 15 октябрь (1530) санында бер өлеше «Г.Камал», соңгы бер абзацы «Г.К.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.
Г.Камал пьесаны 1914 елда Казанда И.Н.Харитонов мәтбагасында «Саран» (комедия биш пәрдәдә, Т.Касбардан тәрҗемә) исеме белән аерым китап итеп бастырып чыгара.
Пьеса 1915 елның 5 октябрендә Оренбург сәхнәсендә куела. Әсәрнең чыгуы һәм сәхнәдә куелуы уңае белән Кәбир Бәкер «Вакыт» газетасының 1915 елгы 10 октябрь (1886) санында «К.Б.» имзасы белән «Татарча театр» исемле мәкалә бастыра. Мәкаләдә «Саран»ның атаклы француз драматургы Мольер (1622–1673) комедиясе булуы күрсәтелә. Г.Камалның бу мәкаләсе К.Бәкер мәкаләсенә аңлатма бирү рәвешендә язылган.

1 Балкан сугышы вакытында «Йолдыз»ның мөхбире сыйфаты илә ... – Балкан сугышы 1912 елның 9 октябреннән алып 1913 елның маена кадәр Төркия белән Болгария, Сербия, Черногория арасында була. Г.Камал Төркиягә (Истанбулга) 1912 елның 25 ноябрендә китә, 1913 елның февралендә (авырып китү сәбәпле) Казанга кайта.
2 «Дөхтәре һинд», «Әшбәр», «Тәзәр» – төрек әдибе Габделхак Хәмид әсәрләре, 1875–1881 елларда иҗат ителгәннәр.
3 Плюшкин – Н.В.Гогольнең «Үле җаннар» поэмасыннан мәшһүр образ.
1919–1933
289 бит.
Татар театры. (Үткән җомга көн Кызылармиялеләр сараенда ...) «Эш» газетасының 1919 елгы 2 февраль (159) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган.

1 ... җомга көн ... – 1919 елның 1 феврале.
2 Кызылармиялеләр сарае... – хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасы ул елларда шулай дип аталган.
3 «Икенче кат яшьлек» – рус язучысы П.М.Невежинның «Вторая молодость» пьесасы. Г.Камал тәрҗемә иткән.
4 Әхмәрева – Заһидә Тинчуринаның кыз вакытындагы фамилиясе. Ул Гражданнар сугышы елларында артистка буларак сәхнәдә дә чыгышлар ясый.

291 бит.
Дингә хезмәт итүчеләр арасында. «Татарстан» газетасының 1923 елгы 12 декабрь (235) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

1 Зәкят һәм фидияләр – мал-мөлкәт хисабыннан чыгып ярлы мөселманнар өчен бирелә торган салым, сәдака. Ул Коръән сүзләре белән законлаштырылган.
2 Адес – Одесса.

292 бит.
«Һинд кызы». «Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 30 октябрь (210) санында «Театрларда» дигән рубрика астында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

1 Дәүләт татар театры – хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры.
2 «Һинд кызы» – төрек әдибе Габделхак Хәмиднең Г.Камал тәрҗемә иткән әсәре.

293 бит.
«Ислам» журналы. «Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 5 ноябрь (214) санында «Г.Камал» имзасы белән басылган.

1 Диния нәзарәте – эчке Россия һәм Себер мөселманнарының дини идарәсе.
2 «Ислам» – «Ислам» мәҗәлләсе (журналы). Уфада айга бер мәртәбә чыга торган дини, әхлакый һәм фәлсәфи журнал. 1924–1927 елларда чыгарыла.
3 Зыя Кәмали – Пәрвәзетдин Кәмалетдинов.

294 бит.
Күчәр башы. «Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 22 декабрь (251) санында «Г. һәм Камал» имзасы белән басылган.
1 Печән базары – Казандагы Киров һәм Париж Коммунасы урамнары чатындагы базар. Чат башындагы мәчет янын «Көфер почмагы» дип йөрткәннәр. Бу гайбәт оясы булып, иске фикерле татар сәүдәгәрләре, динчеләр шунда җыелып, «яңалар»дан көлеп, хатын-кызны хурлап кала торган булганнар. Шул ук вакытта бу урын пычраклыгы белән дә дан тоткан. Печән базары революциядән соң да шактый еллар яши.
2 «Васита» ширкәте – Казанда китап басу һәм сату белән шөгыльләнгән ширкәт (җәмгыять).

296 бит.
Ислам, хәлифәлек мәсьәләсе һәм империалистлар. «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 елгы 27 март (66) санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. Мәкаләнең ахырына «Бу мәкаләнең бер җире дә үзгәртелмичә басыла. Редакция» дип куелган.

1 Гарәбстан – мәкаләдә Согуд Гарәбстаны күз алдында тотыла.
2 Европа сугышы – 1914–1918 елгы Беренче бөтендөнья сугышы күздә тотыла.
3 Нәҗет – Согуд Гарәбстанындагы провинция.
4 Ваһһабиләр – гарәп илләрендә XVIII гасыр азагында барлыкка килгән дини-социаль агым тарафдарлары. Нәҗдә шәһәрендә (Үзәк Гарәбстан) күчмә кабиләләр – бәдәвиләр арасында Мөхәммәд ибн Габделваһһаб диннең сафлыгын яклап вәгазьләр сөйли. Ул һәм аңа иярүчеләр – ваһһабиләр – исламның борынгы «рәвеше»н кайтаруны, бер Аллага гына ышануны таләп итеп, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм изгеләргә табынуга каршы чыгалар. Бу тәгълиматны Нәҗдә феодаллары бәдәвиләрне Мөхәммәд ибн Согуд җитәкчелегендә берләштерү өчен идеологик корал итеп файдаланганнар.

5 «Кәнеж төрекләр» – «Яшь төрекләр», Төркиядә шул исемдәге партия.
6 «Иттихадчылар» – Төркиядә «Иттихад» («Бердәмлек») исемендәге партия тарафдарлары.
7 «Кәмалчы динсезләр» – Төркиядәге Мостафа Кәмал (1881– 1938) яклы кешеләр. М.Кәмал – Төркия Республикасына нигез салучы һәм аның беренче президенты.
8 Хитталылар – хәзерге Кече Азия территориясендәге борынгы дәүләт кешеләре.
9 Истанбул хәлифәлеге – Мисыр солтаннары, Гарәбстанны буйсындырганнан соң, үзләренә мөселман диненең башлыгы – хәлифә титулын да алалар. Төрек солтаннары хәлифә булган чорны автор шулай – Истанбул хәлифәлеге дип атый.
10 Мәккә – Согуд Гарәбстанының иң борынгы шәһәрләреннән берсе, бөтендөнья мөселманнарының хаҗга бара торган изге урыннары.
11 Хиҗаз – Мәккә, Мәдинә шәһәрләре урнашкан өлкә.
12 «Каб» мөселманнары ... – кыбытыйлар (русча – кобты) – борынгы Мисыр халкына караган төркем.
13 Вахидеддин – 1918 –1922 елларда төрек солтаны булып идарә итә. Төркиядә солтанлыкны бетергәннән соң, 1922 елның 1 ноябрендә Төркиядән кача.
14 Шәйхелислам – солтан Төркиясендә руханилар башлыгының титулы, ягъни Истанбулның баш мөфтие. Ул солтанның вәзире дәрәҗәсендә торган һәм аның иң мөһим фәрманнарына ризалыгын биргән. 1924 елда Төркия Республикасы хөкүмәте шәйхелислам титулын бетерде.
15 Мөхәммәд – (570 ел тирәсе – 632), гарәп дөньясының дин һәм дәүләт эшлеклесе.
16 Сәхабәләр – Мөхәммәднең юлдашлары, аны күреп белгән замандашлары.
17 Әбүбәкер – (573–634 еллар) гарәпләрнең беренче хәлифәсе. Мәккәдә туган, корәеш кабиләсеннән; зур сәүдәгәр һәм казый булган. Байлыгы һәм үз нәселе тарихын яхшы белүе аркасында аның җирле халыкка йогынтысы зур була. Ул – Мөхәммәднең актив тарафдары. Әбүбәкернең кызы Гайшә – Мөхәммәднең хатыны. Һиҗрәттән соң бирелә мөһаҗирләрдән – күчеп килүчеләрдән торган община оеша; аның башында Мөхәммәд белән бергә сәүдәгәрләрдән Әбүбәкер һәм Гомәр торган. Мөхәммәд үлгәннән соң, 632 елда Әбүбәкер хәлифә итеп сайлана. Үләр алдыннан, 634 елда, ул Гомәрне үзенең варисы итеп игълан итә.
18 Гомәр – (591 ел тирәсе – 644), икенче хәлифә. 634–644 елларда хәлифә булып тора.
19 Госман – (656 елда үлә), өченче хәлифә. 644–656 елларда хәлифә булып тора.
20 Гали – Гали ибн Әбүталиб (661 елда үлгән), 656–661 елларда идарә иткән дүртенче хәлифә.
21 Мөгавия – Галидән соң тәхеткә утырган хәлифә. Өмәвиләр династиясенә (661–750) нигез салучы һәм аның беренче хәлифәсе.
22 Язид – өмәвиләрдән икенче хәлифә, 680–683 елларда идарә итә.
23 Габбасилар – (750–1258), өмәвиләрдән соң хәлифәлек тәхетенә утырган гарәп хәлифәләре династиясе. Мөхәммәднең әтисенең энесе Габбастан башланган.
24 Сәлҗукилар – (1055–1118) сәлҗук төрекләре. Төрки-угыз (төрекмән) кабиләләренең берсенең исеме.
25 Госманнар – Төркия дәүләтенә нигез салучы Госман (1258 ел тирәсе – 1324 яки 1326) исеме белән төрекләр «госманнар», «госманлылар» дип тә аталалар.

303 бит.
Әзәрбәйҗан драматургы Мирза Фәтхегали Ахундов. «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 11 март санында «Галиәсгар Камал» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1 М.Ф.Ахундов 1878 елның 10 мартында (искечә стиль) үлә. «Иртәгә» дигән сүз ялгыш киткән. Күрәсең, мәкалә алданрак әзерләнгән булган.
2 Төньяк татарлары – Урта Идел һәм Урал буе татарлары күздә тотыла.

3 Безнең яшь театрыбыз Фәтхегали бабаның әсәрләреннән бик озак вакытларга кадәр файдаланып килде. – М.Ф.Ахундов пьесаларының татар сәхнәсендә уйналуы турында мәгълүматлар очрамады. Г.Камал аның әсәрләреннән иҗади файдалануга ишарә ясый булса кирәк.

305 бит.
Тыкшынмагыз! (Редакциягә хат.) «Кызыл Татарстан» газетасының 1929 елгы 26 апрель (193) санында басылган.
1929 елның язында Г.Камалның иҗат эшчәнлегенә утыз ел тулуы бәйрәм ителә. Ул бик күп оешмалардан, аерым кешеләрдән тәбрик хатлары, телеграммалары ала, аларга җавап итеп әлеге хатын яза.
Хат Г.Камалның моңарчы чыккан җыентыкларында кыскартып бирелгән. Текст газетадан алынды.

1 Гаяз әфәнде – Гаяз Исхакый күздә тотыла.

306 бит.
Тормыш юлым. «Совет әдәбияты» журналының 1933 елгы 4–5 санында басылган.
Мәкаләнең ахырына «Г.Камалның үзе тарафыннан 1931 елның 31 июлендә язылган автобиографиясеннән» дигән искәрмә бирелгән.
Текст «Совет әдәбияты»ннан алынды.

1 XIX гасыр өчен яңа стиль белән иске стиль аермасы – унике көн. Г.Камал, ул аерманы XX гасырдагыга тиңләп, унөч көн итеп санаган. Хәзер Г.Камалның туган көне дип 6 гыйнвар санала.
2 Сикертән – хәзерге Арча районындагы авыл.
3 Фәтхулла Мамаев – камчатчы сәүдәгәр; Галиәкбәрнең каенатасы Хәбибулла Мамаевның бертуган абыйсы.
4 «Госмания» – Казандагы Тихвинская (хәзерге Тукай) урамындагы мәдрәсә. Г.Камал яшәгән Маҗар Фазлый йорты (хәзер Тукай урамы, 5 нче йорт) белән янәшә булган.
5 «Халидия» – Казандагы Поперечная Мало-Мещанская (хәзерге Нариман урамы, 98 нче йорт урамындагы «Зәңгәр мәчет» мәдрәсәсе. (Казанның Иске Татар бистәсендә 1830 елда салынган бу мәчет бинасы хәзер дә исән. Ул архитектура истәлеге булып исәпләнә.)
6 «Мөхәммәдия» – Казандагы Тихвинская урамындагы (хәзерге Тукай урамы) мәдрәсә (Г.Баруди мәдрәсәсе). Казанда 1882 елда Галимҗан Баруди (Г.Галиев, 1859–1921) тарафыннан ачылган мәдрәсә (хәзерге вакытта профтехучилище; Тукай урамы, 34 нче йорт). Заманында татарның иң алдынгы мәдрәсәләреннән саналган. Г.Камал бу мәдрәсәгә 1893 елда укырга керә һәм 1900 елда аны тәмамлап чыга.
7 Хан – монда Әстерхан мәгънәсендә.
8 Мәкәрҗә – Түбән Новгород шәһәре янында ел саен була торган ярминкә.
9 «Зәваллы чуҗык» – «Кызганыч бала». Төрек әдибе Нәмикъ Кәмалның (1840–1888) «Зәваллы чуҗык» (1873) дигән пьесасыннан Г.Камал тәрҗемәсе.
10 Борадәран Шәрәфләр – Борһан һәм Гыйльметдин Шәрәфләр күздә тотыла.
11 Ә.Мостафин – Мөхәммәтәмин Мостафин, «Мәгариф» көтебханәсе ширкәте җитәкчеләреннән.
12 «Мәгариф» нәшрияты 1904 елда ачылган.
13 Алкин – Сәедгәрәй Алкин күздә тотыла.
14 Йосыф Акчура улы – Йосыф Акчурин (1876–1935), сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист; бала чагыннан ук Төркиягә китүе сәбәпле, ул гадәттә төрекчә генә сөйләшә һәм яза торган була.

15 «Йолдыз» ... гәзитәсе тукталганчы ... – «Йолдыз» газетасы 1906 елның 15 гыйнварыннан чыга башлап, 1918 елның 21 июнендә (барлыгы бер мең тугыз йөз сан чыкканнан соң) Совет хөкүмәте карары нигезендә туктатыла.
16 Мөселман социалистлар комитеты – М.Вахитов, Г.Сәйфетдинов инициативасы белән Казанда 1917 елның язында оештырылган милли революцион-демократик оешма.
17 «Совет Восточного фронта» – Көнчыгыш фронтның революцион хәрби советы.
18 Автор беркадәр ялгыша: аңа «Хезмәт батыры» исеме 1924 ел-да түгел, ә 1923 елның язында бирелә. (Татарстан. 1923. 5 май.)

308 бит.
Яза башлавым тарихы. Бу мәкалә башта «Г.Камал сүзе» дигән исем астында «Совет әдәбияты» журналының 1933 елгы гыйнвар (1) санында басылган. Мәкалә алдыннан бирелгән керештә Г.Камалның «... сүзе»н Татарстан совет язучылары союзының оештыру комитетының беренче киңәйтелгән пленумында сөйләгәнлеге әйтелгән. Әдип бу мәкаләне эшләвен дәвам иттергән. Алга («Минем язучылык, үземчә, кызык кына башланды» дигән җөмләгә кадәр) өзек өстәп, Г.Камал аның исемен үзгәрткән, һәм ул 1938 елда чыккан «Галиәсгар Камал әсәрләре» дигән җыентыкта «Яза башлавым тарихы» исеме белән басылып чыккан. Текст, нигездә, шуннан алынды. Ләкин, журнал варианты белән чагыштырылып, кайбер урыннарына төзәтүләр дә кертелде.

1 ... атам ... «Госмания» мәдрәсәсе ... күршесендә тора иде. – Хәзерге Тукай урамы, 5 нче йорт.
2 «Белек» – В.В.Радловның 1871 елда мәктәп балалары өчен басылып чыккан татарча уку китабы.
3 «Рисаләи Газизә» – үзе нугай ыруыннан булып, Бохарада яшәгән Суфи Аллаһиярның (1624 – 1713) «Сөбател-гаҗизин» («Аллага ялваруда ныклык») исемле китабына шәрех (киңәйтеп бирелгән аңлатмалар) итеп 1807 елда Таҗетдин Ялчыгол углы (1837 елда үлгән) тарафыннан язылган әсәр. Ялчыгол бу әсәрен үзенең Газизә исемле кызына багышлап язган һәм шуңа күрә «Рисаләи Газизә» («Газизә китабы») дип исем куйган.
4 Г.Ильясиның «Бичара кыз» драмасы беренче тапкыр – 1887 елда, ә Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы 1888 елда басылып чыгалар.
5 ... Ирек мәйданында ... ташпулат бар иде. – Казандагы рус драма театрының элеккеге бинасы. Соңыннан янып юкка чыга.
6 Мәкәрҗә ярминкәсе – элекке Түбән Новгород шәһәре янындагы Макарьеводa ел саен була торган ярминкә.
7 Мәрҗани мәдрәсәсе – Казанда Мәрҗани мәчете күршесендә ике катлы таш бинада бүгенге көндә Казан ислам көллияте урнашкан.
8 «Фра дьявол» – спектакль исеме.
9 «Садко» – Н.А.Римский-Корсаков операсы.
10 ... Насыйриның русча сүзлеген ... – 1904 елда Казанда басылып чыккан «Русча-татарча лөгать» күздә тотыла.
11 ... Миргаяз Иманаевтан русча укыйм. – Рус теле укытучысы Миргаяз Иманаев истә тотыла.
12 Шәехгаттар – Шәехгаттар Иманаев (1875 – ?), юрист, 1913 – 1914 елларда (барлыгы ун сан) Казанда чыккан «Хокук вә хәят» журналының мөхәррире; соңрак шәһәр судьясы, коллежский асессор.
13 «Фауст» – И.В.Гете әсәре.
14 Ш.И. – Шәехгаттар Иманаев.
15 Бр. Кәримевләр – борадәран Кәримевләр.
16 Н.Кәмалның «Зәваллы чуҗык» драмасы төрек телендә 1873 елда басылып чыккан.
17 «Бәхетсез егет» драмасының беренче варианты 1900 елда басылып чыга.
18 Г.Камал «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә 1893 – 1900 елларда укый.

19 Г.Баруди – Галимҗан Баруди (1859–1921), «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең хуҗасы-имамы.
20 ... иске зиярәт өстенә мәчет ... – Казанның хәзерге 5 нче шәһәр больницасы тирәсендәге урын. Әлеге мәчет 1914 елдагы янгын вакытында юкка чыга.
21 «Сарай» номерлары – Казанда Печән базары тирәсендәге кунакханә. Хәзерге Париж Коммунасы урамындагы 9 нчы номерлы бина.
22 Тимерша Соловьев (1875–1947), Оренбургта чыккан рәсемле көлке «Чүкеч» журналының нашире һәм мөхәррире булу өстенә Мәкәрҗә ярминкәсендә «Двухсветный» («Кушъякты») дип аталган ресторан да тоткан.
23 Приказчиклар клубы – хәзер Казанда Яшь тамашачылар театры урнашкан бина (А.Н.Островский урамы, 32 нче йорт).
24 «Беренче театр»ны язып ... – «Беренче театр» комедиясе 1908 елда язылып, шул ук елда «Гасыр» нәшрияты заказы белән И.Н.Харитонов типографиясендә басылып чыга. Сәхнәдә 1908 елның августында Мәкәрҗә ярминкәсендә уйнала.
25 «Бәхетсез егет»нең төзәтелгән икенче басмасы 1907 елда чыга. Сәхнәдә беренче тапкыр «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1908 елның 12 гыйнварында Уральск шәһәрендә куела.
26 «Саран» пьесасы, 1912 елда тәрҗемә ителеп, 1914 елда И.Н.Харитонов мәтбагасында аерым китап булып басылып чыга.
27 Г.Камал Мольерның «Ирексездән табиб», «Хаста» һәм башка әсәрләрен тәрҗемә итә. Алар, сәхнәдә куелсалар да, басылмыйча калганнар.
28 «Шәрекъ клубы» 1908 елда Казанның Кабан күле буенда Хәйрулла Хәмитов дигән бер байның йортында ачыла. 1910 елда Евинглистовский урамына күчә (хәзерге Татарстан урамы, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты күршесендәге өч катлы бина).
29 «Сәйяр» – беренче татар профессиональ театр труппасы. 1906–1907 елларда оешкан.
30 «Уйнаш» пьесасы 1910 елда языла һәм шул ук елның декабрь аенда сәхнәгә куела.
31 «Дәҗҗал» драмасы 1912 елда язылып, шул ук елның 30 мартында «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела.
32 Хәмзә бай – «Беренче театр»ның персонажы. Аның прототибы Г.Камалның каенатасы – Казанның зур байларыннан берсе, мех белән сәүдә итүче Садыйк хаҗи Хәйбуллин.
33 «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясе 1911 елда языла һәм шул ук елның 11 ноябрендә сәхнәгә куела.

313 бит.
Минем персональный пенсионер булуымның тарихы. 1932 елның икенче яртысында языла башлап, тәмамланмый калган мемуар характерындагы әсәр. Автор үлгәннән соң, «Совет әдәбияты» журналының 1934 елгы 6 (июнь) санында басылып чыккан. Беренче тапкыр «Галиәсгар Камал әсәрләре»нә (Казан, 1935) кертелгән.
Текст «Совет әдәбияты»ннан алынды. Әсәр «Г.Камалның басылмаган әсәрләре (үлүенә бер ел тулуы уңае белән)» дигән рубрика астында Гомәр Галинең түбәндәге кереш сүзе белән бирелгән:
Бу кулъязма турында
Укучылар алдына куелган бу өзек – Галиәсгар Камал ага үлгәннән соң аның кулъязмалары арасыннан килеп чыккан, хәзергә чаклы матбугат дөньясына чыкмаган әсәрләренең берсе. 1932 елның җәендә Галиәсгар Камал агага берничә язучы һәм бигрәк тә Татгосиздатның матур әдәбият секторында эшләүче иптәшләр тарафыннан менә шундый бер тәкъдим ясалган иде: «Хәзергә чаклы татар совет әдәбиятында мемуар төсендә язылган әсәрләр бөтенләй юк. Әгәр, Галиәсгар ага, син шундый бер эшкә тотынсаң, кыйммәтле бер әсәр бирә алыр идең», – диелгән иде. Галиәсгар Камал ага бу тәкъдимне бик яхшы каршы алды һәм шул характерда русча язылган кайбер әсәрләр белән дә махсус рәвештә таныша башлады (мәсәлән, Свирскийның «Моя жизнь» дигән китабы һ.б.). Ләкин үзе исән чакта конкрет рәвештә бу эшкә керешү турында ишетергә туры килмәде. Болай да шаянрак табигатьле Галиәсгар ага бу эшне тәмам итеп, аның бу эшен көтеп йөрүчеләрне әзер факт

алдында калдырырга теләгән булса кирәк. Һәрхәлдә, безгә шунысы ачык: укучылар алдына куелган менә бу әсәр – һичшиксез, Галиәсгар аганың алда зур бер китап итеп язарга теләгән әсәренең бер өлеше. Кулъязма гади мәктәп дәфтәренә, кәгазьнең ике ягына бик пөхтә итеп яңалиф белән язылган (барлыгы егерме бит). Галиәсгар ага кәгазьләре арасында бу язмага бәйләнешле булган башка берәр нәрсә (план, каралама һ.б.) очрамады. Бу кулъязма, әлбәттә, Галиәсгар аганың үз гомеренең соңгы елларындагы әдәби эшчәнлеген күрсәтү өчен гаять әһәмиятле документ. Ул нык тикшерелергә тиешле. Ләкин мин бу урында әлегә әнә шул фактик справка белән канәгатьләнүне тиешле таптым.
Гомәр Гали.
1 Хәзер Галиәсгар Камалның туган көне дип 1879 елның 6 гыйнвары санала.
2 Фуксовский урам – хәзерге Галиәсгар Камал урамы.
3 Суворов йорты – хәзерге Г.Камал урамындагы (29 нчы номерлы) йорт сүтелгән инде.
4 Госманов мәдрәсәсе – Казанның зур байларыннан Җиһанша Госманов салдырганга, «Мәдрәсәи Госмания» дип йөртелгән мәдрәсә.
5 Мазар Фазлый йорты – совет чорында Тукай урамындагы 5 нче номерлы йорт (хәзер сүтелгән).
6 Түбән Масра – хәзерге Арча районындагы авыл.
7 «Иман шарты» – гарәп әлифбасы һәм төрле догалыклардан торган кечкенә кулдагы китап. Иске (кадим) мәктәп-мәдрәсәләрдә балаларга иң беренче бирелә торган дәреслек.
8 Ястү – шәфәкъ беткәч укыла торган кичке намаз.
9 Яңа Масра, Сикертән, Масра – хәзерге Арча районындагы авыллар.
10 Әнәс сәхабә – Әнәс бине Малик.
11 Кошман – хәзерге Татарстан Республикасының Кайбыч районына керә торган авыл.
12 Ар – удмурт («вотяк» сүзенең синонимы).
13 Проломный урамы – Казан шәһәрендәге хәзерге Бауман урамы.
14 Печән базары мәчете – хәзерге Мәскәү һәм Париж Коммунасы урамнары чатындагы мәчет («Ак мәчет» дип тә йөртелгән).
323 бит.
Габдулла Тукай турында истәлекләр. Г.Камалның үләр алдыннан язган иң соңгы әсәре. «Совет әдәбияты» журналының 1933 елгы  июнь (6) санында басылган. «Әсәрләр»гә (1951, 1982) кертелгән. Текст «Совет әдәбияты»нан алынды.

1 Шәрәфләр – монда Гыйльметдин Шәрәф күздә тотыла.
2 «Московские номера» – Казандагы кунакханә.
3 Ботаника бакчасы – Казанның хәзерге Һ.Такташ урамындагы Зооботаника бакчасы.
4 Борадәран Кәримевләр – бертуган Мөхәммәтҗан, Хәсән, Шакирҗан һәм Шәрифҗан Кәримевләр; Казан миллионерлары, китап бастыручы һәм сатучы ширкәт хуҗалары.
5 Балкан сугышы. – Монда Беренче Балкан сугышы күздә тотыла. Балкан Союзы дәүләтләре (Болгария, Греция, Сербия һәм Черногория) белән Төркия арасында башланган бу сугыш 1912 елның 9 октябреннән 1913 елның 30 маена кадәр дәвам итә һәм Төркиянең җиңелүе белән тәмамлана.
6 Клячкин больницасы – Г.Тукай үлгән больница. Казанның хәзерге А.Н.Островский һәм К.Нәҗми урамнары чатындагы хәзерге Сәламәтлек саклау министрлыгы бинасы.
Г.Камал «Әсәрләр»енең өч томында телгә алынган аерым шәхесләр, дини-мифик исемнәр, җыентык, альманах һәм
газета-журналларның алфавит
тәртибендәге күрсәткече
А
Абдуллин Искәндәр (1935–1992), тел галиме – 3: 332.
Агиев Фәхрелислам (1887–1938), язучы, журналист – 3: 368.
Адәм, дини мифология буенча җирдәге беренче ир кеше – 2: 465, 467.

«Азат» (1906, Казан), газета – 1: 338, 339; 2: 454, 455; 3: 56, 99, 101, 119, 125, 306, 331, 332, 333, 334, 340, 341, 342, 343, 347.
«Азат халык» (1906, Казан), газета – 1: 339; 2: 454, 455; 3: 119, 331, 334.
Аитов Локман (1891–1971), артист – 1: 354.
«А.Казани» (псевдоним) – к.: Камал Г.
Акмулла (Акменла) Мифтахетдин (1831–1895), татар-башкорт-казакъ шагыйре – 3: 67, 342.
Аксакал (псевдоним) – 1: 357.
Акчура (Акчурин Йосыф, 1876–1935), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, – публицист, профессор – 3: 246, 306, 372.
Акчуриннар: Хәсән һ.б., Сембер губернасында фабрика хуҗалары, сәүдәгәрләр, җәмәгать эшлеклеләре – 3: 327.
Александр II, Россия императоры – 3: 50, 52.
Алкин Ильяс (1895–1937), милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, педагог – 2: 458.
Алкин Сәедгәрәй (1867– 1919), җәмәгать эшлеклесе, адвокат, – 3: 54, 86, 306, 341, 372.
Аллаһияр (1624–1713), төрки телле суфи шагыйрь – 2: 114, 451; 3: 373.
«Сөбател-гаҗизин» (1802, Казан).
«Алма», авторы билгесез шигырь – 2: 466.
Алмаев Мәхмүт (1874–1907), шагыйрь, журналист, полиграфия белгече – 3: 310.
«Аң» (1912–1918, Казан), әдәби журнал – 1: 339, 340; 3: 351, 368.
Апанаев Габдулла (1862–1919), Казан мулласы, җәмәгать эшлеклесе – 2: 454, 455; 3: 306, 332, 333, 351.
Араблинский Хөсәен (1881–1919), әзәрбәйҗан артисты, режиссер – 1: 343, 353, 354.
Арапова Нәфига (1900–1943), артистка – 3: 290.
Арландо (Орландо, 1860–1952), 1917–1919 елларда Италиянең хөкүмәт башлыгы – 2: 329, 468.
Атласов Һади (1876–1938), тарихчы, җәмәгать эшлеклесе – 3: 306.
«Африка харитасы», китап – 3: 225.
Ахундов Мирза Фәтхегали (1812–1878), әзәрбәйҗан мәгърифәтчесе, язучы, фикер иясе – 3: 303, 304, 331, 371.
Ә
Әбү бәк Мөҗәледдин – 3: 299.
Әбүбәкер (573–634), гарәпләрнең беренче хәлифәсе – 3: 67, 302, 371.
Әбүгалисина (Ибн Сина, Авиценна, 980–1037), Урта Азиядә яшәгән энциклопедист галим, философ, медик, шагыйрь, музыкант, астроном – 2: 118.
Әбүзәри (Әбүзәрев) Г., «Йолдыз» газетасының хосусый мөхбире – 3: 367.
Әбүзәров Хөсәен, нашир – 3: 136, 361.
«Әдип» (псевдоним) – к.: Камал Г.
«Әлгасрелҗәдид» (1906–1907, Уральск), демократик юнәлештәге әдәби журнал – 3: 86, 323, 324, 344, 345.
«Әлислах» (1907–1909, Казан), демократик юнәлештәге газета – 1: 342, 344, 352, 353, 354, 355; 2: 227, 456; 3: 78, 126, 168, 324, 344, 352, 354, 355.
«Әл-кәрмәк», газета – 3: 297.
«Әл-лива», Мисырда М.Кямил (1874–1908) тарафыннан XX гасыр башында чыгарылган газета – 3: 69, 342.
«Әл-мәнар», XX гасыр башында Мисырда күренекле ислам реформаторы Мөхәммәд Рәшид Риза тарафыннан нигезләнгән журнал – 3: 69, 297, 342.
«Әл-мөәйяд», Мисырда XX гасыр башында чыккан газета – 3: 69, 342.
Әмирхан Фатих (1886–1926) – 1: 344, 345, 350, 351, 354, 355; 3: 136, 188, 325, 332, 334, 335, 344, 352, 354, 355, 356, 358, 361, 368.
«Яшьләр» (1910).
Әмирханов Хөсәен (1814–1893), Казан мулласы – 3: 60, 341.

Әнәс бине Малик (612–709), Мөхәммәд пигамбәр заманында Мәдинә шәһәре мөселманнарының күренеклеләреннән – 3: 316, 375.
Әнвәр бәк (паша) (1881–1922), Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 256, 260, 275, 276, 277, 278, 281, 282.
Әпсәләмов Мифтах (1889–1927), артист – 3: 292.
Әр-Рәсүли – 3: 70.
Әсәдулла агай, вак сәүдәгәр – 3: 321.
Әсгать Мәхмүд (1847–1918), төрек, дин галиме – 3: 165, 357.
«Тарихы ислам» (1908).
Әс-Сафах Габдулла – 3: 73.
«Әс-сәгадәт», Мароккода гарәп телендә чыккан газета – 3: 68.
Әс-Сөгуди – 3: 297.
«Әүлия» (псевдоним) – к.: Шәфигуллин В.
«Әхбар» (1907–1909, Казан), газета – 3: 135, 353.
Әхмәд Мидхәд (1844–1913), төрек язучысы, публицист, тарихчы – 3: 237, 238.
Әхмәд Мохтар паша, Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 279.
Әхмәди, XVIII гасыр төрек шагыйре – 3: 66, 342.
«Әхмәдия» – 3: 66, 342.
Әхмәдуллиннар , бертуган Вәли һәм Гали «Сабах» көтебханәсе хуҗалары – 3: 356.
Әхмәров Гайнетдин (1864–1911), тарихчы – 3: 185, 186.
Әхмәров Шиһаб (1882–1966), журналист, нашир, педагог – 3: 345.
Әхмәрова (Заһидә Тинчурина, 1897–1988), укытучы, артистка – 3: 289, 290, 369.
Әхмәт бай – к.: Хөсәенов Ә.
Әхмәтҗанов И., бертуган Кәримевләрдә приказчик – 3: 309, 310.
Әхмәтҗанов Фазылҗан һәм Фазылгалләм, китап һәм галантерея сәүдәгәрләре – 1: 360; 3: 306.
Әхмәтҗанов Шәриф – 3: 245.
«Әхтәри» – к.: Г.Камал.
Б
Бабур Заһретдин (1483–1530), Урта Азия хакиме, язучы – 3: 67, 342.
«Бабурнамә».
Багданов Идрис (1886–1916дан соң), драматург – 1: 340, 350; 3: 158, 312, 335, 354.
«Помада мәсьәләсе» (1908);
«Югалган хатын» (1908).
Бадамшин Гариф (1865– 1939), Чистай сәүдәгәре, I, II Дәүләт Думалары депутаты – 3: 347.
«Баку» (1902–1918, Баку), газета – 1: 353.
«Бакырган» – 2: 227, 243, 244, 456, 458.
Бакырганый Сөләйман (?–1186), Урта Азиядә яшәгән суфи шагыйрь – 2: 456, 458.
Баруди Галимҗан (Галиев, 1857–1921), дин эшлеклесе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе имамы, мөфти – 3: 310, 372, 374.
Бать Александр Гедеонович, присяжный поверенный, адвокат, кадетлар партиясе әгъзасы – 3: 54, 341.
Баязидский Зәки (1889–1959), артист – 1: 356, 357.
«Бәдәвам», авторы билгесез көйле әсәр – 2: 246, 459; 3: 60, 100, 341.
Бәкер Кәбир (Бәкерев, 1885–1944), драматург, журналист – 1: 345, 352, 355; 3: 220, 245, 287, 288, 368.
«Чән там» (1907).
Бәшири Зариф (1888–1962), татар шагыйре, прозаик, журналист – 3: 135, 343, 358.
«Бәянелхак» (1906–1912, Казан), газета – 1: 99, 112, 113, 120, 347, 349; 3: 42, 43, 44, 48, 86, 125, 306, 331, 332, 339, 341, 342, 352, 353.
Бедный Демьян (1883–1945), рус совет шагыйре – 2: 442.
«Безнең байрак» (1922–1924, Казан), газета – 2: 442; 3: 306.

«Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләремез һәм төп мәкъсудымыз» (1907, Оренбург), брошюра – 1: 343.
«Белек» (1872, Казан), әдәби хрестоматия – 3: 309.
Бигиев Заһир (1870–1902), татар язучысы – 3: 345.
Бизе (Визе) Владимир Юльевич (1886–1954), Арктиканы өйрәнүче совет галиме – 2: 167, 452.
Богданов Гариф (1889–1955), педагог – 3: 155, 356.
«Хуҗа һәм приказчик» (1907).
Болгарская Гөлсем (1891–1968), артистка – 1: 356, 357; 3: 289, 368.
Боначич Антон Петрович (1878–1933), рус җырчысы – 1: 268.
Борһанетдин Мәрҗани (1856–1916), Казан мулласы, Ш.Мәрҗанинең улы – 3: 217, 364.
Бунfamiят-Задә Дадаш (1888–1938), әзәрбәйҗан дәүләт эшлеклесе, нашир – 1: 353.
Бурнаш Фәтхи (1898–1942), татар шагыйре, драматург, журналист – 2: 451, 452.
Бу Хамәрә – 3: 70.
В
«Вакыт» (1908–1918, Оренбург), газета – 1: 353, 355, 356, 358; 2: 227, 456; 3: 42, 84, 112, 113, 232, 342, 343, 349, 352, 362.
Варламов Константин Александрович (1849–1915), рус артисты – 1: 268.
Василий III, Рус дәүләте, идарәчесе, князь – 3: 341.
Вахидеддин (1861–1926), 1918–1922 елларда төрек солтаны – 3: 301, 370.
Вахитов Мулланур (1885–1918), сәясәт эшлеклесе – 3: 306.
Вәли Ярулла (1879–1937), татар язучысы һәм драматургы – 3: 149, 151, 210, 220, 221, 312, 335, 354, 355, 364, 365.
«Оят, яки Күз яше» (1902).
«Ачлык кушты» (1908);
Вәлишин Мөхәммәт, артист – 2: 448.
Венецианов Миний Соломонович, Казанда присяжный поверенный – 3: 54, 341.
Вильгельм II (1859–1941), 1888–1918 елларда Германия императоры һәм Пруссия короле – 2: 361, 470.
Вильсон Вудро (1856–1924), 1912–1921 елларда АКШ президенты – 2: 251, 329.
Вит М., француз язучысы – 2: 473.
«В мире мусульманства» (1911–1912, Петербург), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета – 3: 224, 365.
«Волжско-камская речь» (1907–1908, Казан), рус телендә чыккан газета – 1: 353.
Вольтер М. (1694–1778), француз язучысы, философ, тарихчы – 3: 303.
Вячеслав Г.М., типография хуҗасы – 3: 179.
Г
Г.Газиз (Газиз Гобәйдуллин, 1887–1937), язучы, тарихчы – 3: 368.
Габделгазиз (1830–1876), 1861–1876 елларда төрек солтаны – 3: 300.
Габделмәҗид (1823–1861), 1839–1861 елларда төрек солтаны – 3: 300, 301.
Габделхәмид (1842–1918), 1876–1909 елларда төрек солтаны – 2: 433, 473; 3: 257, 258, 261, 280, 300.
Габдрахман бәк, Төркиядә монетный двор мөдире – 3: 258, 263.
Габдрахман паша, Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 263.
Габәши Хәсәнгата (1863–1933), тарихчы, казый – 3: 185, 360.
Габдәһ Мөхәммәд (1849–1905), Мисыр мөселман реформация идеологы – 3: 342.
Газәли Әбү Мөхәммәд (1058–1111), философ, дин галиме – 3: 69, 70, 71, 342.
Газиев Сәгъди, Казанда кибет хуҗасы – 3: 321, 322.
Газраил, дини-мифологик персонаж – 2: 273, 461.
Гайнуллин Г., артист – 1: 353.
Гайнуллин Мөхәммәт (1903–1985 ), әдәбият галиме, профессор – 2: 448, 457; 3: 332.
Гали (Гали ибн Әбуталиб, ? – 661), гарәпләрнең дүртенче хәлифәсе – 3: 302, 371.

Гали Гомәр (1900–1954), тәнкыйтьче, публицист, язучы – 2: 448, 449; 3: 374, 375.
Гали Мөхәммәт (1893–1952), язучы, әдәбият галиме – 2: 332, 337.
Галиева, артистка – 1: 353, 3: 389.
Галими М. – 3: 163, 170, 358.
Гаспринский Исмәгыйль (1851–1914), Кырым мирзасы, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, «Тәрҗеман» газетасының нашире һәм мөхәррире – 3: 309, 352.
Гатуф бәк, Төркиянең Россиядәге консулы – 3: 240.
Гафури Мәҗит (Габделмәҗид, 1880–1934) – 3: 130, 142, 336, 339, 352, 354.
«Алмашыну» (1905);
«Үги балалар» (1908).
Гёте Иоһанн Вольфганг (1749–1832), немец шагыйре һәм фикер иясе – 3: 309, 373.
«Фауст» (1773–1775).
Гоголь Николай Васильевич (1809–1852) – 1: 340, 350; 2: 445, 446; 3: 138, 368.
«Ревизор» (1935);
«Женитьба» (1933–1941).
Гомәр (591–644), гарәпләрнең икенче хәлифәсе – 3: 302, 371.
Гомәров Абдулла (1906–1974), тәрҗемәче, мөхәррир – 2: 459.
Гордлевский Владимир Александрович (1876–1956), рус галиме, Көнчыгышны өйрәнүче – 1: 344, 355.
Горький Максим (1868–1936) – 1: 28, 340, 342.
Госман (якынча 575–656), гарәпләрнең өченче хәлифәсе – 3: 302, 371.
Госман (1258–1324 яки 1326), Төркия дәүләтенә нигез салучы – 3: 371.
Госман Хатип (1908–1992), әдәбият галиме, профессор – 2: 457.
Госманов Җиһанша, Казан бае, «Госмания» мәдрәсәсен салдыручы – 3: 375.
Гъ.К. – к.: Камал Г.
Гыйззәт Бәян (1918–1991), әдәбият галиме һәм сәнгать белгече – 1: 351; 3: 332, 356.
Гыйззәтуллина Сәхипҗамал (Волжская, 1885–1974), беренче татар артисткасы – 1: 353, 354, 356, 368; 3: 311.
Гыйлаҗи абзый. Г.Камал әтисенең бертуганы – 3: 316.
«Гыйшык бәласе», бер пәрдәлек комедия – 1: 365.
Д
Давыдов Александр Давыдович (1849–1911), рус җырчысы – 1: 268.
Датиев Аслан Гәрәй, «В мире мусульманства» газетасы мөхәррире – 3: 224, 365.
Дәҗҗал, дини-мифологик персонаж – 1: 108, 109; 2: 93, 95, 96, 97, 104, 450.
Девишев, артист – 3: 353.
Деникин А.И. – 2: 302, 340, 442.
«Деятель» (Казан, 1896–1917), иҗтимагый-әдәби журнал – 3: 340.
«Дин вә мәгыйшәт» (Оренбург) дини, әдәби журнал – 3: 166, 358.
«Дингә каршы» (1939, Казан), әдәби җыентык – 2: 462.
Динмөхәммәтов Ишмөхәммәд (1849–1919), дин эшлеклесе, кадимче – 3: 132, 352.
Джакометти Паоло (1816–1882), Италия драматургы – 2: 446.
Дмитриев Мадко (1859–1918), болгарияле генерал – 3: 259.
Дузе Элеонора (1858–1924), итальян актрисасы – 2: 440, 473.
Думави Нәҗип (1883–1933), татар шагыйре, прозаик – 3: 130.
Е
Екатерина II (1729–1796), Россия императрицасы (әби патша) – 2: 449; 3: 58.
Еникеев Гайса (1864–1931), морза, сәяси эшлекле, III, IV Дәүләт Думалары депутаты – 3: 351.
Ершов Николай – 2: 453.
Җ
Җамал бәк – 3: 277.
Җәлал бәк, Төркиядә дәүләт эшлеклесе – 3: 282.

Җәмил паша – 3: 255.
Җәгъфәрев Г. – 3: 157, 164.
«Җәгърафия мөгаллиме» (1908).
Җәбраил, дини-мифологик персонаж – 2: 114, 541.
Җәмил Хан – 2: 448.
З
«З.Г.-ва» (псевдоним) – к.: Камал Г.
Залесский Владислав Францевич (1861–1922), Казан, дәүләт университеты профессоры, хокук белгече – 3: 54, 340.
Зәбири (Зәбиров) Хәбибрахман (1881–1933), нашир, Октябрьдән соң нәшрият эшчесе – 3: 153, 355.
«Зәйнәп К-ва» (псевдоним) – к.: Камал Г.
«Гыйлем вә җәһел» (1908).
«Земщина» (1909–1917, Петербург), газета – 3: 224.
Зыя әл-Кәмали (Пәрвазетдин Камалетдинов, 1873–1942), педагог, дин философы – 3: 114, 115, 293, 350, 369.
Зөһрә әл-Таһирия (Таһирова, 1889–1972), укытучы – 3: 339.
И
Иблис, дини-мифологик персонаж – 2: 95, 101, 450, 466.
Ибн Согуд Мөхәммәд – 3: 370.
Ибн Халдун (1332–1406), гарәп тарихчысы, философ – 3: 69, 71, 342.
Ибраһим бәк – 3: 281.
Ибраһимов Габдерәшид (1857–1944), җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, публицист – 3: 125, 352.
Ибраһимов Галимҗан (1887–1938) – 1: 336, 348, 357; 2: 442, 444, 447, 456, 457; 3: 332, 334, 336.
Иван Грозный (Иван IV Васильевич, 1530–1584), 1547 елдан беренче рус патшасы – 3: 58, 341.
«Идел» (1907–1914, Әстерхан), иҗтимагый-сәяси, әдәби газета – 3: 216, 364.
Идрис, дини-мифологик персонаж, пигамбәр – 3: 69.
Идрисов Ибраһим, «Милләт» мәтбагасы хуҗаларыннан берсе – 3: 166.
Идрисов Мөхәммәд (1882–1948), мәтбагачы, рәссам, шрифтист, гравер – 3: 166.
Идрисов Юныс – 3: 221, 222.
«Икъдам», Төркиядә чыккан газета – 3: 274.
Ильминский Николай Иванович (1822–1891), рус педагогы, Казан дәүләт университетының төрек-татар телләре кафедрасы профессоры, миссионер – 3: 191.
Ильяс Г. – к.: Хәсәни Ә.
Ильясый Габдрахман (Ильясов, 1856–1895), татар драматургиясен башлап җибәрүче – 3: 308, 345, 373.
«Бичара кыз» (1887).
Имам Әгъзам (Әбү Хәнифә Ногман бине Сабит, 699–767), ислам динендәге Хәнәфи мәзһәбенә нигез салучы атаклы фәкыйһ – 2: 451.
«Иман шарты», дини китап – 3: 314.
Иманский – к.: Мортазин-Иманский.
Иманаев Миргаяз (1870–1927), рус теле укытучысы – 3: 309, 373.
Иманаев Шәехгаттар (1875 – ?), юрист, «Хокук вә хәят» (1913–1914, Казан) журналы мөхәррире – 3: 309, 373.
Иманколый Садыйк (1879–1938), Казан мулласы, шагыйрь – 3: 60, 341.
«Иршад» (1905–1908, Баку), газета – 3: 349.
«Ислам» (1924–1927, Уфа), дини-әхлакый вә фәлсәфи журнал – 3: 293, 369.
«Ислах» – к.: «Әлислах».
Исмәгыйль бәк – к.: Гаспринский И.

Исмәгыйль хәзрәт, Түбән Масра авылы мулласы – 3: 198, 314.
Исхак Әхмәт (1905–1991), татар шагыйре – 2: 457.
Исхакый Гаяз (Исхаков, 1878–1954), – 3: 137, 188, 194, 305, 307, 361, 372.
«Ишан Гали» (псевдоним) – к.: Камал Г. – 2: 235, 301, 458, 459, 460, 469, 473.
Ишми, Ишмөхәммәд – к.: Динмөхәммәтов.
Ишми, артист – 3: 313.
Й
«Йолдыз» (1906–1918, Казан), иҗтимагый-сәяси, әдәби газета – 1: 339, 340, 342, 345, 348, 349, 351, 352, 353, 354, 355, 356, 357, 358, 359; 2: 227, 456, 457; 3: 112, 113, 120, 125, 132, 133, 184, 211, 232, 233, 287, 306, 323, 324, 328, 331, 334, 335, 341, 343, 369.
Йосыф Гыйззетдин шаһзадә (Төркия) – 3: 266, 365.
К
Кадермәтов Минһаҗетдин Йосыф (1871–1925), календарьчы публицист – 3: 14, 350.
Кадыйр, Түбән Масра авылы кешесе – 3: 314.
Кадыйров Мөхәммәтгали – 1: 306; 3: 306.
«Казан мөхбире» (1905–1911, Казан), газета – 2: 454, 455; 3: 42, 43, 48, 86, 125, 331, 332, 339, 341, 352, 358, 359, 360, 361, 362, 363, 364, 365, 366, 368.
«Казакъ» – к.: Бәкер Г.
Казани Г. (Г.Камал) – 1: 359, 360.
Казанский Гыйлаҗ (1891–1938), артист – 1: 354.
«Казанский телеграф» (1893–1916, Казан), иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм коммерция газетасы – 3: 190.
Камал Әнәс (1908–1978), татар драматургы, Г.Камалның өлкән улы – 2: 448.
Камал II Габдрахман (1896–1948), артист, Г.Камалның бертуган энесе – 1: 340.
Камал I Габдулла (1893–1933), артист, режиссер, Г.Камалның бертуган энесе – 1: 340.
Камал Галиәсгар (1879–1933) – 1: 28, 71, 192, 336–351, 359, 360; 2: 161, 187, 213, 235, 301, 442–447, 454, 455, 458, 459, 460, 469–473; 3: 3, 4, 12, 14, 18, 43, 44, 120, 121, 285, 305, 306, 307–376.
Камалетдинов Галиәкбәр (1850–1921), Г.Камалның әтисе – 1: 336.
Камалова Зәйнәп (1899–1977), артистка, Г.Камалның бертуган сеңлесе, – 1: 340.
Камил паша, Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 259, 263, 276, 277.
Капустин Михаил Яковлевич (1847–1920), Казан дәүләт университеты профессоры, II, III Дәүләт Думалары депутаты – 3: 121, 348.
Карәхмәт, цирк көрәшчесе – 3: 327.
Кариев Габдулла (1886–1920), артист, режиссер, татар профессиональ театрына нигез салучы – 1: 353, 354, 355, 356, 357, 358, 359; 3: 210, 311, 313, 326, 360, 363, 366, 368.
Карпов Евтихий Павлович (1857–1927), рус язучысы, режиссер – 1: 340.
Касбар (Касаб) Теодор – 3: 287, 288, 311, 368.
«Каспий» (1881–1919, Баку), газета – 1: 353; 3:76.
Кәмал Мостафа (1881–1938), Төркия Республикасына нигез салучы һәм аның беренче президенты – 3: 370.
Кәмал Нәмикъ (1840–1888), төрек язучысы – 1: 360; 3: 306, 309, 310, 372, 373.
«Зәваллы чуҗык» (1873);
«Кызганыч бала» (1900).
Кәмил М. (1874–1908), Мисырда Англия колонизаторларына каршы милли-азатлык хәрәкәте эшлеклесе, публицист – 3: 342.
Кәпиев Әбүбәкер, Спандияр XX йөз башы казакъ шагыйре – 3: 87, 342.
Кәрам Габдрахман (1878–1947), театр тәнкыйтьчесе – 1: 342, 352, 357; 2: 448; 3: 184, 286, 360, 368.
Кәримевләр: бертуган Мөхәммәтҗан, Хәсән, Шакирҗан һәм Шәрифҗан, китап бастыручы һәм сатучы ширкәт хуҗалары – 1: 352, 359; 3: 123, 124, 211, 309, 310, 326, 355, 363, 364, 373, 376.

Кәрими Фатих (1870–1936), татар язучысы, журналист – 2: 456; 3: 123, 124, 140, 141, 161, 166, 335, 351.
«Мирза кызы» (1907);
«Хәкыйкатьме, хыялмы?» (1908).
Кәримов Гариф, Мәскәү сәүдә институты студенты – 3: 249.
Керенский Александр Федорович (1881 –1970) – 2: 335.
Кермэ (автор) – 1: 355.
«Кечкенә Рәшид», «Балалар дөньясы» сериясеннән беренче китап, (1908, Казан) – 3: 160, 357.
Килмансу (Клемансо, 1841–1921), 1917–1920 елларда Франция премьер-министры – 2: 329, 468.
«Кисекбаш» («Кисекбаш китабы»), XII–XIII гасыр шигъри ядкәре – 2: 241, 458.
«Кияү эзләү» (1907, Казан), тәрҗемә пьеса – 3: 155, 356.
Клячкин Григорий Абрамович (1872–1946), Казанда шифаханә хуҗасы, табиб, медицина фәннәре докторы – 3: 328, 376.
Коләхмәтев Гафур (1881–1918) – 1: 350, 353; 3: 147, 306, 332, 333, 335, 356.
«Яшь гомер» (1908).
Колмәмәт Хәмит (1895–1941), артист – 2: 448; 3: 290.
Колчак Александр Васильевич (1874–1920) – 2: 280, 287, 298, 302, 442, 447, 462.
«Коммунист» (Баку), әзәрбәйҗан телендә чыккан газета – 3: 296.
«Коммунист» (1932–1934, Мәскәү), татар телендә чыккан газета – 3: 296.
Корбангалиев Мөхетдин (1873–1941), педагог, тел галиме, профессор – 3: 195, 306, 333, 335, 361.
«Хисап мәсьәләләре һәм гадәди мисаллар» (1910).
Коръән, мөселманнарның төп дини китабы – 1: 65, 66; 2: 79, 96, 103, 104, 112, 115, 211, 225, 283, 450, 456; 3: 12, 60, 227, 316, 352, 369.
«Кояш» (1912–1918, Казан), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета – 1: 355, 357; 3: 328, 360, 368.
«Көрәш еллары» (1958, Казан), җыентык – 2: 458.
Крылов Иван Андреевич (1769–1844) – 3: 167, 358.
Кугушев Исмәгыйль (1897–1968) артист, режиссер – 2: 448.
Кудашев Ильяс (Ашказарский, 1884–1948), артист һәм режиссер, татар профессиональ театрын оештыручыларның берсе – 3: 111, 349.
Кулалаев Әхмәт (1887–1924), артист – 1: 353, 356, 357.
Куропаткин А.Н. (1848–1925), патша генералы – 2: 455.
Кызыл (псевдоним) – к.: Камал Г.
«Кызыл алма», борынгы әдәбият ядкәре – 2: 237, 456.
«Кызыл байрак» (1917–1918, Казан), газета – 2: 442; 3: 306.
«Кызыл ил» (1922–?, Әстерхан) – 2: 448.
«Кызыл көрәшче» (1919, Казан), гаскәри газета – 2: 442, 3: 306.
«Кызыл Татарстан» – к.: «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»).
Л
Лавров Петр, народник, «Эшчеләр Марсельезасы» җырының авторы – 3: 347.
Лебедев, 1918 елда Казанга кергән ак чехларның гаскәр башлыгы – 2: 457.
Ленин Владимир Ильич (1870–1924) – 2: 122, 128.
Лидваль, эре аферист һәм спекулянт – 3: 88, 345.
Ллойд Джордж (1863 – 1945), 1916–1922 елларда Англия премьер-министры – 2: 329, 468.
Лотфулла, вак сәүдәгәр, тегүче Әсәдулла улы – 3: 321.
М
Мазар Фазлый, йорт хуҗасы – 3: 313, 375.
Максуди Садри (1878 –1942), җәмәгать эшлеклесе, II, III Дәүләт Думалары депутаты – 3: 190, 361.

Максуди Һади (1868 –1941), җәмәгать эшлеклесе, журналист, «Йолдыз» газетасы мөхәррире – 2: 456; 3: 83, 85, 306, 327, 344, 345, 360, 367, 368.
Максудов Сафиулла (1858 – ?), Казан өязе Күлбаш авылы мулласы, II Дәүләт Думасы депутаты – 3: 348.
Мамаев Фәтхулла, камчатчы сәүдәгәр, Галиәкбәр Камалетдинов каенатасы Хәбибулла Мамаевның бертуган абыйсы – 3: 306, 372.
Мансур Зыя (1916–1965), татар шагыйре – 2: 448.
Маркс Карл (1818–1883) – 3: 97.
Маяковский Владимир Владимирович (1893–1930) – 2: 442.
«Мәгълүмат» (1908–1910, 1915–1918), Уфада чыккан дини журнал – 1: 344.
Мәҗитов Зәет (1927–2000), әдәбият галиме, шагыйрь – 2: 448.
Мәрҗани Борһанетдин (1856–1916), Казан мулласы, Ш.Мәрҗанинең улы – 3: 216, 217, 364.
Мәрҗани Шиһаб (Шиһабетдин әл-Мәрҗани, 1818–1889), татар тарихчысы, мәгърифәтче галим һәм педагог – 3: 216, 217, 364, 373.
«Мәтбагачылык тарихы» – к.: Әхмәров Г.
Мәфтуха, карчык – 3: 322.
Мәхмүд Әсгать (1847–1918), төрек галиме – 3: 165, 357.
«Тарихе ислам».
Мәхмүд Газнави (970–1030), Урта гасырлар идарәчесе, хәрби эшлекле – 2: 451.
Мәхмүд Шәүкәт паша, Төркиянең дәүләт эшлеклесе – 3: 255, 259, 267, 281, 282.
Мәһди, мөселман динендәге шигыйләр мәзһәбендә (сектасында) уникенче имам Хөсәен (873 елда туган); мәһди – «туры юлга әйдәүче» дигән сүз – 2: 93, 104, 450.
Мәһдиев Мөкәрәм (1902–1938), режиссер – 2: 459.
Мәһдиев Мөхәммәт (1930–1995), әдәбият галиме, язучы – 2: 459; 3: 332.
Микеланджело Буонарроти (1475–1564), атаклы итальян рәссамы, архитектор, шагыйрь – 2: 446.
«Милли юл», Г.Исхакый каширлыгында Берлинда чыккан журнал – 3: 305.
Минһаҗетдин Йосыф – к.: Кадермәтов.
Миңлебаев Фәйзелкотдус, Тәтеш өязе мулласы, I Дәүләт Думасы депутаты – 3: 349.
Михайлов Михаил Ларионович (1829–1865), рус революционеры, язучы һәм журналист – 2: 380, 472.
Мольер (1622–1673), француз драматургы, актер – 1: 340, 348; 3: 287, 289, 311, 368, 374.
«Саран» (1668).
Морадова (Суфия Коләхмәтева, 1889–1972), язучы Г.Коләхмәтевнең сеңлесе, табиб – 1: 353; 3: 137, 155, 356.
Мортазин-Иманский Вәлиулла (1885–1938), артист – 1: 353, 355, 356, 357, 358; 3: 311.
Мортазин Сәхибгәрәй (?–1969), мәгариф эшчесе, әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы – 2: 458.
Мостафа Нәҗип бәк – 3: 277, 278.
Мостафин Габдерахман (1886–1936), Казан дәүләт университеты тәмамлаган табиб, Х.Ямашев дусты – 3: 182, 219, 360.
Мостафин Мөхәммәтәмин (Әмин), «Мәгариф» көтебханәсе ширкәте җитәкчесе – 3: 306, 372.
Мостафин Хәсән – 3: 199.
Мостафи Ш. – 1: 358.
Мотыйгый Камил (Төхфәтуллин, 1883–1941), нашир, җырчы – 3: 323, 344, 345.
Мохтар бәк, Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 281.
«Мөхтәсар», ислам диненең юридик законнары турындагы китап – 1: 166; 2: 86.
Мөгавия (661–750), гарәпләрдә Галидән соң тәхеткә утырган хәлифә. Өмәвиләр династиясенә нигез салучы һәм аның беренче хәлифәсе – 3: 302, 371.
Мөстәкыймев, Казан дәүләт университеты студенты – 3: 182, 325.

Мөхетдин Гарәби (1165–1240), Мисырда яшәгән суфи галим – 3: 69, 342.
Мөхетдинов Насыйх (1892–1943), педагог, җәмәгать эшлеклесе – 3: 357.
Мөхәммәд (570 ел тирәсе–632), пәйгамбәр – 2: 449, 456, 473; 3: 302, 307, 368, 370, 371.
Мөхәммәд ага – к.: Шаһтахтинский М.
Мөхәммәдгали бине Мөхәммәдшакир Габдерәхими – к.: Рәхим Г.
«Мөхәммәдия» – к.: Чәләби.
Мөхәммәд Рәшид Риза, Мисырда чыккан «Әл-мәнар» журналы мөхәррире – 3: 297, 298, 299.
Мөхәммәд Фәррах Әлмөнияди – 3: 297.
Мөхәммәтҗан Хафиз (Әхмәрев), Казан сәүдәгәре, кадимче – 1: 347.
Муко Юлий Адольфович (?–1945), балетмейстер – 3: 292.
Муса, дини-мифологик персонаж – 2: 462; 3: 128, 352.
Муса – к.: Бигиев М.
Мусков, мөхәррир – 3: 355.
Мутин Мохтар (1886–1941), артист – 3: 289.
Н
Нажи бәк – 3: 277.
Назыйм паша, Төркиядә дәүләт эшлеклесе – 3: 278.
Насретдин Хуҗа, әкият персонажы – 3: 59.
Насыйри Каюм (1825–1902), – 3: 308, 309, 321, 345, 372, 373.
«Русча-татарча лөгать» (1904).
Нәҗми Кави (1901–1957), татар язучысы – 2: 449; 3: 376.
Нәфиз бәк – 3: 278.
Нәфыйгов Рәфыйк (1928 – 2001), тарихчы, профессор – 3: 332.
Невежин Петр Михайлович (1841–1919), рус драматургы – 3: 289, 369.
«Икенче кат яшьлек» (1918).
«Нива» (1870–1917, Петербург), рус телендә чыккан рәсемле атналык журнал – 3: 311.
Нигъмәти Галимҗан (1897–1941), әдәбият галиме, профессор – 2: 445, 447, 449.
Низами Гянҗәви – 2: 466.
Николай II, Россия императоры – 2: 241, 291.
Нурадунгян (?) Төркиядә дәүләт эшлеклесе – 3: 278.
Нугайбәк Гыймад (1881–1943), тел галиме, журналист – 3: 362.
Нуркин Заһид (1888–1966), журналист – 1: 359.
Нуруллин Ибраһим (1923–1995), әдәбият галиме, профессор – 3: 332.
Нух, дини-мифологик персонаж – 2: 462.
О
«Октябрь революциясенең бер еллык бәйрәме бүләге» (1918, Казан), шигырьләр җыентыгы – 2: 457.
Островский Александр Николаевич (1823–1886) – 1: 340,345; 2: 446; 3: 111, 286, 349, 368, 374, 376.
«Гроза» (1859);
«В чужом пиру похмелье» (1855) («Галимнәр илә наданнар»).
Ө
«Өлфәт» (1905–1907, Петербург) газета – 3: 125.
П
«Пенти Хәмид» – к.: Мольер.
Петр Великий (Петр I, 1672–1725) – 3: 227, 365.
Пишон (1857–1933), XX гасырның 20 нче елларында Франциянең тышкы эшләр министры – 2: 329, 468.
Победоносцев К.П., реакцион дәүләт эшлеклесе – 2: 454.
Пуришкевич Владимир Митрофанович (1870–1920), рус сәяси эшлекле – 3: 206, 252, 362.
Пушкин Александр Сергеевич (1799–1837) – 2: 467; 3: 171.

«Сказка о золотом петушке» (1834) («Алтын әтәч»).
Р
Рабгузи (Насретдин бине Борһанетдин), XI йөзнең икенче яртысы – XIV гасыр башы Алтын Урда язучысы – 3: 67, 342.
«Кыйссасел-әнбия» (1311).
Рәмиев Зөфәр (1938 елда туган), әдәбият галиме, текстолог – 3: 336.
Рәмиевләр, сәүдәгәрләр, алтын приискалары хуҗалары, җәмәгать эшлеклеләре: Шакир (1857–1912), Закир (Дәрдемәнд, шагыйрь, 1859–1921) – 2: 227, 456; 3: 204, 212, 345, 362.
Рәмиев Сәгыйть (1880–1926), татар шагыйре – 1: 28; 3: 311, 344.
Рәми Исмәгыйль (1895–1969), журналист, библиограф – 2: 447.
Рәүф бәк, Төрек крейсеры командиры – 3: 273.
Рәфгать бәк, Төркиядә дәүләт эшлеклесе – 3: 281.
Рәхим Гали (1892–1943), язучы, әдәбият белгече – 3: 172, 173, 210, 335, 359, 363.
«Җир йөзе» (1913);
«Дача кайгысы» (1914).
Рәхимов Фатих – 3: 245, 246.
Рәхманкулов Габделмәннан (1858–1908), мөгаллим, Кәримевләр типографиясендә управляющий – 3: 211, 364.
Рәшид баба, Рәшид казый – к.: Ибраһимов Габдрәшид.
Риза Рәшад Мөхәммәд, Мисырда чыккан, «Әл-мәнар» журналы мөхәррире – 3: 297, 298, 299, 300.
Римский-Корсаков Николай Андреевич (1844–1908), рус композиторы – 3: 309, 373.
«Садко» (1896).
«Русские ведомости» (1816–1917), Мәскәүдә чыккан газета – 1: 344, 355.
Руссо Жан Жак (1712–1778), француз философы, мәгърифәтче, язучы, композитор – 3: 303.
«Русь православная и самодержавная» (1905–1916, Казан) газета – 3: 340.
С
Савов Сава (1865–1940), болгарияле хәрби эшлекле, генерал – 3: 259.
«Сагыйка» (псевдоним) – к.: Камал Г.
«Садко» – к.: Римский-Корсаков Н.А.
Садри Мөхәммәт (1913–1999), татар шагыйре – 2: 458, 464.
Садыйк абзый, Г.Камал әнисе Мәүгыйзәнең бертуган энесе – 3: 320.
Садыйк хәзрәт – к.: Иманколый С.
«Саиб» (псевдоним) – к.: Камал Г.
Салих, дини-мифологик персонаж – 3: 128, 352.
«Саран» – к.: Мольер.
«Санин», Төркиядә чыккан газета – 3: 204, 205.
Сатламышский Камил – 3: 99, 100, 101.
Сәгыйд Хәлим паша, Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 263, 267, 279, 281.
«Сәгълүк», дини китап – 1: 20.
Сәйдәшев Әхмәтҗан (1840–1912), сәүдәгәр, «Бәянелхак» газетасы нашире – 3: 120, 121, 122, 347, 351.
Сәйдәшев Мөхәммәтҗан, «Бәянелхак» газетасы нашире – 3: 347, 351.
Сәйфетдинов Галимҗан (1883–1918), сәяси эшлекле, журналист – 1: 338.
Сәйфи-Казанлы Фатих (1888–1937), татар язучысы, драматург, журналист – 2: 447; 3: 338.
Сәлах хәзрәт, Казан мулласы – 3: 314.
Сәлимова, артистка – 3: 210.
Свирский – 3: 375.
Сибгатулла – 3: 255.
«Сигнал яки ишарә», авторы күрсәтелмәгән кечкенә хикәя – 3: 153, 355.
Ситников Федор Львович, гипнозчы – 3: 143, 144, 354.

«Совет әдәбияты» (1933–1965), әдәби журнал, «Казан утлары»ның элгәре исеме – 1: 336, 348, 355; 3: 372, 374, 376.
Соколовский Аполлоний Яковлевич, протоиерей – 3: 54, 340.
Соловьев А.Т., Казанда 1896–1914 елларда чыккан «Деятель» журналы, беренче рус революциясе вакытында чыккан «Русь православная и самодержавная» газетасы мөхәррире – 3: 54, 340.
Соловьев Тимерша (1875–1947), «Чүкеч» (1906–1910, Оренбург) журналының мөхәррире һәм нашире – 3: 310, 326, 374.
Солтанов Мөхәммәдъяр, мөфти – 3: 366.
Софронов, октябристлар партиясе тарафдары – 3: 53.
«Социалистик Татарстан», төрле елларда «Эш», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны» исемнәре белән чыккан газета – 1: 336; 2: 448; 3: 301, 306, 307, 336, 367,369, 370, 373.
Сөембикә (1516 тирәсе – 1554 тән соң), Казан ханлыгы идарәчесе – 3: 185.
Сувор Хәйрулла (Хәйрулла Хәлиуллин), йорт хуҗасы – 3: 313.
«Сөлләм казый», мантыйк китабы – 2: 81, 449.
Сөләймания (Сөләйманова) Фәхрелбәнат (1857 – 1959), публицист, укытучы, тәрҗемәче – 3: 339.
«Мөсәррәт яки хөррият» (1905).
Сүнчәләй Сәгыйт (1889–1937), шагыйрь – 2: 467; 3: 153, 155, 355.
«Тунгатай. Кыргызлар тормышыннан» (1908) [тәрҗемә].
Т
«Тавыш» (1907, Казан), татар эсерлары газетасы – 3: 119, 350.
Таҗетдин Ялчыгол углы (1768–1838), язучы, тәрҗемәче – 3: 308, 373.
«Рисаләи Газизә» (1807).
«Таң йолдызы» (1906, Казан), татар эсерлары газетасы – 1: 359; 3: 119, 350.
Тагиев – 1: 357.
Такташ Һади (1901–1931) – 3: 376.
Тамарин Галибәк, Польша мөселманы, мөхәррир – 3: 24.
Тарханова, актриса – 3: 353.
«Тасвире әфкяр», Төркиядә чыккан газета – 3: 260.
«Татарин-театрал» (псевдоним) – 1: 352.
«Татар поэзиясе антологиясе» (1956, Казан) – 2: 457, 458, 459, 460, 461.
«Татарстан» – к.: «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»).
«Татар совет поэзиясе» (1952, Казан), җыентык – 2: 464, 468, 469, 470, 471.
«Татарстан хәбәрләре» – к.: «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»).
«Татар театры» (1926, Казан), мәкаләләр җыентыгы – 1: 364.
«Тәгъбирнамә», төш юрау китапчыгы – 2: 305, 463.
«Тәгълимел-мөтәгаллим», мәдрәсәләрдә уку китабы – 3: 26, 338.
«Тәкый гаҗәб», тезмә дини әсәр – 3: 60, 100, 341.
Тәлгать бәк (1874–1921), Төркиянең дәүләт эшлеклесе – 3: 277.
«Тәнзыймәт», Төркиядә чыккан газета – 3: 252, 265.
«Тәрәкъкый», кулъязма газета – 3: 310.
«Тәрҗеман» (1883–1918, Бакчасарай), газета – 3: 83, 84, 85, 114, 115, 119, 125, 227, 309, 350, 352.
Театр Шәех – 3: 308, 309.
Тилли К.А., Казанда типолитография хуҗасы – 3: 178, 179.
Тинчурин Кәрим (1887–1938), татар драматургы, режиссер, артист – 1: 356; 2: 448; 3: 290, 363, 369.
Тинчурина Заһидә, укытучы, артистка – 3: 369.
Толстой Лев Николаевич (1828–1910) – 3: 153, 159, 355, 356, 357.
«Бог правду видит, да нескоро скажет» («Алла хаклыкны

белә, ләкин тиз әйтми»);
«Много ли человеку земли нужно?», 1886 («Кешегә күпме
жир кирәк?»);
«Ассирийский царь Асархадон», 1903 («Ассирия патшасы
Асархадон»);
«Три вопроса», 1904 («Өч сөаль»).
«Томас Эдисон кем?», тәрҗемә китап – 3: 153.
«Тормыш» (1913–1918, Уфа), газета – 1: 354.
«Төрек», Мисырда төрки телдә чыккан газета – 3: 68, 71.
«Төрек йорды», Төркиядә чыккан журнал – 3: 246.
«Төрек сүзе», Төркиядә чыккан газета – 1: 343.
Троцкий Лев Давыдович (1879–1940), дәүләт эшлеклесе – 2: 452.
Тукай Габдулла (1886–1913) – 1: 339, 343, 345, 347, 348, 353, 355, 358; 2: 444, 449, 455, 458, 465, 466; 3: 130, 131, 160, 171, 320, 323, 324–328, 332, 334, 335, 336, 344, 353, 357, 358, 372, 376.
«Г.Тукаев шигырьләре» (1907);
«Алтын әтәч» (1908).
Туктаров Фуад (1880–1938), публицист, Октябрьдән соң эмигрант – 3: 167, 351, 353, 358.
У
«Уклар» (1906, Уральск), рәсемле сатирик журнал – 3: 324.
«Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» (1930, Казан), җыентык – 2: 449.
Уральский Габдулла (1903–1942), артист – 3: 292.
Урманчиев Әхмәт (1880–1922), «Ялт-йолт» журналы мөхәррире – 3: 328.
«Усал» (псевдоним) – к.: Туктаров Ф.
Ү
«Үзбәк» (псевдоним) – к.: Тинчурин К.
Ф
Фазыл, Г.Камал бала вакытларда ишегалды җыештыручысы – 3: 313.
Фәйзи Мирхәйдәр (1891–1928), татар драматургы, шагыйрь – 2: 447.
Фәйзи Харис (1870–1933), педагог – 3: 152, 335, 355.
«Гыйльме әшья» (1908).
Фәйсал бине Габделгазиз, Согуд Гарәбстанының патшасы – 3: 297.
«Фәләстин», газета – 3: 299.
Фәхретдинев Риза (Ризаэтдин, 1859–1936) – 2: 456; 3: 184, 353, 360.
«Фикер» (1905–1907, Уральск) газета – 3: 84, 323, 324.
Фикри Лотфи, газета мөхәррире – 3: 252, 265.
Фиргавен – 2: 280, 462.
«Фра дьявол», спектакль – 3: 309, 373.
Фукс Карл Федорович (1776–1846), Казан дәүләт университеты профессоры, медик, этнограф, тарихчы – 3: 313.
Х
Хаҗи Гадел бәк, Төркия дәүләт эшлеклесе – 3: 281.
Хаҗи Теләши М.Б. – 3: 365.
«Хакка шөкер», көйле дини әсәр – 2: 452.
Хаккый Исмәгыйль, төрек әдибе – 3: 238.
Халиди Фатих (1850–1923), татар драматургы – 3: 308, 373.
«Рәдде бичара кыз» (1888) [тәрҗемә].
Хам, дини мифология буенча Нух пәйгамбәр баласы – 2: 280, 461.
Хамматов Шәмси (1919 –1988), журналист, публицист – 3: 332.
Ханзафаров Назыйм (1937 елда туган), әдәбият галиме – 2: 447.
Харитонов Иван Николаевич (1859–1954), Казанда типография хуҗасы – 3: 166, 174, 178, 179, 180, 188, 211, 212, 225, 232, 357, 359, 365, 366, 368, 374.

«Хат болгатты», авторы билгесез пьеса – 1: 350; 3: 124.
Хаува, дини мифология буенча җирдәге беренче хатын-кыз – 2: 465, 467.
Хәбибуллин Мәгъсүм (1941– 2003), әдәбият белгече – 3: 336.
Хәйбулла – 3: 322.
Хәйдәр, 1800–1826 елларда Бохара әмире – 3: 73, 343.
Хәйри бәк, Төркиядә дәүләт эшлеклесе – 3: 281.
Хәйрулла хәзрәт Госманов (1866–1910 нан соң), Оренбург янындагы Каргалы бистәсе мулласы, II Дәүләт Думасы әгъзасы – 3: 184.
Хәйрулла хәлфә Госманов – 3: 184.
Хәйям Гомәр (якынча 1048–1122 елдан соңрак), фарсы-таҗик шагыйре, математик, философ – 2: 81.
Хәким Сибгат (1911–1986), татар шагыйре – 2: 459.
Хәмид Габделхак (1852–1937), төрек шагыйре һәм драматургы – 1: 340; 3: 287, 292, 368, 369.
«Дөхтәре һинд» («Һинд кызы»);
«Әшбәр»;
«Тәзәр».
Хәнәфиев Кәрим – 3: 306.
Хәсәни Әхмәдгәрәй (1883–1934), журналист, нашир – 1: 356; 3: 123, 124, 138, 147, 160, 189, 351, 357, 361.
Хәсәнгата казый – к.: Габәши Хәсәнгата.
«Хәят» (1904–1910, Баку), әзәрбәйҗан телендә чыккан газета – 3: 125, 352.
Хилми Хөсәен паша – 3: 267.
Хисмәтуллин Габделхәй (1895–1977), әдәбият галиме, текстолог – 3: 332.
Хозыр Ильяс, дини-мифологик персонаж – 2: 368, 451, 466, 470.
Хөсәенев Вәли (Мөхәммәдвәли, 1871–1933), мулла, «Дин вә мәгыйшәт» (1906–1918) журналы нашире – 3: 358.
Хөсәенов Әхмәт (1837–1906), Оренбург сәүдәгәре – 3: 182, 360.
Хөсәенов Мәхмүд (1839–1910), Оренбург сәүдәгәре – 2: 227, 456.
Хөсәен хәзрәт (Хөсәен Әмирханов, 1814–1893), Казан мулласы, тарихчы – 3: 60, 341.
Хуҗа Баһаветдин (1318–1389), Бохарада яшәгән шәех, суфичылыкта нәкышьбәнди юнәлешенә нигез салучы – 1: 15, 114, 357; 2: 116, 118, 451.
«Хуҗа һәм приказчик» (1907, Казан) тәрҗемә пьеса – 3: 155, 356.
Һ
«Һади» (псевдоним) – к.: Камал Г.
«Һатиф», (псевдоним) – 1: 404.
Һартман Моритс (1821–1872), чех шагыйре – 2: 471.
Һинди әфәнде – к.: Кадермәтов М.
Ч
Чәләби Мөхәммәд Язычы углы (?–1451 яки 1453 елда үлгән), төрек шагыйре – 2: 449; 3: 24, 66, 72, 82, 338, 343.
«Мөхәммәдия».
Черексулы Мәхмуд паша – 3: 281.
Чехов Антон Павлович (1860–1904) – 1: 350; 3: 111, 311, 349.
«Хирургия» (1884);
«Злоумышленник» (1885).
Чиркова М., типография хуҗасы – 1: 360.
«Чүкеч» (1906–1910, Оренбург), сатирик журнал – 2: 227, 456; 3: 351, 358, 374.
Ш
Шамильский Шакир (1892–1945), артист – 3: 292.
Шамов Афзал (1901–1990), язучы, тәрҗемәче – 2: 449.
Шаһи, Ишми дигән артистның әтисе – 3: 313.

Шаһимәрдәнова Фатыйма, артистка – 1: 353.
Шаһтахтинский Мөхәммәд (1848–1931), әзәрбәйҗан журналисты, нашир, галим, җәмәгать эшлеклесе – 3: 83, 85, 344.
Шәех Сәнуси – 3: 229.
Шәмсетдинова, артистка – 1: 353.
Шәрәф Борһан (1881–1938), нашир, журналист, җәмәгать эшлеклесе – 1: 344; 3: 306, 309, 310.
Шәрәфләр, мәтбагачылар – 3: 130, 306, 324, 327, 354, 358, 372, 376.
«Шәригать һәм заман», сәхнә әсәре – 3: 311.
«Шәркы рус» (1903–1904, Тифлис), төрки телдә чыккан газета – 3: 83, 125, 344, 352.
Шәфигуллин Вәли (1894–1939), журналист, сәяси эшлекле – 2: 457, 458, 459.
Шәһидуллин Шәрәф (Шәрәфетдин), календарьчы, нашир – 3: 123, 174, 359.
«Заман календаре»;
«Безнең Казан» (1909).
Шершеневич Гавриил Феликсович (1863–1912) – хокук белгече, I Дәүләт Думасы депутаты, Казан дәүләт университеты профессоры – 3: 54, 121, 340.
Ширалиев – к.: Коләхмәтев Г.
Шнәйерсон, яһүд раввины – 3: 211.
Шмидт, сырахানә хуҗасы – 3: 325.
Шөкри бәк – 3: 282.
«Шура» (1908–1918, Оренбург), иҗтимагый, фәнни, әдәби журнал – 2: 227, 228; 3: 362.
«Ш. Яров» (псевдоним) – 1: 356.
Э
Эдисон Томас (1847–1931), электр техникасы өлкәсендә уйлап табучы америкалы галим – 3: 153.
Эмилия Генриховна, буфетчы ханым – 3: 325.
«Эстрада», өченче китап (1957, Казан) – 2: 464.
«Эш» (1918–1920), көндәлек сәяси, әдәби вә иҗтимагый газета, «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының элгәре исеме – 2: 442, 443, 458–465, 468–471; 3: 306, 336, 369.
«Эшче» (1918–1931, Казан–Мәскәү), газета – 2: 442, 443; 3: 306.
«Эшче» (псевдоним) – к.: Камал Г.
Ю
Юнусовлар, Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре – 2: 227, 456.
Юань Шикай (1859–1916), Кытай хәрби һәм сәяси эшлеклесе – 3: 91, 92, 93, 94, 346.
Южин-Сумбатов Александр Иванович (1857–1927), рус артисты, драматург – 1: 340.
«Южная мысль», Одессада чыккан газета – 3: 240.
«Южная неделя», Одессада чыккан газета – 3: 240.
Юзиев Ибраһим (1865–1912), Харитонов типографиясендә хәреф җыючы һәм басу остасы – 3: 166, 357.
Я
«Явызлыкның җәзасы», проза әсәре – 3: 169, 170, 358.
Язид, өмәвиләрдән икенче хәлифә – 3: 302, 371.
«Яктылык җиңә» (1955, Казан) – 2: 448.
«Ялт-йолт» (1910–1918, Казан), сатирик журнал – 1: 339, 358; 3: 328, 331, 335.
Ямашев Хөсәен (1882–1912), татар революционеры, публицист – 3: 218, 219, 306, 332, 360, 364.
«Яңа декламатор» (1925, Казан), шигъри җыентык – 2: 459.
«Ярым алма», дини хикәяләр китабы – 2: 458.
Ясәви Әхмәт (XI гасыр ахыры –1066), Урта Азиядә төрки телдә язган суфи шагыйрь – 2: 451.
Яхшыбаев Сабит (1890–1930), театр рәссамы – 3: 332, 333, 366.

«Яшен» (1908–1909, Казан), сатирик журнал – 1: 339, 344; 2: 226–228, 242, 444, 454–456; 3: 168, 325, 326, 327, 328, 331, 334, 356, 358.
«Яшенче» (псевдоним) – к.: Камал Г.
Яэҗүҗ-мәэҗүҗ, мифологик ике халык исеме – 2: 101, 450.

## Г.Камал әсәрләренең библиографиясе

### 1900

Намикъ Кәмал. Кызганыч бала : өч фасылдан гыйбарәт театр уены / мөтәрҗиме Г.Казани (Г.Камал). Казан : Чиркова мәтбагасы, 1900. 48 б.
Өч бәдбәхет. Күп йөрүче хатын, явыз карчык, кеше хатынына тәмгы кыйлучы/ мөәллифе Г.Казани. Казан : Чиркова табгыханәсе, 1900. 32 б.
Бәхетсез егет : драма биш пәрдә илә тәэлиф ителмештер. Казан : «Торговый дом борадәран Кәримевләр» мәтбагасы, 1900. 108 б.
Гали Мозаффар. Баштан үткән бер эш / мөтәрҗиме Г.Казани. Казан : Чиркова табгыханәсе, 1900. 15 б.

### 1901

Балаларга бүләк. Һәдиятел сыйбиян / назыймы Галиәсгар бине Галиәкбәр әл-Казани. Казан : Чиркова табгыханәсе, 1901. 20 б.

### 1903

Сабир хәзрәт [Титул битендә «Гыйбрәт», хикәя үзе «Сабир хәзрәт» дип атала. «Нашире – Галиәсгар бине Галиәкбәр Камалетдинов» дип куелган]. Казан : И.Н.Харитонов мәтбагасы, 1903. 28 б.

### 1904

Балаларга бүләк. Һәдиятел сыйбиян / назыймы Галиәсгар бине Галиәкбәр әл-Казани. Казан : Домбровский табгыханәсе, 1904. 20 б.

### 1905

Өндәү : шигырь // Казан мөхбире. 1905. № 5 (11 ноябрь). (Имзасы – «Саиб»*)
Азатлык : шигырь // Казан мөхбире. 1905. № 8 (28 ноябрь). («Саиб»)
Кем гаепле? // Казан мөхбире. 1905. № 13 (15 декабрь). («Зәйнәб Г. К-ва»)
Русиядә мөселманнар : шигырь // Казан мөхбире. 1905. № 14 (19 декабрь). («Саиб»)
Бер тәшәббес // Казан мөхбире. 1905. № 16 (26 декабрь). («Г.Камалетдинова»)
Кем гаепле? // Казан мөхбире. 1905. № 16 (26 декабрь). («Зәйнәб Г. К-ва»)

### 1906

Кире фикер // Казан мөхбире. 1906. № 27 (20 гыйнвар). («Зәйнәб Г. К-ва»)
Хөррият һәм без // Казан мөхбире. 1906. № 30 (30 гыйнвар). («Һади»)
Заман – хокукымызны үземез мөхафазә кыйлырга лязим булган замандыр // Азат. 1906. № 1 (1 февраль). («Г.»)
3 ноябрь манифесты ни бирә? // Азат. 1906. № 1 (1 февраль). («З. Г-ва»)
Дума, Дума, Дума // Азат. 1906. № 1 (1февраль). («Г.К.»)
Кнәзләр заманында истикъляль // Азат. 1906. № 2 (3 февраль). («Зәйнәб Г. К-ва»)
Әтраф хәбәрләре // Азат. 1906. № 2 (5 февраль). («Г.К.»)
«Иркенчелек кадәр...» // Азат. 1906. № 3 (7 февраль).
Безнең кирәк: шигырь // Азат. 1906. № 4 (9 февраль). («Һади»)
И мөселман, йокламагыл! : шигырь // Азат. 1906. № 5 (12 февраль). («Һади»)
Килешкән ялган // Азат. 1906. № 7. (16 февраль). («Саиб»)
Белек һәм тереклек // Казан мөхбире. 1906. № 38 (17 февраль). («Саиб»)
Уртаклашу татарның табигатенә килешәдер // Азат. 1906. № 8 (19 февраль). («Саиб»)
Табышлы талаш // Казан мөхбире. 1906. № 40 (22 февраль). («Саиб»)
Бер сүз // Казан мөхбире. 1906. № 41 (24 февраль). («Саиб»)
Хәзрәтләргә ник тиямез? // Азат. 1906. № 12 (3 март). («Һади»)
Милләт көймәсе : шигырь // Азат. 1906. № 12 (3 март). («Һади»)
Тугъры мәкъсудка әйләнгеч юл белән җителсә дә ярар // Казан мөхбире. 1906. № 46 (6 март). («Саиб»)

Йокыда : шигырь // Азат. 1906. № 13 (7 март). («Һади»)
Кыргыз илә татар // Вакыт. 1906. № 5 (11 март). («Саиб»)
Гаеп кемдә? // Азат. 1906. № 26 (31 март). («Һади»)
Өмид киселде // Азат. 1906. № 29 (9 апрель). («Г.»)
Ник беттек? // Вакыт. 1906. № 14 (13 апрель). («Һади»)
Русия мәмләкәтенең бурычлары // Азат. 1906. № 37 (23 апрель). («Г.К.»)
Безем хәлләр : шигырь // Азат. 1906. № 38 (25 апрель). («Һади»)
Англиядә басма иркенлеге // Азат. 1906. № 42 (2 май). («Г.К.»)
Фас мәмләкәтенең кызганыч хәлләре // Азат. 1906. № 43 (4 май). («Г.К.»)
Имамнар вә агайлар // Азат. 1906. № 45 (7 май). («Һади»)
Егъламаган балага имчәк бирмиләр : шигырь // Азат. 1906. № 45 (7 май). («Һади»)
Мәкъсудның гакесе тугъды // Азат. 1906. № 46 (9 май). («Саиб»)
Әтраф хәбәрләре // Азат. 1906. № 53 (24 май). («Г.К.»)
Искелек сакчыларына ачык хат // Азат. 1906. № 54 (25 май). («Саиб»)
Крәстиәннәр һәм Дума // Азат. 1906. № 55 (27 май). («Г.К.»)
Бер каз өчен тәртипсезлекләр // Азат. 1906. № 55 (27 май). («Г.К.»)
Русия мөселманнары иттифакы ни нәрсәдер? // Азат халык. 1906. № 1 (4 июнь). («Г.»)
Яңа китап вә гәзитәләр // Азат халык. 1906. № 7 (16 июль). («Г.»)
Безниләр күрмәдек? // Казан мөхбире. 1906. № 125 (30 июль). («Һади»)
Вакыт җитте : шигырь // Азат халык. 1906. № 15 (12 сентябрь). («Һади»)
Революция булганчы Франциядәге авыл халкының тормышы ничек булган? // Азат халык. 1906. № 15 (12 сентябрь). («Г.К.»)
Бәраәт кичәсе [Баш мәкалә урынында] // Йолдыз. 1906. № 38 (16 сентябрь). («Г.Камалетдинов»)
Идарәләрдән [«Азат халык»ның «Йолдыз» газетасына кушылуы турында] // Йолдыз. 1906. № 39 (24 сентябрь). («Г.Камалетдинов»)
Борчылырмыз // Йолдыз. 1906. № 42 (4 октябрь). («Г.К.»)
«Ислях» гәзитәсе // Йолдыз. 1906. № 47 (17 октябрь).
Зур сүз вә зур вакыйга // Йолдыз. 1906. № 48 (21 октябрь).
Гәзитәләр хакында // Йолдыз. 1906. № 56 (22 ноябрь).
Ислам матбугаты // Йолдыз. 1906. № 66 (20 декабрь).
Тел бәхәсе // Әлгасрелҗәдид. 1906. № 12 (декабрь), («Саиб»)
1907
Бәхетсез егет : драма биш пәрдәдә. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1907. 108 б.
Үз гәзитәләремездән // Казан мөхбире. 1907. № 197 (1 гыйнвар). («Г.К.»)
Гәзитә эчендә гәзитә // Йолдыз. 1907. № 74 (12 гыйнвар). («Яшенче»)
Эләкми калынды : кечкенә фельетон // Йолдыз. 1907. № 76 (20 гыйнвар). («Яшенче»)
Бу ел Думага кемнәрне сайлаячакмыз? // Йолдыз. 1907. № 81 (1 февраль).
Морателтәэссеф яхуд морателтәгассыб // Йолдыз. 1907. № 81 (1 февраль). («Яшенче»)
Кытайда ислам вәкилләре // Йолдыз. 1907. № 83 (8 февраль). («Яшенче»)
Шәһре Казан, февраль 8 // Йолдыз. 1907. № 83 (8 февраль).
Тәбрик, тәшәккер вә рәҗа // Йолдыз. 1907. № 83 (8 февраль).
Думага сайлау нәтиҗәләре // Йолдыз. 1907. № 83 (8 февраль).
Мәхкәмәи шәргыя хакимнәреннән гаҗаиб бер тәфрикы зәүҗә // Йолдыз. 1907. № 86 (15 февраль).
Депутатлар озату. (Петербург юлында. Беренче урын) // Йолдыз. 1907. № 88 (20 февраль). («Яшенче»)
Гәзитә караклыгы // Йолдыз. 1907. № 90 (24 февраль).
Депутатлар озату. (Петербург юлында. Икенче урын) // Йолдыз. 1907. № 91 (27 февраль). («Яшенче»)
Дахили хәбәрләр // Йолдыз. 1907. № 92 (1 март). («Яшенче»)
Депутатлар озату. (Петербург юлында) // Йолдыз. 1907. № 94 (8 март). («Яшенче»)

Депутатлар озату. (Петербург юлында. Дүртенче урын) // Йолдыз. 1907. № 95 (10 март). («Яшенче»)
Кытайдан мәктүб // Йолдыз. 1907. № 98 (17 март). (Тәрҗемә кыйлдым – «Яшенче»)
Ачларга ярдәм // Йолдыз. 1907. № 106 (5 апрель).
Ике Дума // Йолдыз. 1907. № 112 (19 апрель).
Гәзитәләр хакында // Йолдыз. 1907. № 114 (1 май).
Ачларга ярдәм эшләре // Йолдыз. 1907. № 120 (16 май).
Мөфти вә депутатлар : ике пәрдәле күренеш // Йолдыз. 1907. № 126 (30 май). («Яшенче»)
Макарья мәктүбләре // Йолдыз. 1907. № 141 (6 июль). («Яшенче»)
«Иттифакы мөслимин»нең изафәсе дөрест түгел, чөн там! // Йолдыз. 1907. № 141 (6 июль). («Яшенче»)
Татарча театр [А.Н.Островскийның «Галимнәр илә наданнар», А.П.Чеховның «Хирургия» пьесаларының куелышы турында] // Йолдыз. 1907. № 145 (15 июль).
«Бәянелхак» һәм «Вакыт» // Йолдыз. 1907. № 151 (29 июль). («Яшенче»)
Макарья мәктүбләре // Йолдыз. 1907. 5 (153), 8 (154), 12 (156), 15 (157), 19 (159) август саннары.
Вак хәбәрләр // Йолдыз. 1907. № 156 (12 август).
«Мәдрәсәи Галия» // Йолдыз. 1907. № 161 (26 август).
«Иршад» гәзитәсе // Йолдыз. 1907. № 162 (29 август).
Думаны истикъбаль // Йолдыз. 1907. № 167 (12 сентябрь).
Гәзитәләрдән // Йолдыз. 1907. № 170 (19 сентябрь).
Үз тарафымнан җавап // Йолдыз. 1907. № 172 (23 сентябрь).
Сайлау алды // Йолдыз. 1907. № 174 (28 сентябрь). («Яшенче»)
Яңа әсәрләр [Ф.Кәриминең «Мирза кызы Фатима», Г.Ильяснең (Әхмәдгәрәй Хәсәнинең) «Хат болгатты» әсәрләре турында] // Йолдыз. 1907. № 177 (5 октябрь).
Бер-ике сүз // Әлислах. 1907. № 2 (октябрь).
Мулла булмагач, чибәр җирдән кыз алып булмый // Әлислах. 1907. № 7 (19 ноябрь). («Яшенче»)
Габдулла Тукаев шигырьләре // Йолдыз. 1907. № 201 (5 декабрь).
Ишмиләр – түнтәрәләр // Йолдыз. 1907. № 203 (12 декабрь).
1908
Беренче театр: комедия бер пәрдәдә. Беренче табгы /мөхәррире Галиәсгар Камал // Театру мәҗмугасы, 5 нче китап. 37 б. [Басылу елы куелмаган]
Мәхбүс шаһзадә // «Шигырьләр» мәҗмугасыннан беренче китап. Казан : Шәрәф мәтбагасы, 1908.
Бәйрәм ашы // Йолдыз. 1908. № 210 (1 гыйнвар). («Яшенче»)
Тәсәлсел мөхаль, бәс, бу да мөхаль // Йолдыз. 1908. № 230 (22 февраль). («Яшенче»)
Яңа шагыйрь [З.Бәшири турында] // Йолдыз. 1908. № 230 (22 февраль). («Яшенче»)
«Помада мәсьәләсе» [И.Багдановның шул исемдәге пьесасы турында] // Йолдыз. 1908. № 239 (19 март).
«Хәкыйкатьме, хыялмы?» [Ф.Кәриминең шул исемдәге әсәре турында] // Йолдыз. 1908. № 243 (28 март).
«Үги балалар» [М.Гафуриның шул исемдәге әсәре турында] // Йолдыз. 1908. № 243 (28 март).
Кечкенә фельетон : мәкальләр // Йолдыз. 1908. № 248 (11 апрель). («Яшенче»)
Гипнотизм мәҗлесендә // Йолдыз. 1908. № 268 (29 май).
«Яшь гомер» [Г.Коләхмәтевнең шул исемдәге драмасы турында] // Йолдыз. 1908. № 270 (5 июнь).
«Ачлык кушты» [Я.Вәлинең шул исемдәге драмасы турында] // Йолдыз. 1908. № 274 (17 июнь).
«Гыйльме эшья» [Х.Фәйзинең шул исемдәге дәреслеге турында] // Йолдыз. 1908. № 277 (24 июнь).

«Уку көтебханәсе» [Л.Н.Толстойның «Алла хаклыкны белә, ләкин тиз әйтми» һ.б. әсәрләр турында] // Йолдыз. 1908. № 277 (24 июнь).
Татарча театр [Г.Багдановның «Хуҗа һәм приказчик» һәм русчадан тәрҗемә ителгән «Кияү эзләү» пьесалары буенча куелган спектакльләр турында] // Йолдыз. 1908. № 285 (16 июль). («Яшенче»)
«Яшен» сукмасын өчен : шигырь // Яшен. 1908. № 1 (3 август). («Мәҗмәгыйддәгъват»тан күчереп язучы «Сагыйка».) («Яшенче»)
Тел берләштерәләр // Яшен. 1908. № 1 (3 август). («Яшенче»)
Игъланчылар ничек шаяралар // Йолдыз. 1908. № 335 (27 ноябрь). («Г.К.»)
Яңа әсәрләр [Л.Н.Толстойның «Кешегә күпме җир кирәк?», «Ассирия патшасы Асархадон», «Өч сөаль» әсәрләре турында] // Йолдыз. 1908. № 343 (7 декабрь). («Г.К.»)
Яңа әсәрләр. «Балалар дөньясы», беренче китап – «Кечкенә Рәшид» // Йолдыз. 1908. № 341 (11 декабрь).
Оренбург–Казан : шигырь // Яшен. 1908. № 5 (17 декабрь). («Яшенче»)
Гласныйлык һәвәскәре // Йолдыз. 1908. № 344 (21 декабрь). («Яшенче»)
1909
Балаларга бүләк. Һәдиятел сыйбиян / назыймы Галиәсгар Камал. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1909. 20 б.
Күгәргән алтыннар : кечкенә хикәя. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе; «Үрнәк» мәтбагасы, 1909. 32 б.
Бүләк өчен. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе; «Үрнәк» мәтбагасы, 1909. 30 б.
Тәкый гаҗәб : шигырь // Яшен. 1909. № 6 (31 гыйнвар). («Яшенче»)
Яңа әсәрләр [Г.Җәгъфәревнең «Җәгърафия мөгаллиме» исемле китабы турында] // Йолдыз. 1909. № 369 (26 февраль).
Тәмсилләр // Яшен. 1909. № 7 (2 март). («Барыйка»)
«Явызлыкның җәзасы» [Әш-Шәех әл-Галиминең шул исемдәге әсәре турында] // Йолдыз. 1909. № 373 (9 март).
Яңа әсәрләр [Г.Рәхимнең «Җир йөзе» исемле китабы турында] // Йолдыз. 1909. № 377 (19 март).
«Безнең Казан». Казан выставкасының рәһбәре // Йолдыз. 1909. № 378 (23 март). («Г.К.»)
Җәйге мәктәпләр, яхуд мәктәпләрнең җәйләүләре // Йолдыз. 1909. № 392 (28 апрель). («Г.К.»)
Яңа китаплар [Г.Тукайның «Алтын әтәч» исемле китабы турында] // Йолдыз. 1909. № 406 (2 июнь).
Иван Николаевич Харитонов // Яшен. 1909. № 10 (24 июнь).
Иван Николаевич Харитонов // Йолдыз. 1909. № 415 (25 июнь).
1910
Бухгалтерия / тәрҗемә вә мөрәттибләре : Г.Камал, И.Кули. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1910. 430 б.
Мөселман студентларымыз // Йолдыз. 1910. № 513 (10 март).
Күрше тавыгы күркә булып күренә! // Йолдыз. 1910. № 513 (10 март).
Яңа әсәр [Ф.Әмирханның «Яшьләр» исемле китабы чыгу уңае белән] // Йолдыз. 1910. № 514 (14 март).
Миссионерлар фикере // Йолдыз. 1910. № 520 (28 март).
Татарча театр [И.Багдановның «Югалган хатын» исемле пьесасы куелуы турында] // Йолдыз. 1910. № 562 (11 июль). («Яшенче»)
Дустыма : шигырь // Вакыт. 1910. № 630 (17 июль).
Бәйрәм хәзерлекләре : шигырь // Йолдыз. 1910. № 589 (22 сентябрь). («Яшенче»)
«Хисап мәсьәләләре» [М.Корбангалиевнең «Хисап мәсьәләләре һәм гадәди мисаллар» исемле дәреслегенә карата] // Йолдыз. 1910. № 614 (25 ноябрь). («Г.К.»)
1911

Уйнаш : драма өч пәрдәдә // Театру мәҗмугасы, II җилд, 11 нче китап. Казан : Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе, 1911. 51 б.
Мәктәп вә мәдрәсәләремез // Йолдыз. 1911. № 653 (6 март).
Сабан туе // Йолдыз. 1911. № 673 (21 апрель). («Г.К.»)
Мәтбага исляхаты // Йолдыз. 1911. № 678 (3 май).
Имля вә хоруф мәсьәләсе // Йолдыз. 1911. № 693 (7 июнь).
Эч пошканда // Йолдыз. 1911. № 703 (30 июнь). («Яшенче»)
Ашыгып эшләнмәс! // Йолдыз. 1911. № 705 (5 июль). («Яшенче»)
Мәкәрҗә сәфәре // Йолдыз. 1911. № 722 (18 август). («Г.К.»)
Татарча театр [Я.Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Г.Рәхимнең «Дачада» пьесалары куелу уңае белән] // Йолдыз. 1911. № 739 (4 октябрь). («Яшенче»)
1912
Дәҗҗал : драма дүрт пәрдәдә, биш картинада. Казан : «Сабах» көтебханәсе; «Өмид» мәтбагасы, 1912. 59 б.
Банкрот : пьеса 3 пәрдәдә. 1 нче табагы // Театру мәҗмугасы, II җилд, 13 нче китап. Казан : Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе, 1912. 72 б.
Мәтбагачылыкта тәрәккъый // Йолдыз. 1912. № 789 (3 гыйнвар).
Әдәби бәхәсләр // Йолдыз. 1912. № 789 (5 февраль).
Дамелла Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең намен таәбид итү хакында // Йолдыз. 1912. № 798 (26 февраль).
Йорт кирәге җәмгыяте // Йолдыз. 1912. № 800 (1 март).
Хөсәен әфәнде Ямашевның җеназа мәрасиме // Йолдыз. 1912. № 808 (20 март). («Г.К.»)
Ак чәчәк бәйрәме мөнәсәбәте илә // Йолдыз. 1912. № 821 (19 апрель). («Г.К.»)
Татарча театр [Я.Вәлинең «Ачлык кушты», К.Бәкернең «Чөн там» пьесалары куелу уңае белән] // Йолдыз. 1912. № 822 (22 апрель).
Кыз сату // Йолдыз. 1912. № 822 (22 апрель).
Русча мөселман гәзитәсе // Йолдыз. 1912. № 823 (24 апрель).
Яңа әсәрләр [Харитонов мәтбагасында телсезләр өчен әлифба чыгу уңае белән] // Йолдыз. 1912. № 831 (13 май).
Африка харитәсе [Африканың географик картасы чыгу уңае белән] // Йолдыз. 1912. № 831 (13 май).
Фатыйха ханым Аитова мәктәбендә кул эшләре выставкасы // Йолдыз. 1912. № 845 (10 июнь).
Хәрефләр исляхы // Йолдыз. 1912. № 845 (10 июнь).
Бакча-шәһәр // Йолдыз. 1912. № 855 (10 июнь). («Г.К.»)
«Сәйяр» труппа [Бу труппа тарафыннан үткәрелгән кичә турында] // Йолдыз. 1912. № 863 (31 июль).
Үз хәлемез // Йолдыз. 1912. № 871 (21 август).
Мөселман рәссам // Йолдыз. 1912. № 877 (6 сентябрь).
Сайлау алдыннан жыеннар // Йолдыз. 1912. № 881 (16 сентябрь).
Үз хәлемездән // Йолдыз. 1912. № 901 (1 ноябрь).
Истанбул юлыннан // Йолдыз. 1912. № 912 (2 декабрь).
Истанбул мәктүбләре // Йолдыз. 1912. 11 (916), 15 (918), 18 (919), 20 (920), 23 (921), 30 (924) декабрь саннары.
Мәрхүм Әхмәд Мидхәд әфәнде // Йолдыз. 1912. 23 (921), 25 (923) декабрь саннары.
1913
Балаларга бүләк. Һәдиятел сыйбиян / назыймы Галиәсгар бине Галиәкбәр әл-Казани. Казан : Антонов мәтбагасы, 1913. 20 б.
Безнең шәһәрнең серләре : манзара биш пәрдәдә. 1 нче табагы //Театру мәҗмугасы, II җилд, 15 нче китап. Казан : Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе, 1913. 92 б.

Кайниш [Уртача тормышлы кешеләр мәгыйшәтеннән пьеса]. Бер пәрдәдә, ике манзарада. 1 нче табагы // Театру мәҗмугасы, II җилд, 17 нче китап. Казан : Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе, 1913. 28 б.
Истанбул мәктүбләре // Йолдыз. 1913. 1 (925), 13 (930), 17 (932), 22 (934), 29 (937) гыйнвар саннары.
Яңа елда ни телисез? [Галиәсгар Камал җавабы] // Аң. 1913. № 22 (17 ноябрь).
1914
Деннери А.Ф. (д’Эниери) һәм Кармен. Хөкемдә хаталык. [Мортон карьясендә үтереш] : драма алты пәрдәдә / мөтәрҗиме Г.Камал. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1914. 219 б.
Островский А.Н. Гроза : драма биш пәрдәдә / мөтәрҗиме Г.Камал. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1914. 160 б.
Касбар Т. Саран : комедия биш пәрдәдә [Төрекләр тормышыннан] / мөтәрҗиме Г.Камал. 1 нче басма // Театру мәҗмугасы, 11 нче кисәк, 19 нчы китап. Казан : Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе, 1914. 131 б.
Кибетче: көлке бер пәрдәдә / русчадан мөтәрҗиме Г.Камал // Театру мәҗмугасы. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1914. 30 б.
Дюфре Морис һәм Руше Жак. Гашыйк: көлке бер пәрдәдә / мөтәрҗиме Г.Камал. Казан : «Мәгариф» көтебханәсе, 1914. 32 б.
«Янә бер соң сүз» // Йолдыз. 1914. № 1228 (15 март).
Идарәгә мәктүбләр [«Гроза»ның тәрҗемәсе турында] // Кояш. 1914. № 376 (1 апрель).
«Бәянелхак» мөхәррире // Кояш. 1914. № 384 (10 апрель), («Галиәсгар»)
Борчак падишаһ [Мамин-Сибиряк әсәре] / мөтәрҗиме Г.Камал // Кояш. 1914. № 484 (14 август).
1915
«Саран» пьесасы хакында // Йолдыз. 1915. № 1530 (15 октябрь).
1916
Таңчы тагын сүгенә башлады // Йолдыз. 1916. № 1601 (31 гыйнвар). («Йолдызчы»)
1918
Өйләнәм!.. Ник өйләндем? : комедия ике пәрдәдә // Театру мәҗмугасы, 1 нче китап. Казан : «Милләт» мәтбагасы, 1918. 32 б.
Көндәш : комедия бер пәрдәдә // Театру мәҗмугасы, 2 нче китап. Казан : «Милләт» мәтбагасы, 1918. 15 б.
Кесә өчен русча-татарча мөкәммәл сәяси лөгать / мөтәрҗиме Галиәсгар Камал. Казан : «Васита» көтебханәсе, 1918. 139 б.
Яңа «Тәкый гаҗәб» : шигырь // Эш. 1918. № 61 (13 сентябрь). («Әүлия һәм компания»се)
Тагы «Гаҗәб» китабы: шигырь // Эш. 1918. № 64 (17 сентябрь). («Әүлия һәм компания»се)
Өр-яңа «Кисекбаш китабы» : шигырь // Эш. 1918. № 66 (19 сентябрь).
«Ак»ка «шөкер» китабы : шигырь // Эш. 1918. № 67 (20 сентябрь). («Әүлия һәм компания»се)
«Бакырган» китабы : шигырь // Эш. 1918. № 68 (21 сентябрь). («Әүлия һәм компания»се)
«Кызыл алма» китабы : шигырь // Эш. 1918. № 69 (23 сентябрь). («Әүлия һәм компания»се)
Мин сөям : шигырь // Эш. 1918. № 74 (30 сентябрь). («Ишан Гали»)
Байлар бишеге : шигырь // Эш. 1918. № 77 (4 октябрь).
«Бәдәвам» китабы : шигырь // Эш. 1918. № 70 (8 октябрь). («Әүлия һәм компания»се)
«Без кол идек бай кулында...» : шигырь // Эш. 1918. № 91 (4 ноябрь). («Ишан Гали»)
Нәүруз мөбарәкбад! : шигырь // Эш. 1918. № 93 (7 ноябрь). («Ишан Гали»)
Кызыль кара, кызыл-кара : шигырь // Эш. 1918. № 96 (13 ноябрь). («Ишан Гали»)
Вильһелм тәхетеннән төште : шигырь // Эш. 1918. № 96 (13 ноябрь).
Милләтчеләр, динчеләр : шигырь // Эш. 1918. № 98 (15 ноябрь). («Ишан Гали»)
Вәгазь-нәсихәтләр : шигырь // Эш. 1918. № 104 (22 ноябрь). («Ишан Гали»)
Булса да булыр шул : шигырь // Эш». 1918. № 105 (24 ноябрь). («Ишан Гали»)

Караларга : шигырь // Эш. 1918. № 113 (4 декабрь). («Ишан Гали»)
Капитал иярченнәренә : шигырь // Эш. 1918. № 116 (9 декабрь).
Спекулянтка : шигырь // Эш. 1918. № 117 (10 декабрь). («Ишан Гали»)
Төш тәгъбире : шигырь // Эш. 1918. № 118 (11 декабрь). («Ишан Гали»)
Таң : шигырь // Эш. 1918. № 119 (12 декабрь). («Ишан Гали»)
Буржуй зары : шигырь // Эш. 1918. № 120 (13 декабрь). («Ишан Гали»)
Ирек авыруы : шигырь // Эш. 1918. № 121 (15 декабрь). («Ишан Гали»)
Капитал тозагында : шигырь // Эш. 1918. № 122 (16 декабрь). («Ишан Гали»)
Туфан : шигырь // Эш. 1918. № 124 (19 декабрь). («Ишан Гали»)
Европа җанварларына : шигырь // Эш. 1918. № 126 (22 декабрь). («Ишан Гали»)
Ят (  ) һәм ия (ія) не бетерү : шигырь // Эш. 1918. № 128 (24 декабрь). («Ишан Гали»)
1919
Әсир моңы : шигырь // Эш. 1919. № 136 (5 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Безнең файда : шигырь // Эш. 1919. № 140 (10 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Буржуй планы : шигырь // Эш. 1919. № 142 (13 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Чагыштыру : шигырь // Эш. 1919. № 144 (15 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Теләк : шигырь // Эш. 1919. № 145 (16 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Корсак : шигырь // Эш. 1919. № 147 (19 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Кызыл флотта : шигырь // Эш. 1919. № 149 (21 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Бары да кача : шигырь // Эш. 1919. № 150 (22 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Бер, ике, өч : шигырь // Эш. 1919. № 152 (26 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Игенченең зары : шигырь // Эш. 1919. № 153 (27 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Галәбә : шигырь // Эш. 1919. № 154 (28 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Маленькие недостатки механизма : шигырь // Эш. 1919. № 154 (28 гыйнвар).
Пәрәвез : шигырь // Эш. 1919. № 150 (30 гыйнвар). («Ишан Гали»)
Ирек таңы : шигырь // Эш. 1919. № 158 (2 февраль). («Ишан Гали»)
Татар театры : мәкалә // Эш. 1919. № 159 (2 февраль).
Капиталга : шигырь // Эш. 1919. № 159 (3 февраль). («Ишан Гали»)
Минем теләк (Кеше гашыйк кара күзгә...) : шигырь // Эш. 1919. № 162 (6 февраль). («Ишан Гали»)
Бию көе: шигырь // Эш. 1919. № 162 (6 февраль). («Әүлия һәм компания»се)
Ярлының җыруы : шигырь // Эш. 1919. № 163 (7 февраль). («Ишан Гали»)
Кар күрәгәндә : шигырь // Эш. 1919. №164 (9 февраль). («Ишан Гали»)
Бай – кибетче : шигырь // Эш. 1919. №165 (10 февраль). («Ишан Гали»)
Ниләр бетте, ниләр калды? : шигырь // «Эш», 1919, №167 (10 февраль). («Ишан Гали»)
Сөйләшү : шигырь // Эш. 1919. № 169 (14 февраль). («Ишан Гали»)
Татарга : шигырь // Эш. 1919. № 173 (19 февраль). («Ишан Гали»)
Бай : шигырь // Эш. 1919. № 184 (5 март). («Ишан Гали»)
Бүген бәйрәм : шигырь // Эш. 1919. № 190 (12 март). («Ишан Гали»)
Кызыл флотта: шигырь // Эш. 1919. № 198 (24 март). («Кызыл»)
«Буржуйны без яратмыйбыз...» // Эш. 1919. № 202 (28 март). («Эшче»)
Большевизм көрәше : шигырь // Эш. 1919. № 208 (6 апрель). («И.Гали»)
Кем көчле? : шигырь // Эш. 1919. № 220 (21 апрель). («Кызыл»)
Артык йомрык : шигырь // Эш. 1919. № 222 (22 апрель). («Кызыл»)
Флот килә : шигырь // Эш. 1919. № 224 (25 апрель). («Кызыл»)
Кызыл армиялеләрнең Беренче май җырлары : шигырь // Кызыл көрәшче. 1919. № 1 (1 май).
Кызыл армияле һәм спекулянт : шигырь // Эш. 1919. № 183 (4 май). («Ишан Гали»)
Ирек нуры : шигырь // Эш. 1919. № 228 (19 май). («Кызыл»)
Сез һәм без : шигырь // Эш. 1919. № 229 (20 май). («Кызыл»)
Алга! : шигырь / Эш. 1919. № 231 (22 май). («Әдип»)
Зар : шигырь // Эш. 1919. № 232 (23 май). («Кызыл»)

Ишан Гали сәяхәте : шигырь // Эш. 1919. № 340 (4 ноябрь).
Ике ел : шигырь // Эш. 1919. № 341 (5 ноябрь). («Ишан Гали»)
Деникин төше : шигырь // Эш. 1919. № 356 (28 ноябрь). («Ишан Гали»)
Истикъбаль : шигырь // Эш. 1919. № 360 (3 декабрь). («Ишан Гали»)
Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре! : шигырь // Эш. 1919. № 364 (30 декабрь). («Ишан Гали»)
1921
Декламацияләр [Җитди, һәҗүви назымнар һәм декламацияләр]. Казан : Шәрекъ коммунистлары мәркәз бюросының нәшере, 1921. 153 б.
Бу китапта язучының беренче мәртәбә басылган шигырьләре: Яңа типта халык җырлары; Нәүрүз (яки Науруз); Шайтаннар биюе; Бер ел элек; Чегән бәете; Минем теләк (Булса бик ак сумса...); Һай, дөнья!; «Матур яр, кенәри» көенә; Яңа «Җизнәкәй»; «Арыслан да сөяк ашый...»; Исемнәр; Бер рәсемгә; Нәрсә сөйләргә кирәк?; Бәрәңге; Әүвәлгечә түгел; Бай сүзе; «Солых булгач...»; Буржуй теләге; Нәсер (Күк йөзе – бер барабан ул...); Алар сафыннан; Хаталык; Белә алмыйм; Бетмәде әле; Халык җырынча; Тәмле нигъмәтләр өстәле; Нәсер (Усал булсаң – асарлар...); «Яңгыратып әйтсә дә ирек азаны...»; Элек һәм хәзер; Табышмаклар; Корды, балам, бу кала.
1923
Дингә хезмәт итүчеләр арасында // Татарстан. 1923. № 235 (12 декабрь).
1924
Һинд кызы // Кызыл Татарстан. 1924. № 210 (30 октябрь).
Күчәр башы // Кызыл Татарстан. 1924. № 251 (22 декабрь).
1925
Галиәсгар Камал әсәрләре [Г. Рәхимнең «Галиәсгар Камал турында берничә сүз» дигән мәкаләсе белән]. Казан : Тат. мат. нәшр. комб. басмасы, 1925. 132 б.
Эчтәлек: Бүләк өчен; Беренче театр; Бәхетсез егет.
1927
Ислам, хәлифәлек мәсьәләсе һәм империалистлар // Кызыл Татарстан. 1925. № 66 (27 март).
1928
Бүләк өчен : комедия бер пәрдәдә. Казан : Яңалиф, 1928. 23 б.
Әзәрбәйҗан драматургы Мирза Фәтхегали Ахундов // Кызыл Татарстан. 1928. № 61 (11 март).
1929
Хафизәләм иркәм : комедия дүрт пәрдәдә. Казан : Татар. дәүл. нәшр., 1929. 36 б. (Тат. сәяси аң-белем баш комитеты.)
Беренче театр : комедия бер пәрдәдә. Казан : Яңалиф, 1929. 15 б.
Г.Камал әсәрләре. 1 т. [Ф.Сәйфинең «Галиәсгар Камал» дигән мәкаләсе белән]. Казан : Яңалиф, 1929. 178 б.
Эчтәлек: Бәхетсез егет; Беренче театр; Безнең шәһәрнең серләре; Банкрот.
Г.Камал чыгышы [М.Яхинның «Галиәсгар ага Камал кичәсе» дигән мәкаләсе эчендә китерелә] // Кызыл Татарстан. 1929. № 89 (21 апрель).
Тыкшынмагыз! : редакциягә хат // Кызыл Татарстан. 1929. № 193 (26 апрель).
1930
Ахыры заман [«Ахыры заман» исемле комедиянең беренче пәрдәсе] // Ун ел эчендә татар матур әдәбияты (1920–1930). Казан : Татиздат, 1930. 320–333 б.
Г.Камал әсәрләре. 2 т. Казан : Яңалиф, 1930. 159 б.
Эчтәлек: Бүләк өчен; Дәҗҗал; Уйнаш; Кайниш; Көндәш; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Күгәргән алтыннар.
1933
Өч тормыш : өч пәрдәдә : клуб сәхнәләре өчен пьеса. Казан : Татиздат, 1933. 39 б.
Эчтәлек: Өч тормыш; Күзсез мастерлар.

Г.Камал сүзе [Татарстан совет язучылары союзын оештыру комитетының 1 нче пленумында сөйләгән] // Совет әдәбияты. 1933. № 1 (гыйнвар).
Габдулла Тукай турында истәлек // Совет әдәбияты. 1933. № 6 (июнь).
Тормыш юлым // Совет әдәбияты. 1933. № 4–5 (июль).
1934
Бүләк өчен : комедия. Казан : Татгосиздат, 1934. 23 б.
Минем персональный пенсионер булуымның тарихы // Совет әдәбияты. 1934. № 6 (июнь).
1935
Галиәсгар Камал әсәрләре [Г.Нигъмәтинең «Драматург Г.Камалның әдәби эшчәнлек юлы» дигән мәкаләсе белән]. Казан : Татгосиздат, 1935. 574 б.
Эчтәле: Бәхетсез егет; Беренче театр; Бүләк өчен; Көндәш; Уйнаш; Банкрот; Дәҗҗал; Кайниш; Безнең шәһәрнең серләре; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Өч тормыш; Күзсез мастерлар; Хафизәләм иркәм; Күгәргән алтыннар.
Кушымталар: Бәхетсез егет; драматург Г.Камалның әсәрләренә библиография; кайбер аңлашылмый торган чит сүзләргә сүзлек.
«Әсәрләр»дә беренче мәртәбә басыла: Тәкый гаҗәб, яки Ахырзаман; Ысулы кадимче; Могҗиза; Җантаһир белән Җанзөһрә; Минем персональный пенсионер булуымның тарихы.
Беренче театр : оперетта // Совет әдәбияты. 1935. № 6 (июнь).
1938
Сайланма әсәрләр [Хан Җәмилнең «Галиәсгар Камал» дигән мәкаләсе белән]. Казан : Татгосиздат, 1938. 534 б.
Эчтәлек: Бәхетсез егет; Беренче театр; Бүләк өчен; Көндәш; Уйнаш; Банкрот; Дәҗҗал; Кайниш; Безнең шәһәрнең серләре; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Өч тормыш; Күзсез мастерлар; Хафизәләм иркәм; Җантаһир белән Җанзөһрә; Күгәргән алтыннар.
Тезмә әсәрләр: Могҗиза.
Кушымталар: Бәхетсез егет; Минем персональный пенсионер булуымның тарихы; драматург Г.Камал әсәрләренә библиография; сүзлек.
Беренче мәртәбә басыла: Ак бөркәнчек (М.И.Михайловтан); Яза башлавым тарихы.
1939
Беренче театр : комедия бер пәрдәдә. Казан : Татгосиздат, 1939. 32 б.
1942
Сайланма әсәрләр. Казан : Татгосиздат, 1942. 388 б.
Эчтәлек: Бәхетсез егет; Беренче театр; Бүләк өчен; Көндәш; Уйнаш; Банкрот; Дәҗҗал; Кайниш; Безнең шәһәрнең серләре; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Хафизәләм иркәм; Яза башлавым тарихы; Минем персональный пенсионер булуымның тарихы.
1944
Банкрот : комедия өч пәрдәдә. Казан : Татгосиздат, 1944. 64 б.
1950
Әсәрләр. 1 т. : драматургия әсәрләре. 1898–1933. [М.Гайнуллинның «Галиәсгар Камал» дигән сүз башы белән] / төз. М.Гали. Казан : Татгосиздат, 1950. 438 б.
Эчтәлек: Бәхетсез егет; Беренче театр; Бүләк өчен; Уйнаш; Банкрот; Дәҗҗал; Безнең шәһәрнең серләре; Кайниш; Көндәш; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Хафизәләм иркәм; Өч тормыш; Бәхетсез егет (беренче вариант); Өч бәдбәхет; искәрмәләр.
1951
Әсәрләр. 2 т. : шигырьләр, проза һәм публицистика [М. Гайнуллинның «Галиәсгар Камалның шигырьләре, публицистик һәм прозаик әсәрләре» дигән сүз башы белән] / төз.: М.Гали Казан : Татгосиздат, 1951. 296 б.
Эчтәлек: Шигырьләр; Хикәяләр.
«Әсәрләр»дә беренче мәртәбә басыла: «15 ел», «Кыз белән җегет» шигырьләре, язучының фельетоннары һәм публицистикасы, «Беренче театр» опереттасы, Г.Камалның псевдонимнары.

1953
Беренче театр : комедия бер пәрдәдә. Казан : Татгосиздат, 1953. 28 б.
Банкрот : пьеса өч пәрдәдә. Казан : Татгосиздат, 1953. 64 б.
1954
Декламацияләр. Казан : Таткнигоиздат, 1954. 31 б. («Масса китапханәсе».)
Истәлекләр: урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен. Казан : Таткнигоиздат, 1954. 36 б. («Мәктәп китапханәсе».)
Эчтәлек: Минем персональный пенсионер булуымның тарихы; Яза башлавым тарихы; Габдулла Тукай турында истәлек.
1969
Драма һәм комедияләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 1969. 299 б.
Эчтәлек: Бәхетсез егет; Беренче театр; Бүләк өчен; Көндәш; Уйнаш; Безнең шәһәрнең серләре; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Кайбер гарәп-фарсы сүзләренә аңлатма.
1978
Әсәрләр. 3 томда : 1 т. : пьесалар / төз., искәрмәләрне хәзерләүче һәм соңгы сүз авт. Б.Гыйззәт. Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. 406 б.
Эчтәлек: Бәхетсез егет; Беренче театр; Бүләк өчен; Уйнаш; Банкрот; Безнең шәһәрнең серләре; Дәҗҗал; Кайниш; Көндәш; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?
Кушымта: Бәхетсез егет; Өч бәдбәхет; Кызганыч бала; Аңлатма һәм искәрмәләр.
Беренче театр Галиәсгар Камалның йөз еллыгына багышлана [Азат Әхмәдуллинның кереш сүзе белән]. Казан : Татар. кит. нәшр., 1978. 187 б. (Татар һәм рус телләрендә.)
1979
Әсәрләр. 3 томда : 2 т. : пьесалар, эстрада әсәрләре, шигырьләр. 1905–1933 / төз., текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче, соңгы сүз авт. Н.Ханзафаров. Казан : Татар кит. нәшр., 1979. 543 б.
«Әсәрләр»дә беренче мәртәбә басыла: Контроль будкасы; Җанлы кино; Казаннан хатлар; Аҗак белән Куҗак (1); Аҗак белән Куҗак (2); Ике туган Алкоголь, Прогул; Прорывлар (1); Прорывлар (2); Һиндстан факире; Корфетдин белән Торфетдин; Хатип белән Латип; Ударник һәм безударник; Өч тормыш (беренче вариант); Хатыннар тегүчесе (тәрҗемә); Ударник; Бозау; Хафизәләм иркәм (беренче вариант).
1982
Әсәрләр. 3 томда : 3 т. : хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр (1900–1933) / төз. : З.Рәмиев (җитәкче), Ф.Ибраһимова, Ә.Алиева, М.Хәбибуллин. Казан : Татар. кит. нәшр., 1982. 415 б.
2004
Сайланма әсәрләр : пьесалар, хикәяләр, истәлекләр / төз. Р.Корбан. Казан : Татар. кит. нәшр., 2004. 302 б.
Эчтәлек: Пьесалар: Бәхетсез егет; Беренче театр; Уйнаш; Банкрот; Кайниш; Безнең шәһәрнең серләре; Өйләнәм!.. Ник өйләндем?; Хафизәләм иркәм;
Хикәяләр: Сабир хәзрәт; Күгәргән алтыннар; Искәрмәләр.
2005
Галиәсгар Камал: әдип һәм заман : язучының йөз егерме биш еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы / Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Казан, 2005. 105 – 153 б.
Эчтәлек: Истанбул мәктүпләре; Гәзитә эчендә гәзитә; Гәзитәләр хакында; Кытайдан хат.

Г.Камал әсәрләре рус телендә
Первый театр [отрывок из комедии] // Красная Татария. 1939. 6 января.
Первое представление : комедия в одном действии // пер. Э.Хаджиевой; вступ. ст. Г.Кашшафа. Казань : Татгосиздат, 1939. 32 с.
Пьесы / пер. Э.Хаджиевой. Казань: Татгосиздат, 1940. 66 с.
Содержание: Банкрот; Из-за подарка.

Банкрот : комедия в трех действиях / Татарское отделение Всероссийского театрального общества. Казань : Татгосиздат, 1944.
Содержание: Классик татарской драматургии Галиасгар Камал; Краткое содержание комедии «Банкрот»; Программа.
Первое представление / пер. Э.Хаджиевой // Пьесы татарских драматургов-классиков. Казань : Татар. кн. изд-во, 1958. С. 105–121.
Из-за подарка / пер. Э.Хаджиевой // Пьесы татарских драматургов-классиков. Казань : Татар. кн. изд-во, 1958. С. 121–135.
Банкрот / пер. Э.Хаджиевой // Пьесы татарских драматургов-классиков. Казань : Татар. кн. изд-во, 1958. С. 135–175.
Тайны нашего города / пер. Г.Фахретдинова // Пьесы татарских драматургов-классиков. Казань : Татар. кн. изд-во, 1958. С. 175–223.

Г.Камалның Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивындагы кульъязмалары
Корсын, балам, бу кала : бер пәрдәлек шигъри скетч [1931 елда язылган дип исәпләнелә]. 13 ф. 1 тасв. 12 эш.
1933 елда без нәрсә өчен көрәшәбез? [Информацион характердагы язма]. 1933. 13 ф. 1 тасв. 29 эш.
Джакометти П. Семья разбойника (Җинаятьче гаиләсе) : биш пәрдәле мелодрама / тәрҗ. Г.Камал. 13 ф. 1 тасв. 32 эш.
Дюма Александр. Дама с камелиями (Чәчәкле хатын) : драма биш пәрдәдә, алты картинада. 1920. 13 ф. 1 тасв. 33 эш.

Г.Камал тәрҗемә иткән, ләкин китап булып
чыкмаган пьесалар*
Мольер Ж.Б. Ирексездән табиб : комедия өч пәрдәдә. 1916 елда куела.
Бер сәгатьлек адвокат : бер пәрдәдә. [русчадан] 1916 елда куела.
Карт өйләнә : комедия бер пәрдәдә. [төрекчәдән] 1916 елда куела.
Южин-Сумбатов А.И. Лачыннар һәм козгыннар : драма дүрт пәрдәдә. 1917 елда куела.
Хәмит Г. Һинд кызы : фаҗига биш пәрдәдә. 1918 елда куела.
Кәмал Н. Ватан : драма. 1918 елда куела.
Кара пәрдә (Билгесез хатын) : драма дүрт пәрдәдә. [русчадан] 1918 елда куела.
Карпов С. Эшчеләр бистәсе : драма. 1919 елда куела.
Невежин П.М. Икенче кат яшьлек. : драма. 1919 елда куела.
Лопе де Вега. Сарык чишмәсе : комедия. 1919 елда куела.
Гордин Я. Иблис: комедия дүрт пәрдәдә. 1922 елда куела.
Хейерманс Г. Надежданың һәлакәте: драма. 1922 елда куела.
Мольер Ж.Б. Скапенның хәйләсе (Хәйләкәр Сөләйман) : комедия. 1924 елда куела.
Сежур В., Брезиль Ж. Сынган күңел.

Г.Камалга нисбәт ителгән, әмма әлегә ачыкланып бетмәгән тәрҗемәләр*
Мольер Ж.Б. Хаста (Мнимый больной) : комедия. 1915.
Трильби Гр.Ге. Оҗмах кошы : драма. 1917.
Әл-Хадәдә Н. Сәлахетдин Әюби : фаҗига. 1917.
Мөнир Ә. Солтан Мөхәммәд-Фатыйх : драма. 1917.
Чиратлы чалбар. 1917.
Хәйдәр Г. Шаһгали хан : фаҗига. 1918.
Итекләр качты. 1920.
Имам Хәмзә. 1922.
Серле Сарай (Сирай). 1924.
Хан кызы Зөһрә. 1924.

Мең сум; Алтын кармак; Ата белән балалар ; Бушбугазлар.

Литературно-художественное издание
Камал Галиасгар (Камалетдинов Галиасгар Галиакберович)
Сочинения
Издание второе, исправленное и дополненное
В трех томах
Том 3
Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Камал Галиәсгар (Камалетдинов Галиәсгар Галиәкбәр улы)
Әсәрләр
Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма
Өч томда
3 том

Мөхәррире Р.В.Сабирҗанов
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире Р.Х.Хәсәншин
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы С.Н.Нуриева
Корректорлары Л.Р.Галимова, Г.Г.Гарифуллина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 29.06.2010. Форматы 84г108 1/32. Шартлы басма табагы 21,84. Тиражы 2100 д. Заказ О-704.
Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru
Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.